# Казан утлары

7. 1991



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:
ТАТАРСТАН
ССРның
ЯЗУЧЫЛАР
БЕРЛЕГЕ,
ГАЗЕТА-
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ,
РЕДАКЦИЯНЕҢ
ХЕЗМӘТ
КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

7

1991

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Н. ФӘТТАХ. Кичү. *Роман* . . . 3
С. ГОРСКИЙ. Явыз Иванның хатыннары . . . 117

ШИГЪРИЯТ

К. СИБГАТ. Кемнәр дәшә безгә... *Шигырьләр* . . . 109
Л. ШАГЫЙРЬҖАН. Икенче микрофон. *(«Йөрәк авазы» поэмасыннан)* . . . 111
Р. МИҢНУЛЛИН. Авыл. Таң вакыты. *Шигырьләр* . . . 114

ГАЛИШЕР НӘВАИНЫҢ ТУУЫНА 550 ЕЛ

Ш. АБИЛОВ. Нәваиның шифалы йогынтысы . . . 143
Г. НӘВАИ. Бөекләрнең таң калулары. *(«Хәйрәтел-әбрар» дастаныннан)* . . . 149

ПУБЛИЦИСТИКА

Д. ВӘЛИЕВ. Ничегрәк яшәргә соң? *(Уйланулар)* . . . 153
А. МӨСЛИМОВ. Рәсми аләк . . . 159
М. ВӘЛИЕВ. «Идел» өчен көрәш . . . 165

СӘНГАТЬ

Г. АРСЛАНОВ. Халык улы . . . 178
Ш. МОНАСЫЙПОВ. Бер канаты җыр иле . . . 181

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Н. ХИСАМОВ. Яңача фикерләү һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсьәләләре . . . 183
Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әдәби фонд уставлары һәм Кабул итү коллегиясе турында положение . . . 186

Котлыйбыз! . . . 177
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . 192

*Баш мөхәррир*

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН**

*Редколлегия*

**ГАРИФ АХУНОВ**
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ФЛҮС ЛАТЫЙФИ**
*(җаваплы сәркәтип)*
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**МАРАТ МӨЛЕКОВ**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РАШАТ НИЗАМИЕВ**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**ГӘРӘЙ РӘХИМ**
**КОЯШ ТИМБИКОВА**
*(бүлек мөхәррире)*
**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ**
*(бүлек мөхәррире)*
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман Н. ФАТТАХА «Бриз», повесть С. ГОРСКОГО «Жены Ивана Грозного», стихи К. СИБГАТА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, Р. МИННУЛИНА.
К 550-летию Алишера Навои: статья Ш. АБИЛОВА «Благотворное влияние Навои», отрывки из дастана А. НАВОИ.
«Публицистика»: Д. ВАЛЕЕВ «Как нам обустроить жизнь», статья А. МУСЛИМОВА «Официальный донос»; статья М. ВАЛИЕВА «Борьба за «Идель».
«Искусство»: Г. АРСЛАНОВ «Сын народа»; статья Ш. МОНАСЫПОВА «На крыльях песни».
«К истории культуры»: Н. ХИСАМОВ «Новое мышление и принципиальные вопросы изучения литературы средневековья».
В номере отмечается 50-летие Г. Рахима.
Уставы Союза Писателей и Литфонда Татарской Республики, положения о приемной коллегии.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: искусство татарских ювелиров — амулетница богатой горожанки; известный поэт, лауреат международного диплома имени Г. Х. Андерсена, лауреат госпремии ТССР им. Г. Тукая Шаукат Галиев.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 13.05.1991 ел. Басарга кул куелды 21.07.1991 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 38449. Заказ И-216. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

## Нурихан Фәттах

# КИЧҮ

РОМАН

### Сүз башы

Бу әсәрне мин бик күптән — теге заманда, 1956 елда ук яза башлаган идем. Иң әүвәл уйланылганча, ул вакытта мин бөтен дөньяны таң калдырырга тиеш булган киң күләмле, тирән эчтәлекле роман-эпопея иҗат итәргә тиеш идем. Роман-эпопея кимендә дүрт кисәктән торырга һәм сугыштан соңгы еллардагы татар тормышын чагылдырырга тиеш иде. Мин тормышны әз генә дә бозмыйча, бизәмичә күрсәтергә, һәр нәрсәдә — аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда дөреслекне ярып салырга тиеш идем.

Роман баштарак «Таяныч» дип, соңга таба беркадәр китапчарак «Хыял вә хәят» дип аталды. Әлеге исемнәрдән үк күренеп торганча, өстебезгә бик авыр йөк алмакчы идек без. Ләкин, нихал итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты. «Хыял вә хәят»не 1963 елга кадәр яздым да, ары дәвам итәргә куәтем җитмичә, тукталып калдым. Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтаҗлык әсәремне тиешенчә очлап чыгарга ирек бирмәде дисәм, мондый сүзләр хәзер аклану булып аңлашылмас дип уйлыйм. Чөнки дөресе шулай.

Утыз елдан артык вакыт үткәч, мин элекке кульязмаларны яңадан карап чыктым һәм романның беренче кисәген укучыга тәкъдим итәргә ярый дигән фикергә килдем. Бүген инде мин аны, албәттә, элекке халендә калдыра алмадым — беркадәр үзгәрттем, тулыландырдым һәм зур әсәрнең бер кисәге итеп түгел, бәлки аерым роман итеп эшләргә тырыштым. Романның күләме дә, колачы да башта уйланылганга караганда шактый кысыла төште. Шуңа күрә аның исеме дә тарайды һәм конкретлашты. Берничә кисәктән торган «эпопея»ны хәзер яшьлеккә хас бер хыял итеп кенә искә төшерергә туры килә. Шулай да, «Хыял вә хәят»тән үсеп, бүленеп чыккан шушы кыйпылчыкта күпмедер дәрәҗәдә безнең яшьлек еллары чагылыш таба алган булса, анысы өчен дә мин үземне чиксез бәхетле санар идем.

*Август, 1990, Казан.*

---

Нурихан ФӘТТАХ (1928) — *әдип, галим, «Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада», «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, күп кенә повестьлар, хикәяләр, әдәби һәм гыйльми мәкаләләр авторы. Татарстанның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Редакция искәрмәсе: авторның теләге белән, әсәрдәге байтак кына диалект сүзләре үзгәртүсез бирелә.

Романны журнал өчен Т. Әйди редакцияләде.

## I



Битендә, маңгаенда рәхәт җылы тоеп, Габделхәй уянып китте. Каршыдагы зур тәрәзәдән бүлмәгә иртәнге кояш нуры төшкән. Бу әле җылынырга өлгермәгән, тузан белән, һәр төрле әчкелтем-төчкелтем исләр белән буталмаган саф нурлар. Кичә кичтән яртылаш ачып куелган тәрәзә ябылмый калган. Биек түшәмле класс бүлмәсенә, кояш нурлары белән бергә, иртәнге салкынча һава кереп тулган. Якында гына, урам белән мәктәп бинасы арасында гына үсеп утырган куакларда шатланып, дөнья бетереп чыпчыклар чыркылдаша. Тәрәзә башында, кояш чыгуына сөенеп, эретеп күгәрченнәр гөрли. Бөтен бүлмәдә, барлык исләрне күмеп, яңа чабылган болын исе, баллы чичкәләр исе, куе үлән исе аңкый.

Ел тәүлегенең шушы вакытында һәр көн кабатлана торган, һәр көн кабатланырга мөмкин булган гадәти бер иртә иде бу. Шул ук вакытта моннан соң инде беркайчан кабатланмаячак әүвәлге һәм ахыргы бер иртә иде.

Өченче көн директор Уфадан кайтып төште. Унынчылар да, укытучылар да аны инде күптән дүрт күз белән көтеп торалар иде. Унынчыларның тизрәк аттестатларын күрәселәре килде, укытучыларның исә уку елын тәмамлап, тизрәк ялга чыгасылары килде. Аннан соң, директор кайту белән, чыгарылыш кичәсе булырга тиеш иде. Иң кызыгы аның менә шул иде.

«Кичә»гә инде күптән әзерләнә башлаганнар иде. Директорның кайту хәбәре тиз арада таралып өлгерде һәм мәктәптә, мәктәп тирәсендә, мәктәпкә катнашы булганнар арасында шундук җанлану һәм ыгы-зыгы башланды.

Кайту белән директор тиешле кешеләрне чакыртып алды, чыгарылыш кичәсен иртәгә үк уздырырга боерды. Бу хакта тиешле кешеләргә хәбәр итәргә һәм, иң кирәклесе, кичәдән соң булачак күңел ачуга яисә мәҗлескә тиешенчә әзерләнергә кушылды.

Мәҗлес өчен кирәк булган барлык нәрсә чынлыкта тулысынча диярлек әзер иде, тик шулай да каяндыр нәрсәдер табасы, каяндыр нәрсәдер алып киләсе, нәрсәнедер пешереп бетерәсе, кыздырып бетерәсе бар иде. Аш-суга әзерләнү химия укытучысы Халидә апа белән унынчыларның класс җитәкчесе Фәрхәнә апага тапшырылган иде. Халидә апа, директор хатыны буларак, җитәкче сыман саналса да, Фәрхәнә апа олырак та, дәрәҗәлерәк тә иде. Аннан соң, чыгарылыш кичәләре уздыру, аш-су, мәҗлесләр уздыру белән аның инде күзе чыккан иде. Шунлыктан җитәкчелеккә быел Халидә апа әллә ни дәгъва да кылмады — телгә-тешкә килмичә, сүзсез генә Фәрхәнә апага юл бирде.

Директор белән, аннан да бигрәк, Халидә апа белән килешкәч, аңлашкач, Фәрхәнә апа кичәгенәк унынчыларга иртән иртүк килергә дип кешеләр җибәргән иде.

Бүген иртән мәктәпкә барырга чыккач, Җәмилә белән Сәкинә, кыек юлны туры итеп, Габделхәйләргә дә сугылдылар. Ләкин Габделхәй, ашыгыч эшем бар, бара торыгыз, мин сезне куып җитәрмен, дип, өеннән чыкмый калды. Кызлар аның нинди ашыгыч эше барын бик яхшы белделәр һәм, артык кыстап тормыйча, үз юллары белән китеп бардылар. Габделхәйнең исә шигырь язасы, дөресрәге, язылган шигырен яңабаштан карап, төзәтеп-шомартып чыгасы бар иде.

Чыгарылыш кичәсендә сөйләячәк шигырен ул инде моннан бер атна элек язып ташлаган иде. Шигырь аңа баштарак бик ошады, шундый ошады — басылачагына әз генә дә шикләнмичә, ул аны шул ук көнне «Коммунизм юлы»на илтеп тә бирде. Редактор Разия апа шигырьне укып чыкты һәм шунда ук үзенең фикерен дә әйтте: әйбәт булган — басарбыз, диде. Соңыннан шулай да өстәп куйды: азагы бераз килеп җитмәгән кебек, диде. Габделхәй редакторның "басарбыз" дигән сүзен генә ишетте бугай, соңгы сүзләренә бөтенләй игътибар да итмәде шикелле. Аның күңелен чиксез куаныч тойгысы биләп алды. Ике-өч көн буена ул әлеге куаныч тойгысы белән дәртләнеп йөрде.

Кичәгенәк ул газетада басылачак шигырен яңадан укып карады. Укыды һәм шигырь аны элеккечә үк сөендерә алмады. Аңа хәзер монда нидер ошамаган кебек булды. Кат-кат укый торгач, ул ошамаган нәрсәнең эзенә дә төште. Аеруча дәртле, тантаналы булып тәмамланырга тиешле соңгы юллар ничектер көчсез, сүлпән һәм буталчык булып чыккан иде. Аннан соң шигырьдә иптәш Сталин образы да тулысынча ачылып җитмәгән иде бугай. Дөресен әйткәндә, иң күңелсезе аның менә шул иде. Бит Сталин турында язарга кыюлыгың җиткән икән, ничек тә аны тиешле политик югарылыкта яңгырата да белергә кирәк! Менә бит ул хикмәт нәрсәдә.

— Рәхмәт сиңа, туган уку йортым, Бөек Сталин — бәхет кояшы! — дип укыды ул, әле кычкырып, әле тавышын әкренәйтеп һәм төрлечә үзгәртеп.

Үз тавышына үзе колак салып тыңлагандай итте дә, әлеге строфаның соңгы юлларын әйтеп карады:

— Рәхмәт сиңа, батыр туган халкым —

Улларыңның изге юлдашы.

«Монда нindидер логик хата киткән, — дип уйлады ул, ниһаять, билгеле бер фикергә килеп. — Ләкин нишләп Разия апа шуны күрмәде икән дә, нишләп җиңел генә басарга риза булды икән?» — дип уйлады ул аннары исе китеп, әйтерсең, аның хатасы өчен ул үзе түгел, бәлки редактор гаепле иде.

Соңгы дүрт юлны ул яңабаштан, өр-яңадан язарга тотынды. Ләкин күпме генә азапланмасын, күңеленә бер генә матур сүз дә, бер генә матур фикер дә килмәде. Үз-үзен көчләп шигырь язарга утырдымы, уйлары аның каядыр читкә тарала да китә. Шул чагында инде кызлар килеп: «Әйдә, Габделхәй, безнең белән!» — дип әйтәләр икән, шигырь дигән нәрсәгә аның карыйсы да килми башлый. Ләкин бүген ул кызлар янына чыгарга ашыкмады. Җәмилә белән Сәкинә икесе бергә булганда аның күңелендә һәрвакыт каршылыклы хис-тойгылар барлыкка килә. Кызларның берьюлы икесе белән дә түгел, бары берсе белән генә буласы килә иде кебек.

Шулай да бүгенге тантаналы көндә аның өйдә каласы килмәде. Кызлар китеп беркадәр вакыт үтү белән, ул алар артыннан юнәлде.

Габделхәй мәктәпкә килеп җиткәндә монда инде кызу эш бара иде. Малайлар шау-шу килеп утын кисәләр. Утын яралар. Кайберәүләр ишегалды уртасындагы түбәсе ябулы кое янында булаша — чыгыр әйләндереп, тимер чылбырны чылтыратып, су күтәрәләр. Кызлар су ташыйлар, утын ташыйлар.

Габделхәй үзләренең классына, үзенең партасына кереп утырды. Зур тәрәзәләре кояш чыгышына караган иркен бүлмәдә — каршы як стенадагы озын кара тактасы, озын кара тактадан берничә адым читтәрәк озын «демонстрация өстәле», ишек янындагы ап-ак миче, портретлары, пыяла капкачлы шкафлары, таблицалары — барысы, барысы да таныш һәм кадерле класс бүлмәсендә сәер бер тынлык хөкем сөрә иде. Бу бүлмәне һәрвакыт шау-гөр килеп торган хәлдә күргәнгә, мондагы тынлык, мондагы иркенлек һәм саф һава Габделхәйгә ничектер кызганыч булып тоелды. Каршыдагы кара такта да, пәке очы белән юнылып-сырланып беткән парталар да, пыяла шкафлар, шкаф эчендәге физика приборлары да — барысы да якын һәм кызганыч тоелды.

Менә бүген ул монда соңгы кат утыра. Моннан соң ул монда килерме-юкмы, билгесез. Килсә дә инде, күрәсең, монда башкалар утырыр, башкалар белем алырлар. Хуҗа булып, батыр булып алар шаулашыр. Никтер моңа ышанасы да килми, ләкин инде моңа ышанмыйча да булмый.

Шулай беравык моңаеп, онытылып утыргач ул чалбар кесәсеннән әвәләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарды. "Моңаерга, Антонина Семеновна әйтмешли, барышнялар сыман җебеп төшәргә ярамый", — дип уйлады ул. Язарга кирәк, үз-үзеңне мәҗбүр итеп булса да язарга кирәк. Николай Островский әнә бер дә җебеп төшмәгән, нинди кыен хәлдә дә көчле әсәр иҗат иткән. Сталинград сугышында совет солдатлары барышнялар кебек моңаеп, җебеп төшсәләр, бернинди җиңү дә булмас иде, Гитлер безне күптән инде кабып йоткан булыр иде. Шулай булгач...

Шигыренең соңгы строфасын ул тулысынча Сталинга — илебезне, халкыбызны коллыктан, үлемнән коткаручы Бөек Кешегә багышларга тиеш. Ул — Кеше генә дә түгел, ул — аллаларга тиң изге зат. Шигырендә Габделхәй Аның даһи образын тулырак, киңрәк ачарка тиеш. Дүрт юлда үзенең бәхетле яшьлеге өчен, унынчыны уңышлы тәмамлап чыгуы өчен, хәзер инде үз алдында бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр ачылуы өчен юлбашчыга кайнар рәхмәтләрен белдерергә тиеш. Ул моны һәркемнең исен китәрерлек итеп, оста һәм тапкыр итеп әйтеп бирергә тиеш.

Тиешен тиеш тә, тик менә аның күңеленә хәзер бер генә матур, оста һәм тапкыр фикер дә килмәде. Аның уйлары хәзер кайдадыр читтә, еракта чабышып йөрде. Бер дә кирәкмәгәнгә күз алдына усал, кыю Җәмилә килде, йомыкыйрак, уйчанрак Сәкинә килде. Күз алдында әлерәк кенә үзе илтеп туккан җирәнгеч сыекча җәелеп ятты, борынына шундагы ачы, тәмсез исләр килеп бәрелгәндәй булды.

Иҗади эш белән шөгыльләнгәндә иптәш Сталин, күңеленә тиешле фикерләр килмәсә, күн итекләрен шыгырт-шыгырт басып йөренергә тотына. Төннәрен ул йөри-йөри уйлый, йөри-йөри яза. Уң кулында аның һәрвакыт тәрепкә булыр. Ул көндез дә, төнлә дә яза ала. Менә ул нинди эшчән һәм корычтай нык ихтыярлы кеше! Шундый булырга иде аңа да... Габделхәйгә дә! Һо, ул чагында! Тәмәке тартуны зарарлы диган булалар, ләкин тәмәке ул башны яхшы эшләтә ди, имеш. Тәмәке зарарлы булса, иптәш Сталин туктаусыз тәрепкә тартмас иде. Ул бит аңа сөргендә чагында өйрәнгән. Ярар, тәмәкесен тартмасаң да була, шулай да өстеңдә аныкы кебек шәп китель, аягыңда аныкы кебек шәп күн итек булса, шигырь, бәлки, үзеннән-үзе язылыр иде.

Күңеленә аның шундыйрак уйлар килде. Бөек шәхескә охшарга тырышкан сыман, ул парта арасыннан чыгып кара такта янына килде, әрле-бирле йөренде дә, яңадан урынына килеп утырды. Юк, йөри-йөри дә ул бернинди яңа фикер уйлап таба алмады. Күңеленнән Сталин исеме белән янәшә куеп була торган мактау, данлау сүзләрен әйтеп карады, шул сүзләрдән төрлечә рифмалар ясады, ләкин аларның берсе дә канәгатьлек тойгысы тудыра алмады. Аерым әйткәндә ярыйсы гына булып тоелган сүзләр бөек исем белән бергә әйтелмәде, төссез, хәтта мәгънәсез булды да калды. Шуның өстәвенә, Габделхәй уйлап тапкан чагыштырулар чынлыкта кайчандыр, кайдадыр укылган, кайчандыр, кайдадыр ишетелгән һәм күптән инде гадәтигә әйләнеп беткән сүзләр иде.

Теләр-теләмәс кенә, көчәнеп кенә сайлана, чүпләнә торгач, ул шулай да баштагы «бәхет кояшы»на тукталырга булды. «Кояшы»га рифмалаша торган «юлдашы»ны калдырыргамы, юкмы икәнлеген белмичә аптырабрак утырганда, класс ишегенең шыгырдап ачылганы ишетелеп китте. Иплән кенә, кыюсыз гына атлап бүлмәгә Җәмилә килеп керде. Габделхәйгә кинәт аякланып, балкып ишектән кояш үзе килеп кергән кебек булды. Аның күңеле яктырып китте, йөрәге шатланып тибәргә тотынды, битенә рәхәт кайнарлык йөгерде. Шул ук вакытта башы беркайчан булмаганча тиз-тиз эшли башлады. Ләкин бу мәлдә «бөек образ» инде каядыр юкка чыккан иде. Үзенең кызарынуын,

шатлыгын күрсәтмәс өчен ул башын түбәнрәк иде һәм тынын кысып көтә башлады.

Йоклаган кешене уятмаска тырышкан сыман, һәр адымын чамалап, йомшак кына басып Җәмилә кара такта белән демонстрация өстәле янындагы аралыктан үтте дә, әйләнеп Габделхәй утырган арткы парта янына килде.

— Нишләп боегып утырасың болай? — диде юри сузып.

Шигырь язу Габделхәй өчен изге эш, яшерен эш исәпләнелә иде. Анынча, кыз белән егет үзара серләшкәндә чит кеше кысылмаска тиеш булган кебек, монда да кем дә булса карап торырга, кысылырга тиеш түгел иде. Җәмиләгә ул күтәрелеп тә карамады. Шулай да ул аны куалап та җибәрә алмады.

— Рәхмәт сиңа, туган йортым... уку йортым... матур йортым... даһи Сталин... — дип кабатлады ул күңеленнән, вәсвәсәгә бирелмәскә, игътибарын читкә юнәлтмәскә тырышып.

Җәмилә ак, матур кулын кара парта өстенә куеп беравык тын гына Габделхәйгә карап торгандай итте дә, уфтанып, хәтере калып:

— Абау! Бигрәк инде, күтәрелеп тә карамый кайберәүләр! — диде.

Габделхәй борынын тартты, ашык-пошык нидер сызгалап куйган булды. Ләкин барыбер эндәшмәде. Ике арада күңелсез тынлык сакланды.

— Гафу ит, — диде кыз күрәләтә үпкә белән. — Василий Михайловичны гына күрмәкче булганыем, — диде аннары ялганлап.

— Аның кабинеты монда түгел, — диде Габделхәй, телгә килеп.

Бу сүзләрне ул үзенчә усал итеп, төрттереп әйтте, ләкин Җәмиләгә бу әз генә дә тәэсир итмәде. Ул шундук елмаеп җибәрде һәм китәргә укталган җиреннән туктап калды да, үтенгән дә, таләп иткән дә сизелгән бер тавыш белән:

— Без хәзер болынга чичкәгә барабыз. Барасыңмы? — диде.

Габделхәй җавап бирергә ашыкмады. Ни өчендер ул үзен Җәмилә белән һәрвакыт уйлап сөйләшергә, сөйләшкәндә дә оста, кырыс һәм бераз гына тупас итеп сөйләшергә тиеш дип исәпли иде.

— Сиңа соң Василий Михайлович кирәкме, әллә минем болынга чичкәгә баруыммы? — диде ул озын һәм катлаулы итеп.

— Әй! — диде кинәт Җәмилә корт чаккандай. — Билләһи газим!.. Утырган була. Әллә кем булган!

Чын күңелдән үпкәләп, ул кырт кына борылды да, малайлар кебек партага сикереп менде һәм, парталар өстеннән зур-зур атлап, ишеккә ташланды. Күз кырыеның яртысы белән генә Габделхәй аның артыннан карап калды. Күзенең яртысы белән генә караса да, арттан ул аның сокландыргыч сылу гәүдәсен күреп калды. Көчле яктыга ялгыш туры караган чактагы кебек, кыз кешенең зифалыгыннан аның кинәт күзе чагылгандай булды, зиһене буталды. Шигырь исә үзеннән-үзе онытылды.

Ничә көн инде үзенең ниндидер көчле, тәэсирле сүзләр сайлап шигырь язарга азаплануы, җан тирләре белән көчәнүе һәм үзе беркайчан да күрмәгән, тоймаган ниндидер чит, ят нәрсәләрне мактарга, данларга тырышуы беренче мәртәбә аңа коточкыч дәрәҗәдә мәгънәсезлек булып тоелды. «Җәмилә турында, кызлар турында, болын һәм хуш исле чичкәләр турында язарга иде шигырьне!» — дип уйлады ул хыяллану сыман бер нәрсә кичереп. Җәмиләнең серле күзләре турында, серле итеп сөйләшүе, көлүе, гүзәллеге турында... Ләкин мондый шигырьләрне элек кенә язганнар. Идеясез, кыйбласыз буржуаз шагыйрьләр генә язган. Алар заманында яраган. Хәзер — юк. Андый коткыга бирелергә ярамый.

Шулай итеп, кабынып китә язган яшь күңелдәге шигъри ялкын үзеннән-үзе сүнде һәм озын, кара тактадагы кебек, күңел күгендә янадан авыр, бәйләнчек һәм мәгънәсез сүзләр калкып чыкты. Даһи Сталин — илебез кояшы... бөек Сталин — безнең юлбашчы... чишмә башы... Йөзек кашы... атаң башы...

## II

Җәмилә китеп күп тә үтмәде, урам яктагы ишекнең шыгырдап ачылганы ишетелде. Авыр ишек шапылдап ябылгач, тәрәзә, шкаф пыялалары сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп-калтыранып куйды. Бөтен игътибарын бергә туплап, тыштагы, читтәге һәр тавышка колак салып утырган Габделхәй ишектән килеп керүченең аяк тавышларын гына түгел, хәтта тын алуын да ишеткәндәй булды.

Класс бүлмәсенә мәктәп директоры Василий Михайлович килеп керде. Габделхәй ирексездән башын югары күтәрде, гәүдәсен турайтты, шулай да дәрестәге кебек аяк үрә басудан үз-үзен тыеп калды. Иң беренче булып күзгә шул ташланды — Василий Михайловичның озынча яңаклары, чәчсез ачык маңгае һәм муены — кием капламаган барлык ачык төшләре утта пешкән кебек кызарып чыккан иде. Бу исә аның озак вакыт тышта, кояшта булуы турында әйтеп тора иде. Аягына ул ялт итеп чистартылган озын кунычлы күнитек, өстенә — кара төстәге галифе чалбар һәм ак күлмәк кигән иде. Сыек, саргылт чәчле башы яланбаш иде.

Василий Михайловичның мондый кыяфәтен һич тә гадәттәгечә дип әйтеп булмый иде. Гадәттәгечә булганда, аның түбәсендә хәрби фуражка, өстендә исә барлык төймәләре каптырылган погонсыз китель булырга тиеш иде.

Директорның өе белән мәктәп арасында нибарысы ике йөз, өч йөз адым чамасы гына булса да, беркайчан ул монда өйдәгечә яланбаш яисә күлмәкчән килми иде. Укучылар да, укытучылар да, шулай ук аның белән очрашкан, аралашкан һәркем аны ярым хәрби формада күрергә күнеккән иде. Барлыгы аның галифе чалбар һәм кительдән торган өч костюмы бар. Костюмнарның берсе ак төстә — нәкъ теге киноларда күрсәтелә торган адмиралларныкы кебек. Икенче костюмы кара, өченчесе яшькелт төстә. Ак костюмын ул җәйге-язгы көннәрдә генә кия, карасын — кыш көне, инглиз поставыннан тегелгән яшькелтен, яңасын бары тик тантаналы бәйрәм көннәрендә генә кия иде.

Василий Михайловичның формалы кием яратуы һич тә аның элекке хәрби кеше булуына һәм шуңа күрә әле булса хәрби тормыштан аерылып җитә алмавына кайтып калмый иде. Алай гына да түгел, заманында аңа хәрби хезмәттә булырга да туры килмәде. Яшь чагында авыру сәбәпле, ул гомумән хәрби хезмәттә булмады. Сугыш елларында исә шул ук ниндидер авыруы аркасындамы, районлагы дус-ишләре аркасындамы, янә армиягә алынмады. Кеше рәтенә керердәй ирләр бармак белән генә санарлык калган куркыныч елларда ул Яңавылдагы кирпеч заводының баш инженеры булып исәпләнде. Кирпеч заводы тимер юлга карый иде, тимер юлда эшләү исә армиядә хезмәт итүгә тиңләштерелә иде. Хәрби киемгә ул шунда күнекте.

Ярым хәрби кием аны, беренчедән, сырма, тун, бишмәт-фәлән кигән теләсә кемнән аерып күрсәтсә, икенчедән, кара халык алдында элекке фронтовик кебек итәп күрсәтә иде. Аннан соң шунысын да әйтергә кирәк, кыршау сыман муенны кысып торган утырма яка, ялтыр төймәләре тезелеп киткән туры изү, калку күкрәк, тактадай иңбаш — кыскасы, шәп китель аны район җитәкчеләренә, хәтта һәр кабинетта, һәр почтмакта урысның иконасы урынына эленеп торган олуг дәрәҗә иясенең портретларына да охшата сыман иде. Тик менә аның портреттагы дәрәҗәле кешенеке төсле кое, калын мыегы гына булмады. Ул инде бер мәртәбә үстереп тә карады. Ләкин аның төссез мыегы кое, калын булып чыкмады — нечкә генә булып үсте дә, тычкан койрыгы сыман очлаеп, ике якка салынып төште. Шулай да ул бераз вакыт оялмыйча кеше арасында шул мыегы белән йөрде. «Учительская»да бөтен халык алдында, шаярткан булып, усал һәм зәһәрле итеп, Антонина Семеновна:

— Бу мыегыгыз белән сез татар-монгол игосы заманнарындагы кысык күзле варварларны хәтерләтәсез, — диде.

Шулай диде. Үзе ямьсез итеп көлеп куйды. Башка укытучылар тып-тын калдылар. Василий Михайлович башта агарынып китте, аннан соң әкрен генә кызарына башлады. Шулай да Антонина Семеновна Васильевага каршы сүз әйтергә йөрәге җитмәде — Антонина Семеновна рус теле һәм әдәбияты укытучысы иде.

Укытучы буларак мәктәп директорына буйсынырга тиеш булса да, башкалар арасында ул үзен бөек милләт вәкиле итеп, шунлыктан барлык татар укытучыларыннан өстенрәк, дәрәҗәлерәк итеп тотарга күнеккән иде. Аннан соң аның шулай кеше йөзен җырта торган гадәте дә бар иде. Моны ул «турысын әйтү», «дөреслек өчен көрәшү» дип атый иде.

Василий Михайлович, оятын-хурлыгын йотып, үз-үзен елмаерга мәҗбүр итте, стенадагы көзге каршысына килде дә, җентекләп үзенең мыеклы мескен йөзенә карап тора башлады. Көзгедән аңа, чыннан да, кысыграк күзле, яңаклы, авыз читләренең ике ягына да салынып төшкән нечкә мыеклы варвар — «татар-монгол» карап тора иде.

«Шулай икән. Бигрәк җирәнгечмен икән болай», — дип уйлады ул күңеле кырылып.

— Вы правы, Антонина Семеновна, — диде ул аркасы белән мичкә терәлеп, кулларын пальто җиңнәре эченә тыгып утырган Васильевага. — Бүген үк кырдырып ташлыйм.

— Юк, юк, кырдырмагыз, болай бик матур! — диде Фәрхәнә апа, директорның мыегын яклап.

Антонина Семеновнаның иң яратмаганы Фәрхәнә апа иде. Башкалар кебек Фәрхәнә апа Васильева алдында куркып яисә ялагайланып урысча сөйләшергә дә тырышмый иде, урысча сөйләшергә туры килгәндә исә сүзләрен коточкыч ватып-җимереп сөйли иде. Дөреслек, гаделлек яратучы Антонина Семеновна мондый чакта аны төрлечә өтеп ала, йә булмаса урыс теленә хөрмәт күрсәтмәүдә, милләтчелектә гаепләп, тәнкыйтьләргә тотына һәм шуның белән бөтән кешенең кәефен кыра иде.

— Кайберәүләрдә әле һаман монгол каны кайный, — диде Антонина Семеновна, Фәрхәнә апага карамыйча.

Василий Михайлович шул ук көнне мыегын кыркып ташлады һәм шуннан соң беркайчан калын, куе мыеклы иптәш булу турында хыялланырга да батырчылык итмәде.

## III

Яңавыл татар урта мәктәбе укучыларының күбесе кебек, Габделхәй дә үзләренең директорларын яратып җиткермәде. Ни өчен яратмаганлыгын ул, күрәсең, үзе дә тиешенчә аңлатып бирә алмас иде. Василий Михайловичны күрдеме, шундук анда ниндәндер курку, сагаю һәм үз-үзен якларга әзер булу тойгысы барлыкка килде. Менә әле дә, каршысында директорны күргәч, ул, ниндидер ярамаган эш өстендә тотылган кебек, куркуга якын бер тынычсызлык кичерде.

— Исәнмесез, Василий Михайлович! — диде ул беренче булып, ясалма бер күтәренкелек белән.

Василий Михайлович та елмайгандай итте, парта арасыннан чыгып үзенә таба атлаган укучысына беренче булып кул бирде.

— А-а, Мухутдинов! Исәнмесез, исәнмесез, — диде.

Мондый көтелмәгән хәлдән Габделхәй тәмам каушап калды, кабаланып ике куллап директорның сөякчел каты кулын тотып алды.

— Исәнмесез, Василий Михайлович! — диде тагын да, ялагайланып. — Күптән кайттыгызмы, Василий Михайлович? Без сезне көттек!

— Коткәнсездер, беләм, — диде директор.

Шулай диде дә, нидер әстәмәкче булды, ләкин вакытында тыелып калды. Габделхәй аның ниндидер кирәкле сүз әйтергә укталып та әйтми калуын бик яхшы аңлады. Ул хәтта директорның нәрсә әйтергә тиешлеген дә белде.

Бу, әлбәттә, «аттестат» булырга тиеш иде. Имтиханнарның барысын да Габделхәй «бишле»гә бирде. Уфага да документлар гел «бишле» белән китте. Василий Михайлович Габделхәйгә аттестат кына түгел, алтын медаль дә алып кайтырга тиеш иде. Бу хакта әллә ни шауламадылар, ләкин унынчылар да, укытучылар да, Габделхәй кебек үк, директорның алтын медаль белән кайтуын көттеләр. Яңавыл татар урта мәктәбеннән әле беркемнең дә алтын медаль алганы юк иде. Дөрес, моңарчы аның алтын медальгә торырлык укучысы булмады. Быел менә андый укучы бар. Ул да булса — Габделхәй. Бар өмет Габделхәйдә. Алтын медаль ул Габделхәйнең үзе өчен генә түгел, бөтен мәктәп өчен, барлык укытучылар коллективы өчен үзе бер бәйрәм булыр иде. Мәктәпнең дәрәҗәсе бермә-бер артыр иде.

Әйе, Василий Михайлович кайткан, әнә ул каршыда гына, якында гына басып тора, ләкин аның йөзеннән дә, сүзләреннән дә нишләптер берниндиди куаныч тәэсире сизелми. Габделхәй моны бөтен күңеле белән тойды. Имтиханнарны тапшырып бетергәннән соң, Василий Михайлович документларны алып киткәннән соң төн йокыларын калдырган татлы хыяллар, бәхет, дан — барысы да кинәт юкка чыкты. Аның урынына күңелдә шыксыз, борчулы бушлык хасил булды.

Шулай итеп, директор әйтәсе сүзен әйтмәде, Габделхәйнең исә сорарга йөрәге җитмәде. Василий Михайлович партадагы дәфтәргә күз төшереп алды.

— Сез һаман шигырь язасыз икән,— диде ул.

— Язган булам шунда, Василий Михайлович,— диде Габделхәй бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән кебек.— Ошамый әле. Кичкә өлгертергә кирәк.

— М-да,— диде директор берни аңлатмый торган бер мөңгерәү белән.— Кирәк дисез инде?..

Аттестат, медаль турында сүз кузгату урынсыз булган кебек, хәзер менә шигырь турында да сүз куерту урынсыз икәнлеген сизеп, Габделхәй сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.

— Бер-ике атна эчендә сез бик үзгәргәнсез, Василий Михайлович. Юлда йөрү килешкән сезгә,— диде ул, кирәгеннән артык кыюланып, ярарга тырышып.

— М-да, Мухутдинов,— диде тагын да директор.— Шигырь шигырь инде ул. Но, однако, сезгә бүген шигырь белән генә ярамый. Выпускной вечерда бүген Сафин иптәш тә булачак.

— Шулаймыни?! — диде Габделхәй.— Без бит аңа делегация белән барганыек. Безне аның янына кертмәделәр. Әйттергән, киләлмим, вакытым юк, дигән.

— Делегация оештыруыгыз дөрес булмаган, Мухутдинов,— диде Василий Михайлович ярым шелтә белән.— Но, однако, Мунир Мухлисович киләчәк. Мин үзем сөйләштем аның белән. Үзем.

— Шәп булган, Василий Михайлович! — диде Габделхәй куанып.

— Шәбен шәп тә, ул анда сезнең шигырегезне тыңлар өчен килмәячәк,— диде Василий Михайлович.— Выступление әзерләргә кирәк. И непременно урычча. Политически выдержанный. Йөзгә кызыллык китерерлек булмасын.

Мунавир Мухлисович райкомның беренче секретаре иде. Аның чыгарылыш кичәсенә килергә ризалык бирүе бик зур яңалык, бик зур шатлык иде, әлбәттә. Чыннан да, ул килә-нитә калса, барлык унынчылар өчен, бөтен мәктәп өчен бу чиксез зур дәрәҗә һәм тантана булачак. Мунавир Мухлисовичның хатыны Галия апа элегрәк Яңавыл татар урта мәктәбендә башлангыч классларда укытучы булган. Аны монда әле дә беләләр. Ләкин ире беренче секретарь булгач та Галия апа балалар укытуын ташлаган һәм хәзер өйдә генә ята, беркайда эшләми бугай. Хатыны укытучы, үзе икенче секретарь чагында иптәш Сафин да мәктәпкә еш килгән. Беренче булгач менә килми башлаган. Бит алар, өстәгеләр, беркайчан астагылар, түбәндәгеләр белән буталмаска һәм һәрвакыт саф һәм дәрәҗәле килеш калырга тырышалар. Быел

әнә килмәкче була икән. Ник? Бәлки, Василий Михайлович алтын медаль алып кайткандыр да, медальне дә, аттестатны да беренче секретарь алдында бирергә җыеналар? Бик астыртын кеше инде ул Василий Михайлович. Хәзер әнә берни сиздермәгән булып кылана. Анысы ярый, ләкин нишләп «выступление»не урысча әзерләргә куша соң ул? Беренче секретарь татар, хатыны татар, кунаклар татар, укытучылардан Антонина Семеновна да, немец теле укытучысы гына урыслар.

— Ләкин ни бит, Василий Михайлович...— диде Габделхәй, нәрсәдер каршы әйтергә җыенып.

— Никаких «ни»!— диде Василий Михайлович, кырт кисеп.— Әйтелгән — эшләгез!

Ялтыратылган күнитекләре белән шыгырт-шыгырт басып, директор ишеккә таба атлады. Тагып куйган кебек, Габделхәй аның артыннан иярде.

— Язып бетергәч тә минем янга керегез,— диде Василий Михайлович коридорга чыккач, ләкин шундук фикерен үзгәртте дә: — Впрочем, хәзер үк керегез. Бер биш кенә минутка,— диде.

## IV

Үзара сөйләшкәндә директор «Василий Михайлович» булса да, чынлыкта ул урыс та, керәшен дә яки анда чуваш та, мари да түгел иде. Ул чеп-чи татар иде. Аның чын исеме Вәсби, атасыныкы — Муллахан иде, фамилиясе бик борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан иде. Шул борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан булган Муллахан карт кайдадыр Борай ягында гомере буена җир тырнап иген иккән, мал-туар асраган ярлы гына, кара гына бер кеше булган. Күрәсең, атасы шундый кара игенче булганга, улы Вәсби шундый ак кеше булырга тырышкандыр да инде. Исемен бозып, урысчалатып әйткәнгә ул әз генә дә үпкәләми дә, ачуланмый да. Киресенчә, болай әйтү аның дәрәҗәсен генә күтәреп җибәрә сыман иде. Үзенең чукындырылган яңа исеменә ул шул дәрәҗәдә күнегеп беткән иде, әгәр дә мәгәр берәр укучы «Василий Михайлович» димичә, «Вәсби абый» яки анда «Вәсби Муллаханович» дисә, директор абый, артык кызмыйча гына, шулай да җанга тия торган итеп, сеңдереп кыздырырга тотына торган иде. «Вәсби абый»ны укучылар түгел, укытучылар әйтсә, Василий Михайлович шулай ук һәр очракта төзәтергә, кисәтергә кирәк дип исәпли иде. Мондый чакта ул гадәттә: «Нинди Мулла, нинди Хан инде ул, Замила Галиахметовна?! Мин инде сезне предупреждать иттем... эндәшмәгез миңа шул... извините за выражение... авыл хатыннары кебек»,— дия торган иде.

Мәктәп директоры вазифасыннан тыш, Василий Михайлович югары классларда физика, математика фәннәре укыта иде. Укытучы буларак ул әллә ни мактарлык түгел, ләкин директор буларак бөтен районда, хәтта бөтен республикада иң булдыклылардан санала иде. Аның бөтен булдыклылыгы исә үзенә буйсынган һәркемне кулында кысып тотуга, югарыдан килгән күрсәтмәләрне бернинди каршылыксыз үтәүгә кайтып кала иде. Иң мөһиме, ул район җитәкчеләренең берсе белән дә телгә-тешкә килмәскә тырыша иде.

Район җитәкчеләре белән килешеп яшәсә дә, мәктәптә, үз коллективында аны бөтенләй диярлек хөрмәт итмәделәр. Берәүләр аны ачыктан-ачык дошман күрделәр, икенче берәүләр дошманлыкларын сиздермәскә тырыштылар. Мондый мөнәсәбәтнең сәбәбе, барыннан да элек, Василий Михайловичның үтә коры һәм формалист кеше булуына кайтып кала иде бугай. Үзе физика-математика укытучысы, хатыны — химия укытучысы булганга күрә, ахрысы, аның өчен дөньяда бары физика-математика да, химия генә игътибарга лаек фәннәр исәпләнелә ала иде. Аннары, әлбәттә, урыс теле.

Бу, билгеле, Василий Михайловичның шәхси карашы гына да түгел, бу бөтен илдә хөкем сөргән гомуми сәясәт басымы нәтиҗәсендә барлыкка

килгән мәҗбүрият иде. Менә шушы гомуми политика карашларын башкаларга көчләп тагарга тиеш булганга, Василий Михайловичның иң ачуын китергәне, эчен пошырып, үртәп торганы татар теле белән татар әдәбияты иде. Тумыштан татар булганга ул, билгеле, үзенең татарлыгын да онытa алмый, хәтта аны онытырга да теләми, шул ук вакытта, коммунист һәм җитәкче буларак, татарлыкны ул онытырга, аңа каршы килергә, аны дошман күрергә тиеш сыман иде.

Габделхәйнең шигырь белән пычранып утыруын күргәч, аның күңелендә үзеннән-үзе яшьлек хәтирәләре калкып чыкты. Бит кайчандыр ул да яшь булды, киләчәктә нәрсәдер кырмакчы булып, очынып-тилереп йөрде! Ул чакта әле хатын да, балалар да юк, җилкәңә таудай булып өелгән җаваплылык тойгысы да юк. Бары дәртле яшьлек бар да, тау-тау бәхетләр вәгъдә иткән матур киләчәк кенә бар. Хәзер инде яшьлек тә, дуслар-иптәшләр дә, хәтта киләчәк тә юк. Киләчәк ул беркайчан булмады бугай. «Киләчәк» дигән вакыт инде күптән килде, бары тик ерактан шундый матур булып күренгән бәхет тә, байлык та, дан-шөһрәт тә кайдадыр качып-посып калды.

Да, бар иде заманалар! Иң гаҗәбе шул, Вәсби Алдынский да, ягъни яшь чактагы Василий Михайлович та, Мухутдинов кебек, шигырь белән җенләнә иде. Да, да, рабфакта укыганда ул чын-чынлап шагыйрь булам дип тилереп йөрде. Бер дә начар да язмады. Рифмалары матур, килешле чыга торган иде. Ул вакытта күпләргә шигырь җене кагылган иде. Әле анда, әле монда шаулатып әдәби кичәләр үткәрәләр, бәхәсләшәләр... талашалар. Эх!..

Берзаман ул иптәшләре арасында талантлы шагыйрь саналып йөрде. Да, талантлы. Заманалар үзгәреп китмәсә, Вәсби Алдынскийдан менә дигән шагыйрь чыгар иде мужыт. Сәхип әл-Назаридан, хәтта Такташтан, Кутуйдан да талантлырак шагыйрь чыгар иде. Но, однако, менә чыкмады. Бөтен эшне замана бозды. Бозылды замана. Юк, Вәсби Алдынскийдан шагыйрь дә, беркем дә чыкмады. Шагыйрь булу, бөек кеше булу турындагы хыял «тормыш кысызына» бәрелеп челпәрәмә килде. Дәрт сүнде, күңел суынды, күңелдә бары ачу, үртәлү дә курку гына торып калды.

Рабфакта укыганда аның шигырьләре сирәк кенә булса да гәзитләрдә, журналларда басылды. Бер елны ул тырышып-тырмашып йөри торгач, аерым җыентык чыгару бәхетенә иреште. Шигырь җыентыгы. Китап. Вәсби Алдынскийның түбәсе күккә тиде. Китапны үз күзләре белән күреп, үз кулында тотып карагач, ул бернечә көн кая басканын белми йөрде. Унысы бер белен калынлыгындагы китапларын кибеттән күпләп сатып алды да, барлык таныш кызларына, дус-ишләренә бүләк итеп йөрде.

Шулай куанычтан исереп, кая басканын белми йөргән көннәрнең берсендә «Кояшлы иртә» исемле җыентыкка рецензия басылып чыкты. «Өч тиенлек шигырьләр» дип аталган рецензия азагына «Гадел Тәрәшле» дигән имза куелган иде. Да, Гадел, Тәрәшле. Көнчел, ялагай, икейөзле дуңгыз. Дуңгызның да дуңгызы. Кешедә бары начар якларны гына күрә торган, тирестә тибенә торган тавык кебек, шуннан үзенә тәм таба торган бер бәндә.

Әлеге рецензиядән соң Вәсби Алдынский шактый вакыт исенә-акылына килә алмады. Исенә-акылына килгән иде, шигырь язуга да, әдәбиятка да кинәт кенә күңеле сүрелде куйды. Гадел Тәрәшленең кайбер сүзләре аңа хәзер дөрес сыман тоелды. Аның бары үз-үзен таныйсы гына килмәде. Әкренләп ул шигырь язудан гына түгел, әдәбияттан һәм шигырьче иптәшләреннән дә читләшә башлады. Шулай итеп, әдәбият арбасына тагылып китә язган Вәсби Алдынский таулы-ташлы юлда очраган беренче дыңгырдыкта ук, тәгәрмәчтән чәчрәп калган каты ләпек кебек, читкә чәчрәп төшеп калды. И шуның белән котылып та калды. Утыз җиденче, утыз сигезенче елларда аның шигырьче иптәшләре, дус-ишләре, таныш-белешләре бер-бер артлы кулга алынганда ул инде әдәбият дөньясыннан бик еракта иде. Гадәл Тәрәшледән дә усалрак, кансызрак тәнкыйтьчеләр аның «өч тиенлек» шигырьләр китабына нишләптер игътибар итмәделәр. Шомлы, дәһшәтле елларда Яңавыл кирпеч заводында кара эшче булып эшләгән Вәсби Суяргулов барысын да белеп-ишетеп торды.

Кирпеч заводына ул тикмәгә генә кермәде. Нәрсә буласын алдан сизенгән сыман, укытучылыгын ташлап, монда ул үз теләге белән керде. Барлык тимер юлчылар кебек, кирпеч заводы эшчеләре начар яшәмиләр иде. Тимер юлчыларның исә ашау-эчү дә яхшы, кием-салымга да мохтаҗлык юк. Тимер юлчыга һәр төрле талон бирелә. Аларның магазиннары аерым, мәктәпләре, клублары аерым, хәтта икмәк заводы да, электр станциясе дә — барысы да аерым, барысы да аларныкы. Тирә-яктагы авыл халкы, Яңавылның ярлы-ябагае черек бәрәңге ашап шешенгәндә тимер ялчылар пох! итеп яшәделәр. Вәсби Суяргулов та бернинди мохтаҗлык күрмәде. Дөрес, монда ул үзен һәрвакыт качкын итеп, яшеренеп ятучы итеп тойды. Кемдер аның элекке эшләрен белеп алыр да тиешле җиргә барып әйтер һәм көтмәгәндә тиешле җиргә алып та китәрләр сыман тоелды. Кайчан алып китәрләр — төнләме, таң алдыннанмы, әллә көпә-көндез эш вакытындамы, аның өчен бөтен мәсьәлә шуңа кайтып калды.

Шул рәвешчә куркыныч утыз җиденче, утыз сигезенче еллар да узып китте. Кулга алулар турында бик үк ишетелми башлады. Сугыш башланыр алдыннан Вәсби Алдынский тәмам тынычланып калды. Аллага шөкер, исән калды, ахрысы. Сугыш башлангач исә бөтенләй икенче борчулар китте. Да, уйласаң чәчләр үрә торырлык. Күрде мескен башлар!

## V

Коридордан шыгырт-шыгырт атлап барганда Василий Михайлович, әйтерсең, берни күрмәде. Кабинет ишеге алдында туктап, гадәтләнгән бер хәрәкәт белән кесәсеннән ачкыч чыгарды да, ашыкмыйча гына йозакны ачты һәм үз артыннан ишекне ябып кабинетына керде. Директорның шулай берни әйтмичә кабинетына кереп китүе, җитмәсә ишекне шапылдатып ябып куюы Габделхәйгә гаҗәбрәк тоелды. «Үзе чакырды, үзе артына борылып та карамады», — дип уйлады ул хәтере калып. Нишләргә белми көтеп торгандай иткәч, ул кыюсыз гына ишек шакыды.

— Да! — диде эчтән Василий Михайлович, «керегез» дигәнне аңлатып.

Габделхәй керде, түргәрәк узды, бернинди ялмасы булмаган озын шәрә өстәлнең бер кырыенда тукталып калды. Василий Михайлович өстәл тартмасын ачып, бик игътибар белән аннан нидер эзләргә тотынды. Ниһаять, ул кирәкле әйберсен тапты, өстәл тартмасын кире ябып куйды, бикләде дә, башын калкытты һәм ике куллап иягенә таянды.

— Беләсезме, ник чакырдым мин сезне?.. — диде ул бераз көттереп. — Шигырегезне күргәч исемә төште... бер серьезно сөйләшергә кирәк сезнең белән. Сез безнең иң алдынгы, талантлы укучыбыз, Мухутдинов...

Габделхәй үзенең алдынгы, талантлы укучы икәнлеген белә иде, ләкин аның бу турыда беркемгә кычкырып әйткәне дә, сиздергәне дә юк иде шикелле. Ул моны сер сыман итеп бары күңелендә генә саклый иде. Үзе сер итеп тоткан яшерен нәрсәне чит кеше авызыннан — мактауга саран директор авызыннан ишеткәч, аның өчен бу көтелмәгән яңалык булып тоелды. Шатлыктан йөрәге җилкенеп куйды. Шулай да, көтелмәгән шатлык тойгысы ташып чыкмасын өчен, ул тыелыбрак торырга кирәк тапты. Чынында ул Василий Михайловичның моннан да зуррак, куанычлырак хәбәр әйтүен көтте. Директорның өстел тартмасында нидер эзләве дә аңа тикмәгә генә түгелдер шикелле тоелды. «Медаль турында әйтмәкче була», — дип уйлады ул шундук үз алдына. Ләкин нишләп шул кадәр көттерә, ялындыра соң ул? Медальнең алтыны булмады, көмеш кенә булды, дип әйтмәкче була микәнни соң?

Василий Михайлович тагын күпмедер көттереп торгандай итте дә әкрен генә сүзгә башлады.

— Ладно, унны бетердегез, аттестат алдыгыз — дальше кая китәргә, нишләргә исәп? — диде ул, дәрес сорагандагы кебек.

— Ныклап уйлаган юк әле, Василий Михайлович, — диде Габделхәй теләр-теләмәс кенә.

Ул ялганлады һәм шул ук вакытта ялганламады да. Ул үзен шагыйрь булырга, нindидер бөек кеше булырга тиеш дип исәпләде. Моңа инде ул күптән күнеккән иде, шуңа күрә бу яшерен хыялының кайчан да булса тормышка ашачагына әз генә шикләнми иде. Ләкин, никадәр гаҗәп булмасын, шушы көнгә кадәр әле ул киләчәктә нишләргә тиешлеге турында да, ничек итеп хыялын тормышка ашырачагы турында да белми иде. Бу турыда кем белән булса да фикер алышырга аның кыюлыгы җитмәде. Укытучылар исә үзләре белеп аннан берни сорашмадылар. Алар, гомумән, аның киләчәге белән дә, хыяллары-ниләре белән дә кызыксынмадылар. Алар бары үз өсләренә төшкән бурычларын гына үтәделәр: дәрес укыдылар, дәрес сорадылар, билге куйдылар, кайчагында саран гына мактау сүзләре әйттеләр, кайчагында шелтә белдерделәр. Әгәр дә мәгәр Мухутдинов Габделхәй мәктәптә «иң алдынгы, талантлы» укучы булмаса, Василий Михайлович, бәлки, аны үз кабинетына чакырып та тормаган булыр иде һәм «алдынгы, талантлы» булмаган бик күп укучыларны моңарчы кулларына шыгырдавык кәгазь тоттырып, дүрт ягың кыйбла дигәндәй озатып калган кебек, аны да шулай озатып калу ягын карар иде.

— Шагыйрь булыргамы исәп, Мухутдинов? — диде директор көлемсерәгәндәй итеп.

— Шулай инде, Василий Михайлович, — диде Габделхәй кызарынып. — Сез бит беләсез... әдәбиятне яратам... шигырь язам.

— М-да. Однако сез физиканы да яратасыз! — диде Василий Михайлович.

— Әдәбиятны ныграк яратам, — диде үзсүзле Габделхәй.

— Нәрсә ратканлыгыгызны сез әле үзегез дә рәтләп белмисез, Мухутдинов, — диде директор шактый коры итеп.

Габделхәйгә бу бик сәер тоелды. Үзенең нәрсә ратканын үзе дә белмәскә, шул кадәр аңгыра микәнни соң ул? «Алдынгы, талантлы» укучы шулай аңгыра булырга тиеш микәнни?! Шулай да ул эндәшми калды. Василий Михайлович белән бәхәсләшү, нәрсәгә булса да аны ышандырырга тырышу, гомумән, читен нәрсә иде.

— Сез әле яшь — күп нәрсәне аңлап та җитмисез, — диде директор, кырыслыгын йомшарта төшеп. — Яшь чакта раткан нәрсәң соңыннан онытыла. Но кайчакта шулай да була: акыл кергәч карашлар, теләкләр үзгәрә, бөтен нәрсәнең асты өскә килә. Киләчәктә шулай булмасын өчен сезнең яшьтә олылар сүзенә колак салу мишәйт итми. Сезгә караганда мин күбрәк яшәгән, күбрәкне күргән. Тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек, аллага шөкер. Бишектәге бала бишкә төрләнә, диләр картлар. Була бит шулай? Була!

— Буладыр, — диде Габделхәй.

— Секрет итеп мин сезгә шуны әйтим, — диде Василий Михайлович, бөтенләй үз кеше булып, — һәрбер талантлы кеше яшь чагында шигырь яза. Шигырь язу гына шагыйрь булу дигән сүз түгел. Беләсезме, сезнең кебек чакта мин дә шигырь яздым.

— Сез дә?! — диде Габделхәй исе китеп.

Василий Михайлович эндәшмичәрәк утырды.

— Да, Мухутдинов, мин дә, — диде аннары дәртсез, шыгырдавык бер тавыш белән. — Как это не удивительно, яздым. Сезне мактаган кебек, мине дә мактадылар, шигырьләремне газеталарда, журналларда бастылар. Даже бер китап та чыгардым. Но мин вакытында акылга утыра белдем. Шигырьгә дә, әдәбияткә дә кул селтәдем. Хәзер менә шуның өчен сөенеп бетә алмыйм.

— Шуның өчен... сөенеп? Ник? — диде Габделхәй аптырап.

— Никме? — диде бераздан Василий Михайлович. — Если ул вакытта мин профессиональ шагыйрь булып киткән булсам... — «Мине сөргенгә сөрерләр иде» димәкче булды ул, ләкин укучысы алдында болай дип әйтергә ярамаганлыгын тиз арада шәйләп алды һәм сүзен башкачарак юнәлештә дәвам итте: — ...ул чагында, беләсезме... ну, ул чагында миннән Тукай да, Такташ да чыкмаган булыр иде. Беләсезме, обществога файдалы-

рак кешеләр кирәк. Шагыйрьләрнең хәле икеле-микеле аларның. Гомергә шагыйрь булып яшәп тә булмый. Мин менә физика-математика факультетын бетердем. Физиклар, математиклар, химиклар һәркайда һәркайчан кирәк. Везде и всегда. Общество шуны сорый. Хәзер шигырь, әдәбият заманы түгел. Пушкиннар, Тукайлар заманы күптән узды. Техника заманы хәзер. Атом заманы. Век атома! Кая карама — машина, кая карама — техника. Техника шигырьне, әдәбиятны, йомшак күңелле кешеләрне кысырыклап чыгара. Сез инде бала түгел, сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә була. Беләсезме, ни өчен Пушкиннар, Тукайлар юк? Икенче Пушкиннар, икенче Тукайлар... менә шуның өчен. И алар булмаячак та! Кайчандыр Англиядә сарыклар кешеләрне «ашап» бетергән кебек... ул турыда беләсез ич... вот... хәзер дә техника шигырьне, шагыйрьне... әдәбиятне, культураны, даже бөтен халыкларны, нацияләрне ашап бара. Менә шундый заманда шагыйрь булу турында хыяллану, извините за выражение, глупость булыр иде.

Василий Михайлович гадәттә булмаганча бик нык җанланып, хәтта кызып-кызып сөйләде. Күрәсең, бу аның күптән уйлап йөри торган, күптән инде чын күңелдән инанган үз фикерләре иде. Менә ул тынып калды һәм, үз сүзләренең ничегрәк тәэсир ясавын белергә теләгән кебек, укучысына күз төшереп алды. Ул аның берәр каршы сүз әйтүен көтте, әгәр дә мәгәр Габделхәй каршы сүз әйтсә, үзенең шундук яңа көч белән кызып китәчәген, ахмак җегет алдында дөрес һәм логичный фикерләрен кискенрәк, тирәнрәк итеп аңлатырга мәҗбүр булачагын уйлап алды.

Ахмак җегет эндәшмәде. Аның карашынча, әдәбият турында, шигырь язу-язмау турында бары әдәбият укытучысы Фәрхәнә апа белән генә, анны «Коммунизм юлы» редакторы Разия апа белән генә сөйләшергә була иде. Бу мәсьәләдә бөтен Яңавылда алардан да ышанычлырак кеше дә юк. Шуңа күрә директорның шундый ачы, зәһәрле сүзләре анда бары шикләнү, сагаю һәм ачу гына тудырды. Василий Михайловичның, беркайчан икенче Пушкиннар, Тукайлар булмаячак, дигән сүзләренә каршы аның үч итеп, ачу итеп: «Менә мин булачакмын!» — дип кычкырасы килде. Ләкин ул кычкырмады. Бу кабинетта, мондый сөйләшү вакытында ул үзен ничек тотарга кирәклеген чамалый алды һәм физика-математика укытучысы әдәбият турында, шагыйрьлек турында нинди генә кимсеткеч сүзләр әйтсә дә, бернинди коткыга бирелмәскә дип күңеленә беркетеп куйды.

— Сезгә берәр технический вузга китәргә кирәк, Мухутдинов, — диде Василий Михайлович яңадан сүзгә башлап. — Сез математикадан, физикадан начар укымадыгыз. Тагын бераз тырышсагыз, шигырьләрегезне онытып торсагыз...

— Шигырь язуны мин ташламаячакмын, Василий Михайлович, — диде Габделхәй әкрен генә, ләкин нык итеп, үз-үзенә ышанып.

Беркайчан көлми торган Василий Михайлович, башын чайкап үз-үзеннән канәгать булып, көлеп куйды.

— Да, сез шунысын да учтите, — диде ул яшь җегетнең кирелегенә әз генә дә игътибар итмәгән сыман. — Сез бит татарча язасыз. Онытмагыз, татар теленең хәзер бернинди значениесе юк. Татар теле авыл капкасын чыкканчы гына кирәк, ди торганые минем әтәй. И дөрес әйткән. Бу бит әле теге заманда. Элек. Татар теле хәзер авыл капкасын чыкканчы да кирәкми. Ул бары авыл хатыннары, картлар теле генә. Ун-унбиш җылдан алар да үлеп бетәчәк. Илле җылдан бер татар калмаячак. Понимаете шуны?

## VI

Яңавыл татар мәктәбе директорының татар теленә, татар әдәбиятына кагылышлы фикерләрен Габделхәй болай да белә иде. Элегрәк тә бу хакта аңа Василий Михайлович белән әйткәләшеп алырга туры килгәне бар иде. Ләкин директорның әле беркайчан да үз укучысы алдында үз карашларын

шундый ачык итеп, шундый куркыныч һәм оятсыз итеп әйтеп биргәне дә, татар теленә карата ачыктан-ачык шундый кимсеткеч сүзләр сөйләгәне дә юк иде бугай.

Директор кешенең, шундый чиста, пөхтә итеп киенгән кешенең бу рәвешчә сөйләнүе Габделхәйгә чиктән тыш ят һәм кыргый булып тоелды. Бөтен тәне, бөтен әгъзалары белән бөрешеп, ул бер йодрыкка укмашып калды.

— Татар беткәч... кем генә калыр соң дөньяда? — диде еш-еш тын алып.

— Анысын тарих күрсәтер. История покажет, — диде Василий Михайлович. — Киләчәктә бөтен дөньяда бер генә тел булачак. Так вот, иптәш Сталин әйтә: ул тел немец теле дә булмас, француз, инглиз теле дә булмас, ди. По всей вероятности, ул урыс теле булыр. И без шуңа барабыз да. Киләчәктә бары урыс теле генә булачак, Башта Советлар Союзында, аннары — бөтен дөньяда. Бу безнең интернациональ бурыч. Без, татарлар, үз телебездән никадәр тизрәк баш тартсак, шулкадәр яхшырак булыр. Тизрәк без мировой культурага ирешәчәкбез.

— Мин моны аңлый алмыйм, — диде Габделхәй.

— Согласен, аңлавы читенрәк, — диде Василий Михайлович. — Но, однако, тормыш шуны күрсәтә. Киләчәктә аңларсыз әле. Хәзергә сез — шагыйрь, татар шагыйре! Если сез турыдан-туры урыйча язсагыз, тогда дело другое.

Директорның авыз тутырып «шагыйрь», «татар шагыйре» дип әйтүе Габделхәйнең күкрәгенә килеп тыгылган авыр ташны ычкындырып җибәрде. Аңа хәзер тын алуы җиңелрәк була башлады.

— Мин бит татарча укыдым, татарча язарга өйрәндем! — диде ул Василий Михайлович белән хәтта бәхәсләшергә әзер булып.

— Вот-вот! Безнең бөтен бәлә дә шунда, — диде директор. — Сезнең кебек талантлы кешеләрне татар мәктәбе харап итә дә инде. Сезне генә түгел. Элек мәдрәсә харап иткән кебек, вапшем безне татар мәктәбе харап итә. Без сезне укытабыз, тырышабыз, государство күпме акча түгә, однако результат нинди? Соңгы өч-дүрт ел эчендә безнең Яңавыл татар мәктәбен бетереп чыккан йөзләп укучының күпмесе вузга керә алган дисез? Күп булса, унлап кеше. Алары да разный пединститут, сельхоз, ветеринария... тоес, мал врачлары, картлар әйтмешли, бет бырачлары. Вот вам простая арифметика! Ә технический вузларга, физика-математика факультетларына — ни одного! Оят бу безнең өчен. Киләчәктә болай булмаячак. Безнең өчен иң дөрес юл — әкренләп татар мәктәпләрен урыйчага күчерә бару. Беренче класстан башлап унга кадәр. Шәһәрләрдә генә түгел, барлык авылларда. Бары шул чагында гына без Москва, Ленинград вузларына керә алырлык укучылар әзерли алырбыз. Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә була. Национальный мәктәп мәсьәләсендә безнең политика шундый. Чуашларда, мари, удмуртларда күптән чын мәгънәсендә үз телләрендә урта мәктәпләр дә юк. Начальный классларда гына, кайберсендә җидегә кадәр генә үз телләрен предмет буларак укыталар. Төньяктагы чукчаларда үз телләрендә башлангыч класслар да юк. Сплошь урыйча.

— Алайса Москва, Ленинград вузларында чукчалар гына укыйдыр хәзер? — диде Габделхәй усал итеп.

Василий Михайлович ишетмәмешкә салынды һәм бер башлаган сүзен очлыйсы килеп:

— Татариядән, Башкириядән читт өлкәләрдәге татар авылларында да күп мәктәпләр урыйчага күчте, — диде. — Аларның кайберләрен утыз җиденче, утыз сигезенче елларда ук яптылар... — Үзенең кирәкмәгәнне сөйли башлавын аңлап, ул беразга тоткарланып калды, тынып торды да: — Так вот, — диде, — башка җирләрдә татар мәктәпләре дә бетә. Без кемнән ким? Нигә безгә артка калырга? Без үзбәк тә түгел, әрмән, грузин да түгел. Без — татарлар! Без беркайчан сыната торган халык түгел!

Үзенең чамадан тыш кызып китүен күреп, Василий Михайлович кинәт тынып калды. Галифе кесәсеннән зур кульяулык чыгарып тирләгән маңгаен сөртте, аннары кульяулыгын авызы янына китерде дә

«кых!» итеп җиңелчә генә төкереп куйды һәм беләгендәге сәгатенә карап алды.

— Ладно, шуның белән бетереп торыйк, — диде. — Шулай да уйлап карарга кирәк, Мухутдинов.

— Уйлармын. Шулай да... — диде Габделхәй.

Әйтәсе сүзен ул әйтеп бетермәде — беренче булып урыныннан кузгалды. Бүтән вакыт булса, Василий Михайлович аны кире урынына утыртыр һәм өстәл пыяласын шакылдатып: «Чтоб это был последний раз! Идите!» — дип куалап чыгарыр иде. Ләкин хәзер ул алай итә алмады. Ул хәттә кире беткән укучысының тупаслыгын да йотарга мәҗбүр булды һәм чыгарга рөхсәт итеп:

— Барыгыз, выступлениегезне языгыз, — диде аталарча.

## VII

Габделхәй кызарынып-бүртенеп ишектән килеп чыкты һәм күзенә ак-кара күренмәгән килеш, коридордан китеп барды. Коридорда аңа Антонина Семеновна очрады. Рус теле укытучысы, гадәтенчә, өстенә ак кофта, кара юбка кигән, кыска, сыек саргылт чәчләрен күпертеп, тырпайтып куйган иде. Габделхәй аны ничектер күзгә-күз килеп бәрелешә язгач кына күреп алды, ясалма елмаеп, кычкырып исәнләште дә, читкә тайпылды.

— Василий Михайлович кыздырган, ахрысы, сезне, Мухутдинов, — диде Антонина Семеновна дусларча, ярым шаяртып.

— Кыздырды... Юк, кыздырмады. Болай гына, — диде Габделхәй, буталып.

— Василий Михайлович андамы? — диде Антонина Семеновна, сүз өчен сүз булсын дигәндәй.

— Анда, — диде Габделхәй, ерагая барып.

Ул озын коридорның аргы башына кадәр барды, сул яктагы соңгы ишекне ачты да, яңадан үзләренең бүлмәсенә — «физика кабинеты»на барып керде. Яңадан үзенең тәрәзә янындагы, иң арттагы таныш партасына барып утырды һәм яңадан шигыренә тотынмакчы булды. Ләкин аның хәле хәзер шигырь язуга җайланырлык түгел иде. Хәзер аның бер нәрсәгә дә күңеле бармады. Хәзер аның кәефе бозылган, күңеле кырылган, барлык хыяллары, өмет-теләкләре челпәрәмә килгән иде.

Аякларын сузып, аркасы белән партаның арткы тактасына бик нык терәлеп ул шактый озак утырды. «Медаль турында сорарга оныткан-мын!» — диде ул бераздан, уйлана башлагандай итеп. Шунда да сорамагач, кайчан сорыйсың тагын? Кичкә кадәр көтәргә туры килә. Яисә Антонина Семеновнадан сорыйсы калган. Ул беләдер, сер итеп кенә әйтер иде әле. Юк, кирәкми. Әгәр синең мәктәбең, телең бетә икән, әгәр сиңа татарча шигырь язу ярамый икән, нәрсәгә кирәк ул медальләр-фәләннәр? Медальсез дә ул барыбер Казанга китәчәк, барыбер шагыйрь булачак. Монысы инде хәл ителгән... ташка уеп язылган.

Ләкин хәзер менә күңеле кырылган бер вакытта ул шигырь язу-язмау мәсьәләсендә билгеле бер карарга килде. «Язмыйм. Шигырен дә, выступлениесен дә, — дип уйлады ул тыелгысыз бер кирелек белән. — Барлык телләрне бер телгә калдырырга тырышучыларга... телеңә, җаныңа тел тидерүче агач директорга уч итеп язмыйм!»

Мондый фикергә килгәч, аңа ничектер җиңел булып китте. Шул ук вакытта эчтә, күңелдә бушлык хасил булды. Аның хәзер кайдыр барасы, нидер эшлисе килде. Класс бүлмәсендә, парта арасында утырып кына берни эшләп булмый иде. Ашыгып коридорга чыкты. Директор кабинеты яныннан үткәндә ничек тә ул якка карамаска һәм ничек тә ул турыдан тизрәк узып китәргә тырышты.

Урамга чыккач ул, уңга китимме, сулга китимме дигәндәй, беравык икеләнеп торды. Сулга китсә, кызлар артыннан болынга барып чыгачак иде: баягынак ул тәрәзәдән аларның болын ягына китеп барганнарын күреп калды. Уңга китсә, тимер юл станциясе ягына барып чыгачак иде. Икеләнүен җиңеп, уңга китте. Тигезле-тигезсез урамнар читеннән атлап бара торгач, озакламый тимер юл вокзалы буена барып җитте.

Тимер юл вокзалы Яңавылда иң күңелле урыннарның берсе иде. Көннең, төннең кайсы вакытында килмә, тормыш монда беркайчан туктапып тормый. Вокзал ишеге һәрвакыт ачык. Вокзал алдында җигүле ат-арба, каядыр китүче, каяндыр кайтучы капчыклы, чемоданлы кешеләр була. Монда үзенә бер төрле исләр килә, үзенә бер төрле тавышлар ишетелә. Агач-күмер төялгән, комбайннар, танклар, станоклар төялгән кызыл вагоннарын тартып, өй тәүмәлеге паровозлар узып киткәндә, аяк астындагы җир селкенә, вокзал тәрәзәләре калтырый. Иң күңеллесе — пассажир поездлары. Алар каяндыр еракган — зәңгәрләнеп торган кырлар, урманнар, аксыл болытлар ягыннан киләләр. Чаф-чож итеп, як-ягына кайнар пар бөркеп килгән тимер паровоз «телеграф» йортын узып туктау белән, шыгырдап вагоннар да туктый. Вагоннардан бәхетле якларга юл тотучы бәхетле кешеләр коела. Алар арасында бәрелеп-сугылып йөрүе дә күңелле. Аларның киеменә, йөзенә карыйсың, аларның сүзләренә колак саласың. Алар һәрвакыт ашыгалар. Җиргә аяк басу белән, кайберләре бидерә тотып кайнар суга йөгерә, кайберләре якындагы базар ягына ашыга, кайберләре перрон буена — аяк асларына бидерәләрен, кәрзиннәрен куеп, кулларына кубәтә тотып, юка гына көлчәләр, бәрәңге кәлҗемәләре сатып торган Яңавыл эспикүләннәре тирәсенә җыела. Алар беркайчан сатулашып тормыйлар. Аларның акчалары унлык та утызлык, йөзлек. Аларның өс-башлары менә дигән — бер җире тузмаган, бер җире ямалмаган.

Паровоз кычкыртып кузгала башлау белән, алган нәрсәләрен кадерләп тоткан килеш, алар вагоннарга йөгерәләр. Вагонга утырыр алдыннан бераз гына ыгы-зыгы булып ала. Вагон әкрен генә кузгала бара, кызулый башлый. Бу вакытта инде барысы да утырып бетә, ләкин шул чакны соңга калган берәрсенең ашыгып йөгерүен күреп алалар да, кычкыра, көлешә башлыйлар. Соңга калучы тоткага исән-имин килеп тотына. Аны күтәреп алгандай тартып алалар. Вагоннар кызулаганнан-кызулый баралар. Иң азакта кулына төреп саргылт флагын тоткан проводник хатын һәм ике зур түгәрәк күз сыман булып буфер тәлинкәләре генә күренеп кала. Паровоз моңсу һәм сагышлы итеп кычкырта-кычкырта зәңгәр билгесезлеккә китеп югала бара.

Хәзер дә Габделхәй, перронда озак кына бәлтерәп йөрде дә, станциядә туктамыйча, җилләнеп кенә узып киткән товарный вагоннарын санап басып торды. Шуннан соң Себер, Урал якларыннан килүче пассажир поездын көтеп алды. Пассажир поезды киткәч, бөтен дөнья бушап калгандай булды.

Әле булса күңеле тынычлана алмаган ялгыз җегеткә монда да күңелсез була башлады. Ул яңадан үзләренең мәктәпләре ягына борылды. Перронда төрле ашамлыклар күргәч, төрле кызыктыргыч исләр иснәгәч, аның өзДерeп-өздереп ашыйсы килде. Ләкин әлегә ашау турында уйларга иртәрәк иде. Әлегә аны онытып торырга һәм ашауга кадәрге буш вакытны ничектер уздырып җибәрергә кирәк иде. Моның өчен базарга кереп, анда-монда каранғалап, шулай ук халык арасында бәрелеп-сугылып йөрергә була иде. Дөрес, бүген базар көн түгел, ләкин анда беркайчан кеше өзелеп тормый. Саталар, алалар, кычкырып сөйләшәләр. Анда күбрәк авыл халкы. Ярлы халык, ач һәм томана халык. Шулай да үз халкың.

Хәзер аның нишләптер базарга да кереп торасы килмәде. Яңавылның иң зур магазиннары, райком, райбашкарма, Сталин клубы һәм шундый «хөкүмәт йортлары» урнашкан Ленин урамындагы универмагка да керәсе килмәде. Аның күңеле һаман мәктәп ягына тартты. Аның өчен бөтен Яңавылда иң якын җир бары шунда гына иде.

## VIII

Болыннан кайтып килүче кызларны ул ерактан ук күреп алды. Күреп алды да адымын кызулата төште. Юк, дөньяда әле бөтенләй үк күңелсез түгел иде, дөньяда әле яшәргә, язарга һәм нәрсәгәдер өмәтләнергә була иде бугай. Ул, елмаеп, кызлар каршысына китте. Кызларның һәркайсы кулларына болыннан җыеп алган чичкә тоткан. Чак-чак кына арыган, йончылган күренәләр, шулай да һәркем шат, көләч. Төркем алдыннан, гадәттәгечә, Җәмилә килә.

Кызлар да аны ерактан ук күреп алдылар, ачуланган булып, шелтәләп, оялтып нидер кычкырган булдылар. Барысы да бергә кычкырганга, аларның сүзләрен аермачык аңлап та булмады. Кызлар белән ара бик нык якынайгач, Габделхәй кырт кына борылды да, мәктәп ягына китте. Кызлар аннан көләргә тотындылар.

— Курыкты! Курыкты! — дигән сүзләр ишетелде.

Габделхәй исә мәктәпкә керә торган бәләкәй капка янына туктады да кызларның килеп җиткәнен көтеп тора башлады. Кызлар килеп җиту белән ул эчке якка керде һәм капканың келәсен элэктереп куйды.

— Билетыгыз бармы? Билетсыз кертмим! — диде Габделхәй беренче булып килеп җиткән Җәмиләнең юлына аркылы төшеп.

— Кит әле! — диде Җәмилә һәм җиңел генә капкадан кереп китмәкче булды.

— Әйттем бит — билетсыз кертмим! — дип кычкырды Габделхәй батыраеп.

Ул арада башкалар да килеп җиттеләр, кычкыра башладылар. Җәмиләнең тавышы ныграк ишетелде. Бер кулын капка ярыгыннан тыгып келәне ачарга азапланганда икенче кулы белән Җәмилә рәшәткә тактасына тотынды. Болыннан яңа гына өзеп алган хуш исле чичкәләр Габделхәйнең битенә үк килеп тигәндәй булды. Шул чакны ул Җәмилә кулындагы чичкә бәйләмен тартып алды да, читкә йөгереп китте.

— Билләһи газим! — диде Җәмилә ярсып.

Капканы каерып ачты да томырылып Габделхәй артыннан ташланды. Алар куыша-куыша бөтен ишегалдын әйләнеп чыктылар. Габделхәй үзендә искиткеч җиңеллек тойды. Җир өстендә аунап яткан утыннар, буш бидерәләр өстеннән, туарылган арба, чүп, тирес өемнәре яныннан ыргылды гына. Ара-тирә ул артына борылып карады. Баштарак Җәмилә бик нык артта калган сыман тоелган иде, ләкин куа килүченең аяк тавышлары озаклямый якынайганнан-якыная барды. Бер әйләнеп каравында ул бик якында гына Җәмиләнең кызарынган ачулы йөзен күреп алды. Шул чакны Габделхәй, малайлар белән куышкандагы кебек, кырт кына борылды да, менә-менә куып җитәргә, тотып алырга тиешле кызны аптырашта калдырып, кирегә йөгереп китте. Шатлыгыннан көлеп җибәрде, ишегалды уртасындагы физкультура мәйданчыгына таба китте, атынгыч баганалары янына җиткәч, артына борылды һәм җиңүче төс белән:

— Тоталмадың! — диде.

— Бир! — дип кычкырды кызарынган Җәмилә.

— Мә! — диде Габделхәй, багана артына качып. Кулындагы чәчәк бәйләмен кызга таба сузгандай итте, Җәмилә тотам дигәндә генә тартып алды да янә качып китте.

— Бир диләр сиңа, бир! — дип кычкырды Җәмилә.

— Тоталсаң — синеке! — диде Габделхәй.

Физкультура мәйданчыгыннан ул мәктәпнең тәҗрибә участогы ягына — җилек-җимеш бакчасы ягына йөгерде. Ачудан Җәмиләнең йөрәгенә капты, хәле бетте, ләкин хәзер аның җиңел генә чигенәсе дә килмәде. Шундый яратып, тырышып җыйган чичкәләрен кире тартып алмаса, аңа хәзер бөтенесе алдында хурлык булыр сыман тоелды. Әнә алар — кызлар-малайлар — читтән генә карап-күзәтеп торалар, эт үскеткән кебек, төрле сүзләр кычкырган булалар. Кайберләре хәтта Габделхәйгә ярдәмгә ташланды.

Җиләк-җимеш бакчасы директор өе белән абзар-куралар арасындарак иде. Габделхәй бакча капкасы янына җитте дә яртылаш ачык калдырылган капкадан эчкә керде һәм үзен куа килүче кызларның борын төбендә генә келәне әләктереп куйды.

— Бирәсеңме, юкмы?—дип кычкырды Җәмилә.

Габделхәй чичкәле кулын әле югары күтәрде, әле читкәрәк алды һәм Җәмиләнәң ачудан, нәфрәттән очкынланган күзләренә карап, шигырь такмаклады:

— Су анасы мин. Китер, кайда минем алтын тарак?

Бир! Бая көндез алып качты синең углың карак!

— Үзең барып җыялар аны бик кирәк булгач! Ялкауланып ятмыйлар,— диде Җәмилә зәһәрле итеп.

Габделхәйне нидер өтеп, чеметеп алгандай булды. Беркайчан үзенә чынчынлап ачулана алмас дип, ни әйтсәң дә, нәрсә эшләсәң дә кичерер, гафу итәр дип уйлап йөргән Җәмиләнең, үзен хәтта яшертен генә яратып йөргән Җәмиләнең усал сүзләренә шагыйрь җегет аптырап калды. Бөтен күңелен биләп алган дәрте һәм тилелеге, төртеп тишкән куык кебек, кинәт пыш-ш! итте.

— Мә. Эчеңә бәйлә,— диде ул кулындагы печәнне киртә аша ыргытып.

Аның күңеле кырылды. Дөнья яңадан күңелсезләнеп, кызыксызланып калды. Җәмилә үзенең кадерле «печән»ен тотып алды. Тотып алды да ашыгып китеп барды. Аның да күңеле кырылды, җылыйсы килде, ләкин бөтенесе авызын җырып карап торганда күз яшьләре күрсәтү җегетлек түгел иде, әлбәттә.

— Нәрсә, күрмәгәндәй карап каттыгыз?!—диде ул ачу белән иптәшләренә.

Авыраеп, төссезләнеп-тоныкланып калган чичкә бәйләмен ул киртә аша карагат, кура җиләк куаклары арасына ташлады да читкә китеп барды. Ә бит ул аны чынлыкта Габделхәйнең партасына утыртып куярмын бәлки диебрәк җыйган иде.

## IX

Уку бетәргә бер ай чамасы вакыт калгач, башка еллардагы кебек, Василий Михайлович быел да чыгарылыш кичәсе үткәрү өчен әзерлек эшләренә керешге. Эшне ул, гадәттәгечә, таныш-белешләреннән башлады. «Заготзерно»да склад мөдире булып эшләгән бер танышы мәктәпкә күчтәнәч итеп ярты пот ак он бирде. Кошчылык комбинаты шулай ук үз кеше иде—анысы ике йөз күкәй бирде, ит комбинаты бухгалтериясендәге «сеңлем Тәгъзимә» биш кило колбаса, күп кенә эчәк-бавыр бирде. Май комбинатында Василий Михайловичның якын танышлары юк иде, шуна күрә майны базардан алырга, «раймаг»тан теләнергә туры килде. Бөтен районда атаклы «Алга» колхозы председателе иптәш Дәүләтбаев бер симез сарык җибәрде. Укытучыларның үзара җыйган акчаларына мәктәп дирекциясе биргән фәлән тиеннәрне куштылар да, эчемлеген, конфетын-мазарын юнәттеләр. Укучылардан бер тиен дә алынмады. Шулай итеп, чыгарылыш кичәсенә шактый мул табын әзерләнде.

Җәйге кояш сүрелеп, аның яктысы, кызуы кими башлагач та, кичке сәгать алтыларда, Сталин клубына, военкоматка һәм райкомга якын урнашкан беренче татар урта мәктәбенә «район җәмәгатьчелеге вәкилләре»—кадерле кунаклар килә башлады. Укучылар һәм берничә яшьрәк укытучы аларны каршылау өчен алдан ук урам як капка янына чыгып бастылар.

Беренче булып, сәгать алты тулар-тулмас борын, роно мөдире, сугыш инвалиды аксак Чынтимеров килде. Мәҗлес уздыру өчен мәктәпкә бер тиен

бирмәсә дә, монда ул үзен хуҗаларча тотты. Укучылар белән дә, укытучылар белән дә теләмичә генә исәнләште һәм беркемгә карамыйча диярлек, үз йортына кергән кебек, туп-туры керде дә китте. Укучылар да, укытучылар да никтер аннан бераз гына шүрлиләр иде. Шуңа күрә Чынтимеров белән очрашу да корырак һәм салкынрак булды. Алдан кушылганча, укытучылардан берәрсе аны директор кабинетына кадәр озатып куярга тиеш булса да, роно мөдирен беркем озатып бармады.

Чынтимеровтан соң вак-вак атлап, як-ягына карап, елмаеп бәләкәй генә гәүдәле, тере, сүзчән Разия апа килеп җитте. «Коммунизм юлы»ның редакторы Разия апа элекке укытучы иде, шуңа күрә монда ул үз кеше. Бишенче класста Разия апа Габделхәйләргә татар теле, татар әдәбияты укытты. Ул вакытларда ук инде Габделхәй шигырь яза иде. Аның беренче шигырьләрен ут чәчеп торган матур кара күзле, кара чәчле, тезелеп киткән ак тешле Разия апасы укыды һәм беренче киңәшләрне дә ул бирде. Шуңа күрә Разия апасын Габделхәй аеруча якын итә, аның сүзенә колак сала. Разия апа үзе дә быелгы унынчыларны «үз балалары» дип белә иде.

Разия апа күренү белән, чыр-чу килеп кызлар шундук аның каршысына бардылар, уратып алдылар, култыклап-җитәкләп дигәндәй аны директор кабинетына кадәр озатып куйдылар. Разия апа да эреләнеп тормады — һәркемгә исеме белән эндәште, һәркемнәң хәл-әхвәлен сорашты, якындагы малайларның, кызларның аркаларыннан сөеп куйды.

Беркадәр вакыттан соң, үзеннән калкурак буйлы хатыны белән парлашып, кошчылык комбинаты директоры — юан гына, таза гына Ибәтуллин килде. Алардан кала, алдан килешеп куйгандай, бер-бер артлы «Заготзерно» вәкиле белән ит комбинаты вәкиле килде. Укучылар яныннан алар башларын югарырак тотып, дәрәҗәле генә үтеп киттеләр, шулай да сәламгә каршы сәлам бирделәр.

Җиденче яртыларда иң олы кунакларның берсе — райбашкарма председателе иптәш Бикчурин күренде. Кая барса да яшел «Победа»га утырып йөри торган председатель мәктәпкә бүген үз аягы белән килгән, үзе генә дә түгел — өчәүләшеп килгән иде. Аның бер ягыннан шат күңелле, чибәр һәм тук кыяфәтле хатыны Нәҗия, икенче ягыннан ялт итеп торган хәрби киемле яшь кенә лейтенант атлый иде. Тоташ карадан киенгән, түшендә орден-медальләре булган, таза, тыгыз тәнле, ак якалы иптәш Бикчурин капкага җитәрәк адымын әкренәйтә төште һәм яшь лейтенантны алданрак уздырып җибәрү өчен читкә тайпылды. Ләкин лейтенантның өлкән кешеләрдән алгарак чыгасы килмәде, ахрысы — юлдашларын уздырып җибәрмәкче булып, ул да читкәрәк тайпылды. Янәвыл өчен гадәттән тыш шәп киенгән, баштан алып аягына кадәр ислемайга коенган җылгыр Нәҗия ачык капкадан керә алмый торган ирләр яныннан җиңел генә узып китте дә, алтын тешләрен, ак, таза муеныңдагы муенсаларын ялтыратып, ихахайлап көлеп җибәрде һәм күзен-башын уйнатып, шул ук вакытта «балакайлар» белән, укытучылар белән исәнләшергә дә онытмыйча, керт-керт атлап кереп тә китте.

Райбашкарма председателе иптәш Бикчурин зур башлы, кызыл йөзле һәм калын кара кашлы бер кеше иде. Хатынының шулай иркен генә узып китүенә ризасызлык белдергән сыман, ул кашларын җыера төште. Озын буйлы, яшь, бәхетле лейтенантның йөзендә исә шаян елмаю чаткылары күренеп калды. Алар шулай ят, җиңел исләр таратып, укучылар белән теләр-теләмәс кенә исәнләшеп узып киттеләр.

Капка янында көтеп торучылар бу өч кунакны күреп кинәт телсез калдылар. Яшьләрнең күзе иң элек яшь лейтенантка төбәлде. Һәркемнең күңеленә: «Кем соң бу?» — дигән сорау килде. Иптәш Бикчуринның шундый зур улы бар микәнни? дип уйладылар кайберәүләр. Нишләп соң моңарчы күренмәде дә, ишетелмәде дә икән? диделәр икенче берәүләр. Кызлар аны ишектән кереп киткәнче күзләре белән ашардай булып карап калдылар һәм шундук чыш-пыш килеп гайбәтләшергә дә тотындылар. Беренче булып Җәмиләнең тавышы ишетелде:

— Уф, йөрәккәем, су бирегез — гашыйк булдым, билләhи газим! — диде ул бөтенесенә ишетелерлек итеп.

Шулай диде дә, Габделхәй ягына астыртын гына күз ташлап алды. Габделхәй исә аны бөтенләй ишетмәмешкә салынды.

## X

Менә сәгать җидегә якынлашты. Озын коридор кунаклар белән тулды. Кунаклар тыелып кына сөйләштеләр, тыелып кына көлешеп-көлешеп алдылар һәм әледән-әле ишек ягына күз төшергәләделәр. Кунаклар гына түгел, хуҗалар да көтте. Капка төбендә сакта калган укучылар килеп-килеп хәбәр итеп кенә тордылар: «Юк әле, күренми», — диделәр. Мәҗлесне башлап җибәрү өчен бөтен нәрсә әзер иде, тик менә бер кеше, иң кадерле, иң олы кеше генә килеп җитмәгән иде.

Василий Михайловичның тынычсызлануы йөзенә чыкты. Ул инде ике-өч мәртәбә райкомга да, иптәш Сафинның квартирасына да шалтыратып карады, ләкин берничек тә Мунавир Мухлисовичны туры китерә алмады. Аның хәтта кайда икәнлеген дә белмәделәр. Василий Михайлович «м-да» диде, бармакларын шартлатты һәм кульяулыгын чыгарып тирләгән маңгаен сөртеп-сөртеп алды.

Көтеп тору озакка сузыла башлагач, кайбер укытучылар, сәгатьләренә карап, кыюсыз гына: «Әллә башлыйбызмы соң?» — диделәр. Василий Михайлович ашыкмаска булды.

Шулвакыт, бөтенләй искәрмәстән дигәндәй, мәктәп капкасы янына аксыл төстәге өр-яңа «Победа» килеп туктады. Кемдер шатланып:

— Килделәр! — дип кычкырды.

Коридорда ыгы-зыгы башланды. Ишеккә якыннар тышка чыктылар, тәрәзәгә якыннар урам якны күзәттеләр. Самавырдай җиз торбаларын ялтыратып, төрле тавышлар чыгарып, баядан бирле карлыккан тамагын чистартып азапланган өч-дүрт кешелек оркестр шатланып «туш» уйнап җибәрде.

Райкомның беренче секретарен каршыларга Василий Михайлович үзе чыкты. Иптәш Сафин белән алар мәктәп ишегалды ягында, бәләкәй капкадан ишеккә кадәр сузып салынган такта басмада очраштылар. Райкомның беренче секретаре корсагы үсә башлаган олы гәүдәле, кара тут йөзле, кара чәчле, илле яшьләр чамасындагы чибәр генә бер татар иде. Өстенә ул затлы яшел гимнастерка, шундый ук төстәге галифе чалбар, аягына озын кунычлы хром итек кигән, хәрби фуражкасын салып кулына тоткан иде. Фуражкасының маңгаенда хәрби эмблемасы, кулбашында алтын погоннары, йолдызлары булса, аны, күрәсең, полковник йә генерал дип уйларга да булыр иде. Тик шулай да аңа чын хәрбиләргә хас җыйнаклык һәм төзеклек җитеп бетми иде. Бу барыннан да элек бил каешының бушабрак торуында, изү төймәләренең тулысынча каптырылмавында һәм, гомумән, үз-үзен тотышында сизелә иде. Кием-салымы белән полковникларга-генералларга охшаса да, иптәш Сафин фронтта булмады, сугышта катнашмады. Яшь чагындагы хәрби хезмәтен исәпләмәгәндә, ул, гомумән, армия кешесе түгел иде. Сугыш елларында районда иң җаваплы эшләрдә эшләде, орденнар-медальләр белән бүләкләнде. «Икмәк фронтында» зур җиңүләргә ирешкәне өчен әле быелтыр гына аңа икенче мәртәбә Ленин ордены бирделәр. Тыйнак кеше, район җәмәгатьчелеге өчен үрнәк кеше буларак, ул бүген орден-медальләрен тагып тормаган, түшенә бары төрле төстәге шакмакларын гына кадап куйган иде.

Иптәш Сафин Василий Михайлович белән кул биреп күреште, бер-ике сүз әйтеп хәл-әхвәл сорашты, соңга калуы өчен гафу үтенде дә, үзеннән чандыррак, тәбәнәгрәк директорның иңбашына аталарча шәфкатьле кулын тиереп алды. Алар шулай кочаклашкан сыман парлашып ишектән керделәр һәм туры директор кабинетына юнәлделәр.

Иптәш Сафинның тормыш иптәше Галия апа яисә Галя Гатовна машинадан соңлабрак чыкты. Аны Халидә апа белән Фәрхәнә апа каршы алдылар. Хатыннар, ирләргә беренче катнашлары юк кешеләр сыман, бәхетле елмаеп, шатланып үз хәлләрен сораштылар һәм күңелле гөрелдәп, ашыкмыйча гына мәктәпкә керделәр.

Коридорның ике ягында да аларны үрә катып укучылар, укытучылар, кунаклар көтеп торалар иде. Озакламый директор кабинетыннан иптәш Сафин белән Василий Михайлович чыкты һәм алар янәшә атлап, коридор уртасыннан килә башладылар. Алардан бераз калышып, Галия апа яисә Галя Гатовна белән Халидә апа һәм Фәрхәнә апа килделәр.

Тантаналы кичә буласы класс бүлмәсенең абзар капкасыдай итеп ачып куелган ишеге янына килеп җитәрәк иптәш Сафин каршылаучыларны сәламләп, даһиләрчә кулын күтәрде һәм парад кабул иткәндәге сыман көр тавыш белән:

— Здрасьте, товарищи! — диде.

— Здрасьте, Мунавир Мухлисович! — диде беренче булып бәхетле Антонина Семеновна.

— Исәнмесез! Исәнмесез, иптәш Сафин! — диделәр башкалар бер-берсен бүлеп.

Җиз торбалы, калай тәлинкәле һәм барабанлы оркестр шатланып, ду китереп тагын «туш» уйнап алды. Командага, үрә катуга күнегеп беткән укучылар, укытучылар, кунаклар — гомуми күтәренкелек тойгысына бирелеп, кинәт шып булдылар, гәүдәләрен турайта төштеләр һәм бөек кешеләр узып киткәнчә тын алырга да куркып тордылар.

## XI

Түргә, стена буена сәхнә сыман итеп калку урын җайланган, калку урынга унлап урындык тезеп куелган иде. Олы кунакларны калку урыннарга утырттылар. Иң уртага, әлбәттә, иптәш Сафин утырды, аның бер ягына райбашкарма председателе иптәш Бикчурин, икенче ягына хәрби диңгез флоты офицеры сыман ап-ак киемле Василий Михайлович урнашты. Калган буш урындыкларга районның җәмәгатьчелек вәкилләре һәм хөрмәтле укытучылар утырды. Хөрмәтле укытучылар арасында элекке укытучы Галия апага яисә Галя Гатовнага да урын табылды.

Олы кунаклар урнашып бетү белән, ашыгып, бер-берсен этеп-төртеп бүлмәгә укучылар кереп тулды. Шак-шок килеп, дөбердәп, шау-шу ясап, алар үз парталарына урнаштылар. Бик үк олы булмаган кунакларны сәхнәгә каршы яктагы беренче рәтләргә — парталар ягына утырткannар иде. Укытучыларның да кайберләре шунда бик үк олы булмаган кунаклар арасына кысылды, кайберләре коридор ягында, ишек төбендә торып калды, кайбер яшьрәкләр унынчылар янына елыштылар.

Кичәне Василий Михайлович ачты. Ул сәхнә белән парталар арасындагы буш урынга куелган һәм өстенә кызыл җәелгән өстәл янына килеп басты да тамагын кырды. Баштарак директор парталар ягына карап сөйләде, ләкин болай ул олы кунакларга аркасын күрсәтә булып чыкты. Василий Михайлович моны тиз арада абайлап алды һәм иптәш Сафин ягына җиңелчә генә баш иеп «извините» диде дә, өстәлнең икенче ягынарак күчендe һәм укучылар массасына карата яны беләнрәк борылды. Аннан соң янә сәхнә ягына күз төшереп алды.

Кереш сүзне Василий Михайлович урысча сөйләде. Иң элек ул бүгенге кичәнең ни өчен җыелуы турында әйтте, бу шатлыклы, тантаналы кичәдә районыбызның беренче секретаре иптәш Сафинның, райбашкарма председателе иптәш Бикчуринның, район җәмәгатьчелегенең һәм шулай ук укучыларның ата-аналары катнашканлыгын әйтте. Район җәмәгатьчелеге арасыннан иптәш Чынтимеров фамилиясен, аннан соң Разия апаны һәм төрле комбинат директорларының исем-фамилияләрен атады.

Кереш сүзеннән соң Василий Михайлович кыска гына итеп быелгы уку елы йомгакларына тукталды, партия тарафыннан үзенә ышанып тапшырылган мәктәп укучыларының фән нигезләрен тиешле дәрәҗәдә үзләштерүләре, бер класста утырып калучыларның былтыргыга караганда ярты процент чамасы азрак булуы, унынчы классны исә быел егерме дүрт укучының барысының да уңышлы тәмамлавы турында сөйләде.

Җыелыш саен диярлек Габделхәйне яхшы яктан гына түгел, начар яктан да телгә алалар иде. Үзенә карата бер үк вакытта яхшы сүз дә, начар сүз дә ишетергә никадәр күнеккән булмасын, хәзер ул, йөрәге еш-еш типкән хәлдә, Василий Михайловичның үз исемен әйтүен көтте. Ул, билгеле, яхшы сүз, мактау сүзе көтте, иптәш Сафинның, район җәмәгатьчелегенең аннан да бигрәк, Җәмиләнең һәм алтын погонлы чибәр лейтенантның ушын алырлык искиткеч хәбәр әйтүен көтте. Һәркемнең ушын алырлык хәбәр исә, аның исәпләвенчә, медаль булырга тиеш иде.

Унынчы класс турында сөйли башлагач, мәктәп директоры, чыннан да, Мухутдиновка киңрәк, озаграк тукталды. Ләкин, гаҗәп хәл, медаль турында бер генә сүз дә әйтмәде.

— Мухутдинов барлык фәннәрне «отлично»га үзләштерде, — диде Василий Михайлович. — Ун ел буена Мухутдинов Яңавыл татар урта мәктәбенең даны булды... Без аңа ышанабыз — киләчәктә ул безнең йөзгә кызыллык китермәс, фән-техниканың теләсә нинди тармагына да үзеннән лаекле өлеш кертә алырлык югары квалификацияле белгеч булыр... И без аннан шуны өмет итәбез дә...

«Әһә, кайсы якка бора!» — дип уйлады Габделхәй, директорның сүзләренә үзенчә бәя биреп. Башкалар, аеруча түрдәге кунаклар, икенче төрлерәк уйладылар, ахрысы. «Мухутдинов» исеме чыгу белән, «Кем ул? Кая ул?» дигән кебек, кызыксынып, укучылар ягына карап-карап алдылар. Хәтта иптәш Сафин да башын ия төшеп, Василий Михайлович урынына күчеп утырган хатынына нидер әйтеп алды. Галия апа яисә Галя Гатовна нидер җавап бирде һәм алар икесе дә күз карашлары белән арттагы Габделхәйне эзләп таптылар. Үзенең шәплегенә үзе гашыйк булып утырган өр-яңа лейтенантның да тәкәббер йөзендә кызыксыну билгесе чагылып калды. Тик ул беркемнән бер нәрсә сорамады — әүвәлгечә күзен каядыр бушлыкка текәп, сәхнәнең иң кырыйдагы урындыгында тораташтай катып утыруында булды.

Василий Михайловичтан соң унынчыларның класс җитәкчесе Фәрхәнә апа сөйләде. Ул татарча сөйләде. Ул да быелгы унынчыларның башка еллардагыга караганда тырышрак, тәртиплерәк булулары, фән нигезләрен яхшы үзләштерүләре турында әйтте. Аннан соң иң яхшы укучыларның исемнәрен телгә алды. Ул да Габделхәйгә аерым тукталды һәм ул да аңа зур өметләр баглавын белдерде.

Укучылар, укытучылар өчен директорның сүзләрендә бернинди яңалык булмаган кебек, Фәрхәнә апаның сүзләрендә дә бернинди яңалык юк иде. Тик шулай да Фәрхәнә апаны барысы да яратып, үз итеп тыңладылар. Мондагы кешеләрнең барысы да дип әйтерлек татарлар иде, татарча аңлыйлар, татарча фикер йөртәләр иде. Бер бүлмәгә җыйналган татарга икенче телдә — урыс телендә сөйләү күпчелекнең күңелендә каршылык, кирелек һәм шул ук вакытта мескенлек, хокуксызлык тойгысы тудыра иде. Директор сөйләгәндә тынын кысып, сагаеп утырган кешеләр Фәрхәнә апа сөйли башлагач елмаеп җибәрделәр. Сөйләп бетергәч исә шаулатып кул чаптылар.

Кул чабу туктар-туктамас борын, директорның сүз бирүен дә көтмәстән, Антонина Семеновна урыныннан торды һәм кызыл җәелгән өстәл янына килеп басты. Үзе алдында укучыларның да, укытучыларның да татарча сөйләүләрен, татарча сөйләшүләрен аның җене сөйми иде. Укучыларының үз телләрендә лыгырдауларын ул әле ничектер гафу да итә ала иде, ләкин татар теле, татар әдәбияты укытучысы Фәрхәнә апаны ул, гомумән, берничек тә гафу итә алмый иде. Теләсә кайчан «учительская»да, директор

бүлмәсендә яисә җыелышларда авыз тутырып татарча сөйләшкәне өчен генә түгел, ул, ахрысы, аны авыл хатыннары кебек таза, тупас һәм үзсүзле булганы өчен дә яратмый иде бугай. Җае чыккан саен ул аны өтеп тә ала, төрлечә мыскыл да итә иде. Кайчагында алар укучылар, укытучылар алдында да әләгешеп киткәлиләр иде. Мондый чакта Фәрхәнә апага, әлбәттә, урысча җавап кайтарырга туры килә. Фәрхәнә апаның урысчасы исә ташка үлчим иде. Үзара бәрелешләр еш кына Антонина Семеновнаның барысын орып-бәреп, класстан чыгып китүе белән, хәтта башы-йөрәге авыртып урынга егылуы белән тәмамлана иде. Бу юлы Фәрхәнә апа урыс телен бозып та сөйләмәде, алай-болай аңа тел дә тидермәде. Ләкин аның район җитәкчеләре алдында рәхәтләнеп, оялмыйча «поганый» телдә болтать итүе Антонина Семеновнаны шактый чыгырдан чыгарды.

Гомумән, бүген аның кәефе шәптән түгел иде. Фәрхәнә апа сөйләгәндә ул әле кызарынып, әле агарынып көчкә тыелып утырды. Кызыл өстәл янына чыгып баскач та ул, дәресен белмәгән укучы кебек, кирәгенчә фикерен туплый алмыйча һәм тиз генә сүз башлап китә алмыйча торды. Сүз башлагач инде, гадәтенчә, урыс теленең бөеклеге турында, урыс телен яхшы белгән кешенең беркайчан беркайда аптырап калмаячагы, урыс телен белгән кешегә һәркайда барлык юллар ачык булуы турында тезеп китте. Атаклы кешеләрнең урыс теленең бөеклеге, көчлелеге турында әйткән мәгълүм сүзләрен искә төшерде. Бу тантаналы кичәдә тәнкыйть сүзләре ят ишетелсә дә, түзмәде, «кайберәүләрнең» укытучы була торып та, урыс телен тиешенчә үзләштерә алмауларына, тиешенчә аны хөрмәт итмәүләренә кызгану белдерде.

Антонина Семеновнадан соң Разия апа сөйләде. Ул да куркып тормады — Фәрхәнә апа кебек татарча гына сиптерде. Шуннан соң райбашкарма председателе иптәш Бикчурин сүз алды. Ул шулай ук татарча сөйләде. Аннан сон химия укытучысы Халидә апа кузгалды. Ул болай да күбрәк урысча гына сөйли иде. Монда да ул күнегелгән гадәтеннән чигенмәде. Алар барысы да мактау сүзләре, тынычландыру, куандыру сүзләре генә әйтергә тырыштылар. Алар барысы да яшьләрне зур тормышка аяк басулары белән котладылар, киләчәктә совет яшьләренең иптәш Сталинның, партиянең ышанычын аклаячакларына, илебез, халкыбыз өчен файдалы кадрлар булачакларына зур өметләр багладылар.

Ил өчен, халык өчен файдалы кешенең нинди(рәк булырга тиешлеген ачык кына күз алдына китерә алмасалар да, алсу битле, саф күңелле яшьләр күтәренке, купшы үгет-нәсихәт сүзләрен тын да алмый тыңлап утырдылар. Моңа кадәр тыңлаган барлык дәресләргә караганда да яратыбрак, бирелебрәк тыңлап утырдылар.

## XII

Котлау һәм үгет-нәсихәт сүзләреннән соң тантаналы кичәнең икенче өлеше — ун классны тәмамлау турында аттестатлар тапшыру башланды. Беренче булып фамилиясе «А» хәрефенә башланган Абдрашитова Галимә чыкты. Менә ул директорның кыска бармаклы сөякчел каты кулыннан кадерле кәгазьне алды да, дәрестә җавап биргәндәге кебек, чатнап торган яңгыравык тавыш белән атабыз Сталинга, туган илгә, мәктәп дирекциясенә рәхмәт сүзләре әйтте. Аның рәхмәте әйтелеп бетү белән, коридор ягындагы оркестр, барлык торбаларын, тәлинкәләрен, барабаннарын эшкә җигеп, бөтен дөньяны яңгыратып «туш» уйнады.

Галимәдән соң Назиф чыкты. Аннан соң Фәнәви чыкты. Укучылар директор кулыннан ялтырап торган бер бит кәгазь алдылар, кычкырып рәхмәт әйттеләр һәм музыка, кул чабу, куанычлы чыш-пыш дулкынында җиңелчә генә тирбәлеп, алпан-тилпән атлап, урыннарына барып утырдылар. Бу минутта бөтен дөньяда алардан да бәхетлерәк беркем булмагандыр, мөгаен.

Габделхәй иптәшләренең сүзләренә бөтенләй диярлек колак салмады. Мондый чакта ул үз фамилиясенең «А» яисә «Б» хәрефенә башланмавына үкенү һәм ризасызлак сыман бер тойгы кичерә торган иде. Бу тойгыда түземсезлек һәм омтылыш та бар иде. Хәзер дә ул бары «Мухутдинов» фамилиясе ишетелүен генә көтте. Менә, ниһаять, Василий Михайлович, кызыл япкан өстәлдәге аттестат кәгазьләренең берсенә күз төшереп алды да Габделхәй көткән фамилияне кычкырды. Болай да киеренке тынлык сагаеп калды. Бөтен класс «Мухутдинов» ягына борылып карады һәм йөзләгән күз карашы аның урыныннан кубып, кызыл өстәл янына барып җитүен күзәтеп тордылар.

Ул, билгеле, яшь лейтенант кебек шәп һәм таза түгел иде. Чандыр һәм ак чырайлы яшь шагыйрьнең өсте-башы да алтын погонлы лейтенантныкы кебек энәдән-җептән генә чыккан түгел. Өстенә ул иске гимнастеркадан бозып теккән, уңган, юкарып беткән иске күлмәк-гимнастерка һәм киң балаклы озын чалбар кигән иде. Иң күзгә ташланганы — озын чәч иде. Колакларын күмеп киткән, чүмеч артына төшеп торган чәчләре бераз гына Такташныкын хәтерләтә иде кебек. Ләкин аныкыдай уттай янган күз карашы, ихтимал, Такташта да булмагандыр. Аның ул рәтле, очкынлы күз карашында балаларча беркатлылык та, кыюсызлык та, шул ук вакытта үз-үзенә ышану, горурлык һәм тәкәбберлек тә бар иде.

Калын, шома кәгазь кисәген Василий Михайлович бүтәннәргә ничек тапшырган булса, аңа да шул рәвешчә тапшырды. Дирекция һәм укытучылар коллективы исеменнән фатиха сүзләре әйтте, нык итеп аның кулын кысты. Шуннан соң оркестр «туш» уйнады. Халык шаулатып кул чапты.

Шуннан соң Габделхәй дә бүтәннәр кебек кычкырып рәхмәт әйтергә һәм, кызыл өстәл янында артык тоткарланып тормыйча, үз урынына барып утырырга тиеш иде кебек. Ләкин, Габделхәй исәпләгәнчә, «тантана» җитәрлек дәрәҗәдә тантаналы булмады. Директор аңа бирелергә тиешлә тагын бер нәрсәне онытып калдырды сыман тоелды. Бөтен халык алдында шул турыда Василий Михайловичның исенә төшерү бик зур әдәпсезлек булыр иде, әлбәттә. Ул моны аңлады, ләкин шул ук вакытта директорның ни дә булса әйтүен көтте. Директор исә берни әйтмәде — башын иештереп, өстәлдәге аттестатларны әвеш-түеш китергән булды. Ул арада укучылар арасында чыш-пыш китте. Габделхәй үзе генә түгел, башкалар да директор медаль алып кайткандыр, күрәсең, аны бүген тантаналы кичәдә тапшыралар диебрәк уйлаштыралар иде.

Иптәшләренең чыш-пышын ишетеп, Габделхәй каушый башлады.

— Нәрсә, выступлениегезне оныттыгызмы әллә, Мухутдинов? — диде Василий Михайлович.

«Әйе шул — выступление...» — дип уйлады Габделхәй, үзенең хәзер генә нишләргә, нәрсә сөйләргә тиешлеген исенә төшереп. Ләкин ул бит «выступление»гә әзерләнмәде! Ярдәм сораган сыман, ул якындагы Антонина Семеновнага күз төшереп алды. «Каушама, сөйлә!» — диде Антонина Семеновна күз карашы белән елмаеп. Фәрханә апа исә ишеттерерлек итеп:

— Шигыреңне укы, Габделхәй, — диде.

Разия апа да шул ук сүзләрне әйтте. Габделхәйгә кинәт җан керде, ләкин әле һаман ул каушавын җиңә алмады — нишләргә белмичә, өстәл янында басып тик торды.

Халык көтте. Башта тын да алмый көтте, аннары сабырлыгын җуеп, сизелер-сизелмәс кенә гөжләргә тотынды. Кемдер пышылдады, кемдер парта шыгырдатты. Иптәш Сафин, яшь җегетнең уңайсызлануын күрмәс өчен, хатынына иелеп, нидер әйтеп куйды.

— Башлагыз. Кыюрак! — диде шул чакны якында гына Антонина Семеновна, команда биргән кебек.

Торгынлык юкка чыкты һәм үзенә ышаныч кайта барганын тойган хәлдә Габделхәй, тамагын кыргалап:

— Иптәшләр... — диде.

«Иптәшләр»не ул татарча әйтте. Макталган укучының уңайсыз хәлдә калуына болай да үртәлеп утырган Антонина Семеновна корт чаккандай урыныннан калкып куйды һәм дорфа гына:

— Мухутдинов, говорите по-русски! — диде.

— Гафу итегез, — диде Габделхәй һәм бернинди тоткарлыксыз «выступление»гә тотынды.

Сөйләгәндә ул берни турында уйламады. Ул бары кайчандыр кемнәндер ишеткән, китаплардан, гәзитләрдән укыган сүзләрен генә исенә төшерде.

— Без бүген барыбыз да зур шатлык кичерәбез, — диде ул дәрестә җавап биргән кебек «шартлатып». — Шатланмаска мөмкинме соң? Бүген без туган мәктәбебез белән, кадерле укытучыларыбыз белән саубуллашабыз. Без олы тормыш юлына аяк басабыз. Безнең күгебез аяз, киләчәгебез якты. Соңгы сүзем итеп шуны әйтәсем килә... бәхетле яшьлегебез, шатлыклы тормышыбыз өчен... партиягә... иптәш Сталинга... шуны әйтәсем килә...

Соңгы сүзләрен, бигрәк тә партиягә, Сталинга кагылышлы сүзләрне аның аеруча күтәренке, тәэсирле итеп тәмамлыйсы килде һәм шигырь язгандагы кебек, иң кирәкле сүз таба алмыйча, бу юлы да төртелеп калды. Шулай да артык каушап, тоткарланып тормады — «безне яңадан-яңа җиңүләргә алып баручы» дип шома гына ялгап алып китте. Кирәкле сүзләрен әйтеп бетергәч ул, «уф, котылдым!» дигән сыман, шаулатып бер тын алды. Аның шулай шаулатып тын алуын бөтен класс ишетеп торды. Фәрханә апа, теләктәшлек белдереп, елмаеп куйды. Тәртипсез Назиф кычкырып көлеп җибәрде. Аңа башкалар кушылды. Күп тә үтмәде, шундый авырлыкны җиңеп чыккан батыр Мухутдиновка чын күңелдән шаулатып кул чабарга тотындылар.

## XIII

Кул чабу озакка сузылмады. Барысы да, Габделхәй белән эш бетте дип уйлап, Василий Михайловичның икенче фамилияне әйтүен көттеләр. Василий Михайлович, чыннан да, нидер әйтергә җыенды.

— Шушы кадерле кичәгә багышлап мин шигырь яздым, — диде Габделхәй, кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарып. — Рөхсәт итсәгез, мин шуны укып күрсәтер идем.

Ул моны директорка карап әйтте. Василий Михайлович, Габделхәй урыныннан кузгалып китмичә сүз башлый алмаган кебек, Габделхәй дә аның рөхсәтеннән башка сүз башлый алмый иде. Директор, ишетмәгән сыман, эндәшми калуны артыграк күрде.

— Укы әйдә, укы! — диде Фәрханә апа директор өчен җавап биреп.

— Укы, укы! — диделәр башкалар да.

Габделхәйгә шул гына кирәк тә иде.

— «Рәхмәт, мәктәп!» диде ул шигырьнең исемен әйтеп, Василий Михайловичның җавабын көтмәстән.

Шуннан соң ул дәртләнеп укырга кереште һәм:

Бакчадагы алсу гөлләр кебек
Чәчәк аттык синдә без, мәктәп.
Аңыбызга якты нурлар сибеп
Син үстердең безне иркәләп,

— диде яшь, көчле тавыш белән.

Мәктәп һәм Яңавыл күләмендәге атаклы шагыйрьнең шактый озын һәм күңелсез шигыре, «выступление»се кебек үк, дәрестә ишеткән, китаплардан, гәзит-журналлардан укып белгән төссез, шома һәм политик тотнаклы сүзләрдән теркәлгән иде. Василий Михайловичны исәпләмәгәндә, беркем дә монда шигырь белгече түгел иде. Шулай да яшь шагыйрьнең кычкырып һәм дәртләнеп таныш сүзләр көйләве тыңлаучыларга ярыйсы ук тәэсир итте.

Рәхмәт сиңа, бөек туган халкым —
Улларының изге юлдашы.
Рәхмәт сиңа, туган уку йортым,
Даhи Сталин — бәхет кояшы!

— дип тәмамлады Габделхәй, тәрәзә пыялалары зыңгырдарлык тавыш белән.

Фәрханә апа куанычыннан елмаеп җибәрде, «Булдырдың!» — диде. Бөтен класс ду китереп кул чапты. Хәтта иптәш Сафин да башкаларга кушылып кул чапты, иптәш Бикчурин шулай ук калышмаска тырышты. Бите, колак очлары уттай янган бәхетле җегет боларның барысын да күреп, тоеп торды һәм ашыкмыйча гына өстәл яныннан кузгалып китте.

Тәненең авырлыгын да, аягының кайсы якка, ничек атлавын да тоймас хәлдә җиңеләеп, үз партасына таба юнәлгәндә аның алсу томан элпәсе белән капланган күз карашына ачулы Антонина Семеновнаның тузынып коридорга чыгып барганы күренеп калды. «Кайтып китте. Килмәячәк бүген», — дип уйлады ул аның турында тыныч кына. «Хәтерен калдырдым, ахрысы», — диде аннары үз-үзенә. Ләкин бит аның да хәтерен калдырдылар! Медаль юк. Булмады. Булмаячак. Нәрсә ул шау-шу килеп кул чабулар алтын медаль белән чагыштырганда!

Урынына килеп утыргач та Габделхәй үзен биләп алган исерткеч тәэсирләрдән тиз генә арына алмады. Әле генә нәрсә турында уйлаган иде соң ул? Ә-ә, Антонина Семеновна... Юк, медаль бугай. Әйе, медаль. Булмады. Булмагандыр, күрәсең. Нигә соң аны башта ук шулай дип әйтмәделәр икән? Нигә шуны сер итеп тоттылар икән?

Күпмедер вакыттан соң аның колагына бик ерактан, куе томан арасыннан ишетелгән сыман, кемнеңдер тавышы килеп җитте.

— Нәрсә? — диде ул артына борылып, илтифатсыз гына.

— Кәбестә! — диде Җәмилә. — Сәкинә кая?

«Сәкинә турында юри сорый. Сөйләшәсе килә», — дип уйлады Габделхәй үз алдына. Әле күптән түгел генә ул, моннан соң беркайчан Җәмилә белән сөйләшмәячәкмен, дип үз-үзенә сүз биргән иде. Хәер, ул инде аны шундук оныткан да иде, тик шулай да Җәмиләгә карата күңелендә энә очы кадәр генә кинә торып калган иде. Аннан соң, хәзер генә шундый бәхетле, күңелле мизгелдә Җәмиләнең ут капкандай Сәкинәне таптыруы бөтенләй урынсыз иде.

— Сакина Тазиева юкмыни? — диде Василий Михайлович класска күз йөртеп.

Барысы да бер-берсенә карашып алдылар. Төрле яктан:

— Юк, күренми.

— Кая булды икән соң ул?

— Әле генә шушындае, — диделәр.

— Нәрсә булган тагын? — диде директор кырыс кына.

Иң арткы партада утырган Җәмилә Габделхәйнең аркасына төртеп алды:

— Сәкинәне күрмәдеңме, димен мин сиңа!

— Нәрсә кирәк сиңа? — диде Габделхәй челәеп.

— Кычкырма ул чаклы! — диде Җәмилә пышылдап.

Бер-ике сүз белән ул Сәкинә турында үзе белгәнне әйтеп бирде. Баягынак болынга барырга чыккач, алар — Җәмилә белән Сәкинә, әйткәләшеп киткәннәр. Үпкәчел Сәкинә ачуланып кире борылган. Аның артыннан йөгереп караганнар, ләкин куып җитә алмаганнар. Җәмилә аны мәктәпкә кайткандыр дип уйлаган. Мәктәптә юклыгын күргәч, өйләренә кайтып киткәндер, дип уйлаган. Аны, билгеле, өйләренә барып алганда да ярар иде, ләкин Җәмиләнең барасы килмәгән. Аттестат кирәк булса, үзе килер әле, дип уйлаган. Ләкин Сәкинә менә юк. Кайда булыр ул? Аның кайдалыгын Габделхәй дә белмәгәч, тагын кем белер? Бит алар... йөриләр!

Сәкинәнең юклыгы Габделхәйне әз генә дә борчымады. Ул Җәмилә кебегрәк: «Аттестат кирәк булса, үзе килер әле», — дип уйлады. Шулай да

Җәмилә алдында бөтенләй кызыксынмаган кеше булып утыру да килешми иде.

— Чыннан да, кая китте икән соң ул? — диде ул Җәмиләнең үзенә үк сорау биреп.

— Кит, билләһи газим! — диде Җәмилә. — Бу кадәр булгач та булырсың икән!

— Үзләре куалап җибәргәннәр дә, хәзер мин гаепле, — диде Габделхәй.

Сәкинәнең юклыгы җайлы гына барган тантаналы кичәнең тәртибен бозды. Василий Михайлович «Тазиева»ның аттестатын бер читкә алып куйды да, аннан соң икенче кешенең фамилиясен әйтергә әзерләнде. Шул чакны Җәмилә кулын күтәреп, парта капкачларын шакылдатып, урыныннан торды.

— Василий Михайлович, Сәкинә Таҗиеваның өйләренә барып килергә рөхсәт итегез? — диде.

— Барыгыз, — диде диретор.

«Әйдә!» — дигән сыман Җәмилә Габделхәйнең кабыргасына төртеп алды, үзе белән бер партада утырган Нәзирәне җитәкләде дә, беркайчан түбә өстендә рәтләп тормый торган, читләренә аллы-гөлле бизәкләр төшерелгән зәңгәр кыекча яулыгын төзәткәләп, тиз-тиз атлап ишеккә таба элдерде.

Җәмиләнең шулай санга сукмагандай кабыргасына төртеп алуы да, беренче булып, әйдәп китеп баруы да Габделхәйнең ачуын китерде. Кем булган дип торырсың — этеп-төртеп кенә йөртмәкче! Йөртми тор әле. Киреләнеп, ул урынында утырып калды.

— Әйдә киттек без дә! — диде шул чакны Назиф Габделхәй ягына карап.

— Әйдә, алайса, — диде Габделхәй теләр-теләмәс кенә.

## XIV

Боларның барысы да кичәгенәк булды.

Менә хәзер ул идәнгә озын өстәл янына сузылып яткан да, яңадан татлы йокыга китәргә азаплана. Ләкин таң аткан, тышта якты, бүлмәгә кояш нуры тулган.

Кичәге көн, дөресрәге, кичәге төн әллә төш, әллә өн булып мәңге аның хәтерендә сеңеп калды.

Кичәгенәк алар үз гомерләрендә беренче мәртәбә укытучылар белән, зур дәрәҗәле кунаклар белән мәҗлестә утырдылар. Бергә, бер өстәл янында ашадылар, эчтеләр. Беркем бер сүз әйтмәде, беркем бер шелтә-фәлән белдермәде. «Эчте» дигәч тә, кызлар авызларына да алмадылар, малайлар да татып кына карадылар. Әз генә, күз каргамаслык кына. Хәтта директор... Василий Михайлович алар белән стаканын чәкештереп йөрде. Кызык инде. Әдәм әйтеп әдәм ышанмас — шундый кырыс, шундый коры Василий Михайлович үзенең укучылары белән, укытучылары белән бергәләп аракы эчте! Иптәш Сафин да, иптәш Бикчурин да эчте. Бар рәвешен китереп, чын ирләрчә шаулатып, мактанышып эчтеләр.

Чак-чак кына башына китеп алгач, дөресрәге, туйганчы ашаганның соңында күңеле күтәрелеп киткән Габделхәй утырган җирдән генә үзенең Яңавылга, Бүә буйларына багышланган яңа шигырен укыды. Шундый хисле итеп, шундый оста итеп укыды — барысы да исләре китеп тын да алмый тыңлап тордылар, аннары күкләргә чөеп мактадылар. Хәер, аның үзенә генә шулай тоелды. Дөресен әйткәндә, «район җәмәгатьчелеге»нең әллә ни исе китмәгән сыман күренде. Бу вакытта инде алар аерым-аерым төркем булып нидер гәпләшәләр, нидер хәл итәләр иде. Иптәш Сафин исә үзенең бәлештәй симез, чибәр хатыны Галия апа янсә Галя Гатовна белән китеп тә барган иде бугай.

Аны бары классташлары гына мактады, ахрысы. Малайлар арасында калкурак гәүдәле, көчлерәк Назиф Габделхәйне күтәреп алып югары чөймәкче булды. Габделхәй аны юри бәйләнә дип уйлады. Кем белә, бәлки чынлап та көнчелектән шулай кылангандыр ул? Чак-чак кына ызгышып китмәделәр. Ярый әле вакытында Габделхәй үзенең хатасын аңлап алды. Аңлап алды да, Назифтан гафу үтенергә тотынды. Шуннан соң алар икәүләшеп, кочаклашып тышка чыгып киттеләр. Очынып, дәртләнеп караңгыда, салкынча һавада озак кына җырлап йөрделәр. Аларга Фәнәви килеп кушылды. Алар беркайчан ачуланышмаска, мәңге дус-тату булырга бер-берсенә антлар бирделәр.

Шулай дөньяларын онытып, мәктәп ишегалдында әрле-бирле йөренгәндә, караңгыда көтмәгәндә каршыларына Җәмилә килеп чыкты.

— Нишләп йөрисез монда бер-берегезгә тагылып? — диде ул исе китеп. — Анда сезне югалтып яталар. Сәкинә үпкәләгән. Абау, шул да булдымы — кызы янына барып та карамый!

Күп тә үтмәде, Җәмилә артыннан Нәзирә килеп җитте, Галимә килде. Шуннан соң алар култыклашып, шаулашып, урамга ук чыгып киттеләр. Ләкин әллә ни ерак та китә алмадылар, озак та йөри алмадылар — Җәмилә барысын да кире борды. Беркем каршы килмәде. Җәмиләнең боерыгына буйсынып, яңадан мәктәп ишегалдына кайттылар. Алар кайтып кергәндә бөркү класс бүлмәләрендә беркем калмаган — барысы да тышка, ишегалдына чыкканнар, җыр-бию башлап җибәргәннәр иде. Бу вакытта инде оркестр да, кайбер кунаклар да кайтып киткәннәр, мәктәптә бары үз кешеләр генә, яшьләр генә калган иде. Күптән түгел армиядән кайткан, җыр һәм рәсем укытучысы Нәҗип абый өздереп гармун уйный, укытучы кызлар, яшь хатыннар биилэр, башкалар исә күңелле шаулашып кул чабып торалар иде.

Сәкинә шунда гына, мәктәп ишегалдында гына булган. Аны эзләргә китүчеләр тиз арада кире борылдылар. Бераз соңлап булса да Сәкинә дә аттестат алды. Ләкин аңа карап кына Сәкинәнең күңеле күтәрелмәде. Менә хәзер дә ул биюче укытучылар янындарак аерылып, бер ялгызы басып тора иде.

Урамнан җыйнаулашып кайтып кергәндә Җәмилә тагын Сәкинәнең үпкәләве турында әйтте. «Үпкәләмәсен, ул да шат күңелле булсын», — дип уйлады Габделхәй үзенең йөргән кызы турында. Ләкин, нихәл итмәк кирәк. Җәмилә Сәкинәдән яхшырак. Гадирәк тә, аңлаешлырак та. Буй-сын, чибәрлек ягына килгәндә, Сәкинәдән әллә кайда өстенрәк. Тик менә укуы гына Сәкинәнекеннән кайтышрак. Бигрәк тә ул урыс теленнән йомшак, физика-математикадан, химиядән йомшак. Аннан соң бик җиңел акыллы да бугай ул. Бик тиз кызып китә, кычкыра. «Язучы — кеше рухы инженеры» булса да, Габделхәйнең әле нишләптер Җәмиләнең холкын-фигылен, эчке кичерешләрен рәтләп аңлаганы юк. Наданлык бу. Шагыйрь... буласы кеше башкаларны, бигрәк тә кызларны яхшы белергә тиеш. Дөрес, Габделхәйнең, инде яратмау мәсьәләсендә үз карашы бар. Аныңча, чын кеше бары тик яхшы укучы кызларны гына, эшчән, тырыш һәм акыллы кызларны гына яратырга тиеш. Андый кыз бик үк матур булмаска да мөмкин. Чын мәхәббәт тышкы матурлык белән түгел, эчке матурлык белән билгеләнә. Сәкинә нәкъ менә шундый кыз. Сәкинәне яратмаска мөмкин түгел!

## XV

Шулай уйлана торгач, көтмәгәндә ул теге лейтенантны исенә төшерде. Бер дә юктан диярлек кәефе кырылды. Беренче күрүдә үк лейтенант аңа ошамады. Ошамады гына түгел, ул аны хәтта җаны-тәне белән яратмас булды. Яратмаса да, әледән-әле аның ягына карап алды, аның турында әйтелгән өзек-өзек сүзләргә колак салды. Берәүләр аны райбашкарма пред-

седателенең туганы икән, диделәр, икенче берәүләр, хатынының энесе икән, диделәр. Венгриядәме, Румыниядәме хезмәт итә икән: ялгамы, бөтенләйгәме кайткан икән дә, шуннан файдаланып менә монда Яңавылга кунакка килгән икән, диделәр.

Берни әйтеп булмый, иптәш лейтенант чибәр җегет. Барыннан да бигрәк аның менә шул чибәрлеге ачуны китерде бугай. Киң җилкә, калку күкрәк, кара каш, кара чәч. Үзе озын, төз гәүдәле. Кәртинкә инде, кәртинкә. Тик менә йөзе нурсыз. Эре. Тәкәббер. Һәркемгә масаеп, мыскыл итеп карый сыман. Кызлар аның йөзенә карамыйлар да, энәдән-җептән чыккан шәп киемнәренә карыйлар да, алтын погоннарына кызыгалар. Җәмиләнең авызында гел шул погон да, китель, төймә булды. Кичәгенәк лейтенант үзен шактый эре тотты. Унынчыны бетереп кулларына аттестат алган җегетләрнең берсе белән дә беренче булып сүз дә башламады, алар ягына хәтта рәтләп карамады да. Шул ук вакытта малайларның башлары аша үреләп, кызларга мактау сүзләре әйтте, кайберләре белән сөйләшергә дә тырышып карады.

Габделхәй һич тә аның үзләре белән аралашуын теләмәде. Ләкин бөтен игътибары аның һаман шул сөйкемсез лейтенантта булды. Чибәр кунакның һәр сүзе, һәр кыланышы анда кире тәэсир тудырды. Габделхәйнең генә түгел, бүтән малайларның да бу кирәкмәгән артык кашыкка ачулары килгән булып чыкты. Икәүдән-икәү генә калгач, Назиф Габделхәйнең беләгеннән кысып тотты да, кайнарланып:

— Әйдә тукмап ташлыйбыз шул погонлы күркәне! — диде.

Назифның Җәмиләгә күзе төшеп йөри. Моны белә. Бервакыт ул хәтта: «Мин аны өйләренә кадәр озатып куйдым», — дип тә мактанган иде. Назифның Җәмиләне көнләп дулавы Габделхәйгә бик ук ошап җитмәсә дә, аның шулай кунак җегетне тукмарга җыенуына каршы килмәде. Назиф ул дуамалрак. Ярсып китсә, лейтенантны чынлап та тукмап ташлавы бар. Ләкин бит лейтенант — хәрби кеше! Ничек итеп аңа кул күтәрәсең? Аның әле кесәсендә наганы да бардыр. Совет армиясенә каршы кул күтәргән дип алып китсәләр?!

Габделхәй Назифка шулайрак диде. Мондый сүз ишетеп Назиф ы-мы итте, үпкәләгән сыман итте, шулай да артык кысташып тормады. Ул арада иптәш Бикчурин хатыны Наҗия апа белән кайту ягына юнәлде. Хуш исле папиросын төтәтеп, алар белән кунак лейтенант та китеп барды.

Габделхәйгә хәзер барысы да көлке тоелды. Ярый әле дурак Назиф коткысына бирелмәгән. Алай-болай эләгешеп киткән булсаң харап эшләр! Ятар идең менә монда хуш исле чичкә арасында... иртәнге кояшта җылынып...

Шуннан соң... шуннан соң алар яңадан үзләренең классларына керделәр, яңадан биеделәр, җырладылар. Барлык кунаклар һәм укытучылар кайтып киткәч, Фәрхәнә апа белән бергәләп таңга кадәр диярлек төрле кызык хәлләр сөйләшеп, хыялланып утырдылар. Фәрхәнә апа «Гөлмәрфуга, бар суга» дигән яңа җыр өйрәтте. Ул аны яшь чагында Казанда ишеткән икән. Фәрхәнә апаның матур итеп җырлавына яшьләрнең исе китте. Алар аны бөтенләй җырлый белми дип уйлыйлар иде. Баксаң, ул да менә дигән иттереп, моңлы итеп, сузып-сузып җырлый икән!

Алар шулай урындыкларын түгәрәкләп тезеп, бер-берсенә сыенып утырдылар, бер-берсенең якынлыгын тоеп, күз керфекләре йомылганчы, тамаклары карлыкканчы җырладылар да җырладылар. Җырны күбрәк Фәрхәнә апа башлады. Җырлап туктагач, бер-ике сүз белән җырның тарихы турында белешмә бирде — монысын фәлән авылның фәлән кешесе чыгарган, диде, монысын кызыллардан ишеттем, монысын солдатлардан ишеттем, диде. «Солдатлар»ның нинди төстә булуын сорап тормадылар. Барыбер түгелмени? Ак булса да, кызыл булса да, кемдер җырлаган, үзебезчә, татарча җырлаган. Шул чактагы бер яшь кызның хәтеренә сеңеп калыр дип ул, бәлки, уена да китереп карамагандыр. Бәлки, аны шул ук көнне атып үтерге́ннәрдер. Җыры менә исән калган.

Шуннан соң... шуннан соң кызлар бер бүлмәдә, малайлар бер бүлмәдә кая туры килде, шунда башларын төртеп йокыга талдылар. Фәрхәнә апа кайтып китмәде — кызлар янында калды.

Дөресен әйткәндә, аларның йокы дигәне йокы да булмады. Бары бераз онытылып кына алдылар. Менә Габделхәй көндәгечә уянып китте. Хәзер инде ничек йоклап ятмак кирәк?!

Йокылы-уяулы килеш беравык уйланып яткач, ул бүлмә эченә күз йөртеп чыкты. Кичәгенәк бөтенесенең игътибарын үзенә җәлеп итеп торган кызыл япмалы өстәл урыныннан күчерелгән, кызылы яртылаш идәнгә салынып төшкән. Идәндә, өстәл өстендә, парталарда, урындыкларда кәгазь кисәкләре, теләсә ничек чәчкәләнгән чичкәләр аунап ята. Идәндә төрлесе төрле кыяфәттә сузылып, бөгерләнеп малайлар йоклап ята. Тәрәзә аша елмаеп иртәнге кояш карый. Бөтен дөнья шундый тын, тыныч. Күңелдә шатлыклы, бәхетле бер омтылыш һәм туасы көнгә зур өмет тойгысы тирбәлә. Әйе, бу аның сабыйлык һәм балалык чорыннан чыгып, күптән вәгъдә ителгән олы тормышка — серле дә, аңлаешлы да сыман билгесезлеккә аяк баскан беренче һәм соңгы иртәсе иде.

## XVI

Шул чакны урам якта көтүченең:

— Чыгары-ың! — дигән тавышы ишетелеп китте.

Шуннан соң чыбыркы шартлады. Күп тә үтмәде, шыгырдап капкалар ачылды. Йокылы тавышлы ниндидер хатын-кыз сыерына, сарыкларына кычкырды. Анасыннан аерылып калган кәҗә бәтие колак тондыргыч чәрелдек тавыш белән кычкыра-кычкыра каядыр йөгереп китте. Ачык тәрәзәдән дымлы тузын исе катыш әчкелтем көтү исе килеп керде һәм мәктәп турысында беркадәр вакыт тигезле-тигезсез атлаган йөзләрчә тояк тавышлары, сарык кычкырган, сыер мөгерәгән тавышлар ишетелеп торды.

Көтү тавышына малайларның барысы да уянып киттеләр. Көтү киткәч йоклап ятарга ярамаганлыгын уйлап урыннарыннан тордылар да, өс-башларын рәтләделәр. Икенче бүлмәдәге кызлар да уяндылар, аякларына бастылар һәм бер-бер артлы тышка чыга башладылар.

Барысы да җыелып беткәч, кызлар Фәрхәнә апаны өйләренә кадәр озатып куярга дигән теләк белдерделәр. Кызларның теләгенә малайлар да кушылды. Фәрхәнә апаның бер ягыннан Җәмилә белән Сәкинә, икенче ягыннан Габделхәй белән Назиф барды. Башкалар аерым-аерым төркем булып, алданрак та, арттанрак та бардылар.

Фәрхәнә апа Яңавыл татар урта мәктәбенең иң өлкән укытучыларыннан санала иде. Баштарак ул башлангыч классларда укыткан, аннан соң үзе укыган. Казанда, пединститутта. Шуннан сон, югары классларда татар теле, татар әдәбияты укыта башлаган. Аның күз алдында инде бик күп балалар үсеп буйга җитте, бик күп балалар менә шулай бүгенгечә «яңа тормышка» аяк бастылар һәм нәкъ бүгенгечә диярлек, күмәкләшеп аны өенә кадәр озата бардылар.

Өлкән укытучы исәпләнелсә дә, Фәрхәнә апа чын яшенә караганда яшьрәк һәм тазарак күренә иде. Көне буе балалар шау-шуы, тузан эчендә гомер кичерә торган укытучыдан бигрәк, ул иртәннән башлап кичкә кадәр саф һавада була торган игенчене хәтерләтә иде. Тумыштан ул, чыннан да, игенче кызы булган, яшьрәк чагында ирләр кебек җир сөргән, печән чапкан, әтисе белән бергәләп урманга, тегермәнгә йөргән. Шул ук вакытта кыш көннәрендә бер-ике ел мәдрәсәдә абыстайдан сабак алырга да өлгергән. Авылда укытучылар җитешмәгән чакта аны мөгаллимә итеп куйганнар. Шуннан башлап ул менә һәр көн диярлек мәктәп юлын таптый.

Белемне ул бик авырлык белән ала. Колхозлашу елларында бик зур мохтаҗлыклар, кыенлыклар күрә. Хәзер инде алынасы белем алынып беткән, михнәтләр онытылган, тормыш җайга салынган. Менә шулай чыгарылыш

кичәләре вакытында, яшьләр белән иске җырлар җырлап утырганда ул еш кына элеккеләрне исенә төшерә. Шул чагында яшьләр аны беренче мәртәбә күргән кебек булалар. Дәрес вакытында ул, билгеле, үзе турында сөйләми, хәзер исә, киресенчә, гел үзе турында, элекке гадәтләр, элекке җырлар, элекке кешеләр турында сөйли. Шулай да ул беркайчан вәгазь дә укымый. «Без үскәндә кыен булды, хәзер сез рәхәт яшисез»,—дигәндәй сүзләр әйтми. Ул бары булганны гына сөйли. Ләкин нишләптер ул беркайчан үзенең туган якларын, туган авылын, аннан да бигрәк, утызынчы елларны исенә төшерми. Ул күбрәк үзенең Казанда укып йөргән заманнар турында гына сөйләргә ярата.

Әле дә, иртәнге урамнан төркемләшеп барганда да, ул тәмләп, тәфсилләп шул елларны исенә төшерде. Беренче елны Казанда бик авыр булган икән. Башлангыч сыйныфта укытуын ташлап, кемгәдер ияреп киткән дә барган Казанга. Танышы ярдәмендә пединститутны эзләп тапкан, «апшежитиегә» урнашкан. Имтихандагы сорауларның берсенә дә рәтләп җавап бирә алмаган. Ярый әле имтихан алучы укытучы татар кешесе булган. Кызганып «яхшы» куйган да, шуннан җайланып киткән. Укыган чагында ягылмаган салкын бүлмәләрдә торган, трамвайда билетсыз йөргәннәр, көне буена рәтләп ашамыйча-эчмичә, күңелсез лекцияләр тыңлаганнар. Буш вакытлары булдымы, студентларны урам чистартырга, шәһәр читендәге төзелешләргә алып бара торган булганнар. Шулай да, ачлыкка, мохтаҗлыкка карамыйча, кичләрен әдәби кичәләргә, җыелышларга, концертларга йөргәннәр. Бер кичәдә Фәрханә апа бик-бик якыннан Тукайны да күреп калган, аның ялкынланып шигырь укуын тыңлаган.

Һәркем үз уена бирелеп, яшьләр тын да алмый тыңлап бардылар. Фәрханә апа сөйләгән һәр нәрсә аларга искиткеч булып тоелды.

— Уф! Бездән булмас инде ул, Фәрханә апа,—диде Җәмилә, авыр күрсенеп.

— Нишләп булмасын?—диде Фәрханә апа.—Тәвәккәл таш йоткан. Тәвәккәлләргә кирәк.

— Тәвәккәлләп кенә булмый шул, Фәрханә апакаем,—диде Җәмилә.— Без инде газитләрдә язылган бер белдерүне дә калдырмый укып барабыз. Кайсына карама, беренче сүз итеп: урыс теленнән имтихан дип куелган. Урыс теле суя безне, Фәрханә апа. Калганын без аның шартлатып биререк.

— Казан булып Казанда бер татарча институт юк,—диде Сәкинә дә сүзгә катышып.—Татарча укытсалар, беребез калмый барып керерек.

— Укытсалар дисең! Имтиханны татарча алсалар да әле!—диде Җәмилә.

— Безнең заманда бар иде,—диде Фәрханә апа.—Барлык институтларда татар теле укытыла иде.

— Бик кызык булгандыр ул, иеме, Фәрханә апа!—диде Назиф.

— Кызык инде... үз телеңдә...—диде Фәрханә апа.—Пединститутта хәзер дә татар теле бүлеге бар диләр бит.

— Безнең пединститутка керәсе килми шул,—диде Җәмилә көттеребрәк.—Без, Фәрханә апа, медицинскига кермәкче булганыек.

— Нишләп үткән заманда сөйлисез?—диде Фәрханә апа.—Ныклап уйламадыгызмыни әле?

— Нинди заманда сөйләшергә дә белмәссең инде, Фәрханә апа,—диде Җәмилә ничектер аңлаешсыз итеп.

— Җәмиләнең фигыль заманнарын буташтыра торган гадәте бар бит аның, Фәрханә апа,—диде Габделхәй.

— Абау! Син генә инде!—диде Җәмилә шундук.

— Аттестат кесәдә—нинди заманда сөйләшсәк тә ярый!—диде Назиф остарып.

Кызлар көлешеп алдылар. Хәтта Фәрханә апа да елмаеп куйды. Куанычтан Назифның йөзе балкып китте. Беркадәр араны яшьләр «фигыль» һәм «заман» темасын төрләндереп, көлешеп бардылар да, киләчәкнең һич тә көлке түгеллеген уйлап, янә тынып калдылар.

## XVII

— Их, Фәрхәнә апа! — диде Җәмилә бераздан тагын да авыр көрсенеп. — Дәрт бар, дәрман юк. Унны бетердек — инде нишләргә? Аптыраш. Яңавылда каласы килми. Монда рәтле эш тә юк. Читкә китәсе килә, кеше буласы килә.

«Читкә китәсе, кеше буласы килә...» — диде Фәрхәнә апа да үз алдына. Ул инде белә мондый нәрсәләрне. Заманында үзе дә шулайрак фикер йөртте. Үз илендә, үз җирендә берни юк, читтә генә тутырып куйганнар сыман тоелды. Юк, читтә дә тутырып куймаганнар. Читтә мондагыдан да авыррак, кыенрак булачак. Кайда гына җиңел соң ул?! Шулай да хәзер аның бу турыда сүз куертасы, яшьләрнең болай да иләс-миләс күңелләрен кырасы килмәде.

— Сез нишләргә уйлыйсыз? — диде ул Сәкинәгә эндәшеп.

— Белмим әле, Фәрхәнә апа, — диде Сәкинә теләр-теләмәс кенә.

— Нишләп белмисең?! — диде Җәмилә. — Менә шушы тиле Җәмилә белән Казанга медицинскига китәргә ниятләп торабыз диген, яр да сал!

— Аны син ниятлисең, мин түгел, — диде Сәкинә үзсүзләнеп.

— Кит, билләһи газим! Бу кадәр булгач та булырсың икән! — диде Җәмилә дусын оялтмакчы булып.

— Яңавылда чәйханә ачам, шуның директоры булам, — диде Назиф остарып.

Кызлар тагын көлешкән булдылар. Назифның көтмәгәндә шулай берәр тапкыр сүз әйтеп көлдерә торган гадәте бар иде. Әйткән сүзе бик үк көлке булмаса да, кызлар аның һәр сүзеннән көләргә генә торалар иде.

— Мине официантка итеп алырсың, яме? — диде Нәзирә Назифның авызына керердәй булып.

— Тапты! Сине генә аласы килеп торадыр, — диде Галимә. — Аның үз официанткасы бар ич!

Барысы да пырхылдап көлеп җибәрделәр. Назифның шат йөзе сүрелеп калды. Җәмилә исә артына борылды да Галимәгә күзен акайтып алды.

— Чәйханәдә синең эшләр тәгәри инде, иеме, Назиф! — диде Галимә, Җәмиләнең ачулы күз карашына әз генә дә исе китмичә. — Безнең аяк очка сазлыкка йорт салырсың, сыер алырсың, үрдәк үрчетерсең.

— Чучка симертерсең, — дип куйды Сәкинә дә. Яшьләр тагын көлешергә тотындылар.

— Юк, мин чучка да симертмим, үрдәк тә асрамыйм, — диде Назиф җитди итеп. — Чучканың исеннән җирәнәм. Сез мине көферлеккә этәрәсез. Татар чучка асрамый, үрдәк тотмый. Иң яхшысы мин корт асраячакмын. Минем, Фәрхәнә апа, беркая аягым тартмый. Барысы да институтка китеп бетсә, Яңавылда рәтле кеше дә калмас.

— Син каласың ич рәтле кеше булып, — диде тагын да Сәкинә.

— Аңа бит чәйханәгә йөрүче кеше дә кирәк булачак, — диде Нәзирә.

— Чәйханәгә рәтсез кешеләр йөрсә дә ярый, директоры гына рәтле булсын, — диде Фәнәви, Назифны яклаган булып.

— Юк, иптәшләр, чәйханәдә эш бармый. Акча да төшми, өскә чыгарга гына тора. Лутчы мин үзебезнең Эткенәвылга кайтып, Җаббаров абый урынына колхоз персидәтеле булам! — диде Назиф. — Йөрәк әрни. Колхоз күтәрәмдә. Халык ач-ялангач. Сез менә барыгыз да шәһәргә качып бетмәкче буласыз. Кем туйдырыр сезне?

— Син! — диде Сәкинә.

— Акылыгыз алтын икән! — диде Назиф. — Менә шулай качышып беткәнгә күрә авылда җүнле кеше юк.

Яшьләр тынып калдылар. Назифның чын күңелдән сөйләвен һәркем яхшы белде. Аңа каршы ни дә булса әйтеп тә булмый, аның

сүзләрен көлкегә әйләндереп тә булмый иде. Бу бик авыр һәм катлаулы мәсьәлә иде. Бүген андый мәсьәләләрне искә төшермәгәндә дә яхшы булган булыр иде. Ләкин нишлисең, Назиф шундый инде. Назиф — авыл малае, чын авыл малае.

Шулай да, бара торгач, яшьләр сүзне яңадан уенга борып җибәрделәр һәм булачак колхоз персидәтеленнән төрлечә көләргә тотындылар. Арада бер генә кеше — Габделхәй генә тупас шаяртуларга, тупас хыялларга катнашмаска тырышты. Аның киләчәге башкаларныкы кебек томанлы, икеле-микеле түгел. Туып килгән яңа көн кебек якты һәм аяз. Аның өчен бар нәрсә ачык һәм аңлаешлы. Менә шундый чакта нниндидер чәйханәләр, чүчкалар, үрдәкләр турында сөйләү — хәтта шаяртып кына сөйләү дә! — аның өчен күңел рәнҗеткеч бер нәрсә булып тоелды. Бу әле бүтәннәрнең киләчәгенә кагылганда шулай. Әгәр дә мәгәр мондый нәрсәләр аның үз киләчәгенә кагылышлы рәвештә сөйләнелсә, аның өчен бу мең мәртәбә авыр һәм күңелсез булыр иде. «Ярый әле мин Назиф түгел», — дип уйлады ул күңеленнән сөенеп.

Тик шулай да аның да киләчәге ал да гөл түгел. Беренчедән, әле булса аның күңелен медаль тырный. Дөрес, өлгергәнлек аттестатында барлык фәннәрдән дә — «отлично». Ләкин шул ук вакытта... Эх, искә дә төшерәсе килми! Аннан соң, Василий Михайловичның татар мәктәпләре, татар теле, татар әдәбияты турындагы сүзләре дә аны бик нык борчуга салды. Ул, билгеле, аның бер генә сүзенә дә ышанмады, тик шулай да җитәкчеләр тарафыннан татар теленә карата булган мөнәсәбәтне күрмәде-белмәде түгел. Болардан башка да кайгы-борчулар җитәрлек. Бүтәннәр кебек ул да газитләрдән иң элек белдерүләр укыды, кайда нинди институт барлыгы белән, кайда нинди фәннәрдән имтиханнар тапшырырга кирәклеге белән кызыксынды. Аннан да бигрәк ул институтларның кемнәрне әзерләп чыгаруларына игътибар итте. Институтларның барысына да диярлек агрономнар, инженерлар, конструкторлар, укытучылар, медиклар, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр әзерләнә диелгән. Тик аларның берсендә дә әдәбиятчы, шагыйрь дигән кеше әзерләп чыгарыла диелмәгән. Бик гаҗәп нәрсә иде бу. Аныңча, Казанда һичшиксез татар шагыйрьләрен җитештерә торган ниндидер уку йорты булырга тиеш иде. Ләкин Габделхәй, Разия апа янына кереп, Казаннан килгән татарча газитләрне никадәр җентекләп укымасын, берничек тә андый институт барлыгын белә алмады. Бу хакта аның кемнән дә булса сорыйсы килмәде — сорадың исә, «Шагыйрь буласы кеше, шуны да белми», — дип көләрләр сыман тоелды.

Габделхәйнең бернигә катышмый баруына иң элек Фәрханә апа игътибар итте.

— Нишләп тынып калдың әле, Габделхәй? — диде ул. — Син кая китәргә, нишләргә җыенасың?

— Кая булсын — Казанга, шагыйрьләр янына! — диде Җәмилә Габделхәй өчен җавап биреп.

— Башта берәр атаклы язучыга самавырчы малай булып керер инде, — диде Назиф, шундук элеп алып.

— Юк, башта Әхмәт байга приказчик булып керергә туры киләчәк аңа, — диде Нәзирә.

— Әхмәт бай кармагына барып капкач, шагыйрь булалмый инде ул, — диде Фәнәви.

— Бай абзыйның кызына өйләнеп җибәрсә, шагыйрь булып торасы да юк, — диде Назиф.

— Әхмәт байны Әмрикәгә качып киткән диләр бит, — диде Габделхәй, иптәшләренең шаяртуына җайлашып.

— Китсәни! Син дә шунда китәрсең, — диде Назиф.

«Надан!» — дип уйлады Габделхәй дусы турында. Кем сине Әмрикәгә җибәрсен?! Шулай да уендагысын кычкырып әйтмәде — алар бит мәңге дустату булырга ант бирделәр!

— Мин, әйдә, Мәскәүдән ары китеп йөрмәм инде, — диде ул.

— Мәскәүгә?! — диде Фәрхәнә апа, чын гаҗәпләнеп. Ул, ахрысы, яшьләрнең сүзенә бик үк игътибар да итми иде. — Иң яхшысы Казан инде сиңа, Габделхәй.

— Без дә шулай дибез бит, Фәрхәнә апа, — диде Җәмилә. — Габделхәй Казанга барып урнашса, безне дә тарттырып алмас микән дибез.

— Алды, күтәп тор! — диде Назиф. — Казанга бер барып урнашса, бөек татар шагыйре Хаптел-эл-Хай безнең ишеләргә сәләм дә бирми инде ул!

Бу Назиф бер остара башласа, һич туктый белми. Шуңа күрә яның шаяртуы еш кына үзара бозылышу белән тәмамлана да. Хәзер дә аның шулай үзен шәп кеше итеп тотуы, туктаусыз үзеннән көлүе Габделхәйнең кытыгына тиде. «Синең ише персидәтелләргә әйләнеп тә карамасыем! — дип әйтәсе килде аның, ләкин әйтмәде, тагын кичәге антлары исенә төште. Аннан соң алар инде Фәрхәнә апаларның өйләренә якынлашып киләләр иде.

— Их, килеп тә җиттек! — диде Җәмилә үкенү белән.

— Киттек кирегә! — диде Назиф.

— Персидәтел булгач та бу безне гел үзе артыннан ияртеп кенә йөрмәкче була, — диде Габделхәй.

— Кире китеп тормыйк инде, әйдәгез, безгә кереп чәй эчеп чыгыйк, — диде Фәрхәнә апа.

— Юк, юк, кермибез!

— Рәхмәт инде, Фәрхәнә апа! — диештеләр яшьләр.

Ләкин аерылышып китә алмыйча озак кына саубуллашып тордылар. Һәркемнең әйтелми калган ниндидер кадерле, бик кадерле сүзләрен әйтәсе килде. Ләкин кадерле, иң кадерле сүзләр дә иң гадәти саубуллашу сүзләре булып чыкты. Кызлар, аналарына елышкан иркә балалар кебек, хискә биреләп, Фәрхәнә апага елыша төштеләр, берсе бер яктан, икенчесе икенче яктан аның күкрәгенә капландылар. Фәрхәнә апа аларның башларыннан, аркаларыннан сыйпады, юату сүзләре әйтте.

— Фәрхәнә апакаем! Шундый яраттык без сине! — диде Җәмилә балаларча сулкылдап.

— Килеп йөрегез, ташламагыз, — диде Фәрхәнә апа.

— Килербез, Фәрхәнә апа, — диде Җәмилә, яшьле күзләрен сөртеп, көләргә тырышып. — Әллә нәрсә булды, Фәрхәнә апа. Кичәдән бирле җылыйсым килә.

Кызлар укытучы апалары белән кочаклашып җылашканда малайлар тын гына читтә басып тордылар. Менә кызлар да әкрен генә, иплап кенә кузгала башладылар. Артларына карый-карый малайлар да кузгалды.

— Габделхәй! — диде Фәрхәнә апа китеп баручылар ягына эндәшеп. — Оныткамын, вакытың булса, килеп чык әле бүген.

— Ярар, килермен, — диде Габделхәй.

— Сау булыгыз! Сау бул! — диде капка төбендәге Фәрхәнә апа, еракла-ша барган «иптәшләр»гә кул болгап.

## Икенче бүлек

### I

Үз артыннан капканы ябып, иркен ишегалга килеп керү белән, Фәрхәнә апаны башка төрле уйлар биләп алды. Иң элек ул Дәүләтгәрәй абзыйны исенә төшерде — «Йокыдан тора алды микән, сыерны савып көтүгә чыгара алды микән?» — дип уйлады. Аннары Йосыф исенә төште. Йосыф бүген төнлә балыкта булырга тиеш иде. Кайтты микән? «Берәр нәрсә алып кайта алды микән?» — дип тә уйлады.

Чолан ишеге ярым ачык иде — димәк, көтү киткәндә йоклап калмаганнар. Фәрхәнә апа туры өйгә кереп тормады. Күңелен тынычландыру өчен иң элек абзар капкасын ачып карады. Капканы ачу белән, борынына җылы тирес катыш чи печән исе килеп бәрелде. Абзар буш иде. Бары тик түбә астындагы печәнлектә бер тавык кына дөнья бетереп, тавыш куптарып кытаклап ята иде. Абзарга күз ташлап алгач, Фәрхәнә апа бакча ягына керде. Бакчаның аргы башында бәрәңге арасында тибенеп йөргән күрше тавыкларын куалап чыгарды да, үзе югында йорт-җирнең исән-имин торуына тәмам ышанып, күңеле тынычланып, өйгә керде.

Ул өйгә килеп кергәндә Дәүләтгәрәй абзый кече якта мич алдында самавыр куярга азапланып ята иде.

— Йосыф кайттымы? — диде Фәрхәнә апа беренче сүзе итеп.

— Кычкырма шул чаклы! — диде Дәүләтгәрәй абзый пышылдап, ярым йокылы тавыш белән.

— Ни булды тагын? Йоклыймыни? — диде Фәрхәнә апа, иренең кисәтүенә артык исе китмичә.

Дәүләтгәрәй абзый җавап биреп тормады, самавырын көйләп яндырып җибәрде дә Фәрхәнә апаның беләгеннән тотып алды һәм «әйдәле, әйдә!» дигәндәй, серле бер кыяфәттә аны олы якка алып чыкты.

Алты почмаклы өйнең артыдан күбрәген алып торган олы якның түрендә, никельле караваг янында ниндидер ят чемодан тора иде. Караватта исә, түшәмнән идәнгә кадәр салынып торган бизәкле чаршау артында, йомшакта, кара чәчләре тәртипсез рәвештә таралып төшкән ниндидер яшь кыз йоклап ята иде. Дәүләтгәрәй абзый әлеге кызны Фәрхәнә апага күрсәтеп алды да, күз тиюдән курыккан сыман, чаршауның ачык калган итәген җыештырыбрак куйды. Чаршау эченнән шәһәрчә ят исләр катыш җылы тән, җылы тын исе килеп бәрелде.

Фәрхәнә апаның йөзе балкып китте.

— Былбыл түгелме соң? — диде ул пышылдап.

— Былбыл дисәң дә ярый, сандугач дисәң дә ярый, — диде Дәүләтгәрәй абзый.

Аяк ачларына гына басып алар читкәрәк киттеләр. Ләкин никадәр сак һәм йомшак атларга тырышмасыннар, ике авыр кешенең артыннан идән сайгаклары шыгырдап калды. Йомшак түшәккә чумып яткан кыз йокы аралаш нидер сизенеп, нидер ишетеп, урынында кыймылдап куйды. Аннан соң аякларын сузып җибәрде, күзләрен ачты. Өстендәге авыр ябынгычын бер якка селтәп ташлады да торып утырды, бер кулы белән чаршауга тотынып, икенче кулы белән караваг башындагы күлмәкләргә үрелде. Киенеп алгач, ялан аяк килеш тып итеп идәнгә басты. Идән такталары ап-ак, тигез һәм шома иде.

Кызның аягына басканын күреп Фәрхәнә апа кире олы якка чыкты. Ашык-пошык чәчләрен рәтләп, иртәнге кояш сыман балкып-елмаеп Былбыл Фәрхәнә апага таба атлады һәм яшь, кайнар беләкләре белән аның тыгыз тәнен кочып алды.

— Чибәрттәй! Исәнме, чибәрттәй! — диде ул сандугачныкыдай шат тавыш белән сайрап.

— Карале, Былбыл! Нинди үскән, танырлык та түгел! — диде Фәрхәнә апа исе китеп.

Былбыл җавап итеп көлеп җибәрде.

— Өйдәгеләр тазамы-саумы? — диде Фәрхәнә апа.

— Барысы да исәннәр, кү-үп итеп сәлам әйттеләр, — диде Былбыл бөтен өй эчен күңелле шау-шу белән күмеп.

— Әти дә, әни дә исән, барысы да исән-сау, — диде Былбыл. — Отпускаңы икесе дә көз көне алачаклар, икәүләшеп Кисловодскига китәчәкләр. Әни әйтте, чибәрттәңне минем өчен дә үп диде, менә шулай, менә шулай итеп үп диде...

Былбыл, әнисенең ничек итеп үбәргә кушканлыгын күрсәткән сыман Фәрхәнә апаның әле бер як битеннән, әле икенче як битеннән үбеп-үбеп ал-

ды. Фәрхәнә апа, әлерәк кенә үзенең укучылары янында уңайсыз елмаеп торган кебек, бу юлы да елмаеп тик торды.

Олы якның ачык ишегеннән керергә кыймыйча торган Дәүләтгәрәй абзый үзенчә шаярткан булып:

— Картайдык. Үбү түгел, кызлар хәзер безнең якка әйләнеп тә карамыйлар,— диде.

— И-и, җизнәкәй, сине күргән дә юк,— диде Былбыл сөенеп.

— Кайчан килдең, ничек килдең?— диде Фәрхәнә апа.

— И-и, чибәрттәй, мин инде кичәгенәк үк килеп җитәргә тиешием,— диде Былбыл, нindидер күңелсез нәрсәне исенә төшермәкче булып.

Ләкин бу минутта аның йөзендә әз генә дә күңелсезләнү билгесе күренмәде. Аның йөзе, күз карашы, бөтен кыяфәте ташып торган шатлык-куаныч белдерде. Нindидер күңелсез нәрсә турында әйтергә тиешле сүзен ул азагына кадәр әйтеп бетермәде, шундук әтисенә күчте, аның әледән-әле авырып китүе турында, әле күптән түгел генә больницада ятып чыгуы, хәзер инде рәтләнә башлавы турында тизеп китте. Әтисенең бик каты авыруы турында әйткәндә дә аның йөзендә әз генә дә кайгы-борчылу сизелмәде. Ул, әйтерсең, гомумән күңелсезләнә белми иде, ул, әйтерсең, бары шатлана гына, бары көлә-елмая гына белә һәм шунлыктан үзе янындагы бар нәрсәгә яктылык, гүзәллек кенә тарата иде.

## II

— Бүген мин таң тишегеннән килеп кердем сезгә,— диде Былбыл туктаусыз сөйләнеп.— Җизнәйне ныклап күрмәдем дә әле...— Шул чакта ул ишектә елмаештырып басып торган җизнәсенә карап алды да, өзелгән сүзен дәвам итеп:— Исәнме, җизнәй... тагын бер исәнләшик әле,— диде.— И-и чибәрттәй, мин индә кичәгенәк үк килеп төшкән булырыем. Беренче көнне билет алып булмады. Килгәндә машиналары ватылды. Ике якта да урман. Туктадык та утырабыз... Син кайда булдың, чибәрттәй? Җизнәй әйткәние — мәктәптәме? Мәктәптә, әйе? Вечер булдымы? И-и чибәрттәй, и-и җизнәй!.. Шофер сүгенә. Машинаны сүгә, начальствоны сүгә. Ачуым килеп бетте шуңа. Төштек тә җиләк эзләргә тотындык. И-и чибәрттәй, җиләк шундый күп! Рәхәтләндек. Кайчан җиләккә барырбыз икән? Гел шуны уйлап килдем. Әйдәгез бүген үк?! Менә бер заман шофер кычкыра башлады... пип-та-пип! Ачуым килеп бетте шуңа. «Әйдәгез, киттек!» — ди. Тотындык чабарга. Ботакка эләгеп, бер хатынның күлмәк итәге җыртылды. Үзем йөгерәм, үземнең көләсе килә.

Ул тыныбрак торган арада Фәрхәнә апа бер-ике сүз кыстырып куйды:

— Карамый йөрсәң, шулай була ул.

— И-и, чибәрттәй, кая ул анда карап йөрү?! Пип-та-пип! — кычкырта да кычкырта. Ачуым килеп бетте шул шоферга,— диде кунак кызы һәм җыртылган күлмәк итәген күз алдына китереп, ахрысы, рәхәтләнеп көләргә тотынды.

Шуннан соң ул нидер исенә төшеп, ашыгып кече якка китеп барды, каяндыр бик ерактан үзенең туган якларын сагынып кайткан кеше сыман, өй эчендәге бөтен нәрсәне күздән кичерде, әледән-әле исе китеп: «Карале, кара! Нинди матур!» — диде, тәрәзә төбендә шау чәчәктә утырган тамчы гөл янына килде дә, беренче мәртәбә күргәндәй, аһылдап җибәрде, иснәп карады, нәфис бармаклары белән гөлләргә кагылгалап алды. Шуннан соң яңадан үзенең юлда күргәннәрен сөйләргә тотынды.

— ...Килеп җиттек тә, чибәрттәй: «Булдымы, киттекме?» — дибез...— Бу вакытта кунак кызы су чәчрәтә-чәчрәтә кече якта битен-күзен юарга тотынган иде.— «Булды»,— ди, машина астыннан кычкыра. Юри чакырган икән. «Берәрегез ручканы әйләндерегез әле»,— ди. Бу безне шуның өчен чакырган икән. Ачуыбыз килеп бетте шуңа. Әллә ничаклы маташтты шул машина-

сы белән. Караңгы төшә башлады... Туктале, Йосыф кая соң? Мин аны күрмәдем, чибәрттәй.

— Мин дә күрмәдем әле,— диде Фәрхәнә апа.— Балыкка киткән бугай ул.

— Пассажирлар сукрана,— диде Былбыл, битен сөртә-сөртә, чибәрттәсенең сүзләрен тыңлап та тормыйча.— Ух та вах киләләр, хәерсез юлга чыктык, диләр, төн кунарга туры килә инде, диләр. Миңа кызык. Машинасын төзәтә алмасыные, мин әйтәм, төнне шушында кунарыек, мин әйтәм. И-и, чибәрттәй, тәки теләгем кабул булды!— диде ул һәм кинәт көлеп җибәрде.

— Җүләр,— дигән булды Фәрхәнә апа.

— Әйтмәсәң дә җүләр инде,— диде Былбыл бик тиз килешеп.— «Җүләр»не ул үзенә карата әйтелгән мактау сүзе дип белде, ахрысы.— Төнлә урманда адашып йөрергә яратам мин, чибәрттәй! Минем әле төнлә Агыйделдә су кергәнем дә бар. Быел әни җибәрмәде. Куркыталар. Нәрсәдән курkalардыр, исең китәр!

— Уфа автобусы кичке биштә килә түгелме соң?— диде Дәүләтгәрәй абзый, сүзгә катышып.

— Биштә,— диде Былбыл.— Без төнге өчтә килеп төштек. Таң атканда. И, шундый матур таң атканда! Таң атканны күргәнең бармы синең, чибәрттәй? Икенче мәртәбә беркайчан таң атканда йоклап ятмаячакмын.

— Алайса синең йокың да туймагандыр инде,— диде Фәрхәнә апа.

— Туймаса тагын!— диде кайгыра белми торган кунак кызы, үз-үзеннән көлеп, чак-чак кына масаеп.— Машинада килгәндә дә йокламадым мин, гел тирә-якны карап килдем. Нинди матур сезнең яклар! Мин гел сездә генә торырыем, чибәрттәй!

Сүзен әйтеп бетерер-бетермәс ул яңадан олы якка чыгып китте, әле бер тәрәзә янына, әле икенче тәрәзә янына килде, узышлый гына тагын бәләкәй өстәлдәге бәләкәй көзгегә карап алды, чәчләрен төзәткәләде, аннан соң бакча ягындагы тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде дә тәрәзәдән башын тыгып:

— И-и, чибәрттәй!— диде.— Нинди күңелле, нинди тыныч сездә! Былтыр килгәндә сезнең өегез кечкенәе, тәбәнәк кенәе. Хәзер шундый иркен...

— Былтыр түгел, былтырдан элекке җыл,— диде Фәрхәнә апа төзәтеп.— Ул чакта син үзең дә кечкенә идең.

— Мин беркайчан кечкенә булмаганмындыр кебек,— диде Былбыл.

— Бик ускәнсең, үзгәргәнсең,— диде Дәүләтгәрәй абзый да кызны мактап.

— Бик ускәнсең, үзгәргәнсең,— диде Дәүләтгәрәй абзый да кызны мактап.

— Чынлапмы, җизнәй?— диде Былбыл һәм кырт кына җизнәсенә таба борылды да бөтен бите-күзе белән, бөтен килеш-килбәте белән балкып, нур чәчеп, елмаеп җибәрде.

— Чынлап булмыйча! Син хәзер — студент. Элек килгәндә укучы гына идең,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Үземне бер дә студент итеп сизмим әле,— диде Былбыл чак-чак кына күңелсезләнгәндәй итеп.

— Имтиханнарыңны бирдеңме соң?— диде Фәрхәнә апа.

— Бирдем,— диде Былбыл, артык исе китмичә.— Тиз-тиз генә бирдем дә, үзебезнең Уфага кайтып киттем. Анда бер-ике көн тордым да менә монда килдем.

— Ничегрәк бирдең соң?— диде Фәрхәнә апа, төпченеп.— Син инде анда да яхшыга укыйсыңдыр?

— «Яхшы» түгел, «отлично». Барысы да «бишле». Ошамый миңа анда. Кешеләренә, шәһәрләренә иялəшә алмыйм. Яратмыйм Казаннарын, гел үзебезнең Уфаны, Агыйдел буйларын сагынам. Сезне сагынам.

— Шулай булмыйча, Казанның аның бернинди яме юк,— дип куйды Дәүләтгәрәй абзый, кунак кызының салпы ягына салам кыстырып.

— Шулаймы, җизнәй? Шулай бит, иеме, безнең Уфа матуррак бит, иеме? — диде Былбыл сөенеп.

— Шулай булмыйча! — диде тагын да Дәүләтгәрәй абзый.

Дәүләтгәрәй абзыйның яшь чагы Уфада узды. Ул анда техникумда укыды, курсларда укыды. Эше кушканга ай саен диярлек аңа Уфада булырга туры килә иде. Шунлыктан Уфа аңа таныштрак та, якынрак та иде. «Казан кызы» Фәрхәнә апа белән алар, уенын-чынын бергә кушып, кайчагында, Уфамы, Казанмы матуррак, ямьлерәк, дип җиңелчә генә бәхәсләшеп тә алгалыйлар иде. Хәзер дә Фәрхәнә апа иренең Уфаны мактаган булып Казанга тел тидерергә чамалавын сизеп алды һәм алдан ук үзенең бу мәсьәләгә мөнәсәбәтен белдерергә кирәк тапты.

— Уфаны хурлыйсым килми, шулай да Казан яхшырак, — диде ул ярым шаяртып.

— Теләсәң нәрсә әйт — Уфа Уфа инде, — диде Дәүләтгәрәй абзый да, бирешәсе килмичә.

— Ура! — диде Былбыл, балаларча кул чабып. — Чибәрттәй җиңелде!

— Ярар, хәзергә җиңелдем, — дигән булды Фәрхәнә апа, бик тиз килешеп.

Шуның белән бу турыда сүз дә бетте, бәхәсләшер җай да калмады. Былбыл тынып калды. Ләкин күп тә үтмәде, яңадан җанланып китте, ашыгып кече якка чыкты, шаулап утырган самавыр торбасын калкытып карады — торбадан төтеннең ничек чыгуын күрәсе килде, ахрысы. Ул арада өйгә ачы төтен исе таралып өлгерде.

— И, җүләр, — диде Фәрзәнә апа.

— Җүләр шул, — диде Былбыл, көлеп. — Мин аны янмый дип торам. Самавыр шаулавы ошый миңа, төтен чыгуы... Бөтен нәрсә ошый миңа. Сездә рәхәт. Суга барып килимме, чибәрттәй? — диде ул кинәт мич янындагы буш бидәрәгә күз төшереп. — Нинди эшегез бар, әйтегез.

— Бакчага күрше тавыклары кермәде микән — бар, куып чыгар, алайса, — диде Фәрхәнә апа.

### III

Мәктәп белән, сөекле укытучылары белән аерылышу тәэсиреннән тиз генә арына алмаган яшьләр беркадәр җир тын гына, моң гына атлап бардылар. Шулай да мондый тынлык, моңсулык озакка сузылмады. Беренче булып тынлыкны Җәмилә бозды һәм барысы да берьюлы диярлек дөнья хәлләре турында яңадан сүз башлап җибәрделәр. Дөнья хәлләре әлеге дә баягы бер үк нәрсәгә, — «зур тормыш»ка аяк баскач нишләргә, кая ничек атлап китәргә, дигән топ мәсьәләгә барып терәлде. Берәүләр моңа җиңел караган сыман тоелды, күптән инде эчен тырнаган нәрсәне уен-көлке белән алыштырырга тырышты. Икенче берәүләр исә уфтанырга, кайгырырга тотынды. Күпчелек беркемгә катышмыйча, эндәшмичә калуны артыграк санады.

Алар шулай бер зур төркем булып, әлегрәк бик үк сизелмәгән якынлык, туганлык тойгысы белән, Яңавылның яртылаш чирәм баскан киң урамыннан бардылар да, Сталин клубы янындагы бакчага якынлаштылар. Сталин клубы да, бакча да күпләрнең танышу, очрашу һәм аерылышу урыны исәпләнелә иде. Клубка житәрәк алар туктап калдылар. Кемдер бакчага керергә, шунда сөйләшеп утырырга тәкъдим итте. Ләкин анда кереп сөйләшер сүз дә, теләк тә юк иде инде, ахрысы. Шулай бераз вакыт таптанып, икеләнеп торганнан соң теләр-теләмәс кенә таралыша башладылар. Назиф белән Фәнәви Эткенәвылга кайтып киттеләр. Истәкләр — Истәккә, Уразылар — Уразыга юнәлделәр. Җәмилә, Сәкинә, Нәзирә Яңавылның бер ягындарак торалар иде. Кызлар бер-берсен култыклап алдылар, карлыгын беткән тавышлары белән «Гөлмәрфуга»ны көйли-көйли, шулай ук кузгалып киттеләр. Габделхәй дә аларга иярде. Ярты юлда Нәзирә үзләренә кереп калды. Бер-берсенә

үпкәләшкән сыман. Җәмилә белән Сәкинә дә, Габделхәй дә бик озак берни эндәшми бардылар. Беренче булып Габделхәй телгә килде.

— Кызлар янында болай бару килешми инде, — диде һәм Җәмилә белән Сәкинәнең икесен ике яктан култыклап алмакчы булды.

Сәкинә шундук кулын тартып алды, читкәрәк тайпылды. Җәмилә алдында аның шулай киреләнүе Габделхәйнең хәтерен калдырды.

— Ярар болай да, — диде Җәмилә дә, Сәкинә кебек үк читкә тайпылып.

Башланып китә язган сүз башланмый калды. Кыен, күңелсез бер тынлык барлыкка килде. «Соңгысы булсын! Моннан соң мин сине беркайчан озатып куймаячакмын», — дип уйлады Габделхәй Сәкинә турында. Алдан килешенгән сыман, ләкин бернинди килешү булмаса да, Сәкинә белән Җәмиләне ул өйләренә кадәр озатып куярга тиеш сыман иде. Иң четереклесе шунда — Сәкинәләрнең өе якынрак, Җәмиләләрнеке арырак иде. Хәзер ул ничегрәк хәл итәргә дә белмичә барды. Яңадан сүз башлап карады, ләкин бу юлы да сүз ялганып китә алмады. Аның хәлен аңлагандай, шул чакны Җәмилә туктап калды һәм беркемгә дә атап әйтмичә генә саубуллаша башлады.

— Тукта! Без сине озата барабыз ич! — диде Габделхәй каушагандай итеп.

— Рәхмәт. Кифая түтиләргә кереп чыгасым бар — өйдә микән, фермада микән, — диде Җәмилә.

Шулай диде дә, кызу-кызу атлап, якындагы тыкрыкка таба китеп барды. Шушы тирәдә аның, чыннан да, бертуган апасы тора иде.

Сәкинә белән Габделхәй ни әйтергә белми аптырап тордылар да берни эндәшмичә кире борылдылар. Сәкинәләрнең өе икенче яктарак калган иде.

— Никтер үпкәләгән, — диде бераздан Сәкинә.

«Синең кебек», — дип әйтмәкче булды Габделхәй, ләкин әйтмәде — баягы ярсуы онытылган иде инде.

## IV

Көн якты иде, кояш кыздыра иде. Урамнарда берән-сәрән атлылар, җәяүлеләр очрады. Парлашып, серләшеп йөрү өчен һич тә уңай вакыт түгел. Шулай да нидер сөйләшергә, аңлашырга кирәк иде. Чөнки моннан соң очрашу өчен бернинди сәбәп тә булмаячак. Сәкинәне өйләреннән чакырып чыгару, бакчага-фәләнгә, кинога-театрга алып бару мөмкин дә булмаячак. Күптән инде Габделхәй үзенең сөйгән кызы бар дип исәпли иде. Үзенә бик күңелсез чакларда ул аңа үзенең эч серләрен сөйли, аның белән кайгы-шатлыкларын уртаклаша иде. Кисәк кенә очрашмый, серләшми башласалар, аңа, күрәсең, бик кыен, бик авыр булыр иде.

Сәкинә белән янәшә атлап барганда ул беренче мәртәбә шул турыда уйлады һәм вакытның шундый тиз үтүенә, имтиханнарның шулай тиз бетүенә чын-чынлап үкенү хисе кичерде. Ләкин, үкенсәң дә, үкенмәсәң дә, хәзер инде берни эшләп булмый. Үткән вакытны, үткән имтиханнарны, үткән ун елны, хәтта менә кичә генә, бүген генә булган күңелле очрашуларны кайтарып та булмый. Адәм баласының һәр адымы, һәр сулышы күз алдында — сизелеп, күренеп! — артта кала, үлә һәм югала бара. Шулай ук Сәкинә белән бергә булган серләшүләр дә үлгән-югалган. Хәзергечә менә шулай эндәшмичә үпкәләгән сыман барулар да үләр, онытылыр микәнни? Нинди кызганыч!

Аңа кинәт моңсу булып китте. Күңеленә берәр уй килде исә, шул кечкенә уен үстерә-үстерә, ул әллә нинди нәрсәләргә барып җитә һәм нәтиҗәдә очына-кырыена чыга алмаслык уй-хыяллар арасына кереп бутала да аптырап туктап кала иде. «Нишләп миңа үткән гомер кызганыч булып тоелды икән соң әле?» — дип уйлады ул бераздан. «Сәкинә белән аралашу кызганыч миңа», — диде ул аннары уй җебенең очына чыгып. Җәмилә дә кызганыч. Бик кызганыч. Ләкин кайсы кызганычрак соң?

Шул ук минутта диярлек Сәкинә туктап калды һәм философ юлдашының катлаулы уйларын бүлдереп, гади генә итеп:

— Бар инде кайтып кит, — диде.

Алар үзләренең гадәттәге чик буена — туктый торган таныш җиргә килеп җиткәннәр иде. Бу — урам чаты, урам чатындагы амбар почмагы иде. Юл ягына чыгыбрак торган, бүрәнә башларына арба тәгәрмәчләре ышкылып киткән, сыерлар, сарыклар ешынып, тәкләр, җөннәр эләгеп калган амбар почмагы иде бу. Монда якында гына Яңавылның май заводы урнашкан һәм әлеге урам якка чыгыбрак торган амбар да май заводына карый иде.

Монда, акка буялган тәбәнәк ялгыз йорт ягында, һәрвакыт гүелдәп сипарат әйләнгәне, кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне, шакы-шокы китереп тимер бидоннар күчергәне ишетелеп тора. Җәен-көзен, хәтта язын-кышын шул яктан, саф һаваны бозып, ачыган-купчегән сөт-эремчек, әйрән исләре килә. Ләкин мондагы гүелдеккә, ят, авырсы исләргә Габделхәй инде күптән күнеккән. Сәкинәне озатып куюының беренче көнендә үк аңа дөньяда май заводы булган җирдән дә матуррак бер җир дә юктыр сыман булып, купчегән сөт-эремчек исләреннән дә татлырак бер ис тә юктыр сыман булып тоела башлаган иде. Бу почмак артында, моннан бер йөз адымнар чамасы читтәрәк Сәкинәләрнең шомырт куаклары арасында бәләкәй генә өйләре балкып утыра. Кызын озата килгәч аның әле бер генә мәртәбә дә шушы амбар почмагыннан ары узганы булмады — узарга рөхсәт юк.

Сәкинәнең инәсе авыру. Түшәк өстендә ята. Әтәсе элеваторда атлы эштә эшли. Өйдә Сәкинәдән башка кул арасына керердәй беркем юк. Бөтен йорт эше, инәсен карау-тәрбияләү тулысынча Сәкинә җилкәсендә. Йорт эшләре күп — сыерлары, сарыклары бар, зур гына бәрәңге бакчалары бар. Шуның өстенә тагын аларда ике бала ята. Аларны карау, көн дә бакчага илтеп кую, бакчадан алып кайту шулай ук Сәкинәгә йөкләтелгән. Кайчан гына булмасын, мәктәптән кайтуына аны таудай эш көтеп тора. Сәкинәнең хәлен аңлаганга күрә, озата килгәч, Габделхәй аны беркайчан тоткарламаска тырыша.

Бүтән көннәрдә шулай булды. Бүген аның тиз генә аерылышасы килмәде. Сәкинәгә хәзер ниндидер бик кирәкле, бик кадерле сүз әйтәсе килде, аның белән ныклабрак сөйләшәсе килде.

— Туктале, китмәле, — диде ул кызның кулыннан тотып.

— Җибәр, — диде Сәкинә.

Тик шулай да тавышында башка көннәрдәге кебек кискенлек, кирелек сизелмәде. Аның бу «җибәр»ендә хәтта якынлык, җылылык та бар иде бугай. Моңарчы үзенең кызыннан кирле-мырлы сүзләр генә ишетергә күнеккән Габделхәйне мондый җылылык, якынлык дәртләндереп җибәрде.

— Әйдә тагын бераз йөреп килəбез, — диде ул.

Иплəп кенә, куркып кына ул аның йомшак кулына тотынды, яратып аны үзенә табарак тартты. Габделхәйнең ихтыярына буйсынып Сәкинә сүзсез генә урыныннан кузгалды һәм алар, амбар почмагы яныннан кузгалып, читкәрәк китеп бардылар.

Габделхәйнең үз гомерендә беренче җиңүе булды, ахрысы, бу, беренче мәртәбә кызны үзенә буйсындыруы һәм беренче мәртәбә... буйсынуы да булды, ахрысы. Һич югы, аның үзенә бу шулай тоелды, чөнки моңарчы аларның яратышулары бер-берсе яныннан сүзсез генә атлап барудан ары узмады. Бу хәтта чын мәгънәсендә яратышу да түгел иде бугай. Моңарчы ул һәрвакыт кыз артыннан үзе тагыла һәм янәшә атлап барганда да аннан чакчак кына артка калып бара торган иде. Хәзер ул аны үзе ияртеп алып китте. Хәзер ул үзендә яңа көч-куәт барлыкка килгәнен тойды.

Беркадәр алар кулга-кул тотынышып бардылар. Шулай да Сәкинә кулын ычкындырырга кирәк тапты — урамда таныш-белешләр очрап куярга мөмкин иде.

— Болай да ярар, — диде ул.

Габделхәйнең хәтерен калдырудан курыккан сыман, ул моны иплəп кенә, ишетелер-ишетелмәс кенә итеп әйтте.

— Апаңнан хат киләме? — диде Габделхәй, сүзгә башлап.
— Юк, — диде Сәкинә.
— Шуның балаларына бәйләнеп калырсың микәнни инде? — диде Габделхәй.
Аның тавышында «шуның балалары»на карата ачыктан-ачык яратмау, Сәкинәгә исә теләктәшлек һәм ярдәм итәргә әзер тору сизелде.
— Белмим, — диде Сәкинә, үлемгә дучар ителгән бер өметсезлек белән.
Ул карый торган балаларның инәсе — Сәкинәнең бертуган апасы Уфада тора иде. Сугыш елларында аның апасы медицина институтын бетергән, кияүгә чыккан. Моннан бер ел элек ике баласын, хатынын ташлап, ире моның маржага өйләнгән. Сәкинәнең апасы ниндидер «кантур»да эшли икән. Былтыр җәй Яңавылга кайткач, ул әлеге балаларын калдырып китте. Киткәндә бөтенләйгә калдырам дип уйламагандыр инде. Бер-ике ай торсыннар әле, килеп алырмын, дигән. Аның әле фатир ягы да җайлы түгел икән. Ире белән аерылышсалар да, бер үк квартирада — берсе бер бүлмәдә, икенчесе икенче бүлмәдә торып яталар икән. Мәхшәр инде, мәхшәр. Менә шул квартираны суд аша бүлешеп, аерым-аерым фатир ясыйсы бар икән. Хаста инәләре каршы килмәгән, калсыннар, ничек тә күз-колак булырбыз, дигән. Әтәләре дә каршы килмәгән. Сәкинәдән сорап та тормаганнар. Балаларын калдырып киткәч, ана кеше көн аралаш диярлек хат язган, сагынам, фәләнтөгән, дигән. Бер ай үтә, ике ай үтә — Уфадан кайтучы-килүче булмый. Бераздан боларга хат килеп төшә: ачуланмагыз инде, хәлем бик начар, акча җибәреп торырмын — кышка икесен дә бакчага урнаштырыгыз — фатир ягы җайланса, язга кайтып алырмын, дигән. Менә кыш та үтте, яз да җитте. Быел җәй балаларның монда торып калуына бер ел булды. Апа кешенең хаты да юк, хәбәре дә юк. Үзе кайтып төшәргә итә микән әллә?
Болар турында Габдехәй Сәкинәдән ишетеп белде. Җае чыккан саен ул Сәкинәнең апасын, балаларын белешеп торды. Сәкинә, билгеле, гомер буена апасының балаларын карап ята алмаячак. Хәзер аңа укырга китәргә, алай да булмаса, берәр эшкә керергә кирәк булачак. Моннан бер атна элек әтәсеинәсе кече кызларыннан Уфага хат яздырдылар: балаларыңны быел да кайтып алырга исәбең булмаса, үзең кайт Яңавылга, таза кешегә монда да эш табылыр, җавабыңны озак көттермә, диделәр. Хатны алар май башында салганнар иде, хәзер инде июль.
— Аңа тагын язарга кирәк! — диде Габделхәй. — Беләсеңме, язуым әле үзем! Язуыммы? Син күчереп җибәрерсең. Оялтып, гарьләндереп язарга кирәк аны, тетмәсен тетеп! Нинди ана ул үз балаларыннан аерым яшәүче? Аның җаны юктыр. Үзе институт бетергән, үзе врач. Аның сеңлесе — син, ун класс белемең була торып, көн-төн сыер саварга, кош-корт карарга, аның балаларын карарга тиеш! Бүген үк яз син аңа.
— Язып булмый, — диде Сәкинә сүлпән генә.
Аның шулай буйсынучан-тыныч тавыш белән җавап бирүе, әз генә дә бу гаделсезлеккә каршылык күрсәтергә тырышмавы Габделхәйнең кайнарлыгын сүрелдерә төште. Ул аптырап калды. Ул бит аңа — Сәкинәгә яхшы булсын өчен тырыша. Сәкинә ничек тә бу тормыш баткагыннан котылырга, ничек тә укырга, кеше булырга тиештер ич!
Габделхәй карашынча, кешеләр ике төркемгә бүленәләр иде. Аларның бер төрлесе — укыган кешеләр, икенче төрлесе — укымаган кешеләр. Укыганнарны ул тагын икегә бүлеп карый. Тормышта ачык максаты булган, ниндидер зур эшләр башкарырга омтылган кешеләр, аныңча, иң беренче баскычта, югарыда торалар. Икенче баскычта, түбәндәрәк — укыган, ләкин бернинди максаты булмаган кешеләр тора.
Аның уенча, укыган һәрбер кеше дан-шөһрәткә омтылырга һәм ниндидер бөек эшләр башкару турында хыялланырга тиеш. Барлык тырышлыклары, барлык максатлары йорт-җир, кием-салым, тамак кайгысыннан узмаган кешеләрдән дә кызганычрак беркем юк.
Сәкинә беркайчан аның кебек каядыр читкә китәргә, ниндидер зур эшләр башкарырга омтылмады. Аның күңелендә ниләр барын, гомумән,

белә торган түгел иде. Бу яктан караганда ул һич тә Габделхәйгә тиң түгел. Аннары аны матур дип тә булмый — кыска буйлы, юантык кына, озын чәчләрен ике толымга үреп йөртә, күзләре яшькелт-зәңгәр. Ул бары укуда гына алдынгы. Шулай булгач, кайчан да булса ул барыбер югары үрләргә тиеш. Начар укыган кеше югары үрли алмый. Аңа бары ярдәм итәргә, аны бары үгетләргә, ышандырырга гына кирәк.

Ни генә булмасын, аны монда сыер-сарык арасында, чит балалар янында калдырырга ярамый. Ничек тә аны үзеңнең артыңнан ияртергә кирәк. Революционерлар, укымышлылар кара халыкны агарту эшен иң элек хатын-кыздан башлаганнар. Хатын-кыз әле дә иң нык изелгән, иң хокуксыз халык. Татар хатыннары бигрәк тә. Менә аның җанлы мисалы. Юк, элек кенә ул шулай булган. Хәзер, билгеле, эшләр башкачарак. Ләкин шулай да Сәкинәне моннан, Яңавылдан, алып китәргә кирәк. Кая? Әлбәттә, Казанга, бары Казанга гына!

— Карале,— диде ул бераздан,— балаларын илтергә дә ташларга Уфасына! Йортны, мал-туарны синнән башка да карарлар. Сиңа медицинскига түгел, берәр техническига китәргә була!

Уйламыйча, ләкин кычкырып әйтелгән үз сүзен ишетеп, Габделхәй кинәт тынып калды. Хәзер ул үзе инанган фикерен түгел, бәлки башкалар фикерен әйтә иде бугай. Василий Михайлович та аны шулайрак үгетләгән иде түгелме соң?!

— Юк инде, булмас, ахрысы,— диде Сәкинә теләр-теләмәс кенә.

Габделхәй эндәшмәде. Сәкинәнең менә шул күңелсезлеге, дәртсезлеге еш кына аның кайнарлыгына салкын су сипкәндәй булды. Мондый чакларда ул нәрсә әйтергә дә белми аптырады да калды. Хәзер дә шулай булды. Алар кешесез тар урамнан беркадәр җир бардылар да кире борылдылар һәм яңадан таныш исләр аңкыткан таныш амбар янына килеп чыктылар. Сәкинә тәвәккәллек сизелеп торган бер үтенеч белән:

— Сау бул инде, Габделхәй. Бар инде кит,— диде.

— Ярый, сау бул,— диде Габделхәй.— Бүген кич Сталин клубына барасыңмы? Бар. Киногa керербез. Мин сине кичке... сигездә көтеп торырмын.

— Белмим әле,— диде Сәкинә.— Өйдә эш күп булмаса...

— Чыгасың алайса?

— Иртәгә, бәлки?

— Ярар, иртәгә!— диде Габделхәй.— Бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмаса — берсекөнгә! Сәгать сигезгә!

— Сигезгә,— диде кыз әкрен генә.

## V

Габделхәй үзләренең ишегалдына киртә аша гына сикереп керде дә, өй ишеген шакып тормыйча, тактадан әмәлләгән бәләкәй генә лапасның печәнлегенә менеп китте. Монда, түбә астында аның үзе җайлаган бик уңай урыны бар иде. Өс киемнәрен салып бер читкә куйды, иске ябынгыч астына кереп ятты да шундук йокыга китте.

Ул бик озак йоклады. Берзаман йокы аралаш табан астының кытыклanганын тоеп, ул уянгандай итте һәм артык борчылмыйча гына «чебен микәнни?» дип уйлады. Шулай да чебен аркасында гына йокысын бүлдерәсе килмәде — чебенне кугандай итеп аягын селтәде дә, икенче ягына әйләнеп, яңадан йокыга чумды. Күпмедер вакыттан соң бәйләнчек чебен яңадан табан астында йөри башлады. Габделхәй, аны-моны уйлап тормыйча, башын калкытты, торып утырды һәм тиз-тиз генә киенә башлады. Бит аның каядыр барасы, кемнедер күрәсе бар иде бугай!

Шул чакны астан иплән кенә кара әрем сузылганы күренде. Җиргә төшә торган баскычка арты белән утырып торган килеш күлмәк җиңен рәтләп маташкан Габделхәйнең аркасын әлеге әрем очы кытыклый башлады. Габделхәй моны ничектер күз кырые белән күреп калды. «Әһә, менә нинди

чебен икән!» — дип уйлады ул һәм, юри күрмәмешкә салынып, үз эше белән мәшгуль булды. Әгәр артына борылып караса, әлбәттә, ул кече энесе Фидаилнең такыр башын һәм шат-хәйләкәр йөзен күреп алган булыр иде. Ул юри озаграк матавшты. Әрсез әрем очы һаман югарырак үрелде, кыюланып абыйсының муенын кытыклады, колагына килеп җитте. Түземлеге төкәнгән абый кеше, бәйләнчек чебеннең кулыннан эләктереп алмакчы булып, кисәк кенә артына борылды.

Шат күңелле «чебен» абыйсының мәкерен сизмичәрәк кайды. Тоттырмас өчен тиз генә иелергә йә булмаса баскычтан төшеп китәргә акылы җитмәде. Карчыгадай өстенә ташланган абыйсыннан ул ялт кына читкә тайпылды. Аның шулай тайпылуы булды, сөяп куелган ышанычсыз баскыч бер якка янтайды, малай исә икенче якка янтайды.

Мондый тамашаны күреп, Габделхәй көләргә дә, җыларга да белмәде. Тиз генә төшеп аның энесенә ярдәм итәсе дә килде, шул ук вакытта тиз генә төшеп булмаганлыгын да шәйли алды. Фидаил исе беркадәр вакыт тыны-өне бетеп, исенә килә алмыйча ятты да ыңгырашып куйды, башын калкытты. Габделхәй анда-монда тотынып җиргә төшеп өлгергәндә Фидаил дә аягына басты. Энесенең пычранып, юешләнеп беткән өстен-башын, кызганыч кыяфәтен күреп, абый кеше тыела алмыйча көләргә тотынды.

— Шул кирәк сиңа, чебен! Икенче йоклаган кешене уятмассың,— диде ул.

Төшкән җире йомшак булганга, Фидаилнең берние дә имгәнмәгән иде бугай. Шулай да, җыларгамы-җыламаскамы дигәндәй, икеләнебрәк торганда, абыйсының үзеннән көлүен күреп-ишетеп, хурланып малай акырып җибәрде. Кинәт җылавыннан туктап калды һәм бар тавышына:

— Сәкинә! Сәкинә! — дип кычкыра башлады.

Габделхәйнең моңа әллә ни исе китмәде, тыела алмыйча һаман көлүендә булды.

— Сәкинә кияве, Сәкинә кияве! — диде Фидаил бөтен тирә-якка ишетелерлек итеп.

Бу юлы инде Габделхәй көлүдән туктап калырга мәҗбүр булды.

— Чебен! Күрсәтермен әле мин сиңа кияүне! — диде ул энесе артыннан ташланып.

Фидаил артына борылып карый-карый, үртәшә-үртәшә туп-туры өйгә йөгерде. Абый кеше аның артыннан ашыкты. Хәзер аның, Фидаилнең кирәген бирүдән бигрәк, өйдәгеләргә энесенең ничек итеп әрем белән кытыклап азаплануын, ничек итеп җиргә егылып төшүен сөйләп көлдерәсе килде. Ләкин аңа кызык хәлне сөйләп көлдерергә туры килмәде. Каршыга коты алынган Фидаил килеп чыкты. Аның артыннан ук диярлек кулына корымланып беткән кыскыч тоткан инәләре күренде. Габделхәй белән алар чак-чак кына бәрелешми калдылар.

— Күземә күренмә! Туп-туры җылгага җөгер! — диде инәсе Фидаил артыннан кычкырып. — Кичә генә юдым күлмәген. Әдәм хуры, җитмәсә шул көе өйгә килеп кергән.

Габделхәй инәсенең ачулы булуын тиз генә чамалый алмады. Фидаилнең баскычтан егылып төшүе турында сөйләмәкче булып авызын гына ачкан иде, Шәмсебанат апа әрнеп, ачынып:

— Йөрисең шунда, олы сабый, — диде. — Тапкан көләр нәрсә, дивана!

Олы тормыштагы, яңа тормыштагы беренче көн Габделхәй өчен менә шулай башланды.

## VI

Габделхәйнең шундук авызы йомылды. «Сәкинәне озатып куйганны яратмый микәнни?» — дип уйлады ул инәсе турында. Шулайдыр. Берәрсе күргәндер дә әйткәннәрдер, әнә малаең кызлар белән йөри башлаган,

дигәннәрдер. Фидәил дә юкка сөйләнмәс. Тыңлап торгандыр. Сиздермичә тыңлап торырга, читтән генә күзәтеп торырга аңа куш.

Габделхәй өйдәгеләр ягына әйләнеп карамаска тырышып, ишек төбендәге почмак янына килеп, өстен-башын чишенә башлады. Өф итеп кенә тота торган, яхшылыкка гына киелә торган пинжәген салып чөйгә элмәкче булган иде, пинжәктәге үрмәкүч авы сыман чүп-тузан күреп, шунда гына каккалый-суккалый башлады. Шуны гына көтеп торган кебек, инәсе шундук сукранырга тотынды:

— Как әйдә, как шунда! — диде. — Көлеп торган була бит әле авызын җырып. Үрнәк күрсәтә! Бар тышка чык — әнә чалбарыңның да карар җире калмаган. Кешедән көлгән була җитмәсә.

«Нәрсә булган соң шулкадәр? Нигә кәефе кырылган?» — дип уйлады Габделхәй эче пошып инәсе турында. Соңгы елларда инәсе бер дә тазалыкка туймый. Тик торганда дигәндәй әле йөрәге, әле башы авырта. Бөтенләй көтмәгәндә кәефе кырыла. Берәр кыек сүз әйтсәң дә, ялгыш өйдә кычкырып сөйләшә башласаң да, киреләнеп-карышып торсаң да, җитә кала — шундук йөзе бозыла, тавышы үзгәрә. Габделхәй аның кайчан нәрсәгә кәефсезләнүен дә белә кебек. Инәсе аның нишләптер Фидәилгә дә, Илгизгә дә артык ачуланмый, бары аңа — Габделхәйгә генә ачулана сыман. Анысы аның шулай тиештер дә. Бит өйдә инәсеннән кала иң өлкәне ул — Габделхәй. Бөтен җаваплылык аның өстенә төшә. Дөресрәге, инәсенең ул беренче ярдәмчесе, уң кулы. Сул кулы — Илгиз. Фидәил — койрык. Сәкинә турында тагын берәр авыз ачсын әле — «Койрык!» дияргә була. «Чебен» дисәң дә шәп. Теләсә нәрсә сөйләнеп, чебен кебек безелдәп йөрмәсен, маңка!

Габделхәй каршы эндәшеп тормады, чалбар балакларына карана-карана мыштым гына тышка чыгып китте дә өс-башын каккаларга-суккаларга тотынды. Өйдә давыл тынсын өчен юри озаграк маташты. Ул кире өйгә кергәндә чыннан да давыл тынган иде. Инәсе башына тастымал урап, кызыл чичкәле мендәр өелгән агач караватына бөгәрләнеп яткан иде.

Габделхәй киемнәрен җайлап элеп куйды да тавыш-тынсыз гына түр почмакта эзләнә бшлады. Монда, гадәттә, иске чүпрәк белән каплап куелган агач табакта һәркемнең үзенә тиешле көнлек азыгы була. Инәсе балалар бакчасыннан эштән кайтканда калдык-постык ипи кисәкләре, кайчагында хәтта пирүк, бәлеш кисәкләре алып кайта, шуларны тип-тигез итеп өч кисәккә бүлә дә әлеге табакка салып куя. Базардан, магазиннан сатып алынган йә булмаса өйдә пешерелгән ризыклар да тигез кисәкләргә бүленеп шунда куела иде.

Габделхәй өйгә килеп кергәндә бердәнбер өстәлнең бер кырыенда Илгиз баш калкытмый нидер укып утыра иде. Абыйсының ашарга эзләнүен күреп, ул башын калкытырга кирәк тапты.

— Мич алдында күбәтә белән сиңа бәрәңге бар, — диде.

Габделхәй төпченеп тормады — мич алдындагы калай күбәтәне өстәлнең икенче башына китереп куйды да, үзенә дип калдырылган ипи кисәге белән тәмләп-тәмләп бәрәңге ашарга тотынды. «Безнең бәрәңге беткәние бит инде — каян алдылар икән шундый тәмле бәрәңгеләрне?» — дип уйлады ул ашаган арада. Бу турыда нишләптер энесеннән сорыйсы килмәде. Каян булсын, инәсе балалар бакчасыннан алып кайткандыр инде. Ул шулай кайчагында аннан бәрәңге, бер-ике кишер йә булмаса чөгендер ише нәрсәләр дә алып кайткалый. «Артып калды да, бүлешеп алдык», — дигән була яисә «пубыр бирде» ди. Кем белә аны, әллә «пубыр» биргән, әллә үзе алган. Дөресен әйткәндә, бу бит... бу бит урлашу. Социалистик милеккә, балаларга тиешле өлешкә кул сузу. Нинди хурлык, инди мәсхәрә! Шундый аңлы, алдынгы укучы, кичәгенәк кенә шундый дөрес сүзләр сөйләгән укучы хәзер менә рәхәтләнеп... урланган бәрәңге ашап утыра!

Үз алдында ул шулайрак дип уйланды һәм уйлаган саен коры бәрәңге тамагына аркылы утыра сыман тоелды. Яңа сауган җылы сөт белән эчеп җибәрсәң, тамакка утырмас иде дә соң — аларның сыерлары да, кәҗәләре дә, хәтта тавыклары да юк. Печәнлекләре генә бар. Анысы да элекке

хуҗалардан калган. Сөт булган көнне була, булмаган көнне — юк. Сөтне Сәкинә генә эчә инде. Сыерлары да, май заводы да якында гына. Ләкин сөт булсын өчен Сәкинәләр кебек көне-төне эшләргә кирәк. Ул менә шигырь язып, кызлар белән йөреп үткәрә. Булмый болай. Нидер эшләргә кирәк, нәрсәнедер үзгәртергә кирәк.

— Каян алдыгыз бәрәңгене? — диде ул Илгизгә утыра торгач.

— Инәкәй базардан алып кайтты, — диде Илгиз.

— Шулаймыни? — диде Габделхәй җиңел сулап.

Өлкән улының талымлый торган гадәтен белгәнгә күрә, Шәмсебанат апа алдан ук Илгизгә шулай дип әйтеп куйган иде. Абый кеше Илгизнең ялганына бер сүзсез ышанды һәм ярып пешерелгән тәмле бәрәңгене ашыкмыйча гына ашавында булды. Калай күбәтәдә ашар нәрсә калмагач, ирексездән аның күз алдында кичә ашаган ашлар килде. Шәп ашаттылар аларны! Башта күкәйгә басылган токмачлы аш бирделәр, аннан соң пешкән бәрәңге белән ит, чәй бирделәр. Иң соңыннан берәр стакан алсу морс булды. Бит дөньяда кемнәрдер көн дә шулай ашап торалар! Нинди бәхетледер алар!

— Күрдеңме әле, синең шигыреңне гәзиткә басканнар, — диде Илгиз утыра торгач бөтенләй көтмәгәндә.

«Шигырь» сүзе ишетеп Габделхәй дерт итеп китте. Ул аны бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде. Шигырь ул бары хыялда гына була торган нәрсә иде, чын тормышта исә бары чүпрәк белән ябылган агач табак, табак төбендә бер-берсеннән аерып куелган ипи кисәкләре, пешкән санаулы бәрәңге, агач караватында бөгәрләнеп яткан инәсе һәм тәрәзәгә бәргәләнеп безелдәгән чебеннәр генә булырга мөмкин иде. Ашавыннан туктап, ул беренче мәртәбә энесенә игътибар беләнрәк карады. Илгиз китап түгел, «Коммунизм юлы»н укып утыра иде.

— Менә, укы, — диде Илгиз газетаны абыйсына таба этәреп.

Габделхәй, тынычлыгын җуйган хәлдә, шулай да тыныч булырга тырышып, «Коммунизм юлы»н кулына алды һәм күрмәс күзләре белән үзенең шигырен эзләп тапты. Иң элек ул шигырьнең калын, эре хәрефләр белән язылган исемен укыды, үзенең исем-фамилиясен укыды. Таныш юлларга озаклап карап торганнан соң, әкрен генә, иҗекләп кенә үзе язган сүзләрне укырга кереште. Бер мәртәбә укып чыккач, үз-үзенә, үзенең бөеклегенә сокланып, таң калып утырды да яңадан укырга тотынды. Әйе, басканнар... Чыннан да басканнар бит, малайкай! Бер генә хәрефен дә төшереп калдырмаганнар!

## VII

Өйдән чыгып китү белән Габделхәй, гадәттә, көндәлек тормыш мәшәкатьләре турында уйламаска тырыша иде. Мондый чакта дөнья аңа матур булып, күңелле булып тоела, ләкин өйләренә кайтып кердеме, ишегалдагы, өйдәге таныш әйберләр, таныш кыяфәтләр, таныш мөнәсәбәтләр белән күзгә-күз очраштымы, бөтен нәрсә гап-гади һәм күңелсез була да кала. Әле генә хыял вәсвәсәсе азындырган яшь күңелнең өйдәге, якын-тирәдәге, бөтен дөньядагы мохтаҗлык һәм кысынкылык белән һич тә килешәсе килми башлый. Ләкин шул ук вакытта ул үзенең бүген дә, иртәгә дә шушында — һәрбер тишек-тошыгыннан ярлылык, мохтаҗлык саркып торган тар, кысан өйдә яшәргә тиешлеген дә аңламый булдыра алмый. Мондагы барлы-юклы әйберләргә, мондагы гадәтләргә, мондагы кешеләргә — инәсенә, энесенә ул бөтен күңеле белән, кендеге белән береккән. Шуңа күрә ул алардан, әйтерсең, беркайчан да аерыла да алмаячак, беркайчан аларны ташлап, каядыр хыял өндәгән якларга китеп тә бара алмаячак кебек иде.

Үз шигыренең газетада басылуы аны күз ачып йомган арада хуш исләр аңкыган, талгын җилләр искән каяшлы болыннарга, бәхетле шәһәрләргә алып китте. Үз алдына елмаеп, ул озак кына тынып утырды. Аның эндәшмәвен күреп Илгиз дә эндәшмәде, инәсе дә тып-тын урынында ята

бирде. Хәер, инәсенең үз хәле хәл. Өлкән улына ул бөтенләй игътибар итмәгән сыман тоелды. Чынлыкта ул бары аны гына күзәтеп ятты, кайчан ничек сүз башларга икән, дип уйлап кына ятты.

Урам якта кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшә-сөйләшә узып барулары ишетелеп калды. Урамдагы тупас тавышларны ишетү белән, шагыйрь җегет, хыял дөньясыннан аерылып, үзенең каты урындыгына төшеп утырды. Күзләрен ачыбрак караса, өстәл өстенә япкан шакмаклы ашаулыкның почмак турысында тишек булуы, ул тишекнең кичәгегә караганда зуррак булуы күренде. Кемдер аны бармагы белән юри зурайткан иде бугай. «Фидәил эше»,—дип уйлады абый кеше. Беренче мәртәбә аңа хәтта ярып пешерелгән бәрәңге дә тәмсез булып тоелды. Бәрәңгенең яңасы җиткән вакытта иске бәрәңге ашап утыр, имеш! Шулай да каян тапканнар соң болар мондый вакытта шундый таза, яхшы бәрәңгене? Базардан, имеш!

— Ашап бетер,—диде ул бер-ике бәрәңгесе калган калай күбәтәне Илгизгә таба этәреп.

— Ярар,—диде Илгиз бик тиз риза булып.

— Туйдың дамыни?—диде Шәмсебанат апа, тавыш биреп.

Габделхәй берни эндәшмичә көтә башлады. Инәсенең тавышыннан ул хәзер үзенә карата шелтә, моң-зар буласын сизенгән кебек булды. Инәсе озак көттермәде, бернинди керешсез шундук тезәргә дә тотынды:

— Хәзер инде сиңа бер атна ашамасаң да була. Атналыкны ашап кайткансыңдыр,—диде.

Инәсенең сүзеннән кызык табып Илгиз көләргә тотынды.

— Нәрсә ыржаеп утырасың?!—диде абый кеше үртәлеп.

— Бер атна ашамый йөрсәң, Хуҗа Насырттин ишәгенә әйләнерсең!—диде Илгиз.

Габделхәй энесенә усал итеп бер карап алды, ләкин шуннан да көчлерәк тәэсир итәрдәй башка чарага кулы бармады. Шулай да ул ачуын йотты һәм, бик кирәкле эш башкарган сыман, шкафның иң югары шүрлегенә куелган иске дәфтәрләрен актара башлады. Монда Фидәилнең кулы җитми торган җирдә аның беренче шигырьләре, рәсемнәре, төрле кирәк-ярак язулары саклана иде.

Ул арада инәсе урыныннан торды, башындагы тастымалын салып ташлады да су эчеп куйды һәм караватында таралып яткан энә-җепләрен, ямаулыкларын алып гадәттәге шөгыленә—нидер ямаргамы, тегәргәме тотынды.

## VIII

— Мизал бирделәрме соң, улым?—диде бераздан Шәмсебанат апа, күтәрелеп карамыйча гына.

Габделхәй иске дәфтәрләрен актарудан туктап калды, каушап, кызарынып инәсе ягына борылды. Медаль турында ул нишләптер онытып җибәргән иде. Чыннан да, бу дөньяда «шигырь» генә түгел, «медаль» дә бар бит әле. Медаль! Ул да бары буш хыял гына булып чыкты. Кемнәргәдер бирәләр, кемнәрнедер мактыйлар, данлыйлар—аңа менә тәтемәде. Нинди хыялланган иде ул бер мәлне «медаль» дигән нәрсә турында! Әйе, булмады. Баштарак булырына бик үк ышанып җитмәсә дә, соңыннан... бер вакыйгадан соң ул инде әз генә дә шикләнми башлаган иде.

Яңавыл татар урта мәктәбендә барлык укучылар өчен иң куркынычы урыс теле иде. Татар мәктәбе булгач, күпчелек фәннәр татарча укытылырга тиеш булса да, күпчелек фәннәр, киресенчә, урысча гына укытылды. Физика-математика—урысча, химия-биология, зоология, немец теле—шулай ук урысча. Хәтта тарих та сигездән унга кадәр—урысча. Укытучыларның күбесе—татарлар. Сөйләвен алар урысча сөйлиләр, ләкин берәр нәрсәне аңлап җитмәсәң, татарча аңлаталар. Дәрестә урысча сорауларга җавап бирергә тиеш булсалар да, шулай да башка вакытта укучылар үзләрен иркенрәк тоталар—чыш-пыш килеп татарча сөйләшәләр, бер-берсенә татарча хатлар

язалар. Тәнәфестә инде бөтенләй татарча! Ләкин урыс теле, урыс әдәбияты дәресендә... Антонина Семеновна дәресендә... чебен очкан тавыш та ишетелми.

Антонина Семеновна — Ленинград марҗасы. Сугыш вакытында эвакуация белән килгән дә торып калган. Монда килгәндә аның малае да булган. Малаен сугышка алганнар. Күп тә тормаган, үле хәбәре килгән. Шуннан соң микән, Антонина Семеновна бик нык холыксызланган. Бәлки элегрәк тә шундый холыксыз булгандыр. Мәктәп ишегалдындагы иске генә бер өйдә бер үзе тора, кеше белән аралашмый, мондагы халыкны яратмый. Аның бар юанычы шул урыс теле дә урыс әдәбияты бугай. Дәрескә кереп утыру белән дөньясын онытып Пушкин, Лермонтов, Толстой турында, дөресрәге, алар иҗат иткән әсәрләр турында сөйли башлый. Беркайчан китапка, дәфтәргә карамый. Барысы да яттан. Аныңча, дөньяда иң бөек әдәбият — урыс әдәбияты, иң даһи язучылар — урыс язучылары. Урыс телен инде әйткән дә юк. Урыс теле — иң бөек тел, иң көчле, изге тел. Урыс телен белмәгән кеше бу дөньяда кеше исеменә лаек була алмый. Иптәш Сталин үзе урыс телендә сөйләшә, урыс телендә уйлый, урыс телендә яза. Бит тумыштан ул — грузин! «Урыс телендә дөрес язарга иптәш Сталиннан өйрәнегез», — дигән иптәш Калинин. Менә бит ул эшләр ничегрәк тора. Ватан сугышы елларында урыс теле барлык халыкларны цементлаучы какшамас көчкә әйләнде. Совет халкы бары тик бөек урыс теле ярдәмендә генә тарихта тиңдәше булмаган җиңүгә ирешә алды. Бүгенге көндә бөтен дөнья халкы үз теләге белән урыс телен өйрәнә. Халыкара трибуналардан Пушкин теле, Толстой һәм Ленин-Сталин теле яңгырый! Шикләнмичә әйтергә була — кырык-илле елдан урыс теле бөтен планетаны яулап алачак!

Еш кына урысча дөрес сөйләшмәгән укытучыларны төзәтә, тәнәфестә берәрсенең ялгыш кына укучылар белән татарча сөйләшкәнен ишетеп калса, бернинди тәкәллефсез рәвештә замечание ясый. Инде укытучылар киңәшмәсендә, үзара сөйләшеп утырганда укытучылар татарча сөйләшсәләр, аңсызларга ул карчыга булып куна.

Дәрестә укучылар белән генә калганда аңа каршы беркем сүз әйтә алмый. Урыс теленә җитәрлек дәрәҗәдә игътибарлы булмаган укучыларны ул әледән-әле чиреккә, еллыкка «начар» кую белән, икенче елга класста утыртып калдыру белән куркыта. Берәр кирерәк укучы шулай да үзенең татарлыгын, татар теленең дә тел булуын якларга, исбат итәргә тотынса, Антонина Семеновна аны кырт кисә дә, урыс теленең бөеклеге турында Ломоносов, Тургенев, тагын әллә кемнәр әйткән сүзләрне исенә төшерә һәм иң ахырда болай гына, кирәксез нәрсә турында сөйләнгән сыман гына: «Берәр даһи язучының, галимнең татар теленең бөеклеге турында әйткән сүзләрен мин хәтерләмим», — дип куя.

Мәктәптә аны беркем яратмый — укучылар да, укытучылар да. Укучылар аны «каз-күз» дип йөртәләр һәм бары «начар» алу, күчми калу куркынычы булган өчен генә аның бер сүзенә дә каршы килмәскә тырышалар. Урыс телен, әдәбиятын яхшы белергә кирәклеген беркем инкарь итми. Беркемнең урыс теленә каршылыгы да юк, чөнки кая барма — бөтен эш урысча. Өйдә, базарда, авылда, анда-монда әле татарча сөйләшергә дә була, ләкин вокзалга, тимер юл буена төштеңме — дөнья үзгәрә дә куя. Бөтенесе — урысча. Алай-болай ялгышып кассир марҗага, идән себерүче марҗага татарча эндәшсәң, ул синең йөзеңә генә төкерми — эттән алып эткә салып, шундук синең үзеңне, телеңне, халкыңны мыскыл итәргә тотына.

Шулай. Барысы да шулай. Быелгы унынчылар өчен урыс теле аеруча авыр булды. Уку елы башыннан ук инде Антонина Семеновна күп кешенең, бигрәк тә якын-тирәдәге авыллардан — Эткенәвылдан, Истәктән, Уразыдан килеп йөрүчеләрнең котын алып куйды. Тырышмасагыз, сочинениедә коелып калачаксыз, диде. Өлгергәнлек аттестаты бирелмәячәк, аттестатыгыз булмаса, кем булырсыз да кая барырсыз? диде. Барлык фәннәрдән яхшы укыган, тик урыс теленнән генә йомшаграк булган Фәния, мескен, түзмәде, җылады. Ул үзе болай чит авылдан килеп тә йөрми, ул — Яңавылга кушылып

бетә язган Җобанай кызы. Ләкин өй тулы бала-чагалары булган Фәниялләр шундый ярлылар — Фәниянең яхшылыкка киеп йөри торган күлмәге дә икеөч җирдән ямаулы. Фәниянең өйдә укып дәрес әзерләнеп утырырга вакыты да юк, шул ук вакытта аның иң зур хыялы — кая да булса читкә китү, институтка булмаса, техникумга керү, кеше булу.

Урыс теленнән дә, Антонина Семеновнадан да бөтен мәктәптә диярлек бары бер генә кеше, бары Габделхәй генә курыкмады. Урыс телен ул беләм дип исәпләде. Антонина Семеновна да әледән-әле шуны тукый килде. Беркайчан ул аңа каты бәрелмәде, беркайчан аның йөзен җыртмады. Кайбер укучылар, Антонина Семеновна Габделхәйне яклый, диделәр. Габделхәйнең үзенә бу бер дә яклау булып тоелмады. Аныңча, бу шулай булырга тиеш тә иде, чөнки ул урыс телен чын күңелдән тырышып укыды. Башка фәннәрне онытса онытты — урыс теленнән бирелгән өй эшләрен дә онытмады, Антонина Семеновнаның киңәшләрен дә онытмады. Анысы гына җитмәгән, үзлегеннән ул туктаусыз китап укыды. Урыс классикларын — Гогольне, Пушкинны, Лермонтовны, Толстойларны, тагын әллә кемнәрне укыды. Антонина Семеновна агитациясенә ул берсүзсез ышанды һәм үзен хәзердән үк коммунистик җәмгыятьтә яшәячәк чын кеше итеп тәрбияләргә булды. Үз-үзенә ул хәтта шундый максат куйды: башта урыс классикларын укып чыгам, аннан соң дөнья әдәбияты классикларын укый башлыйм, диде. Ул билгеле, татар әдәбиятыннан да йөз чөермәде, ләкин мәктәптә татар китабы юк дәрәҗәсендә иде. Сталин клубы каршындагы китапханәдәге барлы-юклы татар китапларын ул инде күптән укып чыккан иде.

Чыгарылыш имтиханында Габделхәй урыс теленнән сочинениене ирекле темага язды. Булачак шагыйрь кеше нишләп анда һәркем белгән, чәйнәлгән Корчагиннар, Маяковскийлар турында язарга тиеш? Шагыйрь кеше ул кайда да иҗат итәргә тиеш. Ул иҗат итте. Бөтен бер дәфтәрне язып тутырды. Беренче булып бетерде дә, дәфтәрен комиссиягә тапшырды да, җиңүче тойгысы белән, җиңеләеп, масаеп мәктәптән чыгып ук китте. «Отлично» булырына ул әз генә дә шикләнмәде.

Өч-дүрт көннән барысын да җыеп, кемнең ничек язуын аңлатканда, көтелгәнчә, иң элек аны мактадылар, «отлично», диделәр. «Уртача»лар күп булса да, «яхшы»лар да, хәтта икенче «отлично» да бар иде. Икенче «отлично» Сәкинәнеке иде. Шунысын да әйтергә кирәк, аттестат бирдермим дип янаган Антонина Семеновна беркемгә дә «начар» куймаган иде. Унынчыларның түбәләре күккә тиде. Һәркем үзен бәхетле санады. Сират күперен үткәч, калганы инде аның чүп кенә!

Класстан таралганда директор Габделхәйне көтеп алды һәм гадәттә булмаганча серле һәм йомшак итеп:

— Кабинетка керегез әле, Мухутдинов, — диде.

Габделхәй керде, көтә башлады. Василий Михайлович нишләптер сүз башламады — өстәл тартмаларын ачкалап, кәгазьләрен әвеш-түеш китергән булды. Аның гадәте шул: кем керсә дә, кем белән сөйләшсә дә, эшем кешесе булып, иң элек шулай өстәл тартмаларын актарып булыша. Шакып-нитеп тормыйча шул чакны кабинетка Антонина Семеновна килеп керде. Бүген ул бераз гына тынгысыз сыман тоелды. Укучылар белән сөйләшкәндә дә ул бүген гадәтенчә башка суккан сыман мәҗбүри, катгый тонда түгел, ничектер йомшак, дусларча итеп, кешеләрчә сөйләште. Габделхәй дә, башкалар да андагы бу үзгәрешкә игътибар итми калмадылар. Һәркем аның турында: соңгы очрашу булганга күрә шулай күңеле йомшагандыр, дип уйлады.

Директор кабинетына килеп кергәч, Антонина Семеновна беркайчан кулыннан калдырмый торган калын кара портфелен өстәлгә бастырып куйды, актарынып аннан бер дәфтәр чыгарды һәм, дәфтәрне кулыннан ычкындырмыйча, Габделхәйгә карап сөйли башлады. Ул сөйләгәндә икенче яктан төртеп тишәрдәй булып Василий Михайлович карап торды.

— Сочинениеңнең эчтәлеге бик яхшы, Мухутдинов, — диде Антонина Семеновна. — Синең мөстәкыйль фикерли алуың күренеп тора. Ләкин кайбер сүзләрдә хаталар киткән. Менә, карап чык.

Мондый көтелмәгән яңалыктан каушап калган Габделхәй калтыранган кулына дәфтәрен алды, актара башлады. Һәр бит саен кызыл кара белән төзәтелгән хаталар күреп аның коты алынды. Ул катты да калды. Нишләп? Ничек? Мөмкин түгел! Хаталы сүзләрне ул укырга тырышып карады, ләкин укый алмады. Ул бары шуны гына аңлады: күп кенә сүзләрдә ул «е» язылачы урында «и» язган, «и» язылачы урында «е» язган иде. Әйе, бу аның йомшак ягы. Ул аны үзе дә белә.

Василий Михайлович аңа башланмаган бер дәфтәр тоттырды һәм шыгырдап торган күңелсез, шулай да йомшаграк бер тавыш белән:

— Менә нәрсә, Мухутдинов,— диде.— Без... комиссия килештек тә, шундый фикергә килдек. Син хәзер үзегезнең класска кереп, төзәтелгән сочинениеңне күчереп яз. Ашыкма. Без монда көтеп утырырбыз. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Габделхәй, үлемгә хөкем ителеп тә ярлыкау ишеткән җинаятьче кебек.

Үзе дә сизмәстән ул җиңел сулап куйды һәм чыгып китмәкче булып урыныннан торды.

— Чыгып йөрмәсен, шушында гына утырып язсын,— диде Антонина Семеновна.

— Алай да була,— диде Василий Михайлович.— Син, Мухутдинов, алайса шушында гына яз. Бер-ике сәгатькә без чыгып торырбыз. Кабинетны эчтән бикләп куярсыз.

Василий Михайлович шулай диде һәм сейфны, өстәл тартмасын шартлатып бикләде, ачкычларны кесәсенә салды. Кабинет ачкычын ул Габделхәйгә тоттырды. Чыгып киткәндә тавышын әкренәйтә төшеп, татарчалап:

— Син инде аңлыйсың булыр — бу турыда ләм-мим! — диде.

## IX

Ләм-мим икән, ләм-мим. Габделхәй бу турыда хәтта инәсенә дә әйтмәде, хәтта үз-үзенә танырга да теләмәде. Бу эш аңа ничектер төштә генә булган сыман тоелды. Ләкин инәсенең «мизал» турында сүз кузгатуы аны сагайта калды. Фәрхәнә апалар, Халидә апалар дәрәҗәсендәге белемле булмаса да, инәсе аның китапча дөрес итеп сөйләшә ала һәм теләсә «мизал» дип түгел, «медаль» дип тә әйтә ала иде. Аның шулай «мизал» диюендә Габделхәй күрәләтә көлү, хәтта мыскыл сыман нәрсә сизде. Василий Михайлович документларны алып Уфага киткәч тә улының куанычына, медаль булачак дигән сүзләренә Шәмсебанат апа үзенең икеләнүен белдерде.

— Медальне аны синең кебекләргә бирмиләр. Юкка өметләнмә,— диде.

Ул чакта Габделхәй бу турыда сүз куертып тормады. Олы яшьтәгеләр гел шулай бер нәрсәгә дә ышанмыйлар. Инәсе бигрәк тә. Ләкин менә көтмәгәндә аның сүзе дөрес булып чыкты түгелме соң? Инәсе янында Габделхәй хәзер үзен кыен хәлдә сизде.

— Медаль юк. Алтыны да, көмеше дә,— диде ул төшенке генә.

— Нигә юк — әйтмәделәрме? — диде инәсе.

— Әйтмәделәр,— диде Габделхәй, Илгиз ягына карангалап.— Уфа бирмәгән. Аңлашыла ич инде. Алар теләсә нәрсәдән хата табарга гына торалар.

— Хата тапканнар шул,— диде инәсе беркадәр кытәренкелек белән.— Урысча язганыңа «уртача» гына куйганнар.

— Булмас! — диде Габделхәй үзе дә сизмәстән, кызарынып-бүртенеп.— Сочинениедән мин «отлично»га яздым!

— Яздың! — диде инәсе.— Бер язганны күчереп яздың. Белми дисеңме әллә?

Габделхәй катты да калды.

— Син... каян беләсең аны? — диде ул беркадәр вакыт эндәшми торганнан соң.

— Беләм инде, — диде инәсе көлемсерәп. — Фәрханә апаң әйтте.

— Аңа кем әйткән?! — диде Габделхәй исе китеп.

— Кем булсын, Халидә апаңдыр, — диде инәсе. — Ир белән хатын арасында сүз торамени? Халидә апаңа Вәсби абыең әйткәндер. Менә шулай тарала инде ул.

— Таралды микәнни? — диде Габделхәй эсселе-суыклы булып. — Нинди хурлык! Иптәшләр белсә, алар ни әйтер?

— Тапкансың хурланыр нәрсә! — диде инәсе, яңадан үзенең ямаубәйләү эшенә тотынып.

Габделхәй уйга калды. Хәзер ул нәрсәгә аптырарга да белмәде. Барыннан да элек аны Василий Михайловичның сүзендә тормавы, үзе эндәшмәскә кушып та, үзенең беренче булып серне чишүе гаҗәпләндерде. Директор кеше шулай буламыни? Сер сакларга дип килешкәннәр икән, иң элек ул үзе — директор — сер сакларга тиеш түгел идемени? Аннан соң аны күчереп язылган сочинениенең хаталы булып чыгуы да бик нык гаҗәпләндерде. Димәк, аларның төзәттергәннәре дөрес булмаган. Димәк, башта ул дөресрәк язган булган. Шулаймы? Аның моңа бик тә ышанасы килде, ләкин ул моңа бик үк ышана да алмады. Гомер буена урыс теле, урыс әдәбияты укыткан югары белемле Антонина Семеновнаның кайда «е», кайда «и» язарга кирәклеген белмәвенә ышана алмады. Сочинениедә бәлки бүтән төрле хаталар тапканнардыр? Бәлки эчтәлеге ошамагандыр? Юк, берничек тә ул моңа ышана алмады. Аның өчен бу чыннан да сер булып калды.

— Җә, улым, инде нишләргә исәп? — диде инәсе яңадан сүзгә башлап.

Тынып, бөрешеп, кечерәеп калган Габделхәй кырын күзе белән генә инәсенә карап алды. Ул аның тынычсызланган ябык чыраен күрде, гадәттәгегә караганда җитезрәк, кабаланыбрак хәрәкәтләнгән бармакларын күрде. Тавышының ничектер тотлыгыбрак, калтыраныбрак чыгуын шәйләде һәм шундук барысын да аңлагандай булды. Хәзер аның инәсен медальдән дә зуррак нәрсә борчый иде бугай. Аның менә хәзер шул борчыган нәрсәсен улына да әйтәсе килә иде бугай. Инәсен борчыган нәрсәләрне исә Габделхәй болай да сизенә иде, шуңа күрә ике арада булырга тиешле зур сөйләшүдә аның өчен әллә ни яңалык та булмаячак иде кебек.

— Мин сине, улым, орчык буе чагыңнан карап үстердем, — диде инәсе Габделхәйнең нәрсә дә булса әйткәнен дә көтмәстән. — Ун җыл буена атасыз карадым, ун җыл буена көттем мин шушы көнеңне. Кеше балалары арасында ким-хур булмасын, өсте бөтен, тамагы тук булсын дип тырыштым. Борлыкмасыннар, сөмсерләре коелмасын дидем. Сез бит өчәү! Бер капканда да — өч кашык! Әтәгез киткәч күргәннәремне, интеккәннәремне, бер ходай гына белә. Песи баласы кебек куеныма салып, җылы тынымны өреп... авызымдагын өзеп карадым мин сезне. Ярый, күрдем бу көннәрне. Таралмыйча, әрәм-шәрәм булмыйча, исән-имин үсеп җиттегез. Хәзер инде сездән дә рәхәт күрәсе килә.

Габделхәй бүлдермичә, караңгы чырай белән тыңлап кына утырды. Үскән чакта үзенең үзләренең нинди авырлыклар, нинди мохтаҗлыклар күрүләрен ул болай да белә иде. Шуңа күрә бу турыда сөйләп, аңлатып торуның кирәге юк. Сугыш елларында гына түгел, хәтта бүген дә — сугыш беткәнгә инде күпме вакыт үтүгә дә карамастан, әле булса алтын тауларының үсеп чыкканы юк. Тормыш һаман элеккечә авырлык белән, этеп-төртеп кенә барыштыра. Анысы шулай. Ләкин киләчәктә, һичшиксез, җиңел булачак, муллык-байлык булачак. Моңа беркем шикләнми. Бу турыда партия, иптәш Сталин ап-ачык итеп әйтте. Аннан соң, инәсенең элек гел үзем генә карадым, үзем генә азапландым, дип әйтүе дә бик үк дөрес түгел. Әтәсе яраланып кайтып яңадан сугышка китеп барганда ул инде кул арасына керә башлаган иде. Илгизгә күз-колак булу, Фидәилне тирбәтү, уйнату — барысы да аның өстендә иде. Үсә төшкәч, җаваплылык тагын да артты. Бары тик менә Илгиз үсеп арттан куып җиткәч кенә, соңгы бер-ике елда гына җаваплылык кими төште сыман. Габделхәйне гел карап үстердем, кеше иттем, дисәң, кеше ышанмас. Ул бары үз тырышлыгы белән генә алдынгы булды. «Мизал»

бирмәгәннәр икән, бирмәгәннәр. Шуның өчен генә аны тырышмаган, көч куймаган, дип әйтерсеңме әллә? Әнә, Назиф авыл малае, тормышлары да начар түгел. Барыбер әллә ни булдыра алмады. Чәйханә директоры, колхоз персидәтеле булу турында хыяллана. Институт турында хыялланмый, имеш, ул. Анда, имеш, шәһәр балалары гына, бай балалары гына укый, шуңа күрә Назиф институтларны яратмый, имеш. Тәтемәгәч яратмый инде. Син, инәкәй, үзең гел дөресен сөйләргә кирәк дисең, үзең әнә тузга язмаганны сөйләп утырасың. Габделхәең булмаса, Илгиз белән Фидәилне ничек карар идең дә, ничек кеше итәр идең аларны?

Үз алдына Габделхәй шулайрак дип уйланды, ләкин уйлаган уйларын кычкырып әйтергә шулай да йөрәге җитмәде. Аннан соң бу турыда әйтмәсәң дә була. Бит боларның барысы да көн кебек ачык!

Шәмсебанат апа, көч-куәт җыйган сыман, беравык тынып утырды да, яңадан сүзгә башлады.

— Киңәш юк, табыш юк, инә кешегә әйтү юк... — диде.

— Тагын ни булган? — диде Габделхәй түземлеген җуеп.

— Казанга биш җылга укырга китәсең ди ич... Дөрес түгелме әллә?

## X

Габделхәйнең өй эчендәге беркемгә дә үзенең эч серләрен, уй-хыялларын белдергәне юк иде. Унны бетергәч нишләү, кая китү-китмәү турында да әлегә бернинди сүз булмаган иде.

— Кем әйтте? — диде ул.

— Кем әйтсә дә, барыбер түгелмени? — диде инәсе. — Тагын синең биш җыл укыганыңны көт... Биш җылда кем бар да кем юк. Мин үлеп китсәм, нишләрсез үзегез генә? Илгиз белән Фидәил нишләр? Уйладыңмы шул турыда?

Соңгы сүзләрен ул калтыравык-кызганыч тавыш белән әйтте. Әллә чынлап та үзенең киләсе биш ел эчендә үлеп китү ихтималына ышанып, хәтта борынын тарткалап алды һәм кулындагы эшен ташлады да күлмәк кесәсендәге кулъяулыгына тотынды.

— Моңарчы әле өстерәлештереп килдек, — диде. — Син дә китеп барсаң мине дә эштән чыгарсалар...

— Нишләп сине... эштән чыгарырлар икән? — диде Габделхәй, берни аңламыйча.

Инәсе озак кына җавап кайтармады.

— Мизал белән җиңел генә институтка кермәкче булгансың да, анысына да керәлмәссең, ахрысы, — диде ул кинәт үз-үзенә каршы килеп.

— Медальсез дә керәчәкмен. Теләсә нинди институтка! — диде Габделхәй усалланып.

— Үзеңә үзең артык ышанасың, улым, — диде Шәмсебанат апа коры гына. — Синең шигырең кемгә кирәк хәзер?!

— Инәкәй! — диде Габделхәй, урыныннан торып, кызарынып. — Минем шигырьгә кагылма. Шигырьнең монда катнашы юк.

— Балалар бакчасындагы татар группасын ябачаклар, — диде инәсе, улының тузынуына әз генә исе китмичә.

Бу сүзләрне ул тирән бер өметсезлек белән, эчке бер тетрәнү белән әйтте. Габделхәй баштарак моны аңлап та җитмәде кебек, ләкин шул ук вакытта ул йөрәк турысында авыр таш барлыкка килүен тойды. Акылы аңлаганчы күңеле инде барысын сизеп алган иде.

Инәсе аның гомере буена диярлек балалар бакчасында тәрбияче булып эшләде. Балалар бакчасы аның икенче туган йорты сымаграк иде. Габделхәй бакчага йөрмәде, ләкин Илгиз белән Фидәилнең берничә елы шунда үтте. Дөресен әйткәндә, ач үлемнән аларны шул балалар бакчасы гына коткарып калды. Хәзер дә ул туйдырып, исән-имин саклап килә түгелме соң?

Инәсенең бу көтелмәгән хәбәре бөтен өй эченә килгән кайгы булып кына түгел, бәлки аннан да зуррак һәм шомлырак бер кайгы, фаҗига булып ишетелде. Габделхәйнең моңа ышанасы килмәде. Кинәт кузгатылган күңеленә урын тапмыйча ул аягүрә басты, ашыгыч эше бар кеше сыман тышка чыгып китте, тар ишегалдында әйләнгәләде дә янадан өйгә керде, янадан өстәл башына килеп утырды һәм тагын тышка чыгып китте. «Булмас, булмас! Мөмкин түгел!» — диде ул үз-үзен юатырга тырышып.

— Минем урысчам такы-токы. Бөтен нәрсә урыска әйләнгәч, без нишләрбез, улым? — диде инәсе Габделхәй янадан өйгә килеп кергәч. — Янадан авылга кайтып китәрбез микәнни?

— Кем әйтте, каян ишеттең? — диде Габделхәй, телгә килеп.

— Сәлимә апаңа ронода әйтеп җибәргәннәр: быел көзгә әзерләнеп торыгыз — татар группасын ябачакбыз дигәннәр.

— Ул нәрсә әйткән? — диде Габделхәй.

— Нәрсә әйтсен — аптырап кайткан. Эшебез эш булмады, ашыбыз аш булмады. Син берәр эшкә керсәң, ичмасам, Илгизне укытып чыгарыр иек. Мин хәзер бүтән эшкә ярамыйм. Нишләрбез, улым?

— Япмаячаклар! Ябып кына карасыннар! — диде кинәт Габделхәй йодрыкларын йомарлап — Хаклары юк! Булмас, ышанмыйм!

— Алар бездән хак сорап тормыйлар шул, — диде Шәмсебанат апа көрсенеп. — Аларныкы замана. Алар әйттеме — бетте!

— Бөтен кеше өчен закон бер. Совет законы! — диде Габделхәй, инәсенең мескенләнүенә ачуы килеп.

— Уфадан сезнең теге директорыгыз бутап кайткан ди. Шул тыкшына теләсә кая. Аннан, имеш, сораганнар, ул әйткән, имеш, мәктәпне дә гел урыска күчерәбез, кадрлар җитәрлек, фәлән-фәсмәтән, дигән, имеш. Башы аягы астына килгере, коры бугаз, тәмуг кисәве... Сугышка бармыйча качып ятты да, башкаларныкы кебек аның да мизал тагып йөрисе килә. Кара йөз!

Василий Михайловичның татар теле, татар әдәбияты, физика-математика турындагы сүзләренә Габделхәй тиешенчә игътибар итеп җиткермәде, ахрысы. Менә хәзер турыдан-туры үзенә, инәсенә, энеләренә — бөтен күнегелгән тыныч тормышка чын мәгънәсендә куркыныч янавы беленгәч, аңлаешсыз сыман булып тоелган сүзләр бөтенләй икенче яктан, чын мәгънәсе белән аңлашыла башлаган кебек булды. Шул ук вакытта Габделхәй үз гомерендә беренче мәртәбә мәктәп директорының ни дәрәҗәдә зарарлы, кара эчле кеше булуын да төшенде кебек. Үз-үзен, инәсен, энеләрен яклап аның көрәшкә ташланасы, мәкерле директорның барып бугазыннан аласы йә булмаса караңгы төндә берәр җирдә сагалап торып, түбәсенә таш белән тондырасы килде.

— Юк, андый закон, юк! — диде ул ишекле-түрле йөреп. — Бетереп кенә карасыннар... ябып кына карасыннар — Сталинга язам!

«Сталинга язу» гаделлекне яклауның иң соңгы һәм иң көчле ысулы иде. Мондый ышаныч хәтта иң көчсезгә дә көч-куәт бирергә, хәтта үлене дә тергезеп аягына бастырырга мөмкин сыман иде. Бу минутта Габделхәй чыннан да үзен тау-ташларны актара ала торган әкият батырыдай итеп хис итте. Аның шулай әтәчләнүенә инәсенең әз генә дә исе китмәде.

— Синең кебекләр тимер юлга эшкә кирәләр, — диде ул, бөтенләй икенче яктан суктырып.

— Кара эшче булыпмы?! — диде Габделхәй. — Майланып беткән сырма киеп... майлы чүпрәк тотып... күмер тузаны эчеп?!

— Кара киемне кисәләр дә, ак күмәч ашыйлар, — диде инәсе. — Кара кием киясең килмәсә, кантурга кер. Хисапчылар курсына укучылар кирәк ди әнә.

— Илектер станциясенә дә алалар малайларны өйрәнчек итеп, — диде шул чакны Илгиз дә сүзгә катышып.

— Кер үзең бик кирәк булса! — диде абый кеше тупас кына.

— Керермен дә шул! — диде Илгиз батыраеп.

— Менә, үстерәсең-үстерәсең дә аларны игелек күрермен дип...

Өйгә бер тиен файдасы тиярлек булмагач, ник кирәк миңа синең ун җыллык белемең? — диде Шәмсебанат апа олы улына.

— Туктале, инәкәй, — диде Габделхәй, тынычрак булырга тырышып. — Унны бетергән малайларны армиягә алалар икән диган сүз дә йөри. Алып куйсалар, барыбер минсез каласың ич.

— Булыр, булыр. Алырлар да җибәрерләр дә. Әле армиягә, әле институтка. Әдәм баласына бер дә үз илендә, үз өендә тормаска тиештер инде. Алалар, озаталар, таркаталар...

— Менә, күрдеңме?! Синең өчен барыбер түгелмени? — диде Габделхәй.

— Барыбер түгел, — диде Шәмсебанат апа. — Тимер юлга керсәң, армиягә дә алмыйлар, тамагың да тук була. Барыбер түгел.

— Мин тимер юлга эшкә кермәячәкмен, — диде Габделхәй нык итеп.

— Инәкәй! — диде шул чакны Илгиз. — Китсен абый укырга. Эшкә мин керермен — минем шагыйрь буласым юк.

— Шагыйрь... — диде Шәмсебанат апа. — Нәрсә әйтергә дә белмим инде мин сезгә. Моңлы кеше бәхетсез була, диләрие элек. Моңлы кеше, бәхетсез кеше эше ул шигырь язу. Затта юкны... Каян кагылгандыр сиңа шигырь җене.

— Каян булсын — картыйдан, синнән! — диде Габделхәй.

— Минем шигырь язганым булмады, кеше язганны гына күчереп яздым, — диде Шәмсебанат апа тыйнак кына. — Без үскәндә ярыйдырые ул. Хәзер әнә заманалар башка.

— Инәкәй, мин монтерлыкка укырга керәм, — диде Илгиз, тагын үзе турында искә төшереп.

Илгиз, абыйсыннан яшь ярымга кечерәк булса да, гәүдәгә аның белән бер чама иде. Быел ул тугызны бетереп унга күчкән иде.

— Бер җыл укыйсың калган, ничек була инде ул? — диде Шәмсебанат апа. — Шул кадәр тырышып укыт та сезне... син тагын җилгә очырырсың микәнни ул тугыз җылыңны?

— Унынчыны кичке мәктәптә укырмын, — диде Илгиз. Күрәсең, бу турыда ул инде күптән уйлап куйган иде.

Әллә уларының гел үзләренчә булырга тырышуларына, әллә чыннан да үз сүзен генә сүз дип исәпләгәнгә, ана кешенең тиз генә Илгизне дә яклыйсы килмәде. Үпкәләгән сыман, ул тынып калды һәм ашыгып бетмәстөкәнмәс ямавына тотынды.

## XI

Киләчәк турында сөйләш-аңлашу шуның белән төкәнде. Уртак фикер табылмады, һәркем үз фикерендә калды. Габделхәй дә, Илгиз дә, инәләрен артык борчымаска теләп, шыпырт кына чыгып киттеләр. Габделхәй үзенең бүген Фәрхәнә апаларга барырга сүз биргән исенә төшерде. Сәкинә дә исенә төште. Бит ул аңа да кичке сәгать сигездә очрашырга сүз биргән иде! Инде сәгать сигезенче. Кая барырга да белмичә, ул бераз вакыт икеләнеп торды. Акылы Сәкинә ягына тартты, күңеле нишләптер Фәрхәнә апаларга омтылды. «Ярар, бүген әле Сәкинә үзе дә чыкмас, эше күптер, — дип уйлады ул, билгеле бер карарга килеп. — Бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмаса — берсекөнгә, дип килештек ич. Шулай булгач...»

Шулай булгач, ул Фәрхәнә апаларга барырга тиеш.

Шәмсебанат апалар белән Фәрхәнә апалар гомер-гомергә дус-тату булдылар, бер-берсенә йөрешеп, ярдәм итешеп тордылар. Моның кайбер сәбәпләре дә бар иде. Яңавылның үзәк урамы исәпләнелгән Ленин урамының сазлы очына күченгәнче, Фәрхәнә апалар Шәмсебанат апаларга икеөч өй аша гына тордылар. Элегрәк, дөньялар имин чагында, алар бер-берсенә ашка-суга йөрештеләр. Мондый дуслыкның сәбәбе, билгеле, өйләрнең бер-берсенә якын урнашуында гына түгел иде. Шәмсебанат апа Фәрхәнә апаның ире Дәүләтгәрәй абзый белән яшьтәшләр һәм авылдашлар иде. Ан-

нан соң Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйнең әтәсе Котдус белән дә кордаш иде. Ирләре сугышта чагында Шәмсебанат апа белән Фәрхәнә апаның серләре тагын да ныграк килеште һәм өч ел буена алар чын мәгънәсендә бер гаилә кебек яшәделәр — кайгысы да, шатлыгы да, хәтта телеме дә уртак булды.

Дәүләтгәрәй абзый сугыштан Котдуска караганда иртәрәк кайтты. Әлбәттә, яраланып кайтты. Кайту белән үзенең элекке эшенә — райфога урнашты һәм сугыш беткәнче шунда утырып калды. Аларның тормышы гөрләп, тәгәрәп барды. Шулай да ике йорт арасындагы дуслык сүрелмәде. Һич югы, Габделхәйгә шулайрак тоелды. Күпчелек вакытларын алар Фәрхәнә апаларда үткәрделәр. Габделхәйнең үзенә дә, энеләренә дә анда беркайчан караңгы чырай күрсәтмәделәр, кыек сүз әйтмәделәр.

Йосыф белән яшьтәш булгангамы, Фәрхәнә апа да, Дәүләтгәрәй абзый да Габделхәйне аеруча якын күрделәр. Ни генә булмасын, Габделхәй дә аларны чын күңелдән яратты һәм, күрәсең, шуңа күрәдер, башкалар да үзен шул ук дәрәҗәдә яраталар, дип исәпләде.

Дәүләтгәрәй абзыйлар Ленин урамының иң кырыенда йорт урыны алып, шунда таудай яңа өй салып чыккач, аралар ерагайгач, ике арадагы мөнәсәбәтләр дә суына төшкәндәй булды һәм барып-килеп йөрүләр сирәгәя башлады. Габделхәйнең быел җәй Йосыфларда бөтенләй булганы юк иде әле.

Тоташ ак челтәрләр корылган, челтәр артында алсу чичкәле гөлләр елмаеп утырган зур, яңа тәрәзәләргә артык туры карамаска тырышып, шул ук вакытта челтәр аша кемнәрнеңдер үзен карап-күзәтеп торулары ихтималын уйлап, Габделхәй җиңел генә ачыла торган биек, яңа капкадан ишегалдына килеп керде. Шуннан соң, аяк астындагы кирпеч кисәкләренә басып, яңа киң баскыч алдына килде. Такта чолан ишеге дә, өй ишеге дә ачып куелган, ачык ишекләргә чебен кермәсен өчен тәрәзәдәге кебек челтәрләр эленгән иде. Ачык ишектән хуҗаларның шаулашып-гөрләшеп сөйләшкәне, Йосыфның ахрысы, скрипка шыңгырдатканы ишетелеп тора иде.

Колагына шат гөрелдек тавышлары ишетелү белән, борынына тәмле аш исләре килеп бәрелү белән Габделхәй шундук үзләренең ярлы өй эчен һәм әлерәк кенә булып алган күңелсез сөйләшүне исенә төшерде. Аларның өендә беркайчан менә шундый шат тавышлар да, скрипка шыңгырдавы да ишетелмәде, тәмле, итле аш исләре дә бөркелеп тормады, ахрысы. Габделхәйнең күңелендә шундук көнләшү һәм ачу тойгысы баш калкытты. Беркайчан берничек аңлатып булмый торган бер сиземләү белән ул үзен монда — бу иркен, яңа һәм бәхетле йортта нindидер хәвеф-хәтәр көтеп торганлыгын шәйләгәндәй булды. «Кунаклар бар. Кире борылып китәргәме әллә?» — дип уйлады ул икеләнеп.

Шулай да нindидер көчкә буйсынып, ул ачык ишектән эчкә керде һәм бик авырлык белән атлап ары юнәлде. Чолан уртасында туктап калды һәм йөрәге еш-еш типкән хәлдә, өй эчендәге, өстәл янындагы тавышларга колак салды. Юк, монда барысы да нindидер ят, ямьсез тавышлы кешеләр иде бугай. «Кермим!» — диде ул ныклы бер карарга килеп.

Ул инде кире борылып китәргә дә иткән иде, шул чакны нидер кычкырып өйдән Дездемона килеп чыкты. Дездемона — Фәрхәнә апаның сугыш бетәр алдыннан туган бердәнбер кызы иде. Дездемона шатланып, кулларын җәеп, Габделхәйгә килеп сарылды. Габделхәй аны күтәреп алды һәм алар сөйләнә-сөйләнә өйгә керделәр.

## XII

Олы якның түрендә, тәрәзә янындарак Йосыф белән Рамус басып тора иде. «Әһә, менә нинди ят тавышлы кеше бар икән монда!» — дип уйлады Габделхәй чыраен сытып. Рамус аның өчен иң яратмаган, иң җене сөймәгән кешеләрнең берсе иде.

Рамусны ни өчен яратмаганлыгын ул бик яхшы белә. Беренчедән, аны үзеннән тазарак булганы өчен яратмый. Икенчедән, аның төсен-битен, кыяфәтен җене сөйми иде. Аннан соң Рамус — Василий Михайловичның олы малае иде. Директорның үзен яратмагач, ул билгеле, аның малаен да ярата алмый иде.

Атасы кебек агач йөзле, балык күзле, дәртсез-җансыз кыяфәтле булуы өстенә, Рамус дөньяга килмәгән бер җайсыз, чорсыз һәм тәкәббер нәрсә иде. Ул беркайчан беркемгә, бернигә шатлана-куана да белми, гаҗәпләнә дә белми сыман иде. Аның өчен дөньяда, әйтерсең, барлык нәрсә таныш, билгеле. Ул инде бөтен нәрсәне күреп-белеп бетергән, барлык кайгы-шатлыкларны кичергән, бөтен җирдә булган, бөтен нәрсәне татып караган. Шуңа күрә ул, әйтерсең, дөньядагы һәркемнән остарак, белемлерәк һәм тәҗрибәлерәк иде. Кыскасы, бу дөньяда аның исен китәрерлек берни дә калмаган иде.

Йосыф белән алар Яңавылның тимер юлга карый торган уникенче урыс мәктәбендә укыдылар. Быел менә икесе дә Габделхәй кебек үк унны бетерделәр. Урыс мәктәбендә чыгарылыш имтиханнары әзрәк. Шуңа күрә алар өлгергәнлек аттестатын да бер атнага элегрәк алдылар. Инәсе татар теле һәм әдәбияты укытучысы булгангамы, Йосыф өйдә, тышта кеше арасында татарча сөйләшүдән әз генә дә тартынмый. Рамус исә ничек тә урысча гына сөйләшергә тырыша иде. Атасы директор булган татар мәктәбендә укучыларны ул, гомумән, кешегә дә санамый һәм шул нигездә Габделхәйгә дә гел кимсетеп карарга күнеккән иде.

Фәрханә апаның улы Йосыфның — Җобанай ягында бергә уйнап үскән Йосыфның Рамус белән дус булуы, шуның белән ниндидер уртак сүз табып сөйләшеп-серләшеп йөрүе Габделхәйнең күптән инде саруын кайната иде. Озак вакытлар аның Фәрханә апаларга килми йөрүенең сәбәбе дә Йосыфның үзенә карата менә шул хыянәте булды бугай. Менә хәзер дә аларның тәрәзә янында янәшә басып торган килеш чөке-чөке сөйләшүләре Габделхәйнең күңелен тырнап куйды. «Юкка килдем», — диде ул тагын да үз-үзенә үкенеп.

Аның килүен барысы да күреп алдылар, күреп алдылар да эшләреннән, сүзләреннән аерылып борылып карадылар. Йосыф кулларын сузып күрешергә килде. Габделхәй исә муенына сарылган Дездемонаны идәнгә бастырып куйды.

— Исәнмесез, — диде ул, Йосыфка кул биреп, ләкин чынлыкта бөтен өй эче белән исәнләшеп.

— Исәнме, Габделхәй, — диде Йосыф, елмаеп. — Әйдә, түрдән уз.

Күрешкәндә ул нык итеп аның кулын кысты һәм озак кына җибәрмичә селкеп торды. Үзләре мәктәбендә ул яхшы спортсмен исәпләнелә һәм үзенең чынлап та спортсмен икәнлеген сиздерү өчен күрешкәндә шулай кул көчен күрсәтергә ярата иде. «Көн дә итле аш ашасаң, кулың көчле була», — дип уйлады Габделхәй, Йосыфның шулай кулны озак җибәрми торуын яратмыйча.

— Котлыйм, кичәгенәк сез дә аттестат алгансыз икән, — диде Йосыф.

— Алдык, — диде Габделхәй тыелып кына.

Рамус та ашыкмыйча гына болар янына килде, авыз эченнән мыгырданып ниндидер котлау сыман сүз әйтте һәм, Йосыф кебек үк, Габделхәйнең кулын кысарга үрелде. Габделхәй аның нәрсә әйткәнен рәтләп ишетмәде дә, шулай ук аның кул кысуын да тоймады. Шул ук вакытта ул үзенең артында гына:

— Ә, Габделхәй икән! Менә әйбәт иткәнсең килеп, — дигән сүзләр ишетте.

Кече якның ачык ишегендә кояштай балкып Фәрханә апа басып тора иде. Ул анда мич алдында нидер пешерү белән булаша иде бугай — бит очлары кызарып чыккан, ак таза беләкләре сызганып куелган иде.

— Әле генә уйлаганыем — гомерең озын булыр әле, — диде Фәрханә апа. — Күрдеңме соң, бездә кунак бар.

— Күрдем, — диде Габделхәй, артык ачылып китмичә.

Күңеленнән уйлап куйды: «Андый кунакны күргәнеңнән күрмәгәнең артык». Фәрхәнә апаларның яңа өйләре элекке байларныкы кебек олы яклы, кече яклы итеп салынган иде. Кухня хезмәтен үти торган кече як белән олы як арасында тар гына аралык калдырылган. Бер яктан икенче якка кергәндә-чыкканда менә шул аралык аша үтеп йөриләр иде. Габделхәй аралыкта, олы як ишеге янында тукталып тора иде. Йосыф аны олы якка, Дездемона кече якка өндәде.

Нишләргә белми аптырабрак торганда ул кече якка борылып карарга мәҗбүр булды. Әле генә Фәрхәнә апа басып торган төштә ят бер кызны күреп ул дерт итеп китте. Ул аны таныды. Моннан берничә ел элек, бөтен өй әчләре белән килеп, алар Фәрхәнә апаларда ял итеп, кунак булып киткәннәр иде. Фәрхәнә апаларның читтә, гомумән, туган-тумачалары күп иде. Җәй саен алар Яңавылга ял итәргә кайталар, кайткан саен диярлек берәр балаларын калдырып китәләр иде. Моннан ике-өч элек Уфадан кунакка әлеге кызыйның тагын ниндидер дус кызы да бар иде. Алар бер-берсеннән калмыйча гел бергә тагылып йөриләр иде. Шуңа күрә аларның берсен дә ялгыз гына туры китереп тә, сүз кушып та булмый иде. Ул вакытта Габделхәй кызларның берсенә — менә хәзер кече як ишеге төбендә басып торганына чын-чынлап гашыйк булды һәм ай буе Йосыф янына керергә куркып, кыздан, үз-үзеннән оялып-качып йөрде. Әтәсе-инәсе белән кыз Уфага кайтып киткәч исә үзен тоткыннан котылган кебек хис итте. Ул чактагы тәэсирләр, хисләр-тойгылар, беркайчан җуелмый торган нурлы тап булып, серле сурәт булып, мәңге аның күңелендә сакланып калды. Еш кына Габделхәйгә ул үзе ярата алачак, үзен искиткеч бәхетле итәчәк хатын-кыз Сәкинә булып, хәтта Җәмилә булып та түгел, бәлки нәкъ менә шундый «нурлы тап» сыман булып тоелды.

## XIII

Башына ул маңгай турысыннан кысып, бик килешле итеп, авылча ак яулык бәйләп куйган, биленә түшләксез алъяпкыч бәйләгән иде. Үт тирәсендә, аш тирәсендә булашканга алсу бите тагын да ныграк кызарып чыккан. Сызганылган матур беләгенә, бармакларына чак-чак кына он буялып калган иде. Өсте-башы җыйнак, килешле — Габделхәйнең әле Яңавылда, Сталин клубында да, пассажир поездыннан төшүчеләр арасында да беркайчан мондый матур сынлы, күркәм һәм ягымлы кызны күргәне юк иде бугай.

Алар, бер-берсеннән күзләрен алмыйча, күпмедер вакыт карашып тордылар. Бу карашу әйтеп бетермәслек дәрәҗәдә озак булып тоелды. Шул ук вакытта бу карашу коточкыч тиз һәм аз да булып тоелды. Бер дә юктан Габделхәй кызарына башлады, тик торганда, бөтенләй кирәкмәгәндә үзенең өс-башына игътибар итте. Үз гомерендә беренче мәртәбә күргән сыман, үзенең тузанланган, катып беткән брезент өсле кара ботинкасына, сидрәп, таушалып беткән киң балаклы чалбарына, иске гимнастеркадан бозып тегелгән килешсез күлмәгенең җиң очларына карап алды. Шундый сылу шәһәр кызыннан бөркелеп торган нәфислек, исерткеч гүзәллек янында ул үзен бик мескен, ярлы һәм ахмак итеп тойды. Үзенең шул ярлылыгы, мескенлеге, ямьсезлеге өчен шундук күңелендә, мәңге бетмәс сызлавык булып, гарьләнү-хурлану ачысы баш калкытты. «Юкка килгәнмен», — дип уйлады ул тагын да төшенкелеккә бирелеп.

— Исәнмесез, — диде ул шулай да беренче булып.

Чибәр кыз җавап кайтармады — сөрмәле күзләрен тутырып аптыраган сыман карап тик торды. Ике арада уңайсыз тынлык барлыкка килде.

— Мин сезне беләм, — диде Габделхәй ашыгып.

— Шулаймыни? Исәнмесез, — диде кыз.

Ул моны ничектер бик җиңел генә, бер дә исе китмичә генә әйтте. Аның «исәнмесез»ендә Габделхәй хәтта үзенә карата саксызлык, салкынлык сизеп алды. Бу аны үтереп ташлагандай булды. Йөзендәге уңайсыз кызыллык шундук юк булды. «Тук. Чибәр. Шәһәр ялкаулары барысы да шундый», — дип уйлады ул кунак кызын түбәнсетмәкче булып.

— Былбылны беләсеңдер ич, Габделхәй? — диде Фәрханә апа янәдан ишек янына килеп.

«Әйе, исеме Былбыл иде бугай», — дип уйлады Габделхәй.

— Беләм, — диде ул.

— Син Габделхәйне беләсеңме соң? — диде Фәрханә апа бу юлы кызга эндәшеп. — Габделхәйне дә белмәгәч... Беләсеңдер. Бердәнбер Габделхәебез инде ул безнең.

Кулларын ак чалбар кесәсенә тыгып, алар янына Рамус килеп җитте. Күрәсең, ул Былбыл белән Габделхәйнең сөйләшүен читтән генә тыңлап торган иде. Көнләшүенә түзә алмыйча, кыз алдында үзен шәп кеше итеп күрсәтмәкче булып, ахрысы, һәм гадәтенчә шактый тупас итеп:

— Янавылда Габделхәйне белмәгән бер эт тә юк, — диде.

Рамус үзе шаяртам дип уйлады, ахрысы — үз сүзеннән үзе кызык табып көләргә тотынды. Дездемона да көлеп җибәрде. Фәрханә апа белән Былбылның йөзе үзгәреп китте. Шулай да алар, ипсез кунакларының урынсыз сүзләрен уенга борып, елмаерга мәҗбүр булдылар. Мондый шаяртуга бары Габделхәй генә елмая алмады. Бөтен тәне белән ул бер йодрыкка йомарланып калды. Аның, ярсып, оятсыз Рамуска ташланасы килде. Ләкин кеше өендә, кунак кызы алдында мондый нәрсә мөмкин түгел иде. Үз-үзен тыеп, шулай да таштай катып калган йөз белән Рамус ягына бер карап кына алды. Рамус аның бозылган йөзен әллә күрде, әллә күрмәде — шул ук тупас, дорфа шаярту белән шаярткан булып, Габделхәйнең аркасына кагып алды. Монысы инде чамадан тыш иде. Габделхәй, үзе дә сизмәстән, шаяртучының кулына сугып җибәрде һәм алай-болай сугышырга туры килсә дигән сыман, ашыгып олы якка таба атлады.

Ул кергәндә Йосыф янәдан үзенең скрипкасына тотынган һәм татарча ниндидер көй чыгарырга азаплана иде. Скрипка тавышы ярсыган Габделхәйне айнытып җибәрде. Берни булмаган кебек, ул ике тәрәзә арасындагы этажерка янына килде, урындыкка утырды да этажеркадагы таныш китапларны караштыра башлады. Шундук аның янына Дездемона килеп җитте, кылтаеп-чорсызланып кулына асылынды, нидер эзләп чалбар кесәсен актарды. Габделхәй, берни сизмәгәндәй, кулындагы китапка кадалып тик утырды. Ләкин әдәпсез кызый куен кесәсеннән шигырь язылган куен дәфтәренә тотынгач, түзмәде, каты гына итеп карак кулны тотып алды да өйдәгеләр игътибар итмәс дәрәҗәдә тыелып кына:

— Сиңа кирәкми ул, — диде.

— Шигырь дәфтәре! Шигыреңне укы әле! — диде кызый, тарткалашып.

Якында гына, идән уртасындагы озын аш өстәле янында, Былбыл табак-савыт урнаштыру белән мәшгуль иде. Габделхәй аның нидер эшләвен күреп-сизеп утырды, ләкин бер генә мәртәбә дә күтәрелеп карамады. Дездемонаның «шигырь» турында сүз чыгаруы аның җен ачуларын кузгатты.

— Кит әле моннан! — диде ул, кызый кулын янә читкә этәреп.

«Шигырь» сүзен Былбыл да ишетеп калды. Эшеннән туктагандай итеп, ул Габделхәй ягына борылды һәм:

— Бүгенге газитта сезнең шигырь басылганмы әллә? — диде.

Газиттә басылган шигырь астына авторның исем-фамилиясе язылган иде, шуңа күрә аның кемнеке икәнлеген сорау урынсыз иде.

— Минеке, — диде Габделхәй шулай да башын калкытмыйча гына.

— Миңа бик ошады сезнең шигырегез, — диде Былбыл.

Габделхәйгә рәхәт булып китте. Ул инде чибәр кыз белән янәдан татулашырга да, ягымлы итеп сөйләшә башларга да әзер иде, ләкин шул вакыт алар янына тагын сөйкемсез Рамус килеп җитте һәм Габ-

делхәйне мактаган сыман, чынлыкта исә аның дәрәҗәсен төшерергә тырышып:

— Это — наша знаменитость!* — диде.

Габделхәйнең йөзенә кан бәрде. Ләкин ул, берни ишетмәгәндәй, башын калкытмыйча, тешен кысып, урынында берегеп утыруында булды. «Күрсәтермен әле мин сиңа «знаменитость»ны!» — диде ул үз-үзенә көчсез бер ярсу белән.

## XIV

Ул арада Йосыф скрипкасын көйләп бетерде һәм җылатып, чыңлатып нииндидер ямьсез көй уйный башлады. Уйнаучы алдында яхшы атлы булып күренергә тырышып, барысы да ахмакларча тынып калдылар. Габделхәй тыңламады һәм үз-үзен мәҗбүр итеп, китаптагы ниндидер физик формуланы аңларга тырышты. Ул инде бер үк сүзләрне биш-алты мәртәбә укып чыкты, ләкин бер нәрсә дә аңлый алмады — бөтен игътибарын буташтырып, ачу һәм нәфрәт көчен таркатып, колак төбендә туктаусыз скрипка чыңлады.

Йосыф уйнап бетергәч, беренче булып Рамус кычкырды:

— Браво! Браво! Во какие у нас таланты![1] — диде.

— И-и Йосыф, шундый матур итеп уйнадың, — диде Былбыл сузып, кылтаеп.

Чытык йөзле Фәрхәнә апа, кече яктан сузылып карады да, Йосыфка эндәшеп, ләкин чынлыкта Габделхәйне күз алдында тотып:

— Йосыф, юынты суын гына түгеп кер әле, — диде.

Габделхәй кичәгенәк мәктәптә дә Фәрхәнә апаның юынты суы түктерүен исенә төшерде һәм яратмыйча: «Нинди бетмәгән су инде ул?» — дип уйлады. Уфа кызы исә, Рамус белән Йосыф алдында үзенең эшчәнлеген күрсәтмәкче булып, тиз генә кече якка чыгып китте һәм бөтен өйгә чәрелдәп:

— Үзем чыгарырмын, чибәрттәй! — диде.

Аңа булышка дип шундук маймул Рамус кузгалды, атасы кебек мыштырдык Йосыф кузгалды. Ләкин алар килеп җиткәнче кунак кызы тулы чиләкне җилтерәтеп алып чыгып та китте. Каш астыннан як-ягына карангалап, Габделхәй аларның шулай тыз-быз килүен ачу белән күзәтеп утырды. «Эшләгез, шул кирәк сезгә!» — дип уйлады ул зәһәрләнеп. Маймул Рамус шулай да кызны куып җитте, ахрысы — Габделхәй аларның чыркылдашып тышкы ишектән чыгуларын ишетеп утырды. «Нинди эшчән!» — дип уйлады ул, «маймул» турында. Үзләрендә бер дә эшчән түгел. Халидә апа нәрсә кушса да, эшлисе килмичә кырык сүзгә җитешә. Монда әнә нинди өлгер, нинди җитез!

Габделхәй карасына коелып, үз алдына үртәлеп утырганда каяндыр Дәүләтгәрәй абзый кайтып керде. Ачык ишек аша Габделхәй аның кулында авыр гына сумка булуын күреп калды. «Магазиннан кайтты», — дип уйлады ул яратмыйча. Дәүләтгәрәй абзый райфо кешесе. Ниндидер начальник. Бәләкәй генә начальник булса да, Яңавылдагы теләсә нинди олы начальник белән әшнә. Яңавылда аны белмәгән кеше юк. Кайда да аның сүзе сүз. Кирәк нәрсәне алар итәк астыннан гына алалар, менә шулай караңгы төшкәч кенә алып кайталар. Үзләре алып кайтасылары килмәсә, китереп бирәләр. Авылдан колхоз персидәтелләре тәпән-тәпән бал, түшкәсе белән ит калдырып китәләр. Белми түгел, беләбез — барысы да күз алдында. Шуңа да аларда һәр көнне итле аш пешә, атна саен кунак була. Яши белә ул Дәүләтгәрәй абзый! Беркем белән бозылышмый, беркем белән ачуланышмый.

---

* — Бу безнең атаклы кешебез!

[1] — Шәп! Шәп! Менә нинди талантлар бар бездә!

Кече якта сумкасын калдырып, Дәүләтгәрәй абзый олы якка чыкты. Габделхәйне күреп алды да:

— Исәнме, Габделхәй,—диде салмак кына.—Инәң нишләп ята, хәле ничек? Илгиз белән Фидаил ни хәлдә?

Дәүләтгәрәй абзыйның беренче булып исәнлек-саулык сораштыруы, тыныч, ягымлы тавышы Габделхәйне юаткан сыман булды. Никтер аның кинәт җылыйсы һәм Дәүләтгәрәй абзыйга зарланасы килде.

— Инәкәйнең кәефе юграк әле,—диде ул.

— Чирләп киттеме әллә?

— Шулай бугай,—диде Габделхәй.

— Сез борчыйсыздыр инде... Илгизме, Фидаилме...—диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Борчымадык шикелле,—диде Габделхәй.

Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйгә якын гына урындыкка утырды да, бик нык арыган кеше сыман, күнитекле аякларын сузып җибәрде. Йөгергәләп аның янына Дездемона килеп җитте һәм нечкә генә куллары белән әтисенең күнитеген салдырмакчы булып көчәнә башлады. Ул шулай олыларның аяк киемнәрен салдырырга ярата иде. Дәүләтгәрәй абзый урыныннан торды һәм, утырган урындыгын да алып, «ишек төбенә»—кече як белән олы як арасындагы аралыкка чыкты. Габделхәй үз урынында утырып калды. Якында гына Дездемонаның көлә-көлә чыр-чу килеп итек салганы, Дәүләтгәрәй абзыйның иренеп кенә үскән кызын мактаганы ишетелеп торды. Дәүләтгәрәй абзый, җай гына, салмак кына сөйләшә иде, шуңа күрә аның кайчан ачуланганын, кайчан шатланганын бик үк белеп тә булмый иде.

Бераздан кайдадыр югалып торган Йосыф та скрипкасын күтәреп олы якка чыкты. Аның артыннан ук Дездемона белән Дәүләтгәрәй абзый килеп керде.

— Әти, тыңлале,—диде Йосыф, яңадан скрипкасын шыңгырдатмакчы булып.

Урысча укыса да, Йосыф шулай китапча «әти-әни» дип сөйләшә һәм сүз арасында Яңавылча булмаган кайбер ят сүзләр кыстыргалый иде. Чыкылдап торган татар баласының әтисе-инәсе белән урысча сөйләшүе ни дәрәҗәдә ят һәм кыргый булып тоелса, Яңавыл шартларында Йосыфның шулай «әти-әни» дип сөйләшүе дә ят һәм кыргый булып тоела иде. Шулай да китапларда «әти-әни»не күп укыганга, Габделхәйгә аның тел бозуы әллә ни зыянлы булып тоелмады.

— Тыңлыйм, улым, тыңлыйм,—диде Дәүләтгәрәй абзый тыныч кына.—Бер җылда бер көй үрәнсәң, ярый инде.

— Тыңлале син, әти, тыңлале!—диде Йосыф һәм әлерәк кенә уйнаган көйне яңадан чыжлата башлады.

Дәүләтгәрәй абзый бирелеп тыңлады. Аның белән бергә Габделхәй дә тыңлады. Хәзер аңа Йосыфның уйнавы дәртлерәк, матуррак, дөресрәк сыман тоелды. Берничә минут эчендә Йосыфның шулай оста итеп уйнарга өйрәнүенә ул шаккатты. «Менә ичмасам талант!»—дип уйлады ул үз алдына.

Шул чакны ашыгып, көлешеп олы якка Былбыл белән «маймул» килеп керде. Йосыф һаман уйнавын дәвам итте, ләкин ягымлы скрипка тавышы Габделхәй өчен кинәт ишетелми башлады. Тынычлык югалды һәм бөтен өй эче караңгыланып калгандай булды.

## XV

Ниһаять, күптән көтелгән аш өлгерде. Терсәкләрен як-якка тырпайтып, ике куллап зур, авыр мискинең тоткаларын чүпрәк белән тоткан килеш, кече яктан Фәрханә апа чыкты. Мискине җайлап кына олы яктагы өстәл уртасына китереп куйды һәм канәгать төс белән елмаеп, өй эчендәге яшьләргә күз йөртеп алды. Аның артыннан ук диярлек бер-берсе өстенә куелган кошта-

баклар күтәреп Былбыл керде, җитез генә кыланып коштабакларны тезеп чыкты. Ул арада озын саплы чүмеч тотып, кылтаеп, як-ягына каранып Дездемона килеп җитте. Фәрханә апа иркә кызының кулыннан озын саплы чүмечне алды да коштабакларга кайнар шулпа бүлә башлады.

— Әйдәгез, кунаклар, утырыша башлагыз,— диде Дәүләтгәрәй абзый, яшьләрне табын янына чакырып.

— Әйдәгез, әйдә,— диде Фәрханә апа да.

Иптәшләрен кыстап-нитеп тормыйча өстәл янына беренче булып Йосыф утырды. Аның янындагы урындыкка тиктормас Дездемона менеп утырды. Габделхәйнең урын сайлап торасы юк иде ул болай да өстәлгә якын гына утыра иде. Шунлыктан урындыгын беркадәр күчергәндәй генә итте. Аның урыны Йосыфның икенче ягына туры килде. Рамус, ниндидер сәбәп тапкан булып, һаман читтә буталды. Бүтән вакыт булса, әйткәнне дә көтеп тормастан, өстәлнең түрге башына ук килеп утырган булыр иде. Хәзер ул ашыкмады — Былбыл утырганны көтте. Габделхәй моны бөтен күңеле белән сизеп утырды. Алай гына да түгел, ул хәтта алар арасында инде ниндидер сөйләшү-аңлашу булуын да чамалап алды.

— Сиңа нәрсә әйтелде, ник утырмыйсың!— диде Дездемона, Рамус янына килеп.— Әйдәле, әйдә!

Габделхәйгә кылтык кызның кыланышы беренче мәртәбә көлке тоелды. Канәгать йөз белән ул үз алдына көлемсерәп куйды. Рамус, Дездемонаның сүзен тыңлаган сыман итеп, өстәлнең ишеккә караган башына — Габделхәйгә каршы якка килеп утырды. Аның бер ягында буш урын калды. Ул, күрәсең, Былбыл шунда утырыр дип чамалады. Ләкин буш урынга Фәрханә апа килеп утырды. Аңа моннан кирәк чакта торып китәргә, кече якка чыгып керергә җайлы иде. Маймулның икенче ягында Дәүләтгәрәй абзый. Дәүләтгәрәй абзыйның икенче ягына Былбыл килеп утырды. Габделхәй җиңел сулап куйды. Шәп булды Маймулга!

Ашый башлаганчы Дәүләтгәрәй абзый иелеп өстәл астыннан бер шешә ак аракы алды да, башта үз рюмкасына салды, аннан соң яшьләр алдындагы рюмкаларга тамызып чыкты.

— Балалар, мине тыңлагыз әле,— диде ул яшьләргә карап.— Бүген бездә бәйрәм. Бу көнне без күптән көттек. Әйтеп куйган сүзебез дә барые — Йосыф унны бетерсә, яшьләрне җыеп күңел ачарбыз, дип. Заманында безнең үзебезгә болай аш-су ясап, күңелле итеп утырулар төшмәде. Балаларыбыз рәхәт яшәсен, дидек. Сезнең өчен дә, безнең өчен дә куанычлы көн бүген. Сез менә унны бетердегез, яңа тормышка аяк бастыгыз. Нур өстенә нур булып Уфа кызыбыз да килеп төште. Кая соң әле үзе?

Дәүләтгәрәй абзый кайчагында шулай шаяртырга ярата иде. Былбылны күрмәгән сыман кыланып, ул каршы яктагыларга игътибар беләнрәк карап чыкты. Дездемона кычкырып көлеп җибәрде. Дәүләтгәрәй абзыйның уң ягында утырган Былбыл шулай ук чын күңелдән көләргә тотынды.

— Монда ич мин, җизнәй!— диде ул.

— Әй, монда икәнсең!— дигән булды шат күңелле Дәүләтгәрәй абзый.

Юан бармакларының очы белән генә тотып ул тулы рюмканы кулына алды һәм бу юлы инде беркемгә дә карамыйча гына:

— Сезнең хөрмәткә эчеп җибәрсәм, ачуланмассыз,— диде.

— Ачуланмыйбыз, ачуланмыйбыз!— дип кычкырды беренче булып әдәпсез Рамус.

Дәүләтгәрәй абзый аракының тамчысын да калдырмыйча эчеп бетерде дә тәлинкәдән каклаган каз ите алып чәйнәргә тотынды.

— Әйдәгез әле, иптәшләр... балалар, житешегез,— диде Фәрханә апа яшьләрне ашарга кыстап.

— Сезне болай аздыру килешеп тә бетми инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый, яңадан сүзгә башлап.— Әллә иң элек эчеп җибәрсеннәр микән, Фәрханә?

— Мин каршы түгел,— диде Фәрханә апа.— Алар хәзер олы кешеләр. Үз акыллары үзләре белән.

— Без эчмибез, җизнәй, кыстый күрмә, — диде Былбыл.
— Юк, юк, эчәбез! — диде Маймул каршы килгән булып.
— Әйдәгез әле, әйдәгез, ашагыз, — диде Фәрхәнә апа кыстап.
— Кая соң минем кашык? — диде шул чакны Былбыл як-ягына каранып, эзләнеп.

Барысы да ашауларыннан туктап, аның ягына борылып карадылар.
— Үземә кашык куймаганмын ич мин! — диде Былбыл көлеп һәм тиз генә урыныннан торды да кашыкка дип кече якка йөгерде.

Былбыл чыгып китү белән Дәүләтгәрәй абзый ашаулык астына яшерелгән кашыкны алып Былбыл коштабагы янына куйды. Былбыл кашык алып килеп яңадан үз урынына утырган иде, өстәлдә кашык күреп, чын күңелдән аптырап калды, аңлап алды да көләргә тотынды. Аңа ияреп бүтәннәр дә көлешә башладылар.
— Кем эше бу? Йосыфтыр әле! — диде Былбыл Йосыф ягына каранып.
— Йосыф булмый кем булсын? — диде Дәүләтгәрәй абзый. — Бар этлек шул Йосыфтан чыга. Разведчик булыр, ахрысы, минем улым.
— Түгел! Түгел! — диде Дездемона, кулларын чәбәкләп. — Йосыф абый түгел, эти үзе!
— Балалы өйдә бур тормас, — диде Фәрхәнә апа. — Ашап кына утырыгыз әле, иптәшләр... балалар.

Иптәшләр... балалар ашап кына утырдылар да. Бер коштабак токмачлы ашны күз ачып йомганчы ялт итеп куйдылар. Аштан соң бәрәңге, кишер, кәбестә белән аралаштырылган йомшак бәрән ите килде. Иткә тотыныр алдыннан Дәүләтгәрәй абзый тагын икенче рюмка тәкъдим итте, ләкин артык кыстап тормады — башкалар күрмәсен дигәндәй, үзе тиз генә эчеп җибәрде.
— Белеп ашагыз — безнең иң олы кызыбыз Диздәкәй карап үстергән бәрән булыр бу, — диде Дәүләтгәрәй абзый.
— Алдый, алдый! Үзә карады, — диде олыларча сөйләшергә ярата торган кызчык.

Итле бәрәңге дә ашалып беткәч, Фәрхәнә апа зур табада томалап пешерелгән балык китерде. Балыклы таба өстенә бәлеш кебек итеп камыр капланган иде. Табаны Фәрхәнә апа туп-туры өстәл уртасына китереп утыртты, пычак очы белән каерып камыр капкачны ачты һәм капкачны өске ягы белән буш коштабакка куйды. Табада түгәрәк күзләре ап-ак булып пешкән кушбашлар, алабугалар тезелеп ята иде.
— Менә болары Рамус белән Йосыф тоткан балыклар, — диде Фәрхәнә апа аңлатып.
— Монысын кем тотты? — диде Былбыл, иң зур балыкка күрсәтеп.
— Мин! — диде Рамус.
— Тоттың! — диде Йосыф көлемсерәп.
— Тагын кайчан барасыз балыкка? Мине дә алып барыгыз әле, Йосыф, — диде Былбыл.
— Браво! Барабыз! — диде Рамус.

Фәрхәнә апа балыкларны һәркемгә тигез итеп бүләргә тырышты. Тик менә иң олы кушбаш мәсьәләсендә генә икеләнгәндәй итеп калды.
— Туктале, монысын тоткан кешенең үзенә бирик, — дип уйлады Габделхәй, олы кушбаштан күзен алмыйча. Башкалар да шулайрак дип уйлады, ахрысы.
— Әтигә бир. Иң олысы — этигә! — диде Йосыф.
— Ярар алайса, — диде Фәрхәнә апа шундук килешеп.

Габделхәйгә бер кушбаш белән алабуга туры килде. Балыкны ул теләртеләмәс кенә ашады. Никтер аңа нәкъ шул балыкларны Маймул Рамус тоткандыр сыман булып, ашый башлау белән аның бөтенесе алдында: «Бу балыкларны мин тоттым!» — дип кычкырыр сыман тоелды.

Яшьләр балык ашаган арада Фәрхәнә апа тагын кече якка чыгып китте, аның чыгуын күреп, Былбыл да аның артыннан кузгалды. Теге якта мич алдында шакы-шокы килеп алар нәрсәнедер күчерделәр, нәрсәнедер әвештүеш китерделәр. Балыкны да ялт итеп куйгач, өстәл янындагылар беравык

тынып утырдылар. Урыныннан беренче булып Дәүләтгәрәй абзый кузгалып китте. Аннан күрмәкче дигәндәй, Йосыф та кузгалды.

— Таралышмагыз, хәзер баллы катык белән җимеш суы килә,— диде Фәрхәнә апа, кече яктан чыгып.

— Мин җимеш суын эчтем инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Кунакларны сыйла, балаларны...

Стаканнарга салынган җимеш суын олы якка Былбыл алып чыкты. Бал катыштырып тәмләтелгән салкын катыкны тыштан Фәрхәнә апа алып керде.

— Катыгы үзебезнеке,— диде Фәрхәнә апа, аңлатырга кирәк табып.— Өрекләре, йөземнәре — Былбыл кучтәнәче.

— И-и чибәрттәй, кеше алдында оятлы итәсең инде,— диде Былбыл уңайсызланып.

## XVI

Баллы катык ашалып, җимеш суы эчелеп беткәч, яшьләр таралыша башладылар. Йосыф скрипкасына тотынды. Фәрхәнә апа белән Былбыл олы яктан кече якка табак-савыт ташыдылар. Дәүләтгәрәй абзый тышка чыгып китте. Габделхәй, Йосыфның скрипка шыңгырдатуын тыңлагандай итте дә, шулай ук тышка чыкты. Бераздан скрипкасын күтәргән Йосыф та күренде. Алар баскычта тын алып, җилләнеп утырганда Рамус чыкты. Аның баскыч төбендәгеләр янында туктап торасы килмәде — каядыр ары китеп барды. Йосыф туктаусыз скрипкасын көйләвендә булды. Дәүләтгәрәй абзый белән Габделхәй аның уйнавына колак салгандай итеп, тын гына утырып тордылар.

— Ничек соң, Габделхәй, кая китәргә, нишләргә исәп? — диде бераздан Дәүләтгәрәй абзый.— Безнең җегетләр әнә Казанга, авиационныйга кермәкче булалар.

Йосыфның Казанга, авиация институтына китәргә ниятләвен Габделхәй болай да белә иде, ләкин аның «җегетләр» белән китәргә исәпләвен ул әле белми иде. Димәк, бергә барачаклар Казанга, керсәләр — бергә укыячаклар.

Алар янына Былбыл да чыкты һәм өске басмада тоткарланып калды. Дәүләтгәрәй абзыйның соңгы сүзләрен ул ишетеп калды бугай.

— Сез бит әле өчегез дә быел унны бетердегез, иеме? — диде ул.

Соравын ул беркемгә дә төбәп әйтмәде, шулай да Габделхәй аны үзенә атап әйтелгән дип аңлады. Бу тагын да баягынак кунак кызының: «Бүгенге гәзиттә ул сезнең шигырь басылганмы әллә?» — дигәне сымаграк булды, чөнки аларның өчесенең дә, быел унны бетерүләре турында инде сүз булган иде.

— Сезгә филолог булырга кирәк, Габделхәй,— диде Былбыл.— Шигырь язучыларның барысы да филолог булалар. Безнең университетта татар кафедрасы бар...

Габделхәй сагая калды. «Университет», «кафедра» сүзләрен аның элек тә ишеткәне бар иде, тик менә аларның мәгънәләрен генә төгәл аңлап җитми иде. «Филолог»ны ул, гомумән, белми иде. Ят, серле һәм аңлаешсыз иде ул «филолог» сүзе. Хәзер менә Былбылның ят, аңлаешсыз сүзләрне шундый тиз һәм җиңел әйтүе Габделхәйгә гаҗәеп тылсым кебек тәэсир итте. Чибәр кунак кызы аңа искиткеч башлы һәм белемле булып тоелды.

Ике арада сүз шулай җайланып китәргә генә торганда каршыга көтмәгәндә Маймул килеп басты.

— Фу, филолог! — диде, кулын селтәп.

Аңа беркем игътибар итмәскә тырышты, ләкин тыныч кына утырганда безелдәп килеп җиткән, биткә, күзгә кунган черкигә игътибар итмәү мөмкин булмаган кебек, бу әдәпсез бәндәгә дә игътибар итмәү мөмкин түгел иде.

— Филологка ни булган? — диде Габделхәй тыелып кына.

Рамус җавап биреп тормады, ямьсез көлеп тагын кулын гына селтәде. Ярый әле шул чакны Фәрхәнә апаның тавышы ишетелде — ул да тын алырга дип баскыч төбенә чыккан иде.

— Университетта татар кафедрасы бармыни? — диде Фәрхәнә апа, бик нык гаҗәпләнеп.

— Бар! — диде Былбыл. — Кырык дүртенче елны ачканнар.

— Без монда берни белми ятабыз, томаналар, — диде Фәрхәнә апа, үзүзен тәнкыйтьләп.

— Татар кафедрасында шагыйрьләр, язучылар укый, — диде Былбыл.

— Әдәби кичәләр оештыралар, үзләренең газеталарын чыгаралар.

— Без укыганда да әдәби кичәләр буладырые, — диде Фәрхәнә апа. — Безнең янга да язучылар киләдерие. Бервакыт Такташ килде.

— Такташ?! — диде Габделхәй. — Сезнең әйткәнегез булмады бугай.

— Исемнән чыккандыр, — диде Фәрхәнә апа. — Кутуй да килә торганые.

— Фәрхәнә апаң ул... Галимҗан Ибраһимовны үз күзләре белән күргән кеше, — диде Дәүләтгәрәй абзый беркадәр серле һәм тантаналы итеп.

Мондый сүз ишетеп, баскыч төбендәгеләр тынып калдылар.

— Теге... халык дошманымы? — диде Габделхәй, үзенең белемле икәнлеген күрсәтәсе килеп.

— Утыра шунда юк-барны лыгырдап! — диде Фәрхәнә апа Дәүләтгәрәй абзыйга ачуланып. — Ул чакта кем белгән аның халык дошманы икәнен? Маңгаена язып куймаган — кеше кебек кеше.

— Кызык, — диде Былбыл. — Сөйләле, чибәрттәй, ничек күрдең? Безнең әти гел искә төшерә аны.

— Кемне? Галимҗан Ибраһимовны?! — диде Габделхәй коты алынып.

— Галимҗан Ибраһимовны, Солтангалиевне, Гаяз Исхакыйны, тагын әллә кемнәрне! — диде Былбыл.

— Ярар, балалар, бик кычкырып сөйләшмәгез, — диде Фәрхәнә апа тынычсызланып, як-ягына каранып.

— Әйдәгез, өйгә керик, — диде Дәүләтгәрәй абзый да.

Барысы да кузгалышып куйдылар, керә торган якка борылдылар.

— Хәзер дә безгә язучылар килә, диспутлар була, автографлар бирәләр, — диде Былбыл.

«Нәрсә соң ул диспут, автограф?» — дип сорыйсы килде Габделхәйнең, ләкин сөйкемсез Рамус һәм Былбыл алдында надан булып күренмәс очен сорамаска булды. Чынында ул андый ят сүзләргә игътибар да итмәде — аны хәзер каршылыклы уйлар биләп алды. Шундый чибәр һәм акыллы кызның җиңел генә, хәтта тотнаксыз рәвештә үз әтисенең халык дошманы Ибраһимовны, фашистлар, империалистлар ялчысы Солтангалиевне, Гаяз Исхакыйны белүе турында авыз тутырып, кычкырып сөйләве аңлашылып җитмәде.

Үзенең бик зур хата җибәрүен Былбыл үзе дә төшенмәде, ахрысы.

— Беләсезме, безнең университетта тагын кем укыган? Толстой! — диде ул сүзне икенчегә борып.

— Кайсы Толстой әле ул? — диде Фәрхәнә апа.

— И-и чибәрттәй! — диде Былбыл. — Шуны да белмәгәч инде!

— Язучы Толстойлар икәү-өчәү булган түгелме соң? — диде Фәрхәнә апа, Былбылның тәнкыйтенә әз генә дә исе китмичә.

— Өчәү! — диде Рамус. — Лев Толстой, Граф Толстой[1], Алексей Толстой.

— Бөек Толстой бер генә — Лев Толстой! — диде Былбыл шактый тантаналы итеп.

— Граф Толстой тоже был великим, — диде Рамус.

— Граф Толстой шул ук Лев Толстой бит инде! — диде Былбыл көлеп.

Ләкин Рамусның бирешәсе килмәде һәм ул кычкырып, кулларын бутап Граф белән Левның икесе ике Толстой булуын исбатларга тотынды.

Габделхәй бәхәскә катнашмаска тырышты. Ул Былбылның чыннан да күп белүен күрде. «Филологлар шундый белемле була торганнардыр инде, — дип уйлады Габделхәй. Ул да филолог булырга тиеш. Шагыйрь генә түгел, филолог та!

---

[1] — Граф Толстой да бөек язучы булган.

Толстойлар турындагы бәхәс өйгә кереп яңадан урыннарга утыргач та дәвам итте. Былбыл Казан университетында укыган бик күп атаклы кешеләрнең исемнәрен әйтте. Ленин, Лобачевский, Щапов... дип тезеп китте.

— Горький! — диде Рамус янә барысыннан да уздырмакчы булып.

Былбыл тагын каршы килде һәм Горькийның Казан университетында укымаганлыгын исбат итә башлады. Рамус бирешергә теләмәде. Былбыл, яклау эзләп, башта Йосыфка, аннары Габделхәйгә карап алды. Йосыфның әдәбиятка кагылышлы бәхәскә кереп торасы килмәде.

— Мин инде литературадан экзамен бирдем, «отлично»га, — диде ул әтисе кебек тыныч кына.

Былбыл да, Рамус та көләргә тотындылар. Габделхәй көлмәде. Аның күңеленә бер уй килде. «Казан университетында бер генә атаклы татар да укымады микәнни?» — диде ул үз-үзенә һәм дәрестә үткән, аннан-моннан укып белгән гыйлемен барларга тотынды. Аның хәзер ничек тә берәр атаклы татар исеме әйтеп ялтырап аласы килде. Ләкин, никадәр исенә төшерергә тырышмасын, андый кешене хәтерли алмады.

— Белдем! — диде ул кинәт. — Каюм Насыйри да Казан университетында укыган!

Былбылның кызып бәхәсләшүдән кызарып чыккан йөзе сүрелеп калды. Каюм Насыйриның Казан университетында укуын-укымавын ул, ахрысы, белеп җиткерми иде, ләкин Казанда берничә татар галиме булганлыгын шулай да чамалый иде, ахрысы.

— Бездә Җәләй бар, Камай бар, — диде ул.

— Ну, пошло![1] Бездә, бездә... — диде Рамус яратмыйча, хәтта нәфрәт белән. — Подумаешь, великие татарские ученые![2]

Маймулның бу мыскыллы сүзләре турыдан-туры Габделхәйнең йөрәгенә килеп кадалды. Аның бөтен эче-тышы актарылып чыкты, үзеннән-үзе йодрыклары йомарланды. Ул яңадан тешен кысып эндәшми калырга мәҗбүр булды. Шулай да мондый киеренкелек озакка бармады — көтмәгәндә өйгә таныш скрипка чыңлап китте. Чәче кыска итеп алынган, озынча зур башын чак-чак кына кыңгыр салып һәм бөтен гәүдәсе белән як-якка селкенгәләп, Дәүләтгәрәй абзый «Салкын чишмә»не сыздыра башлады. Скрипка тавышы бераз гына карлыккан сыман тоелды, шулай да аның дәртле, моңлы һәм тынычландыргыч авазлары бөтен өй эчен тутырды, ачык тәрәзәдән тышка, кичке тынлыкка агылып чыкты.

Шәп итеп, яхшы итеп скрипкада уйнарга өйрәнү Дәүләтгәрәй абзыйның күптәнге хыялы иде. Ул аңа яшь чагында музыка түгәрәгенә йөргәндә өйрәнештереп калган иде. Ләкин менә шул бик күптән өйрәнештереп калганыннан артыгын өйрәнергә аның вакыты да, мөмкинлеге дә булмады. Ул уйный белгән көйләр дә бик күптәнге иде, музыка түгәрәгендә отып калган көйләр генә иде. Күңеле аеруча нечкәргән чакларда ул менә шуларны яңадан казып чыгара һәм тыңлаучылар алдында шуның белән бераз гына мактанып алырга да ярата иде. «Салкын чишмә»дән соң ул тын да алып тормыйча «Уел»га күчте, «Уел»дан «Тәфтиләү»гә күчте.

Үзе белгән, үзе яраткан көйләрне уйнап бетергәч, Дәүләтгәрәй абзый, тыңлыйлар микән дигән сыман, башын күтәреп карады, урындык аркасына элеп куелган кульяулыгын алды да, битен, аеруча күз төпләрен сөрткәләде. Аңа шаулатып кул чаптылар. Мактау сүзләре дә ишетелде. Бераз вакыттан соң Дәүләтгәрәй абзый яңадан уйный башлады.

— Менә монысы мин малай чакта ишеткән көй, — диде ул.

Уйнап туктагач, җиңүче төс белән яшьләргә күтәрелеп карады.

— Кем белә, — нинди көй? — диде.

---

[1] — Башланды!
[2] — Харап, татарның бөек галимнәре, имеш!

Бу көйне ул, гомумән, сирәк уйный иде, шуңа күрә аның нәрсә уйнаганын хәтта Йосыф та әйтә алмады. Йосыф исә күптән инде әтисенең барлык көйләрен отып алуны һәм аның кебек скрипкада өйрәнүне үзенең төп максаты итеп куйган иде. Габделхәй бары тыңларга гына ярата һәм бер генә көйне дә хәтерендә калдыра алмый иде. Күп белүче Былбыл белән Маймул-Рамус та авызларына су капкандай тынып калдылар.

— «Күзгә ачы җилләрдә» түгелме соң?—диде Фәрханә апа.—Яшьләр белмиләр андый җырларны.

— Нинди матур көй, җизнәй!—диде Былбыл, телгә килеп.

— Татар бригадасы көе. Кызыл әрмисләр марш атлап йөрерләрие шушы көйгә,—диде Фәрханә апа аңлатып.

— Безнең әти дә сөйли аларны... татар бригадасын,—диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый скрипкасын Йосыфка тоттырды.

— Җәле, улым, син дә күрсәт өнәреңне,—диде.

Йосыф кыстатып тормады, бераз гына ашыгып-кабаланып, үзе белгән «Ком бураны» белән «Әпипә»не уйнап алды.

Йосыф уйнаганда Фәрханә апа кече якка чыгып китте һәм, гадәтенчә, табак-савыт шалтыратырга тотынды. Аның артыннан Былбыл да иярде. Дәүләтгәрәй абзый шулай ук каядыр чыгып китте. Олы якта үзләре генә калгач, Маймул, чыраен сытып:

— Брось ты пиликать!—диде Йосыфка.—Терпеть не могу разные там «Әпипә». Давай что-нибудь повеселее.

Музыка тавышы тынып, Василий Михайловичныкына охшаш ямьсез шыгырдавык тавыш ишетелү белән, Габделхәй айнып киткәндәй булды. Шундук ул үзенең янында гына иң явыз дошманы барлыгын исенә төшерде. Музыка тәэсире бетте, тынычлык югалды һәм кем дә булса хәзер искәрмәстән йөзенә китереп сугар, йә аркасына кадар сыман тоелды.

## XVIII

Рамусның киңәшенә колак салган сыман, Йосыф шундук скрипка шыңгырдатуыннан туктап калды. Тегесе кабаланып этажерканың аскы бүлеменнән патефон тартып чыгарды, шапылдатып аны өстәлгә куйды да, тоткасыннан шыгыр-шыгыр әйләндерә-әйләндерә, көйләп җибәрде. Иске патефон гыжылдавык тавыш белән фокстрот көйли башлады. Бөтен өй эчен җанны үрти торган чит-ят музыка һәм шалтыр-шолтыр тавыш тутырды.

— Давай танцевать!—диде Маймул кече яктан килеп чыккан Былбыл каршысына килеп.

— Хәзер,—диде Былбыл һәм тиз-тиз генә өстәл өстен сөртеп алды да, яңадан теге якка чыгып китте.

Рамус аны көтеп торды. Балкып, Былбыл яңадан олы якка чыгып килгәндә кыю гына аның биленнән, кулыннан тотып алды. Шалтыр-шолтыр музыкага алар идән уртасыннан әйләнгәләп киттеләр.

Ишек ташлап Фәрханә апа килеп җитте һәм көлемсерәп биючеләргә карап тора башлады. Дездемона, бөтен өй эчендә үзен хуҗа санап, чыр-чу килеп, туктаусыз аяк астында буталды.

Фокстроттан соң алар вальс биеделәр. Вальс пластинкасын озаграк әйләндерделәр. Былбыл Йосыф белән дә биеде. Йосыфтан соң чират Габделхәйгә җитте. Көлеп-елмаеп Былбыл Габделхәй каршысына килеп туктады да, сул кулын күкрәк турысына куеп, уң кул очы белән күлмәк итәген тоткан килеш, киноларда күрсәтелә торган барышнялар сыман, чак-чак кына баш иде.

— Әйдәгез, мин сезне танцыга чакырам,—диде тылсымлы итеп.

— Мин тансавайт итә белмим,—диде Габделхәй караңгы чырай белән.

— Иһи!—диде Былбыл, күзләрен зур ачып, матур кашларын сикертеп.—Белмисез? Әйдәгез өйрәтәм—җиңел генә ул!

— Өйрәнәсем килми,— диде Габделхәй.

Үзенең шулай катгый рәвештә җавап бирә алуына, кемне сайласам да булдыра алам дип, чибәрлеге белән масайган кыз алдында җебеп төшмәвенә Габделхәйнең күңеле күтәрелеп куйды.

— Оставьте его в покое, он стишки сочиняет,— диде Маймул сүзгә кысылып.

— Сез бер дә шагыйрьләрне яратмыйсыз икән,— диде Былбыл, Рамуска ачуланган булып.

— Терпеть не могу шәирләрне!— диде Маймул оятсызланып, Габделхәйнең күзләренә карап.

Шагыйрь җегетнең йөзенә кинәт кан бәрде, күз аллары томаланып калды. Ул исенә акылына килеп, нәрсә булганын аңларга өлгергәнче, Рамус Уфа кызының биленнән тотып алды. Борын төбендә генә җилләнеп алар китеп тә бардылар. Габделхәй, авыр, хәлсез аякларын өстерәп, ишеккә таба юнәлде.

Тышта әле бик үк караңгы түгел иде. Шулай да инде көн сүрелгән һәм кичке һавада тынлык, тынычлык урнашкан иде. Баскычта үзе генә Дәүләтгәрәй абзый утырып тора иде. Габделхәй әйтми-нитми кайтып китәргә һәм моннан соң беркайчан бу өйгә аяк басмаска дип чыккан иде. Ләкин баскычта Дәүләтгәрәй абзыйны күреп, ул тагын икеләнеп калды. Аның яныннан үпкәләгән сыман кайтып китү килешмәс шикелле тоелды.

— Корыга китте бит әле, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый күккә карап.— Яңгыр кирәк, яңгыр.

— Яңгыр?— диде Габделхәй, бик үк аңламыйча.

— Бәрәңгеләргә яңгыр кирәк. Печәнгә дә соң түгел,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Печәнгә төшкәннәр инде. Берәр чүмәлә әзерләп булырмы быел...

— Шулай шул,— диде Габделхәй.

Алар шулай печән турында гәпләштеләр дә тынып калдылар. Өйдән һаман гыжылдавык музыка тавышы ишетелде, урамнан тузан туздырып, тирә-якка әчкелтем төтен исе таратып, ниндидер машина узып китте. Шул чакны җилләнә-җилләнә Былбыл килеп чыкты.

— Их, монда нинди рәхәт!— диде ул һәм борылып өйдәгеләргә:— Сез дә чыгыгыз!— диде.

Аның тавышын ишетеп, баскыч төбенә Йосыф белән Маймул да чыкты.

— Әйдәгез, патефонны монда чыгарабыз?— диде Былбыл.

Маймул белән Йосыф ашыгып, хәтта бер-берсен узышып, яңадан өйгә кереп киттеләр һәм патефонны күтәреп чыктылар да баскыч өстенә, киң тактага җайлап куйдылар. Уфа кызы белән Маймул баскыч алдында, җир өстендә тансавайт итмәкче булып карадылар, ләкин чирәм арасыннан таш, кирпеч кисәкләре күренеп торган тигезле-тигезсез урында парлашып бию уңайсыз булып чыкты. Тансы үзеннән-үзе тукталып калды. Патефонны кире өйгә кертеп куярга туры килде.

Ләкин беркемнең дә яңадан өйгә керәсе килмәде. Шул ук вакытта таралышырга да ашыкмадылар. Капка янында Йосыфның үзе ясаган турнигы бар иде. Спорт Йосыфның иң яраткан шөгыле иде. Кызлар белән дә, яшьтәшләре белән дә ул бары спорт турында гына җанланып, дәртләнеп сөйләшә ала иде. Кунакларны ул үзенең турнигы янына алып килде һәм турникта беренче булып уйнап күрсәтте. Ашаганнан соң тәне шактый авыраюга да карамастан, күнегүләрне ул җиңел һәм оста башкарды. Йосыф дөпелдәп җиргә төшкәч, бердәнбер хөкемче Былбыл, мактау белдереп, кул чапты.

— Минә ул — спортсмен!— диде.

— Булмый... авыр...— дигән булды Йосыф тыйнак кына.

— Кем тагын, кем?— диде Былбыл болай да котырырга гына торган малай-җегетләрне котыртып.

Аның сүзләренә беренче булып Рамус кузгалды. Атасының иске кителеннән бозып тегелгән ак пинҗәген салып киргәгә элде, учына төкерде дә,

җинел генә ыргылып, шома тимерне эләктереп тә алды. Көн саен диярлек шулай турник белән булашканга, күнегүләрне ул да ярыйсы ук оста башкарды. Былбыл аңа да мактау сүзләре әйтте. Рамус турниктан төшергә ашыкмады — дәртләнеп, кызарынып тагын беркадәр атынды, чәчләрен полтыратып, туп-туры Былбыл каршысына сикереп төште.

— Оһо! — диде Былбыл.

Беркадәр тынлыктан соң ул янә Габделхәйгә борылып карады.

— Хәзер — Габделхәй! — диде Былбыл, ярым боерулы тавыш белән. Йосыфның да, Рамусның да бары Уфа кызы алдында шәп күренү өчен генә шулай кара тиргә батып азаплануларын Габделхәй бик яхшы белде һәм аларның һәр кыланышын яратмыйча күзәтеп торды. Кыланчык кыз үзенә эндәшкәч ул, бар ачуын бергә җыеп:

— Мин маймул түгел, — диде.

Кызның көләч, бәхетле йөзе шундук сүрелеп калды. Үпкәләп, хәтере калып, ул матур иреннәрен күптерде һәм әдәпсез малайга арты белән борылды. Габделхәй күңеленнән тантана итте. «Шул кирәк сиңа! Икенче масаймассың», — дип уйлады ул. Аның тагын да усалрак, тагын да тупасрак итеп әйтәсе, юри кызның ачуын китерәсе һәм шул рәвешчә барысы өчен аннан да, башкалардан да үч аласы килде. «Шул кирәк сезгә! Шыт!» — дип кабатлады ул күңеленнән.

## XIX

Габделхәйнең сүзләре Былбылның гына түгел, башкаларның да кытыгына тиде. Тынычрак, салмаграк Йосыф, Габделхәйнең холкын белгәнгә, ачуын тышка чыгармаска тырышты. Рамусның исә һич тә моны йотып җибәрергә исәбе юк иде, ахрысы. Ул үзен бар яктан да Габделхәйдән шәбрәк, көчлерәк һәм бәхетлерәк дип исәпли иде. Үзенең шәплегенә, көченә таяна торган бәхетле кешеләргә генә хас бер кыюлык, тәвәккәллек белән ул ашыкмыйча гына Габделхәй янына килде.

— Әйдә, күрсәт батырлыгыңны, нәрсә катып торасың багана кебек! — диде. Шулай диде дә, бар көченә Габделхәйнең күкрәгенә төртеп җибәрде. Габделхәйнең әле беркайчан да Рамус белән күрәләтә бәрелешкәне дә, көч сынашканы да юк иде. Ул аны бары читтән генә, ерактан гына дошман күреп йөри иде. Турыдан-туры бәрелешергә Рамусның директор малае булуы да, артык оятсыз, былагай булуы да комачаулый иде бугай. Шуңа күрә ул Габделхәйгә, чыннан да, бар яктан да көчлерәк һәм өстенрәк булып тоела иде.

Хәзер менә аның искәртмәстән китереп төртүе булды, тәненә агач кулның килеп кагылуы булды, Габделхәйдә кинәт тиле ярсу, көч-куәт барлыкка килде. Бу минутта ул үз дошманының директор малае булуын да, үзеннән көчлерәк, кыюрак, шәбрәк булуын да онытты һәм йодрыгын йомарлап бар көченә оятсыз кыяфәткә тондырды. Оятсыз кыяфәт мыйк! итеп калды, артка чөйлекте. Шулай да тиз арада исенә килде һәм Габделхәйнең үзенә дә берне китереп сылады.

— Ташлагыз! Нәрсә сез... — диде Йосыф сугышучыларны аермакчы булып.

Ләкин ул арада ике әтәч чын-чынлап эләгешеп киттеләр. Рамус Габделхәйне ике куллап тотып алды, күтәреп алды да, баш аркылы ыргытмакчы булды. Тарткалаша торгач, ул аны шулай да аркасы белән җиргә екты һәм, кулларын як-якка каерып, тезе белән күкрәгенә басмакчы булды. Габделхәй тимер кулны ярсып тешләп алды. Авыртуга түзә алмыйча тегесе чинап җибәрде. Габделхәй исә пружинадай сикереп йөзтүбән әйләнде дә аягына басты. Ике яшь әтәч, уттай янган күзләре белән бер-берсенә карашып торгандай иттеләр дә, яңадан бер-берсенә ташландылар. Бу юлы инде беркемнең дә егыласы килмәде, кулын тешләттерәсе дә килмәде. Сабан туе көрәшчеләре кебек, алар бераз вакыт бер урында таптандылар һәм икесе дә

берьюлы диярлек бер-берсенең кулларын тотып алдылар. Бу юлы да Рамус өлгерлек күрсәтте — ике куллап Габделхәйнең биленнән эләктереп алды һәм тагын да баш аркылы чөймәкче булып азаплана башлады. Бу аның иң яраткан алымы иде, ахрысы. Ләкин тагын күтәреп ташлый алмады. Алар тагын әүмәкләшеп җиргә егылдылар.

Монысында Рамус алданрак сикереп торды. Торды да, аяклана алмаган Габделхәйне бар көченә капка ягына төртеп җибәрде. Габделхәй арты белән капкага барып бәрелде. Ул бернинди авырту тоймады. Ләкин үзенең директор малаеннан хәлсезрәк, көчсезрәк икәнлеген аңлады. Бу минутта ул үзендә чиксез нәфрәт һәм дошманлык тойды. Аңа берничек тә җиңелергә ярамый иде. Аңа ничек тә җиңәргә, дошманын ничек тә сытарга, изәргә һәм барысы өчен бик каты итеп үч алырга кирәк иде. Капкага бәрелгәч, ул туп кебек кире ыргылды һәм читкә тайпылган Рамусның ике куллап башыннан тотып алды. Бар көченә ул аны үзенә кыса башлады. Алар тагын җиргә егылдылар. Монысында Габделхәй өстә калды һәм исенә-акылына килергә өлгермәгән дошманын изәргә, сытарга тотынды. Колак төбендә куркып, шомланып кычкырган тавышлар, кирәксез киңәшләр ишетелде. Кемдер Габделхәйнең күлмәген тотып алды. Габделхәй тоткан кулны ачу белән сугып җибәрде.

— Җибәр күлмәкне, җибәр! — дип кычкырды ярсып.

Аны тотып алучы Йосыф булып чыкты. Габделхәй күлмәк тартучыга борылган арада Рамус аягына басты. Аның өсте-башы, бите-күзе тузанга, яшел чирәмгә буялган, киемнәре әвәләнеп беткән, авыз читеннән исә шыбырдап кан ага иде. Учы белән ул авыз читен тотып карады да яңадан Габделхәйгә тукталып куйды. Габделхәйне артына яшереп, Йосыф аның юлына аркылы төште.

— Сугыштыгыз, кыйнаштыгыз — җитте! — диде нык итеп.

— Кил әйдә, кил. Тагын бирермен! — диде Габделхәй гайрәтләнеп.

Сугышчылар, бер-берсеннән ике-өч адым читтә басып торган килеш, өс-башларын каккаладылар, канаган, күпкән, авырткан җирләрен тотып-тотып карадылар. Габделхәйнең канаган җире юк иде, бары тик авызына тузан кергән дә кул аркасы чиылган һәм... уң аягындагы ботинканың башы купкан иде. Ботинка башы, очлы кадакларын күрсәтеп, шүкә авызы сыман ыржаеп тора иде. Кадерләп кенә кигән ботинкасының шулай харап булуын күргәч, Габделхәйгә нәрсәдер бик-бик кызганыч булып тоелды. Күз ачып йомган арада ул уңаягындагы шул түфлиен салып кулына тотты да, әлеккедән дә ярсыбрак, үзенең дошманына ташланды. Ләкин аны тагын Йосыф эләктереп алды.

— Җитте! Булды! — диде Йосыф ачуланып.

— Нәрсә шуны яклыйсың?! — диде Габделхәй көдрәеп. — Сөяген он итәм мин аның! Масаймасын... директор малае булгач та!...

Якында гына Дәүләтгәрәй абзыйның тавышы ишетелеп китте.

— Ни булды, балалар, нишлисез? — диде ул борчылып.

Габделхәй тирә-ягына күзен ачыбрак карады һәм өй эчендәгеләрнең барысының да аптырап үзләренә карап торуларын күреп алды.

— Үзе башлады. Әллә аннан кыйнатып торыргамы?! — диде ул хуҗалар алдында акланган сыман.

— Ие, ие, Рамус үзе башлады! — диде Былбыл да.

Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа башларын чайкадылар, шелтә сыман, үкенү сыман бер-ике сүз әйттеләр дә, яшьләр эшенә кысылуны кирәксез санап, авыр гына, күңелсез генә кире борылдылар. Алар артыннан Былбыл да иярде. Тиз арада ул өйдән комган белән җылы су алып чыкты. Иң элек Рамус янына килде һәм юыну өчен кулына җылы су салмакчы булды. Рамус ачу белән комганны сугып җибәрде. Сулы комган шапылдап җиргә барып төште. Рамус, беркемгә карамыйча, капкага юнәлде. Урам якта, капка артында аның Габделхәйгә карата әйтелгән янау сүзләре ишетелде:

— Я еще покажу тебе!

## Өченче бүлек

### I

Чыгарылыш кичәсендәге кебек үк, һәр төрле җыелышларда, очрашуларда, дәрес вакытында мәктәп директоры да, укучылар да, гомумән, барлык акыллы кешеләр, бөтенесе беравыздан диярлек: сезнең киләчәгегез — алда, сезнең өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган, сезнең өчен барлык юллар ачык, дип әйтергә яратсалар да, мәктәптән тәмам киселеп, берничә көн мәктәпсез чын тормышта яшәп карагач та Габделхәй акыллы, белемле укытучыларның, өлкән кешеләрнең бик үк дөрес әйтмәгәнлекләренә төшенде. Мәктәпкә чакта вәгъдә ителгән томанлы мөмкинлекләр белән тормыш хакыйкате арасындагы аерманың ни дәрәҗәдә зур һәм тирән булуын көннән-көн төшенә барган саен, каушау һәм аптырау тойгысы да көчәя барды.

Алдагы киң, якты дөньяга, бәхетле тормышка омтылган яшь күңелнең юлына аркылы төшүче иң беренче албасты — мохтаҗлык һәм хәерчелек булды. Үзенең киләчәктә кем булырга тиешлеген, кая китәргә ниятләвенне ачыклау белән генә инәнең бирелмәгән рөхсәтен алып кына ярлылык-хәерчелек мәсьәләсен хәл итеп була торган түгел. Хәерчелек мәсьәләсен хәл итү өчен исә барыннан да элек акча дигән бик тә күңелсез бер нәрсәне хәл итәргә кирәк иде.

Акча ул кайберәүләрдә капчыклап йөрде, тик менә аларда гына — Габделхәйләрдә генә — капчыклап та, янчыклап та булмады. Айның билгеле бер вакытында күренгәләп алды да, тиз арада каядыр таралып юкка чыкты. Сугыш беткәнче алар әтиләре өчен беркадәр пособие алып тордылар. Ләкин сугыш бетеп ярты ел чамасы үтмәде, нишләптер, анысы да туктап калды. Шәмсебанат апа дөреслек эзләп башта райсобеска барды. Райсобеста райвоенкоматка барырга куштылар. Военкоматтан Шәмсебанат апа кайгырып, карасына коелып кайтты. Бер атна чамасы рәтләп сөйләшмәде. Габделхәй төпченмәде.

Сугыш елларында үскән барлык малайлар кебек, ул шактый иртә үз иркендә яши башлады. Дус малайлары белән бергәләп алар еракка — Бүә буена су керергә дә йөрделәр, карагат, җиләк-җимешкә дә йөрделәр. Алып кайткан җимешләрен, карагатларын базарда яки тимер юл буенда сатып, әзме-күпме акча эшләделәр. Исәя башлаган малай-шалай бер заман, олылардан күрмәкче, «эспикүлән» эшенә әвәсләнеп китте. Буш вакытлары булдымы, тимер юл буена баралар да, поездлан төшкән пассажирлардан, каядыр ерак җирләргә китүче солдатлардан вак-тояк нәрсәләр — папирос, зажигалка, карандаш, дәфтәр ише нәрсәләр сатып алалар, аннары, бәясен бераз арттырып, шуларны базарда сатып йөриләр. Акчасы күбрәк кеше кием-салым, сәгать кебек әйберләр, затлырак әйберләр алып сата. Мондый товарның файдасы да күбрәк кала.

Габделхәй дә бераз вакыт шундый сату-алу белән йөрде, кайчагында Илгизне дә ияртте. Шулай итеп, алар беркайчан инәләреннән акча сорамадылар. Киресенчә, еш кына үзләре алып кайттылар. Кайчагында, инәләре әйткәнне дә көтмәстән, үзләре тапкан акчага берәр бидерә бәрәңге, бер-ике кило он да алып кайттылар.

Әйе, инәсенә ул һәрвакыт үзе ярдәм итте һәм беркайчан аннан бер тиен акча алмады. Хәзер дә алмас. Хәер, инәсенең бирер акчасы да юк — ул аны белә. Кыскасы, акчаны тагын үзенә табарга туры киләчәк. Бары үзенә генә! Ләкин ничек итеп?

Дөрес, аның күптән, бик күптән беркемгә әйтмичә тиенләп җыйган яшерен акчасы бар. Илле ике сум да кырык тиен чамасы. Искечә. Яңача ул алай ук түгел. Биш сум да җегерме дүрт тиен генә. Бу бик аз. Илле ике сумны хәтта акча дип тә булмый. Яңавылдан Казанга кадәр билет бәясенә генә

җитәчәк. Поездда беркем билет алып йөрми анысы. Каяндыр Урал, Себер якларыннан килгән байлар — зур корсаклы директорлар, начальниклар-фәләннәр генә ул йомшак вагоннарда билет белән йөриләр. Авыл халкы, Яңавыл халкы вагон араларында, вагон түбәләрендә йөри, товарный вагоннарга эләгеп китә. Казанга барып төшсәң, анда инде акча кайгысы бетәчәк. Шәһәр халкы көрәп акчасын ала, авыз тутырып ипи ашый. Барып төшкәч тә стипендия сорарга була. Бирмиләр икән, элекке көнлекчеләр кебек, берәрсенә ишегалды себереп торучы булып эшкә ялланасың йә булмаса хәлсез корткаларның сумкаларын, чемоданнарын күтәрешәсең. Киноларда күрсәтәләр ич. Ничек тә тамак ялгарлык акча эшләргә булыр әле. Инде алай да булмый икән, Идел буена эш эзләп китәсең, баржа бушатасың! Горький кебек. Горький университетка акчасы булмаган өчен түгел, аттестаты булмаган өчен керә алмаган. Теге... Маймул шуны да белми. Горький, имеш, Казан университетында укыган! Укыган, укымыйни!

«Туктале, нишләп мин Горький кебек баржадан утын, тоз бушатып йөрергә тиеш?» — диде ул бераздан, үз-үзенә каршы килеп. Аның бит беркайда бастырылмаган шигырьләре бар! Казанда ул югалмаячак. Барып кына җитсен, анда инде ничек тә акча табачак!

Ләкин, төптән уйлап караганда, шундый ерак юлга илле ике сум белән түгел, йөз дә илле ике сум, хәтта мең дә илле ике сум белән чыгу хәерлерәк булыр иде, әлбәттә. Хезмәтче булып ялланулар, баржа бушатулар, шигырь бастырулар — алар барысы да һавадагы торна.

Акча кирәк, акча! Акча монда да кирәк, Казанда да кирәк булачак. Билет алу өчен генә түгел, тамак өчен генә түгел, яхшырак чалбар, пинжәк, яңарак туфли алу өчен дә кирәк булачак.

Авызы ачылган ботинкасын исенә төшергәч тә Габделхәйнең эче жу итеп китте. Теге көнне ул Йосыфлардан яланаяк кайтты. Икенче көнне ботинкасының купкан башын кире урынына беркетергә тырышып карады, ләкин берни барып чыкмады. Бөтенләй яланаяк калмас өчен ул туфлинең купкан өлешен киез итек ямаган кебек, тышкы яктан берничә кат кәтүк җебе белән тегеп, эләктереп куйды. Болай үзе киярgә ярый сыман, шулай да ямалган җире ямьсез булып күренеп тора. Дөрес, аның ямалган ботинкасын әле беркем дә күрмәде. Күрсәләр, нәрсә дип әйтергә дә, ничек итеп шуның белән урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә. Аның бит әле Сәкинә белән очрашасы да бар!

Габделхәй шулай ямалган ботинкасы хакында, гомумән, акчасызлык, мохтаҗлык хакында уйланып-бетеренеп йөргәндә, көтмәгәндә аяк астыннан диярлек икенче төрле кайгы һәм борчу калкып чыкты.

## II

Улы Габделхәй белән булган сөйләшүдән соң Шәмсебанат апа бик озак тынычлана алмады. Илгизнең эшкә керәм дип канатланып йөрүе дә, Фидәилнең үзе кебек ише малайлар белән Бүә буена җиләккә йөрүе дә, Габделхәйнең исә элеккегә караганда ягымлырак булуы да — берсе дә күңелен юата алмады. Ул һаман борчулы, боек йөрде. Агач корты кебек аның күңелен бертуктаусыз нидер талый, нидер кимерә иде кебек.

Балалар бакчасында татар группасын ябалар икән диган сүз дә әлегә тынып торды. Бакчадагы кайберәүләрне бу сүз әле һаман агулап торса да, Шәмсебанат апа өчен хәтта монысы да арткарак чигенде. Аңа хәзер бу ялгандыр, берәр төрле уйдырмадыр сыман тоела башлады.

Бу көннәрдә Шәмсебанат апа үзеннән бигрәк балалары, бигрәк тә Габделхәй өчен борчылды. Ул аның чын мәгънәсендә үсеп җиткәнлеген күрде, үз кулы астыннан чыга барганын күрде. Ул әле күңеле белән һаман аны үзе янында торгызмакчы булды, шул ук вакытта тотып торырга инде көченнән килмәгәнлеген дә аңламый булдыра алмады. Әгәр дә мәгәр аның Габделхәе кая да булса китеп барса, моннан соң инде беркайчан кире Яңавылга, инәсе,

энеләре янына әйләнеп кайтмас, кайта алмас — югалыр, юкка чыгар һәм шундый нык күнегелгән тормышның асты өскә килер сыман тоелды.

Күңелсез сөйләшүдән соң бер-ике көн үткәч, Шәмсебанат апа улы белән яңадан сүз башлады. Авыр язмышка дучар ителгән кеше кебек, бик кыенлык белән:

— Улым... — диде — син анда... Казанга китәм дисең дә... синең бит паспортың юк. Нишләрсең икән?

Көндәлек тормышта адым саен диярлек һәр төрле язу, документ, белешмә кебек нәрсәләр таләп ителсә дә, бу мәсьәләдә Габделхәй әле бик тәҗрибәсез иде. Институтларга керү турындагы белдерүләрнең һәркайсында керүчедән нинди документлар соралуы ап-ачык итеп язылган иде. Ләкин, Габделхәй фикеренчә, югары уку йортына керү өчен аттестаттан башка, берничә шигырь дәфтәреннән һәм шагыйрь булырга көчле теләктән башка берни дә кирәкмидер шикеллерәк тоела иде. Аннан соң, берничә фәннән керү имтиханы тапшыру да аның өчен нишләптер мәҗбүри түгел сыман иде. Бит аның аттестатында барысы да «бишле!» Аңа алтын медаль бирергә тиешләр иде! Алтын медальлеләрне исә теләсә кайда имтихансыз алалар. Мәсьәләгә кайсы яктан килеп карасаң да, югары уку йортларына керү турындагы белдерүләрдә әйтелгән таләпләр аның өчен түгел, бәлки бөтенләй башка кешеләр өчен язылган сымаграк аңлашыла иде. Шуңа да ул әлеге кирәкле документлар эзләү турында уйлап та карамады.

Инәсе паспорт хакында сүз чыгаргач, ул каушап калды. Аның өчен бик тә, бик тә четерекле мәсьәлә иде. Илгизнең, Фидаилнең, барлык классташларының туу турында таныклыклары бар, аныкы менә юк. Ул дөньяда бар да, юк та. Чынлыкта ул туган, кеше булган, ләкин Закон каршында ул — кеше түгел.

Мәктәпкә укырга кергәндә дә, күрәсең, аның таныклыгын сорап тормаганнар. Ул чакта, бәлки, тәртибе шундый булгандыр. Укыган чакта да беркем аннан таныклык сорамады, аның кирәклеге турында да искә төшермәделәр. Укыймы? Укый. Әйдә, укысын, кеше булсын. Ул әнә укыды, унны бетерде, теләсә нинди кеше түгел — шагыйрь кеше булмакчы. Шагыйрь булу өчен туу турындагы таныклык таләп ителми, шигырь яза белү таләп ителә. Шулай булырга тиеш түгелмени? Үз-үзен юатып, еш кына ул шулайрак фикер йөртте.

Былтыр яз көне Илгиз кебек үк укуын ташлап тимер юлга, вагоннар депосына эшкә керергәме әллә, дип җенләнеп йөргәндә беренче сүз итеп аннан туу турында таныклык һәм мәктәптән белешмә сорадылар. Аның кулында бер төрле язуы да юк иде. Кирәкле кәгазьләрнең юклыгы беленгәч, аның белән хәтта сөйләшеп тә тормадылар. Шуннан соң ул укуын ташлап эшкә керү турындагы уеннан бик тиз баш тартырга мәҗбүр булды. Бу хакта ул беркемгә дә сөйләп тормады. Шулай да бу беренче сабак аның күңелендә шактый тирән уелып калды.

Узган бер ел эчендә бу да онытылып өлгерде. Габделхәй үзенең туу турында таныклыгы булмаган кимчелекле кеше икәнлеген ничектер исеннән чыгарып ташлады. Менә хәзер аның исенә төшерделәр. Шундук аның күңелендә былтыргы каршылыклы уй-фикерләр калкып чыкты.

Инәсе әйткәнчә, Габделхәйнең әтәсе Котдус белән алар Казанда педагогия техникумында танышканнар, дөресрәге, алар анда бергә укыганнар. Габделхәйнең әтәсе Котдус кайдадыр Оренбург ягында туган, бик яшьли ятим калган, балалар йортында тәрбияләнгән. Шуңа күрә ул үзенең нәселнәсәбен, атасын-анасын рәтләп белмәгән дә. Соңгы курста укыганда алар өйләнешеп бергә тора башлаганнар. Укуларын тәмамлагач, аларны Татарстанның иң еракгагы төбәкләренең берсенә — Агыйдел буендагы Бурсык дигән авылга укытучы итеп җибәргәннәр. Габделхәй менә шунда Бурсыкта туган.

Бу еллар дөньяның бик тә буталчык чагы булган. Көтмәгәндә авылдагы кемнәр беләндер яшь укытучылар арасында каршылык килеп чыккан. Тормыш шартлары да шәптән булмаган. Бер-ике ел эшләгәннәр дә болар,

Яңавылга — инәсенең туган якларына кайтып киткәннәр. Иң элек Янтыкка кайтып төшкәннәр. Укытучы кеше, культуралы кеше буларак, яшь ата белән ана кечкенә Габделхәйне «әти», «әни» дип сөйләшергә өйрәткәннәр. Ләкин авыл балалары көлгәнлектән, Габделхәй тиз арада «әткәй-инәкәй»гә күчкән. Боларын Габделхәй үзе дә хәтерли. Ләкин аның биографиясендә ул үзе белми: хәтерләми торган нәрсәләр дә җитәрлек.

Инәсе әйткәнчә, Габделхәйнең туу турындагы таныклыгын алар — әти белән әни кеше — «Йосыф-Зөләйха» китабы эчендә саклап тотканнар. Әтисе дә, әнисе дә искечә яхшы белгәннәр һәм кайчагында элекке китапларны карап-укып утыра торган булганнар. «Йосыф-Зөләйха», «Бүз йекет», «Кисекбаш» исә Котдус әтинең иң кадерләп саклый торган китаплары булган. Анда-монда күченеп йөргәндә «Йосыф-Зөләйха» да, аның эченә кыстырылган таныклык та, күз тиюдән саклый торган догалыклар да, шулай ук Габделхәйнең кургаш кәгазьгә төрелгән беренче чәче дә юкка чыккан. «Йосыф-Зөләйха» катыргысы эчендә «Бүз йекет» белән «Кисекбаш» та булган.

Әлеге китапларны Шәмсебанат апа берзаман Таифә исемле бер укытучы кызга биреп торган икән. Таифә, надан булса да, җылан кебек астыртын һәм кара эчле булып чыккан. Китапларны ул бер айдан китерермен дип алып киткән, ләкин китермәгән. Бер айдан китап хуҗасы Котдус Мөхетдиновны авыл советына чакыртып сорау ала башлаганнар. Совет балаларына син шулай «Йосыф» китабы укытасыңмыни, яшь буынны дин сөреме белән агулыйсыңмыни? Фәлән-төгән ... — берсе дә калмаган.

Котдус Мөхетдиновның моңа бик нык кәефе кырылган, борчылган, йокыдан, тамактан калган. Уйлашканнар-киңәшкәннәр дә болар, көннәрдән бер көнне кайтканнар да киткәннәр. Ярый әле токарлаучы булмаган. Илгиз Янтыкта туган. Янтыкта бер кыш торгач, Яңавылга күченгәннәр.

Котдус Мөхетдиновны Яңавылда кулга алалар. Таң алдыннан татлы йокы вакытында киләләр дә каядыр алып китәләр. Чит кешеләрнең тупас тавышлары, инәсенең йөрәк өзгеч итеп, куркыныч итеп кычкырып җибәрүе, шапылдап ишек-капка ябылуы — барысы да Габделхәйнең исендә, йөрәк түрендә. Ләкин барысы да... төштәге кебек кенә.

Котдус Мөхетдинов халык дошманы булган икән, дип, сәвиткә каршы яшерен армия туплауда катнашкан икән, солтангалиевчеләр белән бер шайкада торган икән, дип, тагын әллә нәрсәләр, дип ул вакытларда бөтен Яңавыл шаулап торды. Шулай да озак шауламадылар — Котдус Мөхетдиновтан соң тагын бер халык дошманын, аннан соң икенче, өченче халык дошманнарын фаш иттеләр. Шулай итеп, әкренләп аны бөтенләй диярлек онытып бетерделәр.

Ул елларда Шәмсебанат апа гел кайгылы йөз белән йөрде. Габделхәйгә ул: «Әтиеңне Кызыл Армиягә алдылар»,— дип ышандырырга тырышты. Габделхәй ышанса да ышанмады, ышанмаса да ышанды. Ул бары әтисенең каядыр китеп баруын гына, үзенең әтисез икәнлеген генә белде. Шушы хәлдән соң алар Яңавылда озак тора алмадылар, барлы-юклы төенчекләрен төйнәделәр дә, яңадан әнисенең туган якларына — Янтыкка кайттылар да киттеләр.

Сугышның икенче елында бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда, солдат киемнәре киеп, яраланып Янтыкка Котдус Мөхетдинов кайтып төште. Ул вакыттагы бәхет-шатлыкны, ул вакыттагы куанычны Габделхәй мәңге хәтерендә калдырды. Дөрес, монысы да төштәге кебек кенә булды. Шулай да монысы өнгә якынрак иде. Теге вакытта аның әтисен, чыннан да, кулга алганнар, атарга хөкем иткәннәр, ләкин үлем җәзасын унбиш ел төрмә һәм гомерлек сөрген белән алыштырганнар. Сазлы, урманлы җирләрдә күпмедер эшләгәч боларны Чиләбе ягына китереп аударганнар. Шунда Чиләбе трактор заводын төзегәндә сакчылардан бер татар кешесе белән танышып, дуслашып киткән. Сугыш башлангач, Котдус Мөхетдинов сугышка җибәрүләрен үтенеп, Мәскәүгә, иптәш Сталинның үзенә хат язган. Илгә, партиягә турылыклы булуымны үлемем белән исбат итәсем килә дигән. Котдус Мөхетдиновның хаты тиешле җиргә барып җиткән — моны армиягә алганнар, сугыш-

ка җибәргәннәр. Сугышта бу бик зур батырлык күрсәткән, яраланган. Аның белән бер ротада сугышкан, бергә ут эченә кергән һәм шундый ук батырлыклар күрсәткән бик күпләргә орден-медальләр биргәннәр, командирлары на «герой» бирелгән, Котдус Мөхетдиновны исә... бер айга ялга җибәргәннәр.

Бер айдан ул китте, хатлар язып торды. Бер елдан соң хаты килми башлады. Күп тә үтмәде, көтмәгәндә Котдус Мөхетдиновның батырларча һәлак булуы турында язу килде.

Габделхәйнең туу турындагы таныклыгын сорап Шәмсебанат апа башта Бурсыкка, аннары Казанга язып карады. Бурсыктан да, Казаннан да рәтле җавап килмәде. Бу турыда Габделхәй соңыннан, үсә төшкәч белде. Әгәр шул таныклык мәсьәләсе юлына аркылы төшсә, нишләргә? Бит аңа болай да паспорт алу вакыты җиткән. Паспорты булмаса, кая барыр, кайда укыр яисә нинди эшкә керә алыр икән соң ул? Инәсе әйткәнчә, әллә тагын Янтыкка күченеп китәргәме? Бөтенләйгә шунда төпләнеп калыргамы? Бит авылда бернинди таныклык та кирәкми, паспорт та кирәкми. Күрәгең генә нык булсын— ... табылыр!

## III

— Дәүләтгәрәй абыең белән сөйләшеп карарга кирәк, улым,— диде Шәмсебанат апа, улының уйларын сизенеп.— Булышса, ул гына булыша алыр сиңа.

Инәсенең сүзләре Габделхәйгә бик дөрес булып тоелды. Әйе, мондый чакта аңа ярдәм кулы сузардай ике генә кеше бар — Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрханә апа гына. Ләкин аларны искә төшерү белән аларда булган ямьсез күренешләр күз алдына килде. Шундук аның йөзе үзгәрде, йодрыклары йомарланды. Үзенең эчке кичерешләрен инәсенә күрсәтмәс өчен ул тиз арада тышка чыгып китте.

Озак кына уйланып, икеләнеп йөргәннән соң ул шулай да Фәрханә апаларга барырга кирәк дигән фикергә килде. Сугышса әллә, ул бит Йосыф белән сугышмаган. Аннан соң Маймул үзе башлады. Барысы да күреп тордылар ич.

Габделхәй Йосыфларга килеп кергәндә Дәүләтгәрәй абзый инде эштән кайткан иде. Фәрханә апа белән Былбыл икәүләшеп бакчада кыярларга су сибеп йөриләр иде. Йосыф өйдә юк иде, ахрысы.

Габделхәйне барысы да дусларча елмаеп, ачык йөз белән каршы алдылар. Аларның бу ягымлылыгында Габделхәй үзен инде күптән гафу итүләрен, хәтта, ихтимал, Рамус белән булган ызгышуны онытуларын аңлап алды.

— Килдеңме, югалган мал?— диде Дәүләтгәрәй абзый, күңелле генә көлемсерәп.

— Мактап кына йөрисең икән әле,— диде Фәрханә апа.— Әйдә, юын, ашарга утырырсың.

Бу сөйләшү барысы да өйгә кергәч булды.

— Мин әле генә ашап килдем,— диде Габделхәй ялганлап.

Йөгергәләп аның янына Дездемона килеп җитте.

— Югалган мал!— диде ул, абыйсының кулларына асылынып.

— Карале, чибәрттәй, бу Диздекәйне!— диде Былбыл көлеп, нинди-дер бик кызык нәрсә әйтмәкче булып.

— Йосыф кая?— дигән булды Габделхәй болай гына, ни дә булса әйтергә кирәк булган өчен генә.

— Йосыфны очратмадыңмыни?— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Әле генә мин аны Сәлимнәргә җибәрдем, җылымнарын белешергә. Шунда сезгә дә кереп чыгарга куштым.

— Иртәгә ял көне. Балыкка барабыз, балыкка!— диде Былбыл.

— Син дә барасыңмыни балыкка?— диде Диздекәй, Былбыл апасына.— Җылан тарту авыр бит ул.

— Нәрсә, нәрсә?— диде Былбыл аңламыйча.— Нинди җылан?

— Җылан шул, ник җылан булмасын!— диде Дездемона.

— Җылан түгел, җылым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Аптыратма кешене, кызым.

— Ул кеше түгел, ул безнең улыбыз,— диде Дездемона, Габделхәй абыйсына сырпаланып.

Аннан көләргә тотындылар.

— Кит, аптыратма абыеңны,— диде Фәрхәнә апа да иркә кызын куган булып.

— Абый түгел, ул безнең улыбыз!— диде Дездемона.

— Уф, үләрсең синең белән!— диде Былбыл көлә-көлә.

— Үлмә әле, үләргә иртәрәк,— диде телмәт кызый остарып.

— Без инде сезгә дә әйтербез дигәниек,— диде Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйгә.— Райфодан үзебезнең атны алабыз. Көне буена. Рәхәтләнеп бер ял итәрбез дидек. Инәңә дә, Илгиз белән Фидәилгә дә әйтербез дидек. Андый-мондый эше юктыр ич инәңнең?

— Юк,— диде Габделхәй.

— Барабыз алайса?— диде Былбыл Габделхәйгә.— Җизнәй әйтә, ул якта карагат, җиләк күп була икән. Габделхәй белә аны, ди. Карагат җыярга бидерә алып барабыз.

Габделхәй үзенең Буә буендагы карагат-җиләкне яхшы белү-белмәвен онытткан иде, ләкин бу турыда Былбыл әйткәч, аңа ул чыннан да шундый белеме булган кеше сыман тоелды. Былбыл аңа бүген беренче мәртәбә күргәндәгегә караганда да матуррак һәм ягымлырак булып күренде. Былбыл исә, гадәтенчә, олы як белән кече як арасында ары-бире йөреп, әле өстәлгә тәлинкәләр китереп куйды, әле кашык-фәлән алып чыкты, яисә узышлый гына тәрәзә челтәрен төзәткәләп алды. Габделхәй яныннан узганда аның ягыннан җиңел, татлы ис таралып калды. Үзен яңадан бәхетле итеп тоя башлаган яшь җегет дөньясын онытып, аның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырды.

## IV

— Ничек соң, имтиханнарга әзерләнә башладыңмы әле, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый аны татлы хыялларыннан бүлдереп.

— Минем әле... — диде Габделхәй, ни әйтергә дә белмичә.

— Бер ниятләгәч, тотынырга кирәк,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Безнең Йосыф физика белән алгебраны өр-яңадан кабатлап чыкты,— диде Фәрхәнә апа.

Аның шулай Йосыф белән мактануы Габделхәйгә ошап җитмәде. Үзенең Йосыфтан һәм аның җан дустыннан башлырак, белемлерәк икәнлеген күрсәтү өчен ул, бик гадәти нәрсә турында сөйләнгән сыман, җиңел генә әйтеп куйды:

— Нәрсәсен кабатлыйсың инде аның?— диде.— Әле генә имтихан тапшырдык, барысы да истә. Имтиханнардан курыкмыйм мин.

— Җәй көне укыйсы да килми инде ул,— диде Былбыл да аның сүзләрен куәтләп.— Мин дә университетка керер алдыннан кабатлап тормадым.

— Имтиханга әзерләнү генә им түгел,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Хәзердән үк аяк киенә башлау зыян итмәс, Габделхәй. Фотога төшәргә, справкалар алырга... юлга чыкканда аларның барысы да кирәк була. Иң кирәге — акча.

Акча сүзе чыккач та Габделхәйгә уңайсыз булып китте. Әйтерсең, «акча» кычкырып әйтергә, бигрәк тә кызлар алдында әйтергә ярамый торган ниндидер оятлы нәрсә иде.

— Минем туу турында таныклык юк бит әле, Дәүләтгәрәй абзый,— диде ул, үзенең акчадан да күңелсезрәк нәрсәсен исенә төшереп. Таныклык

турында ишеткәч, Дәүләтгәрәй абзый да, Фәрханә апа да шикле рәвештә тынып калдылар һәм бер-берсенә карашып алдылар.

— Загска барып карадыңмы соң?—диде Дәүләтгәрәй абзый озак кына эндәшми торганнан соң.

— Юк шул әле,—диде Габделхәй.—Мин әле шул турыда киңәшергә дип килгәнием. Инәкәй дә шулай диде. Булмаган таныклыкны каян алыйм инде мин аны?

— Шулай...—диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Нишләрсең икән соң?—диде Фәрханә апа, Габделхәйгә түгел, Дәүләтгәрәй абзыйга эндәшеп.—Үзең барып карамый булмас шул, иеме?

— Шулай,—диде Дәүләтгәрәй абзый тагын да ничектер аңлаешсыз итеп.—Ярар, ул турыда артык борчылма син, Габделхәй,—диде ул аннары билгеле бер карарга килеп.—Үзем барып карармын тиешле җиргә. Әдәм булгач әрәм булмассың, алла боерса. Сиңа бит иң кирәге—паспорт.

— Шулай инде,—диде Габделхәй.

— Ярар, берәр атнадан әйләндереп чыгарырбыз без аны,—диде Дәүләтгәрәй абзый ышанычлы итеп.

— Безнең җизнәй тотынса, булдырмый калмый инде ул,—диде Былбыл.

Габделхәй җиңел сулап куйды—аның кинәт өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды. Дәүләтгәрәй абзыйның әйткән сүзен үтәячәгенә ул да әз генә дә шикләнмәде. Аның төп йомышы, нигездә, башкарылды дип исәпләргә була иде, аңа инде саубуллашып кайтып киткәндә дә начар булмас иде. Бит бүген ул Сәкинә белән очрашырга тиеш! Шулай да ул нишләптер ашыкмады. Аның һич тә моннан, бу якын, ягымлы кешеләр яныннан кузгалып чыгып китәсе килмәде. Сүзендә тормау бик үк яхшы түгел иде, әлбәттә, хәтта начар, бик начар иде. Һич югы шуның өчен генә булса да ул моннан чыгып китәргә тиеш иде. Ләкин ул менә утырды да утырды.

— Безнең Илгиз монтер булам дип котырып йөри бит әле,—диде ул бер дә юктан энесен исенә төшереп.

— Алай икән,—диде Дәүләтгәрәй абзый.

Бераздан Габделхәйнең балалар бакчасындагы татар группасын ябарга итүләре турында сүз башлыйсы килеп китте, ләкин башламады; тыелып калды. Аның өчен бу берни белән чагыштырып булмый торган зур, җаваплы һәм куркыныч нәрсә иде. Акча турында кычкырып сөйләшергә ярамаган кебек, бу турыда да кычкырып, башкаларга ишеттереп сөйләргә ярамый сыман иде. Аның үзе өчен генә түгел, бүтәннәр өчен дә шулай сыман иде. Чөнки, аның аңлавынча, бу милләтчелек булачак иде.

— Җылдан-җыл инәкәй дә олыгая,—диде ул инәсе турындагы фикерен икенче якка юнәлтеп.—Фидәил дә борчый. Кичәгенәк суга батканда чак калган. Яңгыр телибез дип малайлар белән су сибешкәннәр, бер-берсен җылгага төртеп төшергәннәр. Кемдер арттан килгән дә, моны да капландырган суга. Батып үлгәндә чак калган. Кайтып кергән берзаман җылый-җылый. Өстеннән шыбырдап су ага, үзе пычранып беткән. Сүзен дә рәтләп сөйли алмый—очкылык тота. Инәкәй тиргәргә тотынды. Ул кайгырмый кем кайгырсын безнең өчен?

Алар олы якта, өстәл янында сөйләштеләр. Ашагач-эчкәч, табак-савыт юу тәмам булгач, Фәрханә апа белән Былбыл аш өстәленең бер башына тегү машинасы җайлап куйдылар да нидер тегәргә тотындылар. Былбыл үзенең чемоданыннан мода журналы алып килде, журналны каршына ачып куйды да, тиз-тиз кыланып һәм әледән-әле көлештереп, иңбашларын сикерткәләп, машинаның шүресен, энәсен тикшереп карады. Фәрханә апага ниндидер киңәшләр бирде, ничек кисү, ничек тегү турында үз белгәннәрен сөйләде. Габделхәй, болай гына караштырып утырган китабыннан аерылып, тегүчеләр ягына карап-карап алды, аларның сүзләренә, хәрәкәтләренә игътибар итте. Ул караганда нишләптер Былбыл да аның ягына карады. Бик кыска вакыт эчендә аларның күз карашлары очрашып алды. Габделхәй шундук күзен читкә борды, китабына иелде, укыгандай итеп утырды да, монда

бары Йосыфны гына көтеп торган сыман, Йосыфка әйтәсе бик кирәкле сүзе бар сыман, үз алдына сөйләнгәләп: «Йосыф та озаклады»—дигән булды.

Шулай корыны бушка әйләндереп утыра торгач, кирәгеннән артык кыюланып:

— Тегү эше бик кызыктыр ул?—дип куйды.

Ул моны Былбылга әйтте. Шәһәрдә тегү-чигү түгәрәгенә йөргән һәм хәзер менә бөтен осталыгын бергә җигеп, җан тирләре белән тырышып, ниндидер шәп күлмәк тегәргә азапланып утырган кызның күңеленә мондый сорау сары май булып ятты. Ул шундук башын калкытты һәм эчкерсез бер елмаю белән елмаеп, җылы нур балкыткан тылсымлы күз карашын Габделхәйгә төбәп:

— Сезнең тегәргә өйрәнәсегез киләме?—диде.

— Безнең Йосыф бер дә аптырап тормый үзенең җыртыгын-тишеген үзе ямый да куя,—диде Фәрхәнә апа.

— Мин дә үзем,—диде Габделхәй беркадәр мактану белән. Ләкин шул чакны ул үзенең ямаулы ботинкасын күз алдына китерде, кызарынды һәм акланган сыман:—Минем машина белән теккәнем юк,—диде.

— Теләсәгез өйрәтәм!—диде Былбыл.

Сүзнең бу якка китүе мөмкинлеген уйламаган Габделхәй аптырабрак калды.

— Шулай да... тегү хатын-кыз эше инде ул,—диде.

Күрәсең, Былбыл да мондый җавап көтмәгән иде.

— Нишләп хатын-кыз эше генә булсын?!—диде ул, үз һөнәрен якларга әзер булып.

— Күбрәк хатын-кыз тегә,—диде Габделхәй.

— Юк, ирләр дә тегә!—диде Былбыл.

— Элегрәк тегүчеләр авылдан авылга йөреп тегәләрие,—диде Фәрхәнә апа.—Барысы да Казан ягыннан, барысы да ирләрие.

— Менә күрдегезме?!—диде Былбыл җиңүче төс белән.

— Мин дә хәтерлим андый тегүчеләрне,—диде Габделхәй.

— Менә, күрдегезме?!—диде тагын да Былбыл.—Җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

— Элек кенә шулай булган ул,—диде Габделхәй остарып.—Элекке кешенең бөтен һөнәре шул җитмештән артмагандыр инде. Хәзерге заманга туры килми ул мәкаль.

Былбыл мондый фикер белән килешмәде. Фәрхәнә апа да килешмәде. Былбыл әйтте, сез халык иҗатын ялгыш аңлыйсыз икән, диде, мәкальдә һич тә төп-төгәл җитмеш төрле һөнәр турында сүз бармый, ул бары рифма өчен генә әйтелгән, диде. Халык иҗатына хас нәрсә бу, диде. Фәрхәнә апа андый ук тирән фәлсәфәгә кереп тормады—дәрестә сөйли торган сүзләрне ул өйдә сөйләргә яратмый иде. Ул бары Габделхәйнең элекке кешеләрне аз һөнәрле итеп күз алдына китерүенә генә каршы килде. Элекке кешенең дә һөнәре күп булган, диде. Шуны исбатлау өчен шундук мисал да китерде. Безнең әтәйне авылда иң оста Шәйми дип йөртәләрие, диде. Шәйми картның кулыннан килмәгән эше югые, диде. Мич тә чыгара, тактадан кисмәк тә ясый, өстәл-урындык та ясый, итек тә баса, өй бурауны инде әйтеп тә торган юк. Мал-туар карау, сугым сую, йорт-җир, бакча эшләрен—барысын да элекке кеше үзе башкарган, диде.

— Мәрхүм әтәй бер генә эшкә өйрәнә алмады,—диде Фәрхәнә апа, сүзен тәмамлап.—Ул да булса—тегү эшенә...

— Менә күрдегезме?!—диде Габделхәй Былбылның үзе кебек.

— Тегү машинасы алырга хәленнән килмәде,—диде Фәрхәнә апа.—Үскәндә без сигез бала үстек. Бераз акчасы булдымы, безгә... балаларга кием-салым алырые, чәен-шикәрен алырые. Җыл да тегүче кертә торганыек. Тегүче бит бушка текми. Әтәй әйтә торганые: ичмасам шушы тегү эшенә дә өйрәнә алмадым—тегүчегә бирәсе акчага ике кызыма билле тун тегәргә булырые,—ди торганые.

— Аның өчен тегү — җитмеш беренче һөнәр булгандыр алайса. — диде Былбыл көлеп.

— Аның өчен җитмеш беренче һөнәр — акча табу булган, — диде Дәүләтгәрәй абзый, үзенчә нәтиҗә ясап.

— Финансист кеше шулай бөтен нәрсәне акчага кайтара да калдыра инде ул, — диде Фәрханә апа.

— Безнең җизнәй — иң акыллы финансист! — диде Былбыл, җизнәсен мактап.

— Акыллысын акыллы да соң... — диде Фәрханә апа, нидер әйтмәкче булып.

— Бөтен нәрсәнең тоткасы — акча, — диде акыллы финансист, нәтиҗә ясап.

## V

Дәүләтгәрәй абзыйның бөтен нәрсәне акчага кайтарып калдыруы Габделхәйгә бик үк ошамады. Акчаның кирәклеге болай билгеле иде, ләкин дөньяда акча белән тигезләп булмый торган, акчага сатылмый торган нәрсәләр дә бар. Бу хакта Габделхәй инде күп укыды, күп ишетте. Дәүләтгәрәй абзый райфо кешесе, бухгалтер кеше, карт кеше. Бәлки чынлап та ул бар нәрсәгә акча күзлегеннән карыйдыр. Ләкин менә Былбылның — аңы һәртөрле искелек калдыклары белән бозылмаган алдынгы карашлы кызның җизнәсе ягына авышуы, аны яклавы Габделхәйгә шактый гаҗәеп тоелды.

Дәүләтгәрәй абзый исә, үзенең иң кирәкле сүзен әйтте дә, ашыкмыйча гына тышка чыгып китте. Габделхәй тын гына утыруында булды. Ул арада Фәрханә апа яңадан үзенең бала вакытлары турында сөйли башлады. Ул, әтисе Шәйми карт үлгәч, сигез бала өелешеп калулары турында, үзенең ат җигәргә өйрәнүе, ирләр белән бергә атлы эшләргә йөри башлавы, Сәет абыйсының шәһәргә укырга китүе турында сөйләде.

Габделхәй инде кайчандыр бу турыда ишеткән иде. Беренче мәртәбә ишеткәндә Фәрханә апаның үзе турындагы һәрбер сүзе аңа яңалык булып тоелган иде. Хәзер исә Фәрханә апаның бу сүзләре аңа бөтенләй диярлек тәэсир итмәде. Картларның, өлкән кешеләрнең элекке заман турындагы сүзләренә карата аның карашы әле шактый буталчык һәм каршылыклы иде. Ул яшәгән кыска гына гомер эчендә туктаусыз аның аңына: сезнең ата-бабаларыгыз авыр һәм караңгы заманда яшәгәннәр, укый-яза белмәгәннәр, көне-төне байларга бил бөккәннәр, дигән фикер сеңдерелде. Мәктәптә шулай диделәр, китапларда, газит-журналларда — һәркайда шундый караш үткәрелде. Ләкин шул үткән заманның җанлы шаһиты булган өлкәннәр, картлар моның киресен сөйләделәр. Еш кына ул картлар, өлкәннәр сүзенә ышанды, ләкин алардан аерылып яңадан дәреслекләр, газит-журналлар белән очраштымы, үткән заман аңа тоташ караңгылык патшасы булып, шул патшалыкта яшәгән барлык кешеләр сукырлар, наданнар, аңгыралар — гомумән, коллар һәм хаерчеләр булып тоелды.

Бервакытны, алтынчыда укыганда, ахрысы, тарих дәресендә ислам диненең барлыкка килүе дигән теманы үткәч, ул инәсе белән дин турында, алла турында бәхәс куертып җибәрде. Кайчандыр Казанда укыган һәм әле дә яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләвен дәвам иттергән инәсе, буш вакыты булдымы, искечә китаплар укый, үз алдына бисмилла итә, амин тота һәм кайчагында белгән догаларын кабатлый иде. Пионер Габделхәй инәсенең мондый икейөзлелегенә күптән инде эче пошып, оялып-хурланып йөри иде. Диннең ничек башланып китүе турында сүз куерткач, инәсенә ул барысын да әйтте дә бирде. Иң яманы шул: «Әткәйнең кулга алынуына син гаепле булгансыңдыр әле!» — диде ул аңа. Инәсе шаккатты. Шуннан соң җыларга тотынды. «Куеnымда җылан үстергәнмен икән! — диде ачынып. — Нишләп мине гаеплисең, улым?» — диде. «Синең иске китапларың өчен алып киткәннәр ич аны», — диде Габделхәй. Ул инде бу турыда Янтык

картыйсыннан, картәтәсеннән сорашып белешкән иде. «Йосыф-Зөләйха»ны әйтәсеңме?»—диде инәсе. «Шуны»,—диде Габделхәй. «Ул бит дин китабы түгел. Борынгылар турындагы китап»,—диде инәсе.

Ул чакта алар арасында шундыйрак сөйләшү булды. Соңыннан Габделхәй үзе дә тупаслыгы, аңсызлыгы өчен бик нык үкенде, кайгырды. Фәрхәнә апа элеккеләрне сөйли башлагач, аның күңелендә яңадан менә шул чактагы нәрсәләр исенә төште. Габделхәйнең элеккеләр белән артык кызыксынмавын күреп, Фәрхәнә апа да сүзеннән туктап калды.

Бераздан Габделхәй тагын Йосыфны искә төшерде, кайтмыймы дигән сыман, тәрәзәгә барып урам якны карап килде. Аңа монда, әлбәттә, күңелле иде, ләкин аны монда күңеллелектә башка әле икенче бер нәрсә дә тоткарлап тора иде. Монда озаклап утыруының төп сәбәбе чынлыкта... Рамус иде бугай. Теге көннән соң ул монда килгәнме-юкмы, иртәгә балыкка барачакмы-юкмы — Габделхәйне хәзер барыннан да бигрәк менә шул нәрсә кызыксындыра иде бугай. Әгәр иртәгә ул да килсә һәм Йосыф белән бергәләп балыкка барырга тиеш булса, Габделхәйгә монда сөйләнгәләп утыруның кирәге юк.

Күңеленнән ул шулайрак дип уйлады, ләкин бу хакта сүз башларга ничектер кыюлыгы җитмәде. Тегү машинасы туктап торган арада өй эчендә шылт иткән тавыш ишетелмәде. Бары тик тәрәзә челтәре белән пыяла арасына кереп калган зур чебеннең бәргәләнеп безелдәве ишетелде дә, тышта, бакча ягында Дәүләтгәрәй абзыйның шыгырт-шыгырт китереп коедан су алганы ишетелде.

— Ярый, сау булыгыз,—диде Габделхәй, ниһаять, китәргә җыенып.

— Нишләп? Китәсеңдәмени әле?—диде Фәрхәнә апа.—Йосыф кайтып җитәр инде.

— Иртәгә кайчан кузгалырга исәп, Фәрхәнә апа?—диде Габделхәй.

— Сез чынлап та киләсезме соң?—диде Былбыл, эшеннән аерылып.

— Киләм!—диде Габделхәй ашыгып һәм үзе дә сизмәстән, кычкырып:

—Рамус киләме?—диде.—Ул булса, килмим.

— Юк, юк, ул килми,—диде Былбыл никтер көлеп.

— Бу арада Рамусның күренгәне юк әле,—диде Фәрхәнә апа, яшьләрнең сөйләшүендә бернинди катнашы юк кеше сыман.

Габделхәй күңеле күтәрелеп ишеккә юнәлде. Капкадан чыгып бераз киткәч тә ул Йосыф белән очрашты.

— Ә, исәнме, Йосыф! Сау бул, Йосыф,—диде ул шаяртып.

— Киттеңмени? Әйдәле, керәбез,—диде Йосыф, аның беләгеннән тотып алып.

Габделхәй берсүзсез аның артыннан иярде.

— Мин киного билет алдым,—диде Йосыф, өйгә кергәч.

— Ничә билет?—диде Былбыл.

— Өч билет. Ярты сәгать вакыт калды. Әйдәгез тизрәк!

— И-и, ник дүртне алмадың, чибәрттәң дә барган булырые,—диде Былбыл.

— Үзегез генә барыгыз,—диде Фәрхәнә апа.

— Әле дә соң түгел—тагын берне табарга була,—диде Йосыф.—Әйдә, барсаң, киен, әни.

— Бармам мин,—диде Фәрхәнә апа.—Сәлимне күрдеңме? Шәмсебанат апаң нәрсә ди? Барамы?

— Сәлим өйдә юк. Хатыны гына,—диде Йосыф.—Җылымны алырсыз ди. Шәмсебанат апа риза, барырбыз ди.

— Сталин клубындадыр ич?—диде Габделхәй дә сүзгә катышып.—Бүген нинди кино соң әле анда?

— Сталин клубында. «Иван Грозный»,—диде Йосыф.

— Иске кино икән,—диде Фәрхәнә апа.

Кече яктагы Былбыл бу яктагы сөйләшүне ишетмичәрәк калды. Һәм ишек янына килеп:

— Нинди картина, Йосыф?—диде.

— «Иван Грозный»,— диде Габделхәй.
— Җә, әни, барасыңмы? Әйдә киен,— диде Йосыф, ашыктырып.
— Күрдем мин аны,— диде Фәрхәнә апа.— Татарны мыскыл итә торган кино. Бармыйм.

Йосыфның кайтуын күреп, тыштан Дәүләтгәрәй абзый да килеп керде. Ул да сүзнең нәрсә турында барганын ишетеп калган иде. Фәрхәнә апа белән бәхәсләшкән кебек:

— Анда бит Казан татарларын мыскыл итәләр. Яңавыл татарларына сүз әйтүче юк,— диде.

Йосыф көлеп куйды. Фәрхәнә апа да күңелсез генә елмайгандай итте. Ул арада өр-яңа күлмәген киеп, түшенә ясалма зур роза чәчәге кадап, кече яктан Былбыл килеп чыкты һәм, карап тормыйлармы дигән сыман, җегетләр ягына күз төшереп алды да, тиз-тиз генә көзге ягына борылды, кәдрәләткән күперенке чәчләрен, изүләрен төзәткәләде, ислемай шешәсен ачып, бармак битенә хушбый тамызды, муенына, колак артларына сөртте. Өй эченә ят, җиңел ис таралды.

— Әйдәгез, мин әзер!— диде ул Йосыфка борылып һәм, җегетләрне көтеп тормастан, очынып-сикергәләп тышка ук чыгып китте.

Урамнан өчәүләшеп барганда, Былбыл:
— Ник көлдегез?— диде Габделхәйгә.
— Юк, көлмәдек,— диде Габделхәй.
— Көлмәдегез? Мин ишетеп тордым,— диде Былбыл.
— Юк, көлмәдек,— диде Йосыф та, Габделхәйне яклап.
— Әллә миннән көләләр микән дип уйлаган идем,— диде Былбыл.

Кинога алар нәкъ башланыр алдыннан гына барып җиттеләр. Халык күп иде, клуб эче шыгрым тулы иде. Алар өчәүләшеп, ашыгып, барысының да күз алдында алга таба уздылар. Утырып торган кешеләр чиктән тыш кызыксынып аларга, дөресрәге, ят шәһәр кызына карап калдылар. Куанычыннан нишләргә белмәгән Габделхәй үзенә төбәлгән һәм кызыксынучан йөзләр арасында бер-ике җирдә класссташ кызларын күреп калгандай булды. Кемдер хәтта: «Габделхәй!»— дип кычкырган сыман да тоелды. Ләкин хәзер ул кемне дә булса күрер, таныр дәрәҗәдә түгел иде. Алар җиденче рәтнең уныньчы, унберенче, уникенче урыннарына утырдылар. Йосыф Былбылның сул ягына, Габделхәй уң ягына туры килде.

## VI

Сеанс башлангач, иң элек журнал күрсәттеләр. Журналда махсус күзлек кигән, каска кигән, зур бияләйле корыч коючылар дөрләп янган мартен мичләрен ачып карадылар; әкәмәт зур чүмечләрдән чәчрәп торган кайнар, сыек металл агыздылар; рельслар сыман булып озынча корычлар тезелде. Үкереп, бөтен экранны тутырып, ниндидер машиналар, танклар үтеп китте. Тантаналы итеп диктор нәрсәдер аңлатып барды. Шуннан соң Кубань буе далаларындагы иксез-чиксез бодай басуларыннан бер-бер артлы тезелеп барган комбайннар күренде. Күкрәкләре ачык батыр комбайнчы шәһәрдән килгән журналистка кычкырып нәрсәдер сөйли, аңлата башлады. Ашлык басуларындагы комбайннар артыннан ук диярлек, диңгез дулкыннарын ярып, бөтен экранны тутырып, крейсерлар узып китте. Күктә самолетлар очты, колакларны тондырып шат музыка яңгырап торды. Аннан соң Мәскәүдә, Ленинградта, тагын ниндидер шәһәрләрдә, кызыл байраклар, портретлар, транспарантлар күтәреп, ташкын булып демонстрантлар узды. Штыклы автоматларын әзер тотып, тыгыз сафлар белән корыч солдатлар үтте.

Если завтра война, если завтра в поход...—

дип җырладылар яшь, көр тавыш белән меңләгән, ун меңләгән ирләр, бөтен дөнья империалистларына янап. Ленин мавзолеендә, аталарча кулын күтәреп, иптәш Сталин фатиха биреп торды.

Бер ун минут чамасы дәвам иткән журналдан соң гөлт итеп ут кабынды. Залда беразга ыгы-зыгы булып алды — кино башлануга, соңга калучылар үз урыннарына килеп утырдылар. Шуннан соң ут яңадан сүнде һәм залның арткы стенасына ясалган төннекләрнең берсеннән ак экранга калтырап-дерелдәп куе яктылык бөркелде.

Габделхәй кинода нәрсә турында сүз барганын озак кына аңлый алмый утырды. Кайчандыр аның бу картинаны күргәне бар иде, андагы күренешләрнең күбесе әле дә хәтерендә иде. Шуңа күрәдер, ахрысы, экрандагы кешеләр аны бөтенләй диярлек кызыксындырмадылар. Ул күбрәк үз янындагы Былбылны уйлады. Ул аннан килгән җиңелчә хуш исне тойды, аның кулы кызның утыргыч култыксасындагы кайнар, нәфис кулына тиеп китте. Бер мәртәбә ул үзенең ямаулы ботинкасы белән кызның танкеткасына, икенче мәртәбә терсәге белән тәненә орынып алды һәм, утка пешкән кебек, тиз арада читкә тайпылды. Ләкин, икенче якка авышу белән тупас каты тәнле ниндидер ир кешегә төртелде.

Кинода күрсәтелгән ниндидер күренешкә карата үз фикерен әйтеп, бер мәртәбә Былбыл аның колагына иелгәндәй итте һәм нидер аңлатырга тотынды. Габделхәй аңламады. Ул бары үз колагы янында җылы, нәфис дулкын тирбәлүен генә тойды. Менә бер заман бөтен зал шаулатып көлергә тотынды. Габделхәй йокыдан уянып киткәндәй булды. Залдагыларның нәрсәдән көлгәнен ул аңламыйчарак калды. Үзе дә сизмәстән Былбыл ягына борылды, аның кулына кагылып:

— Ни булды? Ник көләләр?—диде.

Пышылдап кына Былбыл нәрсәдер аңлатырга тотынды. Габделхәй аңламады. Бу минутта ул кинодан бигрәк үзенең кыюлыгы, әрсезлеге турында уйлады, әдәпсез кулын тартып алды да, оятыннан нишләргә белмичә, яңадан экранга текәлде. Ярый әле Былбыл аның уттай янган битен күрмәде. Беркадәр игътибарын туплагач, ул залның нәрсәдән көлүен төшенеп алгандай булды.

Мәскәү патшасы янына килгән татар илчесе, урыс сүзләрен бозып: «Казан балшой-балшой, Маскыва малинки-малинки».— диде. Зал, күрәсең, шуннан көлде. Урысча сөйләшә белмәгән татар илчесен мыскыллап көлде. Шул сүзләрне әйткән борынгы татардан бигрәк, бүгенге татардан — барлык татарлардан көлде.

Габделхәйгә кыен һәм күңелсез булып китте. Хәзер ул экранда күрсәтелгән күренешләргә, кешеләргә игътибарсыз гына карый алмады, хәзер ул һәр сүзгә колак салырга, һәр хәрәкәтне күңеле аша үткәрергә мәҗбүр булды. Соң дәрәҗәдә уяу һәм сак булып, ул экранда үзен тагын мыскыл итүләрен, үзенә, халкына пычрак атуларын көтте.

Менә Казанга сугыш белән килгән Иван Грозный гаскәрләрен күрсәттеләр. Казан җирендә муеннарыннан җиргә күмеп куелган урыс әсирләрен һәм аларны төрлечә мәсхәрә итүче вәхши татарларны күрсәттеләр. Кинодан аңлашылганча, Казан татарлары һәрвакыт канэчкеч һәм кыргый булганнар, Мәскәүгә, урысларга һәрвакыт явызлык эшләгәннәр, аларны кысканнар, талаганнар һәм аларга берничек тә дөньяда яшәргә ирек бирмәгәннәр. Гаделлекне, дөреслекне яклаучы, үз туган илен дошманнан сакларга, соңгы тамчы канына кадәр «поганый татарин» белән сугышырга әзер торучы батыр урыслар, мәскәүлеләр тимер киемнәргә төренеп, тәреләр күтәреп, вәхшиләр оясын туздырырга киләләр. Иван Грозный да, аның якыннары да, гаскәр дә — барысы да изгеләр, гайрәтлеләр. Алар — чын халык вәкилләре. Алар урыс даны өчен, Мәскәүнең иминлеге өчен сугышалар. Нәкъ хәзерге замандагы кебек... фашист илбасарларына каршы көрәшкәндәге кебек, гадел сугыш алып баралар.

Кинодан Габделхәй бик авыр тойгы белән чыкты. «Ник күрсәтәләр моны? Ник?!»—дип уйлады ул читтән тыш аптырап. Халыклар дуслыгы, диләр, урыс белән татар дус, туган, диләр. Дус, туган булгач, бер-береңне мыскыл итү нигә кирәк, кемгә кирәк? Татарның үз киносы юк. Казан өчен сугышның чынында ничек булганын татар үзенчә күрсәтә алмый. Киносы бул-

са да, бүгенге татар урысны шул кадәр мыскыл итеп күрсәтмәс иде. Бит татарча китапларда урысны мыскыл иткән бер сүз дә юк! Урыс китабында, Урыс киносында андый сүзләр тулып ята. Ник болай бу? Кая монда дөреслек, кая тигезлек?

Кинодан чыгучы халыкның күбесе шулай ук күңелсез һәм караңгы чырайлы иде. Бары тик кайбер урыс кешеләре генә, уенын-чынын бергә кушып, кинода әйтелгән сүзләрне кабатлыйлар, үзләренең таныш татарлары белән мыскыллашалар. Усалрак малай-шалайлар исә, бөтен урамга ишетелерлек итеп: «Казан балшой-балшой, Масква малинки-малинки!»—дип, «Бей татар!» дип кычкыралар, шаркылдап көлешәләр иде.



## VII

Габделхәй, Йосыф һәм Былбыл, халык төркеменнән аерылып, үзләре ягына киттеләр. Алар сөйләшмәдәләр. Кино турында сөйләшеп, фикер алышып булырлык түгел иде. Әгәр андагы сүзләрне, андагы күренешләрне яңадан искә төшерә башласаң, иң якын кешеңнең нечкә җиренә кагылырсың да, аның күңелен җәрәхәтләндерерсең шикелле иде.

Йосыфлар өенә килеп җитәрәк, Габделхәй туктап саубуллаша башлады.

— Әйдә Габделхәйне озатып куябыз?—диде Былбыл Йосыфка.

— Әйдә,—диде Йосыф.

— Мин үзем дә курыкмыйм,—диде Габделхәй. Шулай да карышып тормады.

— Әйдәгез әле берәр күңелле нәрсә турында сөйләшәбез!—диде Былбыл малайларның икесен дә култыклап алып.

— Нәрсә турында сөйләшәбез соң?—диде Йосыф.

— И-и Йосыф, җегет кеше шундый сорау биреп торамыни?!—диде Былбыл.—Кызлар белән булганда нәрсә турында сөйләшәләр соң? Ай турында, йолдызлар турында!

— Казан турында, Уфа турында ярамыймы?—диде Габделхәй, кызның җаена ятарга тырышып.

— Миңа бөтен нәрсә кызык,—диде Былбыл чак-чак кына ясалма бер күтәренкелек белән.—Әнә, карагыз әле, карагыз—ай йөгерә! Кызык бит, ыймы?

— Ай йөгерми, болытлар агыла,—диде Йосыф.

— Юк, йөгерә!—диде Былбыл.

— Әллә сез астрономия укымадыгыз?—диде Йосыф, күрәсең Былбылны чын күңелдән сөйли дип уйлап.

— Нәрсә соң ул астрономия? Беренче мәртәбә ишетәм андый сүзне,—диде, Былбыл.

— Нәрсә?!—диде Йосыф шаккатып.—Ну... күк турында...

— Күк турында түгел, айлар, йолдызлар турында,—диде Былбыл үзенең берни белмәвен онытып.

— Айлар дип сөйләшмиләр. Күктә ай бер генә,—диде Габделхәй.

— И-и, карагыз әле, карагыз!—диде Былбыл, ишетмәмешкә салынып.—Әнә, әнә, күрәсезме?

— Нәрсә соң, нәрсә?—диде Йосыф, күккә каранып.

— Берни күрмим,—диде Габделхәй дә.

— И-и, шуны да күрмәгәч!—диде Былбыл.—Күзегез шунда калсын!—диде ул кинәт һәм үзенең хәйләсеннән канәгать булып күләргә тотынды.

— Ах, харап булдым!—диде Габделхәй ыңгырашып, күзенә тотынып.

— Ни булды?—диде Былбыл, көлүеннән туктап.

— Уф, беттем, харап булдым!—диде Габделхәй аның саен шомлы итеп.

Аптырап Йосыф та, Былбыл да туктап калдылар.

— Берни күрмим—күзем күктә калды!—диде Габделхәй.

Былбыл яңадан көләргә тотынды. Соңлап булса да, Йосыф та аңлап алды һәм шулай ук көлеп куйган булды. Өчәүләшеп, бөтен урамны шаулатып

алар шулай көлешә-көлешә бардылар һәм көтмәгәндә ачыган сөт, әйрән исе аңкып торган җиргә килеп җиттеләр. Габделхәй шундук Сәкинәләр ягына карап алды. Анда ут янмый иде, ул якта тып-тын һәм караңгы иде. Таныш амбар почмагы да, куе караңгылыкка күмелеп утырган таныш йорт та — берсе дә хәзер Габделхәйнең күңелендә үкенү һәм вөҗдан газабы уята алмады.

— Минем бик озаклап айга карап торганым бар,— диде Былбыл яңадан ай темасына күчеп.— Айда көянтәсе-чиләге белән Зөһрә кыз басып тора, диләр. Бер дә көянтәле-чиләкле кызга охшамаган андагы таплар.

— Минем дә караганым бар — охшамаган,— диде Габделхәй дә.

— Минем ныклап караганым юк,— диде Йосыф.— Минемчә айга бары шагыйрьләр генә озаклап карый.

«Шагыйрь» сүзен Йосыф, әлбәттә, Габделхәйгә карата әйтте. Былбыл янында үзен шулай «шагыйрь» дип атавы Габделхәйне үсендереп җибәргәндәй булды.

— Чынлап карасаң, шагыйрь булмаган кешегә дә күренә ул,— диде «шагыйрь» сүзенә аеруча басым ясап.

— Юк, күренми,— диде Йосыф.

— Алайса, син анда берни дә күрмисеңмени?— диде Былбыл.

— Айны мин астроном булып күзәтәм,— диде Йосыф, әллә чынлап әллә шаяртып.

— Ура! Бездә шагыйрьләр дә, астрономнар да бар,— диде Былбыл.

— Бер астроном, бер шагыйрь,— диде төгәллек яратучы Йосыф.— Өченчесе кем?

— Өченчесеме? Өченчесе шагыйрь дә, астроном да түгел,— диде Былбыл.— Өченчесе — филолог... то-есть шагыйрь дип әйтсәң дә була.

— Бөтен дөньяны шагыйрьләр баскан икән,— дигән булды Йосыф.

— Беләсезме, мәктәптә укыганда мин дә татарча шигырьләр яздым,— диде Былбыл.

— Чынлапмы?— диде Габделхәй исе китеп.— Кызларның шигырь язганын беренче мәртәбә ишетәм.

— Сез барлык эшләрне ирләрнеке, кызларныкы дип бүләргә яратасыз икән,— диде Былбыл җиңелчә шелтә белән.

— Юк, мин алай бүлмим,— диде Габделхәй.

— Юк, юк, бүләсең, Габделхәй!— диде Былбыл, кайнарланып. Аның шул «бүләсең, Габделхәй» дигән сүзендә яшь егеткә карата аеруча якынлык сизелеп киткән сыман булды.

— Чынлап, минем ишеткәнем юкые кызларның шигырь язганын,— диде Габделхәй.

— Малайлар гел шулай инде алар — беркайчан безнең сүзгә ышанмыйлар,— диде Былбыл үпкәләгән сыман, ләкин үпкәләү аңа бөтенләй ятышмый иде.

— Хәзер язасыңмы соң?— диде Габделхәй, аның үзе кебек «син»гә күчеп.

Былбыл тиз генә җавап кайтармады. Станция ягында сузып-сузып паровоз кычкырды, кемнеңдер капкасы артында эт өргәне ишетелде.

— Искә төшерәсе килми,— диде бераздан Былбыл күңелсез генә.— Куркыныч төштәге кебек... Менә бу «Иван Грозный» кебек... Ташладым мин шигырь язуны. Бишенчедә, алтынчыда яздым. Үзем язган шигырьләрне сәхнәгә чыгып сөйләдем. Бер мәртәбә радиодан да сөйләттеләр. «Кышкы көндә» дип атала. Җиденчедә безнең мәктәпне яптылар. Без укыган мәктәп бик иске иде. Ике катлы агач йорты. Урыс мәктәбе таштан салынган. Тәрәзәләре зур, спорт заллары, актовый заллары бар. Ишегаллары иркен. Татар мәктәбендә балаларга бернинди шартлар юк, дигән сылтау белән, безне үз мәктәбебездән куалап чыгардылар да, бөтенебезне урыс мәктәбенә тутырдылар. Шундый кыен булды, шундый кайгырдым. «Бармыйм! Бармыйм!» — дип җылаганым әле дә хәтердә. Уку урысча. Күп нәрсә аңламыйбыз. Парталарга урыс балалары белән аралаштырып утырттылар. Татарча берәр сүз әйтсәң, укытучылар тирги, урыс балалары мыскыл итә, чәчтән

тарталар, төртеп китәләр. Арткы партада Саша дигән бер җүнсез малай бар иде. Тәнәфестә булсын, кайтырга чыкканда булсын — күзне ачырмый... «Татарка, поганка! Татарка, поганка!» дип кычкыра. «Поганка» нәрсә булгандыр — аңламыйм. «Татарка»ны аңлыйм. Нигә минем «татарка»лыгым мыскыл сүзедер — шулай ук аңлашылмый. Бер көнне кайттым да, «татарка» буласым килми, мин әйтәм, җылыйм. «Берни эшләп булмый, кызым, мин — татар, син — татарка»,— ди әти. «Татарка» булган өчен хурланмаска, горурланырга кирәк ди, татар ул бөек халык, ди. Шулаен шулай да, ничек итеп горурланасың «татарка» булган өчен? Тарих дәресендә Иван Грозный да Петр Первый. Татарны җиңүче бөек патшалар. Урыс патшалары нинди генә илне басып алмасыннар, кайда гына җырткычлык эшләмәсеннәр — һәркайда «азатлых өчен көрәшәләр», «урыс данын арттыралар». «Татар», «татар-монгол» бары сүгенү сүзе буларак кына кулланыла. Әдәбият дәресендә Пушкин да Лермонтов, Толстой... Шулай ук бөекләр.

— Алар, чыннан да, бөек,— диде Габделхәй.

— Анысы шулай,— диде Былбыл.— Ләкин безнең дә үзебез өчен кадерле, бөек кешеләребез бардыр бит?

— Бар!— диде Габделхәй ашыгып.

— Мин Казанга баргач кына белдем: Мулланур Вахитов Ленин белән бергә эшләгән. Аннан соң — Солтангалиев!— диде Былбыл, тавышын әкренәйтә төшеп.— Алар — революционерлар... бөек революционерлар!

— Мин дә беләм,— диде Йосыф чак-чак кына мактанып.— Тукай, Такташ...

«Шуннан башка беркемне дә белмисең шул!» — дип уйлап куйды Габделхәй Йосыф турында. Былбыл алдында бу турыда кычкырып әйтергә кирәксенмәде.

— Мин кайтып җиттем,— диде ул, үзләре өе ягына караштырып.— Сез мине озата килдегез, хәзер мин сезне озатып куйыйм.

— Син безне озатма инде, яме, Габделхәй. Без — икәү, курыкмабыз,— диде Былбыл гади генә итеп.— Иртәгә очрашырбыз. Ярый, сау бул.

— Сау булы... гыз,— диде Габделхәй теләр-теләмәс кенә. Йосыф белән Былбыл китеп бардылар. Алар киткән якка, караңгыга Габделхәй озак кына карап торды. Йосыфтан ул әз генә дә көнләшмәде. Шулай да бу минутта Былбыл янында аның Йосыф түгел үзен күрәсе килде.

## VIII

Икенче көнне ул иртән иртүк Йосыфларга китте. Ул килеп кергәндә иркен ишегалдында, лапас янында җиңел кәрендәскә җигелгән ат тора иде. Дәүләтгәрәй абзый белән Йосыф җиргә җәеп салынган җылымны төреп яталар иде. Габделхәй туры алар янына килде, исәнләште һәм әйткәнне дә көтмәстән, Йосыфка җылым төрергә булыша башлады.

— Инәң киләме? Хәле ничек?— диде Дәүләтгәрәй абзый, беренче сүзе итеп.

— Килә. Миннән торып калдылар,— диде Габделхәй.

— Әйбәт булган,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Хәзер ул гадәттәгегә караганда кызурак, ашыгыбрак кыймылдый, ашыгыбрак сөйләшә иде. Балык тоту аның иң яраткан шөгыльләреннән берсе иде, шуңа күрә, һәрбер балыкчы кебек, ул да бу эшкә тыныч кына карый алмый иде, ахрысы.

Җылым төрелеп беткәч, Дәүләтгәрәй абзый абзар баганасындагы дуңгәләктән атның каеш тезгенен чишеп алды, тезген очын дуга башындагы боҗра аша үткәрде дә камыт бавына бәйләп куйды. Шуннан соң ул туктаусыз авызлык тимерләрен чылтыратып, башын чайкап, койрыгын селтәп, чебен-кигәвен куып торган кара бияне иплән кенә капка ягына борды.

— Кая, чыгалармы әле тегеләр?— диде ул Йосыфка һәм шул ук вакытта өч эчендәгеләргә эндәшеп.

Аның шул сүзләрен генә көтеп торган кебек, чолан ишегендә Фәрханә апа белән Былбыл күренде.

— Җәгез, булдыгызмы?— диде Дәүләтгәрәй абзый, хатын-кызны ашыктырып.

— Булдык, булдык, җизнәй!— диде, Былбыл.

Башына ул чәчен бергә туплап кыска гына яулык бәйләп куйган өстенә эре чичкә төшерелгән кыска итәкле ситса күлмәк һәм иркен балаклы озын чалбар — спортсменнар чалбары киеп куйган иде. Фәрханә апа белән алар икесе дә кулларына авыр-авыр төргәкләр, сумкалар тотканнар иде.

— И-и чибәрттәй, Габделхәй килеп тә җиткән!— диде Былбыл Габделхәйне күреп.— Исәнме, Габделхәй. Кара, син бик иртә торасың икән.

— Балыкка барганда йоклап ятып булмый инде,— диган булды Габделхәй.

Ашыгып ул Былбыл янына килде һәм авыр сумкаларның берсен үз кулына алды.

— Рәхмәт,— диде Былбыл.

— Әллә бәрәңге салмаганнар инде?— диде Фәрханә апа, керәндәс төбендәге яшел печәнне актаргалап.

— Эх, салмаганбыз шул!— диде Йосыф.

Ул тиз генә чоланга кереп китте һәм аннан тулар-тулмас итеп салынган бер бидерә иске бәрәңге алып килде, бидерәне җылым янына, керәндәс артына куймакчы булды. Дәүләтгәрәй абзый бу эшне күрде, сүзсез генә бидерәне Йосыфның кулыннан алды да печән арасына җайлап утыртып куйды.

— Коелып бетәр ул анда, артта,— диде ул бераздан, аңлатырга кирәк табып.— Диздекәй кая? Бармыймыни?

Соңгы сүзен ул Фәрханә апага карата карап әйтте. Фәрханә апа җавап биреп өлгергәнче, Йосыф яңадан өйгә кереп китте һәм йокысы ачылып җитмәгән сеңлесен күтәреп килеп тә чыкты. Диздекәйнең йөзе чытык иде. Бер туфлиен аягына кигән, икенчесен кияргә өлгермичә кулына гына тоткан иде. Йосыф сеңлесен керәндәс эченә печән өстенә утыртып куйды да:

— Киен тизрәк!— диде.

Дәүләтгәрәй абзый ым кагу белән, Габделхәй олы капканы ачып куйды һәм ат-арба урам якка чыкканчы капканы тотып торды. Шуннан соң алар Йосыф белән икәүләп капканы кире ябып куйдылар, Эчке яктан аркылы агач салып бикләделәр.

Кәрендәснең уң ягына Дәүләтгәрәй абзый, сул ягына Былбыл утырды. Сытылырга гына торган чытык йөзле Дездемонаны Былбыл үз алдына утыртты. Габделхәй ат башына, Йосыф артка, җылым янына урнашты. Фәрханә апаны утыртмадылар. Ул әкрен генә арттан иярде. Шәмсебанат апалар килеп җиткәч, алар бергәләп юл буйлап килергә, Йосыф аларны кайтып алырга тиеш иде.

— Син безнең лакей,— диде Былбыл арттагы Йосыфка.

— Әниләрне алырга кайтканда мин барин булырмын,— диде Йосыф.

— Мин — кучер,— диде Габделхәй, Дәүләтгәрәй абзый кулындагы дилбегәне үз кулына алмакчы булып.

Ат бик көр иде, яшь һәм житез иде. Дәүләтгәрәй абзыйның дилбегәне үз кулыннан ычкындырасы килмәде.

— Кучерлыкка укырга кирәк,— диде ул көлемсерәп.

## IX

Кояш чыгып, әкрен генә җир өстеннән күтәрелә барса да, көн әле салкынча иде. Юл буендагы үләннәрдә чык тамчылары елтырый, арба артыннан әлегә тузан да тузып калмый, тирә-якта кошлар, чикерткәләр тавышы да бик үк ишетелми иде.

Яңавылдан Бүә буена бару өчен тимер юлны чыгарга, тимер юлны чыгу өчен исә беркадәр җир тимер юл янынннан барырга кирәк иде. Юл аша чыга

торган турыга җитәрәк, Дәүләтгәрәй абзый атын тыя төште, поезд-фәлән килмиме дип як-ягына карангандай итте дә кычкырып:

— Аллага тапшырдык!— диде һәм дилбегәне бушатып җибәрде.

Керәндәс юл аша чыкканда рельслар арасындагы шпаллар дөбердәп калды. Ат такыр юлдан иркенләп, җиңеләеп юрттыра башлады.

— Мә, кучер, син тот хәзер,— диде Дәүләтгәрәй абзый, дилбегәне Габделхәйгә биреп.

Габделхәй дилбегәне алды һәм куанычыннан елмаеп, җиңелчә генә сызгырып җибәрде.

— На малкай!— диде.

Габделхәйнең кайнарланган битенә салкынча җил бәрде. Ат тоягыннан, тәгәрмәчләрдән як-якка җиңелчә балчык кисәкләре чәчрәп калды.

Күп тә үтмәде, арба юлы тузанланып беткән вак куаклар арасына килеп керде. Юл читендә моңаеп, йокымсырап, тузан кунган үләннәр, ак, зәңгәр тәтәйләр, чыпчык сабыннары утырып калды. Куаклардан куркытылган вак кошлар очып чыкты. Куаклыкны узгач, арба юлы түбән таба йөгерә башлады. Атның үзенә буйсынмаска чамалавын сизеп, Габделхәй дилбегәне тартыбрак тотты. Юл һаман түбәнәя барды һәм бөтенләй искәрмәстән диярлек, текә булып аска шуышты. Тигез басулар, тузанлы куаклар артта калды. Аякларын терәп баскан килеш, артына каерылып, Габделхәй бар көченә атны тыярга тырышты. Ләкин аны алай гына тыеп калырлык түгел иде инде.

— Җибәр, үз көенә җибәр!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Тауның яртысын узгач, Габделхәй дилбегәне бушатып җибәрде. Үзен иректә сизгән кара бия куш аяклап чабарга тотынды.

Аста, түбәндә чытыр-чатыр урманнар, сазлыклар һәм уйдык-уйдык акланнар белән тулы иңкүлек башланды. Язгы ташу вакытларында су баса торган бу иңкүлекнең каршыдагы ягы Сакат тауларына барып терәлә. Әле тауларга якын килеп әле ерагаеп, урманнар, болыннар арасыннан Бүә суы агып ята иде.

Тау төшкәндә Дездемона чыркылдап кычкыра башлады. Былбыл да курыкты, ахрысы — ул шундук Габделхәй янындагы тимер тоткага ябышты. Габделхәй аның кулын тойды, чак-чак кына артына борылгандай итте дә:

— Курыкма! Мин монда!— диде.

Бер заман кучерның колак төбендә генә Дәүләтгәрәй абзыйның мактап әйткән сүзләре ишетелеп китте:

— Булдырдың, Габделхәй!

— Кучерлыкка имтихан бирдең. «Бишле»!— диде Былбыл да, җизнәсенең сүзен җөпләп.

Шатлыгыннан авызы колагына җиткән Габделхәй каерылып артына борылып карады. Аның күз карашы Былбылның күз карашы белән очрашты. Оста кучерга күңеллерәк булып китте. Шул ук вакытта ул Йосыфның юклыгын да күреп алды.

— Йосыф кая?— диде, коты алынып.

Габделхәй атны тыя төште. Барысы да артларына борылып карадылар — керәндәс артында, чыннан да, Йосыф юк иде. Габделхәй атны туктатырга кирәк тапты. Артка, тау ягына карап, бераз вакыт көтеп тордылар. Еракта, агачлар арасында Йосыфның тавышы ишетелеп китте. Озакламый ул үзе дә күренде.

— Исән, исән!— диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый берни әйтмәде — бары керәндәс артындагы җылымга гына күз ташлап алды.

— Мин үзем төшеп калдым,— диде Йосыф килеп җиткәч.

Былбыл белән Габделхәй аннан көләргә тотындылар. Йосыф яңадан үз урынына — җылым янына менеп утыргач, ат аңадан кузгалып китте.

Куе урман эчендәге юл тар һәм чокыр-чакырлы иде. Ике якта да ботак очлары тоташып, аралашып үскән тал-шомырт, карама, зелпеләр тыгызланып утыра. Тәгәрмәч казыган чокыр-чакырлы җирләрдә керәндәс әле бер якка, әле икенче якка авышты. Биткә, күзгә ботак очы

тимәсен өчен, арбадагыларга әледән-әле башларын иярга, читкә янтаерга туры килде.

Дымсу һәм ярым караңгы урман эченнән озак кына баргач, кинәт көн яктырып китте. Түбә өстендә яп-якты, чип-чиста булып зәңгәр күк йөзе күренде. Шул ук вакытта якында гына шаулап аккан су тавышы ишетелде.

Ташкичү дип атала торган бу төштә Бүә бик нык саегып калган иде. Язгы ташудан соң елга уртасында озын гына ком утравы барлыкка килгән иде. Елга ярлары ике якта да текә һәм биек иде. Балыкчылар килгән якта, Яңавыл ягында ул бөтенләй диярлек шәрә иде. Каршы якта исә күз күреме җиткән кадәр ераклыкта яр буйлары комлыклар һәм җырып чыккысыз тал куаклары белән капланган иде.

Бүә ярына якынлашкач, Дәүләтгәрәй абзый дилбегәне яңадан үз кулына алды һәм атны туктатты да яшьләрнең барысына да арбадан төшәргә кушты. Су янында ул үзе дә җиргә төште. Атның күкрәген, янбашларын сыйпалады, корсак астына кунган кигәвеннәрне куалап җибәрде. Авызлыкны ычкындырып аркалыкны бушайткач, кара бияне суга якынрак китерде. Кара бия, озын муенын сузып, пошкыра-пошкыра, аяк астында туктаусыз агып яткан суны тәмләп эчәргә тотынды. Ат су эчкәндә Дәүләтгәрәй абзый яратып, иркәләп аның корсагыннан, янбашларыннан сөеп торды. Эчеп туйгач, ат башын калкытты, рәхмәт әйткән сыман, җиңелчә генә пошкырып куйды.

Дәүләтгәрәй абзый аркалыкны күтәртеп бәйләде дә арбага менеп утырды һәм атны саерак, тигезрәк җирдән алып бара башлады. Шул ук вакытта кычкырып: «Аллага тапшырдык!»—диде. Тимер кыршаулы тәгәрмәчләр астында, су төбендә вак ташлар кыштырдады, тәгәрмәч тәпиләре тирәсендә су чупылдады.

Яшьләр суга, яктылыкка, су өстеннән очкан акчарлаклар тавышына—тирә-якка сокланып, хозурланып яр кырыенда карап тордылар, су уртасына керә барган арбалы атны, Дәүләтгәрәй абзыйны күзәттеләр. Яр читендә сай булса да, елганың уртасы шактый тирән булып чыкты. Су башта алгы тәгәрмәчнең тугымына җитте, аннан соң тугымны да күмеп китте. Бераздан су арткы тәгәрмәч тугымын да күмә язды. Суның иң тирән төшендә, уртада арткы тәгәрмәч тугымы да күмелде. Чыланмас өчен Дәүләтгәрәй абзый ат башына күчеп утырды. Ул арада керәндәскә су керде һәм аска салынган печән калкып, агып китте. Артка бәйләп куелган җылым су астында күмелеп калды.

Икенче як яр читенә килеп чыккач ат туктады һәм бөтен гәүдәсе белән кагынып, өстендәге су тамчыларын койды. Керәндәс төбеннән шыбырдап су акты. Дәүләтгәрәй абзый дилбегәне селтәп җибәрде, «На, малкай!»—диде һәм ат таллар арасыннан җиңел генә кузгалып китте.

Ул арада малайлар, Былбылдан читкәрәк китеп, өс киемнәрен, чалбарларын салдылар.

— Барыгыз, бар, сез алдан китегез!—диде Былбыл малайларны үз яныннан куалап.

— Кем белән чыгасың—минем беләнме, Былбыл апаң беләнме?—диде Йосыф Дездемонага.

— Синең белән. Син көчлерәк,—диде Дездемона.

Йосыф иелеп аны кулына күтәрде. Дездемона ике куллап абыйсының муеныннан, аяклары белән биленнән кочып алды. Бер кулы белән сеңлесен, икенче кулы белән төрелгән чалбарын, аяк киемнәрен тотып, Йосыф алдан атлады. Габделхәй дә чалбары белән ямалган ботинкасын тотып аның артыннан атлады. Ялан аякка су башта салкын тоелды. Ләкин тирәнгәрәк керә барган саен аның салкынлыгы бөтенләй сизелмәс булды. Аякларга, бөтен тәнгә туктаусыз нидер сөйләнеп, каядыр ашыккан суда, елгадан гаҗәеп бер рәхәтлек һәм көч-куәт бәрелде.

Кичүнең тирән төшенә җиткәч, Габделхәй онытылып артына борылып карады.

— Карама!—дип кычкырды Былбыл, кабаланып.

Ул да малайлар кебек чалбарын, аяк киемнәрен салып кулына тоткан, күлмәк итәген күтәреп учына алган һәм вак ташларга иплəп кенә баса-баса, суга таба килеп ята иде. Габделхәй оялып шундук йөзен читкә борды. Былбылның нидер кычкыруын ишетеп, Йосыф та артына борылып карады. Аңа да ярым боерып, ярым үтенеп әйтелгән «Карама!» янгырады.

Малайлар, тирән җирне үтеп, икенче якка, комлыкка барып чыктылар һәм үзара мәгънәле генә карашып, елмаешып, ат юлыннан югары менеп киттеләр. Яр өстендә аларны Дәүләтгәрәй абзый көтеп тора иде. Малайлар чалбарларын киделәр, ләкин аяк киемнәрен киеп тормадылар. Барып җитәргә инде күп калмаган иде. Хәзер инде тәпи-тәпи барсаң да була иде.

Ул арада Былбыл да менеп җитте һәм керәндәстә үзе утырган урында печән юклыгын, җитмәсә керәндәс төбенең чыланган булуын күреп кычкырып җибәрде.

— Монда утырып булмый!—диде.

— Габделхәй янына ат башына утыр. Анда коры,—диде Йосыф.

— Үзем генәме?! Мин куркам!—диде Былбыл.

— Икегез утырыгыз,—диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Сыярбыз микән соң?—дигән булды Габделхәй һәм бер дә юктан кызарына башлады.

— Сыярбыз, сыярбыз!—диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый керәндәс төбенә үзенең иске гимнастеркасын җәеп куйды, шуның өстенә утырды да Диздекәйне үз алдына утыртты.

— Әйдәгез, кузгалдык, балалар,—диде беркемгә дә атап әйтмичә, шулай да Габделхәйне күз алдында тотып, чөнки дилбегә аның кулында иде.

Ат кузгалып китте. Алар ярты чакрым чамасы җирне ачык болын уртасыннан бардылар да ярым караңгы әрәмә арасына килеп керделәр. Юл монда тигез иде, шулай да керәндәс әледән-әле як-якка чайкалды. Арба чайкалганда Былбыл куркып җиңелчә генә кычкырып җибәрде, көлде һәм үзенең сөенечен белдереп, каядыр читкә күрсәтеп, әледән-әле: «Карале, кара!»—диде. «Нинди матур!»—диде. Бер мәртәбә арба бик нык янтайгач, ул Габделхәйнең биленнән тотып алды. Бәхеттән исергән җегетнең куанычы эченә сыймады. Бөтен тәне уттай янды, колак очлары кызарып чыкты. Үзенең шатлыгын, кызаруын, оялуын башкаларга сиздермәс өчен ул кирәксә дә, кирәкмәсә дә дилбегә какты. Дәүләтгәрәй абзый сыман: «Әйдә, малкай!»—диештереп, кычкырып-кычкырып алды.

Бөтенләй көтмәгәндә диярлек юлчылар киң, иркен болынга килеп чыктылар.

— Каяле, мин дә тотып карыйм дилбегәне!—диде Былбыл Габделхәйнең колагына пышылдап.

Кучер, икеләнгәндәй итеп, Дәүләтгәрәй абзый ягына карап алды.

— Бай абзый нәрсә әйтә бит әле!—диде ул көлеп.

— «Бай абзый», дилбегәне тотыйм әле?—диде Былбыл.

— Күп калмады инде, балалар,—Дәүләтгәрәй абзый икеле-микеле итеп.

— Әнә, алырга кушты,—диде Былбыл һәм Габделхәйнең кулындагы дилбегәне алды да көлә-көлә селтәнергә тотынды:—На, малкай! На!

Кара бия дилбегәнең икенче кулга күчүен сизеп, колакларын шомартып, әле уңга, әле сулга карап-карап алды, ләкин җайланган адымын әз генә дә үзгәртмәде.

— Бик каты чаптырма әле! Арбадан төшеп калам инде,—диде Йосыф Былбылга, үзенчә шаярткан булып.

— Менә хәзер тауга җитәбез, шунда төшеп калырсың,—диде Былбыл.

— Ачуымны китерсәгез, тауга җиткәнче дә төшеп калырмын!—диде Йосыф.

Болын аша үткәч, иске такыр юл яңадан саз һәм урман исе килгән куе чытырманлыкка килеп керде. Чытырманлыктан соң арба юлы беркадәр үргә күтәрелде һәм шул чакны иркен генә болын күренде.

— Менә, килеп тә җиттек, балалар,—диде Дәүләтгәрәй абзый, эчке бер тантана белән.

## X

Ат туктау белән, барысы да шыбырдашып җиргә коелдылар һәм арбадагы әйберләрне алып куйдылар. Дәүләтгәрәй абзый атны борды һәм дилбегәне Йосыфка тоттырды.

— Мә, улым, тиз йөре,— диде.

Йосыф, дилбегә үз кулына кергәч тә, масаеп, горурланып Былбыл белән Габделхәй ягына карап алды, керәндәскә, әтисенең дымлы гимнастеркасына утырды да:

— Барин китте!— диде һәм бер дә кирәкмәгәнгә сызгырып җибәрде.

— Тиз йөре!— диде Дездемона, кул болгап.

— Брезент алырга онытма,— диде Дәүләтгәрәй абзый, Йосыф артыннан кычкырып.

Алар нәкъ Бүә яры буена туктап калганнар иде. Ярның бу ягы сөзәк иде, су буе комлы һәм иркен — җылым тартырга җайлы иде. Каршы якта исә, кызыл балчыгы коелып торган текә яр өстендә, тыгызланып, бер-берсенә сыенып, карамалар, юкәләр, усаклар тынып калган, алардан арырак, барысыннан да биегрәк булып, бик зур ялгыз чыршы калкып утыра иде. Бераз гына үрдәрәк, тирән су өстенә тамырлары-ниләре белән, тамыр арасындагы туфрак кантарлары белән зур-зур агачлар егылып төшкән иде. Аларның кайберләре су уртасында утырып калган, кайберләре корыган башлары белән суга капланган, кайберләре исә башкалар өстенә сузылып ятканнар иде. Ул тирәдәге су тагын да тирәнрәк булып, серле һәм куркыныч булып тоела иде.

Иртәнге кояш нурында коенган болын, куаклар, каршыдагы урман ягында бөтен нәрсә туктаусыз гүләп, чеңләп, шаулап тора сыман иде. Шул ук вакытта юкәләрдән, чык тамчылары җемелдәшкән болын өстеннән хуш исләр бөркелә. Суның тирән җирендә чулт-чулт итеп чабаклар сикерә, яр буенда канатларын сызгыртып, түбәннән генә керәшәләр очып йөри иде. Кайдадыр еракта, Очлы тау ягында тоныграк тавышлы ниндидер олы кош кемгәдер кычкырып-кычкырып куя иде.

Суга иң элек Дәүләтгәрәй абзый якын килде, сүзсез генә карап торды да, үзенең артындагы Габделхәйгә эндәшкән сыман:

— Тегеләрне күтәргә туры килер,— диде.

— Әйдә, җизнәй, күтеп тормыйбыз!— диде якындагы Былбыл, аның нәрсә турында әйткәнен чамалап.— Өч кеше бер җылымны тарта алмыйбызмы әллә?

— Без әле дүртәү,— дигән булды Габделхәй.

— Юк, Былбыл, күтәргә туры килер,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Барыгыз сез хәзергә җиләк, карагат карый торыгыз, мин җылымны җайлап куярмын. Өчәүләп без тартуын тартырбыз бәлки, ләкин аның иң кызыгы бергәләп тарту, Былбыл!

— Шулай шул,— диде Габделхәй дә килешеп.

Дәүләтгәрәй абзыйның җиләк-карагат җыярга кушуы аның күңеленә хуш килде.

— Кайчан су керәбез?— диде Дездемона.

— Шаулама!— диде Габделхәй Дездемонага бармак янап.— Су буенда кычкырып сөйләшергә ярамый, балык курка.

— Әйе, әйе, курка,— диде Былбыл да.

Дәүләтгәрәй абзый җылымны җиргә салды һәм игътибар белән аның һәр күзәнәген карарга тотынды.

— Барыгыз, бар, ераграк китегез моннан,— диде ул яшьләргә кул селтәп.— Кирәк булгач, үзем чакырырмын.

Габделхәй белән Былбыл, Дездемонаны ияртеп болын ягына китеп бардылар. Бу яктагы болыннар, әрәмәләр Габделхәйгә таныш иде. Ул мондагы һәрбер куакны, һәрбер чокыр-чакырны биш бармагыдай белә иде. Былбылның ул сул ягыннан, яныннан гына атлап барды. Ул аңа мондагы әрәмәләр, җиләклекләр турында сөйләде. Узган кышны икесенә бер мылтык алып

Йосыф белән шушында ауга килүләре күпме патрон шартлатып та, бер чыпчык та атып ала алмаулары турында сөйләде.

— Нинди мылтык? Автоматмы әллә?— диде Былбыл куркып.

— Ау мылтыгы!— диде Габделхәй.— Дәүләтгәрәй абзыйныкы. Ул бит аучы да.

— Беләм,— диде Былбыл.

Шуннан соң Габделхәй өченче ел көз көне инәләре белән, күрше хатыннар белән шушы ук болынга балан җыярга килүләре, адашулары һәм елгада балык шартлатып йөрүче нindидер шикле бәндәләрне очратулары турында сөйләде.

Алар шулай мавыгып үзара сөйләшеп барганда Дездемона туктап калды, шыңшырга тотынды һәм киреләнеп җиргә үк утырды.

— Ни булды?— диде Былбыл чүгәләп.

Дездемона ни булганын әйтеп тормады, сул аягын ике куллап тотып алды да, иелеп, табанына казалган үлән шырпысын эзләргә тотынды. Аяк киемен ул әтисе янында калдырган булган икән. Дездемона янына Габделхәй дә иелде, Былбыл белән бер-берсенә якын килеп, алар икесе дә әбәләк кызыйның уч төбедәй бәләкәй генә тәпиен карарга тотындылар. Габделхәйнен битенә Былбылның яулык астыннан чыгып калган берничә чәч бөртеге тиеп китте, борынына аның кайнар тыны килеп бәрелгәндәй булды. Артык якынаюдан куркып, уңайсызланып ул тиз генә башын читкәрәк алды. Былбыл исә, берни сизмәгәндәй, бирелеп Дездемонаның табаныннан шырпы эзләде.

— Кая соң, берни күрмим,— диде ул табанга өрә-өрә.

— Мин анда бармыйм!— диде Дездемона шыңшып.

— Ә, менә икән!— диде Былбыл, ниһаять.

Нәфис тырнак очлары белән ул нидер эләктереп алды, көлеп җибәрде. Аннан күрмәкче, авыртудан котылуына сөенепме, Дездемона да көлеп җибәрде.

— Булды!— диде ул җиңел сулап.

— Кем элек?— диде Былбыл.

— Минелек!— диде Дездемона.

Алар шундук урыннарыннан сикереп тордылар, аякларына бастылар. Дездемона «элек» булды, Былбыл апа арткарак калды, Габделхәй тагын да арткарак калган булып чыкты.

— Бар, тиз генә аягыңа киенеп кил,— диде Былбыл Дездемонага.

Әле генә «бармыйм» дип карышкан кызый хәзер инде «аягыма кимим» дип карыша башлады.

— Барсын шулай гына,— диде Габделхәй.

## XI

Чабылган болын аша үткәч, алар күләгәле әрәмә эченә килеп керделәр. Габделхәй алдан барды. Ул аркылы сузылып яткан, ауган агачларны атлап чыкты, кайберләрен әйләнеп үтте, үзеннән артта килүчеләрнең битенә тимәсен өчен, ботакларны як-якка аерып тотып торгандай итте.

Әрәмә артык куе түгел иде, шулай да Дездемона тагын шыңшырга тотынды. Хәзер ул «анда бармыйм» дип киреләнде.

— Бар син кит,— диде Былбыл аңа.— Әтиең әнә анда гына — күренеп кенә тора.

— Бар, бар,— диде Габделхәй дә.— Моннан без сине карап торырбыз.

— Сукмакка чыгарып куй!— диде Дездемона таләп итеп.

Кызның сүзен тыңлап, әрәмәдән кире чыгарга туры килде. Яр буендагы Дәүләтгәрәй абзый күренеп кенә тора иде. Дездемона, артына борылып карый-карый, әтисе ягына йөгерде. Ул ерагайгач, Габделхәй Былбылга карап алды да яңадан кузгалып китте. Якында гына ул яхшы белгән «Карагат күле» бар иде. Аның хәзер Былбылны шунда алып барасы килде.

Сирәк куаклар аша үткәч, болынга черегән яфрак исе, саз исе килеп бәрелде. Озакламый саз исен ылыс исе алыштырды. Алар төбендә берән-

сәрән абага сыман үләннәр үсеп утырган ниндидер чыршылыкка килеп керделәр. Бер-берсеннән тигез ара калдырып утырган чыршы төпләрендәге җир өсте тоташ кызгылт ылыс белән түшәлгән иде. Тын алуы монда иркенәеп китте. Куе чыршы араларыннан тасмадай сузылып, кыйгачлап кояш нурлары төшкән. Кояш нурларында бер ботактан икенче ботакка сузылган үрмәкүч аулары җемелдәшә иде. Тирә-якта тын, тып-тын иде. Бер-берсенә сыенып, бер-берсеннән уздырып биеккә, яктыга үрелгән төз, купшы чыршылар, илаһи тынлыкны бозарга теләмәгәндәй, тынып-йокымсырап утыралар иде. Аяк атлаган саен бары тик йомшак, коры ылыслар кыштырдаганы ишетелә дә чырт-чырт итеп коры ботаклар гына калгалый иде.

— Нинди күңелле!— диде Былбыл исе китеп.— Менә нинди күңелле икән монда!

Шулай аяк астындагы ылыс юрганын таптап, аркылы сузылган үрмәкүч ауларын өзгәләп бара торгач, көтмәгәндә тукран тавышы ишетелеп китте. Кайдадыр якында гына, корыган чыршы башында, тукран корыч томшыгы белән бер-бер артлы тукылдатып алды. Былбыл да, Габделхәй дә икесе дә берьюлы сискәнеп киттеләр, туктап калдылар һәм шундый каты тукылдатучының үзен күрмәкче булып, муеннарын сузып, як-якка карана башладылар.

— Кая соң ул? Күрәсеңме син?— диде Былбыл пышылдап, Габделхәйгә таба елышып.

— Күренми,— диде Габделхәй.

Тын алырга да куркып алар өзак кына күзәтеп тордылар, ләкин тукылдаган тавыш яңадан кабатланмады. Габделхәй кузгалып китмәкче булып аягын гына кузгаткан иде, тукран тагын тырылдата башлады.

— Әнә!— диде Габделхәй, якындагы агач башына күрсәтеп.

Бик нык игътибар белән Былбыл каядыр югарыга карарга тотынды.

— Юк, берни күрмим,— диде ул.

— Күзең шунда калсын!— диде Габделхәй.

— Ай, күзем күрми!— дигән булды Былбыл шаянланып.

Икесе дә кичәге сөйләшүне искә төшереп, көлешеп алдылар һәм кузгалып киттеләр. Тоташ яфраклы агач урманы уртасында утрау сыман булып утырган чыршылык зур түгел иде. Озакламый чыршылар артта калды һәм яңадан саз исе — куе, сусыл үлән һәм җыелып, череп яткан су исләре килә башлады. Монда кайчандыр шаулап Бүә аккан. Елга үзенә яңа юл салгач, иске юл күлгә, күл сазлыкка әйләнгән. Хәзер ул камыш сыман биек үләннәр белән, вак-вак түмгәкләр белән, ялгыз куаклар белән капланган озынча бер батынкы җир иде. Котырып үскән куаклар арасында, оя-оя булып утырган камышлы түмгәкләр арасында — әле анда, әле монда төнбоеклар, бака ефәкләре белән чуарланган кесәлдәй куе яшькелт сулар ялтырап ята иде. Уйдык-уйдык суларның кайберләре зур гына, кайберләре кибеп бетеп бара һәм шул сулы чокыр төпләрендә корыган саз үләннәре моңаеп утыра иде.

— Мин куркам. Анда бармыйк, Габделхәй,— диде Былбыл.

Ул моны баягыча ярым пышылдап әйтте, якындагы ниндидер куркыныч җан ияләре ишетмәсен, дигән сыман итеп әйтте. Кызның йөзендә Габделхәй куркудан бигрәк шомлану, тынычсызлану күрде.

— Нәрсәдән куркасың?— диде ул кызның үзе кебек үк пышылдап.

— Үзем дә белмим,— диде Былбыл.— Әнә анда... куаклар арасында кемнәрдер карап торалардыр кебек.

— Кем булыр икән соң ул анда?— диде Габделхәй, сүзне уенга бормакчы булып.— Әйдәле, барып карыйк — чыннан да, берәрсе яшеренеп ятмый микән анда?

Бу сазлыкка әле быел кеше аягы басмаган иде бугай. Карагат әле нык-лап пешмәгән, үрдәк атарга инде соң. Габделхәй төбәп барган куакның кояшка каршы ягына килде дә иелә төшеп бер ботакны күтәргәндәй итте. Авыр ботакның төбеннән алып очына кадәр эре җимешле тәлгәшләр асылынып тора иде. Яңа пешә башлаган карагат шундый эре, тәлгәшләр шундый күп иде — ботакта хәтта яфракларга да урын калмаган.

— Менә ул!— диде Габделхәй бер-ике тәлгәшне өзеп алып.

— Бу миңа күчтәнәчме, Габделхәй?— диде Былбыл.
— Күчтәнәч, ләкин аны әле ашарга ярамый,— диде Габделхәй.
— Мин аны ашамыйм — гәрәбә кебек итеп тагып кына куям,— диде Былбыл балаларча куанып һәм чыннан да каралҗым карагат тәлгәшен изүендәге сәдәпкә тагып куйды.— Матурмы?— диде ул аннары.
— Матур,— диде Габделхәй, аның түшенә кырын күзен төшереп.
— Монда җиләк юкмыни?— диде бераздан Былбыл.
— Җиләк бар барын, тик моннан ерак,— диде Габделхәй.— Монда әле кызыл карагат та бар. Анысын инде җыйсаң да була.
— Минем әти ярата кызыл карагатны,— диде Былбыл.— Балыктан соң кереп җыярбыз, име? Мин әтигә кызыл карагат алып кайтырмын.
— Мин аны сиңа үзем җыеп бирермен. Күпме кирәк — шул кадәр!— диде Габделхәй.
— Ярар, шулай итәрбез,— диде Былбыл, килешеп.
Ул шулай дип әйтергә дә өлгермәде, нинди дер кара шома нәрсәнең аяк астыннан гына диярлек шуышып баруын күреп алды һәм коты алынып:
— Җылан!— дип кычкырып җибәрде.
Куркудан Габделхәй дерт итеп китте, борылып Былбыл ягына карады һәм шул ук мизгелдә кояшлы ачык җирдә ашыга-ашыга боргаланып, куркыныч елкылдап китеп барган зур гына җыланны күреп алды. Җыланга карата анда табигый дошманлык тойгысы саклана иде. Бу аның канына сеңгән иде. Җыланны күрсәң, теләсә кайда үтерергә, үтерә алмасаң, ничек тә аннан ераграк булырга кирәк иде. Бары тик йорт җыланына, мөгезле җыланга һәм тузбашка гына кагылырга ярамый иде. Йорт җыланы йортны саклый, бәхет китерә, мөгезле җыланның мөгезен күргән кеше гомергә бәхетле була, дип исәпләнелә иде. Аларны куркыткан кара җыланны үтерергә кирәк иде. Ләкин ул әнә качты. Качсын әйдә.
— Уф!— диде Былбыл, йөрәк турысына кулын куеп.— Шундый куркытым! Йөрәк дөп-дөп тибә. Тотып карале менә!
Аны-моны уйламыйча ул Габделхәйнең үзеннән-үзе салынып төшкән кулын тотып алды, аны-моны уйламыйча бик каты дөпелдәп типкән йөрәге турысына китерде. Кызның йомшак кулы үз кулына килеп тигәч тә, йомрыланып калкып торган тыгыз күкрәгенә кагылып киткәч та яшь җегетнең куркудан юкка чыккан кайнар каны яңадан уянды, кулына җан керде һәм көчле дулкын булып бөтен тәненә таралды. Җылан, курку, җирәнү — барысы онытылды, якында, янәшәдә бары тере булып, сокландыргыч булып илаһи зат кына торып калды. Корт чаккандай, кулын ул шундук тартып алды, колак очларының кызарына барганын тойган хәлдә, күз карашын читкә борды. Былбыл да, үзенең саксызлыгын аңлап, тынып калды.
— Нинди куркыныч!— диде ул, телгә килеп.
— Әйдә, китик моннан,— диде Габделхәй.— Кемнәрдер карап та тора дисең...
— Әйдә,— диде Былбыл күндәм генә.

## XII

Бер ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, атларын кызу атлатып, Йосыфлар да килеп җитте. Атны ярдан читкәрәк, зур шомырт куагы төбендә туардылар да, кешәнләп якындагы болынга утларга җибәрделәр. Фәрханә апа белән Шәмсебанат апа, балыкчылар балык тотканчы дип, якын-тирәне әйләнеп чыкмакчы булдылар. Бу яктагы болыннарны, куаклыкларны — кайда җиләк, кайда карагат булуын алар да яхшы беләләр иде. Шуңа күрә, яр буенда артык тоткарланмыйча, үзара нидер сөйләнеп, әкрен генә читкә китеп бардылар. Ләкин алар әле генә Габделхәй белән Былбыл булган якка түгел, бөтенләй икенче якка киттеләр.
Әкрен генә, ялкау гына агып яткан Бүә шундый саф, шундый тонык сулы иде, ныклабрак карасаң, су төбендәге иң вак ташларны да аермачык

күрергә була иде. Мондый тоныкъ суда балык тотып булмаячак иде, әлбәттә. Җылым сала башлаганчы Дәүләтгәрәй абзый Йосыф белән Илгизне ургә, ләм-ком актарып, суны болгата башларга җибәрде, Габделхәйгә үзе янында калырга кушты.

— Мин нишләргә тиеш, җизнәй — диде Былбыл, үзенең эшсез калуын күреп.

— Син балык җыеп торырсың,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Балыкны без җыябыз Фидәил белән!— диде Дездемона.

— Алайса мин су комларга барам!— диде Былбыл һәм, рөхсәт булганны да көтмәстән, якындагы керәндәс ягына йөгерде.

Анда ул аяк киемен салып куйды, як-ягына каранып һәм чак-чак кына оялып-уңайсызланып, өс киемнәрен салып ташлады, чәчен-башын, күкрәкчәсен төзәткәләде һәм Йосыф белән Илгиз артыннан йөгерде. Габделхәй аның биегәндәге сыман матур аяклары белән килешле йөгергәләп баруын арттан карап калды. Ул аның кояшта янган сылу беләкләрен, аркасын күрде, бүтән чакта чит күзләргә күрсәтелми торган барлык зифа буен күрде һәм сокландыргыч матурлыкка исе китеп, зиһене чуалып, шундук күзен читкә борды. Нишләптер Дәүләтгәрәй абзый аңа карап торадыр сыман тоелды. Ул тиз генә Дәүләтгәрәй абзый ягына күз салды, аның үзенә игътибар итмәвен күреп, яңадан Былбыл ягына борылды. Ләкин бу вакытта сихри күренеш инде юкка чыккан иде. Ул бары аның куаклар артыннан:

— Йосыф! Илгиз!— дип кычкырган шат тавышын гына ишетте.

Былбыл китеп барганнан соң Дәүләтгәрәй абзый беркадәр вакыт көтеп торды, тоныкъ су уртасыннан болыт сыман булып әкрен генә болганчык агым якынаеп килгәне күренгәч, «аллага тапшырдык»ны әйтеп, суга керде дә Габделхәйгә ым кагып:

— Әйдә, Габделхәй, башладык!— диде.

Габделхәй җылымның икенче башындагы шома агачны җайлап кулына тотты. Әкрен генә тартылган челтәрле җылым су эчендә күмелә барды. Дәүләтгәрәй абзый кулындагы җылым таягын ничек тә елга төбеннән шудырырга тырышып, һаман эчкәрәк, тирәнгәрәк керде. Су башта аның балтырына, тезенә җитте һәм туктаусыз күтәрелә барды. Дәүләтгәрәй абзыйның ак ыштанына кыстырып куелган күлмәк эченә һава тулды. Болай да олы гәүдәле ир кешенең аркасы мендәр сыман күпереп торды.

Яр читендәге вак ташларны, бакыргач кабыкларын шыштырдатып, себереп-өстерәтеп җылым койрыгы тәмам суга күмелгәч, Габделхәй дә суга керде һәм авыр җылымны агымга каршы тарта барып, әкрен генә атлап китте. Ул арада Дәүләтгәрәй абзый елганың уртасына җитте. Су өстеннән аның зур башы, киң кулбашлары, ара-тирә кулындагы җылым таягы гына күренде. Җылым тарту минут саен авырая барды. Дәүләтгәрәй абзый исә һаман тартуында булды һәм ничек тә икенче як ярга барып чыгарга, ничек тә елганы җылым белән иңләп, бүлеп алырга тырышты.

Габделхәй, аякларын комлы су төбенә терәп, әкрен генә алга таба хәрәкәтләнде. Чынлыкта бу алга табу бару да түгел, бары җылымны агымга каршы тигез итеп тотарга тырышу гына иде.

Нык тартылган җылым җәтмәсенә әледән-әле нәрсәләрдер килеп бәрелде. Габделхәйгә шулай зур-зур балыклар килеп бәреләдер сыман тоелды. Бу анда яңа көч һәм омтылыш тудырды. Ул туктаусыз җылымны, Дәүләтгәрәй абзыйны күзәтте, шул вакытта тал куаклары артындагы чырчуга да колак салды. Анда, куаклар артында, су өстендә Былбылның шат һәм дәртле тавышы ишетелеп-ишетелеп китте.

Дәүләтгәрәй абзый, елганың икенче як ярына барып чыккач, «булды бу» дигән сыман канәгать бер төс белән Габделхәй ягына карап алды. Габделхәй аның ни әйтергә теләгәнен чамалап алды һәм үзе тирәсендә бөтерелгән Фидәилгә пышылдап:

— Бар, йөгер тегеләр янына!— диде.

Шуны гына көтеп торган Фидәил, су чәчрәтә-чәчрәтә ургә таба йөгерде. Кычкырып, кулларын бутап аның артыннан Дездемона чапты. Күп тә

үтмәде, тал куаклары артыннан су комлатучылар килеп чыкты. Чыр-чу килеп, коточкыч шау-шу ясап, алар җылым тартучыларга таба якыная башладылар.

## XIII

Җылым тартучылар янына беренче булып Илгиз килеп җитте һәм җылым алдыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый янының йөзеп чыкмакчы булды. Ау барышын уяу күзәтеп торган Дәүләтгәрәй абзый, судан зур йодрыгын чыгарып, Илгизгә ачуланып алды. Бу аның җылым алдына керергә ярамый дигәнен аңлатты. Илгиз кирегә йөзеп, комлы ярга барып чыкты да, өстендәге суларын коеп, дөп-дөп басып, җылым артына төште. Илгиз артыннан ук диярлек яр буйлап ашыгып Былбыл килеп җитте.

— Мин нишләргә тиеш? Мин нишлим, җизнәй?—диде ул Дәүләтгәрәй абзыйга.

Ул шат иде, ул эшчән иде. Бу минутта ул шундый чибәр иде!

— Монда кил, монда!—диде Габделхәй.

Былбыл тиз арда Габделхәй янына килеп җитте һәм, аның кебек үк, җылым таягына тотынды.

— Баудан тарт!—диде аңа Габделхәй.

Җылым таягына койрык сыман итеп озын гына бау ялганган иде. Суда бүртеп тыгызланган бауны Былбыл ике куллап тотып алды да бар көченә тартырга тотынды. Теге якта Илгиз Дәүләтгәрәй абзый янына барып чыкты һәм шулай ук җылым таягына тагылган баудан тарта башлады. Бераздан Йосыф килеп җитте. Йосыф бауга тотыну белән, җылым тарту җиңеләеп китте. Шауламаска, Тавыш-мазар чыгармаска тырышып, дәртләнеп һәм бердәм булып алар үргә таба хәрәкәтләнделәр.

Дәүләтгәрәй абзый, кул селтәп, аларга туктарга кушты. Бу яктагылар туктагандай иткәч, үзе алгарак чыкты һәм әкрен генә елга уртасына таба борыла башлады.

Дәүләтгәрәй абзый таза иде, көчле иде, тик шулай да бөтен бер җылымны агымга каршы тартып бару аның үзенә генә авыррак иде. Йосыф әтисе белән Илгизне күзәтеп кенә барды һәм әтисенә авыр була башлагач та, агым уңаена йөзеп, Илгиз янына барып та җитте. Илгиз кулындагы бауны алар икәүләп тарта башладылар.

— Ашыкма! Күтәрмә! Төптәнрәк алып бар!—диде Дәүләтгәрәй абзый үзенең көчле һәм житез улын тыеп.

Шул ук вакытта Габделхәй дә ара-тирә боерыклар бирде:

— Ярга тартыгыз, ярга!

Бу вакытта инде алар елга уртасыннан узганнар һәм Габделхәйләр ягындагы комлы ярга якынлашып киләләр иде.

Шапыр-шопыр су чәчрәтеп, ярга иң элек Йосыф килеп чыкты.

— Ашыкма, ашыкма!—диде Дәүләтгәрәй абзый.

Менә ул үзе дә комлы ярга аяк басты. Болганчык су өстендә дугаланып тартылган зур чылтәр — җылым челтәре авызының моңарчы су астында булган аскы өлеше күренде. Җылым авызы җыела, кысыла барды һәм шул чакны «капчык» төбендә чәбәләнгән, тыпырчынган ялт-йолт килгән эреле-ваклы кушбашлар, чабаклар, алабугалар күренеп калды. Күптән көтелгән шул тере балыклары белән, су төбеннән эләгеп кергән яшел-йошел үләннәре, муртайган агач тамырлары һәм йодрык зурлыгыдай ташлары белән авырайган җылым тыгыз судан, агымнан котылып, арып-алҗып, кызу ком өстенә килеп җыгылды.

Җылым тартучылар, бауларын-таякларын бер читкә ташлап, барысы берьюлы диярлек балыкка ябырылдылар. Дәүләтгәрәй абзый җылымга бер күз карашы ташлап кына алды — күпме нәрсә кергәнен болай гына чамалады да канәгать төс белән читкә китеп барды. Балык җыюны тулысынча яшьләргә тапшырды. Бу эштә тәҗрибәлерәк кеше буларак, Йосыф җылым-

ның авыр таш бәйләнгән төбеннән ике куллап тотып, балыкларны, чүп-чарны җир өстенә селекте. Комлыкка эре-эре кушбашлар, алабуга, чабаклар белән бергә вак көсләр, ташбашлар коелды. Фидаил белән Дездемона, кызык итеп, иң элек вак балыкларны җыя башладылар.

— Аларын суга җибәрегез, суга!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Балыклар, койрыклары белән җиргә бәреп, югары сикерделәр һәм ничек тә суга төшеп котылмакчы булдылар. Балык күрү белән кыргый дәрт һәм аучылык омтылышы уянган адәм балалары елтыр тәнле юеш балыкларны тимер бидерәгә тутыра тордылар.

Бераз хәл җыйгач, Дәүләтгәрәй абзый икенче мәртәбә сөзеп карамакчы булды һәм җылымның бер башыннан өстерәп яңадан суга кереп китте. Җылымның икенче башыннан Йосыф белән Габделхәй килеп тотты. Аларның шулай мыштым гына дигәндәй яңадан суга кереп барулырын күреп, янә Былбыл килеп җитте.

— Мин нишлим, җизнәй? Миңа ни эш кушасың?— диде.

— Син, Былбыл, бидерәдәге балыкны саклап тор,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Искәндәр белән Фидаил балык куркытырга дип үргә йөгерделәр.

Балыкчылар бу юлы озак булашмадылар, тиз арада җылымнарын тартып чыгардылар. Монысында балык бөтенләй диярлек эләкмәде. Җәтмә төбеннән бер бәләкәй шукә белән бер алабуга гына чыкты. Дәүләтгәрәй абзый ерактан балык оясы булып тоелган тирәнрәк, аулаграк төшне дә сөзеп карамакчы булды. Сөзүен сөзделәр, ләкин балык инде киткән иде. Өченче мәртәбә җылымга берни эләкмәде. Моның шулай булырга тиешлеген Дәүләтгәрәй абзый үзе дә белә иде, әлбәттә. Тик әле булса күңеле тынычланып җитмәгән иде бугай. Хәзер инде аның, балык тотудан бигрәк, балык эләкмәвен күреп тынычланасы килә иде бугай.

— Җитеп торыр, балалар. Комсызлыкның да чиге була,— диде ул нәтиҗә ясап.

Шуннан соң алар җылымны өстерәп читкә, тигезрәк җиргә алып чыктылар. Койрыгыннан күтәреп, төбендәге чүп-чарны койдылар да печәне чабылган җир өстенә кибәргә җәеп куйдылар. Дәүләтгәрәй абзый малайларны утынга җибәрде, үзе керәндәс төбендәге балтасын алып учакка таган әзерләргә тотынды. Таганны җайлагач, балык чистартучы Былбыл янына килде.

— Буламы, Былбыл?— диде.

— Була, җизнәй!— диде Былбыл.

Ләкин тәҗрибәле җизнәй ничегрәк «булганын» шундук чамалап алды һәм, су буена чүгәләп, балык чистартышырга тотынды. Малайлар күп итеп утын алып килделәр, утыннарын булачак учак янына өеп ташладылар да, үзләре су керергә йөгерделәр. Былбыл аларның җыйнаулашып килүен күреп-ишетеп торды. Малайлар су керә башлагач, күзенә төшкән чәчләрен төзәткәләп, алар ягына карап-карап алды.

— Ярар, калганын үзем карармын, Былбыл,— диде Дәүләтгәрәй абзый аның тынычсызлануын күреп.

Балыкны чистартып бетермичә китеп бару Былбылга уңайсызрак тоелды, ахрысы.

— Мин нишлим соң, җизнәй?— диде ул гадәтенчә.

— Су керә тор,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Былбыл су керергә китәргәмә-юкмы дигәндәй икеләнебрәк торганда, алар янына йөгереп малайлар килде.

— Дәүләтгәрәй абый, атны коендырыйк әле?— диде Илгиз.

— Коендырыгыз. Шушы тирәдә генә,— диде Дәүләтгәрәй абзый рөхсәт итеп.

Илгиздән чак кына калышып, алар янына Габделхәй дә килеп җитте. Дәүләтгәрәй абзыйның сүзләрен ишетү белән ул:

— Мин — беренче!— дип кычкырып җибәрде.

— Мин — икенче!— диде Фидаил, бәләкәй абыйсыннан уздырып.

— Мин — өченче! — диде Былбыл.

Илгиз дә, аннан арттанрак килгән Йосыф та берни әйтә алмый калдылар. Бүтәннәр исләренә өлгергәнче, Габделхәй болынга ат янына йөгерде, аның артыннан малайлар иярде, Былбыл иярде. Алар килеп җиткәнче, бәхетле Габделхәй ат янына якынлашты, кыюланып, шулай да ипләп кенә, сакланып кына аның муеныннан, күкрәгеннән сыйпалады, тәнендәге кигәвеннәрне куалады. Атның юашлыгын күреп, ул аның башыннан сыйпап, алды һәм шуның белән тиешенчә дуслашты да тезгенне чиште. Элегрәк җәй көннәрендә аның колхозда атлы эшкә дә йөргәне бар иде, атка атланып малайлар белән узышканы да бар иде. Биек ат сыртына ул элегрәк арбага фәләнгә басып атлана иде. Ләкин якында гына көнчел малайлар карап торганда, Былбыл карап торганда хәзер ул калку урын эзләп тора алмый иде инде — ике куллап ат сыртына тотынды да бар көченә югары ыргылды һәм атланып та алды.

Атка артык якын килмичә, малайлар Габделхәйне читтән генә күзәтеп тордылар. Алар аны су ягына китәр дип көттеләр һәм, ул атлангач та юл биреп, шундук читкә тайпылдылар. Ләкин Габделхәй болын ягына борылды һәм очынып, сөенеп, еракгагы әрәмәләр ягына элдерде. Малайлар аның артыннан кычкырып, шаулашып калдылар. Тавышлар ерагая башлау белән ул кире борылды һәм шатлыктан: «Әһә-әй!» — дип кычкыра-кычкыра, бүгә якынайды.

Малайлар аны яр буенда көтеп торалар иде.

— Атта бик шәп чабасың икән син, Габделхәй! — диде Былбыл мактап.

Бу минутта Габделхәйгә бүтән берни дә кирәкми иде. Ул җинүче, ул бәхетле иде. Су янында ул җиңел генә сикереп төште һәм эре генә:

— Кем икенче? — диде.

— Мин икенче! — диде Илгиз.

— Юк, мин! — диде Фидәил.

— Фидәил — икенче! — диде Былбыл да, Фидәилне яклап. — Син, Габделхәй, тәртипне бозма, без бит кычкырдык инде.

— Дөрес, кычкырдык, — диде Габделхәй. — Хәзер Фидәил, аннан — Былбыл.

— Хәзер — мин, хәзер — мин! — диде Фидәил һәм сул аягы белән тезгенгә басып, үрмәләп диярлек ат сыртына менеп китте.

Габделхәй аңа арттан булышып торды. Фидәилнең дә олы абыйсы кебек болын ягыннан һай-һайлап чабып киләсе килде. Ләкин шул чакны Дәүләтгәрәй абзыйның тавышы ишетелде.

— Атны интектермәгез, балалар, — диде ул. — Суда гына җөртегез.

— Ярар, ярар, Дәүләтгәрәй абый, — диде Габделхәй, атны су ягына борып.

— Җибәр! Мин үзем! — диде Фидәил атка атланып алгач та.

Абый кеше аның кычкыруын колагына да элмәде. Йосыфның читтә булуыннан файдаланып, ул үзен атның тулы хуҗасы итеп тойды. Җитәкләгән килеш атны ул бераз су эчендә йөртте дә Фидәилгә төшәргә кушты. Фидәил карышты, аяк-кулларын селтәде. Габделхәй сүз тыңламас энесен аттан тартып төшермәкче булган иде, малай чәрелдәп кычкырырга тотынды.

— Ярар, утыр шунда кичкә кадәр, — диде абый кеше.

Ачуланып, ул энесенә су сибәргә тотынды. Шуны гына көтеп торган кебек, көлә-көлә Дездемона да Фидәилгә су сибәргә керешге.

— Атка да сибегез, атка да! — дип кычкырды Габделхәй.

Барысы да төрле яктан су сибәргә тотындылар.

Башкаларга караганда үзен остарак, тәҗрибәлерәк санап, Габделхәй атның әле бер ягына чыкты, әле икенче ягына чыкты, аның әле янбашын, әле күкрәген юды. Башкалар да аннан күрмәкче атны юындырырга, сыларга-сыйпарга тотындылар. Агымга каршы күкрәген куеп, елга уртасындарак басып торган кара бия үзе тирәсендә чырчу килүчеләргә карангалап, колакларын шомартып, чиксез рәхәтлеккә бирелеп тик торды.

Ат белән мавыккан арада Фидаилгә беркем игътибар итмәде. Ат өстендә тик утыру аның үзенә дә күңелсез була башлады, ахрысы. Артык шауламыйча, шыпырт кына шуып төште дә башкалар кебек су сибәргә кереште. Шуны гына көтеп торган Габделхәй Былбылга ым какты.

— Әйдә, атлан!— диде.

— Ничек атланырга соң моңа?— диде Былбыл, атның кай җиренә тотынырга да белмичә.

— Менә шулай ике куллап җилкәсенә тотын,— диде Габделхәй өйрәтеп.— Аягың белән минем кулга бас.

Өйрәткәнчә, Былбыл атның калку җилкәсенә тотынды, сул аягы белән Габделхәйнең уң кулына басты да бар көченә талпынып җибәрде. Габделхәй аны табаныннан тотып югары күтәргәндәй итте. Былбыл атка шактый җиңел атланды. Ләкин аның атлануы үзенчә булды. Ике аягын да атның сул ягында калдырып, ул атның биленә җайлап утырды да сөенечтән көлеп җибәрде.

— Нык тотын. Ике куллап тотын,— диде Габделхәй.

Атның алдына чыгып, ул әкрен генә кузгалып китте. Куркыпмы, шатлыныпмы, Былбыл җиңелчә генә кычкырып җибәрде. Шундук бер яктан Йосыф, икенче яктан Илгиз килеп җитте. Су эченнән бара торгач, утырган урынында Былбыл җайлаша төште, тезгенне үз кулына алды да, кыюланып:

— Җибәрегез, җибәр! Үзем!— дип кычкыра башлады.

«Үзем икән, үзем»,— дип уйлады Габделхәй һәм йөгәнне ычкындырып читкәрәк чыкты. Шул чакны ул Фидаилнең ат койрыгына тагылып, арттан йөзеп килүен күреп алды.

— Борыл! Ярга таба борыл!— дип кычкырды ул Былбылга.

Былбыл көлә-көлә һаман эчкәрәк, тирәнгәрәк керә барды. Фидаил яхшы йөзә белми иде. Абый кеше Фидаилне ат койрыгыннан куалап җибәрмәкче булды. Фидаилнең чәрелдек тавышын ишетеп барысы да артларына борылып карадылар.

Малайлар Фидаил тирәсендә ыгы-зыгы килгәндә Былбыл ат өстеннән шуып төште дә суга чумып юк та булды. Күпмедер вакыттан соң ул су астыннан килеп чыкты, башын калкытты, битендәге суны сыпырып төшерде һәм Габделхәйне күреп елмайды да, «әйдә, ку!» дигән сыман кул болгады.

## XIV

Былбыл үргә, ауган агачлар ягына йөзде. Анда никтер бик куркыныч сыман иде. Тирәндә, су төбендә ауган, егылган агачлар арасында ниндидер ят һәм куркыныч нәрсәләр бардыр кебек иде. Былбылның берни уйламыйча нәкъ шул якка таба йөзеп баруы Габделхәйне шомландырып куйды. Аннан соң ул аны ерак йөзә алмас, хәлсезләнер дип тә уйлады. Былбылда исә бернинди хәлсезлек галәмәте сизелмәде — ул бик тиз һәм тигез йөзде. Габделхәй, никадәр кызу йөзмәсен, һич тә аңа якыная алмады.

Тиздән Былбыл ауган агачлар турысына җитте, ауган агачларны узып китте. Габделхәй исә һаман арттан өстерәлде. Алда икенче төрле ярлар, икенче төрле күренешләр ачылды. Уң якта куе таллык башланды, сул якта язгы ташудан соң утырып калган озынча комлыклар күренде.

Комлы ярга кадәр ничек тә куып җитмәкче булып, Габделхәй бар көченә йөзәргә тотынды. Бер мәлне ул кызга шактый якынаеп калды. Былбыл артына борылып, күреп алды һәм үчекләшкән сыман:

— Ник каласың? Калма!— дип кычкырды.

Габделхәйгә агым бу турыда көчлерәк сыман тоелды. Шулай да ул, бөтен көчен эшкә җигеп, алга ыргылды. Ара бераз кыскара төште.

— Җитәм, барыбер җитәм!— диде ул җилкенеп.

Былбыл көлде, чалкан әйләнде дә, матур беләкләрен алмаш-тилмәш хәрәкәтләндереп, бернинди көчәнүсез диярлек кызулый башлады. Габделхәйнең эче жу итеп китте — ул үзенең алай ук кызу йөзә алмаганлыгын танырга мәҗбүр булды.

— Туктале! Мин сине!— диде ул ерагая барган кызга янаган булып.

Ләкин аның тавышы бик көчсез булып чыкты, хәтта үзенә дә ныклап ишетелмәде. Ара ерагайганнан-ерагайды. Габделхәй хурлыклы рәвештә артка кала барды. «Юкка бәйләндем»,— дип уйлады ул пошынып. Аның хәзер кызны куып җитәргә дә, барысына кул селтәп кире китәргә дә көченнән килмәде. Кояшлы көн кинәт караңгыланып калды, яр буендагы таллыклар, комлыклар күренмәс булды.

Шул чакны ул Былбылның сулга — елганың уң як ярына борылуын күреп алды. Менә ул сай җиргә җитте, су төбенә басты да елмаеп Габделхәй ягына карады. Аның шундый эчкерсез елмаюын күрү белән судан килеп чыккан тере балык сыман, әкияттәге су кызы сыман елкылдап, нур чәчеп торган сылу тәнен күрү белән, искиткеч бер могҗиза булып яшь җегетне яңадан көч-куәт һәм омтылыш биләп алды. Үзенең котылуына сөенеп, ул шулай ук ярга таба борылды.

Комлыктан читтәрәк, арырак тал куаклары күпереп утыра иде. Яр буе тын һәм аулак иде. Түбәндә, ауган агачлардан арырак, ат коендыручыларның чыр-чуы ишетелә дә, баш өстендә очып йөргән ялгыз акчарлакның «чичи» дигән борчулы тавышы ишетелә иде. Монда аның оясы, ояда бала чыгарырга утырган дусты бар иде бугай. Югарыдарак, тоташ яшел урман белән капланган калкулык өстендә, төшлеккә якынлашып килүче кояш кыздыра иде.

Былбыл сай җирдә беравык басып торды. Габделхәйнең дә ярга борылуын күреп, коры җиргә чыкты һәм беркем аягы басмаган чиста ком өстенә ауды.

— Уф, арыдым!— диде ул якында, үзе янында Габделхәйне күреп. Аннан соң, үзенең аннан яхшырак йөзүе өчен гафу үтенгән сыман һәм шул ук вакытта бераз гына мактанасы килеп, әйтеп куйды:

— Мин бит Агыйделдә үскән,— диде.

Габделхәй аның сүзләренә бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Арып хәлсезләнеп ул да комга ауды. Былбылның сул ягына, бик якынга ауды һәм үзенең ни сөйләгәнен үзе дә рәтләп аңламастан:

— Әһә, тоттыммы?!— диде.

Былбыл комда йөзтүбән капланып ята иде. Авырайган юеш беләген Габделхәй тупас кына кыланып, кызның батынкы биленә салды. Кыз тынып калды. Аның шулай тынып калуын аңсыз бала үзенчә юрап әле генә сихри сыман тоелган батынкы, тыгыз билне үзенә таба якынайтмакчы булды. Мондый көтелмәгән әдәпсезлектән кыз аптырап калды, башын калкытты, торып утырды һәм тырма кебек авыр, җансыз кулга сугып җибәрде.

— Кагылма миңа!— диде ул усалланып.

Аңсыз баланың оятлы йөзенә кинәт кан бәрде. Ул үзен хурланган итеп тә, хаталанган итеп тә тойды. Беркадәр вакыт йөзтүбән капланып ятты да, үкенү сыман бер нәрсә тоеп, хатасын уенга әйләндермәкче булып, былагайланып кызның юеш тәненә кайнар ком сипте. Ләкин эш узган иде инде — кырылган күңелне ком сибеп кенә төзәтеп, хатаны уенга әйләндереп булырлык түгел иде.

Былбыл атылып аягына басты һәм берни әйтмичә, горур төстә, дошманнарча үпкәләгән сыман читкә китеп барды. Габделхәй, оятлы йөзен кая куярга белмичә, кайнар комга капланды. Шулай да кырын күз белән генә ул чибәр кызның яртылаш комга буялган матур аякларын, комлы үкчәләрен, сары җирлеккә кызыл чияләр төшерелгән тыгыз тукымадан тегелгән һәм сылу тәнне йомырылап кысып торган тар, кыска киемен, күкрәкчәсен күреп калды. Ул аның яр буендагы компарны шыштырдатып атлавын, аннары суга керүен, йөзеп китүен ишетеп ятты.

Аяз күктә кояш көлде, елга өстендә «чи-чи» килеп акчарлак көлде, комлы ярны, таллыкларны юып, көлә-көлә серле Буә акты. Мәсхәрәгә калган малай-җегет берни тоймады, берни сизмәде. Аның өчен бөтен нәрсә юкка чыкты. Әйтерсең, ул бар дөньядан аерылгандай булды. Дөресрәге, якты дөнья, тере дөнья исәрмәстән аннан баш тартты. Бер нәрсәнең кызыгы,

мәгънәсе калмады. Күкрәгеп дә авырттырып, ачыттырып бары оят һәм хурлык кына торып калды.

Шулай онытылып ята торгач, мәңге үлмәс мин-минлек кинәт башын калкытты. «Китсен!» Бик кирәге бар иде!» — дип уйлады ул, пычракка салып тапталган дәрәҗәсен акламакчы булып.

Китсен! Китә бирсен! Кем соң ул шулкадәр? Бер дә әллә кем түгел әле. Бер кыланчык шунда. Ул киткәннән дөнья җимерелмәс. Кайтып китсен үзенең Уфасына. Бүген үк китсен — ул киткәч, ичмасам тынычлап яшәргә булыр.

Йөзтүбән капланып, ул озак ятты. Кымшанмыйча, кузгалмыйча ятты. Берзаман аның күңеленә: «Югалтырлар, борчылырлар, шикләнерләр»,— дигән уй килде. Аннан соң үтереп ашыйсы да килә башлады. Күрәсең, төш җиткәндер.

Тукмап ташлагандай хәлсез тәнен көчкә күтәреп, ул аягына басты, суга керде, тәнендәге комнарын сыпырып төшерде дә чумып алды. Баштан аяк бөтен тәнендә шифалы суның иркәләвен тойгач, аңа бераз җиңел булып китте. Аның килгән юл белән кайтасы килмәде. Нишләптер ул анда — бая гына китеп барган яр буенда малайларны йә булмаса Уфа кызын очратыр сыман тоелды. Аның хәзер беркем белән очрашасы килмәде. Ут туп-туры Бүәнең икенче ягына чыкты, таллык җырып яр өстенә менде һәм шәрә тәнен ботак-сатакка, каты үлән сабакларына сыдырттырып, әрәмәлек арасыннан китеп барды.

Ул ашыкмады, шулай да туктап та тора алмады. Аны хәзер кемдер әйдәп, җитәкләп алып бара сыман тоелды. Яр буенда, ат коендырган төштә һаман тавышлар ишетелде. Шул тавышлар арасыннан Габделхәй үзе өчен хәзер чит булган, дошман булган теге кызның тавышын тотып алмакчы булды. Анда аның тавышы ишетелмәде. Аның борынына кинәт төтен исе килеп бәрелде. Барган юлыннан чак кына уңга каерылып, ул туры учакка таба атлады.

Учакка җитәр-җитмәс, якында гына, куе шомырт куаклары артында кемнәрнеңдер әкрен генә сөйләшеп утыруларын ишетеп, ул туктап калды. Куак артында сөйләшеп утыручылар баштарак кына аңа «кемнәрдер» булып тоелды. Аларның кемнәр булуын ул бик тиз аңлап алды. Ләкин әлеге «кемнәр», бик аңлаешлы сүзләр сөйләсәләр дә, шулай да аларның кем, нәрсә турында сөйләшкәннәрен тиз генә төшенеп җитә алмады. Сүз арасында ул үзе өчен барлык сүзләрдән якынрак «Габделхәй» дигәнне ишетеп калды. Аның шундук колагы үрә торды.

«Габделхәй»не инәсе әйтте. Ул аны бик нык кайгырып-борчылып әйтте. Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа ни өчендер аны юатырга, нindidер ышанмастай нәрсәгә ышандырырга тырышалар сыман тоелды.

Инәсе тормышның авырлыгыннан зарланды. «Котдус исән булса»... — диде дә төртелеп туктап калды. Аның тавышында күз яше сизелгәндәй булды.

— Исән булырга да мөмкин, Шәмсебанат,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Сугыш бит ул!..

Габделхәй шуннан башкасын ишетмәде. Олыларга күренәсе килмичә, ул артына чигенде, читкәрәк китте. Инәсенең тормыш авырлыгы турында, аттай өч малайны, өч тамакны туйдырырга, аларның өстен-башын карарга кирәклек турында Фәрхәнә апалар, Дәүләтгәрәй абзыйлар белән сөйләшеп утыруында бернинди яңалык юк иде. Әтисе Котдусны искә төшерүендә дә бернинди яңалык юк иде. Бик нык кайгырган, борчылган чакларында ул һәрвакыт диярлек шундыйрак сүзләр сөйли. Әледән-әле үзенең Котдусын искә төшерә, бергә булган чакларын, кайчандыр бик күптән әйткән сүзләрен кабатлый. Элегрәк мондый искә төшерүләр, күз яше агызып алулар еш кабатлана иде. Пособие мәсьәләсендә военкоматка барып кайткannan соң инәсенең кайбер сүзләреннән Габделхәй шуны аңлады: Котдус Мөхетдинов үлмәгән. Ул, ахрысы, теге якка качып киткән. Әлегә бу бик үк билгеле түгел, шулай да тикшерелә, дигәннәр бугай военкоматта. Үлгәнме,

качканмы икәнлеге ачыкланганчы, пособие тукталып тора, дигәннәр, ахрысы, аңа.

Әнә алар шул турыда сөйләшеп утыралар. Ничектер сагаеп, шомланып һәм серле итеп сөйләшеп утыралар. «Исән булырга да мөмкин...» Ничә ел инде алар аның шулай исән булырга да мөмкин булуына ышанып яшиләр! Шул ук сүзләрне аларга теләсә кем әйтә. Теләсә кем генә түгел, Дәүләтгәрәй абзый да әйтә. Әллә соң ул аның кайдалыгын белә микән? Исән булса, кайда булыр аның... аларның әтиләре? Гаҗәп. Исән булса, көтмәгәндә кайтып төшсә, нинди шәп булыр иде! Бу турыда уйлавы да куркыныч. Бу шундый зур һәм серле нәрсә. Исән булса... Исән булган кеше үзенең балалары янына, хатыны янына, үзенең иленә, өенә кайтырга тиештер ич инде... Сугышка чаклы, сугыш вакытында кайда гына, кем генә булуына да карамастан, үз җиренә кайтырга тиештер ич?!



## XV

Чигенә барып, ул яңадан Буә ярына барып чыкты. Комга утырды, суга керергә дә, кермәскә дә белмичә, күрмәс күзләре белән уйга калды.

Бер заман ул якында гына үзен эзләүчеләрне ишетеп алды.

— Абый!— дип кычкырды куак артыннан Илгиз.

Шулай кычкырып, ул ары китеп барды. Габделхәйнең һаман үтереп ашыйсы килде.

— Абый!— дип кычкырды тагын икенче яктанрак Илгиз.

— Ни булды, ник кычкырасың?—диде абый кеше тавыш биреп.

— Кая булдың, нишләп йөрисең?—диде Илгиз абыйсы янына килеп.

— Йоклап киткәнмен,—диде Габделхәй ялганлап.

Икәүләп алар учак янына килделәр. Табынны ялгыз карама төбенә, күләгәле җиргә әзерләгәннәр иде. Барысы да чабылган болын өстенә җәелгән киң ашаулык тирәсенә түгәрәкләнеп утырганнар да, кемнедер көтәләр иде сыман. Йосыф белән Фидаил янында Габделхәйгә урын калдырылган иде. Ул туры шунда барып утырды. Уфа кызы Йосыфның икенче ягында утыра иде. Габделхәй аның ягына карамаска тырышты һәм килеп утыру белән, аны-моны сораштырмыйча, кашыкка тотынды.

Ашаганда беркем игътибар итмәде. Аякларын читкәрәк сузып җибәреп, табынга ничектер яны беләнрәк утырган Фәрханә апа гына беркадәр вакыттан соң:

— Нишләптер безнең Габделхәй тынып калган әле,—диде.

Барысы да Габделхәй ягына борылып карадылар.

— Балык ашаганда сөйләшергә ярамый — балык кача,—диде Габделхәй.

— Ашаганда качмый инде ул!—диде Дездемона.

— Төшереп җибәрсәң кача,—диде Фидаил.

— Габделхәй дөрес әйтә, балалар, ашаганда сөйләшергә ярамый,—диде Дәүләтгәрәй абзый.—Ашаганда сөйләшсәң, ач каласың.

Балык шулпасы тәмле булды. Изелеп пешкән балык үзе шулпадан да тәмлерәк булды. Ашап туйгач, корымланган бидерәне су буена алып төшеп, ком белән ышкып юдылар да учакка чәй кайнатырга куйдылар. Кара карагат яфрагы, мәтрүшкә салып кайнатылган чәй дә бик тәмле булды. Чәй эчәр алдыннан Фәрханә апа һәркемгә үзләре җыеп алып килгән җиләктән, карагаттан өлеш чыгарды. Дәүләтгәрәй абзый исә киндер чүпрәккә төрелгән бер бөтен ипине кулына алды да үткер чалгы пычагы белән кисәргә әзерләнде.

— Кибән башы — үземә!—диде Дездемона.

— Юк, миңа!—диде Фидаил.

— Мин элек әйттем — үземә!—диде Дездемона.

— Син көн дә ашыйсыңдыр әле кибән башын,—диде Фидаил, үпкәләп.

Табын янында уңайсыз тынлык урнашты. Шәмсебанат апаның йөзе кызганыч булып үзгәреп китте.

— И улым!...— диде ул кече улын шелтәлисе килеп, ләкин аның шелтәсе шелтә булып түгел, әрнү булып ишетелде.

Габделхәй энесенең кабыргасына төртеп алды. Хәтере калып, Фидәил җыларга ук кереште.

— Солдат кеше җылап тормый инде ул, Фидәил,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Солдат кеше җылап торса, нимес аны ата да үтерә.

Фидәил шып булды. Өлкәннәр бер-берсенә карашып алдылар. Дәүләтгәрәй абзый кулындагы ипине тәгәрмәч кебек итеп әйләндергәләде дә, Фидәил белән Дездемонага карап:

— Мин кычкыртмадым. Сез кычкырткан дөрес түгел. Кемгә элек?— диде. Соңгы сүзен ул кисәк кенә әйтте һәм аның «кемгә элек» дигәне «кемгәлек» булып ишетелде.

— Миәлек!— диде солдат буласы Фидәил.

— Миәлек!— диде Дездемона да, арткарак калып.

Үзен алдаганнарын ул күреп торды, аның да хәтере калды, ләкин әтисенең сүзенә каршы килергә, үпкәләргә, җыларга шулай да кыюлыгы җитмәде.

— Беренче кибән башын — Фидәилгә!— диде Дәүләтгәрәй абзый, түгәрәк ипинең бер кырыен кисеп алып.— Икенче кибән башы — Дездекәйгә!

Дәүләтгәрәй абзый түгәрәк ипинең икенче кырыен да кисеп алды да кибән башны кызына бирде. Дездекәй яшь аралаш елмаеп җибәрде. Балаларның куанычын күреп, олылар җиңел сулап куйдылар.

Чәй эчеп бераз ял итеп алгач, хатын-кызлар табак-савытларны җыештыра башладылар һәм барысын да тагын су буена алып төшеп, шалтыр-шолтыр китереп, юарга, ышкырга тотындылар. Эшләре беткәч, Шәмсебанат апа белән Фәрхәнә апа, буш бидерәләрен күтәреп, яңадан әрәмәләр ягына китеп бардылар.

Ул арада кояш, төшлекне узып, баю ягына авышты. Көн сүрелә, күләгәләр озыная һәм икенче якка күчено башлады. Кичке якта Дәүләтгәрәй абзый тагын бер мәртәбә җылым салып карамакчы булды. Бу юлы су комлатучылар да, җылым тартучылар да, тук булганга, күрәсең, артык тырышмыйча гына, эленке-салынкы гына кыландылар. Шулай да балык кермәде түгел, керде. Дәүләтгәрәй абзыйның тәмам күңеле булды. Гадәтенчә, ул вак балыкларны алып тормады — биш-алты эре кушбаш белән алабуганы, бер-ике шүкәне алды да, калган барысын суга койды.

— Икенче килүгә үсеп торыгыз!— диде коелган балыклар артыннан.

Күләгәләр озынайганнан-озынайды. Тирә-якта су исе, яшел үлән, тал исе килә башлады. Күләгәле җирләрдә генә түгел, ачык, кояшлы җирдә дә чебен-черки күбәйде. Су өстеннән куышып, узышып энә караклары очты, елганың әле бер төшеннән, әле икенче төшеннән чулт-чулт итеп көмеш балыклар сикерде.

Дәүләтгәрәй абзый өйгә алып кайтасы балыкларны, юеш печәнгә төреп, капчыкка салды да, яхшылап кераңдәс төбенә урнаштырды. Шуннан соң кибәргә җәеп куйган җылымны селеккәләп, яңадан чүп-чардан чистартты һәм җайлап кына җыя башлады.

— Бар әле, тегеләрне чакырып кил,— диде ул үзе янында булашкан Иосыфка.

Иосыф кузгалып китәргә өлгергәнче, «тегеләр»нең үзара сөйләнеп, су буена таба кайтып килүләре күренде. Ләкин алар туры кәрәндәс янына килмәделәр, кыеклатып елга буена төштеләр дә, башларындагы яулыкларын салып, битләрен-кулларын юдылар.

— Бүә буйга килеп су да кереп булмады инде,— Фәрхәнә апа үкенгәндәй итеп.

— Керегез. Тиз булыгыз,— диде Дәүләтгәрәй абзый, аларның сөйләшүен ишетеп.

— Әйдәле, Шәмсебанат,— диде Фәрхәнә апа тәвәккәлләп.— Су да кермичә китсәң, гөнаһлы булырсың.

— Әйдә алайса,— диде Шәмсебанат апа.

Алар комлы яр буйлап түбәнгәрәк китеп бардылар.

— Мин дә сезнең белән барам!— диде Дездемона.

— Мин дә!— диде Былбыл.

Хатын-кызлар су керергә китеп баргач, ир затындагылар юлга әзерләнә башладылар. Бер ярты сәгатьтән бөтенесе әзер булды — ат җигелде, су керүчеләр кире килделәр. Фәрхәнә апа белән Шәмсебанат апа парлашып кәрендәскә утырдылар, алар арасына Дездемона кысылды. Йосыф дилбегә тотып, ат башына утырды. Калганнар җәяүләп арттан кайтырга тиешләр иде. Ат кузгалып китәр алдыннан гына Былбыл кәрендәс артына, җылым янына килеп утырды.

— Мин монда кайтам,— диде ул.

— Син... кайтасыңмыни?— диде Фәрхәнә апа, артына борылып, гаҗәпләнеп.

— Кайтам,— диде Былбыл.

— Мин дә утырам,— диде Фидаил дә, Дездемона сыман инәсе янына елышмакчы булып.

— Алайса, болай итик,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Син, Фәрхәнә, ат тотарсың. Йосыф үз урынына артка утырыр, аның урынына Былбылны утыртырбыз да... Фидаил дә утырыр.

— Алай итмик, әти,— диде Йосыф.— Кичүне чыгарып куйыйк та, әниләр үзләре кайтып китсеннәр. Иң кыены кичү. Без җәяүләп кайтырбыз.

— Дөрес, улым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Урык-сурык ат интектереп йөрисе юк.

— Әйдә, алайса, ат башына утыр,— диде Фәрхәнә апа Былбылга эндәшеп.

— Ярар инде, кичүгә кадәр шушында гына барырмын,— диде Былбыл теләр-теләмәс кенә.

Фәрхәнә апа кысташып тормады, алдына борылды да, дилбегәне селтәп җибәрде. Коне буе ашап ял итеп коч җыйган кара бия җиңел генә кузгалып китте.

— Кичүдә безне көтеп торыгыз!— дип кычкырды Йосыф.

— Көтәрбез, көтәрбез!— диде бәхетле Фидаил, кул болгап.

— Көтәрбез, көтәрбез!— диде Дездемона да.

## Дүртенче бүлек

### I

Онытыла язган күңелсез нәрсә, ойгә кайткач, яңадан искә төште — каны саркып торган чи яра булып, ачыттырып сызлый башлады. Бүтән вакытта читтән кайтып кергәч һәр почмагы, һәр чүпрәге шундый кадерле булып тоела торган җылы ой эче Габделхәйгә бүген көтсез булып күренде. Бу кыйсан, тәбәнәк һәм ярлы ойдә аның бер минут торасы килмәде. «Авылга китәргә кирәк. Картыйларга, картәтәйләргә!» — дип уйлады ул, тормышка ашмастай нәрсә турында хыялланган кебек. Аңа хәзер киңлек, иркенлек һәм җирдәге оҗмах бары анда гына сыман тоелды.

Ләкин хәзер вакыт соң инде, хәзер генә берничек тә авылга китеп барып булырлык түгел иде. Үз-үзенә урын таба алмыйча, ул урамга чыкты һәм станция ягына китеп барды. Анда яктырак, күңеллерәк. Анда авылдагы кебек киңлек-иркенлек юк, ләкин анда һәрвакыт хәрәкәт сизелә. Әле бер яктан, әле икенче яктан дөбердәп поездлар килә. Вагоннарга, әчкелтем ят исләргә, ят кыяфәтле кешеләргә ияреп ниндидер башка илләрнең-җирләрнең бу як тагы караңгылыкка, тарлыкка охшамаган дәртле рухы, омтылышы килә. Үзеннән-үзе аларга ияреп, вагоннарга тагылып-тотынып китәсе, алар күргән киңлекләрне, иркенлекне һәм бәхет илен күрәсе килә.

Ләкин бүген хәтта монда да Габделхәйгә әллә ни күңелле булып тоелмады. Пассажир поезды килергә әле иртә иде, станциядә — читтәге юлларда арыган-алҗыган кыяфәттә буш күмер вагоннары гына тезелеп торалар иде. Аннан соң тоныкк кына ут балкыган вокзалдагы кешеләр дә бүген нишләптер күңелсез һәм йончылган булып күренделәр. Балалары, капчыклары, төенчекләре белән озынча утыргычларда йокымсырап утырган кешеләрне күргәч, Габделхәй нишләптер Сәкинәне исенә төшерде. Сәкинә аңа хәзер бик-бик кызганыч булып тоелды. Бит алар очрашырга сүз куешканнар иде! Менә хәзер кинәт кенә, искәрмәстән генә очрашып куйсалар, нинди шәп булыр иде! Уфа кызына үч итеп, ачу итеп. Аларның Сәкинә белән икәүләшеп көлешә-көлешә узып киткәнен читтән күреп калса Уфа кызы, тагын да шәбрәк булыр иде. Икенче көлмәс, кыланчыкланмас. Борыны бик тиз салыныр иде! Шыт! Шул кирәк аңа. Монда килеп әллә кем булып йөрергә кем булган шул кадәр?!

Шулай үз алдына уйланып-хыялланып, ул караңгы урамнардан Сталин клубы ягына атлады. Анда инде кино башланган. Урам якта кинога керә алмый калган малай-шалай гына җыелып тора. Һаман шул «Иван Грозный»ны күрсәтәләр икән.

Габделхәйнең урысча кычкырып сөйләшкән татар малайлары янында туктап торасы килмәде. Ул туры үзләренең мәктәбе ягына китеп барды. Мәктәп тирәсен әйләнеп үтте дә кире үзләре ягына борылды.

«Сау бул инде, сау бул, мәктәп,— дип уйлады ул. Кабат монда килеп булмас. Килсәң дә, кызыгы булмастыр. Нинди кызганыч — күпме гомер шунда үтте, күпме шатлык-кайгы шушында туды. Сау бул, мәктәп. Тагын килеп булмаса, сау бул инде, кадерле мәктәп!

Икенче көнне, таң атып әтәчләр кычкыра башлау белән, ул уянып китте. Менә тагын яңа бер көн башланды. Инәсе эшкә иртүк китә иде. Янтыкка кайтып килү турында аның белән элегрәк тә сүз булган иде инде. Укуын бетергәч тә ул кайтып, андагыларның хәлен белеп килергә тиеш иде. Авыл турында әйткәч, инәсе сөенде генә. Тиз-тиз генә кучтәнәчен төйнәп бирде, анда кайткач кемгә нәрсә әйтергә кирәген исенә төшерде. Аннан соң әйтеп куйды: «Әллә Фидәилне дә аласыңмы үзең белән?» — диде. Габделхәйнең үзе генә барасы килде. Инәсе кыстап тормады, күп итеп сәлам әйтергә кушты да, эшенә китәргә ашыга башлады.

Янтыкка ике юл бара иде. Аның берсе әйләнгечтән — күпер аша, икенчесе турыдан — Сакат аша, карурман аша бара. Тау менә, тау төшә. Турыдан юл куркынычрак исәпләнелә. Элек-электән монда качаклар яткан, юлчыга юлбасарлар чыккан. Хәзер исә узган-барганны Яңавыл ышпанасы талый, дип сөйлиләр.

Габделхәй турыдан китте. Озак кына ул кичәге дымлы, караңгы юлдан барды һәм күпмедер вакыттан соң кояш яктысы төшкән кичү турысына барып җитте. Яр буенда комлыкта тояк эзләре, кәрендәс эзләре ярылып ята иде. Шунда ук аяк эзләре дә күренде. «Кем эзе булыр бу?» — диде ул җиңелчә хыялга бирелеп. Теге Уфа кызыныкы түгел микән? Юк, түгелдер. Табаны бик зур бу кешенең. Йосыфныкыдыр.

Кичәге күренешләрне яңадан искә төшереп тору Габделхәйгә йомшаклык, җебегәнлек булып тоелды, ләкин ул күренешләр — якты көн, елга, комлык һәм сихри гүзәллек аның күз алдыннан китмәде. Үзе дә сизмәстән, ул көрсенеп куйды. Өстендәге барлы-юклы киемнәрен салып, бергә җыеп төрде дә, инәсенең кучтәнәче белән бергә ике кулына да җайлап тотты да, анадан тума суга керде. Салкынча һава белән чагыштырганда су җылырак тоелды. Киемнәрен икенче як ярга чыгарып куйгач, кире килеп тирән җирендә чумып-чумып алды. Иртәнге суда коенгач, җиңел һәм рәхәт булып китте. Кичәдән бирле җанын игәп, күңелен тырнап торган уйлар кул белән алгандай юкка чыкты.

Кичүдән соң юл икегә бүленде — берсе аның кичәгенәк балык тотып ял итеп яткан болын ягына китте, икенчесе Сакат ягына борылды. Юл чатында Габделхәй киенде һәм судан. Бүәдән, кәрендәс эзләре батып калган яр буй-

ларыннан аерыласы килмәгәндәй, беравык артына борылып карап торды да, Сакат юлы белән китеп барды.

Юл буенда берән-сәрән юкәләр, балан, шомырт куаклары очрады. Анннары сөреп нарат утыртылган ачык җир башланды. Шуннан соң тоташ юкә урманы китте. Урман юлында, күләгә белән аралашып, кояш нурлары балкып-балкып алды. Агач башларында туктаусыз бал кортлары гүләп торды. Һавада исерткеч бал исе, кояш нуры һәм яшел яфрак исе аңкып торды. Урман юлы, уңга-сулга борылмыйча, әкрен генә югары үрмәләде.

Габделхәй ашыкмады. Әледән-әле агач башларына каранды, кошлар тавышына колак салды, бара торгач кинәт артына борылды да, кемнедер күрергә теләгән сыман, ботаклар арасыннан карап тора башлады. Анда... артта калган кичүгә якын җирдә, кичәгенәк балык тотып яткан яр буенда, чыннан да, кемдер торып калган сыман булып, «кемдер» һаман аны күзәтә сыман булып тоелды. Иң гаҗәбе шул: Габделхәй кебек ул да моңсу, ул да сагышлы сыман иде.

Тау өстенә менеп җиткәч, аяк атлавы җиңеләя төште. Урман сирәгәйде, юкә агачларын сарып алган баллы гүелдек тоныкланган сыман тоелды. Менә озакламый юкә урманы да бетте, юкә урманыннан соң берән-сәрән чикләвек куаклары очрап куйды. Чикләвек куаклары да артта калгач исә яздан бирле ат тоягы, арба тәгәрмәче күрмәгән тар юлның ике ягында да бодай басулары җәелеп китте. Бодай инде баш кыскан. Тигез, куе. Сизелер-сизелмәс кенә искән талгын җилдә туктаусыз тирбәлеп, чайкалып утыра. Нинди хозур, нинди күңелле!

Бодай җире ерак-еракларга сузылды. Баш өстендә тургайлар сайрады, юлда чыпчыклар чыр-чу килде. Кеше якынлашуын күреп, чырылдап, пырылдап, алар шундук көтүләре белән күтәрелеп киттеләр. Кайдадыр якында гына, бодай арасында, чалгы чарлаган сыман тавыш чыгарып тартар кычкырды. Ялан табаннарың белән кайнар җирне тою, күз алдында төпсез зәңгәр күкне күреп бару, шыштырдаган-кыштырдаган, безелдәгән һәр төрле тавышларны ишетеп бару күңелле, иситкеч күңелле һәм рәхәт иде.

Ләкин күңелле, рәхәт юл да озакламый арыта, ачыктыра башлады. Кул очындагы җиңел төенчек авырайганнан-авырайды. Барыннан да бигрәк, ашыйсы килде. Хәер, ашыйсы килүнең туганнан бирле бетеп торганы да булмады, ахрысы. Иртән ул үзләрендә берни капмады диярлек. Авылга барып җитсәм, туйганчы салкын катык белән кайнар бәрәңге ашармын, дип уйлады. Шул гадәти кечкенә уй тора-бара беркайчан тормышка ашмастай хыялга әйләнә башлады.

Күп тә үтмәде, еракта — Янтык ягында — зәңгәрсу рәшә диңгезе артында әкияттәге сыман бәләкәй генә, матур гына өйләр, бәрәңге бакчалары һәм күккә ашкан биек тупыллар күренде. Елның кайсы гына вакытында булмасын, һәрвакыт кайнар бәрәңге белән салкын катык ашый торган һәм шунлыктан дөньяда иң бәхетле исәпләнергә хакы булган кешеләр менә шунда яшәп яталар иде инде.

## II

Ерактан шундый матур һәм төзек булып, муллык, байлык һәм гүзәллек дөньясы булып тоелган Янтык якыная барган саен төссезләнә барды. Юлдан уң якта, авыл читендә «Алга» колхозының ат фермасы таралып ята. Ат фермасы басылып, тишелеп беткән салам түбәле бер-ике озын, тәбәнәк корылмадан, киртәләнеп алынган утарлардан һәм йөз еллык тирес-салам өемнәреннән гыйбарәт иде. Киртә буенда, тышкы якта колыннлы бия ашанып йөри дә, юл буенча Сакат ягыннан килүче ялгыз кешегә исе китеп, ала бозау карап тора иде.

Габделхәй җимерелеп, баганалары кыйшаеп беткән һәм атлы арба узып китәрлек кенә киңлектә ярты лаш ачып куелган капкадан авыл урамына килеп керде. Чын мәгънәсендә әле бу урам да түгел, бу бары бер тыкрык кына

иде. Кайчандыр биш-алты йорт балкып утырган тыкрыкта хәзер нибарысы бер йорт утырып калган иде. Тыкрыкның ике ягыннан да киртә сузыла; киртәнең урта бер җирендә, уң якта, ике баганалы иске капка караеп утыра, капка артында исә уртасы чокырланып торган иске өй урыны ырҗаеп ята иде. Ишегалды, дөресрәге, кайчандыр ишегалды булган ташландык җирдә, черек салам түбәле кәҗә абзарыннан, иске тирес, салам, чүп-чар өемнәреннән башка берни юк; бәрәңге бакчасын әрем, алабута күмеп киткән; өй артында шау чәчәктә утырган шомырт куагын талап, сындырып бетергәннәр.

Тыкрыктагы берданбер исән йорт та иске һәм тәбәнәк. Йортның кыйшайган түбәсе, маңгайга төшереп киелгән солдат пилоткасы шикелле, урам якка таба чөйлегебрәк тора. Әллә шунлыктан, әллә аскы ниргәләр җиргә батканлыктан, өй түбәсе өйнең үзеннән зуррак һәм биегрәк булып күренә. Ишегалдындагы каралты-кура төзек кенә, таза гына. Бакча ягында, аллы-гөлле мәк чичкәләре арасында, бер-ике умарта янында, бер башына авыр таш, тимер тәгәрмәч бәйләнгән сиртмәсен, һавада асылынып калган буш бидрәсен тотып, озын торыклы кое баганасы калкып утыра.

Төзек өйнең каршысында, тыкрыкның икенче ягында, шулай ук кое сиртмәсе утырып калган. Сиртмәнең бавын кисеп алганнар, сиртмә агачында як-якка каранып олы козгын утыра. Нәкъ әкият китапларындагы кебек. Юк, фашист гаскәрләре ватып-җимереп киткән украин, белорус авылларындагы кебек. Кинода, киножурналларда, газета-журналлардагы фотоларда аларны еш күрсәтәләр. Күрсәттеләр. Габделхәй аларны күп күрде. Кое сиртмәсе янындагы яртылаш җимерелгән мич калдыгы да, очы сынган ялгыз чыршы да — барысы да, барысы да сугыш елы киноларындагы, фотоларындагы кебек. Тик менә күккә күтәрелгән төтен баганалары күренми дә, җир өстендә аунап яткан мәетләр генә юк. Аннан соң автоматлы солдатлар да кайдадыр шул тирәдә генә качып яталардыр сыман.

Габделхәй, як-ягына карангалап, күңелсез тыкрыкны узып китте дә, тар елга аша салынган тишек-тошык күперне чыгып, олы урамга килеп керде. Үңда аны тагын бер ташландык йорт каршылады. Кайчандыр бай, купшы булган, хәзер инде тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән кадакланган, чолан такталары каерылып алынган бу нык, таза, ләкин үле йорт яныннан узганда Габделхәйнең күңелендә чиксез кызыксыну да, курку-шомлану да уяна торган иде. Бу турыдан ул тиз-тиз генә узып китмәкче булды һәм җансыз-өнсез, әмма каберлек сыман серле истәлекләр белән тулы тәрәзәләргә, кәрнизләргә озаклап карамаска тырышты. Шул ук вакытта карамыйча да булдыра алмады. Ташландык хәлендә дә бу йорт үзенә карата хөрмәт һәм соклану уята иде.

Элек бу Гали бай йорты булган, диләр. Гали бай заманында иген белән сату иткән, бөтен авыл халкын киендереп-туендырып торган. Анысы инде аның бушка туйдырмагандыр — монысын картый белән картәтәй генә әйтә. Алар гел элеккене мактап сөйләргә яраталар. Гали бай көз көне халыктан очсызга ашлык сатып алган да, кыш көне шул ук ашлыкны Сарапулга, Илдиәнгә илтеп саткан. Бер ачлык елны бөтен авылга бушлай он тараткан, имеш. Авылдагы мәчетне дә ул салдырган, мәдрәсә тоткан, ярлы шәкертләрне үз исәбенә укыткан. Әллә чын, әллә ялган — хәзер инде каян беләсең! Бай бай инде ул. Революциядән соң моны кулга алганнар, хатынын, балаларын — барысын җыйнап сөргенгә озатканнар. Өйләре менә утырып калган. Гали бай йортын нишләптер җенле, ияле, дип тә сөйлиләр. Гали байга баеп китәргә, имеш, өй ияләре, гаиб ирәннәр, җен-пәриләр булышкан. Җен-пәриле булганга да әле булса исән килеш утырадыр бу йорт — юкса күптән инде аны сүтеп алып йә утынга яккан булырлар иде яисә аны фермага күчереп, мал абзары итеп тотарлар иде.

Бу йорт хакында Янтыкта тагын шунысын да сөйлиләр иде: Гали бай, имеш, исән икән, сугыш алдыннан качып-посып авылга кайтып киткән икән дә, кайткач авыл картларына әйткән икән, имеш: минем йортны сүтмәгез, озакламый, алла бирсә, дөньялар үзгәрер, мәчет манараларын кисүчеләрнең

үзләренең башлары аяк астына тәгәрәп төшәр, дип әйтеп әйткән икән, имеш.

Гали байныкыннан соң бер-ике йортны узып киткәч, Габделхәй тагын бер йортка игътибар итте. Бу теге тыкрыкта торып калган йорттан да мескенрәк, искерәк һәм таушалганрак иде. Моның да аскы ниргәләре череп җиргә баткан, түбә кыегы кемнедер сөзәргә җыенган сыман, шулай ук алга сөрлеккән һәм шундый нык сөрлеккән — хуҗалар, күрәсең, чыннан да берәрсен сөзеп ташламасын дигәндәй, түбәне урам яктан нечкәрәк озын бүрәнә белән терәтеп куйганнар. Урам яктагы өч тәрәзәнең берсе дә төзек түгел: берсенең аскы өлгесенә такта кадакланган, икенчесенең бер өлгесе бөтенләй пыяласыз, өченчесе эчке яктан томалап куелган — тышкы якта ватык-китек пыяла кисәкләре генә елтырап күренә. Мөрҗәдән сыек кына булып төтен чыга, урамга балтырганлы тәмсез аш исе таралган. Әйтүләренә караганда, бу теге Хасан күлендә япон самурайлары белән сугышта батырлык күрсәткән, орден алган, бөтен районга атаклы Мансур Хәбибрахманов йорты. 1941 елны Гитлер басып кергәч, Мансур Хәбибрахманов, атаклы батыр буларак, үзе теләп, беренчеләрдән булып, сугышка киткән һәм шунда үлеп тә калган.

Габделхәйнең тәрәзәләргә каранып баруын өй эчендәгеләр күреп калдылар, ахрысы. Шул чакны ниндидер бер хатын-кыз эчке яктан тәрәзәгә килеп капланды һәм, «кем икән бу?» дигән сыман, кузгалмыйча озак кына карап торды. Мансур Хәбибрахмановның тол хатыны, ахрысы. Күрәсең, үткән-сүткәнне карап калып, әле һаман үзенең Мансурын көтәдер. Мескенкәем. Нинди кызганыч!

## III

Габделхәй картәтәйләренең өе зур гына, биек кенә иде. Каралты-кура, киртә-койма нык кына, төзек кенә. Өй артларында, урам буенда зур гына урын биләп, әкәмәт зур булып, биек булып, карт юан тупыл үсеп утыра. Аның күләгәсе бөтен урамны, бөтен ишегалдын каплап ала. Шуңа күрә монда кояш нуры төшкән җиргә караганда карангырак та, салкынрак та тоела сыман. Урам яклары төзек булса да, ишегаллары шулай да ташландык хәлдә. Кая карама, тәртипсезлек күзгә ташлана — киртә буенда калай комган аунап ята, лапас астында киселгән, туралган каен утыны таралып ята — беркемнең аны яхшылап өеп куярга кулы җитмәгән. Әллә вакыты юк, әллә хәле юкмы соң? Шунда ук, чапкычка аркылы төшеп, үткер балта тынып калган. Ишек төбендә үк диярлек, аяк астында, кабыгы төшерелгән ап-ак юкагачлар аунап ята.

Габделхәй, ишегалды ягындагы сыңар тәрәзәгә карана-карана, чолан ишегенә таба атлады. Тәрәзәдә беркем күренмәде. «Өйдә юклар бугай»,— дип уйлады ул. Ләкин чолан ишеге ачык иде. Тавыш-тынсыз гына атлап, Габделхәй ачык ишектән керде, өч-дүрт басмалы тар баскычтан менде һәм каршыдагы ябык ишек алдында туктап тормыйча, уңга, икенче як ишеккә таба борылды.

Фәрхәнә апаларныкы кебек картәтәйләрнең дә йорты алты почмаклы, ике яклы иде. Тик аларның бүлмәләренә чолан яктан аерым-аерым ишек аша кереп-чыгып йөриләр иде. Бүлмәләрнең берсе җәйге як, янсә җәйге өй дип, икенчесе кышкы як янсә кышкы өй дип атала иде. Җәй көне алар, гадәттә, зуррак, иркенрәк якта торалар, кыш көне утын әзрәк сорый торган кечерәк якка күченәләр иде. Салынган чакта аларның да йорты шулай байларча иркендә, рәхәттә яшәү өчен җайланган булган.

Кышкы якның ишеге ачык иде. Габделхәй, биек бусагадан ары узмыйча, ачык ишек алдында туктап калды. Картәтәсе, бөтен иләнне юкә кабыгы белән күмеп, артсыз урындыкта чабата ясап утыра иде. Ишектә кемдер барлыгын чамалап, ул эшеннән туктап калды, күзенә төшкән киез эшләпәсен күтәргәндәй итте дә Габделхәйгә текәлде, таныды һәм

— Һы, Гаптелхәй түгелме соң?—диде.

Ишектә елмаеп үсмер җегетнең чыннан да Габделхәйме, түгелме икәнлеген тикшереп карамакчы булган сыман, картәтәй урыныннан кузгалып куйды, тезендәге бар нәрсәсен идәнгә сыпырып төшерде дә аягына басты.

— Исәнме, картәтәй!—диде Габделхәй, бусага аша атлап.

— Килдеңме?—диде карт, каешланып беткән, буын-буын булып каткан сөякчел кулын күрешү өчен сузып.

Габделхәйнең картәтәсе җитмешнең теге ягында иде инде. Бер керфеге калмаган күзләре кысылып, йомылып беткән, иске чүпрәк сыман тире каплап торган яңак сөякләре йодрыктай булып калкып чыккан иде. Кайчандыр ат кылыдай каты, куе сакал-мыегы сирәкләнеп беткән һәм хәзер аның борын астында, ияк очында элекке гайрәтле чакларыннан калган ике-өч бөртек аксыл төкләр генә тырпаеп тора. Картәтәйнең колак артында да шундый ук төкләр күренгәли, маңгайдан югарырак түбә өсте исә яшен ташыдай шоп-шома һәм такыр иде. Өстендәге күлмәге терсәк турысыннан, җилкә турысыннан ямалып куелган, ачык изүеннән картларча ябык һәм сөякчел тәне күренеп тора. Ак киндер ыштаны күлмәгенә караганда арурак күренә, ләкин гел чабата ясау белән шөгыльләнгәнлектән, тез башлары сидерәп беткән иде. Аягына ул куныча кисеп ташланган ямаулы иске киез итек киеп куйган иде.

Габделхәй өйгә керде, күреште. Шуннан соң, тоткарланып тормыйча, түргә узды, үрелеп тәрәзәдән урам якка карап алды. Ишек ачык булса да, өй эчендәге һава бөркү тоелды. Картәтәсе янында озак тормыйча, ул икенче якка чыгып китте. Монда ишек-тәрәзәләр ябып куелган, аннан соң бу якта аш-су пешә, шунлыктан аш өстәлен, казан тирәсен чебен сарып алган иде.

Теге яктагы кебек, бу яктагы өй эче дә бик ярлы иде. Өйдә элеп алырлык берни юк. Казан янындагы киштәдә борынгыдан калган чаршау калдыгы эленеп тора да караулы агачта керләнеп беткән тастымал асылынып тора. Аннары ишек төбендәге агач чөйләрдә иске-москы кием-салым күренгәли. Түрдәге сике өстендә, керләнеп беткән мендәргә башын ташлап, чәче мамыкка буялып беткән бер кыз бала йоклап ята. Ябылмаган тәнен, кулларын, аякларын чебен сарган.

Габделхәй селтәнеп чебенне куып җибәрде дә, бала өстенә яулык сыман чүпрәк ябып куйды. Инәсе җибәргән күчтәнәчне почмактагы шүрлекнең иң югары тактасына куйгач, кире картәтәсе янына чыкты.

— Картый кая?—диде ул.

— Кем белә аларны...—диде картәтәй дәртсез генә.

Ул яңадан чабатасына тотынган иде. Аның өчен хәзер дөньяда тез өстенә сузып салынган чабатасыннан башка беркем, берни юк иде сыман.

— Җиләккә киткән бугай... балаларны ияртеп,—диде ул бераздан.—Сезнекеләр соң... тазалармы? Нишләп яталар?

— Тазалар. Сәлам әйттеләр,—диде Габделхәй.

— Каян килдең—турыданмы, күпердәнме?—дип куйды тагын бераздан картәтәй.

— Турыдан,—диде Габделхәй.

— Син гел турыдан... каңсамулларча!—диде картәтәй көлемсерәп.

*Ахыры бар*

# ШИГЪРИЯТ

## Кадыйр Сибгат

### Кемнәр дәшә безгә...

Балачактан Күкләр якын булды.
Үсә-үсә Күккә карадык.
Гашыйк булгач,
Җиргә чалкан ятып,
Күккә карап йолдыз санадык.
Хәзер дә бит һаман Күктә күзләр.
Нәрсә көтәм?
Нәрсә юксынам?
Җиребездә нидер җитми кебек.
Янибызда кемдер юк сыман.
Булмаганны кеше юксынмый ул.
Булмаганны кеше тоя алмый.
Тоя икән,
инде сизә икән,
йөрәккәен кеше тыя алмый.
Тарта мине,
магнитлардай тарта,
көтә анда безне кемнәрдер.
Эзли алар.
Алар да бит безне
йөрәкләре белән күрәдер.
Галәм иркен.
Тавыш ерак китә.
Сөйләшәсе килә:
Сез — кем ул?
Галәм чиксез.
Шушы чиксезлектә
ялгыз булса бу җир...
Мескен ул!
Безнең өчен генә Кояш батмас,
Безнең өчен генә Таң атмас,
Ялгыз булу безнең — мөмкин түгел,
ялгыз итеп ходай яратмас!
Ишетәм мин!
Гомер буе безне
кем чакыра?
Безгә кем дәшә?
Бар ул анда,
бар ул тере җаннар...
Күкләр белән күңел сөйләшә!

### Тетрәгән Җир

Көтмәгәндә бу Җир
кайчак убылып китә.
Ил кайгыга бата —
бер тетрәве җитә.

Йә чайкалып куя,
йә селкенеп ала.
Шәһәр торган җирдә
хәрабәләр кала.

Булганы юк аның
тыныч торган чагы.
Кайный Җирнең каны,
кайный Җирнең җаны,

Тетрәндердек Җирне
үзебез дә шактый.
Аның кайтавазы
рәхмәт булып кайтмый.

Тетрәр чагы аның,
тетрәр чагы — бигрәк.
Кеше — Җиргә бәла,
кешегә Җир кирәк.

Телгә килер тагын —
тетрәр кайсы якта?
Җир тетрәүләр безгә
җавап булып кайта!

Тетрәсә дә бу Җир
кайсы төбәгендә,
тетрәү үзәкләре —
кеше йөрәгендә.

---

Кадыйр СИБГАТ (1942) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән унга якын китап авторы. Чаллыда яши.*

## Гомерлек сорау

Кайлардан килде ул безгә?
Инде күптәннән таныш.
Гомерең буена бара
һаман шул бер уй-сагыш.

Елдан-ел ныграк бәйләнә —
тыныч көннәре сирәк.
Кеше дә бер, гомер дә бер —
язмышны аңлау кирәк.

Кемнәр без? Кайдан киләбез?
Юллар кайсы тарафка?
Аңлап булмый, белеп булмый
артка, алга карап та.

Ниләр көтә илне-җирне,
Кешелекне ни көтә?
Менә шушы билгесезлек
бүген җанны өшетә.

Яшибез кебек. Әллә соң
белмичә яшәп була?
Гомер үтә, кичләр була,
җавапсыз көннәр туа.

Без кая таба барабыз? —
Алда шул сорау тора!

## Уяндык та...

Кайларда ул көләч йөзле еллар?
Алкышлары китми колактан.
— Киттегезме? — диләр —
Җиттегезме? —
Яулык болгый еллар ерактан.
Елларны да мандык,
юлларны да,
ыштанны да мандык кызылга.
Уяндык та...
тирән уйга калдык —
йөзләр чытык,
тешләр кысылган.
Тешне кысып гомер итеп булмый.
Инде күптән тешләр әрниләр.
Күпме еллар...
Күпме гомер шулай...
Оят безгә!
Без бит гарьлеләр.
Кодрәт кирәк.
Үтисе бар әле
замананың зарур эшләрен.
Юкса, шулай
кысып яши-яши,
коелып та бетәр тешләрең...

## Бары шулай гына

Гел хурланды кеше җиңелүгә,
җиңүләргә тартты гомер буе.
Берәүнең дә җиңеләсе килми,
тик җиңүдә, тик җиңүдә уе.

Беренчеләр без булырга тиеш:
күп яшәдек инде җиңә-җиңә.
Җиңүләргә салдык гомерләрне,
еллар очты, мөлкәт очты җилгә.

Хәлең җитсә җиңү кирәктер дә...
Хәлең юкта җиңелү дә кирәк.
Икесен дә кабул итәр өчен
акыл кирәк бераз, сабыр йөрәк.

Каян килгән диген ул батырлык?
Бик йөрәкле затлар булганбыз шул.
Без ыштансыз килсәк тә дөньяга,
идеяле булып туганбыз шул.

Җиңелмәдек! Безне кемнәр җиңсен?!
Җиңә-җиңә инде тәмам ардык.
Алдыбызда якты маяк! диеп,
караңгыга таба китеп бардык.

Һәм туктадык. Болай булмый икән.
Дөреслеккә карап башны идек.
Җитте безгә бу җиңүләр! дидек,
Җитте безгә җиңелүләр! дидек.

Табынырга аллаң булмаганда
Кеше булу зарур икән, димәк.
Җиңелүсез, җиңүләрсез генә
яшәү кирәк бүген, яшәү кирәк!

Мактанмыйча, зурланмыйча гына,
Без инде ул Бөек, дими генә.
Башкаларны хурламыйча гына,
капиталистларга тими генә.

Имин генә, тыныч таңнар белән
көн итәргә язсын безгә ходай!
Гаделлек һәм кешелеклек белән...
Бары шулай гына... Бары шулай!

# Лена Шагыйрьҗан

## Икенче микрофон

(«ЙӨРӘК АВАЗЫ» ПОЭМАСЫННАН)

Микрофонга килеп басканчы ук
Фикер туплыйм, акыл җыям мин.
Регламентка, белмим, сыярмынмы,
Үз шигыремә мәгәр сыям мин...

Мин политик түгел, ә шулай да
Трибунага кайчак менгәлим.
Трибун шагыйрьләрнең ярсып-ярсып
Сөйләгәнен бармы күргәнең?..

Бардыр... әмма кулга каләм тотып,
Шигъри яуга барып кергәндә,
Йөрәк тибешен аның, төннәр буе,
Шөкер, санап тормый берәү дә...
«Чир» инде ул... Табиб чакыртмыйсың,
Им-том белән булмый дәвалап.
Караңгыда шагыйрь күбрәк күрә,
Шагыйрь халкы — төнге ябалак...
Мин политик түгел, шагыйрь генә.
Мин көрәшче түгел — җырчы мин.
Сәясәткә тыгылып үземне дә,
Якыннарымны да борчымыйм...
Әйткәнемчә, фиркаләргә кермим,
Сыйнфый аңым, ахры, чиклерәк.
Сайлауга да бармый кала идем, —
Монысы инде, димсең, шиклерәк?
Сәясәтнең монда катнашы юк...
«Прописка» — бөтен сәбәбе.
Мин исәптә түгел идем илдә —
Шактый гомер шулай яшәдем...
Ярый әле «утыз җиде» түгел,
Терәгеңә терәп атмыйлар...
...Егетен ташлап киткән кызларга да
Хыянәтче исемен тактылар...
Ярый, монысы инде үткән — беткән.
Турысы бар сүзнең, кыегы...
Белсәң иде, нинди «мәгълүматлар»
Җыйды икән миңа кәгәбы?..
Дөрес булса, анысы түзәр идең...
Хәрам керсә әмма, үпкәлим! —
«Черек күл»нең аның исе яман,
Тирәсеннән
Борыным каплап, урап үткәлим...

* * *

Гөлләр белән бик күп сөйләштем мин,
Алар таный минем тавышны...
Микрофоннан бүген кешеләргә
Сөйләр идем әрну-сагышны...

Калды инде сөю ялкыннарым
Салкын чишмәләргә түгелеп...
Калкып чыкты рәнҗү-каргышларым,
Әйтми йөргән — моннан күп элек...

Микрофонда гына мени хикмәт —
Күбрәк сөйләр минем күзләрем:
Йөзләремә чыккан ничә еллар
Әйтәлмичә дәшми түзгәнем...

Мин политик түгел, сайлый-сайлый,
Иярмәдем төрле төркемнәргә.
Сайлап алдым үземә ялгызлыкны,
Бәйле булмас өчен беркемгә дә...

Ялгыз калу — батыр калу сыман,
Җиңел түгел ләкин мәйдан тоту.
Бер чыбыктан сөргән «бердәмнәр»не
Җиңелдер дә, бәлки, бәйдә тоту...

Мин политик түгел, шагыйрь генә,
Күпләр өчен гади шигырьче.
Игенче бар илдә, тимерче бар,
Очрап куя хәтта сихерче...

«Ике балам, бер ирем бар», — диеп
Мактана алмыйм, анысы бар инде...
«Дөрес яшәү» кысалары миңа
Кысанрак күптән, тар инде...

Үз дөньясы була шагыйрьләрнең,
Дәрвишлек дип көлә күрмәгез.
Теге дөнья өчен бу дөньяда
Газап ләззәтләрен күргән без...
Табигатьтән тумыш табибләргә
Тамыр серен ача үләннәр.
Ә шагыйрьләр сүзләр тамырыннан
Тарихны да укый белгәннәр...

Акмуллалар, акмунчалар иле,
Аклык — милләтемнең үз төсе...
«Хаклык» өчен «Аклык» дигән сүзгә
Тик бер хәреф кала өстисе...
«Аклык чире» йокса, «акылсыз» дип,
Диагнозны бик тиз куялар...
Каргаларга каләр каркылдашып,
«Ак карга»ны читкә куалар...
Акыл — аклык,
Акыл — вакланмый,
Акыллылар үпкә сакламый.
«Акыллылар сыйныфы» беркайчан да
Бер аяктан «алга» атламый...
Сыйныф дигән сүзне яратмыйм.
Миңа никтер якын бөтенлек.
Әллә инде «сыйныф» дия-дия

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН (Шакирҗанова) — *шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Кешеләрне аерып бетердек...
...Мин сәясәт белән шөгыльләнмим.
Сәяхәткә чыгар идем мәнә,
Ил капкасы бикле булмаса...
Сингапурны урап кайтыр идем,
Их!
Яшәп ятса икән шунда бөрәр
«Сыйнфый дошман» дигән тумачаң...
Иркем булса, канатлы кош кеби,
Илләр буйлап очар идем сайрап.
Тел ачкычым белән ачар идем
Шигырь сарайларын үзем сайлап.
Ә шагыйрьгә күпме кирәк — жырын
Алмасалар тартып, ул бай инде.
Качмый, патшалары чакырса да,
Сайлап ал, дип, әйдә, бер бай илне...
Чын шагыйрьләр алыштырмас төсен,
Яраклашып кимәс битлек-кабык.
Укысыннар иде политиклар
Халык шагыйрьләрен эзләп табып...
Укысыннар иде халык күңелен
Микрофонга килеп басмас борын.
Тыңласыннар иде тып-тын калып,
Җиргә сеңгән зарын, моңын, җырын...
Политиклар алар шигырьне дә
Үзләренчә юрый торганнардыр.
Эчтән генә әле кайбер сүзгә
Үртәлеп тә йөри торганнардыр...
Мин политик түгел, шагыйрь генә.
Үзем хатын-кызлар затыннан мин.
Төрки телдә женси төрләнеш юк,
Шигъри телдә ир дә, хатын да бер...
Шигъри тел ул — шигъри сурәт, бизәк.
Серле, моңлы япон танкаларын[1]
Мин дә беләм...
Безнең шигырь авыр...
Турыдан ярган сугыш танкыларын
Хәтерләтә безнең шигырьләр...
Язучыга кызыкма син, ахир,
Язмыш аның түгел җиңелдән —
Безнең шигырь һаман шинельдән...
Шула-ай, тыныч кына дөнья көтү
Шагыйрь жанга хәрам, яттыр ул.
...Бүген бик күп оста шигырьчеләр
Нәрсә языйм, диеп аптырый...
Мендәремә башны куйганда да,
Каләмемне ерак куймыйм мин.
Уйлар миңа шигырь булып килә,
Рифма белән шәбрәк уйлыйм мин...

* * *

...Мин политик түгел, шагыйрь генә.
Илләр буйлап китәр идем мәнә.
Ә илчегә диләр, үлем юк...
Илле булсам, илле илгә чыгып,
Илче булыр идем — илем юк...
Шулай җырладык без. Бүген, бәлки
Кемдер әйтер, бу җыр иске, дип.
Сызып ташла моны шигыреңнән,
Бу җыр, малай, артык кискен дип...

Сызмыйм әле, белеп калсын яшьләр
Безнең «күрмәгәнне күргән»не.
Сызып атып кына булмый аны
Гомер буе җырлап йөргәнне...
...Шагыйрьләр шул сүзләр тамырыннан
Мәгънә эшеп, мәгънә үрәләр.
Шагыйрь затлар мине таныды болай,
Таныймыдыр вак-вак түрәләр?..
Анысы аның пүчтәк, вак мәсьәлә —
Теләсә кем диеп атагыз...
Бик тәкәббер түрәләргә үзе дә
Бөгелеп тормый әле апагыз!..
Аңламыйлар алар безнең телне,
Алар барыбер шигырь укый белми,
Алар бәгырен шигырь уты телми.
Шигъри сорау кала җавапсыз.
Алар өчен шигырь — савапсыз...
Иң арзанлы сүз дә, минемчә,
Кыйммәтрәк шигырь телендә.
Укучы да сизәр, тыңлаучы да
Ни ятканын телнең төбендә...
Их, аңлагыз шагыйрь йөрәген сез,
Каләм күзе — галәм күзендә.
Йөрәк йолдызының һәр тажыннан
Тамчы-тамчы тамар газаплары,
Күк йолдызы багар гаҗәпләнеп:
«Шигыре яна мәллә эзендә?..»

* * *

Тыңлыйсызмы, ишетәсезме мине,
Микрофонга куеп йөрәкне,
Әйтеп калыйм инде, бер кабынгач,
Әйтер сүзем шактый гыйбрәтле...

Сирәк сүзләр кирәк... Хак сүзең дә
Җилгә очар ишетеп туйсалар.
Телне өзгән кебек була, кисәк
Микрофонны өзеп куйсалар...

...Дөнья чуар, дөнья базарында
Берәү — итче, берәү — гәҗитче.
«Бу бит поэзия түгел, бу бит —
Нотык сүзе», — диеп, тәнкыйтьче
Язып куяр, бәлки, дәфтәренә.
Теләсә ни диеп атагыз...
Пәрәвездән нечкә жепләрдән дә
Шигырь үргән кеше апагыз...
Кылдан нәзек үксез җырларымның
Аңламады төбен берәү дә.
«Шигырь йортын» яңартырга иде,
Калдырмаска иде тирәүгә...
«Иреклеме» анда, «иҗеклеме»,
Сыешамы-юкмы чыгырга, —
Мин ирекле булып калыр идем
Үзем язган һәрбер шигырьдә...
Социаль чир кыса безнең тынны,
Гипноз белән булмый дәвалап...
Караңгыда шагыйрь күбрәк күрә,
Шагыйрь халкы — төнге ябалак...
Кичә язган китап
Ничә яздан
Чыгар икән, диеп басмада,
Котә шагыйрь...
Чират күперенең
Иң авыры шулдыр, господа!..

[1] Бишьюллык шигырьләр.

«Асрамага шигырь сатам», — диеп
Печән базарында торыйммы...
Әллә кереп китап кибетенә,
«Рухи печән» бераз сорыйммы?..
Шагыйрь суверенитетын яклап
Тавыш бирсә күктән тургайлар,
Кушылыр иде аңа бертавыштан
Мең сулышлы курай-сорнайлар...
Тугыз улын тапкан Тугзак ана
Тулгак газапларын кичергән...
Тулгактан да яман — яңа туган,
Бишек көтеп туңган шигырьгә...
Рәхәтләнеп бала табарга да
Ирек юк ди, әнә, Кытайда...
«Бүтән язма, кәгазь юк», — дип, берсе
Әйтеп карасамы Тукайга?! —
Укытыр иде илле иманнарын!..

Көн-төн кайрап план кайчысын,
Кәгазь тәхет биләп утырганнар
Татыр иде Тукай камчысын!!.
Белә микән шуны мөхәррирләр.
Шагыйрь өчен бер сүз — бер гомер,
Хәреф иләүчеләр һәр хатаның
Тоз салганын жанга белмидер...
Тел төбендә ятканы бар сүзнең,
Торганы бар телнең очында.
«Регламент» дип әнә кисәтәләр,
Ярый, туктыйм инде шушында.
Ноктасы шул: беркөн политиклар
Яклап гражданин Шигырьне,
Бер жылы сүз әйтсә,
микрофонны
Шундук Сандугачка бирермен...

# Роберт Миңнуллин

## Авыл. Таң вакыты

Яланда калган ялгыз ат,
Кичә кичен качкан да,
Хуҗасы килгәнне көтә,
Тау башына баскан да.

Агачлар йокымсыраган,
Чыклар чыккан үләнгә.
Җилләр дә ояларыннан
Чыкмаганнар белемгә.

Уйламый да уянырга,
Авыл яктыра гына.
Яктылык килеп сыена
Һәркемнең торагына.

Беленер-беленмәс кенә
Яктылыкка төренеп,
Тора авыл чак күренеп —
Юкка чыга төн эреп.

Аксыл каеннар да әнә
Билдән томан эчендә.
Ул томаннар ни өчендер
Ак каеннар төсендә.

Ачыла таң капкалары,
Яктыга җан тартыла.
Күнеккәнме караңгыга? —
Яктыдан тән тартына.

Яктылык белән күк йөзе,
Бөтен тирә-як тула.
Төннең бүтән чарасы юк —
Караңгылык яктыра.

Таң әтәче кинәт кенә
Җибәрде сөрән салып...
Кыймылдый, уяна авыл,
Көтүгә тора халык.

## Каурый болыт

Карый миңа,
Карый болыт,
Карый болыт, —
Каурый болыт.

Нинди коштан,
Каурый болыт,
Калдың икән
Каерылып?

Нидер булган
Каләмемә —
Җавап бирми
Таләбемә.

Яза алмыйм
Теләгәнчә —
Килеп чыкмый
Төбәгәнчә...

Каурый болыт,
Каурый болыт,
Төшче миңа
Каурый булып!

## Чыныктыралар

Агачлар һаман
Үсә торалар,
Юкса башларын
Кисә торалар.

Яңа ботаклар
Чыгып торалар.
Аларны шулай
Чыныктыралар.

Без дә агачлар
Шикелле икән.
Әллә инде без
Сихерле микән?

Чыныктырдылар
Шулай безне дә.
Күреп торасыз —
Исән без менә!

## Талбишек

Бездә бишек әллә ничек —
Талдан, җырдан үрелә.
Җырлы бишек, җылы бишек
Эленә өй түренә.

Җырлый бишек, елый бишек!
Җырлый-елый моңлана —
Әллә бишек, әллә инде
Бишектә яткан бала?!

Бишеге дә үрелгән шул
Сөндә үскән таллардан —

---

Роберт МИННУЛЛИН (1948) — *шагыйрь, «Бәхетле булыгыз», «Сөенсеннәр әле каеннар», «Мәңгелек сәфәр» һ. б. татар һәм рус телләрендә дөнья күргән лирика, балалар өчен күпсанлы китаплар авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Жырчы таллар, елак таллар...
Моңнар тама алардан.

Ул талларга ал таңнарда
Сандугачлар кунгандыр.
Кунып кына калмагандыр,
Оя корган булгандыр.

Сеңгәндер ул талбишеккә
Әнкәмнең моңнары да.
Шулайдыр шул, талбишекнең
Юк шуңа тынганы да.

И тирбәлә өй түрендә
Талбишек талгын гына...
Үрсәгез бишек, алыгыз
Безнең як талын гына.

Ничек жырламасын бишек,
Сөн талларыннан үр дә!
Талбишектә үстем мин дә —
Сизелмимени бер дә?!

## Күз төсле дә түгел әле

*Шагыйрь дустым Ринат Хәйри истәлегенә*

Күзләрне күрдек кенә бит,
Күзләргә кердек кенә.
Күзебез житә безнең дә,
Дидек тә күлдек кенә.

Күз төсле дә түгел әле:
Агачлар ямь-яшелдән.
Гомер безнең яшьлекне дә
Яшеллеккә яшергән.

Жәй бездән, күңелебездән
Китәргә жыенмаган.
Алмагачта — ал алмалар,
Әле дә жыелмаган.

Яшел үләннәр һаман яшь,
Сылу гөлләр сулмаган.
Әллә күзме озаклаган,
Әллә жәйме соңлаган?!

Югыйсә, жәй төсле әле.
Кайда син, көз? Килсәнә!
Кемгә килер, кемгә килмәс...
Көн дә килмәс — килсә дә.

Ничә шигырьлек дөнья бу,
Ничә жырлык гомерләр!
Бүгенге моңсулыкларны
Шигыремнән белерләр.

Жаным үкси... Сәер бер хис:
Үлдең дә... үлмәдең дә...
Жәйләрдә калдың инде син,
Көзләрне күрмәдең дә.

Үлдең дә... үлмәдең дә...

*5 сентябрь, 1990 ел.*

## Көнбагышым

Көнбагышым,
Көнбагышым,
Син — көн кошым,
Сары кошым.
Ник очмыйсың,
Сабыр кошым?

Көнбагышым,
Көнбагышым,
Алда — көзем,
Алда — кышым.
Ниләр алда?
Ниләр анда?
Белмим ансын —
Алдагысын.

Көнбагышым,
Көнбагышым,
Тоясыңмы
Көн агышын?
Тыңлыйсыңмы
Көй агышын?

Көнбагышым,
Көнбагышым,
Син бит минем
Мең сагышым,
Син бит минем
Моң-сагышым,
Син — язмышым,
Көнбагышым!

## Авыл. Тупыл белән сөйләшү

Тупыл туган, исәнме?
Мин исеңә төшәмме?

Син һаман да төз, биек —
Торасың күккә тиеп.

Синең кебек булырга,
Күккә тиеп торырга

Тырыша идем көн дә
Үскән чагында мин дә.

Үсеп булмады артык,
Колакларымнан тартып

Торсалар да үсмәдем.
Менә шулай эшләрем.

Ә син бик озын идең.
«Әйдә, биеккә!» — дидең.

Мин бит беренче кабат
Чыгардым синдә канат.

Татыдым синдә кукне.
Егылдым синнән купме?!

Ектың да, елаттың да,
Соңыннан юаттың да.

Ныгыттың шулай тәмам.
Әмма мин сиңа — һаман

Бәләкәйдер шул инде.
Үсә алмам, соң инде...

Ачуланмассың инде!

## Нигезләр

Газизләрдән газиз туфрак,
Изгеләрдән изге нигез!
Туган җирнең газизләре
Нигезләрдән бизде, дибез.

Кемдер бизгән, кемдер түзгән,
Кемнәрнедер биздергәннәр,
Өметләрен өздергәннәр —
Күпме шундый без белгәннәр.

Бәргәләнә, өзгәләнә
Бәгырьләре киткәннәрнең, —
Күз яшьләрен түккәннәрнең,
Чит җирне үз иткәннәрнең.

Юатырга үзебезне
Тәкърарлыйбыз бер үк тәгъбир:
Кешеләрне йөртә язмыш,
Бәндәләрне йөртә тәкъдир.

Ничек кайтсын чит туфракка
Кендекләрен беркеткәннәр.
Көтмә, нигез! Кайтмый икән,
Кайтмый икән бер киткәннәр.

И илдәшләр, нигездәшләр,
Кайталмыйбыз ни сез, ни без...
Көтә, бәләм, туфрак белән
Тигезләнгән азмы нигез.

И сез!.. И без!..

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## С. Горский

# ЯВЫЗ ИВАННЫҢ ХАТЫННАРЫ

### I



елның 25 июлендә Мәскәүнең Кызыл мәйданында кара таңнан кызу эш кайнады. Алдагы көндә үк анда әрдәнә-әрдәнә бүрәнә белән такта, берничә зур тимер казан, тау-тау чылбырлар һәм үткен ыргаклар ташып куйдылар. Мәскәү халкы бу хәстәрлекләрнең ни аңлатканлыгын бик әйбәт белә иде: Иоан Васильевич патшаның бөтен мир каршында җәзалап үтерү һәм газаплаулар белән күңел ачуы беренче мәртәбә генә түгел, ләкин моңа кадәр Мәскәүнең беркайчан да болай берьюлы күпләп җан коюны күргәне юк иде әле: чөнки, сизелеп тора, бүген гадәттән тыш нәрсә әзерләнә.

Ул көнне кем авызыннандыр җан тетрәткеч хәбәр таралды: патша, имеш, опричникларына, урамда очраган бер кешене тотып алып, җәзалап үтерергә кушкан. Шунлыктан Мәскәүдә иртә таңнан үлем тынлыгы урнашты. Бары тик Кызыл мәйданда гына тук-тук итеп балта тукылдавы белән пычкы чинавы гына яңгырап торды һәм кайбер бушап калган урамнар буйлап, атларының иярләренә себерке белән эт башы тагып, «падишаһның ышанычлы ялчылары» гына шаулап анда-монда чапкалады.

Иртәнге сигез тирәләрендә мәйданда киң итеп эшләнгән 18 дар агачы калкып чыкты. Алар арасында, «Калку урын» дип аталган биек бер җирдә, зур учак әзерләделәр; ә аның өстенә, су тутырып, иләмсез киң һәм тирән чуен кисмәк элеп куйдылар. Менә бермәлне учакны ялкын телләре чорнап алды һәм тиздән кисмәк өстеннән, болыт кебек бөтерелеп, ап-ак бу күтәрелә башлады. Мәйданда урнашкан тирән тынлыкта дөрләп янган бүрәнәләрнең кинәт шарт-шорт ярылып китүләре һәм кисмәктәге суның быкырдап кайнавы гына ишетелә. Эшчеләр, үзләренә кушылганны әзерләп бетереп, тизрәк мәйданнан чыгып таю ягын карадылар. Кызыл мәйданда булачак җәзалауга кирәк-яракларны әзерләтүче берничә күзәтүче опричник кына калды.

Нәкъ сәгать унберддә Кремль диварлары эчендә дөп-дөп итеп шөлдерле барабаннар кагу һәм ачы итеп быргы кычкыртулар башланды. Тиздән Спасс капкасы шар ачылып китте һәм эчке яктан халык агымы чыгып килүе күренде. Иң алдан, кар кебек ап-ак атка атланып, тәкәббер кыяфәтле Иоан Васильевич патша үзе килә. Ул «җиңелчә кием» белән генә, ягъни парчалы кыска кафтаннан гына, әмма аның башында, күзне камаштырып, алтын бизәкле очлым ялтырый, биленә кылычын таккан, ә уң кулына озын сөңгесен кысып тоткан. Патша артыннан, икенче булып, аның яраткан улы Иоан бара. Патша малае да «җиңелчә кием»нән һәм ул да, әтисе кебек үк, кылыч-сөңге белән коралланган. Атасыннан аермалы буларак, болардан тыш аның атының иярендә себерке белән эт башы чайкала, чөнки ул опричнинаның иң зур башлыгы булып санала иде.

Патша малае артыннан мәйданга ат менгән йөзләп опричник килеп чыкты, ә алардан соң хөкем ителгәннәр төркеме күренде: бу юлы алар, чынлап та, 300 чамасы иде. Каты газапланулардан соң алар аякларын көч-хәл белән генә сөйрәп киләләр. Суырылып, яшькелт-көлсу төскә кергән йөзләрендә тәмуг газаплары һәм бөтен нәрсәгә битарафлык катып калган. Арадан кайберләре, хәтта нишләүләрен дә аңламыйча, ахры, туктап-туктап калалар һәм, сакчылар айбалталары белән аркаларына төрткәләп куалагач кына, тагын кузгалып китәләр. Усал патшага каршы ас-

тыртын килешү оештыруда гаепләнгән бичаралар иде алар. Новгород белән Псковны җимереп кайткач, Мәскәүдә дә рәхимсезлек белән бөтен халыкның өнен алырдай ни дә булса кылырга кирәк иде Иоанга. Боеручысының һәр теләгән алдан сизеп торучы Скуратов тиз генә зур «фетнә» ачты: аның башында архиепископ Пимен тора, имеш. Нәтиҗәдә, зинданнар һәм төрмәләр тоткыннар белән шыгрым тулды, күз күрмәгән, колак ишетмәгән газаплаулар белән сорау алулар башланды һәм моңа дучар ителгәннәрнең бөтенесе дә диярлек ачы хөкемгә тартылдылар. Арада атаклы боярлар һәм хәтта өлкән Басманов белән Вяземский кенәз һәм шундыйлар кебек патшаның иң якын күргән кешеләре дә бар иде.

Иоан «Калку урын» янына килде һәм атны туктатты. Бушап калган мәйданны кырыс карашы белән сөзеп чыкты һәм, кашларын җимереп, беркемгә дә төбәп тормыйча боерык бирде:

— Халыкны җыярга. Явыз җаннарның ничек бетүен күреп торсыннар.

Опричниклар: «Һәйдә! Һәйдә!» — дип кычкыра-кычкыра, төрле якка ташландылар. Мәскәүнең бөтен урамнарында ат тояклары тыпырдавы, айбалталар белән капкаларга һәм ишекләргә шап-шоп бәрүләр яңгырый башлады. Шәһәр кешеләре, тын алырга да базмыйча, патша әмеренә буйсындылар. Ярты сәгатьтән алар берәм-берәм Кызыл мәйданга агыла башладылар һәм тиздән анда меңәрләгән кешедән торган халык төркеме җыелды.

Шуңа кадәр бер сүз дәшмичә Калку урынга текәлеп карап торган патша атын халыкка таба борды һәм, тавышын күтәрә төшеп, сүз башлады:

— Халык! Хәзер син газаплаулар һәм җәзалап үтерүләр күрерсең. Карап тор, ләкин курыкма. Бу — минем үземне һәм патшалыгымны һәлак итәргә астыртын нијят корган хыянәтчеләргә җәза бирүем. Җавабыңны бир: хаклымы минем хөкем?

Иоанны тыгыз боҗра булып уратып алган опричниклар, бөтен мәйданны тутырып, кычкырыша башладылар:

— Хаклы! Хаклы! Мең яшә, Бөек Падишаһ! Явыз җаннар белән хыянәтчеләрнең дөньяда эзе калмасын!

Алар кычкырган сүзләрне Кызыл мәйданга тулган халык күтәреп алды. Мондый минутларда дәшми калу артык хәтәр кылану булыр иде шул.

Патша сизелер-сизелмәс ишарә ясады һәм, җан өшетерлек әшәке җәзалап, кеше үтерүләр башланды. Хөкем ителгәннәрне тиз генә үтермәделәр, башта аларны иң азгын хыял да уйлап таба алмастай алымнар белән газапладылар.

Җәза бирүне уналты яшьлек үсмер кызын патша гаремына җибәрергә риза булмауда гаепләнгән сарай бояры Висковатыйдан башладылар. Бояринны, аягыннан асып куеп, башына кайнап торган су койдылар, аннары Малюта Скуратов аның колакларын һәм борынын кисеп төшерде, ә бүтән опричниклар мескеннең кулларын әкрен генә кисеп өзделәр һәм шуннан соң җәллад, бояринның кара канга баткан бөтен гәүдәсе көзән җыергандай тартышканын түйганчы карап торды да, күнеккән хәрәкәт белән аны кыл урталай ярып чыгарды.

Шул мизгелдә, өнсез калган халыкны кинәт дәррәү дерт иттереп, Кремль диварлары ягыннан шатланып көлгән тавыш яңгырап узды. Җәзалап үтерүләрнең ирексез шаһитларыннан берничәсе — коточкыч газаплаулардан җан биргән Висковатыйның канлы кисәкләреннән күз карашларын читкә алырга үзләрендә ихтыяр көче тапканнары — Кремль диварының өске киртләре арасында кояш нурларында ялтырап киткән хатын-кыз кокошнигы күреп калды.

Патша үзе дә шул якка таба борылып карады. Бармагы белән ишарәләп, Малютаны үзе янына чакырып китерде һәм, дивар ягына таба ымлап, әкрен генә:

— Әйт, тавыш-тыннары чыкмасын анда. Кызыгыр нәрсә түгел,— диде.

Иоанны ярты сүздән аңларга өйрәнгән Малюта Спас капкасына таба ашыкты. Спасс манарасы диварындагы тимер ишек хәзерге көннәрдә дә исән, явызҗан Скуратов, әнә шул ишек аша үтеп, тар таш баскыч буйлап Кремль дивары өстенә күтәрелде. Дивар өстендә, калын таш киртләчләр артында, киң коридор сузыла, аннан, туптан һәм мылтыктан атар өчен махсус ясалган аралыклар аша, бөтен шәһәр күренә. Ә Кызыл мәйдан моннан караганда уч төбендә кебек җәелеп ята.

Шунда, дивар киртләре аралыкларына капланып, купшы киемле дүрт хатын мәйданга карап тора иде. Алар мәйданда барган җәзалаулар белән шулкадәр нык мавыкканнар иде ки, хәтта патша илчесенең үзләре янына менүен сизми дә калдылар. Малюта аларның берсе янына якынайды һәм, үзенә таба аркасы белән басып торса да, биленә кадәр бөгелеп, аңа түбәнчелек белән сәлам бирде. Озын, зифа буйлы, егерме биш яшьләрдәге чибәр хатын иде ул. Үзе янында кыштырдау тавышы ишеткәч, хатын артына борылып карады. Малютаны күргәч, аның кара кучкылрак йөзенә алсулык йөгерде, түбәнгә таба төбәлгән озын керфекләре артындагы зур күзләрендә усал очкын ялтырап алды, күмер кебек кап-кара куе кашлары бергә кушылдылар.

— Ни кирәк сиңа?— дип сорады ул һәр сүзен кистереп.

Малюта тагын бер мәртәбә аның алдында бил бөкте һәм:

—Падишаһ Иван Васильевич мине, үзенең колын, сиңа, падишам, урынсыз көлүең белән халыкны һәм ахирәт кызларыңны котыртмасын дип әйтергә кушып җибәрде,—диде.

Чибәр хатын мыскыллык белән иреннәрен кысып куйды.

—Бар, патшага әйт,—дип җавап бирде ул.—Кайчан күңелем күтәрелә, шунда көләчәкмен мин: бер үзенә генә күңел ачарга димәгән.

Скуратов, тагын бөгелеп баш иеп, кире китте.

—Шайтандыр бу... хатын-кыз түгел бу, ә җен...—дип, мыгырданды ул баскычтан төшкәндә.

Бу гүзәл ханым Иоан патшаның икенче хатыны Мария иде. Биек таулар кочагында иркенлектә үсте ул, җилдертеп атта да чаба белә, теләсә нинди корал белән дә эш итә ала иде. Аның атасы, черкас кенәзе Тәмгрүк, Мәскәү патшасыннан Мариянең гүзәллеге турында ишетүе һәм аны үзенә хатынлыкка алырга теләве турында хәбәр килгәч, шаккатты.

—Патшаның муенын борып атачак бит ул!—диде ул чын күңелдән патшаның яучысы булып килгән дума эшләре башкаручы Шеинга.

Иоанның муенын Мария, әлбәттә, борып атмады, әмма ул үзен шундый итеп куя алды ки, тажлы ире аның теләсә нинди капризын бертуктаусыз үти иде. Туган илендә ул сабый чактан ук кораллы бәрелешләргә, йөгәнсез кыргыйларча үч алышуларга, кан коюларга күнегеп үсте. Кызыл мәйданда тантаналы төстә берничә йөз кешенең җәзалап үтереләчәген белгәч, ул Иоаннан уңайлы чак туры китереп, үзенә һәм тагын яраткан өч бояр кызына Кремль дивары өстеннән карап торырга рөхсәт алды. Башта аның бу сәер үтенече патшаны бик нык гаҗәпләндергән иде. Мәскәү барлыкка килгәннән бирле, хатын-кызлар моңа кадәр, качып-посып кына булса да, җәзалап үтерүләрдә һәм, гомумән, халык күп җыела торган төрле тамашаларда катнашмыйлар иде. Ул аны бу уеннан кире кайтырга үгетләп карады, әмма хатыны, әгәр дә Кремль дивары өстендә торырга рөхсәт итмәсәң, үз-үземә кул салачакмын, дип кырт кисте. Мариянең бу янавы коры сүз генә түгеллеген яхшы белә иде Иоан. Бервакыт хатын моны исбат иткән иде инде.

Бергә тора башлауларының беренче елында ук Мария Иоаннан үзенең 18 яшьлек энесен, Петр Темгрюкович кенәзне, катгый рәвештә сарайга хезмәткә алуын таләп итте. Патша баш тартты, чөнки Темгрюков кенәзләрнең аңа кадәр беркайчан да сарайда урын тотканнары юк иде, шуңа күрә билгесез бер яшь егетне зур урынга кую патшаның якын даирәләре арасында, һичшиксез, ризасызлык китереп чыгарачак иде.

—Әгәр дә аны сарай хезмәтенә алырга теләмәсәң, падишаһ, мин асылынып үләчәкмен,—дип өстәде Мария тыныч тавыш белән.

Иоан ул чакта көлеп кенә куйды. Әмма шул ук төнне патша хатынының өендә дөнья күрмәгән хәл булды: Марияны озын сөлгедән ясалган элмәктән алдылар. Патша хатынын исән-имин алып кала алдылар алуын, тик бу хәл патшага шулкадәр нык тәэсир итте ки, шуннан бирле ул үзенең йөгәнсез холыклы хәләл җефетенә бүтәнчә каршы килмәс булды. Һәм менә бүген дә ул, ата-бабасы калдырган гореф-гадәтләрне бозып, хатынының Кремль дивары өстенә менүенә юл куйды, тик бу турыда беркем дә белмәсен, дип каты кисәтү генә ясады.

Шуңа күрә, Висковатый соңгы сулышын алганда, Мариянең тыела алмыйча кычкырып көлеп җибәрүе Иоанның бик нык ачуын чыгаруы аңлашыла торгандыр.

Скуратов киткәч, патша опричникларына кыска-кыска әмерләр бирде һәм җәза бирүләр дәвам итте. Баштарак Иоан хөкемгә тартылганнарның бер йөзгә якынын кичерергә уйлаган иде, әмма хәзер, берсенә дә ташлама ясамыйча, бөтенесен үлемгә дучар итте.

Бичараларның өсләренә кайнар су койдылар, гөрзи белән башларын ярдылар, кылыч белән кисәкләргә турадылар, сөңге белән чәнчеделәр, астылар, кистеләр. Шундый коточкыч мәхшәр дүрт сәгать буе дәвам итте. Кан исеннән исергән патша үзе дә, җәлладларга кушылып, сөңгесе белән өч кешене калап үтерде.

Ниһаять, барысын да җәзалап үтереп бетерделәр. Шуннан соң баштан-аяк канга баткан опричниклар, «Һәйдә!» дип кычкырышып, Иоанны уратып алдылар. Патша чиксез канәгать иде. Ул, ашыкмыйча гына, танымаслык булып гарипләнеп беткән мәетләр белән тулы Кызыл мәйданны, атын әкрен генә атлатып, әйләнеп чыкты. Калку урынга кире урап килгәч, шат йөз белән Скуратовка карап:

— Ярый, Малюта, фетнәчеләрнең эшен бетердек. Инде хәзер аларның тол хатыннары белән ятимнәрен киметергә кирәк. Киттек! Минем арттан!—диде.

Шул сүзләр белән патша туп-туры халык төркеме өстенә таба чаптырып китте. Яран опричниклары аның артыннан томырылдылар. Патша әмере белән мәйданга җыелган халык мондый борылышны көтмәгән иде. Коточкыч хәл алдында каушап калган кешеләр тизрәк тирә-якка сибелделәр, әмма канга исергән өер, атларын бөтен көчкә чаптырып, аларны рәхимсез рәвештә таптап узды. Патша, якындагы урам почмагына борылып, күздән югалды: аның артындагы мәйданда, аяусыз ат то-

яклары астында тапталып гарипләнгән һәм бөтәрләнгән кешеләрдән торган киң ачыклык ясалып калды.

Ә Кремль дивары өстеннән мәйданга кабат көмеш кебек чыңлаган шат көлү тавышы яңгырады.

Патша белән падиша күңел ачалар иде.

## 2

Висковатый боярның иркен пулатлы агач йортында авыр кайгы-хәсрәт хөкем сөрә. Кызыл мәйданда нинәр булуын өйдәгеләрнең барысы да белә иде. Хуҗа хатын тирән кайгыдан авыруга сабышты: ул үзенең ял итү бүлмәсендә түшәктә ята. Караваты янында аны кечкенәдән карап үстергән карчык кына утыра, әмма аның хуҗабикәне төрлечә юатырга маташуы файдасыз иде. Бояр хатыны аны ишетми дә иде, ул дәшми-тынмый бер ноктага карады да катты.

Висковатыйның кызы, уналты яшьлек Наталья, асрау кызлар арасында үз бүлмәсендә утыра. Элек монда һәрвакыт күтәренке күңел ачу, яшьләрнең дәртле көлүе, җыр һәм бию яңгырап тора иде; опричниклар бояринны, аяк-кулын бәйләп, алып киткәннән бирле бу бүлмә дә тынып калды. Бары кайчакта гына, авыр чирле кеше ятагы янында утыргандагыдай, курка-курка гына үзара пышылдашу, авыр итеп уфтану белән әледән-әле сулкылдап кую гына ишетелеп киткәли.

Көндезге сәгать бишләр тирәсе иде. Хезмәтчеләр, гадәт буенча, төп пулатта кичке тулай аш өчен өстәл әзерли башладылар. Шулчак кинәт иркен ишегалдында ниндидер кыргый тавышлар яңгырады. Ялчылар тәрәзәләргә ташландылар һәм һич көтелмәгән гаҗәп хәл күрделәр: биек болдыр янында патша үзе атыннан төшеп маташа! Скуратов хөрмәт йөзеннән аңа ярдәм итеп тора. Бөтен ишегалды атлы һәм атларыннан төшкән опричниклар белән тулган: алар үзара бик каты кычкырышалар, һава күтәреп шар көлешәләр һәм, кызык өчен, вакытында качып өлгермәгән хезмәтчеләрнең аркаларына камчылары белән сыдыралар иде. Бернинди яхшылык вәгъдә итмәгән бу хәлне күрүгә, ялчылар бары да ашыга-ашыга төрле ерак почмакларга ташландылар.

Иоан болдырга менде. Әмма аны хуҗалардан беркем дә каршыламады. Ул, туктап, өстенлек белән кеше кайгысына сөенгән карашын зур йортның тәрәзәләренә ташлады һәм үзенең опричникларына таба борылды:

— Кунакка килүебезне күреп, шатлыкларыннан акылдан шашканнар, күрәсең. Берсенең дә безне каршы алырга башына керми. Ишекләрне үзебезгә ачарга туры килә.

Берничә опричник калын имән ишеккә ташланды: ул эчтән эшермә белән аркылы бикләнгән булып чыкты.

— Патшаларын кунак буларак күрәселәре килми икән боларның,— диде Иоан ясалма тыйнаклану белән.— Кире борылып китү әйбәтрәк булыр, ахрысы.

Шулвакыт ишек, айбалталар белән сугуларга һәм гайрәтле киң җилкәләрнең бәрүенә чыдамыйча, капыл ачылып китте. Патша, усаллык белән йөзен чытып, тупса аша эчкә атлады. Аның артыннан, шау-шу күтәреп, опричниклар өере иярде.

Бу мизгелдә хатын-кызлар ягында ни башланганын сүз белән генә аңлатып булмый. Куркуларыннан акылдан шашарга җиткән асрау кызлар, чыелдаша-чыелдаша, төрле якка чәчелделәр, әмма качып котылу мөмкинлеге юк иде: моның өчен бердәнбер юл — баскычтан төшеп, пулатның «кара ягы»на кереп шылу. Ә анда аста ярым исерек кешеләрнең ерткычларча кычкырышуы ишетелә иде. Шушы паника арасында бары тик ике генә кеше үзен тыныч тотты: җәзалап үтерелгән Висковатыйның хатыны белән уналты яшьлек кызы иде алар. Бүген алар икесе дә үзләренең иң кадерле кешеләрен югалттылар. Хуҗабикә өзелеп сөйгән иреннән ятим калды, ә аның кызы — әтисеннән башка әле тагын ярәшкән егетен, яшь кенәз Оболенскийны югалтты: аны да бүтәннәр белән бергә җәзалап үтерделәр. Өйгә бәреп керүчеләрнең тавышын хуҗабикә ишетмәде дә булса кирәк. Ул һаман элеккечә, тавыш-тынсыз, бөтен дөньяга битараф караш белән бер хәрәкәтсез ята бирде. Тәрбияче карчык кына үзалдына нинәрдер сөйләнде, аптыравыннан кулларын җәеп-җәеп җибәрде, бүлмә буйлап арлы-бирле сугылды, дога укырга тырышып карады.

Бояр кызы Наталья, опричникларның кыргыйларча шаулашуына һәм асрау кызларның акырышуларына игътибар итмичә, тынсыз утыра бирде. Елый-елый кызарып беткән күзләре хәзер коры иде аның. Ул үзенә таба ниндидер гаять дәрәҗәдә куркыныч бер нәрсә якынлашуын сизенә иде, әмма аны, соңгы көннәрдә башыннан үткән авырлыклардан соң, берни белән дә куркытып булмый иде инде.

Иоан юлында очраган «асраулар бүлмәсе»нә керде һәм тирә-ягына карады: анда бер җан иясе дә юк иде. Аның кашлары тагын да ныграк кысылдылар.

— Йәле,— диде ул,— кармалап чыгыгыз әле, безгә хуҗабикә анакай белән чибәркәй кыз янына юл күрсәтерлек берәрсе табылмасмы?

Бер минуттан патша каршында, кайдандыр караңгы бер почмактан өстерәп чыгарылган, ике хезмәтче дер калтырап басып тора иде инде. Иоан аларга, тавышын ягымлырак итәргә тырышып, үзен хуҗабикәләре янына алып барырга кушты. Баш тарту турында әйтеп тә торасы юк, әлбәттә, патша артыннан бөтен өер бояр хатынының йокы бүлмәсенә юнәлде.

Берничә дистә авыр аяк тавышын ишеткәч, Висковатыйның тол калган хатыны исенә килде. Ул, авыр күтәрелеп, ятагының кырыена торып утырды һәм гаҗәпләнгән күз карашын ишеккә таба төбәде. Бер үк вакытта аның күңелендә: ә бәлки бояринны кичергәннәрдер, дигән дуамал өмет тә уянды. Ләкин менә нишләп соң аның белән бергә гаскәриләр дә килде икән?..

Хуҗабикәнең башыннан тагын әнә шундый борчулы бик күп сораулар йөгереп узды, әмма ул аларны аңы белән кабул итеп өлгермәде. Төрле бизәкләр белән сырлап ясалган ишекне кемдер итеге белән тибеп ачып җибәрде һәм биек тупса артында Иоан Васильевич патша күренде. Бояр хатыны аһ итте! Ул үзенең эчке юка күлмәктән генә утыруын да, күпереп торган аксыл-сары чәчләренең, җилкәләрен каплап, дулкын-дулкын булып биленә кадәр салынып төшүен дә онытkан иде. Ул, нәни генә кошчыкның зур зәһәр еланга карап катканын хәтерләтеп, куллары белән тезләренә таянган һәм усал карашы белән үзен сихерләгән Иоанга текәлгән иде.

Иоан ишек төбендә туктап калды. Бояр хатынын мондый хәлдә түшәк өстендә табармын дип көтмәгән иде ул.

Бары тик тәрбияче карчык кына хисен җуймаган иде. Ул патша каршына йөгереп килде һәм, туп-туры аның йөзенә бәреп:

— Җанкыйгыч нәрсә! Бояринны үтерүең җитмәдемени сиңа, ерткычлыгыңны монда дәвам итәргә килдеңме! Тагын нәрсә кирәк сиңа монда?— дип кычкырды.

Үзе дә көтмәгәндә бояр хатынының йокы бүлмәсенә килеп кергән Иоан, бәлки, канлы инстинктларына ирек куймаган да булыр иде, ләкин карчыкның кылануы аны ярсытып чыгарды.

— Монда нәрсә кирәкме миңа?— дип кайтарып сорады ул бераз карлыккан тавыш белән.— Хәзер белерсең, җен карчыгы! Малюта! Мин бояр хатыны белән гәпләшкән арада аякларыннан асып куй әле шуны!

Опричниклар, тәрбияче карчыкка ташланып, авызына дыңгычлап ниндидер чүпрәк тыктылар һәм, аякларына озын пута бәйләп, ишек өрлегенә асып куйдылар.

Бояр хатыны һаман бер сүз дә дәшмәде. Патша аның янына килде. Аның төпкә баткан күзләрендә бернинди өмет калдырмаган чиркәнеч ут ялтырый иде.

— Йә, хуҗабикә-анакай,— дип башлады ул юха тавышы белән: күңеленнән алдан ук газаплы үлемгә дучар иткән корбаннары белән ул әнә шулай сөйләшә торган иде.— Җан дустыңны вак кисәкләргә турап ташладык. Бер киселгән кире ябешми. Аңардан калган мал хәзер безгә, патша милкенә күчәргә тиеш, димәк. Әнә шуның өчен без синең янга кунакка килдек тә. Кире какма, хуҗабикә, сөйләп бир: казнагызны кайда саклыйсыз?

Бояр хатыны бер сүз дә дәшмәде. Иоанның ни әйткәнен ишетерлек хәлдә түгел иде ул. Патша усал итеп елмаеп куйды һәм Скуратовка таба борылды:

— Нәрсә, Малюта, бояр хатынының теле иреннәренә бәйләп куелган, ахры? Чишеп карыйбызмы әллә?

Малюта патшаны ярты сүздән аңлый торган кеше: кайдандыр кып-кызыл утлы күмер тулы чүлмәк килеп чыкты, билбауларыдан алынган пычаклар ялтырап китте һәм сорау алу башланды. Мескен тол хатынны ике сәгать буе интектерделәр, әмма аңардан бер сүз дә тартып ала алмадылар. Явыз патшаның килеп керүе шулкадәр нык тетрәндергән иде аны, ул исен югалтып катып калды, шуңа күрә тәненең авыртуларын тоймады да бугай. Дәшмәвенә ачулары кабарган опричниклар, моны үҗәтләнүе дип аңлап, чамадан тыш кылана торгач, Висковатыйның хатыны җан биргәнен сизми дә калдылар.

Алларында җансыз гәүдә ятканын күргәч, Иоан аларга:

— Гаярь хатын булып чыкты бу,— диде.— Ярар, аңардан башка да булдырырбыз. Безнең кулда кызы бар бит әле.

Бояр кызы Наталья ул арада күпмедер дәрәҗәдә һушын җыеп өлгергән иде. Асрау кызларның берсен ул, аста нинди тавышлар икән анда, белеп мен, дип түбән төшереп җибәрде. Теге кыз берничә секундтан, куркудан чырае качып, кире йөгереп менде.

— Харап булдык!— дип кычкырды ул, тыны бетеп.— Анабыз-хуҗабикә янына опричниклар килгән. Патша үзе дә шунда.

Кызлар ягында чыелдашу башланды. Барысы да качу ягын карады. Бүлмәдә бер Наталья гына ваемсыз кыяфәт белән утырып калды. Яшь булуына карамастан, ул патшаның килүе нәрсә белән бетәчәген бик яхшы аңлый иде...

Ике сәгать вакыт узды. Бояр кызы һаман да шулай бер урында хәрәкәтсез утыра бирде. Астан ниндидер яман тавышлар, җан өшеткеч гүләү ишетелә иде. Менә, ниһаять, гүләү, көчәеп, аның бүлмәсенә якынлаша башлады. Баскычта авыр аяк та-

вышлары яңгырады һәм бер минуттан кызлар бүлмәсенә Иоан килеп керде. Кызыл мәйданда берьюлы йөзәрләгән кешенең канын койганнан соң, тагын ике сәгать буе хуҗабикәне газаплау аның канга сусавын бераз баскан иде инде. Күз нурлары сүнгән, иреннәрендә арыган һәм ягымлы дип әйтерлек елмаю күренә.

— Исәнме, чыпчык баласы,— диде ул.

Наталья кәнәфиеннән торды. Нишләвен үзе дә аңышып бетермәстән, Иоан янына килде һәм, бөтен көченә селтәнеп, йодрыгы белән аның битенә тондырды. Патша опричниклары кызга ташландылар һәм күз ачып йомганчы путалар белән аяк-кулын бәйләп ташладылар. Кызның кыланышы патшаның ис-акылын алды. Ул берничә секунд дәшми торды. Бөтенесе дә аның бояр кызына җәза төре эзләвен аңладылар. Ниһаять, ул карлыккан тавышы белән көлеп җибәрде:

— Кыю кызый!— диде ул.— Күңелен күрергә туры килер. Яле, патша малае, күрсәт әле шунда үзеңнең ир-егетлегеңне. Кызлар күңелен күрә беләсеңме икән! Ә сез,— дип дәвам итте ул, опричникларга таба борылып,— бүтән кызлар белән юана торыгыз. Төрле почмакларда качып-посып яткан кыз-кыркыннар аз түгелдер монда, шөт. Ә мин утырам, кечтеки генә ял итеп аласым килә.

Шул сүзләрен әйтеп, Иоан кәнәфигә чумды. Опричниклар, тиз арада табып, асрау кызларны сөйрәп чыгардылар, ә патша улы Иоан Натальяга ташланды һәм шунда ук, патша күзе алдында, пәри туе башланды...

## 3

Балачактан бернинди чикләү-тыю кебек нәрсәләрне белмәгән һәм боярлар аздырып бетергән (ә соңыннан ул аларның барысын да, кызганып тормыйча, үтертеп бетерде) Иоан гомере буе ата фәхешче булды. Тарихчыларга аның күпмедер дәрәҗәдә кешечә яшәгән ике атнасы гына билгеле. Ул да булса, беренче кәләшенең куенына кергәннән соң үткән атналар иде алар.

1546 елның 16 февралендә унҗиде яшьлек Иоан Васильевич Анастасия Захарьина дигән кызга өйләнә. Захарьиннар нәселе бик үк данлыклылардан булмый (татар нәселеннән чыкканнар.— Тәрҗ. искәрмәсе), ләкин яшь патшаның йөрәген Анастасияның гүзәллеге әсир итә һәм, бигрәк тә, хатын-кызларга гына хас үтә нәфислеге, кече күңеллелеге җанын эретә. Иоан хатын-кыз ләззәтен унөч яшеннән татый. Боярлар, аның игътибарын дәүләт белән идарә итүдән читкә борырга теләп, бертуктаусыз «мәхәббәт җимешләре» белән очраштырып торалар үзен. Шуңа күрә, яшь патша сөяркәләрен көн дә диярлек яңадан яңага алмаштыра. Беренче мәртәбә «законлы» өйләнүенә кадәр боярлар аңа дүрт ел эчендә берничә йөз кыз кочтырып өлгерәләр. Әлбәттә, аларның күпчелеге мәхәббәт сихерен яхшы белүче, бик нык шомарган һәм азгын кыз-кыркыннар була: алар кыланчыклык һәм ясалма дәртлелек белән генә тәҗрибәсез патшаның күңелен яуларга тырышалар. Чөнки Иоан турында боярлар арасында, ул ут чәчеп торган дәртле хатыннарны гына ярата, дигән фикер туган була.

Әмма балачагы нинди генә гарип хәлләрдә үтмәсен, яшь патшаның йөрәк түрендә, сүнәр-сүнмәс кенә булса да, тыныч бәхеткә сусаган бер очкын пыскый. Йола буенча оештырылган «кәләш күрсәтү» мәҗлесендә ул, кияү буларак, бар халыкны шаккаттыра: бөтен патшалыктан махсус җыеп китерелгән чибәр бояр кызлары, кыланчыкланып елмаеп, аның игътибарын яуларга тырышалар һәм моның өчен алар нинди генә чаралар кулланмыйлар, ә ул тыйнаклыгы аркасында башкаларның мыскыллап елмаюларыннан башканы күрмәгән Захарьинаны сайлап ала.

Гадәттәгечә шаулатып, зиннәтле туй бәйрәме үткәрәләр. Һәркем кызыксынып, хәзер патша нишләр икән, дип көтә.

...Бер атна эчендә патша танымаслык булып үзгәрә. Аюлар һәм шамакайлар катнашкан кыргый уеннар бетә, патша сараена тулган җинел холыклы кыз-кыркын юкка чыга, оятсыз җырлар тынып кала. Иоан хәзер һәркем белән ягымлы итеп сөйләшә, кытлык кичергәннәргә юмартларча ярдәм итә. Ул хәтта зиндан һәм төрмәләрдә интеккән күп кенә тоткыннарны иреккә чыгара. Патшаның болай үзгәрүен аның яшь хатыныннан күрәләр. Анастасия, чынлап та, бөтен җаны-тәне белән аңа уңай тәэсир итәргә тырыша; әмма, ул теләгенә ирешсә дә, киләчәк көннәр боларның барысының да бүтән сәбәп аркасында булганлыгын ачык күрсәтә: Иоанга тыныч гаилә тормышының элекке типтереп яшәвеннән, җир белән күк кебек, аерылып торуы ошаган — бары шул гына. Бу — аның йөрәк түрендә сүнеп бетмәгән теге очкынның беренче һәм соңгы тапкыр дөрләп алуы гына булган икән.

Югарыда әйтеп үткәнчә, Иоан гаилә тормышы кушканча яшәүгә ике атна гына түзде. Март аеның беренче көннәрендә ул кинәт танымаслык үзгәрде һәм, иң гаҗәбе дә шунда, моңа бер сәбәп тә юк иде. Беркөнне иртән ул йокы бүлмәсенә кизү торучы боярны чакыртып алды. Анастасия, тыйнак кына итеп, патша хатыны түшәктә яткан җиргә ят ир кешене кертү килешми бит, дип әйтеп куйды.

Иоан тупас шаркылдап көлеп җибәрде:

— Синме инде ул патша хатыны?! Элек тә Настька Захарьина идең син, хәзер дә шулай калдың. Телим икән, шушы ук секундта монастырьга ябам да үземне бүтәнгә өйләнәм!

Мондый нәрсәне һич көтмәгән Анастасия ирексездән әкрен генә «ой!» дип кычкырып куйды һәм җылап җибәрде. Шулвакыт чакыртылган боярин килеп керде. Ул бик уңайсызланды. Чөнки патшаныкына гына түгел, хәтта гади боярларның йокы бүлмәләренә дә чит кешеләрне кертү катгый тыела иде. Боярин, ишек катында туктап, бил бөгеп сәлам бирде һәм патшаның әмерен көтә башлады.

— Менә нәрсә, Семен Федорович! — диде аңа Иоан, түшәгеннән күтәрелә төшеп. — Әйт анда, аюларны әзерләсеннәр. Күңел ачасы килә башлады.

Анастасия дерт итеп куйды. Андый «уеннар»ның нинди коточкыч хәлләр белән беткәнен бик яхшы белә иде ул һәм, патша алардан мәңгегә баш тартыр, дип өметләнә башлаган иде. Боярин кабат бөгелеп баш иде һәм чыгып китте. Киләчәктә патшаның шундый «уеннар»ының бер корбаны булачак Оболенский иде ул.

Боярин чыгып киткәч, Анастасия Иоаннан бу ниятеннән баш тартуын ялварырга тотынды.

— Исеңә төшерче, падишаһым, — диде ул, — моңа кадәр ничек әйбәт яшәдек ич. Бөтен нәрсә аяз күк кебек якты һәм тыныч иде.

— Гарык мин бу тыныч тормыштан, — дип җавап бирде Иоан, түшәгеннән торып. — Көн дә бер үк нәрсә. Элек ничек булган, киләчәктә дә шулай яшәячәкмен.

Ул, Анастасиянең иркәләп ялынуына илтифат итмичә киенеп, дәшми-тынмый чыгып китте.

Шул ук көнне иртән патша мәйданында «уен» үткәрелде. Патша ул «уеннар»га үзен нәрсә көткәнне белмәгән кешеләрне «катнаштырырга» ярата иде. Гадәттә, анда бистә кешеләрен, бигрәк тә ерактагырракларыннан чакыртып китертә торган иделәр. Бу юлы да шулай иттеләр. Кирәк чакта туры килә бит, нәкъ шул көнне Мәскәүгә ерак бистәдән, ниндидер дәгъвалы эшләрен җайлар өчен, берничә кеше килгән иде... Аларга, сезнең белән патша үзе сөйләшергә тели, дип барып әйттеләр. Бистәчеләр шундук каушап төштеләр һәм, иң яхшы кафтаннарын киеп, Кремльгә ашыктылар. Аларны туп-туры патша мәйданына китерделәр, ә анда боярлар, дьяклар, сарай хезмәтчеләре һәм гаскәриләр җыелган иде инде. Кызыл болдыр дип аталган сарай ишеге төбе биек тимер рәшәткә белән уратып алынган. Анда патшаның иң якын кешеләре басып тора. Бистәчеләрне болдыр каршына китереп бастырдылар. Аларны шундук сөңге тоткан гаскәриләр тыгыз боҗра булып уратып алды. Ул арада Кызыл болдырда ыгы-зыгы башланды. Берничә яшь сарай сакчысы биек итеп эшләнгән зур тәхет алып чыгып, югарырак урынга куйды. Алар артыннан Иоан үзе дә чыкты. Бөтен мәйдан аны сәламләп кычкыра башлады, патша моңа сизелер-сизелмәс баш кагу белән җавап бирде. Ул, тәхетенә утырып, үзе янына яшь Басмановны чакырып алды һәм ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Башла, — диде.

Басманов алгарак чыгып басты һәм, бистәчеләргә мөрәҗәгать итеп:

— Бөек Государь, бөтен Русиянең патшасы Иоан Васильевич сезгә, бистә кешеләре, мәрхәмәт күрсәтә, — диде. Бистә кешеләре ашыга-ашыга җиргә тезләнделәр.

— Ә мәрхәмәте аның менә нинди: Государь сезгә үз күзләре алдында уенда катнашырга мөмкинлек бирә.

Басманов кемнәргәдер, башларга кушып, ишарә ясады. Бистәчеләрне уратып алган сөңгечеләр боҗрасы бер урында өзелде. Менә шул ачыклыкта иләмсез зур өч көрән аю күренде. Ерткычларны, борын тишекләре аша уздырылган боҗрага беркетелгән озын чылбырлар белән тотып, мал караучылар алып килгән иде... Мондый «уеннар»га күнеккән ерткычлар түземсезләнеп алга омтылдылар. Аюларны күргәч, бистә кешеләре кычкырып җибәрделәр һәм таш кебек катып калдылар. Басманов тагын кулы белән ишарә ясады: мал караучылар чылбырларны кулларыннан ычкындырдылар һәм шуны гына көткән кибәндәй зур гәүдәле ерткычлар корбаннарына ташландылар. Бистәчеләрне саклап торган боҗра, ерткычларны эчтә калдырып, кабат йомылды.

Бистәчеләр, котлары алынып, качу юлын эзли башладылар, ләкин беркая да китәрлек түгел иде: алар да, аюлар да тыгыз боҗра эчендә һәм, кай якка гына ташланмасыннар, гаскәриләрнең очлы сөңгеләренә барып төртеләләр иде. Аюлар корбаннарын күз ачып йомганчы куып җиттеләр. Үлем ачысын тоеп, соңгы чиккә җиткән коралсыз бистәчеләр ялангач кул белән сакланырга маташып карадылар, төрле якка ташландылар, җирдә тәгәрәделәр, ярдәм сорап акырыштылар-бакырыштылар. Арка үзәкләрен өшетердәй бу күренешне тыныч кына күзәтеп торган патша кычкырып көлеп җиберде. Аңа боярлар хоры кушылды. Дьяклар һәм башка ваграклар, үз дәрәҗәләрен белеп, түбәнчелек белән хихылдаштылар, әмма аларның

һәрберсенең үз жаны да уч төбендә иде: бистә кешеләре өлешенә тигән «бәхет» аларның үзләрен дә һәркөн сагалап тора иде.

«Уен-көлке» озакка сузылмады. Аюлар бистә кешеләрен, берәм-берәм бәреп егып, сыта башладылар. Шартлап сөякләр сынганы ишетелде. Ерткычлар, корбаннарының баш чүмечләреннән көчле тырнаклары белән эләктереп, күнеккән осталык белән тиресе-ние белән чәчләрен кубарып төшерделәр. Мәйдан ташларына кара кан чәчрәде, җир бөгәрләнеп-изелеп беткән гәүдәләр белән тулды. Алар һаман кыймылдыйлар иде әле. Иоан күзләреннән яшь чыкканчы рәхәтләнеп көлде.

Ниһаять, «уенны» аюлар үзләре туктатты. Читлекләренә кире алып китүләрен көтеп, иреннәрен ялый-ялый, читкә чыгып утырдылар. Патша, урыныннан торып, сарайга кереп китте. Боярлар да аның артыннан иярделәр. Мал караучылар чылбырларны кулларына алдылар, мәйдан бушый башлады.

«Уен-көлке»дән патша туп-туры төшке ашка керде. Туйдан соң ул, сарайда кабул ителгән йоланы бозып, хатынынннан аш өстәле артына утыруны таләп итә башлаган иде. Гадәттә, патша хатынын бу турыда алдан ук кисәтеп куялар иде, шуңа күрә ул, аш залына иреннән алдарак кереп, патшаны аягүрә торып сәламләп каршы ала торган иде. Иоан бу юлы аш палатасына керде һәм туктап калды. Ялчылар белән сарай кизүчеләреннән башка анда беркем дә юк иде. Ул кашларын җыерды һәм беркемгә дә туры төбәмичә:

— Патшабикә кайда?— дип сорады.

Сарай кизүчеләренең икесе җан-фәрманга патша хатыны теремына ташландылар. Бернича секундтан алар, кире урап кереп, патшабикәнең авырып торуы турында хәбәр иттеләр.

— Сафсата!— дип кычкырды патша.— Монда чакыртырга. Риза булмаса, көчләп китертергә!

Анастасия, чынлап та, чиргә сабышкан иде. «Уеннар»ның сарай каршындагы мәйданда үткәрелүен белмичә, ул үзенең бүлмәсендә тәрәзә янына барып басты һәм аста кешеләргә аю өстерүне күреп калды. Бу коточкыч күренеш аны шулкадәр нык тетрәтте ки, шундук чиргә сабышты. Әмма, авыр хәлдә булуына карамастан, буйсынырга туры килде аңа. Патшабикә, кайнар битен салкынча су белән чылатып алды да, көч-хәл белән аякларын атлатып, аш бүлмәсенә юнәлде. Патша аны караңгы чырай белән, шикләнеп каршы алды, әмма бер сүз дә әйтмәде. Тик аның аш артындагы шаян сүзләрендә хатынына нинди дә булса бер әшәкелек эшләргә теләве нык сизелеп тора иде. Ул, шаркылдап көлә-көлә, теге мескеннәрне ерткычлардан талаткан чактагы төрле кызык урыннарны кабат-кабат искә төшерде һәм икенче мәртәбәсендә Анастасияны да үзе белән бергә Кызыл болдырга алып чыгарга вәгъдә итте. Иоан өчен бу мәҗлес тыныч гаилә тормышы белән хушлашу иде.

## 4

Өйләнгән кеше булса да, патша кабат буйдаклар тормышына күчте.

Идарә эшләренең бөтенесен дә боярларга калдырды ул, ә үз вакытын тулысынча ауга йөрүгә, канлы кырыс уеннарга, монастырьларда кунакта сыйлануларга, ә күбрәге хатын-кызлар белән «пәри туйлары» оештыруларга багышлады. Өйләнүенә өч атна үтте дигәндә, аның Мәскәүдәге сарае элеккечә хатын-кызлар белән тулды, соңгы вакытта аларның саны хәтта илледән ашты. Хәзер инде Иоан аш вакытында Анастасияның үзе янында утыруын да таләп итми. Аш палатасында падиша урынында берьюлы дистәләрчә кыз-кыркын утыра.

Алар арасында дьякларның, хәтта еш кына зур дәрәҗәле боярларның хатыннары һәм кызлары күренә. Әнә шундый юллар белән күпләр патшага якынаюга ирешәләр иде. Мисалга, мәсәлән, бары тик кызының гадәттән тыш чибәрлеге аркасында гына Шемурин исемле бер дьяк, бояр дәрәҗәсенә күтәрелеп, дан алуга ирешә. Анастасия хәзер, гомумән, ире өчен арткы чиратта калды. Дөрес, кайчагында әле дә Иоанның күңелендә аңа карата нииндидер җылылык кебек нәрсә уянып куя һәм ул, элеккечә иркәләп һәм түземлек белән, аның зарларын тыңлый, андый көннәрдә аш вакытында янына чит хатыннар кертүне тыя һәм үз хатынын чакырта, әмма мондый ләйсән яңгырлы минутлар сирәгәйгәннән-сирәгәя бара иде. Анастасия озакламый дәүләт башында торган иренә булган элекке йогынтысыннан бөтенләй кире кайтарып алалмас колак какты.

Әнә шулай бер ел үтеп китте. Иоанның үз-үзен тотуы тагын да сәеррәк була барды. Хәзер аның ярсуын чыгару өчен юк кына сәбәп тә җитә иде. Киләсе минутта аның нишләячәген беркем дә әйтеп бирә алмый: чөнки ул һәрвакыт шушы мизгелдәге капризы яисә шул секундта алган тәэсир астында эш итә иде. Бервакыт Анастасия, ил тоткасы булган иренең кәефе күтәренке чагыннан файдаланып, үзенең якын туганнарының берсен сарай хезмәтенә алуны үтенде. Ни өчендер аның бу

кечкенә үтенече патшага бик шикле күренде. Ул, йодрыклары белән ташланып, Анастасиягә берничә мәртәбә каерылып сугып җибәрде һәм тирән мәгънә белән:

— Ярый, син дигәнчә булыр,— дип чыгып китте.

Икенче көнне падишаның телгә алган туганын сарайга алып килделәр һәм аңа шамакай киеме киендерделәр...

Мәҗлес көйләнгән эзеннән дәвам итте. Ә ике сәгатьтән «уен-көлке» мәйданында шамакай Василий Захарьинның иң усал аю сытып-өзгәләп бетергән канлы гәүдәсе ята иде инде.

1547 елның 11 апреле иде ул көн. Икенче көнне бөтен Мәскәүне ялкын чорнап алды һәм дәһшәтле ут өермәсе өч ай буе дәвам итте... Мәскәү халкы янгын чыгуда азгын боярларны гаепләде. Куркып калган Иоан типтерүләрен онытырга мәҗбүр булды. Коточкыч гарасат аның зиһенен томалады. Азгын хатын-кызлар белән үткәрелгән «пәри туйлары» һәм канлы «уен-көлкеләр» бетте. Патша көнетөне дога кыла башлады, руханилар белән озын-озын әңгәмәләр корды. Мондый үзгәрешләр Анастасияны бик нык шатландырды, өстәвенә, ул яңа туган малае Дмитрий белән мәш килә иде. Әмма яшь патша малаеның гомере озын булмады — ул, биш яше дә тулмас борын, фаҗигале үлем белән үлеп китте. 1557 елда аның икенче улы, Федор Иоанович, дөньяга килде. Икенче баласын табу тыйнаклыгы һәм гади халыкка карата юмартлыгы белән матур даны таралган Анастасияның боярлар алдындагы абруен тагын да ныграк күтәрде. Шул чорларда патшаның күңелендә үзенең балачагын гарипләткән боярщинадан рәхимсез үч алу теләге ярала башлады.

1560 елның 7 августында Анастасия патшабикә кинәт дөнья куйды. Үлем түшәгендә ул өч кенә тәүлек ятты: хәтта иң танылган имчеләр дә аның нидән сырхаулавын ачыкларга өлгермәделәр.

Анастасияны җирләгәннән соң, Иоан атна буе, беркем белән дә очрашырга теләмичә, үз бүлмәсендә ялгыз утырды, хәтта иң якын боярларына да күренмәде. Ул Анастасияның вакытсыз үлемен чын йөрәктән авыр кичерде. Ниһаять, кабул итү залына чыкты: боярлар каршында бөтенләй башка кеше басып тора иде. Утыз яшьлек патша ак сакаллы карт кебек бөкерәйгән, аның тирән җыерчыклар белән ергаланып беткән йөзе лимон кебек саргайган. Төпкә баткан нурсыз күзләре, тынычлык таба алмыйча, әле бер якка, әле икенче якка йөгереп торалар; аларда, залда утыручыларның арка үзәкләрен өшетеп, ниндидер шомлы ялкын ялтырап китте. Нәкъ әнә шул көннән инде Иоан патшаның «Явыз» дигән каһәрле кушамат алган яңа тормышы башлана. Рәсәй тарихында да шул көннән яңа чор килде.

5

...Озакламый Иоанның соңгы елларда тыелып торган инстинктлары, йөгәннәрен салып атып, кабат калкына башлады. Күпне күргән Кремль диварларының моңа кадәр Анастасия вафатыннан соң палаталарда патшалык итә башлаган вәхшилекне һәм азгынлыкны үзенә сыйдырганы юк иде әле. Бөтен сарай тоташ бер гарәмгә әйләнде. Алай гына булса бер хәл, патшаның һәр бояры шунда барган «пәри туйлары»нда катнашырга мәҗбүр иде. Хөкем сөргән бу ямьсез йолага буйсынырга теләмәүчеләрне әшәке үч көтте.

Иң элек Иоан, Анастасия патшабикәне җирләгәннән соң бер атна үткәч тә, дуубарып дөнья күрмәгән зур мәҗлес оештырды: анда, патшаның якын түрәләреннән башка, сарайга алданрак җыеп китерелгән хатын-кызлар да катнашты. Мәҗлес ахырына таба чын мәгънәсендә вәхшиләр оргиясы башланды. Патшага ялагайлана торгач, боярлар бөтенләй әдәп дигән нәрсәне оныттылар. Арада берләнбер карт кенәз Оболенский гына, бернәрсәгә дә катнашмыйча, шундагы хәлләр өчен оялып утырды. Иоан түзмәде, аннан, нишләп башкалар кебек күңел ачмыйсың дип сорады.

— Государь!— дип җавап бирде карт кенәз калтыранган тавыш белән.— Карт көнемдә бөек рус патшасының әдәм көлкесенә әйләнүен күрү бик авыр миңа һәм минем үземнең дә хурлыкка төшәсем килми. Күзеңне ачыбрак тирә-ягыңа карале: патша өстәле артында җыен ләх исерек һәм азгын кызлар утыра. Синең палатаңны шулар бизәргә тиешмени?! Һич югында үзеңнең атаңны, Василий Ивановичны, хәтереңә төшер! Ул барында мондый хурлыкның бездә булганы юк иде. Җитди кешеләр олпатлык саклап ашап утыралар иде монда, акыллы әңгәмәләр коралар иде алар, ә исерекләрнең кыргыйларча шаркылдашуы, оятсыз җырлары кебек нәрсәләрнең ишетелгәне булмады. Башымны кисәргә кушсаң куш, әмма минем җаным мондый түбәнлекне күтәрә алмый!

Иоан кинәт агарынды. Иреннәре кисәк-кисәк тартыша башлады. Ләкин ул үзүзен тыеп калды һәм ясалма ягымлылык белән:

— Патшалыгыбызның абруе турында кайгыртканың өчен рәхмәт сиңа, Иван кенәз,— диде.— Әтиемә тугрылыклы хезмәт иттең син. Һәм мин үзем дә синең кылган яхшылыкларыңа зур бәя бирәм. Бүгенгә кайтарып җибәрәм мин сине. Иртәгә төшке аш вакытында кил, бүтән төрле сый белән сыйлармын үзеңне.

Оболенский, бил бөгеп хушлашып, чыгып китте.

Икенче көнне, төшкелек җиткәч, карт кенәз сарайга килде. Аны аш палатасына уткәрделәр. Анда аны патша белән берничә яраны каршы алды. Хатын-кыз заты юк иде. Патша аны, ачык йөз белән олылап, үзе янына утыртты, үз кулы белән аның алдына затлы ризыклар куйды. Мәҗлеснең дуены җиткәндә, хезмәтчеләр хәмер өләшә башлагач, патша Оболенскийга «олы чәркә» китерергә кушты. Бу — кунакка зур хөрмәт күрсәтү санала иде. Бер хезмәтче көмеш кунага куелган алтын савыт белән мөлдерәмә тулы эчемлек китерде һәм, идәнгә кадәр диярлек бөгелеп, кенәзгә тәкъдим итте. Оболенский, торып басып, савытны кулына алды, бөгелеп патшага рәхмәтен белдерде һәм йола кушкан буенча савытны бер йотуда бушатып куйды. Ләкин эскәмиясенә кире утырырга өлгермәде, аның авызыннан канлы-сары күбек бәреп чыкты. Ул кинәт чайкалып китте һәм, авыр гәүдәсе белән гөрселдәп, идәнгә ауды. Кулындагы алтын чәркәсе зыңлый-зыңлый идән буйлап тәгәрәде.

— Шатлыгыннан бөтенләй исерде дә кенәз,— диде патша мыскыллы тавыш белән.— Чыгарып атыгыз шуны.

Оболенскийның гәүдәсен күтәреп алып чыгып киттеләр. Һәм шул секундта аш палатасына кәефләнеп өлгергән хатын-кызлар кереп тулды: сыйлану нәкъ кичәгечә дәвам итте.

Оболенский үчен алганнан соң берничә көн узгач, Иоан патша Репнин дигән кенәз белән дә үзенчә исәп-хисап ясады. Бераз вәхшиләрчә күңел ачкач, ул көнне патша музыкантлар чакыртты һәм төрле маскалар китерергә кушты. Үзе иң ямьсез шамакай битлеге киде дә шашып биергә тотынды. Моны карап торган Репнин кенәз, гарьлектән тыела алмыйча, елап җибәрде. Иоан аның янына йөгереп килде һәм аның битенә дә маска кидерергә теләде. Кенәз, масканы патша кулыннан тартып алып, аяк астына салып таптады:

— Патшага килешә торган эшмени бу?— диде ул җан ачысы белән.— Син үзең аңламасаң, мин, боярың һәм дума киңәшчең, шамакайланырга теләмим!

Иоан шунда, яшен тизлеге белән бил каешыннан суырып алып, хәнҗәрен картның ябык күкрәгенә батырды.

Мондый кан коюлар көн дә диярлек бер-бер артлы булып тордылар. Боярларның күңеленә курку төште. Хәзер аларның берсе дә сарайга киткәндә өйләренә кире исән әйләнеп кайтачагын белми иде. Арада иң атаклылары үзара киңәш тота башладылар. Бәхәсләшә торгач, патшаны икенче тапкыр өйләндерергә кирәк дигән уртак бер фикергә килделәр. Анастасия исән чагында патшаның, бозыклыкларының бөтенесеннән дә баш тартмаса да, болай артык кансыз кыланмаганын яхшы хәтерли иде алар...

Черкас кенәзе Тәмгрук кызына Иоан патша әнә шул чорда өйләнде.

Никах мәҗлесен 1561 елның 21 августында үткәрделәр.

Әмма яңа патшабикә Мария йомшак күңелле Анастасияның бөтенләй капма-каршысы булып чыкты. Кавказ таулары арасында туып үсеп, ерткыч хайваннар ауларга һәм башка төрле шундый куркыныч нәрсәләргә күнеккән чибәр хатын җаны-тәне белән шау-шулы тормышка омтыла иде. Кызлар ягындагы вак-төяккә чумган тыныч тормыш кына аны канәгатьләндерми иде, әлбәттә. Мария бик теләп аш бүлмәсенә үзе килеп керә, ирләр белән бергә шатлана-шатлана, аю өстерүләрдә катнаша һәм хәтта, боярларның котын качырып, Кремль диварлары өстеннән Кызыл мәйданда махсус оештырылган кеше җәзалап үтерүләрне дә бик рәхәтләнеп күзәтеп тора. Ул Иоанны, канлы «уеннар»дан тыясы урынга, шундый нәрсәләргә үзе этәрә иде. Шуңа күрә, боярларның аны озакламый күрәлми башлаулары яхшы аңлашыладыр. Иоанның күптәнге якын кешесе һәм киңәшчесе Адашев бояр, ничектер бервакыт кыюлыгы җитеп, Мәскәү патшабикәсенә канлы «уен-көлкеләр»дә катнашу, биек дивар өсләренә менеп йөрү килешми, дип ычкындырды. Алексей Адашев шул сүзе өчен икенче көнне үк ерак сөргенгә сөрелде. Иоан Адашевны, бары тик аның көчле дуслары күплеген истә тотып кына, исән калдырды, чөнки халык арасында үзе өчен куркыныч шау-шу күтәрелүе мөмкин иде.

Марияны боярлар күрәлмәсәләр, Мария да аларга шундый ук нәфрәт белән җавап бирде. Патшаны үзенә ныграк бәйләп тотарга теләп, ул аның фәхешлегенә үзе юл ача иде. Моның өчен Мария үз тирәсенә иң гүзәл кызларны җыйды һәм күзеннән читтә калганнарны иренә тәкъдим итә башлады. Хәзер инде элек ирс ясаганга охшаган «пәри туйлары» падиша теремына да күчте, ә моңа кадәр андый хәлнең сарайда гомергә булганы юк иде. Шулай итеп, икенче мәртәбә башлы-күзле булгач, Иоан тагын да йөгәнсезрәк уйнашчы юлына басты. Мария, иренең фәхешлеген хуплау белән бергә, үзе дә ким-хур утырмады. Ул үзе дә, Иоанның күз алдын-

да ук диярлек, көн дә соярка алыштырып торды. Хәмер эчә-эчә һәм төрле бозык юлларда йөреп мие томаланган патша берни дә сизми иде. Әгәр дә берәрсе, кыюлыгы житеп, хатынының кыланышы дәүләттә тоткан биек урынына килешми, дип патшага бу турыда ишарәли башласа, Мария шундук чарасын күрә: яисә кыюбашларның муены гына тырпаеп кала, яисә аны кош очып житә алмаслык ерак сөргенгә сөрәләр иде.

Иоанга Мариянын йогынтысы көннән-көн арта барды. Ул анын барлык йомшак якларын өйрәнеп бетерде һәм шуннан бик оста файдалана иде. Опричнинанын барлыкка килүенә Рәсәй, башлыча, Марияга бурычлы. Патша элегрәк тә бояр халкына бик нык шикләнеп карый иде, ә инде Мариянын йогынтысына эләккәч, ул аларнын һәрберсенә үзенә явыз дошманлык эзли башлады. Анын тирәсендә хәзер бөтенләй башка кешеләр: Малюта Скуратов, Федор Басманов, кенәзләрдән Афанасий Вяземский, Бельский, Василий Грязной һәм башкалар бөтерелә башлады... Беренчеләрдән булып, Иоанга «фетнәчеләргә каршы көрәшер өчен» махсус дружина төзергә Вяземский кенәз тәкъдим итте. Бу дружинага, әлбәттә, башлыча «иң яхшылар», ягъни патша тирәсендә соңгы вакытларда бөтерелә торган кешеләр керергә тиеш иде. Вяземский белән Грязной, Иоанны тизрәк үз якларына аударыр өчен, ашыгыч рәвештә киң тамыр җәйгән фетнә «ачтылар»: боярларның күбесе фетнә башында тора, янәсе. Дөньяда эзе дә булмаган «фетнә»не алар шулкадәр кара буяулар белән тасвирлап, сөйләп бирделәр ки, болай да теләсә кемнән бик тиз шикләнүчән, куркак патша, астына шыр җибәреп, Коломенскоега чыгып ычкынды, ә аннан озакламый Тайнинское авылына күчте. Мария да аңардан калмады, әлбәттә. Тайнинскоега тиз арада, гаҗәпкә калган руханилар белән боярлар киңәше белән, вәкилләр китте. Алар бөтен халык исеменнән патшаны Мәскәүгә кайтырга димләделәр. Иоанның башта ишетәсе дә килмәде. Бер ай буе ул, 1565 елның 3 гыйнвареннан 2 февральгә кадәр, качып яткан өненнән кузгалмады да. Ниһаять, ул, әгәр дә боярлар аның шартларына риза булсалар, дип, тәхетенә кайтып утырырга ризалыгын бирде. Бу вакытта утыз яшьлек патшаны танырлык та түгел иде: бөкрәеп беткән житмеш яшьлек картны хәтерләтә иде ул. Боярлар, нишләсеннәр, ризалыкларын бирделәр. Һәм патша Кремльгә кайтып төште. Каршы алырга җыелган халкы патшаны күреп шаккатты: әйтерсең лә, аның бер генә чәч бөртеге дә калмаган шәрә башына саргылт тире тарттырып куйганнар! Маңгае астындагы тирән чокырларда өметсезлеккә төшкән тонык күзләр шәлперәеп каткан. Ләкин тыштан карaганда хәлсез күренгән ябык гәүдә эчендә рәхим-шәфкатьнең нәрсә икәнен белмәгән явыз җан ашкынып торганын сизмиләр иде әле алар. Мәскәүгә кайтуына бер атна үтәр-үтмәс, патша боярларга үзенең вәгъдә иткән «шартлар»ын житкерде һәм теләләр аһ иттеләр.

Аһ итмәслек тә түгел иде шул: Иоан үзенә бер мең тән сакчысы билгеләп куя һәм аларны «опричниклар» дип атый. Бу булды бер. Шуңарга өстәп, дәүләтнең егермеләп иң бай шәһәрен һәм Мәскәүнең бик күп урамнарын үзенең шәхси биләмәсе итә. Рәсәй патшалыгы белән Мәскәүнең үзенә тигән шул өлешләренә «опричнина» дигән атама бирә. Һәм үзен аларның бердәнбер тулы хокуклы хуҗасы дип игълан итә. Ә дәүләтнең үзеннән арткан җирләрен, «земщина» дип атап, боярлар карамагына калдыра. Бу булды ике. Әмма патша ясагы моның белән генә бетмәгән иде: дәүләтне, алда әйткәнчә, ике өлешкә бүлгәнче үк, «земщина»ның булачак хуҗалары патшага, Тайнинскоеда качып ятарга мәҗбүр булганы өчен, йөз мең тәңкә алтын акча түләргә тиешләр: ә бу — ул заман өчен колак ишетмәгән, күз күрмәгән чиксез зур байлык иде. Ләкин боярларга чигенергә урын калмаган иде инде — килешү шартларын алдан билгеләмичә, үзләре сукырларча ризалык биреп ташладылар ич.

Каен чырасын шәм итеп тоткан надан Рәсәйдә «канлы опричнина» чоры әнә шулай башланды.

Опричникларның башлыклары, халыкка кылган этлекләре өчен җавап тотарга туры килмәсен өчен, көн саен диярлек патшага яңа фетнә «ачулары» турында исәп-хисап биреп торалар иде. Тора-бара бу «ачышлары» белән опричниклар патшаның котын ботына төшерделәр: Иоан Мәскәүдән бөтенләй китәргә карар кылды һәм озакламый Александровский бистәсенә күченде. Опричникларның хәйләсен — алар моны, рәхәт тормышта яшәп, үзләренең кирәклеген исбат итәр өчен генә эшлиләр иде — яхшы белеп торган Мария, ире белән китәргә теләмичә, Кремльдә калды. Иоан моңа кул гына селтәде. Хәзер аңа Мариянын дөньяда булуы-булмавы барыбер иде. Ул үзенә, элеккеләреннән дә зуррак итеп, әр-яңа гарем булдырды һәм анда май эчендә йөзгән кебек рәхәттә яши бирде. Элек тә бик тартынып тормаган Мариясы, ире янында булмагач, хәзер бөтенләй авызлыгын салып ташлады: ул да үзенең канында булган барлык азгын инстинктларына ирек куйды. Кремль сараеның хатын-кызлар теремында хәзер үзе шунда чакта башкала күргән оргияләрдән калышмаган «пәри туйлары» котыра башлады... Мондый очракларда, гадәттә, халык арасында төрле имеш-мимешләр, гайбәтләр тарала. Гайбәткә киртә юк бит.

Мария белән дә шулай булды: имеш, ул «ирләр арасында бөтенләй анадан тума шәрә йөри, имеш тә сарай бүлмәләрендә утыздан артык сөяркә һәм аларны һәр төн саен берәм-берәм үзе янына чакыртып ала икән» кебек сүзләр патша колагына да барып җитте.

— Патшабикәне таныйм!— дип көлде генә Иоан, моны ишеткәч.— Әйдә, күңел ачсын рәхәтләнеп. Ә без ходайдан аны ярлыкавын теләрбез.

...Әмма Иоан, азгын кыланышларына ничек кенә битараф булмасын, Мариянең бер генә адымын да үз игътибарыннан читтә калдырмады. Ул аның сөяркәләре белән типтерүенә төкереп тә бирмәде, ә менә бервакыт шымчылары аның колагына: Мария, аны тәхетеннән бәреп төшерү нияте белән, фирка оештыра, дигән хәбәр җиткергәч, тиешле чарасын күрергә карар кылды.

Ә Мариянең күңелендә, чынлап та, шундый бер уй туа башлаган иде. Ирен тәхетеннән мәтәлдерер өчен бик кулай чак. Опричниклардан таланып, төрле «вакытлы хакимнәр» кулында соңгы чиккә җитеп бөлгән ил көчле властьны бөтенләй онытып бара иде инде: чөнки «бер сәгатьлек Калифлар» үзләре дә, берсе артыннан икенчесе, эшафотта башларыннан колак кага тордылар. Ә Александровский бистәсендә бикләнеп яткан Иоан үзе хакимлек астында яшәүчеләргә ниндидер бер җисемсез өрәк булып кына тоела башлаган иде инде. Шуңа күрә, бу вакытта аны бәреп төшерү халыкка әллә ни тәэсир итмәс иде, мөгаен. Иң беренче булып, шундый форсат барлыгы турында Марияга сөяркәләре арасыннан яшь боярин Андрей Федоров әйтте: ул аны соңгы чорда үзенә якынрак итә башлаган иде. Федоров, бөлгән нәселдән чыккан кеше булса да, дан-шөһрәт яратуы һәм үҗәтлеге аркасында Мария янына менеп җиткән иде, әмма аның мин-минлеге моңа гына риза булмады. Патша хатынының иң яраткан сөяркәсенә әйләнгәч, ул, акылын җуеп, таҗ турында да хыяллана башлады. Тагын берничә яшь бояр, шул ниятен хуплап, аңа кушылды. Әкренләп, заговор сымаграк бер нәрсә оешты. Патшаны, аның якын кешеләрен үтерү максаты белән яшерен план да туды.

Ат абзары мөдире дигән вазифа башкаручы Федоров, көн дә диярлек, Александровский бистәсендә була иде, ләкин опричниклар аны үз рәтләренә кертмәделәр. Беркөнне Иоан, күңелле итеп төшке сыйланудан соң, уен-көлке белән кәеф күтәрер өчен шамакайлар булып киенергә тәкъдим кертте.

— Шамакайлык нәрсә ул!— дип кычкырды Иоан бераздан.— Кемне дә булса патша киеменә киендерергә! Миннән башка безнең арада тагын кем патша була ала икән, күрим әле!

Патша киеме, таяк һәм таҗ китерделәр.

— Федоров, киен!— дип әмер бирде патша.

Федоров, башкаларга кушылып көлә-көлә, патша булып киенде. Иоан үз кулы белән аның башына таҗ кидерде, кулына патша таягы тоттырды һәм, җитәкләп алып барып, биек урынга тәхеткә утыртты. Шуннан соң патша, биленә кадәр бөгелеп, аңа баш иде һәм тантаналы рәвештә:

— Исәнлек-саулык телим сиңа, рус җиренең бөек патшасы,— диде.— Син теләгән нәрсәңне алдың минем кулымнан. Ләкин сине патша итү кодрәтемнән килсә, сине тузанга әйләндерү дә кодрәтемнән килә!

Шул сүзләрен әйтүгә, Иоан патша хәнҗәре белән Федоровның күкрәгенә кадады. Исерек опричниклар Федоровка ташландылар һәм, үтереп, гәүдәсен тышка чыгарып аттылар. Шул ук көнне бүтән фетнәчеләр дә юк ителде.

Федоровның үтерелгәнен ишеткәч, Мариянең җен ачулары чыкты һәм ул Иоаннан үч алырга ант эчте... Әмма патша опричникларына: Мариядан күзне язмаска, аның янына беркемне дә кертмәскә һәм аның үзен Кремльдән чыгармаска, дигән каты әмер бирелгән иде.

Патшаның боерыгы Марияга бик нык тәэсир итте. Ул, кызу канлы көньяк кешесе, җанында ташып торган дәртен түгәргә мөмкинлек калмагач, сагышыннан кара чиргә сабышты. 1569 елның 1 сентябрендә Марияны җир куенына тыктылар.

## 6

Мариянең үлеме Иоанның кәефен бозалмады. Ул хәтта кайгырган булып кылануны да кирәк дип тапмады. Бу вакытта ул инде, башы-аягы белән фәхешлеккә батып, үзенең дошманнарыннан канлы үч алу белән юана иде.

Марияны җирләгәннән соң, Иоан моңарчы күз күрмәгән «спорт» төре уйлап тапты. Опричникларын ияртеп, эре җир биләүчеләргә көтмәгәндә барып төшү ошый башлады аңа. «Очраклы гына узып барышлый» килеп керүләрен алар, әлбәттә, фетнә эзләү белән аклыйлар иде. Башта алар сарайда күңелләре туйганчы сыйланалар, шуннан соң, ләх исерек килеш, өерләре белән атларына атланып, кыргыйларча акырыша-акырыша, күзләре кая төшә, шул якка ташланалар иде. Юлларында

беренче туры килгән вотчинада туктап, «шаярып алу» көндәлек норманың бер өлеше генә була. Сүз дә юк, патшаны кайда да чиксез олы хөрмәт белән каршы алалар. Иң яхшы бүлмәгә алып керәләр, иң тәмле ризыклар белән сыйлыйлар. Әмма, аның кәефен күрер өчен чәчләре белән идән себерсәләр дә, хуҗалар өчен мондый визитлар бер генә төрле нәтиҗә белән тәмамлана: иң элек Иоан, нинди дә булса вак нәрсәгә бәйләнеп, үзенең юлдашларына хуҗаларның «кабыргаларын санап чыгарга» боера. Менә шуннан соң китә инде! Хуҗаларны, канга батырып тукмап, үтереп ташлыйлар, ләкин әлегә яшьрәк һәм чибәррәк хатыннар белән кыз-кыркыннарга тимиләр. Ирләр белән эшне бетергәч, соңгыларын патша каршына тезеп бастыралар: ул алар арасыннан берәрсен яисә берьюлы икесен үзенә сайлап ала, ә калганнарын опричникларына бирә. Кайчагында бу оргиялар ике-өч көнгә кадәр сузыла. Әнә шулай утырмага баруларны Иоан «хатын сайлау» дип атый иде.

Ә ул вакытта Мәскәү дәүләтенең хәле көннән-көн мөшкелләнә бара иде. Хатын-кызлар белән типтерүләрдән һәм уйдырма фетнәчеләрдән үч алулардан башы чыкмаган патша дәүләт эшләренә борылып та карамады. Ә шул арада Кырым ханы Дәүләт-Гәрәй зур гаскәр белән Мәскәү янына килеп җитте. Урыс гаскәрләре, көтүчесен югалткан сарык кебек, аңа каршы торырлык түгел иде. Патша, опричникларын ияртеп, Ярославлга качты. 1572 елда Кырым татарлары Мәскәүнең көлен күккә очырдылар. Дөрес, хан чигенергә мәҗбүр булды, чөнки урысларга ярдәмгә, исәпсез-сансыз гаскәр белән, Польша короле килергә чыккан, дигән ялган хәбәр таралган иде. Шулай да хан буш кул белән китмәде. «Фетнәчеләр» белән кыю сугышкан Иоан шулкадәр югалып калган иде ки, ханның бөтен кимсетелүле таләпләренә берсүзсез күнде. Берәттән, үзләре күптән түгел басып алган Әстерханны да аңа бирде. Куркаклыгы өчен Дәүләт-Гәрәй аңа җирәнеп карый иде. Рәсәй патшасына мыскыллап каравы аның үз иленә әйләнеп кайткач, Иоанга җибәргән хатында да ярылып ята иде:

«Русь дәүләтенә минем үз дәгъвам юк. Казан белән Әстерхан өчен үч алу йөзеннән генә яндырам һәм талыйм мин аны,— дип яза ул,— ә кулыма төшкән мал-мөлкәтеңне барыбер әрәм-шәрәм итеп бетерәм мин. Бөтен җирдән эзләдем мин сине: Серпуховтан да, Мәскәүнең үзеннән дә: таҗыңны тартып алып, башыңны чабарга теләгән идем, ләкин син Серпуховтан да, Мәскәвеңнән дә таеп котылдың, ир горурлыгың һәм оятың калмаган булса да, патшалыгыңның бөеклеге белән шапыринган буласың! Хәзер миңа Дәүләтеңнең юллары яхшы таныш: әгәр дә бер файдасызга Рәсәйдә тоткынлыкта асраган илчемне ирекә җибәрмәсәң, әгәр дә мин таләп иткәннәрне берсүзсез үтәмәсәң һәм миңа үзең өчен, балаларың белән оныкларың өчен ант иткән грамота җибәрмәсәң, тагын өстеңә яу белән киләчәкмен».

Патшаның болай артык нык мескенләнүенә хәтта иң якын опричникларының да ачулары кабарды. Алар патшаны тагын бер тапкыр башлы-күзле итеп карарга булдылар. Чөнки аның шулай Кырым алдында мәлҗерәп төшүен очраклы «хатыннар» эзләп табудан башы чыкмавыннан күрәләр иде алар. Патша, бик теләп, өченче никахка ризалыгын бирде. Йола буенча, тантаналы рәвештә «кәләш сайлау» оештырдылар. Бу вакытта яндырылып, көлгә әйләнгән Мәскәү кабат тернәкләнеп килә башлаган иде инде. Башкалага, бирнә кызларын ияртеп, йөзләрчә бай бояр гаиләсе килеп төште. Алдан билгеләнгән бер көнне Грановитый пулатта «кәләш карау» мәҗлесе үткәрелде. Залга, озын рәт итеп, Рәсәйнең иң атаклы чибәр кызларын тезеп бастырдылар. Менә бервакыт, таягына таяна-таяна, пеләш башлы, бөкре гәүдәле, авызында бер теше калмаган Иоан килеп керде. Ул, аякларын көч-хәл белән сөйри-сөйри, очлы күзләрен, яңа пешкән алма кебек алсу йөзле, яшь, чибәр кызларга текәп, рәт буйлап китте. Кызлар, дулкынлануларыннан дер калтыранып, тыйнаклык саклау йөзеннән, күзләрен идәнгә төбәп басып тордылар. Менә бервакыт патшаның картларча тоныкланган күзе үзенә туп-туры карап торган күзләр белән очрашты. Какча гына гәүдәле, әмма бик тә зифа буйлы бер кыз, әз генә дә курыкмыйча, аңа карап тора иде.

— Бик кыю!— диде патша, гүзәл кыз каршында туктап.— Атың ничек?

— Марфа, Сабуров кызы,— дип ачык итеп җавап бирде кыз.

Патша, яңадан бер сүз дә әйтмичә, алга үтте. Ә чирек сәгатьтән дума бояры патшаның хатынлыкка Марфа Сабурованы сайлап алуын игълан итте.

Сабуровлар дигән боярлар нәселе (Татар нәселе.— Тәрҗ. иск.) атаклыгы белән аерылып тормый иде. Кәләшнең атасы Иван Сабуров, патшаның лачынчысы саналса да, чынында, сарайдан читләшеп, күбрәк үзенең эрактагы биләмәсендә яши иде. Патшаның аның кызын сайлавы бояр өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Тиздән аларның Мәскәүдәге кечкенә өйләрендә ашыгыч әзерлек башланды. Нәкъ шул чорларда Иван Сабуров янына күптән түгел үлгән Марияның бертуганы — Михаил Тәмгрүк кенәз килеп йөри иде. Тора-бора ул алар йортында үз кеше булып китте. Әкренләп Марфа аңа шактый ияләшеп өлгерде. Беркөнне кичтән Тәмгрүк бояр кызына күчтәнәчкә берничә шикәрләнгән җимеш алып килде.

— Патша өстәленнән бу, бүгенге төшке аштан,— диде ул.

Марфа, аны-моны уйламыйча, күчтәнәчне кабул итте. Шул көннән башлап ул, болай да какчалыгы белән аерылып торган кыз, күзгә күренеп сула башлады. Өстәвенә, аңа ниндидер өянәк ябышты. Бу күңелсез хәбәрне шундук патшага җиткерделәр, әмма ул, бернигә дә карамастан, Сабуровага өйләнәчәкмен, дип кырт кисте.

Туй үтте. Ә ике атнадан Марфаны җирләделәр.

Үч алуларга чират җитте. Патша Марфаның сәер чиренең яшь Тәмгрүк кенәз шикәрләнгән җимешләр бүләк иткәннән соң башлануын ачыклады. Михаилны очлы казыкка утырттылар. Аңардан башка, бу эштә шикле күренгән тагын берничә боярны җәзалап үтерделәр.

## 7

Марфа Сабурованың үлемен Иоан чын йөрәктән авыр кичерде. Бәлки, аны бу өченче хатыны туйдырып өлгермәгән булгандыр. Ике атна буе ул берьялгызы яшәде; бары тик Малюта Скуратов кына, көненә берничә тапкыр аның янына кереп, Марфаны үтерүдә гаепләнгән кешеләрдән сорау алуларның нәтиҗәсе турында җиткереп торды.

Ниһаять, патша кабул итү палатасына чыкты. Бу турыда алдан кисәтелгән опричнина башлыклары һәм исән калган боярларның барысы да сарайга җыелдылар. Пыш-пыш сөйләшүдән палата гүләп тора: соңгы вакыйгалар турында фикер алышу бара. Скуратов аларга патшаның «җаны бер дә таза түгел», дип әйтеп өлгергән иде инде, ә бу — Иоанның кәефе бик начар чагы дигән сүз, шуңа күрә аннан бүген теләсә нәрсә көтәргә була. Боярлар, эчтән дер калтырап, җан саклап калу кайгысында утыралар иде.

Менә эчке яктан бүлмә ишекләре ачылып китте. Аннан кораллы ике сакчы чыгып, тәхет куелган биек урын янына барып басты. Палатада шылт иткән тавыш та калмады. Берничә секундтан эчке яктан әкрен генә чыштыр-чыштыр атлаган аяк тавышлары ишетелде һәм ишектә патша күренде. Аны күргәч, хәтта аның иң якын җан дуслары саналган Басманов, Колтовский һәм башкалар эчләреннән аһ итеп куйдылар. Тәхет янына, шомлы өрәк кебек, ниндидер җан иясе якынлашып килә кебек иде. Иоанның өстендә кара каеш белән билдән буылган руханилар җиләне. Башында очлы бүреге биек булып калкып тора. Уң кулында — гадәттәге озын таягы. Идәнгә кадәр салынып төшкән монах мантиясе артыннан сөйрәлеп килә. Тирән җыерчыклар белән ергаланып беткән һәм, каны качып, саргайган йөзендә җан әсәре калмаган. Күз уемнары, мәетнең баш сөяге тишекләре кебек, каралып тора: тик аларның төпләрендә генә нурсызланып сүнеп беткән күзләре, тонык кына пыскып, ялтырыйлар иде.

Ул беркемгә дә игътибар итмәде, хөрмәт күрсәтү йөзеннән бил бөгеп сәламләүләргә дә җавап бирмәде, бөкрәйгән килеш алга үтте һәм, авырлык белән биек урынга менеп, тәхетенә чумды. Тынлык озакка сузылды. Иоан күзләрен йомды һәм залда җыелганнарга ул йокыга китә башлаган кебек тоелды. Әнә шулай берничә минут дәвам итте. Менә кинәт Иоанның күз кабаклары югары күтәрелде һәм аның күзләрендә барысына да яхшы таныш булган усал очкын ялтырап узды. Ул күз карашы белән тиз генә каршында басып торган кешеләрне барлап чыкты һәм Григорий Грязнойга текәлде. Канлы оргияларның барысында да салкын канлылык белән катнашкан опричник шулчак маңгаена салкын тир бәреп чыкканын тойды, аның аркасын нидер чемердәтеп узды.

— Якын кил, Гриша,— диде патша ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Григорий тәхет янына якынайды.

— Әйтүләренә караганда, Гриша,— дип шулай ук үлем түшәгендә ятучы кеше тавышы белән дәвам итте патша,— син миннән алда Марфа Сабурованы яраткан булгансың икән. Әйтче миңа, шул чакта ук чирле идеме ул?

Бөтенесе дә сагаеп калдылар. Мондый сорауның кабул итү палатасында, өстәвенә, чит боярлар каршында яңгыравы бик сәер хәл иде алар өчен. Бүген монда җыелган халыкны ниндидер гадәттән тыш вакыйга көтә, күрәсең. Грязной каушавыннан ни дип әйтергә дә белмәде. Иоан түземлелек белән берничә минут көтеп торды, шуннан соң гына, тавышын тагын да ягымлырак итәргә тырышып, кабат сүз башлады:

— Нишләп эндәшмисең, Гриша? Марфаны яратуыңда бернинди дә начарлык күрмим мин. Мин үзем дә сөйдем ич аны. Электән үк авырмадымы икән ул, шуны гына ачыклыйсым килә.

Моннан соң да дәшми тору куркыныч иде. Грязной бөтен көчен җыеп:

— Дөрес җиткергәннәр сиңа, бөек падишаһ,— дип җавап бирде.— Сабуроваларда элегрәк булгалый идем мин һәм Марфа туташны үземә кодаларга ниятем бар иде. Ә чирле икәнлеген белмәдем мин.

— Димәк, яучы җибәрергә теләгән идем, дисең?— дип иренен кыйшайтып елмаеп куйды Иоан.— Ә нишләп җибәрмәдең соң?

—Син, падишаһ, аны үзенә хәләл җефетлеккә сайлап алырга теләк белдердең.

Иоан карлыккан тавыш белән көлеп җибәрде:

—Ха-ха-ха! Димәк, синең кәләшеңне мин тартып алганмын? Ярый. Алайса, мә, шуның өчен сиңа миннән булсын бүләк!

Шул сүзләр белән Иоан, бөтен көченә селтәнеп, таягының үткен очы белән Грязнойның битенә кадады. Таякның очы аның бер күзенә туры килде. Грязной, җан ачысы белән кычкырып, идәнгә ауды.

—Эшен бетерегез шуның,—дип өстәде Иоан тыныч тавыш белән. Тәхет янында басып торган Скуратов салкын канлылык белән бил каешыннан пычагын суырып алды һәм аны коточкыч авыртудан идәндә бәргәләнгән Грязнойның күкрәгенә батырды. Грязнойның мәетен шундук палатадан өстерәп алып чыгып киттеләр.

Үч алу патшаның кәефен күтәреп җибәрде. Аның иреннәрендә елмаюга охшаган нәрсәләр күренде.

—Кияү егете белән эшне төгәлләдек,—диде ул. Аның тавышы бу юлы ягымлырак ишетелде.—Хәзер кәләш эзләргә кирәк. Малюта! Әзерме?

—Бөтен нәрсә син теләгәнчә, падишаһ,—дип җавап бирде Малюта, идәнгә кадәр бөгелеп.

—Киттек алайса!—дип кычкырды патша.

Патша чанасын атлы опричниклар уратып алды һәм алар, кар тузаннары туздырып, урам буйлап каядыр чаптылар. Патша янына чанага Малюта белән Басманов һәм Владимир Ростовский утырды. Патшаның кая таба юнәлгәнен беркем дә белми иде һәм сорарга батырчылык итүче дә табылмады.

Шәһәр артта калды, Коломенское ягына таба борылдылар. Опричниклар, патша үзе яраткан Коломенское сараенда күңел ачарга тели икән, дип уйлыйлар иде, әмма патша чанасы, анда туктап тормыйча, ары үтте. Юл буе бер сүз әйтми тын гына уйланып утырган Иоан бервакыт ягымлы тавыш белән Ростовскийга дәште:

—Ә бит без, кенәз, кунакка сиңа барабыз. Куып чыгармассың, шәт?

Кенәз югалып калды.

—Кичерә күр, падишаһ, ничек инде...—дип тотлыкты ул.—Киресенчә, мин бик шат булырмын... тик... син минем алдан кисәтмәдең... тиешенчә хөрмәт белән кабул итә алмам, дип куркам.

—Бу турыда борчылма, кенәз,—дип тирән мәгънә белән әйтеп куйды патша,—сый-хөрмәтне без үзебез белән алдык.

Мәскәүдән егерме биш чакрымнар чамасы читтә Владимир Ростовскийның биләмәсе бар иде, гаиләсе белән шунда яши иде ул. Кенәз бүтән чакта патша сараеннан ераграк булырга тырыша иде, Иоан опричнина оештыргач, бигрәк тә нык читләште.

Патша кәрваны, ниһаять, кенәзнең биләмәсенә барып житте. Аның шулай бер көтмәгәндә килеп керүе өйдәгеләр арасында, кырмыска оясына таяк тыккан кебек, ыгы-зыгы куптарды. Кенәз патшадан, хуҗалыгында тиешле күрсәтмәләр бирер өчен, бераз вакытка чыгып керергә рөхсәт итүен үтенде. Патша ачык йөз белән рөхсәт итте.

Хуҗа чыгып киткәч, Иоан игътибар белән палатаны карап чыкты, мыскыллы елмаеп куйды һәм юлдашларына карап:

—Владимир кенәзнең тормышы бер дә зарланырлык түгел икән,—диде.

Шулвакыт бүлмәгә Ростовский үзе килеп керде. Аңа хатыны ияргән иде. Анысы, киң көмеш кунага куеп, хәмер салынган чәркәләр алып кергән. Хуҗабикә патша янына килде һәм, бил бөгеп, аны хөрмәт белән сәламләде, ә кенәз үзе:

—Бәхетле ит безне, бөек падишаһ, чәркә белән шушы винобы йотып куйчы,—диде.

—Ашыкмый тор!—дип туктатты аны Иоан.—Сый-хөрмәтне үзебез белән алдык, дип мин сиңа юлда әйткән идем бит инде. Син дә минем винобы тәмләп кара. Тукта, уларың кайда соң синең?

Ростовский яшь кенәзләрне чакырырга кушты. Патшаның ымын үтәп, Кремль сараеннан алып килгән савыт белән эчемлек китерделәр. Скуратов дүрт чәркәгә күчтәнәч эчемлекне салды һәм хуҗаларга бирде. Шулвакыт Ростовскийның зиһененә моның мәгънәсе барып житте. Ул тавыш-тынсыз гына хатыны белән уларын үбеп, бәхилләште һәм кинәт эчеп җибәрде. Тегеләр дә аңа ияртеләр. Берничә минуттан алар идәндә үлем белән тартышып яталар иде инде. Почмактагы түре астында утырган җирәнгән Иоан, шаркылдап көлә-көлә, ачы эчкән хуҗаларның агониясен карап торды. Бичаралар идәндә тынып калгач, Иоан урыныннан торды:

—Хуҗалар безнең килүне өнәп бетермәделәр, күрәсең. Кунакларыннан алдарак эчеп күбенделәр. Үзебезне үзебез сыйларга туры килә.

Кенәз йортында оргия башланды.

Ростовский кенәзнең бөтен «гаебе» бары тик шуңардан гыйбарәт иде: ул—Марфа Сабуровага исем кушучы ата булган кеше, ә Марфаның үз атасы, «көч

кулланып» сорау алуларга түзмичә, кызым кече яшьтән үк чирле иде, дип әйтте, ә бу турыда Ростовский белә иде, диде.

Кенәз биләмәсендә үзләре генә калгач, патша бер тәүлек буе типтерде. Аннан соң «хатын эзләргә» чыгып китте. Әнә шундый «кәләш эзләп чыгып китүләрнең» берсендә алар Милославский кенәзнең йортына туры килделәр, ә бу вакытта өйдә хуҗабикә белән балалары гына утыра иде. Шуңа күрә алар ишек кагучыларның кемнәр икәнлеген ачык кына танымадылар. Кенәзнең ялчылары, опричниклар өерен патша үзе алып килгәнлеген белмичә, коралланып, бик каты каршы тордылар. Бер дистәгә якын опричник шунда башын салды. Иоан үзе дә очраклы гына исән калды. Хурлык булса да, чигенергә туры килде. Әмма Милославскийга бу «җиңү» бик кыйммәткә төште. Берничә сәгатьтән аның йортын биш-алты йөз опричник камап алды. Операциягә Иоан үзе җитәкчелек итте. Яраннарына ул, бу йортта бер генә кешене дә исән калдырмаска, хәтта хатын-кызлар белән яшь балаларны да аямаска, дип бик каты кисәтеп куйды. Аннан-моннан гына коралланган ялчылар озак каршы тора алмадылар, әлбәттә. Тиздән опричниклар йортка басып керделәр һәм анда Иоан чорында ерткычлыгы белән нык аерылып торган үч алу башланды. Җиңүчеләр, патшаның боерыгын истә тотып, беркемне дә аямадылар. Хатын-кызлар башта, гадәт буенча, чират аша уздылар, шуннан соң аларны да кылычлары белән вак кисәкләргә турадылар. Суеш барган чакта Иоанның холкына хас булган бер кечкенә вакыйга булып алды. Йомшак күңеллелек белән аерылып тормаса да, Басманов, кул күтәрергә йөрәге җитмичә, патша янына Милославскийның ике айлык оныгын алып килде. Сабый шулкадәр матур һәм ярдәмгә мохтаҗлыгы белән кызганыч иде ки, хәтта кансыз опричниклар да аңа кагылырга кыймадылар. Иоан, сабыйны кулына алып, үпте һәм:

— Патша сүзе Ходай алдында,— диде.— Ә мин бу йортта бер генә җан иясе дә исән калмасын, дидем. Шулай булсын!

Һәм үзе янында ук сабыйны чалып ташларга кушты...

## 8

Марфа үлгәннән соң Иоан әнә шулай күңел ачты. Ниһаять, бу аны тәмам туйдырды һәм ул яңадан өйләнергә карар кылды. Әмма ләкин шунысы бар: православие чиркәве өч кенә тапкыр өйләнергә рөхсәт итә, шунлыктан дүртенче никах берниндә канунннарга да сыймый иде. Шулаен шулай да, ләкин бит Иоан өчен кануннар юк. Дүртенче хатынга ул Анна Алексеевна Колтовскаяны сайлады һәм бер изге атага никах догасы укырга боерды. Изге ата патша сүзеннән чыгарга базмады, әлбәттә, һәм тиздән ул, җиренә җиткереп, никахлашу йоласын башкарды. Әнә шундый формаль нәрсәләр артта калганнан соң гына, Иоан епископларын җыеп алды һәм алар каршында шундый нотык белән чыкты:

— Изгелек өләшүчеләр! Явыз кешеләр минем беренче хатынымны, Анастасияны, сихерләп, газаплап үтерделәр. Икенчесенә, черкас кенәзе кызына, ачы бирделәр һәм ул, коточкыч газапланулардан һәм интегүләрдән соң, Ходай тәгалә янына китте. Мин шактый озак вакыт ялгыз түздем, өченче тапкыр бары тик ике җитди сәбәп аркасында гына өйләнергә карар кылдым: беренчедән, мин дә тере кеше, икенчедән, балигъ булып өлгермәгән балаларымның ятим үсүе миңа җан тынычлыгы бирмәде — мин бу фани дөньяны, сабыйларны ятим калдырып, ташлап китәлмадым, ә хатынсыз яшәүче кешене бу дөньяда бик күп бозык юллар сагалап тора бит. Митрополит Кирилл фатиха биргәннән соң, мин бик озак үземә ярардай кәләш эзләдем, ничәмә-ничә кыз арасыннан, ниһаять, берсен сайлап алдым, ләкин көнчелек, дошманлык дигән явыз нәрсә патша хатыны исеме алып кына өлгергән Марфаны һәлак итте: ул кәләш чагында ук хастага әйләнде һәм ир хатыны булып ике атна да яшәргә өлгермәде, саф кыз көенә бу дөньядан китте. Авыр кайгыдан ушыма килә алмыйча, мин калган гомеремне монахлыкта уздырырга карар кылган идем, ләкин сабыйларымның бер ярдәмчесез калуларын һәм Дәүләтемнең бүгенге көндә нинди авырлыклар кичерүен күреп, дүртенче тапкыр башлы-күзле булырга тәвәккәллек иттем. Бу мизгелдә мин, түбәнчелек белән аягызга егылып, сездән, Изгелек өләшүчеләрдән, шуңа рөхсәтегез белән фатихагызны ялварам.

«Изгелек өләшүчеләргә», патшаның бу сәер нотыгыннан соң, аның никахын танырга гына калды. Алар аңа, сүз өчен генә булса да, җиңелчә епитимья йөкләделәр: ул бер ай буе, Ходайдан ярлыкавын сорап, көнгә йөз тапкыр дога кылырга тиеш. Ләкин Иоан өчен бу җәза нульгә тиң иде.

Анна Колтовская күп яклары белән Тәмгрүк кызы Марияга охшаган иде. Черкас кызы кебек үк, ул да йөгәнсез холкы һәм тыйнаксыз дәртлелек белән аерылып торды. Агулап үтерелгән чирләшкә Сабуровадан соң, Анна Иоанны үзенең көчле ихтыярына буйсындырырга ирешә. Патша, вакытлыча гына булса да, тыйнакланып калды, күпләп-күпләп дошман эзәрлекләүләр һәм аларны җәзалап үтерүләр туктады.

Иоан хәзер көннәр буе хатынының теремында юана иде. Ул еш кына, сарайда канунга әйләнгән этикетка кул селтәп, хезмәткәрләренең докладларын шунда ук кабул итә башлады.

Анна иренең күңелен яуларга бик оста булып чыкты. Хәзер сарайның хатын-кызлар ягында һәрвакыт җыр-биюләргә һәм патшаның теләсә нинди теләген үтәргә әзер торучы чибәр хатыннар мәш килә башлады. Падиша иренең алар белән «уен-нар» оештыруына бармак аша гына карый иде. Көнләшүнең нәрсә икәнен белми иде ул, чөнки Иоан, ир буларак, аны әз генә дә кызыксындырмады.

Хатынының теремына Иоан, гадәттә, иртән килеп керә. Анда аны ачык йөз белән каршы алалар. Падишаның йокы бүлмәсендә, махсус биек итеп эшләнгән бер урында, йомшак кәнәфи тора иде. Анна ирен, ишек төбенә үк барып, бил бөгеп каршы ала. Патша үз урынына барып утыра. «Терем көне» әнә шулай башлана иде.

Иоан шуннан соң үзе иң якын күргән хатын-кызларны янына чакырып ала, алардан хәл-әхвәл сораша, бераз шаян сүзләр кыстырып кайчакта мәзәкләр сөйләп ташлый, уен-көлке арасында аларның үтенечләрен тыңлый, гозерләрен канәгатьләндерә, кайберләренә юмартлык белән зур-зур биләмәләр бүләк итә, бәхәсле дәгъваларны алар файдасына хәл итә. Русь дәүләтенең бу чорын бик хаклы рәвештә, «хатыннар патшалыгы» дип атыйлар.

Бу чорда хәтта аның иң якын опричниклары да арткы планга күчтеләр. Иоанның «ышанычлы эте» Малюта Скуратов та вакытлыча патшага булган элекке йогынтысын югалтып торды. Хәтта, бик кирәк чакларда да, патша янына Аннаны уратып алган хатыннар аша гына керергә мөмкин иде.

Опричнинага каршы Анна даими рәвештә аяусыз көрәш алып барды. Иоанга кияүгә ул унсигез яшьлек кыз чагында чыкты. Ә ул заманнарда аның кебекләр «сазаган кыз» санала иде. Иоан аны хатынлыкка бөтен тәненнән дәрт бөркелеп торганын күргәч кенә алды. Әмма Анна йөрәгенең яшерен бер почмагында патшаның үзенә дә, бигрәк тә аның опричникларына да ачы нәфрәт саклый иде. Анна Колтовская кайчандыр мәхәббәт ялкынында яна иде. Әмма аның сөйгән егете Воротынский кенәз ни беләндер Вяземский кенәзнең ачуын чыгарды һәм Мәскәү зинданнарының берсендә җәфалап үтерелде. Анна моны бер секундка да онытмады. Ул, патшага йогынты ясый алуыннан файдаланып, әкрен генә, әмма шактый уңышлы рәвештә, опричнинаны тар-мар итә башлады. Ул, әлбәттә, үзе өчен үч алу турында уйлады, әмма моның белән ул опричниклардан санап бетергесез бәлаләр күргән Русь дәүләтенә дә файда китерә иде. Бер ел эчендә, Иоан аның йогынтысы астында яшәгән чакта, опричнинаның барлык башлыклары да диярлек яисә җәзалап үтерелделәр, яисә еракка сөргенгә сөрелделәр. Ә гади опричникларның кечкенә кырын эшләре дә элекке кебек гафу ителми иде, хәзер алар да кырыс җәзага тартылдылар. Моның өчен Аннаның үзенең яисә аның теремында яшәүче бояр кызларының бер сүзе дә җитә иде: гаептә тотылган һәр опричникны Иоан, аны шул хәлдән алла гына иң ышанычлы кешесе санаса да, судсыз-нисез эшафотка озатыра торды.

Шулай булгач, опричникларның Колтовская белән аның сарайдагы дусларын дошман күрүләре бер дә гаҗәп түгелдер. Бигрәк тә, Аннага булган мәхәббәте аркасында харап булган Андрейның атасы, Воротынский кенәз, аны бөтен җаны-тәне белән күрә алмый иде. Карт кенәз улының ачы язмышы өчен чын күңелдән Аннаны гаепләде: чөнки ул, Анна үзе патша хатыны булырга теләгәндер дә, Андрейның ээрлекләвеннән куркып, аны үз юлыннан алдыртып ташлагандыр, дип уйлый иде. Воротынский ничек булса да яшь падишаның башын ашарга ант эчте. Кенәзнең хатын-кызларга гына хас нәфисләлек белән башкалардан аерылып торучы туганыннан туган Борис Ромодановский исемле бер яшь энесе бар иде. Бәхетсезлегенә каршы, әнә шул яшүсмер егет мажаралар ярата торган кеше булып чыкты. Воротынский аны үзе янына чакыртып алды.

— Борис! Миңа бер яхшылык эшләргә телисеңме? — диде ул. — Бәрәттән үзең дә күңел ачарсың.

Ромодановский, әлбәттә, бик рәхәтләнеп риза булды. Кенәз аңа үзенең планын сөйләп бирде: Воротынскийның Ирина исемле ерак кардәше бар иде; Борис, үзен әнә шул кыз дип атап, падиша теремына үтеп керергә тиеш. Борис Мәскәүгә үзенең ерактагы биләмәсеннән күптән түгел генә килде, димәк, аны кем дә булса таныр, дип куркасы юк.

Унтугыз яшьлек Борис Ромодановский, үз гомеренә куркыныч тозак корылуын башына да китермичә, шатлана-шатлана агасына ярдәм итәргә булды. Шушы килешүдән соң, карт кенәз Иоанга «бояр кызы Ирина»ны тауларга күтәреп мактый башлады: шәһвәт сөя торган патша ул «кыз»га падиша теремына керергә рөхсәт итеп кенә калмады, хәтта аны тизрәк чакыртуны таләп итте.

Аннаның теремында әнә шулай итеп «бояр кызы Ирина» пәйда булды. Борис Ромодановский үз ролен шулкадәр оста башкарды ки, ялганны беркем дә сизмәде. Иоан, гадәте буенча иртән, теге «кыз» падиша белән таныштырылган көнне үк, теремга кереп, яңа боярышняны үзенә күрсәтүләрен таләп итте. Мондый борылышны

котмәгән Борис югалып калды. Йөзе кып-кызыл булды, ә бу төс аңа тагын да ныграк килешә иде. Хатын-кызлар мәсьәләсендә тиңдәше булмаган патша каршында зифа буйлы «кыз» уңайсызланып басып тора иде: ул аны баштан-аяк бик җентекләп карап чыкты һәм, күңеленә хуш килү билгесе итеп, «бояр кызы Ирина»га үз казнасыннан энҗе муенса бүләк итте.

Шул көннән башлап, Иоан «бояр кызы Ирина»га карата үтә ягымлылык күрсәтә башлады. Патша беркем алдында да уңайсызланып тормый иде, бервакыт ул, законлы хатыны үзе янында басып торуга игътибар да итмичә: «Яшь бояр кызы миңа урын җәйсен»,— дип боерып чыгып китте.

Кич җиткәч, «бояр кызы Ирина» патшаның йокы бүлмәсенә кереп китте...

Төн уртасы тирәсендә Кремль сараенда Иоанның ярсып кычкырган тавышлары яңгырады. Патша җен кебек котырына иде. Ул, юка озын күлмәкчән килеш, канга баткан таягы белән кизәнеп: «Очраган берегезне үтерәм!»— дип җикерә-җикерә, бөтен палаталар буйлап чабып йөрде. Барысы да куркып качып беттеләр. Беркемне дә очратмагач, ул башкалар кебек үк коты алынган Аннаның палатасына ташланды. Чабып килгән уңайга ачу белән ишекне шар ачып ташлады, ләкин тупсаны атлап уза алмады — бумасы тотып, тупсага аркылы егылды. Шуның аркасында гына Анна исән калды. Мондый хәлдән соң патша, гадәттә, хәлсезләнеп, бөтен нәрсәгә битараф кала торган иде. Бу юлы да шулай булды. Аны, күтәреп, йокы бүлмәсенә илттеләр. Ә анда Борис Ромодановскийның канлы гәүдәсе аунап ята иде: өстендә бояр кызларыныкы кебек купшы бай күлмәк, муенында патша бүләк иткән энҗе, ә янында өзгәләнеп беткән ясалма чәч толымнары. Борисның тәне карарга куркыныч иде: патшаның очлы таягы белән тишкәләнмәгән җире юк иде аның...

## 9

1572 елның 15 апрелендә Тихвинский монастыре янына атлы опричниклар белән уратып алынган бөркәүле зур авыр арба килеп туктады. Аның алдыннан, атының җилкәсенә авыр гәүдәсе белән ята төшеп, Малюта Скуратов үзе чабып килде. Килүчеләрне көтеп торганнар иде, күрәсең, монастырьның авыр тимер капкасы шундук ачылып китте. Авыр арбаны җәмигъ чиркәүнең таш ишек төбенә үк терәтеп туктаттылар. Опричниклар атларыннан төште. Скуратов арба янына килде һәм, аның кечкенә ишеген ачып, кискен-кискен берничә боерык бирде. Арбадан, башыннан ук томалап тунга төрелгән, нииндидер кешене күтәреп төшерделәр һәм аны чиркәүгә алып керделәр: анда игуменья белән бергә монах хатыннар басып тора иде инде. Патша өчен махсус ясалган ишек каршында кәнәфи тора иде, алып кергән кешене шунда утырттылар. Тунын салдыргач, монах хатыннарга ап-ак булып агарынган йөз күренде: алар бигрәк тә аның ярымшашкан зур күзләренә игътибар иттеләр. Хатынның башында берни дә юк иде. Куе озын чәчләре, тәртипсез таралып, җилкәсе аша кәнәфи артына салынып төште. Падиша Анна, Иоан Васильевичның дүртенче хатыны иде ул.

Кинәт, чиркәү эчен тутырып, елау аралаш шашкан тавыш яңгырады:

— Теләмим! Кара каргышлар төшсен сезгә! Мин патша хатыны! Хакыгыз юк!

Анна, истерикага бирелеп, кәнәфиендә арлы-бирле бәргәләнә башлады. Кәнәфи янында басып торган Малюта тыныч хәрәкәтләр белән бил каешыннан пычагын алды һәм, билбавының очын кисеп, шуны патша хатынының авызына бөтәрләп тыгып куйды. Чиркәү эче кабат тынып калды. Әмма Анна һаман да, тавыш-тынсыз, кәнәфиендә төрле якка бәргәләнә иде. Моңа игътибар итмичә, аның чәчен кырка башладылар. Анна бу вакытта һушын югалткан иде инде...

Яңадан бер сәгатьтән фани дөньяда Анна исемле патша хатыны юк иде инде. Аның урынында чиркәүдә тыйнак кыяфәтле Дария исемле инокиня басып тора иде. Ә тагын бер сәгатьтән инокиня Дария иң югары дәрәҗәле монах хатынга әйләнде. Чиркәүдән күтәреп алып чыкканда аның түшендә, йөрәкләргә шом салып, ап-ак кеше башы сөяге эленеп тора иде. Чәче кыркылган башын япкан капюшонга да кеше башы сөяге сурәте чигелгән иде. Аны монастырьдагы табут куя торган төрбәләрнең берсенә мәңгегә тереләй ябып куйдылар: ул анда, беркемне дә күрмичә, тагын 54 ел яшәде. Дөньяда барлыгы да онытылып беткән Анна 1626 елның августында җан бирде: ә бу вакытта Мәскәү тәхетендә Романовлар нәселе утыра иде инде.

## 10

Анна Колтовская белән эшне бетергәч, патшада өйләү дигән нәрсәнең эзе дә калмады. Моңа кадәр ул шулай да, тыштан гына булса да, үзенең төрле бозык юлларда чабуларына һәм гаепсезләрне җәзалап үтерүләренә нинди дә булса законлылык төсе бирергә тырыша торган иде. Хәзер Иоан ул битлеген дә салып ыргытты. Иң башлап ул Воротынский белән Ромодановский нәселләренә һөҗүм итте.

Карт кенәз Воротынский бертуган агасының улы Борисның үтерелүе турында шул ук төнне белде. Мондый хәлне көткән иде ул, шуңа күрә алдан ук качарга әзерләнде. Ләкин патша ялчылары аңардан өлгеррәк булып чыкты. «Патшаның ышанычлы эте» Малюта, патша бүлмәсендә төнлә булган хәлләрне ишетүгә, Борис Ромодановскийның кеше кулындагы сукыр корал булганлыгын шундук аңлап алды һәм тиз генә ярдәмчеләрен Воротынскийны тотарга җибәрде. Алар кенәзне көймәле арбасына утырып маташканда эләктереп алдылар. Һәм, аяк-кулын бәйләп, зинданга илтеп яптылар. Икенче көнне иртән аңардан сорау алуда Иоан үзе катнашты. Карт сер бирмичә, үзен горур тотты. Кыйналып, имгәнеп бетсә дә, сынмаган сөякләре калмаса да, кенәз берүк сүзне кабатлады:

— Берни дә белмим. Минем гаебем юк.

Ул үзенең язмышы хәл ителгәнлеген бик яхшы белә иде, әмма, катырак торса, һич югында якын туганнарын коткарып калып булыр, дип уйлый иде... Шул өмет белән жан да бирде. Әмма Иоан үч алуда ярты юлда тукталып калуны белми торган кеше иде шул. Кенәзнең үзе белән эшне бетергәч, ул җәлладларына аның ике кызын мәсхәрәләргә боерды һәм шуны үз күзләре белән карап торды. Аннан соң Кремль сарае мәйданында моңарчы күрелмәгәнчә искиткеч зур «аю өстерү уены» уздырылды: канга сусаган аюлар ул көнне берничә минут эчендә, Воротынский белән Ромодановский кенәзләрнең берсен дә калдырмыйча, бөтен туган-тумачаларын өзгәләп ташладылар.

Тагын бер ел вакыт узды. Чамадан тыш типтерүләр Иоанны алҗыта башлады. Икенчедән, аңа, үзенең мәңге туймас җенси теләкләрен канәгатьләндерер өчен, көн дә каядыр чыгып чабарга туры килә иде: чөнки, таләпләрне ул ничек кенә каты куймасын, боярлар үзләренең хатыннарын һәм кызларын «буйдак» сараена якын җибәрмәс өчен бөтенесен эшлиләр иде. Патша озакламый, яңадан өйләнергә кирәк, дигән фикергә килде. Әмма бер киртә бар: дүртенче никахы белән булган хәл архипастырьларның тагын берсенә ризалык бирмәячәген көн кебек ап-ачык күрсәтте. Иоан аларның ризалыгын сорап тормады. Шул чорда Спасо-Преображенский чиркәвендә (Нарат урманы Спасы) Никита исемле бер кеше рухани булып тора иде, элегрәк опричник булган бу кеше анда патша таләбе буенча куелган иде. Шул Никита, патша пәри кызы белән никахлашырга теләсә дә, йоласын үтәргә әзер тора иде. Патшаның гозерен ишеткәч, ул шатланып никах укырга риза булды.

1573 елның ноябрендә Иоан Васильевич Мария Долгорукая исемле кенәз кызы белән никахлашты. Тик патшаның бу өйләнүе алдагыларыннан да фаҗигалерәк финал белән бетте.

Зофаф төне үтүгә, Иоан кабул итү палатасына сөмсерләре коелып килеп чыкты. Яшь кияүнең кәефен ни кырганны белмәсәләр дә, бөтенесе сагаеп калдылар. Патша берничә докладны гына тыңлап торды, кырыс кына кул селтәде һәм үз ягына кереп китте. Тиздән сарай мәйданында кар шыгырдады: патша кәрваны Александровский бистәсенә таба чаба иде. Ул заманнарда Александровский бистәсендә балыкка бик бай зур буа бар иде. Ул буаны «патша буасы» дип йөртәләр иде, чөнки патша өстәленә балыкны әнә шул судан тотып китерәләр иде.

Аларны бил бөгеп сәламләп каршы алдылар: яшь падиша өчен яңалык иде бу, ул моны балаларча кызыксынып күзәтте. Мондый олылауны гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде аның. Яшь кәләшенә юл буе бер сүз катмаган патша, беркемгә дә күтәрелеп карамыйча, чанасыннан төште һәм сараена кереп китте. Скуратов та берсүзсез аның артыннан иярде.

Ярты сәгатьтән Александровский бистәсе кешеләре колактан-колакка патшаның нindидер сәер нәрсә әзерләве турында сөйли башладылар: чөнки дисгәләгән кеше «патша буасы» өстендәге ныгып җитмәгән бозны ватып, бик зур бәкe ясап маташа иде.

Төш вакыты җиткәндә күлнең өчтән бер өлеше боздан арчылган иде инде. Шуннан ерак түгел җиргә яр өстенә биек кәнәфи китереп куйдылар. Боз өстенә беркемне дә җибәрмәс өчен, буаны җәяүле һәм атлы гаскәриләр уратып алды. Сарай капкасы ачылып, аннан бер төркем кеше чыгып килгәндә кичкә энгер-менгер җитеп килә иде инде. Иң алдан атына менгән патша бара. Аның артыннан утын чанасына җигелгән икенче ат килә. Чана төбендә бер кечкенә гәүдә ята. Патшаның яшь хатыны иде ул. Мария һушсыз күренә, шуңа карамастан, аны баулар белән ныклап чана карамаларына бәйләп куйганнар. Төркемнең азагында, һәрвакыттагыча, Малюта Скуратов белән атлы опричниклар килә. Утын чанасына җигелгән ат буаның боздан арчылган төшенә каршы килеп туктады. Иоан, бармагы белән ишарәләп, Малютаны үзе янына чакырып алды һәм аңа берничә сүз әйтте. Скуратов буа уртасы турына чыкты һәм, җыелган халыкка карап, сүз башлады:

— Православныйлар! Сез хәзер Бөек Государьның үзенә хыянәт итүчеләрне, аларның кем булуына карамастан, ничек җәзалавын күрерсез. Долгорукийлар, патшага хыянәт итеп, аны Мария княжнага өйләндерделәр, ә Мария никахка кадәр үк

кем беләндер булган һәм моны патшага әйтмәделәр. Шуңа күрә, государь Марияны Ходай карамагына тапшырырга карар кылды.

Шул сүзләрне әйткәч, Малюта утын чанасы янына килде һәм, пычагын алып җигелүле атның койрык тирәсенә — сыртына кадады. Ат кинәт сикереп куйды. Опричниклар да атка ташландылар һәм айбалталары белән аңа төрле яктан суга башладылар. Куркып калган мескен хайван, ак-караны күрмичә, алга томырылды. Берничә секундтан су чапылдавы яңгырады һәм җигүле ат, чанасына бәйләп салынган падиша белән бергә, кургашын кебек кара суны тирә-якка чәчрәтә-чәчрәтә, боз астына кереп югалды.

Тамашачылар, ихтыярсыз, берьюлы аһ иттеләр. Шуннан соң тынлык урнашты. Барысы да, сихерләнгәндәй, су өстенә карап катты: тирә-якка таралган түгәрәк дулкыннар һәм һава куыклары белән тулган буа озакламый күзге кебек тип-тигез булып калды. Патша урыннынан торды, баш киемен салып, чукынды һәм үзалдына гына:

— Ходайның ихтыяры үтәлде,— диде.

Шуннан чоң ул атына атланды һәм, опричникларын ияртеп, сарайга таба юнәлде: анда, патша әмере белән, бистәнең барлык чибәрләрен җыйганнар иде инде. Тиздән сарайда иртәнгә кадәр сузылган оргия башланды...

Мәскәүгә кайткач, Малюта, патшага ярарга тырышып, суга батырып үтерелгән Марияның бертуган абыйсы Петр Долгорукийны тотып китерергә боерды. «Патша хатынын харап иткән» явызның кем икәнен әйттерер өчен, аның имгәнмәгән җирен калдырмадылар. Коточкыч газаплауларга карамастан, кенәз малае Петр Долгорукий, үҗәтләнеп бер генә сүз тәкрарлады:

— Мария сеңлемне бер генә явыз харап итте — ул патша Иоан Васильевич,— диде.

Скуратов патшага княжичның моңарчы беркемдә булмаган үҗәтлек күрсәтүе турында хәбәр итте. Иоан аны игътибар белән тыңлап торды һәм яшь кенәзне өенә кайтарып җибәрергә кушты.

— Петр Долгорукийны үз биләмәсенә җибәрергә, сеңлесенең гөнаһлары өчен аны гаепләмәскә, ул аның тәртибе өчен җавап тота алмый,— диде.

Патшаның мондый гадәттән тыш йомшак күңеллелеге бөтенесен гаҗәпкә калдырды. Әмма Скуратов, хуҗасының бик тиз үзгәрүчән усал холкын яхшы белгәнгә, үзенчә эшләргә булды: ул ярымүлем хәлендә яткан яшь Долгорукий янына зинданга керде һәм аны үз кулы белән суеп ташлады. Ә патшага: «Княжич Петр ниндидер билгесез чирдән җан бирде»,— дип кереп әйтте. Хуҗасының ялгышларын ышанычлы хезмәтче әнә шулай төзәтә иде.

Малюта чынлап та ялгышмады. Иоанның кече күңеллелеге озакка бармады: ике атнадан Кремльдә бөтенләй бүтән тормыш башланды. Иоанның яраннарының әлегә кадәр беркайчан да мондый әшәке типтерүләргә барып җиткәне юк иде: 1574 ел башыннан Мәскәүдә ачыктан-ачык фәхешлек хөкем сөрә башлады. Уйнаш әз генә вакытка тыныбрак тора да кабат, дулкын-дулкын булып, бөтен шәһәргә җәелә иде. Азмы-күпме хәллерәк кешеләр башкаланы тизрәк ташлап китүне карадылар, күбесе, һич югында, кызлары белән хатыннарын ераккарак яшерергә тырышалар иде.

Хәзер патша, иртән ятагыннан торуга, «тән юучыларны» чакыртып ала. Шәһәрнең иң чибәрләре арасыннан сайлап алынганнар иде алар. Шулар патшаның, картаеп бөрешкән ябык тәнен әйбәтләп юып, исле май белән ышкып чыга. Ә бу вакытта патша, анадан тума шәрә калып, урындыкта утыра. Кайчагында ятып торуны артыграк күрә: читтән караганда нәкъ мәет юалар, диярсең. Тәне чистарынгач, Иоанны шундый ук гүзәл хатын-кызлар киендерә.

Әнә шушы чорда Иоан Швеция принцының хатыны Екатеринаның искиткеч гүзәл икәнлеге турында ишетте һәм аны ничек тә үз кулына төшерергә карар кылды. Шул максат белән ул Воронцов дигән илчесен Стокгольмга җибәрде. Әллә илчесе пешмәгән кеше булып чыкты, әллә шведлар русларны санга санап бетермиләр идеме, король белән аудиенциягә ирешкәнче унбер ай үтеп китте, ә ул арада Швециядә дәүләт башлыгы алмашынып, тәхеткә чибәр Екатеринаның ире принц Иоан үзе менеп утырды.

Теләгенең уңышсызлыкка юлыгуын белгәч, патша илче Воронцовның кайтып житүен түземсезлек белән көтә башлады. Беркайчан үз хисләрен тыярга күнекмәгән Иоан бу көннәрдә, гомумән, ярсуыннан дилбегәдән ычкынды. Хәтта Скуратов, Басманов кебек иң якын кешеләре дә аның күзенә чалынудан куркалар иде.

— Швециядә булдыксызлык күрсәтеп кайткан өчен,— дип сүзен башлады ул, ниһаять, Воронцов кайтып җиткәч,— без боярин Никита Воронцовны эт караучы вазифасы белән бүләклибез.

Бу сүзләрне ишеткәч, Воронцов чайкалып куйды.

— Бөек падишаһ!— диде ул калтыранган тавыш белән.— Мин чын күңелдән синең атаңа, истәлеге якты булсын, Василий Иоанновичка хезмәт иттем. Синең үзеңә дә ышанычлы һәм тугрылыклы хезмәтче булдым. Синең ачуыңны кабартырлык бер-

нинди начарлык та эшләмәдем мин. Болай мыскыл иткәнче, җәзалап үтерт. Воронцовлар нәселендә берәүнең дә эт караучы булганы юк иде әле.

Патша мыскыллап елмайды һәм:

— Ярый алайса, боярин Никита,— диде.— Эт караучы булырга теләмисең икән, минем палаталарда кал. Шамакай булырсың. Ел буе Швециядә ятып, буш кул белән кайтып керүеңнең бер файдасы тигәндер бит.

Патшаның ишарәсе белән шөлдерләр тагылган шамакай киеме алып керделәр. Шөлдер чыңлавын ишеткәч, Воронцов хәнҗәрен тартып чыгарды һәм кабул итү бүлмәсенең аргы почмагына ташланды:

— Барып чыкмас! Үтерәм!

— Үтермисең,— диде Иоан тыныч тавыш белән һәм тәхетеннән торып басты.— Мин сиңа үз кулларым белән кафтан кидерәм.

Патша Воронцов янына таба атлады. Барысы да, ни булыр, дип тынып калдылар. Патша әкрен генә бояринга таба якынлашты. Хәнҗәренең сабын кысып тоткан Воронцов, нишләргә белмичә, аңа карап катты... Иоан аның янына ук килеп житкәч, ул шашкан кешедәй кычкырып көлеп җибәрде һәм:

— Димәк, Воронцовларны халык алдында мәсхәрә итәсең, Иоан Васильевич?! Мәңге буласы юк моның!— дип кычкырды да, опричниклар кулын тотып өлгергәнче, бөтен көченә күкрәгенең сулъягына кадады. Хәнҗәр нәкъ йөрәгенә туры килде. Бер секундтан идәндә мәет ята иде инде. Иоан карлыккан тавыш белән көлеп җибәрде һәм Скуратовка таба борылды:

— Ну, Малюта, сиңа бер эш кимеде. Юкса, бу үләксә белән азапланырга туры килгән булыр иде.

Бояринның гәүдәсен алып чыгып киттеләр. Патша палатасында кабул итү дәвам итте.

## 11

Александровский бистәсенең сараенда чын мәгънәсендә гарем иде. Көнчыгыш хәрәмнәреннән ул бары тик бер генә ягы белән аерылып тора: аның гаремындагы хатын-кызлар чагыштырмача ирекле иделәр. Евнух кебек хәрәм агалары каравыллап тормыйлар иде аларны, патшаның якыннарыннан кайсы кирәргә теләсә, шул керә ала иде анда. Иоан үзе, алардан туеп, муеннан гарык булды. Сарай кәнизәкләре генә канәгатьләндерерлек түгел иде инде аны. Ул хәзер күңел ачуны бик еш читтән эзли башлады. Бервакыт ул яраткан танышы Петр Васильчиков кенәз янына барып чыкты. Кенәзнең чибәрлеге белән бөтен тирә-якка даны таралган, унҗиде яшьлек Анна исемле кызы бар иде. Патшаның күзе шул кызга төште һәм ул дус кенәзенә кызын сарайга җибәрергә тәкъдим итте. Горур холыклы Васильчиков баш тартты. Иоан, аның каты торуын күргәч, икe дә уйлап тормыйча, мин аңа өйләнәчәкмен, диде һәм икенче көнне үк Васильчиковка яучылар җибәрде. Патша теләгенә каршы килү турында уйласы да юк иде. Шулай итеп, Анна Васильчикова патшаның алтынчы хатыны булды. Кем никах укыгандыр бу юлы аларга, билгесез, әмма ничек кенә булмасын, Анназы патша хатыны, дип барыбер беркем дә санамый иде. Патриарх белән епископлар бу никахны законлы дип танымадылар. Хәер, Иоан үзе дә аларның ризалыгын алырга тырышмады.

Анна белән Иоан өч кенә ай яшәп калды. Беркөнне кыз ничектер серле рәвештә кинәт җан тәслим кылды. Ә халыкка, Иоанга чыкканчы тап-таза кыз булса да, «күкрәк чиреннән үлде» дип игълан иттеләр. Мескенненең гәүдәсен яшерен рәвештә, төнлә, сарайдан алып чыгып, Суздальдагы кызлар монастырена күмәргә җибәрделәр. Гомумән, патшаның бу өйләнүе бик күп имеш-мимешләр белән уратып алынган иде. Анна Васильчикованы патша үз янына күтәрсә дә, аның якын туганнарыннан берсен дә сарай тирәсенә якын китермәде, ә бу — рус патшаларына хас нәрсә түгел иде.

Вяземский кенәзне җәзалап үтергәннән соң, патша, яшь Басманов белән бергә, ат караучыларның берсе булып хезмәт иткән Никита Мелентьевны да үз тирәсенә якынайтты. Патшасының һәр теләген арттырып үтәргә әзер торучы бик шома кеше иде ул. Беркөнне патша, тугрылыклы ялчысына үзенең мөнәсәбәте әйбәт булуын күрсәтер өчен, аның йортына сугылды. Патшаның болай бик гади килеп керүе йорт хуҗасы өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде. Ул, әлбәттә, каушавыннан аны кая утыртырга белмәде. Өйдә ыгы-зыгы купты. Патшаны өйнең иң түренә утырттылар, тиздән кунак ягына Мелентьевның хатыны — чибәрлеге белән күзнең явын алып торган Василиса да чыкты. Ул, кунага тезеп, чәркәләр белән күз карасы кебек саклап тоткан чит ил виносы кертте. Василиса патшага бил бөгеп сәлам бирде. Патша, үзенә билгеләнгән чәркәне кулына тотып, торып басты.

— Исәнлек телим сиңа, хуҗабикә,— диде ул аңардан күзен алалмыйча.— Ә хуҗаңа шундый гүзәлкәйне бездән яшерен тотканы өчен шелтә беллерәм.

Василиса комач кебек кып-кызыл булды. Гади ат караучы хатыны буларак, ул сарайга керү турында хыяллана да алмый иде. Патшаның бу сүзләре аның йөрәгенә сары май булып япты: моннан соң аның өчен сарай ишеге ачык, диган сүз иде бу. Ә Милентьевка патшаның сүзләре бөтенләй икенче төрле тәэсир иттеләр. Сарай тирәсендәге тормышның нинди икәнен ул, үз күзе белән күреп, бик әйбәт белә иде инде, шунлыктан үз гаиләсенә нинди куркыныч янаганлыгын яхшы аңлады. Мелентьевның күзләрендә усал очкыннар ялтырап куйды. Ул ап-ак булды. Әмма, үз-үзен тыеп, патша алдында түбәнчелек белән бил бөкте:

— Мәрхәмәтле сүзләрең өчен мең-мең рәхмәт әйтәбез, бөек падишаһ,— дип җавап бирде ул.— Ходай сиңа озын гомерләр бирсен. Ә Василиса белән эш болай: ат өзәңгесе тотып торучы гади хезмәтченең хатынына патша күзе алдында басып тору килешми. Бар, үз эшеңдә бул!— дип өстәде ул хатынына кырыс тавыш белән.

Василиса тагын бер тапкыр патша алдында бил бөкте һәм чыгып китте. Әмма шул арада патшага шук караш ташлап өлгерде: ә ул — хатын-кызларның иң ышанычлы коралы бит!

Чибәр хатын чыгып киткәч, аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торган патша Мелентьевка таба борылды:

— Василисаны бүген үк сарайга җибәр,— диде ул каршы төшмәслек итеп.— Яшьлегән әрәм итеп монда ятмасын!

Мелентьев бер сүз дә җавап бирмичә баш иде. Патша тиздән кайтып китте.

Әмма Василиса ул көнне дә, иртәгесен дә сарайга килмәде. Мелентьев үзе дә анда барып күренмәде. Өченче көн киткәч, Иоан аны исенә төшерде. Өзәңгече Мелентьев кайда, дигән соравына, Скуратов, ул авырый, дип җавап бирде.

— Ә Василиса?— дип төпченде патша.

— Анысы да авырып торам дип әйтә,— диде Малюта, иреннәрендә чалынып киткән елмаюын яшермичә.

— Табиб немецны җибәрегез,— дип боерды патша.— Һәм аны кисәтеп куйсыннар: алар яныннан урап кайтуга туп-туры минем янга керсен.

Ике сәгатьтән имче немец Бомелиус патша катына керде. Ул аңа Мелентьевның, чынлап та, җиңелчә сырхаулап торуын, ә Василиса янына аны, табиб кеше булса да, кертмәүләрен әйтте.

— Түшәк хасталарының хәлләрен белеп кайтырга кирәк,— диде Иоан һәм:— Малюта, үзең белән бер фляга хәмер дә ал,— дип өстәде.

Патша, Малюта белән Басмановны ияртеп, Мелентьевларга китте. Хуҗа башын түшәктән күтәрә алмый ята иде. Патшаның теге вакытта көтмәгәндә килеп керүе аны бик тирән борчуга салган иде, хәтта бизгәк тоту авыруы башланган иде.

Патшаның кабат килеп керүе өйдәгеләр өчен тагын да көтелмәгәнрәк булды: йорт хезмәтчеләре Мелентьевның үзен кисәтергә дә өлгермәделәр. Иоан туп-туры аның йокы бүлмәсенә үтте.

— Чир аягыңнан бәреп ектымы, Никита?— дип сорады патша, үз тавышына мөмкин кадәр аның хәленә керергә тырышу төсе биреп.

— Авырып торам шул, бөек падишаһ,— дип җавап бирде Мелентьев, урыныннан көчкә кузгалып.

— Зарар юк, Никитушка, хәзер терелтәбез без сине. Малюта! Безнең хәмерне салып бир әле аңа. Бәлки, шуны йоткач, җиңелрәк булып китәр.

Мелентьев патшага текәлеп карады, Малютага таба борылды һәм бөтенесен дә аңлады.

— Государь!— диде ул калтыранган тавыш белән.— Ходай үзе хөкем итсен сине. Мин сиңа каршы килергә җөрьәт итмим. Мин бары тик... әгәр дә, рәнҗетергә теләп, Василисага кул салсаң, теге дөньядан киләчәкмен мин синең яныңа.

Иоан карлыккан тавыш белән көлеп җибәрде һәм читкә борылды. Шул арада Скуратов, чәркәгә хәмер агызып, Никитага бирде. Хуҗа кеше чукынды һәм кинәт эчеп җибәрде. Берничә минуттан алар алдында мәет ята иде инде.

Мелентьевны күмеп, ике көн узгач, Василиса сарайда күренде. Бик тә зәһәр чибәр һәм купшы хатын сарайда тиз арада беренче урынны үзенә алды. Таушалып, мәлҗерәйгән Иоанны ул үзенә чын мәгънәсендә гашыйк итте: патша аның теләсә нинди капризлы теләген үти иде. Шуннан файдаланып, Василиса Мелентьева кыска вакыт эчендә үзенә көндәш булырлык хатын-кызларның бөтенесен сарайдан кудырды. Һәм шул ук вакытта ул патшаны да янына якын җибәрмәде: анысы өмет белән өметсезлек арасында интегә иде. Ул моны яшерен бер максат белән эшләде: патша хатыны булу иде аның хыялы. Һәм ул тәки шуңа иреште дә! Озакламый патша җиденче никах мәҗлесе үткәрде.

Үзеннән-үзе аңлашыладыр, патриархтан фатиха алу турында сүз дә йөртү мөмкин түгел иде. Чөнки бу никах бернинди кысаларга да сыймый иде; хәер, шөһрәт сөюче Василисага бер генә нәрсә кирәк иде бу очракта: патша хатыны дигән исем алу.

Иоанны Василиса үз канаты астында ике ел чамасы тота алды. Фаҗига көтмәгәндә килеп чыкты.

Бервакыт Иоан швед илчесен кабул итте. Балтика диңгезе буйларының язмышы турында бара иде сүз: шулчак ике ил өчен дә бик мөһим нәрсәләр хәл ителүе мөмкин иде. Шуңа күрә кабул итү палатасына патшаның ышанычлы кешеләре генә чакырылды. Сөйләшүләр иң җитди өлешкә килеп җитте дигәндә генә патша, кызу әңгәмәне кисәк бүлдереп, тәхетеннән торды һәм үз ягына чыгып китте. Швед илчесе, җилкәсен җыерып, тирән аптырашта ялгызы утырып калды. Иоан, кызу-кызу атлап, хатыны янына юнәлде һәм аның йокы бүлмәсенең ишеген кинәт каерып ташлады. Василиса терем уртасында басып тора иде: йөзе кызарып чыккан, әреннәрендә каушау катыш ясалма елмаю катып калган. Иоан артына борылды һәм:

— Малюта! — дип кычкырды.

Скуратов килеп керде.

— Теремны тентеп чык! — дип боерды аңа патша кырыс тавыш белән һәм, ишек катында туктап, авыр таягына таянды. Василиса күзгә күренеп агарынды, әмма бер сүз дә әйтмәде.

Малюта падишаның йокы бүлмәсен җентекләп тентүгә керешге. Озак та үтмәде, ул караватның ефәк чыбылдыгы артыннан лачын өйрәтүче Иоан Колычевны тартып чыгарды. Яшь, чибәр егет, язмышының хәл ителгәнен күреп, терем уртасына чыгып басты һәм ярсуыннан калтыранган патшага кыю караш ташлады:

— Государь! Синең алдагы гаебемне тулысынча таныйм, — диде ул. — Ышерепнитеп торасы юк. Минне аяусыз әшәке җәза көткәнен дә беләм. Тик соңгы сүземне әйтергә рөхсәт ит миңа. Син Василисаның ирен, Никитаны харап иттең, хәзер аның үзен дә юк итәчәксең. Үзеңә читтән бер күз сал әле. Уйлап кара: сиңамы соң яшь хатын белән яшәргә?! Аның урынына...

Шулчак патша таягының очлы башы егетнең сүзләрен бүлдерде. Василиса һушын җуеп идәндә ята иде инде. Патша үзе дә, бумасы тотып, идәнгә тәгәрәде: швед илчесе аны ул көнне көтеп ала алмады.

Икенче көнне Александровский бистәсендә ике мәет җирләделәр. Бистә читендә киң итеп кабер чокыры казып куелган иде. Ә җеназа укучы чиркәү руханиe Кремльдән китерелгән ике табутта кемнәр ятуын да белмәде. Аңа хәтта мәрхүмнәрнең исемнәрен дә әйтәп тормадылар. Чиркәүдәге табутлар янында яшь Басманов кына басып торды. Рухани, бик нык гаҗәпләнеп, табутларның берсендә ниндидер кыштырдау тавышына берничә мәртәбә игътибар итте, ләкин Басмановтан сорарга базмады. Табутларны, чиркәүдән алып чыгып, икесен бер чокырга күмделәр. Басманов кушуы буенча, кабер өстен җир белән тигезләделәр.

Табутларның берсендә Иван Колычевның мәете, ә икенчесендә — аяк-куллары бәйле һәм авызына чүпрәк тыгылган тере Василиса ята иде.

## 12

Кремль сараенда тагын яңа гарем барлыкка килде. Василиса исән чагында туктала торган күпләп кеше үтерүләр кабат яңарды. Плахага беренче чиратта, әлбәттә, Колычевның якын туганнары күтәрелде. Алардан соң Василиса Мелентьеваның нәселен тамырыннан корыттылар. Иоан бу юлы шулкадәр ярсыган иде ки, корбаннардан сорау алганда үзе дә шунда зинданда утырды һәм аларны үз куллары белән газаплады. Гаепсезгә кан кою берничә ай дәвам итте.

Шул ук вакытта Иоан өйләнү кирәклеге турында да онытмады, әлбәттә. Һаман үзенә кәләш эзләтеп кеше чаптырды. Ниһаять, ул хатынлыкка Наталья Коростованы сайлады, ләкин эш көтмәгәндә бер киртәгә барып төртелде. Натальяның бер абзасы Новгородта архиепископ булып тора иде. Шул архиепископ Леонид, Мәскәүгә патша янына барып, туганнан туган сеңлемне синнән мәсхәрә иттергәнче, үз кулым белән үтерәм мин аны, дип кискен рәвештә кырт кисте. Иоан ярсуыннан моның белән әллә ниләр эшләп ташлаячак, дип көттеләр, әмма ул, гаҗәпкә каршы, аның горур сүзләрен тыныч кына үткәреп җибәрде һәм хәтта Леонид белән бик ягымлы итеп сөйләште.

Шул ук көнне сарай мәйданында бүтәннәренә охшамаган бер уен оештырылды. Сарайның арткы ишегеннән аю тиресенә салып тегелгән ниндидер зур төргәк алып чыгып, мәйдан уртасына куйдылар. Шуннан соң эт карауч ылар дистәгә якын бик зур гәүдәле усал этләр алып килделәр һәм аларны җирдә торган төргәккә өстерә башладылар. Этләр, күз ачып йомганчы, башта аю тиресен, аннан соң аның эченә терелэй салып тегелгән кешене өзгәләп ташладылар. Архиепископ Леонид иде ул.

Бу хәлдән соң, карышып маташуына карамастан, Наталья Коростова сарайга урнашырга мәҗбүр булды. Шулай итеп, ул барыбер патшаның кулына килеп керде, тик патша хатыны дигән исемнән генә колак какты. Моңа, ирексездән, аның агасы

Леонид гаепле иде. Хәер, патша Наталья белән барыбер берничә ай гына юанды. Аннан соң ул бичара кыз эзсез юкка чыкты. Сөякләрен, бәлки, хәзерге вакытта казыну эшләре алып барылган Кремль асты мәгарәләреннән археологлар табып алырлар...

## 13

Натальяның юкка чыгуы Федор Нагой дигән боярның Мәскәүгә кайтып кергән чагына туры килде. Ул бик күп еллар инде сөргендә яши иде, шуңа күрә Иоанның көтмәгәндә үзе янына чакыртып алуын ул ни дип юрарга да белмәде. Ә чынлыкта патшаның аны «кичерүе» бик гади аңлатыла иде. Патша каһәренә юлыккан боярның биләмәсенә бервакыт, очраклы рәвештә, Одоевский дигән кенәз Варшавадан кайтып килешли сугылып үткән иде. Польша короле янындагы миссиясе бик тә уңышсыз беткәнлектән, кенәз ничек тә патша белән икесенең арасын әйбәтләргә тырыша иде, шунлыктан ул, буяуларын кызганмыйча, бояр кызы Мария Нагаяның чибәрлеген күкләргә күтәреп мактады. Тырышуы юкка чыкмады: патша шундук, Марияне күрергә теләп, сөрелгән боярны, бөтен гаиләсе-ние бергә, Мәскәүгә кайтарырга боерды.

Одоевский бер дә күпертмәде: Мария Нагая, чынлап та, рус чибәрләренең идеалы саналырлык иде шул (Татар нәселеннән — Тәрж. иск.).

Озакламый, кайтып төшүләренә бер-ике көн дигәндә, Федор Нагойга патша Мәскәүдән ерак түгел бер җирдән зур биләмә бүләк итте һәм берничә көннән үзе дә аларга килеп чыкты. Бу вакытта Иоан бик нык бетәшкән картны хәтерләтә иде инде: хәтта иярендә дә көчкә-көчкә генә утырып тора иде ул.

Федор Нагой патшаны, бил бөгеп, баскыч төбендә каршылады. Ә кунак булмәсендә хуҗабикә, көмеш куна өстенә ике алтын чәркә куеп, көтеп тора иде: берсе — патшага, икенчесе — йорт хуҗасына куелган иде. Иоан өйгә керде, тирәягына каранды, ризасызлык белән кашын җимерде һәм, хуҗабикәнең сәламләвенә җавап бирмичә:

— Әйбәт каршы алмыйсың мине, боярин, — диде. — Мин синең өчен бөтен яхшылыкларымны эшләдем, ә син мине үпкәләтергә ниятләгәнсең.

Нагой югалып калды.

— Мәрхәмәтеңнән калдырма, Бөек Государь, — дип җавап бирде ул. — Сине үпкәләтү турында уйлау мөмкинме?! Нәрсәдән чыгып әйтәсең син аны?

— Ә шуннан: кызыңны күрсәтергә теләмисең миңа. Ә ул, сөйләүләренә карагандa, әйтеп бетерә алмаслык чибәр кыз икән!

Патшаның сүзләре Нагойга үзен «кичерү»нең сәбәбен ачык аңлатып бирде. Әйтергә кирәк, Марияны шуннан алда гына сөргендәге биләмәләренә күрше булып яшәүче бер боярның малаена димләгән иделәр алар. Әнә шуңа күрә ул гүзәл кыз әтиләре белән бергә Мәскәүдә түгел иде. Ә патшага бу турыда дөресен әйтеп бирү бик куркыныч, чөнки боярга бөтен гаиләсе белән бергә кайтырга боерылган иде. Нагой патшага, кызым авырып тора, дип әйтеп котылмакчы булды, Әмма Иоан аны тиз бүлдерде:

— Зыян юк, боярин, — диде ул шат күңел белән. — Кызыкаең хаста булса да, күрәсем килә. Янына алып бар мине.

Хуҗабикә, куркуыннан, кулындагы кунасы белән чәркәләрен идәнгә төшереп җибәрде. Чәркәләр зыңлап идән буйлап тәгәрәп киттеләр, хәмер түгелде. Хәлиткеч мизгел иде бу. Бояр патшаның аягына егылды һәм, кичерүен ялварып, аның боерыгын тулысынча ук үтәмәвен, Марияның бу минутта Мәскәүдә түгеллеген сөйләп бирде.

Көткәнгә каршы, патша аны ачуланмады. Киң күңеллелек күрсәтеп елмайды:

— Менә шулай ул, Федор! Мине карама күленә утырту җиңел түгел. Ә хәзер кызың артыннан шундук кеше җибәр! Берсекөнгә кабат килеп чыгармын. Әгәр дә инде мин икенче килгәндә ул монда булмаса, үзеңә үпкәлә...

Нагой, патша китүгә үк, элекке биләмәсенә чапты һәм кызын алып кайтты. Мария елады, ярәшелгән киявеннән аерганчы, үтер мине дип тә карады, әмма даншөһрәт сөюче бояр, кызының ай-ваена карамыйча, патшаның теләген үтәргә карар кылды.

Нагойларга Иоан үзе әйткән вакытында кабат килеп җитте. Бу юлы аңа чәркәне Мария тәкъдим итте. Патша аны бик нык ошатты. Аның янында ук, бөтен йолаларны бозып, Федорга:

— Ярый, боярин, мин үземә-үзем яучы булам. Кызыңны яраттым, Мәскәү падишасы булыр, — диде.

Мария һушыннан язып егылды. Ә Нагой, мөмкин кадәр нык бөгелеп, патша алдында түбәнчелек белән баш иде. Көткән иде ул моны.

Патша, идәндә һушсыз яткан кызга ымлап, иреннәрен кыйшайтты:

— Күренеп тора: боярышняның күңеленә хуш килмәдем. Зарар юк. Яши-яши ияләшер.

Бер атнадан шаулатып туй иттеләр. Әлбәттә, чиркәү йолалары бу юлы да патриарх белән епископлардан башка гына үтте. Сигезенче никахны да шул ук теге Никита исемле рухани укыды. Туй өстәле янында «туй атасы» булып — патшаның үз улы Федор, кияү ягыннан «кияү егете» булып — Василий Иванович Шуйский, килен ягыннан «кияү егете» булып Борис Федорович Годунов утырдылар. Барысы да Мәскәүнең киләчәктә булачак патшалары иде алар.

Патшаның үз туеннан соң, икенче көнне үк улы Федор да Борис Годуновның бертуган сеңлесе Ирина Годуновага өйләнде (Татар нәселеннән.— Тәрҗемәче иск.). Иоан аны моннан алда гына киленлеккә сайлап алган иде.

Күпмедер вакыт Мәскәү сараенда тормыш тыныч кына үз агымы белән барды. Мария падиша үз язмышына буйсынды һәм Иоанга карата үзен яхшы тотты. Патша үзе дә яңа тормышыннан бик канәгать иде. Бер генә ягы белән ошамый иде аңа яшь хатыны: Мария еш кына бер сәбәпсез балавыз сыга торган иде. Бу аның ачуын кабарта башлады. Беркөнне патша, хатынының елап утырган чагын туры китереп, әгәр дә үзеңне шат тотмасаң, «этләргә тотып бирәчәкмен», дип бик каты кисәтте. Мондый янаудан соң, Мариянең күңеле күтәрелмәде, әлбәттә: патша белән хатыны арасыннан кара мәче йөгереп узган кебек булды. Сарайда элеккечә түшәм күтәреп типтерүләр яңара башлады. Кабат исерекләрнең акырып-бакырып җырлаулары ишетелә башлады, өстерәлчекләр белән кыргыйларча төн үткәрүләр, канлы уенкөлкеләр ишәйде...

Нәкъ әнә шул чорда Иоан, үзенең тәхетен кулыннан тартып алырга теләвеннән шикләнеп (ә бу чынлап та шулай иде), оргияларыннан калмаган өлкән улын, Иоанны, авыр таягы белән сугып үтерде. Бу фаҗигадан соң патшаны алмаштырып куйган кебек булды: Ул хәзер үзе кебек бертуктаусыз кәеф-сафа корырга теләмәүче кешеләргә шикләнеп карый башлады. Мария, бу яктан алганда, аңарда нәфрәт кенә уята иде. Ә патшаның үзендә, киресенчә, шәһвәт ярату хисе көннән-көн арта барды. Ул кайчак акылдан шашар чиккә җитә иде. Бервакыт ул ныклап авырый башлады. Бик нык хәлсезләнде, соңгы айларда аны, гомумән, күтәреп йөртергә туры килә иде. Ничектер бер төнне аның янында улын үтергәннән соң ятим калган килене, ул-бу булмасын, дип, кизү утыра иде. Иоан бермәлне үзенә хәл кереп киткәндәй тойды. Ярдәм итүләрен көтмичә, үз көче белән урыныннан торды. Килене кәнәфидә йокымсырап утыра иде. Иоан көтмәгәндә аңа, кулларыннан үзенә таба тартып, мәхәббәте тууы турында дәртләнеп сөйләргә тотынды. Көрмәкләшү китте. Иоан аны, бөтен көчен куеп, караватына егып салырга маташса да, килене көчлерәк булып чыкты: аның кулыннан ычкынып, үз бүлмәсенә йөгерде.

Бу — патшаның үз гомерендә соңгы тапкыр талпынып алуы иде.

Дөрес, ул озакламый торып аягына баса башлады, ләкин аның соңгы сәгате сугарга күп калмаганлыгын барысы да яхшы аңлыйлар иде инде. Моны патша үзе генә сизми иде әле. Ул тагын хатын алмаштырырга әзерләнергә кереште.

Патшага шул чорда Англия королевасының бик тә чибәр бер туганы бар икән, дип сөйләгәннәр иде, ул әнә шул Гонтингон графинясын — Мария Гастингсны кулга төшерү турында хыяллана башлады. Ул инде хәзер, Мария Нагаяга карата булган начар мөнәсәбәтен, хатынының бала табарга торган чагы булуына карамастан, чит кешеләрдән дә яшерми иде. Иоан Лондонга Федор Писемский исемле дворянны «кәләш күреп кайтырга» җибәрде: «Королева галиҗәнапләренә Мария Нагаяның чын падиша түгеллеген һәм аның тиздән, чәче кыркылып, монастырьга җибәреләчәген» җиткерергә кушты ул аңа.

Әмма Иоанның явызлыклары турында бик күп ишеткән Мария Гастингс моны тыңларга да теләмәде. Аптырагач, королева Елизавета бик оста бер хәйлә уйлап тапты: Мария Гастингс шушы була дип, патша илчесе Писемскийга ниндидер шадра йөзле бер сазаган кызны күрсәттеләр. Аны күргәч, илче Мәскәүгә ашыкты: Мария Гастингсны чибәр дип алдаганнар, ул убырлы карчыктан да ямьсезрәк икән, диде.

Елизаветаның хәйләсе өчен Мария Гастингсның гүзәллеге турында патшага сөйләгән инглиз лейб-медик Роберт җавап тотты: аны зинданда җәзалап үтерделәр.

Әмма бу эш моның белән генә тәгәлләнмәде: инглизләр королевасы Мәскәү белән икс араны якынайтырга бик тели иде, ул тиз арада Иоан янына үзенең чиктән тыш вәкаләтле илчесе Джером Баусны җибәрде. Ул Иоанга королеваның үз кулы белән язган хатын тапшырырга тиеш иде, ә анда королева рус патшасына, Мария Гастингс урынына, үзенең бертуган агасының кызына, күптән түгел генә тол калган Анна Гамильтонга өйләнергә тәкъдим итте.

Ләкин бу проект тормышка ашмый калды: Иоан, Елизаветаның бик күп шартларына, Англия сәүдәгәрләренә Рәсәй җирендә чиксез ирек бирү, алар китергән товарлар өчен ясак түләтмәү, бүтән илләрдән килгәннәргә аны икеләтә арттыру, Кремльдә бер генә рус хатын-кызын да калдырмау, шул исәптән, Мария Нагаяны

да куып җибәрү һәм шуның ише тагын башка шартларының бөтенесенә дә диярлек бирсүзсез күнсә дә, соңгысына батырчылык итмәде, чөнки Мария бала табып өлгергән иде инде. Баус бернисез кире кайтып китәргә мәҗбүр булды. Иоанның гомерендә беренче мәртәбә кеше хәле белән исәпләшүе иде бугай бу. Әмма патша «йомшаклык күрсәтүе» өчен үкенүен икенче көнне үк ачык белдерде: аңа Мариянең, ниһаять, аякка басуын һәм «улы белән бергә (Дмитрий исеме бирәләр ул балага) патшаның мәрхәмәтле күзләренә күренергә теләвен» җиткергәч, Иоан бик дорфа итеп:

— Үз теремында гына утырсын һәм чакырылмаган җиргә тыкшынмасын!— дип кырт кисте.

Мария аны яңадан табутында ятканда гына күрә алды.

1584 елның 17 мартында патша Шуйский кенәзне Швециягә җибәрде: аңа күптән түгел швед короленең бик тә чибәр бер хатын-кыз туганы бар, дип әйткәннәр иде. Иоан Швеция королена сансыз күп ташламалар ясарга вәгъдә бирде һәм аңа якын дуслык тәкъдим итте. Әмма Шуйскийга Русь дәүләтенең чиген үтеп чыгарга язмаган иде: икенче көнне аны атлы хәбәрче куып җитте һәм Иоан Васильевич патшаның үлүе турында хәбәр итте. Иоан, шахмат уйнап утырганда кинәт тәгәрәп, җан биргән иде.

Ризван **ХӘМИД** тәрҗемәсе.

**ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН**

*Унтугызынчы гасырның бөек рус әдипләре, Рәсәй үз тарихында өч зур кайгы кичергән, дип санаганнар: Ярославна кайгысы, монгол явы кайгысы һәм... Иван Грозныйдан (Дуртенчедән) күргән кайгы. Ә тарихи шәхесләрдән кемнәргә күбрәк мөрәҗәгать иткәннәр дисәк, әдәби һәм фәнни әсәрләрнең үзәгендә, Борис Годунов һәм Бөек Петрдан кала, шулай ук Иван Дуртенче патшаны күрербез. Без, татарлар, «Явыз Иван» дигән кушаматка бөтенләй икенче төрле эчтәлек бирәбез — чөнки сәбәбе баштан ашкан! Ә бит Иван Дуртенчегә ул кушаматны безнең бабалар түгел, патша исән чагында ук рус халкы үзе биргән. Сере нәрсәдә соң моның? Бер яктан карагандa, ул — хәрби полководец, дәүләт эшлеклесе һәм Рәсәйнең иң беренче рәсми патшасы, ә икенче яктан — Явыз Иван, Рәсәйгә иң зур кайгы китерүче. Сәер түгелмени бу? Бер-берсе белән сугышып, аерым биләмәләргә таркалып беткән рус халкын берләштереп, дәүләтен башка халыклар җире исәбенә дистәләр тапкыр киңәйтсен дә, «Явыз» дигән ләгънәт алсын, имеш! Бүген генә ул кайбер шовинистлар Казан ханлыгы әлеге чорларда Рәсәйнең вассалы булган, Мәскәүгә ясак түләп торучы мескен бер ханлык булып яшәгән, дип исбат итәргә тырышалар. Казан ханлыгы барыбер таркалып юкка чыккан булыр иде, янәсе. Юк, монда нәрсәдер тотапшып бетми: кем инде аек акылдан үзенең кул астындагы бер мескенне җиңгәне шатлыгыннан нәкъ Кызыл мәйдан уртасына — Рәсәйнең иң изге саналган җиренә «Василий Блаженный храмы» кебек һәйкәл төзеп куя?! Андый «тарихчылар»ның максаты астыртынга охшый: мөстәкыйльлегегезне югалтканга артык пошынмагыз, Казан ханлыгының бүгенге варислары, әллә ни югалтмагансыз, Рәсәй сезгә прогресс алып килгән, дияселәр килә кебек.*

*Иван Дуртенченең кем, нинди кеше булганлыгын белү безнең өчен бик кирәк. Аның дәүләт башлыгы буларак кылган эшләре турында укучы яхшы белә. Тагын нәрсә билгеле? Татар телен, үз ана теле кебек, су урынына эчкән (Карамзинны укып карагыз), эпистоляр жанрда борынгы рус әдәбиятында мәгълүм эз калдырган, кырыс холыклы патша. Ә шәхси тормышында нинди булган икән ул? Тарихи шәхесләрнең иҗтимагый эшчәнлегенең серле яклары еш кына аның шәхси тормышы аша ачыла бит. Әнә шуңа күрә без Иван патшаның гаилә тормышына мөрәҗәгать итәргә булдык. Укучы үзе нәтиҗә ясар. Бигрәк тә XX гасыр явызы Сталинның кемнән үрнәк алуы ачык күренер, дип уйлыйбыз.*

*«Явыз Иванның хатыннары» исемле бу документаль әсәр 1912 елда Мәскәүдә «Дело» китап нәшриятында басылып чыккан.*

# НӘВАИНЫҢ ШИФАЛЫ ЙОГЫНТЫСЫ

Үзбәк халкының тиңдәшсез шагыйре, олуг фикер иясе һәм дәүләт эшлеклесе Нәваиның тууына 550 ел. Галишер Нәваи яшәп иҗат иткән вакыттан безнең көннәргә кадәр күп сулар аккан. Бу дәвер эчендә кешелек дөньясы зур үзгәрешләр кичергән: әүвалгеләре урынына башка типтагы җәмгыятьләр барлыкка килгән, кешеләр дә үзгәргән, карашлары киңәя, рухиятләре байый барган, берсе икенчесен яңа буыннар алмаштырган. Шулай булуга да карамастан, ерак үткәннәрдәге бөек затлар калдырган иҗат җимешләре үзләреннән соңгы һәр заманның яңа буын укучысына һаман да рухи азык һәм илһам чишмәсе булып кала килаләр. Чөнки ул әсәрләрдә бөтен кешелек дөньясын кызыксындырган мөһим мәсьәләләр чагылыш тапкан була. Аларда гаделлек, тигезлек, хөрлек, кешене олылау, илгә, халыкка турылыклы булу идеялары алга сөрелә. Шуңа күрә дә, андый әсәрләр дәүләт, кыйтга чикләрен үтеп, һәр яңа заман укучысының күңеленә хуш килеп, аны биләп алалар. Нәваи әсәрләре — әнә шундыйлардан.

Күп халыкларның дөнья шигърияте күгендә Гомер һәм Фирдәүси, Низами һәм Руставели, «Игорь полкы турында җыр» авторы һәм Кол Гали, Данте һәм Нәваи, Шекспир һәм Пушкин, Гете һәм Шевченко, Мәхтүмколый һәм Тукай кебек якты йолдызлар бар. Галишер Нәваи әнә шул йолдызлар төркеменең иң мөхтәрәм урынында. Ул үзенең тере вакытында ук легендар шәхескә әверелде, бөек шагыйрьлеге, чын кешелеклелек сыйфатлары белән телдән-телгә күчеп, макталып сөйләнде, даны еракларга таралды. Нәваи «югалып кала торган гына бер исем түгел. Бу шундый бер нурлар чәчеп торган исем ки, аның балкыган шәүләсен бөтен җирдән табарсыз»[1], — дип язды шагыйрь, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе Н. Тихонов.

Нәваи үзенең шагыйрьлек даһилыгын, дәртен, көчен һәм тынгысыз эшчәнлеген халкына, иленә хезмәт итүгә багышлады һәм шул юлда тормышның күп авыр сынауларын башыннан кичерде.

Анда искиткеч җанлы картиналар, сокландыргыч табигать манзаралары, ил белән гаделлек нигезендә идарә итүче идеаль хөкемдарлар, соңгы сулышларына кадәр турылыклы булып калган мәхәббәт каһарманнары — барысы да бар.

Бу иҗат мирасы — алдынгы кешелек мәдәниятенең гүзәл казанышларыннан. Ул төрле жанрда утыздан артык зур әсәрләр калдырды. Аның лирик шигырьләре «Чар диван»га («Дүрт җыентык»ка) тупланган. «Хәмсә»гә («Бишьлек»кә) атаклы биш дастаны кергән: «Хәйрател әбрар» («Изгеләрнең хәйранлыгы»), «Фәрһад вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Сәбгаи сәйяр» («Җиде сәйяр»[2], «Садди Искәндәр» («Искәндәр дивары»). Болардан тыш, Нәваиның «Лисанет тайр» («Кош теле»), «Мәхбүбел-колуб» («Күңелләрнең сөйгәне»), «Мизанел-әүзан» («Вәзеннәр үлчәве»), «Мөхакәмәтеллөгатәйн» («Ике телнең бәхәсе»), «Рисаләи мөгамма» («Шигырь сере турында рисалә»), «Вәкъфия»[3], «Китабел-гаруз» («Гаруз турында китап») шикелле мәшһүр әсәрләре бар.

Халык феодаль тәртипләр кысуында җисми һәм рухи изелеп яшәгән бер вакытта, Нәваи гаделлек нигезендә җәмгыятьне савыктыруны куйды һәм кешене рәхәтлектә яшәтергә теләде, аны зурлады. Шушы гуманлык — кешелеклелек идеяләрен ул үзенең тиңдәшсез таланты белән тудырылган гаҗәп әсәрләрендә чагылдырды, акыл көчен, сәләтен, йөрәк тибешен халыкка багышлаган һәм шушы юлда үзен корбан итәргә әзер торган Фәрһад кебек каһарман образларын иҗат итте, сүз сәнгатенең искитмәле матур әсәрләрен бирде.

Бөек Галишер Нәваи татар халкына бик якын. Ул аның үз кешесе, үз шагыйре кебек. Үзбәк һәм татар халыкларының бик электән килгән мәдәни һәм әдәби мөнәсәбәтләре моны ачык күрсәтә. Үзара бу бәйләнешләрнең тарихы тирән, бай.

Ислам дине Идел буе болгарларына, хәзерге Казан татарларының борынгы бабаларына, Урта Азия аша үтеп кергән. Ул вакытларда мөселман мәдәниятенең үзәкләреннән берсе — Бохара хәлиткеч роль уйный. Сәүдә һәм икътисади мөнәсәбәтләр белән бергә, мәдәни бәйләнешләр тагын да үсә.

---

[1] Тихонов Н. Низами һәм Нәваи. — «Совет әдәбияты», 1947, № 9, 112 б.

[2] Кайбер очракларда «Җиде планета» дип тә әйтелә.

[3] Вәкъфия: вәкыфлекне — җәмәгать файдасына вәгъдә ителгән байлык, милек-мөлкәтне билгеләү турында (әсәр).

Ислам дине белән бергә, болгарларга яңа язу килә. Бу үзе генә дә зур мәдәни казаныш була. Болгар дәүләтендә тәрәкъкыятькә киң юл ачыла. Гарәп дөньясыннан, Иранннан, Урта Азиядән Болгарга галимнәр килә, мәдрәсәләр ачыла, китап тарала. Дини әсәрләр белән бергә фикъһе, адаб, тыйб, фәлсәфә, нәфис әдәбият, шигърият әсәрләре дә киң урын алган була. Болгардан барган яшьләр Бохара, Сәмарканд, Һират, Бәлх, Багдад, Таһран, Тәбриз мәдрәсәләрендә белем алалар һәм алар аңда гарәп, фарсы-таҗик, үзбәкнең мәшһүр галимнәренең әсәрләре белән танышалар. Шунлыктан Болгар иленең укымышлылары Әбу Мөхәммәд ал-Харәзми, Әбу Насыйр Фараби, Әбу Рәйхан Бируни, Әбугалисина кебек бөек галимнәрнең һәм бик күп голамәләрнең әсәрләрен белгән булалар. Болгар зыялылары гарәп, фарсы телләрен яхшы үзләштереп, үзләре дә әсәрләрен күбесенчә шул ике телдә язганнар.

Урта Азиядән Йосыф Хас-Хаҗибнең «Котадгу белег»ен, Әхмәт Югнәкинең «Һибәтел-хәкаек»ын, Әхмәт Ясәви һәм Сөләйман Бакырганиларның хикмәтләрен болгарлар яхшы белгән. Ә. Ясәви белән С. Бакырганиның суфичылык карашлары Идел буенда киң таралган, болгар-татар әдәбияты тарихында аның киң катлау халык мәнфәгатьләре белән бәйләнгән тормышчан, һәр төр золымга, гаделсезлеккә каршы юнәлдерелгән оппозицион агы да көчле була. Шундый мәдәни һәм әдәби бәйләнешлар мохитында Болгар илендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» кебек әсәре дөнья күрә.

Болгар, Алтын Урда составына кергәч тә, мәдәни һәм әдәби үсешен туктатмый, хәтта ул бу дәүләтнең мәдәниятен барлыкка китерүдә нигез була һәм аны алга таба үстерүдә мәркәзгә әйләнә. Күп галимнәр, әдипләр, шагыйрьләр Идел буена килә ләр. Сарай Бәркә мәдәният учагына әверелә. Алтын Урда заманындагы мәдәниятнең нигезен тәшкил иткән Болгар мәдәнияте Казан ханлыгы һәм аннан соңгы дәверләрдәге мәдәниятнең дә гомуми әсасе һәм аның дәвамы булып тора.

Казан ханлыгында Урта Азия белән үзара мәдәни бәйләнешләр конкрет төс ала. З. М. Бабыр үзенең тарихи сәхифәләрендә болай яза: «Шәйбани ханның яхшы сорутлар вә хуб нәкъкашлары бар иде. Ул заманда анче соут вә нәкъкаш баглар кеше юк иде. Ахыр Шәйбани хан (аларны) Казан ханы Мөхәммәл Әмин ханга йебәрде».

Бу — гаҗәеп дустанә, мәдәни бәйләнешләрнең бер күренеше. Димәк, болар арасында җырчылар, рәссамнар, музыкантлар белән бергә, әдипләр, шагыйрьләр дә булганнар, дип ышанып әйтә алабыз. Алар үзләре белән Казанга музыка кораллары, сәнгать әсәрләре, китаплар китерүләре бик мөмкин. Нәваиның Казанда саклана торган «Хәмсә»се белән «Чар диван»ы XVI йөзгә караган нөсхаләре шундый юл белән килгән дип уйларга кирәк. Казандагы кулъязмалар фондларында Нәваи әсәрләренең берничә дисталәгән нөсхаләре саклана. Татар укымышлылары тарафыннан гасырлар буена төзелә килгән мәҗмугаләрдәге Нәваи шигырьләрен, газәлләрен санап бетерү мөмкин түгел. Татар әдәбияты тарихында Нәваи әнә шулай урын алды һәм аның үсешенә йогынты ясап торды. Татар шагыйрьләре, әдипләре өчен Нәваи илһам диңгезе булды.

Бу — XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗатында бик ачык күренә. Титан Нәваи белән ярсу йөрәкле Мөхәммәдьярны заман сорауларына айнык караулары, золымга корылган җәмгыятьне савыктырырга омтылулары, халыкның авыр язмышын җиңеләйтергә тырышкан теләкләре якынайта.

Нәваи иҗатындагы төп мотив — кеше турында кайгырту, хезмәт кешесен зурлау, аның акыл көченә дан җырлау. «Хәйрател-әбрар»да ул болай ди:

*Адәми ирсәң, димәгел адәми*
*Аны кем, юк халык гамедин гами.*

Бу юлларны кешелек җәмгыятенең чын асылы — кешедә, кешенең яшәешендә, аның иҗади көчендә икәнлекне яхшы аңлаган акыл иясе генә әйтә алырга мөмкин иде һәм Нәваи аны әйткән дә.

«Хәйрател-әбрар» иҗат ителгәннән соң 426 ел үткәч, Тукайның:

*Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,*
*Һич кайгысыз кеше булса — адәм түгел, —*

дип язуында Нәваидагы шул ук фикер, мәгънә яңгырады. Урта Азия җирлегендә чәчәк аткан Нәваи иҗатындагы кешегә кешеләрчә, гуманлы караш гасырлар аша ерак Идел буендагы уңдырышлы туфракта җимеш бирә — үзенең яңадан чагылышын таба.

Мөхәммәдьяр да:

*Нәфегъ тикүр адәмгә сәни кән,*
*Гакыйл ир, ир куңлигә салма түңел, —*

дип, кешегә файда китерергә, аның дәрәҗәсен сакларга, кайгыга дучар итмәскә чакырды.

Халыкка намуслы хезмәт күрсәтү теләге Нәваиның күз уңында булды.

*Ирәнләр хезмәтедин чикмәгел баш.*
*Әгәр башынга гәрдундин йагар таш, —*

дип, Нәваи батырларча аваз ташлады.

Мөхәммәдьяр да, Нәваи эзеннән барып:

*Мән тәкый фәрман биләдур һәр эшем,*
*Куймаган ил куңли чөн гәрдешем, —*

дип, халык өчен үзенең эшчәнлеген туктатмаячагын белдерә.

Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында кешене бөек яратылыш итеп карау, кешелек җәмгыятен гаделлек нигезендә савыктыру, илне тәзекләндерү һәм шуларның нәтиҗәсе буларак халыкны рәхәт тормышка ирештерү идеясе Нәваидагы утопия карашларына барып ялгана.

Нәваи өчен дә һәм Мөхәммәдьяр өчен дә хөкемдарның нинди диндә булу яисә булмавында түгел, ә аның гаделлегендә.

Хөкемдарның үзендә гаделлек сыйфатларын тәрбияләүдә бердәнбер юл итеп ул заманда үгет-нәсихәт саналды. Дидактик әсәр булу ягыннан Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы аеруча характерлы. «Нуры содур»да, Сәгъдинең «Бостан»ындагы һәм Нәваиның «Махбубел-колуб»ендәге кебек, гадел булмаган җәмгыять тәртипләре гаепләнә һәм гадел хөкемдарда булырга тиешле әхлак сыйфатлары санала: беренче урында гаделлек, сәхи-юмартлык, рәхим-шәфкатьлелек, вафа — сүздә тору, гафу итүчәнлек, дөресне сөйләү. Кешеләрдә югары әхлак, мораль, әдәп сыйфатлары булдырырга тырышу һәм чор җәмгыятенең алдында торган һәм ул хәзерге заман өчен дә актуаль булып кала.

Түңел — борчылу, өметсезлек.

Нәфегъ — файда.

Ирәнләр — ир-егетләр.

Гәрдун — күк.

Бу урында Нәваи йогынтысы уңаеннан Мөхәммәдьярга киңрәк тукталуга сәбәб шунда ки, Нәваи вафатыннан соң ул аның иҗатына беренчеләрдән булып мөрәҗәгать итә һәм андагы алдынгы идеяләр, югары сәнгать чаралары, тормышчан образлар белән татар әдәбиятын баета.

Нәваи татар әдипләре, шагыйрьләре өчен үрнәк, остаз булды. XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колый Нәваи иҗатында билгеле бер урын алган оппозицион суфичылык мотивларына хас шигъри сыннарны файдаланып, дөньяви эчтәлекле тормыш күренешләрен сурәтләде.

Татар мәдрәсәләрендә шәкертләр Нәваи әсәрләрен яхшы белгәннәр, аларны дәреслек итеп файдаланганнар. XVII йөз ахырында бер шәкерт «Рисаләи шамсия» исемле фикъһе китабының буш кәгазенә 12 юллык газәл язып калдырган. Ул:

*И Нәваи, әһле дәрднең һич дәвасы юк икән,*
*Дәрд* өчен дәрман теләрмен, һич (тә) дәрман мәндә юк, —*

диган бәет белән тәмамлана.

Шәкерт Нәваины үзенең рухи җитәкчесе, юл күрсәтүчесе санап мөрәҗәгать итә. 1748 нче елда Казан губернасы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә шәкерт Рәфикъ бине Биккол, Сәгъдинең «Гөлстан»ын күчереп тәмам иткәч, азагында:

*Пәрем* булса, очуб кидсәм алысдин та канатым бар,*
*Канатым көйсә очмакдин, йөгүрсәм та хәйатым бар, —*

диган бәетне язып, Нәваидан дип күрсәткән.

Күренә ки, татар мәдрәсәләрендә шәкертләр Нәваины яхшы белгәннәр һәм бу бөек остазның иҗаты алар өчен җан азыгы биргән.

XVIII гасырның ахырында яшәгән татар шагыйре Сиражетдин Кызыл-Җари үзенең газәлләрендә Нәваины еш кына телгә ала.

Татар халкы Нәваи йөзендә үзбәк шигъриятен әнә шулай якын иткән. Нәваиның үзен илһам рухын өрүче санаган, аның талантын югары бәяли белгән.

Нәваи әсәрләре хрестоматияләргә кертелеп, мәдрәсәләрдә кулланма итеп файдаланылган. Татарстанның Тимәш авылы мәдрәсәсендә Әхмәдҗан бине Мөтәһһар тарафыннан 1840 нчы елда төзелгән «Шигырьләр тәзкирәсе»ндә, М. Ивановның 1842 нче елда басылган «Татар хрестоматиясе»ндә, С. Кукляшевның 1848 нче елда нәшер ителгән «Диваны хикәяте татар» дәреслегендә Нәваиның бик күп шигырьләре, газәлләре кергән.

Урысның көнчыгышны өйрәнүчесе профессор И. Н. Березин XIX йөз урталарында Казан император университеты матбагасында нәшер иткән «Төрек хрестоматиясе» томнарында Нәваиның берничә дисталәгән шигырьләрен, газәлләрен, «Мәхзәнел-әсрар» кебек дастанын бастырып, алар белән күп төрле халыкларның укучыларын таныштыруда мактаулы, зур изге эшләр башкарды.

Нәваи әсәрләре татар халкына шулкадәр якын ки, аларны укучылар үз шагыйрьләренең әсәрләре кебек итеп белгәннәр. XIX йөзнең беренче яртысында яшәгән Г. Кандалыйның шигырьләр җыентыгында «Аерма» исемендә 8 мисраглы шигырь Нәваиның «Лисанет тайр» әсәреннән алынган. Бу шигырь С. Кукляшевның «Диваны хикәяте татар» китабында да бар.

Г. Кандалый мәхәббәт белән сугарылган шигырьләрендә Нәваи иҗатындагы Ләйлә вә Мәҗнүн, Фәрһад һәм Ширин образларын үзенә үрнәк итте һәм гади халык арасыннан алынган геройларында чын сөю сафлыгын чагылдырырга теләде.

---

* Дәрд — сызлану, газаплану, хәсрәт.
* Пәрем — (каурый) канатым.

*Дәхи борын заманда үтте Фәрһад,*
*Ки Ширин атлы кыз чөн итте фәрйад.*

Бирелә Кандалыйның Нәваидагы каһарманнарны күз алдында тотуы бәхәссез. «Фәрһад вә Ширин» дастанында шундый юллар бар:

*Жобинлар гул-гулу кирпиклары хор,*
*Кабоглар көнг-кенгу, огызлары тор...*

*Саманди саиридин кук тавсани ланг,*
*Куеш рухсори олында хажил рәнг.*

Танылган шагыйрь Әхмәт Исхак тәрҗемәсендә бу юллар бик тә матур яңгырыйлар:

*Яңаклар — гөл, ә керфекләр — энәдер,*
*Ә кашлар — киң, авызлар — кечкенәдер...*

*Атыннан күк аты да артта калыр,*
*Йөзен күрсә кояш, ул да оялыр.*

Г. Кандалый да мәгъшуканы Нәваидагы шикелле купшы бизәкләр белән сурәтли:

*Тулган ай дик йөзең матур икәндер,*
*Ике битең кояш дик нур икәндер.*

*Кашы кара сызылган күз өстендә,*
*Яңа ай дик һавада — күк йөзендә.*

Г. Кандалый күптәннән килә торган шигъри чараларны, әлбәттә, үзенең кичерешләренә, нечкә тойгыларына мауфыйк иҗади эшкәртә.

Нәваи төрки шигырен — назымын төзү сәнгатен дә башлап өйрәтүчеләрдән булды. Аның «Китабел-гаруз», «Мизанел-әузан», «Рисаләи Мөгаммә» әсәрләре гасырлар буена татар мәдрәсәләрендә дәреслек булып кулланылдылар. Шагыйрьләр аларга таянып каләм тибрәттеләр һәм Нәваины остазлары санап горурландылар. XIX йөз шагыйрьләреннән Г. Чокрый иптәшләре алдында шагыйрьлеге белән мактанып та ала торган булган. Шул ук вакыт шагыйрь Вәлиулла Алкаев дусты Г. Чокрыйга мөрәҗәгать итеп:

*Әгәр булдың исәң мәшһүр, орыб лаф улмагыл мәгърур,*
*Вә фәукы келле зи гыйлми галимне ник оныттың син.*
*Могамме фәннедән серне белән-белү бу әсирне,*
*Бу фәнне һәм Нәваи, Физули, Бәдилдин алдың син*[1],

— ди.

Бу юлларда В. Алкаев үзенең һәм Г. Чокрый кебек шагыйрьләрнең сүз сәнгатенең нечкәлекләренә төшенүдә һәм сүзләренә ачкыч табарга тырышуда Нәваи, Фөзули һәм Бәдил кебек мәшһүр осталардан өйрәнгәнлекләрен икърар итә. Әлбәттә, төрки шагыйрьләр өчен Нәваиның остаз булуы бәхәссез.

Татар шагыйрьләре, димәк, дөнья әдәбиятының бик күп төрле җирләрендә алдынгы саналган иҗат ияләренең иң яхшы әсәрләре белән таныш булганнар һәм, алардан өйрәнеп, сүз сәнгатен баетканнар, анда яңа сәхифәләр ачканнар. Бу исә татар әдәбиятының бик еракларданн килә торган көче, тирәнлеге һәм колачы хакында гына сөйли.

Ш. Мәрҗани дә Нәваиның башкалар өчен остаз булуы хакында яза. Ул үзе Бохара вә Сәмәркәнд мәдрәсәләрендә белем алып, мәшһүр галим, философ булып формалаша. Үзбәк мәдәнияте һәм әдәбияты тарихын яхшы белгән Ш. Мәрҗани Нәваи турында да киң мәгълүматка ия булган. «Вәфиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф» әсәренең IV томында Нәваига багышлап язган зур мәкаләдә ул болай ди: «...Галишер Хорасан илендәге галимнәрнең иң бөекләреннән — мәшһүрләреннән, үз заманындагы әдипләрнең иң югары идеалы — үрнәге иде... Мохтаҗларга булышучы, олуг галимнәрнең таянычы, атаклы әдипләрнең ярдәмчесе иде... Галишер Нәваи үтә юмарт, кешеләр өчен һимматле, тырыш, сохбәте утырышы татлы. Мәҗлесләре әдипләр, галимнәр, шагыйрьләр белән тулы булып гөрләп торган...»[2]

Мәрҗани Нәваи эшчәнлегенең күп яклары турында җылы сүзләр белән тәфсилләп сөйли.

---

[1] Мәгънә: *Әгәр син мәшһүр булгансың икән, мактанып тәкәбберләнмә,*
*Күп гыйлемле галимне син нигә оныттың!*
*Шигырь могъҗизасе фәнен белү серләрен*
*Син бит Нәваи, Физули, Бедилдин алдың!*

[2] Мәрҗани Ш. Вәфиятел-әсляф вә Тәхиятел-әхляф. (кульязма). 1850, IV т. 212—213 б.

Татар халкының билгеле мәгърифәтчесе, тарихчысы һәм әдибе К. Насыйри мәгърифәтчелек идеяләрен таратуда, халыкны гуманистик, әхлаклылык сыйфатларында тәрбияләүдә Нәваи мирасыннан киң файдаланды һәм аны халыкка пропагандалады. «Мәхбүбел-колуб»нең аерым бүлекләрен ул үзенең «Фәвакиһел-җөласа фил-әдәбият» (1880) һәм «Кавагыйде китабәт» (1891) дигән әсәрләрендә бастырды.

К. Насыйри «Ләһҗәи татари» (1892) сүзлегенең керешендә укучыларга XIV—XV йөзләрдәге чыгтай-үзбәк әдәбиятының парлак якты йолдызларыннан Лотфи, Нәваи, Бәйкара, Хәйдәр, Бабыр кебек шагыйрьләре турында киң мәгълүмат бирә. «Болар мәшһүр мөсаннифлардыр ки, (иҗат иясе-дер), чыгтай теле аларның мөсаннәфаты (әсәрләре) белән мәгъмур (тәзек) булмыштыр»[1],— дип яза ул.

XIX йөз ахырында язучы Ф. Халиди, Низами һәм Нәваи әсәрләреннән файдаланып, татарча «Фәрһад вә Ширин» һәм «Ләйлә вә Мәҗнүн» хикәяләрен иҗат итеп бастырды.

Татар әдәбияты үсеше тарихында Нәваиның роле бәһасез. Аның иҗат мирасы бостанындагы чәчәкләрнең хуш исләрен бөек Тукай бакчасындагы гөлләр сулышында да сизәсең. Нәваидагы мотивларның Тукайга килеп тоташуы хакында инде әйтелде. Менә тагы бер мисал. Тукайда:

*Очты дөнья читлегеннән*
*Тарсынып күңлем кошы,—*

дигән, кешенең әйләнә-тирә мохитка карашыннан, ә дөньяның кешегә булган мөнәсәбәтеннән барлыкка килгән философик тирән эчтәлекле юллар бар. Шушы юлларны, хәтта тулы мөндәриҗәсе һәм сүзләрдәге охшашлыгы белән башлап Нәваида да очратабыз:

*Йа, җан кошы очты җисми хасдин,*
*Газме ватан әйләде кафесдин.*

Нәваиның татар шигъриятенә булган көчле йогынтысы нәфис классик шигъри энҗе парчалар биргән Дәрдемәнд иҗатында да ачык күренә. Дәрдемәнд, классик әдәбиятыннан файдаланып, осталыгын үстерде һәм гаҗәеп матур шигъри үрнәкләр бирде. Мәсәлән, ул «Рәсем» шигырен Нәваидан дип күрсәтә. Әлбәттә, бу шигырь аңа Нәваи иҗаты аша килеп кергән.

«Шура» журналының башында торган Дәрдемәнд Нәваи иҗатын халыкка таратучылардан булды. Мәкаләләренең берсендә ул Нәваины «төрки шагыйрьләрнең юлбашчысы вә төрки әдәбиятының остазы вә нигез салучысы»[2],— дип бәяләде.

Нәваи иҗаты белән кызыксыну алга таба да сүрелмәде. Совет властенең беренче елларында тозелә башлап, 1923 елда Казанда басылган «Татар әдәбияты тарихы»ның I җилдендә үзбәк әдәбиятына багышланган махсус бүлек бирелә. Аның авторы Г. Рәхим XII гасырда башланган «Чыгтай (үзбәк) әдәбияты бик бай вә көчле... XV гасырда килгән чыгтай шагыйрьләренең иң олугысы һәм иң атаклысы, һич шөбһәсез, Мир Галишер Нәваидер... Ул иң югары урынга куелып, чыгтай әдәбиятының атасы саналган. Чынлап та, Нәваи — Урта Азиянең «Алтын гасыр» әдәбияты өчен классик бер язучы. Ул үз заманында да, үзеннән соң да бик күп тәкълидчеләрнең (иярүчеләрнең) мәйданга килүенә сәбәб булган»[3],— дип язды.

Нәваи мирасын өйрәнүдә профессор Г. Сәгъдинең роле шулай ук зур. Ул Нәваины һәрвакыт дөньякүләм художник итеп таныды, үзбәк халкының бөек классигы дип бәяләде. Нәваи әсәрләрендәге тормышчан мотивлар, чынбарлыкны сурәтләгән реаль күренешләр, кешелекнең алдынгы идеаллары белән сугарылган җанлы образлар Г. Сәгъдигә аны реалист язучы, шагыйрь дип бәяләргә нигез бирде[4].

1940—41 нче елларда Татарстанда Нәваиның 500 еллык юбилеена зур әзерлек барды. Газета-журналларда мәкаләләр басылды. Мәсәлән, галим Бакый Халид Нәваиның 500 еллык бәйрәменә багышлап язылган мәкаләсендә бу бөек шагыйрь иҗатындагы алдынгы карашларны күрсәтеп, аны халыкның дөньяви мәнфәгатьләре белән яшәгән һәм шуларны әсәрләрендә чагылдырган гигант шагыйрь дип атады[5]. Шул вакытта Казан шәһәрендәге урамнарның берсенә Нәваи исеме бирелде. Сугыш башлану сәбәпле, Нәваиның юбилее кичектерелде. Сугыштан соңгы елларда татар мәдәнияте дөньясында Нәваи иҗатын өйрәнү тагын да җанланды.

1948 нче елда Татарстан китап нәшрияты Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» дастанын татар теленда бастырып чыгарды. Әдип вә шагыйрь М. Максуд «Фәрһад вә Ширин» дастанының татар теленә тәрҗемәсе турындагы мәкаләсендә: «Нәваи — халыклар бәхете өчен көрәшүче бөек гуманист һәм аның иҗаты — мәңге үлмәслек әсәрләр»[6],— дип язды.

Әсәрне тәрҗемә итүче Әхмәт Исхак «Нәваи — үзбәк әдәбияты классигы» дигән мәкаләсендә болай ди: «Бөтен дөнья классик поэзиясенең гигантларыннан берсе булган Нәваиның Көнчыгыш ха-

---

[1] Насыйри К. Ләһҗәи татари. Казан, 1892. 3 б.
[2] Дәрдмәнд. Галишер Нәваи.— «Шура» журналы, 1909, № 17.
[3] Рәхим Г. Чыгтай әдәбияты.— Татар әдәбияты тарихы, I җилд. Борынгы дәвер, I бүлек, Казан, 1923, 122, 141—142 б.
[4] Сәгъди Г. Символизм турында. Мәскәү, 1932, 6 б.
[5] Халид Б. Галишер Нәваи (туына 500 ел тулуга карата).— «Совет әдәбияты», 1940, № 4, 72 б.
[6] Максуд М. «Фәрһад вә Ширин» (Рецензия) — «Совет әдәбияты»,— № 7, 1947, 101 б.

лыклары поэзиясенә йогынтысы бик зур булды. Әзербайҗан, төрекмән, казакъ, татар һ. б. халыкларның әдәбияты күп гасырлар буенча аның иҗат йогынтысы астында үсте»[1].

Нәваиның 525 еллык юбилее Татарстанда зур тантанага әверелде. Бу бөек затны татар халкы олуг ихтирам белән искә алды. Нәваиның татар әдәбияты тарихында тоткан урыны турында газета-журналларда мәкаләләр басылды. Фәнни конференцияләрдә докладлар укылды, китапханәләрдә күргәзмә оештырылды.

Урта гасыр үзбәк классик шигърияте сүз гәүһәре диңгезен тәшкил иткән Нәваи иҗаты татар культурасының үсү тарихы белән әнә шулай бәйләнгән.

Нәваи шигърияте әле бүген дә җанга азык булып, җирдә кешеләрне бәхетле итү өчен батыр эшләргә рухландыра. Шул яктан ул төрле милләтнең иҗат көчләренә даими тәэсир итә килде. Нәваи заманыннан башлап, төрки халыклар шигъриятенең алга таба үсеше бу даһи шагыйрь иҗаты белән тыгыз бәйләнгән халдә барды. Нәваи аларга үрнәк булды, аңа таяндылар, аннан илһам, көч алдылар.

Муса Җәлил шигърият дөньясына аяк баскан чорында үзенә сүз сәнгатенең Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Нәваи кебек корифейларының көчле йогынты ясаганлыклары хакында яза.

Татар совет шигъриятенең якты маягы, халык шагыйре Хәсән Туфан үзбәкнең танылган шагыйре Гафур Голәмгә багышлап язган «Ташкент бакчаларында» (1939) исемле шигырендә Нәваи тәэсиренең тылсымлы көче хакында сөйли.

*Чакырып син, гүя, табынырга*
*Төркестанның бөек улларын:*
*Бабыр, Хәйям һәм Нәваи белән*
*Җанымны да минем сыйладың...*
*Иңебездә шунда Нәваиның*
*Иркәләүче кулын сизәбез:*
*Иблискә[2] без, димәк, бирешмичә,*
*Туганнарча яши беләбез.*

Бу мәкаләдә Нәваи турында сөйләгән, фикерләр әйткәннәрнең барлык хезмәтләре дә телгә алынмады. Шундыйлардан: Р. Фәхретдинов, Җ. Вәлиди, Г. Габәши, Ә. Вәлиди, М. Гайнуллин, Х. Хисмәтуллин исемнәрен санап, аларның да сүзләрен китерергә мөмкин иде. Кыскасы, татар мәдәнияте һәм әдәбиятындагы барлык чыганаклар да Нәваи рухына тирән ихтирам белән сугарылган.

Нәваи иҗаты татар халкын Урта Азия һәм Көнчыгыш мәдәнияте белән таныштыруда зур күпер булып торды. Шул күпер аша килгән алдынгы идеяле әсәрләр һәм уңай традицияләр татар әдәбиятын үстерүгә ярдәм иттеләр, үзара туганлык, дуслык хисләрен ныгыттылар. Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә: «Үзбәк әдәбияты Урта Азиядәге бер мәдәниятнең җимеше булып, безгә дә, госманлыларга да, әзербайҗан әдәбиятына да зур тәэсир ясады. Моның алтын дәверендә җитешкән шагыйрьләреннән Нәваи кебекләре Төркестанда ничаклы кадерле булса, Анатолиядә дә шул кадәр мәшһүр иде»[3], һәм Идел-Урал буенда да ул шулай.

**Шакир АБИЛОВ**

---

[1] Исхак Ә. Үзбәк әдәбияты классигы Галишер Нәваи.— «Совет әдәбияты», 1948, № 5, 91 б.

[2] Х. Туфан иблис дип Сталин культы елларындагы куштаннарны, ялагайларны, һәр нәрсәдән гаеп табарга, милләтчелек ярлыгы тагарга тырышып йөрүче әләкчеләрне-гайбәтчеләрне ала.

[3] Ибраһимов Г. Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтләрнең тарихын өйрәнүдә марксизм ысулы.— «Безнең юл», № 2, 1922, 43 б.

# Галишер Нәваи

## Бөекләрнең таң калулары

(«ХӘЙРӘТЕЛ-ӘБРАР» ДАСТАНЫННАН)

Әгәр дә зольмәттән гарык иқән җир,
Агачлар җимешен кояр давыл-җил.

Юләрләр утырса, булып түрә, баш,
Җәүһәр — җир астында калыр,
өстә — таш.

Юлыкса әгәр дә яманга заман,
Кол итәр үзенә барын да һаман.

Яманлык белән гел ат алган Зөһәл[1]
Күкләрдә булыр — ул үзәктә һәрмәл.

Түбән бит тора гел Мөштәри[2] анда,
Ни мәгънә явызлык өстен булганда?

Нәкъ шуннан яхшыга яманлык та, бел,
Бакчаны баса гел чәнечкеле гөл.

Кем дә кем сөттән дә булса саф һәм
пакь,
Теләдер кылычлар бәгырен һәрчак.

Бик горур тотканга кыя тау үзен,
Бетергән яралап ул айдай йөзен.

Яктырак гәүһәрдән булса кем дә кем,
Ул бәла тауларын очрата һәркөн.

Булса да утпәрәст[3] һиндлы кап-кара,
Гел якут тәхеттә, уйлап бер кара!

Кем кемне сүз белән кылса әсир, кол,
Тутый кош шикелле, гел тоткында ул.

Кешеләр йөрәген чукып ерткыч кош,
Патшалар сагында көн күрә тыныч...

Җәберле бер ярлы, гыйлемгә сусап,
Сөекле илкәен китә дә ташлап,—

Ялангач аягы чебиләп беткән,
Чәнечке үләннәр тырнап, кан иткән.

Уралган башына сәләмә чалма,
Сәләмә өстенә син күз дә салма!

Култыкта бар йөге — китап та дәфтәр,
Укырга ашкынып чаба шулкадәр.

Кош кебек гүя ул очып бармакта,
Китабы аның әйләнгән канатка.

Җик күрә, булганга ярдәмгә мохтаҗ,
Бер телем нанлык та акчасы юк, ач.

Дугадай бөгелгән гәүдәсе хәлсез,
Теле тик селкенә, тормый гамәлсез...

Максаты — күрмәгән теләккә җитү,
Ашмаган хыялын чынбарлык итү.

Кешеләр — көтү күк, бер якыны юк,
Кайтырга туган як ерак шактый ук.

Урам да, өй дә күп, дөкан[4], базар да,
Тик белми ул кая кемгә барырга.

Горбәтлек ана нык тәэсир итә,
Кәефе кырылып, саргаеп бетә.

Көнозын каңгыра, күрми тәгам, аш,
Мендәре, төн житсә, урамдагы таш.

Килә алмый һушына, йокылы күзләре,
Уй белән узылган, йокламый төннәре.

Көч-хәлгә, таң аткач, баса аякка,
Юл саба тинтерәп мәдрәсә якка.

Хәлләрен ул кемгә кылмасын бәян,
Шаяртып, көлкегә алалар һаман.

Алганчы өйрәнеп бер фән дәресен,
Гомернең ул җуя иң кадерлесен.

Горбәттә үткән көн яманнан яман,
Моннан да яманны табарсың каян!

Сөйләргә тел бармый хәлләрен аның,
Әйтергә теле юк язган каләмнең.

Шулай ул гамь, заман утларын йотып,
Ун-унбиш ел михнәт газабын татып,

Мәдрәсә алдында билләрен бөгеп,
Иртәдән кичкәчә күз нурын түгеп,

Барына түзеп, гел иза чиксә дә,
Үз-үзен мосафир-сукбай сизсә дә.

---

[1] Зөһәл — Сатурн планетасы.
[2] Мөштәри — Юпитер.
[3] Утпәрәст — утка табынучы, мәҗүси.
[4] Дөкан — магазин.

Китсә дә атланып гореәт атына,—
Бик азлар ирешә үз максатына...

Аздан да күпләр итә канәгать,
Сагалый күпләрен җәфа вә афәт.

Тәгәрмәч кебек зыр әйләнеп заман,
Ахырда камил ул җитешә тәмам.

Җитешеп житкәнче бер сәхибкыран[1]
Утыз ел заманнар туздыра буран.

Күңеле аның нәкъ гыйлем диңгезе,
Гүя шул диңгездә ул йөзә үзе.

Яһүдчә, дисәң, ул белә яһүдчә,
Һинд телен, дисәң, беләдер һиндчә.

Актарсаң, бар гыйлем анда табыла,
Гүя бер тамчыда дәрья чагыла.

Мәгънәле сүзләре үтә йөрәккә,
Сөйли ул һәр сүзен төреп бизәккә.

Каләмен алып сүз яза ул, йә хат,
Бу сүздә чагыла чын әбелхаят[2].

Һәр сүзне бәйләп күк белән, хәл итә,
Синаның[3], төшенеп, төбенә җитә...

Күрсә дә тәкъдирдән шундый илтифат,
Башында шактый ук кайгы-мәшәкать...

Үзенә итсә кем гыйльмен васитә[4],
Халкын да, үзен дә хурлыкка илтә.

Дәрәҗә, дип кылса галим хыянәт,
Бу галим тудырыр җирдә кыямәт!..

Үзем, дип, сузса кул кемдер гыйлемгә,
Бу — тәрү ефәкне нәҗес[5] киемгә.

Әгәр үз юлында нык торса галим,
Гыйлеме буенча эш итсә ганим[6],

Салмаса хәрам мал, байлыкка күзен,
Фани бу дөньяның таныса йөзен, —

Бел аны нуры дип дан җәүһәренең,
Үзедер шуларның ул һәрберенең:

Нур да ул, гәүһәр дә, чын галим үзе,
Йолдызлы асманда ул күкнең күзе.

Кем дә кем җитсә бу югарылыкка,
Гаҗәпләнүләрнең бары да — юкка.

Ямаулы булса өстенә кигәне,—
Шундыйдыр гөлнең дә кайчак күлмәге.

Максатың, Нәваи, гыйлемдер һәрмәл,
Алгач ул гыйлемне, кыл инде гамәл!

*Әдхәт СИНУГЫЛ тәрҗемәсе.*

## Газәлләр

* * *

Хыянәте белән берәү йөрәгемне кан итте,
Сусыз чүлдә күңелемне үзенә ватан итте.

Тугрылык качкандай аннан, аһ, мин дә кача алсам...
Тик юк шул, бу гыйшык минем гомеремне хата итте.

Бу дөньяда тугрылыкка тугрылык тапкан бардыр,
Тик шагыйрь, мең җәфа күреп, йөрәген калкан итте.

Гыйшыктан егылган кеше, сихәт сорама инде,
Бу чирдән һич дәва юк, ул — яшәүне ялган итте.

Дөнья бәһасе түлә дә кулга гади чүлмәк ал,
Җәмшид җамына ымсыну сансызларга сан итте.

---

[1] Сәхибкыран — астрология фәне буенча, ике сәйяра (планета) очрашкан мизгелдә туган бала. Андый бала бик бәхетле вә зур мәртәбәле була, имеш.

[2] Әбелхаят — мәңгелек суы.

[3] Синаның — Әбугали-Ибн-Синаның.

[4] Васитә — яшәү чыганагы.

[5] Нәҗес — шакшы.

[6] Ганим — уңышлы (ганимәтле)

Котылсаң бу арзан гамьнән, и күңелем, шөкер ит,
Бәгъзеләр янә дус табып тажларын тузан итте.

Сорамагыз безнең хәлне, сез — акыл ияләре,
Мәҗнүннәрнең вәсвәсәсе дөньяны кысан итте.

Тугрылык тапкан кешенең бил бөгәрмен алдында,
Хыянәтләр мине шулай буйсынган инсан итте.

Сөрем сөртермен йөзенә, тапсам әгәр күңелне,
Ул минем якты таңымны дөм караңгы таң итте.

Гадиләргә мәрхәмәт кыл, ханым, алла ярлыкар,
Безне ярлы яратып ул, шуңа сине хан итте.

Беркем юктыр, и Нәваи, күктән золым тоймаган,
Берәүләрне чит-ят күреп, берәүне якын итте.

* * *

Толымнарын таратуга, көнем төнгә әйләнде,
Йөзен яшерде ул — кояш ак томанга әйләнде.

Чабып үтте аргамагы — сынган күңелем өстеннән,
Давыл алып китте өйне, ул тузанга әйләнде.

Шул ләләдән аерылу телгәли бәгыремне,
Күзләремнән саркылган яшь кара канга әйләнде.

Аһ иттем, ләкин бәхетем йокыдан уянмады,
Гәрчә йөз мең фетнә купты, мәкер янда әйләнде.

Мин әле сәрхуш түгел дә, тик сакый өчен инде
Бу кеше күптән дәһри, диннән язганга әйләнде.

Кафирә сөеп хур булдым, атлагандай урамнан
Баш иеп — гүя бер кафер мөселманга әйләнде[1].

Чәчмә, былбыл, сагышыңны, моңлы Нәваи кебек,
Гөлләр арасында ул кыз алсу таңга әйләнде.

* * *

Кан йотып гомер буе үземә бер яр эзләдем,
Ләкин мин аны тапмадым, гәрчә гаярь эзләдем.

Берсенә жаным фида кылып сыгынмадым — яр булыр,
Алдады ул, мин аңладым — үземә гарь эзләдем.

Белмимен, бу фани җирдә юктыр ул миңа пар зат,
Аһ, гомер җитмәс табарга... мин барыбер эзләдем.

Ул табылмас инде монда, элпә каплаган күзне,
Мин пәриләр арасында үземә зар эзләдем.

Гыйшык серен күңел менә күз белән фаш итә ич,
Шул серне яшерергә дип җанга юллар эзләдем.

Шәех белән ханәкәдә мин яктылык тапмадым,
Мәйханәгә килеп хәмер тулы гөлсар эзләдем.

---

[1] Урта гасырларда башка дингә күчкән кешене гыйбрәт өчен шәһәр урамнары буйлап йөртә торган булганнар.

И Нәваи, чын иптәшне тапмадым гамьле җирдә,
Ялгызлыкка баттым хәзер, тәңредән әр эзләдем.

* * *

Күз кычыта, диден миңа, әйттем мин: шәраб тамыз,
Нигә аңа шәраб, диден, мин сәрхуш инде ансыз.

Гөл куагында кайчакта йомылган чәчәк була,
Шул тулышкан чәчәк кебек могҗиза синең авыз.

Һич туктамый күз яшьләре, ага төнлә һәм көндез,
Гаҗәп түгел — чайпалганга корымый бакый диңгез.

Йөзең синең — Кояш мәллә, әллә йөзеңме — Кояш?—
Ни аерма? Минем өчен алар икесе игез.

Күзләрем белән кагылам синең этең эзенә,
Минем күзләрем шикелле сибелеп ята ул эз.

Баш иеп каршылый үзбәк, тартынма, вакыт тыгыз,
Ана сөте кебек хәләл тустагандагы кымыз.

Без мәңгегә сакыйларның колы булырбыз төсле,
Шәраб сатучыга лаек мондый ул һәм мондый кыз.

Бу түгәрәк күк гөмбәзе алып килә гамь, михнәт,
Юанычны исә чәркә тирәсендә табарбыз.

Ходай бүлгән вакыт чыгып, аерылсак та бу йорттан,
И Нәваи, тагын килеп тәрәзәсен кагарбыз.

*Ркаил ЗӘЙДУЛЛА тәрҗемәләре.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Диас Вәлиев

# НИЧЕГРӘК ЯШӘРГӘ СОҢ?

УЙЛАНУЛАР*

Безгә, шәт, соңгы биш-алты елда юлыбызга игътибар белән карарга вакыт җиткәндер инде. Алдан ук әйтеп куям — 1985 елның апрелендә ясаган беренче адымы өчен без, һичшиксез, М. Горбачевка рәхмәт әйтергә тиешбез. Җәмгыятебезгә яңалык һәм үзгәрешләр бик кирәк иде. Кызганычка каршы, бу кешенең тарихтагы роле шушы беренче адым белән тәгәлләнде дә инде, чөнки әлеге сәясәтнең нәтиҗәләре коточкыч күренешләр тудыра бара.

Дөньядагы коммунистик хәрәкәткә ифрат зур зыян китерелде. Безнең белән берлек төзегән, безгә тартылган, безнең кебек үк, социалистик җәмгыять турында хыялланган илләрне тәшкил итүче тирә-юнебез тәмам янып бетеп бара. Көнчыгыш Европада, Латин Америкасында, Азиядә, Африкада булсын — бер үк хәл. Варшава солыхы илләренең бердәмлеге дә таркалды, дияргә ярый, НАТО блогы, ике Германиянең берләшүе нәтиҗәсендә, яңа көчләр белән баетылды. Көнчыгыш Германия армиясенең бездәге иң яңа кораллар белән тәэмин ителгән булуын исәпкә алганда, НАТОның куәте ничек, ни бәрабәренә дә чамаларга мөмкин. Шулай ук АКШ белән ике арадагы мөнәсәбәтләр дә безнең файдага үзгәрми. Кыскасы, һәм СССРның, һәм дөньяның куркынычсызлыгы тәмам какшады. 1941 елның көзеннән соңгы чорда, беренче мәртәбә, СССРның мәйдан ягыннан бөтен калу-калмавы да шик астына куела башлады. Илнең үзәге саналган РСФСРны уратып алган барлык республикаларда диярлек, хәзер инде РСФСРның үз эчендә дә, «үзәк»нең сизмәмешкә салышуыннан файдаланып, аерылу хәрәкәте, сепаратистик процесслар җәелде. Моннан биш ел гына элек йодрыктай бердәм дәүләт, бөтен дөнья күз алдында, комлы балчыктай ишелде дә төште.

Инде икътисади хәлләребезне карыйк. Эчкечелеккә каршы уздырылган «мәшһүр» көрәш аркасында илдәге соклангыч йөзем бакчалары кырылды. Берничә республиканың гомерлек һөнәренә, көнкүрешенә, төп икътисадына зыян салынды, наркобизнес яңа куәт алды, дәүләтнең болай да саегып калган кесәсеннән миллиард сумнар астыртын сәүдә итүче «эшкуарлар» кулына агыла башлады. Производствода Дәүләтчә кабул итү ысулын яңарту утыз меңнән артык югары квалификацияле эшчене кысрыклап чыгарды, тик әйберләрнең сыйфаты барыбер яхшырмады. Дәүләт предприятиеләре турындагы камил булмаган закон әйберләрнең кыйммәтләнүенә китерде, сатып алучыга арзанлы товарлар калмады, илне инфляция чире урап алды. Хезмәт халкының бер өлешенә яңа төр ясак салу хезмәт җитештерүчәнлеген киметте, әйберләр азрак чыга башлады.

Хикмәт нәрсәдә соң? Болганчык суда балык шәп каба, диләр бит әле. Билгеле бер төркемдәге сәяси көчләргә илдәге җитешмәүчәнлекләр, йөзләгән качаклар, армиядәге башбаштаклыклар, милләтара ыгы-зыгылар, әле анда, әле монда кабынып-кыбынып ала торган сугышлар уңай тәэсир итә. Мондый шартларда социализмның нигезен какшату бик җиңел ләбаса! Бу «революцион» процессның кем тегермененә су коюын аңлавы авыр түгел. Барысы да — илдәге необуржуазия файдасына. Бусы исә торгынлык елларында барлыкка килгән мафиячеләрдән яралды. Бездәге бу коточкыч хәлләр шулай ук дөнья капиталын да кызыктыра, чөнки мондый мөмкинлекләр, иркен мәйданнар, арзанлы эш көче күптән, төшләренә кереп, аны йөдәтә иде инде.

Мин 1987 елда Бөтенсоюз язучылар конференциясендә чыгыш ясадым. Конференция Ленинградта, Октябрьнең 70 еллыгына багышланып уздырылган иде. Халыкның

* *Авторның «Уйланулар»ы редакция фикеренә туры килеп бетмәскә дә мөмкин, алар укучыга бәхәс төсендә тәкъдим ителә. (Редакция искәрмәсе.)*

җәмгыятьне демократияләштерү, хәбәрдарлык кебек яңалыклардан тәмам исергән чагы. Мин, социализмның һәм, гомумән, дөньяның алдан билгеләнгән бер концепциясен булдырмый торып, алга китеш мөмкин түгеллеккә инанган идем. Шуңа күрә социализмның өч фазалы җәмгыять икәнлеге турында сөйләдем.

Бу концепцияне кыскача гына аңлатырга мөмкин. Капитализм да, үзенең үсеш юлында, өч баскыч үтә: беренче адымында ул туплау чорын кичерә; аннары дәүләт монополиясе капитализмы башлана, тоталитар идарә формалары, диктаторлык режимы һ. б. (Муссолини Италиясе, Гитлер Германиясе, Франко Испаниясе һ. б.); ниһаять, өченче баскыч — демократик капитализм. Монда инде парламент системасы җайга салынган, кешене яклау чаралары көйләнгән (Швеция, Австрия, АШК һ. б.).

Бу юлга басу өчен илдә нык алга киткән промышленность, байлык булу шарт. Мондый мөмкинлекләргә ирешмәгән илләр исә, шулай ук тизрәк үсү өчен, эволюцион юлны өнәп бетермичә, революция аша алга сикерәләр. Сикереш, капитализмның кайсы фазасыннан булуга карап, илдәге хәлләр дә төрлечә формалаша. Кайбер илләр аңа хәтта феодализмның кайбер баскычыннан да сикереп чыгарга омтылалар (әйтик, Россия, Кытай, Монголия, Куба һ. б.).

Социализмның үзендә дә өч баскычлы үсеш котелә: беренчесе — дәүләт капитализмы, монда капиталга дәүләт баш, ә дәүләт исә нинди дә булса бер партиягә берләшкән төркем кулында. Бу баскычта милек тулысынча дәүләт карамагында саклана, илдә кырыс диктатура режимы хөкем сөрә, шәхес дәүләттәге тоталитар идарәгә буйсындырыла. Моңа мисал итеп СССРдагы 1917—1956 еллар чорын, Мао-цзе-дун җитәкләгән Кытайны, Пол-Пот Кампучиясен китерергә мөмкин. Шуннан соң социализм икенче баскычка күтәрелә ала, парламентлы, демократияләштерелгән җәмгыятькә аяк баса. Бердәм дәүләт милке, социалистик базар шартларында, өлешчә шәхси милеккә дә бирелә. Моны җәмгыять бик җентекләп тикшереп тора. 1956 елдан СССРда шул баскычтагы үсеш күзәтелде. Менә шул юлларны узгач, социализмның өченче баскычына атларга була — бу инде тулы демократиягә ирешкән җәмгыять, монда милек формалары бик нәтиҗәле ысулларга тигезләнгән, кеше социаль яктан иң камил яклау чаралары тапкан була. Бу төр җәмгыять әлегә, кызганыч ки, беркайда да тәэзелмәгән.

Менә шушы өченче баскычта кешелекнең үсеше чын-чынлап социализм дәрәҗәсенә күтәрелә дә инде. Бу ноктада капитализм белән социализмның юллары кушыла, алар бер-берсенә каршы системалар булудан туктыйлар, киресенчә, бу юлда алар бер-берсен тулыландыралар. Нәтиҗәдә, кешелек җәмгыятенең иң камил системасы — коммунистик җәмгыять туа.

Социлизмның без хәзер яши торган икенче фазасында һәм аның артыннан килүче өченче фазасында, шулай ук капитализмның өченче фазасында ике система арасында мөнәсәбәтләр тыныч була, чөнки бу чорда аларның арасында уртак максатлар бар. Инде уйлап карыйк: нәкъ шушы дәвергә җиткәч кенә бездә һәм чит илләрдә дә илне капитализмның беренче фазасына, беренчел туплану дәверенә этәрүче мафиоз көчләр, консерватив-реакцион карашлы «укытучылар» килеп чыкты. Әйтерсең лә дөньяга кан коюлы сугышлар, гитлерлар, сталиннар кирәк?! Без бу юлга аяк бассак, андый күренешләрнең тууы — көн кебек.

Фаразларымның бик үк табигый булмавын аңлап, мин бу мәсьәләләргә анализ ясап та күрсәтәчәкмен. Дөрес, мин 1990 елда чыккан китапларымда да, вакытлы матбугаттагы һәм радиодагы чыгышларымда да болар хакында әйткәләгән идем инде. Кабатлануларым өчен кичерерсез. Максатым — кешеләр фикерендә борылыш ясау, искечә уйлаулардан арындыру, теоретик бер яктылык кертү.

Иң әүвәл шуны әйтим: аңлатмаларымда мин беренчелеккә омтылмыйм һәм бу мөмкин дә түгел, чөнки нәкъ шул хакта Маркcның язмалары бар. Моңа кадәр Маркcның мин игътибар иткән «1844 елның икътисади-фәлсәфи кулъязмалары» исемле әсәренә берәү дә күз салмаган шикелле. Бер генә галимебездә дә бу хезмәткә мөрәҗәгать итүне күргәнем юк. Аңлашыла да: моңа кадәр бу язмадан файдалану бездәге сәясәт өчен кулай түгел иде.

Бүген дә әле без күбрәк Ленин-Сталин теориясенең үз җәмгыятебез чорына туры килердәй өлешләре белән генә мавыгабыз. Ленин күбрәк яшәгән булса, Сталинны генсеклыктан куып чыгарсалар, Бухарин исән калса, хәзер бездә нинди тормыш хөкем сөрер иде икән? Һәм башка шуңа охшаш фаразлар корабыз. Мин исә сезне моннан 156 ел элек К. Маркcның социализмга хас беренче баскыч, беренче фаза турында әйткән фикерләре белән таныштырмакчы булам.

«Коммунизмның беренчел баскычында, — дип аңлата ул, — шәхси милек гомумиләштерелә һәм бетерелә... Физик тостә барысын да үз кулына алу — аның яшәеш максаты; эшче категориясе көн тәртибеннән төшми генә түгел, ә бөтен кешегә хас булып кала... Бу коммунизм шәхесне тәмам юк итә... Шәхси милекчелек, бигрәк тә бай милекчелек, һәрчак көнчелек уята, аны юк итү хисен тудыра... Тупас коммунизм исә менә шуңа ирешә: милекчелек бетә, нинди дер минимум турында, яшәү минимумы турында фикер барлыкка килә. Шәхси милекне бу рәвешле бетерү һич тә аннан тулысынча файдалануны күздә тотмый, чөнки бу дәвердә хәтта ирешелгән культура һәм цивили-

зация да кире кагыла, ярлыларның бернәрсәсе дә булмаганнарның гадилегенә яңадан борылып кайту күзәтелә».

Шуңа өстәп тә куя әле Маркс: «Коммунизмның бу тирәндәге уртаклык — бары тик хезмәтнең һәм, гомум бер капиталистның җәмгыятькә түләгәне шикелле, хезмәт хакының уртаклыгы гына».

Каты әйткән! Коммунизмга мондый туры бәяләмәне мин бер генә антикоммунисттан да укыганым юк иде. Һәм шунысы гыйбрәтле: бәя дөп-дөрес һәм ул безнең илдәге 1917—1956 еллардагы тормышка бик туры килә. Аңлашылса кирәк: аның «гомум бер капиталист» дигәне безнең «дәүләт» төшенчәсенә тәңгәл. Дәүләт милке бездәге һәрнәрсәгә, хәтта кешенең үзенә дә иң беренче тамга булып ябышты. Солженицынның «Архипелаг ГУЛАГ» әсәрендәге «дәүләт коллары» образын хәтерегезгә төшерегез!

Инде алга китеп карыйк, социализмның икенче фазасына күчик, Марксның аңа карата мөнәсәбәтенә игътибар итик. Социализмның икенче баскычы бездә КПССның XX съездыннан соң киңрәк сулыш алды: торак төзелешенә игътибар артты, крестьяннар паспортлы, «ирек»ле булдылар, репрессияләнгән миллион җаннарга «аклану» килде. Хәтта әдәбият та бераз иркен мәйданга чыкты. Дөрес, кешегә кешеләрчә мөнәсәбәт сизелсә дә, дәүләтчелектән җәмгыятьчелеккә борылыш булса да, бу әле ярты лаш кына ясалган адым иде һәм ул һич тә барлык ихтыяҗларны канәгатьләндерә алмады. Бу адымның ярым-ярты лыгы, бер яктан, капитализм тарафыннан сугыш янавы белән куркытылып тору, икенче яктан, эш башындагы Хрущев, Брежнев, Андропов, Черненко кебек лидерларның хакимияте белән аңлатылырга тиеш. Брежнев чоры бу хәрәкәткә аеруча зур зыян салды, аны хәтта «сталинчылык»ка кире китү дип тә атарга ярыйдыр.

Маркс социализмның бу чорын болай тасвирлый: а) бу социализм сәяси яктан, демократик яки деспотик; б) дәүләттә әле шәхси милекчелектән китү бетмәгән яки ул әле аның тәэсирен тоя, кешеләр гүя үзләрен аңлый башлаган кебек, үз-үзеннән читләшү юк инде.

Кыска гына шушы бәяләмәдән күренгәнчә, Марксның бу фазаны аңлавы чикле, бик тә абстракт. Аның каравы, без бу фазаны үз җилкәбездә татып беләбез. Бу чорда дәүләт милке җәмгыятьчелек милкенә әйләнә башлый: кооперативлар, арендалар, акционерлык җәмгыятьләре барлыкка килә. Социаль һәм сәяси сферада демократик, хокукый дәүләт туа. Социализм «кешелекле»рәк була.

Кызганычка каршы, бездә хәзер коммунистик җәмгыять турында сөйләү модадан чыкты. Коммунизм идеяләре XX гасыр тарихында коелган кан белән пычратылды. Кызганыч. Уйлап карагыз, бер хатынны бандитлар төркеме көчли икән, монда аның ни гаебе бар?! Коммунизм идеяләрен дә сәяси көчләүчеләр шул хәлгә китереп чыгардылар инде. Мин шулай да кешелеккә якты маяк булып балкырга тиешле коммунистик җәмгыятьне тасвирларга телим. Бу хакта Маркс болай яза: «... шәхси милек бетә — бу бит кешене кимсетүче фактор. Һәм шул чынбарлыкта барысы да кеше өчен генә башкарыла торган чын-чынлап гуманистик җәмгыять туа. Монда кеше белән табигать арасында да, кеше арасында да бернинди дә каршылык калмый». Бу социализм гуманизмга тәңгәл килә.

Аннары ул дәвам итә: «Аңлашыла ки, революцион хәрәкәт шәхси милекнең бетерелүенә таба бара... Бу мәсьәләне хәл итү кешене һәртөрле чикләнүләрдән: диннән, гаиләдән, дәүләттән азат итә һәм аны иҗтимагый чынбарлыгына, кешелегенә кайтара». Яшь Маркс моның белән шуны аңлата: коммунистик җәмгыятьтә кеше табигать баласы үз башлангычына әйләнеп кайта, субъективизм һәм объективизм, эшлеклелек һәм җитешмәүчәнлек кебек бер-берсенә каршы торучан көчләр юкка чыга. Кыскасы, сәясиикътисади байлыклар яки сәяси-икътисади хәерчелек урынына бай ихтыяҗлы бай кеше килә. «Бай кеше» дигәндә, кешенең рухи байлыкларга булган омтылышын һәм ихтыяҗларын да исәпкә алырга кирәк... Коммунизм, — ди Маркс, -ул киләчәкнең якындагы энергетик принцибы һәм мәҗбүри бер формасы, әмма бу да әле кешелекнең үсешендәге соңгы баскыч түгел...»

Ифрат тирән фикерләр, шулай да мин бәхәсләшүчеләрнең усал сүзләрен дә ишетәм кебек инде. Алар беравыздан: «...Нигә Марксның башлангыч чордагы фикерләренә таянырга?» Яки хәтта: «Әй, бетмәде инде ул классиклар сүзенә ышыкланып, әллә нинди теорияләр чыгарып азапланулар!» — дип җикеренәләр кебек.

Моңа каршы ни дим соң? Маркс — Маркс инде ул. Миңа аның фикерләре тирән тоела һәм мин шулардан файдаланам. Әгәр шул ук фикерләр башкаларда, мәсәлән, Бисмаркта яки Александр Македонскийда табылса, мин алардан алган булыр идем.

Бу урында безнең бүгенге «демократик һәм азат» матбугатыбызда бик тырышып пропагандалана башлаган капитализм турында да берничә сүз әйтергә мөмкин. Вакытында Польшада, СССРда яшәгән француз советологы К. Кароль: «Башта Көнбатышны карикатурага әйләндереп яздылар, — ди. — Хәзер исә шул ук Көнбатыш чынбарлыгын, карикатура дәрәҗәсенә җиткереп, мактарга тотындылар. Әйтерсең лә, монда барысы да — ал да гөл. Шул җәмгыятьтә яшәүче без фәкыйрьләргә бу мактауларның дөреслеккә туры килмәве бик яхшы билгеле бит».

Яки менә АКШ галиме Ральф Нейдер фикере: «Акциялэр миллионнарча кеше кулында булса да, алардан файда күрүчеләр бармак белән генә санарлык. АКШ халкының нибары 1,6 процентын тәшкил итәрлек кешеләр кулында акцияләрнең 92,4 проценты тупланган. Күз алдыгызга 200 кеше сыешлы кечкенә бер залны китерегез. Менә шул залга АКШ промышленностеның өчтән ике өлешен һәм дөнья производствосының өчтән бер өлешен үз карамагында тотучы кешеләрне сыйдырырга була. Аларның көч-куәтенә, мал-байлыгына фиргавеннәр вә императорлар да көнләшеп карар иде!»

Капиталистик илләрнең үз галимнәре әйткән мондый фикерләрне бик күп китерергә мөмкин. Хикмәт шунда: сүз әлеге җәмгыятькә объектив караучы кешеләр тарафыннан әйтелә бит. Шуны аңларга иде: кешелекнең мөкәммәл җәмгыятьне әлегәчә төзеп карый алганы юк. Безгә азмы-күпме теориясе мәгълүм булган коммунизм да абсолют форма түгелдер, дип фараз кылам мин. Моңарчы әлеге шул социализмның беренче баскычындагы безнең җәмгыятьне иң шәп җәмгыять, дип тукып килделәр. Хәзер исә киресенчә ышандырмакчылар: янәсе, бары тик капиталистик мөнәсәбәтләр аша гына җәмгыятькә ирешергә мөмкин. Тегесе дә, монысы да —чеп-чи ялган. Капиталистик илләрнең дә җитешмәгән яклары баштан ашкан. Әлбәттә, капитализм үз мөмкинлекләреннән чыгып иң күркәм сыйфатларны, социаль-икътисади мөмкинлекләрне тудырды. Тик капитализмның мондый үсешкә ирешкән өченче баскычында әлегә берничә ил генә яши. Ул илләрнең кайберләре әле икенче стадиядән чыгып бетмәгән, шуңа күрә фашизм сыйфатлары да, тоталитар режим да җитәрлек саклана. Ә Латин Америкасында, Азиядә, Африкада исә беренче баскычтагы капиталистик илләр күп. Диктаторлык, милитаристик режим, икътисади яктан арттагылык, чит илләргә бурычка бату, киләчәккә булган ышанычсызлык — бу төр илләрнең үзегенә үтә.

Мин, менә шул күзәтүләремнән чыгып, безгә үзебез сайлаган социалистик юлдан тайпылмаска кирәк иде, дип әйтәм. Социализмның икенче баскычына аяк баскач, аның алга булган үсеш юлын ныгытып өйрәнергә һәм билгеләп куярга кирәк иде. Бу аның өченче фазасына күчү мөмкинлеген тудырачак. Монда перспектива бар, моның киләчәге якты, ичмасам!

Кызганычка каршы, безнең пешмәгән сәясәтчеләр илне кирегә тарталар, капиталистик җәмгыятьнең беренче фазасына кертергә азапланалар. Бу юлда безне ниләр көтә соң? Карап карыйк! Швеция, Австрия, ФРГ, США кебек илләр рәтенә баса алырбызмы? Юк, әлбәттә. Безгә бары тик Азия, Африка илләрендәге тормышны гына күтәргә кала: андагыдай хәрби режимнар, переворотлар, фашистик ысуллар... Минемчә, бары тик шулай гына.

Безнең бу «яңа» юлны Көнбатыш галимнәре дә хупламый. Мәсәлән, Гарвард университеты профессоры Дж. К. Гэлбрейт болай ди: «СССРны Смит заманындагы базар мөнәсәбәтләренә этәрүчеләр хаклы түгел... Мин аларга базар мөнәсәбәтенә бары халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү сферасында гына күчәргә киңәш итәр идем. Ә зур предприятиеләрне министрлыклар карамагыннан чыгарырга кирәк... Социализм, яраклаша белмәгәнгә күрә, бүгенге тетрәнүләргә килеп терәлде. Аңа хәзер ашык-пошык примитив капитализм ягына борылырга түгел, акрынлап яраклашу эзенә төшәргә кирәк иде».

Академигыбыз С. Шаталин исә бөтенләй башка якка тарта: «...Җитәр инде! — дип, чәчрәп-чәчрәп чыкты ул. — Болай да хәерче, ярым ач халыкны, коммунистик җәмгыять турында әкият сатып, буш сүзләргә күмеп калдырмыйк! Шәхси милекчелеккә юл куярга кирәк, аның бөтен формаларында! Реаль, азат предпринимательлеккә күчәргә вакыт җитте. Шәхси милекне танымыйча торып, нәтиҗәлелек мәсьәләсе хәл ителмәячәк!»

Мондый фикерләрне, кызганычка каршы, башка галимнәребез дә еш кабатлый. Мин мәсьәләгә башкачарак карыйм. Фикерләремне аңлатырга тырышыйм әле. Иң әүвәл ачыклыйк: бүгенге көнгә безнең икътисад нинди? Ул фәрманга буйсынган, күрсәтмәләргә таянган һәм соң чиккәчә җимерелеп беткән. Житештерүче көчләр (колхоз-совхозлар, завод-фабрикалар һ. б.) белән дәүләт арасындагы (аның Госпланы, Госкомцены, Госснабы, министрлыклары), җитештерүчеләр һәм файдаланучылар арасындагы мөнәсәбәтләргә килик. Бу мөнәсәбәтне булдыручы каналлар шыплап бюрократлар белән тулган, ә мафиоз элементлар аларны таркатып бетергән, шул хәлләр бүлешү мөнәсәбәтләрендә астыртынлыкны тудырып, базар мөнәсәбәтләренә һичнинди мөмкинлек тә калдырмаган.

Брежнев чорында әлеге мөнәсәбәтләрнең бозылуы тәмам баштан ашты. Татарстанның бер район кибетендәге хәлләрне генә искә төшерик. Сүз җиде йөз мең сумлык җәнлек тиреләре турында бара. Менә шул тире, үзебезнең вакытлы матбугат сүзенә ышансак, хәтта базага да эләкмәгән, җәнлек совхозында ук сатылып беткән. Кибеткә исә бары акча гына керә икән. Бу эшнең башында КПСС райкомы, Башкарма комитет, хәтта Эчке эшләр министрлыгы бүлекчәсе кешеләре тора.

Шушы кечкенә генә мисалдан чыгып, илдә реаль властьның кем кулында икәнлеген ачыкларга мөмкин. 1989 елның ноябрь аендагы белешмәләргә караганда, илдәге 150 миллиард сумлык байлык ел саен астыртын юлдагыларга, «күләгәдәге» икътисад иясе кулына кереп бара. Монысы — СССР Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары.

Башкалар исә бу сумманың 500 миллиардка җитүен дә әйтә. Күп нәрсә бездән яшерен алып барыла. Бюджетның күп тармакларында яшерен саннар бар. Хәтта СССР һәм РСФСР халык депутатлары да аптырап-аптырап сорап куялар: кая китә соң үл безнең байлык? — диләр. Республика, әйтик, 6-7 миллиард сумлык табыш бирә, үзендә нибарысы 700 миллион сумлыгын файдаланалар. Калган байлык кемгә күчә? Хәтта Политбюро әгъзалары да партия кассасына кергән миллиардларның ничек туздырылуын белми. Эчке эшләр министры исә колонияләрдәге мәхбүсләр тарафыннан тудырылган дистә миллиардларча сумлык байлыкның кайдалыгын уйлап баш вата. Кассалардагы байлык алар карамагында түгел.

Әле күптән түгел генә безгә, оборона чыгымнары — 17 миллиард (елга), дип белдерәләр иде. Алай булмаган икән. Җитмеш миллиард икән ул. Кайберәүләр әле бу санның да дөрес булмавын сөйли, имештер, ул — 200, хәтта 300 млрд.-ка җитә.

Халыктан аның үз байлыгын шул дәрәҗәдә яшерә алган кара көч безне тәмам аптыраштә калдыра. Бу «көч»нең кайдалыгын белерлек түгел, димәк, ул теләсә кайда була ала. Аның, әлбәттә, депутатлар арасында да, КПСС әгъзалары составында да булуы бик ихтимал. Ә хуҗалык эшләрен җитәкләүчеләрне һәм башкаларны әйткән дә юк инде.

Эшләп-эшләп тә тормышында җиңеллек тапмаган массалар, әлбәттә, производствоның нәтиҗәләренә турында кайгыртмый. Җитәкчеләр, ягъни власть башындагылар — нигездә, алар партаппарат кешеләре булал торган иде — бу хәлдә шулай ук тәэсир итү көченнән мәхрүм итәлә бара. Үзенең көчсезлеген чамалый. Шул рәвешле, җәмгыять алдында бер генә сорау торып кала: инде нишләргә, ничек яшәргә соң?

1989—1990 елларны безнең илдә нәкъ шул сорау тирәсендә бәхәсләр барды. Әмма бер генә сессиядә дә, съездда да мәсьәлә бөтен җитдилеге белән куелмады. Тамырынача ачыкланмады, төп мәсьәләне читләтеп-читләтеп кенә телгә алгаладылар. Чынында исә мәсьәлә бик җитди. Һәм теоретик, һәм практик яктан. Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләр тулысынча үстерелеп җитмәгән. Аны шул хәлендә 1917 елдан кертелгән «хәрби коммунизм» пыран-заран китереп ташлый. 1921 елда моңа яңадан кайтырга бер мөмкинлек булып ала. НЭП башлана, тик аны 1926 елда ук бетерәләр. Бу мөнәсәбәтләр астыртын юл белән яшәргә мәҗбүр итәлә, алыпсатарлар, вак-төяк караңгы бизнес башлана. Сталин чорында бу күренешләрне туздыргалап, хөкем итеп торалар, ә инде Брежнев вакытында өнә шул яман күренешләр гөрләп чәчәк атты.

Кыскасы, социализмның буеннан-буена бу мөнәсәбәтләр, тарихи фактор буларак, яши бирә. Социализмның башлангыч чорларында котылгысыз шушы хәлләр дәвам итәчәген хәтта Маркс та белеп җиткерә алмаган.

Бу объектив үсешне аңламау социализм белән янәшәдә яшәп килүче буржуаз мөнәсәбәтләрне тыюга һәм аны астыртынлыкка этәрә, җәмгыятьтә котылгысыз гаделсезлекләр арта. Ә буржуаз мөнәсәбәтләр исә, бозык хәлдә булса да, барыбер яшәүдән тукталмый.

Сорау туа: нишләтергә соң бу буржуаз сыйныф калдыгын, бу төр мөнәсәбәтләрне? Бу сорау бүген дә актуаль булырга тиеш. Аңа өч төрле җавап булырга мөмкин. Яки без аңа бөтен җәмгыять күләмендә җеназа чыгарга тиешбез, ягъни тамырын корытырга, бетерергә; яки аңа тулы яшәү хокукы бирәбез дә үзебез әсирлеккә төшәбез. Яки инде — өченче юл — җәмгыятьтә аның үз урынын билгелибез, социалистик ысулларга зыян зарәт салмаслык кысаларга куып кертәбез.

Шушы вариантларны берәмтекләп тикшереп чыгыйк әле! Беренче вариантны башкара алабызмы без? Алабыз. Армия, КГБ, МВД, коррупциягә бирешмәгән партаппарат һәм дәүләт эшлекләләре, шулай ук тәртипкә сусаган массалар ярдәмендә илдә яшәп килүче необуржуазия элементларын юк итәргә бик мөмкин булыр иде. Икътисадны берәз гына булса да җанландыру өчен предприятиеләргә, колхоз-совхозларга мөстәкыйльлек тә бирсәң, илне тотрыкландырырга да мөмкин, әмма бу барыбер шул сталинча идарә итүгә кайтып кала инде.

Икенче вариантта без необуржуазиягә тулы хокук бирә алабыз. Бүгенге хәлдә ил нәкъ шул юлга йөз тота. Моның өчен күп кенә депутатлар да, матбугат та, икътисад хезмәткәрләре дә бик тырыша. Нигездә, без социализмның моңарчы корылган бинапарын сүтәргә җыенабыз. Карап карыйк әле: бөтен власть необуржуазия кулына күчкәч, илдәге башка сыйныфлар, тәмам хәерчелеккә килеп терәлгән крестьяннар, очын-очка ялгап җан асраучы эшчеләр, соңгы елларда аеруча кыен матди хәлдә калган интеллигенция вәкилләре — барысы да дөнья буржуазиясе кулында, аның карамагында торып калачаклар.

Әле бу мәсьәлә хәл ителеп бетканче ук илдә моңарчы күрелмәгән тәртипсезлекләр башланып китте: производствоның җитештерүчәнлеге нык кимеде, илдә милләтара бәрелешләр, хәтта кан коюлар булып тора, инфляция һәм башка шуңа охшаш хәлләр тамыр җибәрә. Нәтиҗә, күренгәнчә, нәкъ беренче варианттагы кебек ук. Бу ике вариант та илне кабат сталинчыл сәясәт кармагына, яңа сугышлар куркынычына, хәтта дөнья сугышына этәрәчәк.

Инде соңгы, өченче вариантның мөмкинлекләрен күздән кичерик. Бу — белгеле күләмдә ирекле, илдәге төрле сыйныфлар һәм төрле милләтләрнең күп төрле карашын сыйдыручы вариант. Монда, иҗтимагый милекнең төрле формалары сакланган хәлдә, чикле рәвештә буржуаз милеккә дә юл куела. Аңа билгеле күләмдә ясак салына. Әлеге яшәү рәвешендә илдәге һәм икътисади, һәм сәяси, һәм иҗади мөмкинлекләр тулысынча файдаланыла ала. Астыртын эшләүче икътисад «күн яктысы»ны чыгарыла. Бу юлны, чагыштырмача, сугыштан соңгы Франциядәге яңарышлар белән тиңләштерергә ярар иде...

Шулай итеп, капитализм һәм социализм үсешендә өч баскычлы теория тәкъдим итү — безнең бүгенге фәлсәфәләребез өчен яңа нәрсә. Кызганычка каршы, социалистик үсеш юлыннан тоташ баш тартуларга корылган хәзерге бәхәсләр җирлегендә моның белән кызыксынучыны табуы кыен. Нишләмәк кирәк — чыдарга кала. Безнең тирәлектә мондый хәлләр еш булып тора лабаса. Иҗат яки акыл кешеләренә мондый битарафлыкны әрнүчә еш кичерергә туры килә.

Тирәннәнрәк уйлап карасаң, бу — кешенең коточкыч фаҗигасе. Җәмгыятенңнең упкынга тәгәрәвен ап-ачык күреп торасың, аны коткару юлларын беләсең, тик шуларны ишеттерү һәм тормышка ашыру әмәлең юк. Мин бу юлы да, моңа кадәр күп тапкырлар кабатланган кебек үк, үземне аңламаячакларын сизәм. Мине аңларга теләмәүчеләр әллә нипәр язып бетерделәр инде. Мәсәлән, «Вечерняя Казань» газетасына бераү болай язып чыкты: «Хөрмәтле язучы һәм «эшчеләрнең яклаучысы» Диас Вәлиев үзен ерөнә марксист итеп күрсәтмәкче. Ул хәтта сталинизм белән брежневизмны да аклап маташа»... (19.5. 1990).

Бу мәкаләдә адым саен — ялган. Тик минем аның һәр сүзенә «бәйләнеп» торасым килми. Шулай да бер мәсьәләне ачыклыйсым килә. Мин — марксист түгел. Күргәнбелгәннәремә һәм инануыма таянып, мин үземне универсалист дип атар идем. Марксны бик хөрмәт итсәм дә, мин аның турында шуны әйтергә тиешмен: ул универсаль-коммунистик тәгълиматның бер өлешен тәшкил итүче өйрәтмәләр генә калдыра алган. Ә менә универсаль-коммунистик тәгълимат — кешелекнең бар галәм белән элемтәгә керерлек фәлсәфәсе ул. Бу тиңдәше булмаган фәлсәфә әле туып кына килә. Универсаль-коммунистик фәлсәфә атеистларны да, дингә ышанучыларны да тиң күрә. Аның төп тезисы булып мондый аңлатма бирелә: яшәеш аң белән билгеләнгән кебек үк, аң да яшәеш белән билгеләнә. Мондый җирлектән торып фикер йөртү, күренеп тора ки, марксизмга караганда, күпкә киңрәк мөмкинлекләр ача.

Мин бу юнәлештә артык сөйләргә җыенмыйм. Шулай да әйтергә кирәк, универсалистик фикерләр һәм бу хәрәкәт бүгенге көндә тирән кризис кичерә. Әмма игътибарлы карашлар бу караңгы көннәрдә дә аның яктылыгын ш.әйләми калмас. Тагын киләчәккә ышанырга һәм аның нәтиҗә ясавын көтәргә туры килә инде. Яңа буыннар марксистларның ачышларына тиешле бәяләрне бирерләр, аның җитешсезлекләрен күрсәтерләр, әлбәттә. Һәм ул чакта без дә үз фикерләребезнең дөреслеген ачыкларбыз.

Бүген төрле диннәр яңарыш чорын, үлеп-терелү кебек, җәмгыятькә яңадан кайту процессын кичерә. Әйдә, ышанганнар ышансын! Алар башлап ышанган иманнарына тугрылыклы калырга тиеш. Әмма, борынгы дин тәгълиматларына яңадан яшәү хокукы бирген тәкъдирдә дә, без үз «инҗилләребезне» язарга, меңнәрчә елларга алга караган универсалистик глобаль доктриналар иҗат итәргә тиешбез! Бу яңа тәгълимат, элекке пошмас өйрәтмәләрдән аермалы буларак, үз көленнән үзе кабат туучан әкият кошы сыман, көрәшләрдә чарланып, киң колачлыланып, бинһая куәтләнеп барлыкка киләчәк...

Шулай да, әгәр без, әлеге мифиоз агымнар тәэсиренә бирелеп, илне социалистик үсеш юлыннан кирегә борсак, тарихның киләчәге әллә ни яхшыга үзгәрмәячәк. Бу хыянәт бары безнең ил өчен генә фаҗига булачак. Бүгенге буын тирескә әйләнәчәк, әллә инде сугышлар аны, ит тарткыч машина аша үткәргәндәй, тәмам харап итәчәк. Универсалистик идеяләр аерым шәхесләр карашы булып кына алга атлаячак. Аны яңабаштан торгызу бурычы башка буыннарга калачак.

Мин үземнең «Мәңгелеккә өч сәяхәт» («Три похода в вечность») исемле китабымда кешелектә өч төрле шәхес булуын тасвирлыйм: микрокеше, макрокеше һәм мегакеше. Тарих сәхифәсенә иң азактан үсеп килеп чыгачак әнә шул мегакеше генә — Җир гражданины — безнең планетаны төрле ыгы-зыгылы иҗтимагый гаделсезлекләрдән, атом-төш шартлауларыннан, экологик һәлакәттән коткарырга мөмкин. Кешелеккә андый шәхесләрнең килүе куңелсезлекләрдән башлана, әмма бу хәл котылгысыз — XX гасырның соңгы еллары шуны раслый. Тик дөньяда андый шәхесләр бар инде. Күрәсең, вакыты җиткән.

# РӘСМИ ӘЛӘК

*Тарих, табигый ки, төрле вакыйгаларга бай. Безнең ил тарихындагы күп кенә хәлләрнең асылына төшенү, җентекләп танышу күп еллар буе мөмкин булмады. Бигрәк тә милли-азатлык хәрәкәтенә кагылышлы документлар, мәгълүматлар җиде йозак астында тотылды, аларга сирәк кенә очракларда сирәк кенә кешеләр үтә ала иде. Илебездә үзгәртеп корулар башлангач, КПССның Татарстан өлкә комитеты архивы да бик каты сер итеп саклаңган материаллар белән танышу өчен мөмкинлекләр ачты. Шундагы бер материал белән журнал укучыларны да таныштырырга булдык. Ул — Татарстандагы һәм кайбер башка республикалардагы милли хәрәкәткә күзәтү. ТАССР ОГПУы 1926 елда аны ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты «Бик тә яшерен» дигән тамга куеп тапшырган.*

*«Бу документны төзеп, без милли хәрәкәт турында агентура характерындагы материаллар белән уртаклашуны максат иттек,— диелә анда.— Тик түбәндә китерелгән фактлар гына бөтен хәлне ачыклап бетерми... Әммә, уйлавыбызча, дошманнарыбызны анализлау өчен алар кирәкле».*

*Инде бу күзәтүнең эчтәлеге белән танышыйк.*

Альберт МӨСЛИМОВ

## Башка республикаларда милли хәрәкәт

## һәм эмигрант төркемнәренең эше

Милли хәрәкәт көрәшен дәвам итүчеләр, мәгълүм булганча, төрек-татар буржуазиясенең революциягә кадәрге эшлеклеләре; алар бу хәрәкәттә революция вакытында да, аннан соң да актив катнашкан. Аларга ияргән, яңа буржуазия тудырган зыялылар да шуларга көч өсти.

Акгвардиячеләр авантюрасын бастыру белән беррәттән бу хәрәкәтне дә бетергәч, андый элементларның бер өлеше Союзда калды, бер өлеше чит илгә китеп барды һәм эшчәнлеген дә шунда күчерде. Милли хәрәкәтнең читкә киткән житәкчеләре төрлесе төрле жирдә: Төркиядә — Константинопольдә, Анкарада; Франциядә — Парижда, Германиядә — Берлинда һәм башка дәүләтләрдә урнашты. Бу кешеләр, үзләрен халыкка милли азатлык көрәшчеләре итеп танытып, кайберәүләрдән матди ярдәм алуга ирештеләр һәм, шулай итеп, бергә оештылар. Хәзерге вакытта андый төркемнәр журналлар да чыгара. Мәсәлән, «Прометей» — Парижда Кавказ эмигрантларының, «Яңа Кавказ» муссаватчы эшлеклеләрнең басмасы булып тора. Беренче саны 1926 елның 5 июнендә генә чыккан «Яңа Төркестан»ны исә Урта Азия эмигрантлары нәшер итә.

Бу басмалар эшчәнлек ягыннан бер-беренә охшаш һәм безгә каршы коткы белән тулы. Милли сәясәтчеләр көрәшкә әзер булырга чакыралар. Көнбатыш илләрен Россия байлыклары белән кызыктыралар, уңышка ирешкәндә, ул байлыклар безгә дә, сезгә дә житәчәк, дип ым кагалар... Аларның тәкъдименчә, «Мәскәүдән мөмкин кадәр күбрәк йолкы, матди хәлеңне ныгыт, гавамны милли рухта тәрбиялә, партияне эчтән таркат, хәрби белгечләрне техникага (авиациягә) йөз тотып әзерлә, кирәк чакта боларның һәммәсен дә гамәлгә ашырырлык һәм совет хакимиятеннән яисә аның дәвамчыларыннан бәйсезлеккә ирешерлек булсын...»

«Яңа Төркестан» журналы зур сабырсызлыгы белән аерылып тора. Ул беренче санында ук Үзбәкстан, Тажикстан, Казагстан милли төркемнәре алдына Совет хакимиятен бәреп төшерү, Союздан аерылып чыгу бурычын куя. Шул журналда урнаштырылган мәкаләсендә Зәки Вәлиди алдан чамаланылган икътисади эмансипация яки режимны өлешчә үзгәрү ягында торучылардан көлә, бүгенге шартларда милләтченең мәсләге баш күтәрү, беренче нәүбәттә Көнбатышка, Англиягә юнәлеш тотып, Совет властен бәреп төшерү икәнлекне дәлилли.

З. Вәлидов: «Бөтен көчне — Урта Азиягә. Эчке районнар нинди дә булса эшлеклелеккә сәләтсез, азатлыкка көньяктан килергә кирәк»,— ди.

Муссаватчы эшлеклеләрнең «Милли Әзербайжан үзәге» дип имза куелган мөрәжәгате Совет хакимиятенең һәлакәт алдында икәнлеген әйтә, алда форсаттан оста файдалану өчен әзер булырга чакыра.

Соңгы хәлләр мондый тынгысызлыкны куәтли. Мәмәт Әмин Рәсүлзадә «Россиядәге сәяси хәл» дигән китапчыгында: «Мөселман кешесе коммунист була алмый, партиялелек битлек итеп кулланырга тиеш, аны хакимиятне төшергәннән соң салып ташларга мөмкин, ә хәзергә властьта торырга, кадрлар әзерләргә кирәк»,— дип яза.

Татарстан эмигрантлары турында берничә сүз. Г. Батталов, Г. Исхаков, Садри Максудов, Фуат Туктаров үз эшчәнлекләре белән аерылып торалар. Алар эмигрант төркемнәре белән элемтәгә кергәннәр һәм Совет властена каршы гомуми көрәштә катнашалар.

Шәрык тарафындагы милли хәрәкәткә тукталыйк. Монда иске рәвештәге пантөркистлыкның йогынтысы зәгыйфьләнгәнлекне әйтеп узарга кирәк. Аның урынына төрле юнәлештәге милләтчелек хасил булды, монысы элеккесе белән бер нәрсәдә яраша: ул — Совет властена каршы көрәш. Шулай да пантөркизм бөтенләй юк, дип әйтеп булмый. Ул Әзербайҗан, Кырым һәм Төньяк Кавказда бик көчле...

Казагстан. Монда шундый бурычлар куела: 1) кооператив аппаратын басып алу һәм буйсындыру; 2) Совет Власте үткәрә торган колонизациягә каршы көрәш; 3) халыкны русларга карата килешмәүчән мөнәсәбәттә тәрбияләү һәм буржуаз-милләтчелек үзаңын үстерү; 4) милли берләшмәләргә йогынты ясарга ирешү.

Кайчакта милләтчеләр ирешкән уңыш — партия, совет оешмаларына эшләүче шул милләт җаваплы хезмәткәрләрнең булышлыгы нәтиҗәсе дә ул.

Әзербайҗан. Муссаватчылар эшчәнлеге аерым игътибарга ия. Аларның тактикасы башка республикалардагы милли төркемнәр тактикасыннан аерылмый диярлек. Аларда шундый омтылышлар күренә: 1) совет аппаратын таркату; 2) совет мәктәпләрен таркату; 3) авылга йогынтыны үз кулларына алу ниятеннән дин әһелләре белән берләшү; 4) җай чыкканда, форсатны ычкындырмас өчен, хәрби кадрлар әзерләү.

Муссаватчыларның уңышы бар инде. Әзербайҗан Мәгариф халык комиссариатын тикшерү йомгакларыннан күренгәнчә, анда совет мәктәбе юк. «Яңа Әзербайҗан комитеты» бар. Ул балаларга, яшьләргә бәйсезлек һәм төрекләрнең берләшүе идеясен ныгыту рухында тәрбия бирү, русларның басып алуына нәфрәт тәрбияләү максатын куя. Әзербайҗан демократларының «Иттихадчылар» партиясе эшчәнлеге дә дикъкатьне тарта. Бу партия Совет властена каршы көрәш юнәлешендә көчле әзерлек эше алып бара.

Башкортстанда элеккеге милли хәрәкәтнең партиясез өлеше Вәлидовны Башкортстанга кайтару мәсьәләсе тирәсендә җәмәгатьчелек фикере тудыра. Вәлидовның элеккеге көрәштәше, хәзерге коммунист Иделхуҗинның «Башкорт хәрәкәте. 1917—1920 еллар» дигән китабы чыкты, анда Вәлидовның эшчәнлеге аклана...

Кырымдагы милли төркемнәр һәм Солтангалиев турында да фикер өстибез. Кырымда «Милли фирка» төркеме яши. Соңгы вакытларда ул Совет власте алып бара торган чараларга бигрәк тә, яһүдләргә каршы актив чыгыш ясады. Бу җәһәттән әлеге төркем Солтангалиев һәм аның тирәсенә тупланучы Мәскәүдәге милләтчеләр белән элемтә урнаштырган. Алар, берничә киңәшмә үткәреп, Солтангалиевнең шундыйрак тәкъдимнәрен кабул иткәннәр: 1) Кырымдагы яһүдләргә каршы җәмәгатьчелек фикерен туплау; 2) Шул мәсьәлә уңаеннан милләтне берләштерү; 3) бердәм мөселман партиясен оештыру. Алга куелган мәсьәләләрне тормышка ашыру өчен, алар быелгы курорт сезонында Кырымда киңәшмә җыймакчы булалар.

Милли элементларның киң җәелгән гамәлләре халыкара һәм эчке хәлләр белән тыгыз бәйләнештә тора (Англия-Совет дәгъвасы, шуңа өстәп ВКП(б) позициясе). Гомумән, милләтчеләр көчле әзерлек алып бара, аларга карата житди игътибар бирү сорала.

Аннары, Татарстандагы милли элементлар эшчәнлеген бәян итүгә күчкәнче, без башка милли республикаларда милләтчеләрнең төрки-татар әлифбасы тирәсендә барган көрәшенә тукталыйк.

Әзербайҗан. Анда яңалиф (латинчалык) хәрәкәте партия һәм хөкүмәт органнары тарафыннан тулысынча хуплана, ә бердәм төрки әдәбият һәм тел хасил итү хакына латинлашуны мәгъкул күргән муссаватчылар һәм башка төркемнәрнең бер өлеше... икеләнеп калды һәм яңалифтән читләшә бара.

Хәзерге вакытта, пантөркистләр һәм муссаватчыларның бер өлеше гарәп хәрефләрен яклаучылар ягына күчкәнлектән, яңалифне кире кагу хәрәкәте көчәйде. Советка каршы яшерен «Яңа Әзербайҗан комитеты» инструкциясендә: яңалиф нигезендә Әзербайҗан әдәбиятының бердәм яшәү зарурлыгын дәлилләү — наданлык ул. Яңалифкә каршы көрәш алып барырга кирәк, чөнки ул безне төрки дөньядан аеру өчен урыс басып алучылары тарафыннан кабул ителгән юнәлеш булып тора».

Үзбәкстан. Анда яңалиф хәрәкәте консерватив зыялылар ягыннан тиз арада каршылыкка очрады. Шәһәр мөгаллимнәре башта яңалиф ягында иде, махсус түгәрәкләр оештырылды, кайбер районнарда яңалифне хәтта мәҗбүри керттеләр. Кукан халык мәгарифе бүлеге үзәктән күрсәтмә бирелгәнче үк мәктәпләрдә яңалиф укыту өчен махсус инструкторлар билгеләде. Гарәп хәрефен яклаучылар моңа каршы чыга. Яңалиф мәсьәләсе уңаеннан җыйналган край киңәшмәсендә кайбер латинчыларның сүрелеп калуы сизелде... Танылган яңалифчеләрнең кайберсе Фитрат ягына басты, ягъни әлифба проблемасын ерак киләчәктә бик камил рәвештә хәл итү фикерендә. Киңәшмә яңалифне өйрәнү буенча Үзәк башкарма комитет, шәһәр һәм өлкә комитетлары, түгәрәкләр турында төшенчә кабул итү белән чикләнде. Үзбәкчәгә ярашлы яңалифне эшләү Үзәк Комитетка йөкләнде. Үзәк Башкарма Комитетта яңалифнең ныклы тарафдарлары булмаганлыктан, латин хәрефе кертүгә каршы кешене сәркатип итеп билгеләделәр. Ул: гарәп әлифбасын камилләштерүдә теләбрәк эшләр идем, дип шаккатырды...

Кырым. Монда әлифба турындагы мәсьәлә беренче мәртәбә 15 ноябрьдә, гарәп хәрефен яклаучылар тәкъдиме белән, мөгаллимнәр корылтаенда куелды. Биредә яңалифкә каршы карар күпчелек тарафыннан кабул ителде. Укытучыларның бер өлеше латинлашуга шулай да уңай карашта иде. Профессор Бәкер Чобанзадәнең яңалифне яклап дәртле чыгыш ясавы сәбәпле, Кырым Мәгариф халык комиссариаты латинлаштыруны үткәрүгә булышу комиссиясен оештырырга мәҗбүр булды...

Казагстан. Монда яңалифчеләр аз санлы һәм пассив. Латинлашу ягында торучы һәм зур йогынтылы казакълар Мәскәүдә бар. Әмма аларның эшчәнлеге очраклы әңгәмәләрдән генә гыйбарәт. Яңалифкә каршы хәрәкәтнең активлыгы мәдәни-агарту органнары эшендә, бигрәк тә Академик үзәк эшендә күренә. Гарәп хәрефен яклаучыларга милли мәдәният көрәшендә зур тәҗрибә туплаган алаш-урдачы Байторсынов житәкчелек итә. Ул әлеге юнәлештә 1926 елның көзендә безнең Казанда да гарәп хәрефе яклы кешеләр киңәшмәсендә чакта күп эшләде.

Төркмәнстан. Мондагы зыялыларның, бигрәк тә башлангыч сыйныф укытучыларының бер өлеше яңалиф ягында. Аларча, латин алфавиты кабул итеп, телнең мөстәкыйльлеген саклап була. Гарәп хәрефен яклаучылар ягында читтән килгән мәдәният эшлеклеләре — әзербайҗаннар, татарлар тора. Хәзерге вакытта алар чагыштырмача көчлерәк.

Төркиядә төрки-татар әлифбасы мәсьәләсенә караш. Ул дәүләт күләмендә хәл ителмәгән әле. Без төрек җәмәгатьчелегенең һәм эмигрантларының консерватив өлешенә тукталабыз. Бу элементлар бәхәс вакытында менә шундый нигезләрдән чыгып эш иттеләр: 1) бу мәсьәлә Төркия өчен дәүләти-сәяси мәсьәлә булып тора (мәгариф комиссары белдерүе); 2) төрки мәдәниятләрне берләштерү һәм бердәм төрки тел булдыру, ягъни, бөтен дөньядагы төркиләрнең мәдәни бердәмлегенә ирешүдә дөнья проблемасының бер өлеше булып торырлык мәсьәлә бу.

Эмигрантлар «Төрек йорты» журналы аша безнең төрки республикаларда гарәп хәрефләрен яклаучыларга куәтле теләктәшлек хәрәкәте үткәрделәр. Алар Баку корылтаендагы төп материалларны, гарәп хәрефләрен яклаучыларның докладларын һәм съездан соң иске әлифбаны яклап кабул ителгән хезмәтләрне кабаттан бастырып чыгардылар. Яңалифкә каршы хәрәкәтнең көчәюе бездә төрек әлифбасын Европа әлифбасына хөкүмәт күрсәтмәләре нигезендә күчерергә теләүчеләрнең эшчәнлеген какшатты, Мәгариф комиссариаты төзегән комиссия исә эшчәнлеген туктатты диярлек...

Бездәге кебек үк, Төркия гарәпчеләре арасында да килешмәүчәнлек килеп чыкты. Аларның бездәге чыгышлары Төркиядә төрки-татар мәдәниятенә таба кайтаваз шикелле яңгырады. Г. Ибраһимовның «Пролетариат революциясе һәм социалистик төзелеш шартларында татар мәдәниятенең язмышы турында» чыгышы, ә Төркиядә З. Вәлидовның «Төрек идеологиясенең кризисы» дигән чыгышы пәйда булды. Ике мәкаләдә дә милли төрки мәдәниятне, тел һәм әдәбиятны мөстәкыйль саклауның зарурлыгы яклана, яңалифләшү Көнбатышка авышу дип бәяләнә һәм аның татар мәдәниятен рус мәдәнияте белән кушылуга китерәчәге әйтелә. Г. Ибраһимовның мәкаләсенә җентекләп анализ ясамыйбыз, З. Вәлидов чыгышына гына тукталабыз. Аның язуынча, төрки-татар мәдәниятчелеге хәзерге вакытта, совет чынбарлыгы шартларында, аерым төрки милләтләрне таркатуга юнәлдерелгән һәм кризис кичерә. Шуның ачык билгеләре: 1) Яңалифчелек хәрәкәтен ясалма рәвештә хасил итү; 2) бер яктан рус пролетариат мәдәниятенә мәҗбүри рәвештә юнәлеш тоту һәм латинлашуга каршы үзеннән-үзе барлыкка килгән саклану хәрәкәте — төрек мәдәниятенең мөстәкыйль яңаруы өчен Көнбатышка авышудан саклану.

Шулай итеп, безнең милләтчеләребез төрек милләтчеләреннән һич кенә дә калышмый. Алар бары тик анда калкытып чыгарылган мәсьәләләрне эләктереп алуда гына сонаралар.

## Татарстан Республикасының милли интеллигенциясе

Мәгълүм ки, Казан революциягә кадәр үк милли эшлеклеләргә бай иде. Октябрь җиңгәннән соң аларның бер өлеше чит илләргә чыгып китте, бер өлеше үзебезнең илгә таралды, бер өлеше Казанда калды һәм, коммунистлар битлеге киеп, үз эшләрен дәвам итте. Баштагы вакытта партиясезләр Мансуров һәм башкаларның төркемнәре белән кушылды... Татарстан Республикасында милли зыялылар туплана башлады, бу бигрәк тә 1926 елда сизелде. Г. Ибраһимов, Н. Надеев аеруча активлык күрсәттеләр. Алар «милли азатлык хәрәкәтенә» дә зур стажлы кешеләрнең зур төркемен Мәгариф халык комиссариаты һәм нәшрият органнарына эшкә урнаштырдылар.

Шуннан соң алар үзара берләшә, оеша башладылар. Г. Шәрәф, И. Биккулов, Садри Вәлидов, И. Әхмәтов һәм башка милләтчеләрнең инициативасы белән «Яңа китап» дигән нәшрият ширкәте кордылар. Беренче очракта бу ширкәткә коммунистларны кертү мөмкинлеге

турындагы мәсьәлә куелды. Безнең ачыклавыбызча, әлеге ширкәт пролетариат идеологиясенә каршы көрәшүне максат итә. Г. Биккулов һәм башкалар Ф. Әмирхан исемендәге әдәби җәмгыять төзүне, аның һәм шундый бүтән язучыларның әсәрләрен пропагандалауны, җөмләдән, Әмирхановның партиягә Ленин чакыруы буенча алуны һәм социалистик төзелешне мыскыл иткән әсәрләрен халыкка таратуны ниятли. (Бу хикәя Мәскәүдәге бер шәхси нәшриятка басарга бирелгән, дигән хәбәрләр бар.) Шәрәф оештырган бу комиссиянең эше әлегә милли элементларга һәм муллаларга Әмирханов турындагы хатирәләрен җибәрүне сорап мөрәҗәгать тарату белән чикләнгән. Әлеге эшлекләләр санаулы кешеләр белән кечкә мәҗлесләр үткәрә, анда үткен мәсьәләләр тикшерелә. (Мәсәлән, Мөхәммәдьяровны Сәламәтлек саклау халык комиссары вазифасыннан азат итү сәбәпле, аңа багышлап оештырылган кичә, медицина уку йортында укучы татар студентлары кичәсе һ. б.)

Дөрес, хәзерге вакытта без андый төркемнең катгый рәвештә тупланганлыгы турында мәгълүматка ия түгелбез. Әмма бу һич кенә дә төркем әгъзаларының безнең белән көрәш алып бару мөмкинлегенә комачаулык итми. Аларның кайбер уңышлары да бар инде. Академик үзәктә хакимлек итәләр, анда Г. Ибраһимовның актив булышлыгы белән гарәп әлифбасын ныклап урнаштыруга ирештеләр, матбугатта зур урын билиләр. Мәсәлән, Академик үзәкнең 1926 елгы эш планыннан һәм Татарстан дәүләт нәшриятының 5 санлы каталогыннан күренгәнчә, чеп-чи милләтче Шонаси 85 басма табакка ия, шул ук вакытта совет язучыларына басма-битләр бик чикләнгән. Нигъмәт Хәкимнең «Ислам тарихы» дигән китабы бастырып чыгарылган, анда мөселманнарның күпчелеге һәм исламның киңәя баруы исбатлана. Элекке эсер Исмәгыйль Рәми тарафыннан татар вакытлы матбугатының 20 еллыгына багышлап альбом-җыентык төзелгән, анда эсер газеталары «Ирек», «Аваз» һәм «Безнең юл» мактала. Мәгълүм милләтче Гали Рәхимнең «Татар әдәбияты тарихы» дигән китабы революциягә кадәрге язучыларны бик тырышып таныта, ә революцион яшь авторлар турында ләм-мим. Г. Ибраһимовның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китабының эчтәлеге сезгә мәгълүм инде.

Кызылармиячеләр өчен хрестоматия русчадан тәрҗемә ителгән. Анда татарлар арасында Октябрь революциясе вакыйгаларына карата 60 бит өстәлгән, бу өлештә эсерларның роленә нык игътибар бирелә. Ф. Бурнашның «Иске җырлар» дигән китабы тормышка пессимистик карашны үстерә. Совет власте дошманнарының «уңышларыннан беркадәресе» менә шулар.

Зарарлы идеологияне тормышка ашыруда Татар дәүләт театрыннан да файдаландылар. Үткән кышкы сезонда Әхмәт Тажетдин-Рахманкуловның өч сериядән торган «Упкын», «Боз астында дулкын», «Үлмәс ханым» пьесалары куелды. Аларда 1905 елгы революция турында дөрес булмаган аңлатма бирелә. Революция житәкчеләре җинаятьче элементлар белән элемтәдә тордылар һәм аларны үзләренә ярдәмгә чакырдылар, дип әйтелә. Үткән сезонда репертуарга милләтче Кәрим Тинчуринның «Нәни абый» дигән пьесасы да кертелгән иде. Аның эчтәлегендә милләтчелек калкып чыккан...

Пролетариат идеологиясенә каршы көрәштә Главлит та файдаланыла. Театрдагы соңгы хезмәтләрне карауны Тинчуринга, табигать белеме хезмәтләрен карауны Шонасига, дингә каршы пропаганданы Рәхмәтуллинга тапшырганнар. Главлит житәкчесе Кәримов күзәтчелек итү мәсьәләләренә салкын карый. Гомумән, милләтчеләр алдагы эшчәнлекләрен җәелдерү өчен уңай перспективага ия.

Сүз уңаеннан Г. Мансуровның Мәскәүдә чыгарган «Татар провокаторлары» дигән китапчыгын да искә алыйк. Анда пантөркизм аклана. Бу брошюраны сугышчан рәвештә туздырырга кирәк.

Инде милли элементларның совет аппаратына йогынтысы турында. Алар тарафыннан милләтчеләрнең юбилейлары зурлап оештырыла, аларга гомерлек пенсияләр вәгъдә ителә. Мәсәлән, Х. Мөхәммәтовка, буржуаз газетаның элеккеге мөхәррире Һади Максудовка, Казан мулласы Мостафа Әхмәтҗановка андый пенсия билгеләнгән инде. Казанда мәдрәсә ачу өчен, безнең таләпләрне инкарь итеп, белешмәләр бирелгән... Хәзерге вакытта танылган илле милләтче совет аппаратында зур урыннар били. Аларның кайберләре милли эшләрдә шактый тәҗрибәле.

Зыялыларның дин әһелләре, буржуазия белән элемтәсе. Анысы бертуган Шәрәфләр аша тормышка ашырыла. Алар исә буржуазия белән, Үзәк диния нәзарәте мөфтие Фәхретдинов белән кардәшлек җепләрендә тоташкан. Мәгълүм ки, Борһан Шәрәф мөселманнарның Бөтендөнья мөселман конгрессына мөрәҗәгатенең мөхәррире иде. Ул Үзәк диния нәзарәте өчен типография оештырырга да маташты. Шәрәфләр идарә итә торган «Урман» сәүдә-промышленность ширкәте мәчетләргә утынны әҗәткә җибәрә...

Зыялыларның һәм уң канаттагы партиялеләрнең бер өлеше Татар-Башкорт республикасы оештыру мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Бу мәсьәлә беренче мәртәбә Зәки Вәлидов тарафыннан куелган иде. Ул, Татарстанны Башкортстанга кушып, әлеге ниятkә ирешү турында фикер йөртте. Аннары шушы ук мәсьәлә Максудов төркеме проектына килеп керде. Әмма башкача итеп, төгәлрәк әйткәндә, Башкортстанны Татарстанга кушу юлы белән. Шунысы да билгеле, әлеге мәсьәлә уң канаттагыларның быел 14 апрельдә Советлар Йорты бинасында үткәрелгән бер киңәшмәдә дә тикшерелгән, анда Казанга кайткан Г. Мансуров та катнашкан. Уң тарафтагыларга Г. Ибраһимов та тартыла, ул башкорт милләтчесе Даут Юлтый белән көрешкән. З. Вәлидов һәм Ибраһимов арасында Бөтендөнья мөселманнар конгрессы вакытында ук анда бар-

ган делегация аша элемтә урнаштырылган, дип уйларга була. Бу З. Вәлидовның «Төрек йорты» журналының дүртенче санында урнаштырылган мәкаләсендә дә чипләтеп сиздерелә. Мәкалә авторы анда үлеп баручы пантөркизмны сакларга чакыра, коммунистларны татарга каршы сәясәт кертүдә гаепли. Болардан күренгәнчә, Г. Ибраһимов аның бер таянычы булып тора. Дөрес, Ибраһимов панбашкиризм идеясенә капма-каршы рәвештә, пантөркизмга күбрәк омтыла.

Милләтчеләр партия һәм хөкүмәтнең интернациональ сәясәтенә, бигрәк тә Хатаевичка каршы кампаниягә зур әһәмият бирә. Алар тарафыннан шундый гаепләүләр күрсәтелә: 1) Татарстан хөкүмәте гамәлләрендә мөстәкыйльлек юк, ягъни, бөтенесе Мәскәү күрсәтмәсе буенча эшләнә; 2) татар эшлекләре һәм, гомумән, зыялылары кысыла; 3) татар эшлекләре төп башына утыртылыр өчен, юри үзләре белмәгән эшкә билгеләнә; 4) кайбер мәсьәләләр төп милләткә зыян китереп хәл ителә; 5) бәяләрне төшерү өлкәсендә эшлексезлек — эш аз, сүз күп; 6) Татарстан буенча бөтен Союз халык саны алуның соңгысында татарларның саны ясалма рәвештә киметеп күрсәтелә; 7) татар хатын-кызларын хезмәткә җәлеп итү әләме астында Советларда татарларның санын киметелә; 8) Татарстан республикасын бетерүгә әзерләнелә, ягъни, районнарга бүлгәләнә һәм житәкчелек гадиләштерелә; 9) халыкның ихтыярын исәпкә алмыйча, яңалиф тагу һәм татар мәдәнияте үсешен, гомумән, тоткарлау.

Эш шуңа барып житте ки, Шәрәф белән Бикбулатов Үзәк башкарма комитет, Совнарком һәм Госплан аппаратларында Татарстан Республикасын районнарга бүлү планын мәсхәрәлиләр, белгечләрне куркытуга кадәр барып житәләр... Милләтчеләр Әхмәтов, Биккулов һәм Бикбулатов Татарстан Республикасыннан демонстратив рәвештә чыгу планын төзегәннәр. Бу программаны ашыруда өлкә комитеты сәясәтеннән канәгать булмаган кайбер партиялеләр, танылган уң тараф кешеләре хезмәт күрсәтә. Моны күзаллау өчен ВКП(б) өлкә комитетының матбугат бүлеге мөдире иптәш Насыйровның белдерүен китерәбез. 1 Май көнне партиясез интеллигент барында ул: «Мин ни өчен өлкә комитеты әгъзасы буларак актив түгел?» — ди. Шунда ук җавап та бирә: «Бу шуның белән аңлатыла, чөнки монда Татарстан республикасы түгел, ә Казан республикасы — биредә татарлар хәлиткеч роль уйнамый, ә казанлылар...» Аннары ул болай дәвам итә: «Без эштә зыялылар ихлас катнашырлык дәрәҗәгә житмәдек әле, алар чын уйларын яшереп, советка тыштан гына яраклашып хезмәт итә». Һәм аннары: «Әлегәчә булган ТССРны, ягъни Казан республикасын йә бетерергә, йә аңа үзенең төзелү максатын акларлык шартлар тудырырга кирәк»,— ди.

Танылган милләтче Әхтәмов 28 июнь көнне үз кешеләренә Хатаевич, Габидуллин һәм Шәймәрдәновнең Сталин тарафыннан кабул ителүе турында хәбәр бирә. Сталин интеллигенциягә карата дөрес сәясәт уздырылмавын таныган, бу сәясәтнең милли даирәләр белән лояль зыялылар берләшүенә булышмаячагын белдергән...

Халыкара һәм эчке хәлләр белән бәйле рәвештә, соңгы вакыттагы күпләп кулга алуларга мөнәсәбәт турында берничә сүз... Күпләр аның «82» протестына кул куюга мөнәсәбәтле икәнлеген әйтәләр. Кайберәүләр исә Ленинградтагы шартлауның нәтиҗәләре дип саный. Өстәвенә шунысы кызыклы, әлеге шартлауны: «Үзләре сугышалар, ә безне утырталар»,— дип, оппозициягә сылыйлар.

## Укытучылык һәм укучыларны тәрбияләү

Авылдагы татар укучыларын тәрбияләү турындагы мәсьәлә зур каршылыкка очрый... Кайбер кантоннарда укытучыларның илле процентка кадәресе дин әһелләре нәселеннән, алар чын тәрбия урынына мөселманлыкны тараталар. Минзәләдән шундый мәгълүматлар килде: Сасыборын, Колын авылларындагы укытучылар ураза тоткан, кичләрен муллалар белән бергәләп, авыз ачырга йөргәннәр һәм Коръән укыганнар. Укучылар, укытучылардан үрнәк алып, шулай ук ураза тоткан. Арча районыннан бер хәбәр: ураза вакытында балалар мәктәпкә йөрмәгән.

## Татар мәдәнияте мәсьәләсе

...Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту алымнары мәсьәләсе буенча конференция булды, ул Татар педагогия җәмгыяте тарафыннан оештырылды. Әзербайҗан, Кырым, Башкортстан, Казагстаннан вәкилләр катнашты. Сәламәт рухлы докладлар белән беррәттән, «ачулы»лары да булды. Аларда Төркия мәдәниятенә юнәлеш тотуның зарурлыгына игътибар ителде, төрки-татар мәдәниятен мөстәкыйль үстерүгә, татар телен чит сүзләрдән арындыруга, бөтен төрки халыклар өчен бердәм хәрби атамалар булдыруга басым ясалды. Тулаем алганда, докладлар милли әлифбаны, телне, әдәбиятны саклау өчен көрәш рухында әзерләнгән иде. Конференциядә яңалифчеләр кысрыкланды. Аларга хәтта үз фикерен әйтергә дә ирек булма-

ды. Конференция тәгалләнгәннән соң иң яхшы гарәп шрифтына конкурс үткәрелде, аннары Татарстан дәүләт нәшрияты мөдире Самат Шәрәфетдинов квартирасында банкет уздырылды, анда Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Измайлов, Бакый Урманчыев, Ибраһим Кулиев, чып-чын милләтче, Татарстан китап нәшрияты хезмәткәре Гаяз Максудов, Академик үзәк хезмәткәре, элеккеге буржуаз эшлекле Удобаш, чып-чын милләтче, Кырым вәкиле Галимҗан Шәрәф, Мөхәммәт Идрисов, гарәп шрифтын яклаучы, Мәскәүдән килгән Котдус Фәхретдинов, Казаннан гарәпче Шаһзадә Тукаев, Уфадан гарәпче Хабибрахман Зәбири, «Шәрык» типографиясенең элеккеге хезмәткәре һәм Шәрәфетдинов үзе бар иде. Бирелә Удобаш Татарстанның Төркия мәдәнияте белән якынаюына һ. б. чакырды. Иң яхшы шрифт өчен премияне кемгә тапшыру турындагы мәсьәлә дә тикшерелде...

## Конкрет тәкъдимнәребез

1. Идеология фронтындагы көрәшне туктату юнәлешендә:

а) Академик үзәктә Г. Ибраһимовның янәдән эшләвенә юл куймаска. Академик үзәктәге вазифаларыннан М. Корбангалиевне азат итәргә, З. Наркинны, Ибраһим Күлиевне (нәшрият һәм матбугат комбинаты), Садри Вәлидовны («Безнең юл» журналы редакциясе), Исмәгыйль Рәмиевне («Гажур»), Гали Рәхимне («Мәгариф» журналы редакциясе), Кәрим Тинчуринны (Татар дәүләт театры) вазифаларыннан азат итәргә. И. Биккулов һәм Г. Шәрәфне уку йортларында дәрес бирүгә мөмкин кадәр кертмәскә. Актив милләтчеләр буларак, аларны эштән бушатырга.

б) Академик үзәкнең эш планын матбугаттан милли караштагы элементларны кысып чыгару максатында яңадан карарга, аларга үзләренең тар белгечлекләре буенча гына эшләү мөмкинлеге бирергә, урыннарына марксистик яктан тотрыклы иптәшләрне җәлеп итәргә. Мондый мәсьәләне 1927 елда куярга мөмкин.

в) Милли элементларны Главлит эшчәнлегенә тартуга юл куймаска һәм әдәбият күзәтүгә игътибарсызлыкны бетерү мәсьәләсенә дикъкать итәргә.

г) Мәдәни оешмаларга — Татар педагогия җәмгыяте, Татар мәдәнияте йорты, «Яңа китап» нәшрияты һәм, гомумән, нәшрият органнарына партия житәкчелеген савыктыру көчәергә тиеш.

д) Ф. Әмирхан исемендәге аерым әдәби җәмгыять оешуга юл куймаска.

2. Совет аппаратын савыктыру өлкәсендә: Фәҗал Терегуловны (Тат. НКВД), М. Таһировны (Академик үзәк), Хәсән Исхаковны (Тат. Совнарком), Мостафа Төмәновны (Татбанк), Вәлитхан Таначевны (Промбанк) эштән азат итәргә. Фәйзелгали Килмәтовне («Игенче» авыл хуҗалыгы склады идарәсе әгъзасы), эштән азат итәргә. Галимҗан Шәрәфне совет аппаратына хезмәткә алмаска. Беренчесен — советка каршы элемент (материал өлкә комитетына җибәрелде), икенчесен — буржуаз эшлекле (өлкә комитетында материал шулай ук бар), калганнарын чеп-чи милләтчеләр һәм буржуаз-милләтче эшлекләләр булганнары өчен.

Болардан тыш, милли сәясәтне гамәлдә үткәрү белән якыннан бәйле органнарда сәяси яктан тотрыклы хезмәткәрләрне эшләтергә (НКЗ, РТЯ һ. б.), чөнки бу — төрле бөгешерүләргә юл куймау шарты.

3. Интернациональ сәясәткә каршы кампанияне булдырмауга административ-суд тәртибендәге чаралар белән ирешергә мөмкин, дип саныйбыз.

4. Татар буржуазиясенә налог басымын көчәйтергә. Шулай итеп, Шәрәфләр житәкчелегендәге «Урман» сәүдә-промышленность ширкәтен бетерүгә ирешергә.

Авыл укучыларын дөрес тәрбияләү, балаларны дини мәктәпләргә тартуга каршы көрәш, авылда ижтимагый-сәяси эшне җәелдерү максатларыннан татар укытучыларының сыйфатын яхшыртырга һәм татар авылларында мәктәпләр санын арттырырга.

Шушы тәкъдимнәрне тормышка ашыра барып, без үзебезнең дошманнарыбыз белән көрәш өлкәсендә куелган максатларга ирешербез, дип уйлыйбыз.

*Мөшәррәф ГАЛИЕВ тәрҗемәсе.*

# Мансур Вәлиев

## «Идел» өчен көрәш

### Сүз башы

Яшьләрнең «Идел» журналын чыгару өчен озак еллар дәвамында барган көрәш татар халкының милли азатлык хәрәкәте тарихына җитди бер сәхифә булып язылыр дип ышанам. Шуңа күрә бу хәрәкәтнең үземә мәгълүм кайбер күренеш-вакыйгаларын тарих өчен теркәп калдырырга булдым.

Әйтеп үтелгәнчә, «Идел» журналын чыгару өчен барган хәрәкәт сугыштан соңгы бөтен чорны эченә ала. Һәм ул көрәш безнең җәмгыятьнең байтак катламнарын иңли. Алда күрербез: әлеге вакыйгалар үзебезнең язучыларыбыздан һәм иҗади берлегебез аппаратыннан алып, СССРның иң югары оешмаларына кадәр, КПСС Үзәк Комитетының Политбюросына кадәр сузыла. Ул чактагы зур-зур политик эшлеклеләрне, ил һәм республика җитәкчеләрен колачлый... Әлеге көрәшкә тагын бер яктан күз салсак: анда безнең бик күп яхшы һәм яман сыйфатларыбыз чагылыш таба, төрле төркемнәрнең һәм шәхесләрнең нинди шартларда ничек хәрәкәт итүе, нинди адымнар ясавы шактый ачык күренә...

Менә шуларның һәммәсен дә искә алганда, әлеге тарих мөһим булып тоела. «Идел» журналын торгызу хәрәкәтенең ни рәвешле баруын белергә генә түгел, ә кемнәрнең кем икәнен чамаларга да мөмкинлек бирә. Шулай ук, анда әле тагын да зуррак көрәшләр торган хәзерге вакытта, үткәннең кайбер тәҗрибәләре, нәтиҗәләре белән уртаклашу да кирәк тесле. Милли көрәш мәйданына килүче яшьрәк буыннар өчен байтак яктан гыйбрәт һәм сабак булып та күренә үткәннең ул эпизодлары.

### «Идел»дә эшли башлау

Ерак Көнчыгышта ике ел офицер булып хезмәт итеп кайтканнан соң мин ярты ел чамасы Язучылар берлегенең әдәби консультанты урынында эшләп тордым. Ә инде 1975 елның ахырында, альманах редакторы булып эшләгән Фаил Шәфигуллин үзенең җан дусты Зөлфәт артыннан «Чаян» редакциясенә күчкәч, мине «Идел»нең редакторы итеп билгеләделәр.

Шунысын да әйтеп китим: мин әле ул вакытта СССР Язучылар берлегендә әгъза булып тормыйм, басылып чыккан китапларым да юк. Язучылар мине бары тик «Социалистик Татарстан»да басылган Фатих Хөснигә «Ачык хат» белән «Казан утлары»нда дөнья күргән берничә рецензия һәм Ерак Көнчыгыштан Равил Фәйзуллин иҗаты турында язылган җыллы гына мәкалә буенча беләләр. Сүз уңаеннан тагын бер кызык момент искә төшә: Ф. Хөснигә әлеге ачык хат басылгач, бик күпләр Мансур Вәлиев дигән яңа исемгә ышанмыйча, аны кемнеңдер псевдонимы дип уйлаганнар икән. Бу исемгә кемнең яшеренүе мөмкинлеген дә тикшерүчеләр булган хәтта. Соңыннан ул хакта үземә кызык итеп сөйләүчеләр очрады. Алар, минем исем-фамилияне иҗекләргә бүлә-бүлә, «чын» авторны эзләп мәш килгәннәр!

Яшьрәк буын укучылар өчен бу альманах турында кыскача гына мәгълүмат та бирел китик. «Идел» альманахы илленче елларның уртасында яшьләрнең күмәк җыентыгы рәвешендә чыга башлый. Аның беренче редакторы күренекле шагыйрь Гали Хуҗи (1912—1966) була. Шуннан соң альманахны төрле елларда Хәсән Сарьян, Марс Шабаев, Фаил Шәфигуллин редакцияли.

Әйтеп үтелгәнчә, ул башта күмәк җыентык төсендә чыга. Ләкин, шуңа карамастан, аның беренче саннары чын журналны хәтерләтә. Бигрәк тә Гали Хуҗи имзасы куелган саннарга карасаң — матур итеп бизәлгән тышлыгы буенча да, бай һәм кызыклы эчтәлеге ягыннан да, авторларның күп һәм төрле булуыннан чыгып та укучыда журнал белән очрашу тойгысы кала. Һәм бүредә, менә шушы хәлне әйтеп киткәннән соң, аз гына чигенеш тә ясыйсы килеп китә.

Күрәсең, әнә шул вакытта ук әдәби җәмәгатьчелектә яшьләргә журнал булдыру фикере шактый сизелерлек булган. Альманахның беренче саннан ук коры һәм рәсми кыяфәт алмавы, ә бәлки хәзерге «Идел» сыман җанлы, кызыклы булырга тырышуы — әнә шул киләчәккә ышаныч, аны өмет билгеседер ул! Илленче елгы беренче «Идел»ләр хәтта үзләренең форматы ягыннан да бүген безгә билгеле «Идел» шикелле!

Бу еллар хакында сүз алып барганда шунысын да искәртеп үтәргә кирәк. Язучыларыбызның илленче еллар ахырында һәм аннан соң булган һәр съездында яшьләр журналын яңадан торгызу мәсьәләсе күтәрелә, яхшы итеп дәлилләнә. Шулай ук бу еллардан башлап уздырылган РСФСР Язучылар союзы съездларында да безнең иҗат оешмабыз башлыклары «Идел» хакында гел сүз кузгаталар. Ләкин... нәтиҗәсе генә булмый ул үтенечләрнең, ул мөрәҗәгатьләрнең!

«Идел» өчен көрәш тарихында аерым урын билэп торган бер зур вакыйга да бар.

Татарстан язучыларының 1968 елда булган съездында залга листовкалар ташлана! Яшьләр журналы сорап! Ул вакыттагы тәртип һәм торгынлык чоры кануннарыннан карaганда моның нәрсә икәнлеген ничек итеп, ни рәвешто аңлатырга икән? Шома гына барган съезд вакытында, югарыдан делегатлар өстенә татарча язылган һәм журнал таләп иткән чып-чын листовкалар ява башласын әле! Бу хәл бит «илдә социализм төзелеп бетеп» килгәндә!

Ул листовкаларның берсе Татарстан Язучыларының VII съезды материаллары белән бергә документлаштырылып, папкага тегеп куелган. Тарих өчен бу эшне башкаручы кешегә дә рәхмәт!

Ә бу листовка турында Казанда никадәр сүз, күпме шау-шу чыкканын белсәгез икән! Минем бит әле яңа гына студент булган чак. Дөресрәге, әлеге вакыйга яз көне булган, ә мин шул елның — ягъни 1968 нең көзендә Казанга килеп, университетка укырга кердем. Ләкин әле листовка дулкыны без килгәч тә тынмаган иде. Университет тулай торагында, егетләр авызында гел шул сүз генә иде диярге дә була. Ләкин артык шаулап түгел, ә качыбрак, бик нык җөелеп үк китмичә генә сөйләшенә иде бу хакта...

Алар сөйләвенә караганда, листовкалар өстән, балконнан ташланган. Хәлне төшенү белән, КГБ кешеләре шундук театрдан ныгу юлын япканнар. Аннары съездга килгән шикле шәхесләрне барлый башлаганнар. Ләкин ул чакны әллә ни ачыклый алмаганнар — бу эшне эшләгән егетләр, листовкалар ташлау белән, тиз генә чыгып ычкынганнар! Тикшерү соңыннан, университет тулай торакларында һәм деканат бүлмәләрендә, КГБ кабинетларында дәвам иткән.

Ул чакта листовкаларның кем эше икәнлекне берәү дә сизгән, белгән төсле түгел иде. Әмма соңга таба моны үз өстенә алырга теләүчеләр күренгәли башлады. Әкренәкрен бу тема мактану өчен бер әйбәт җай да булды шикелле.

Тик мин, әле хәзергә кадәр, листовкаларның кемнәр тарафыннан ташлануын белмим. Шул елларда укыган университет студентлары икәнлеге — монысы төп-төгәл факт инде. Аныcына шик юк төсле.

Ләкин, кем генә башкарса да, бу эш «Идел» өчен көрәш тарихында иң якты вакыйгаларның берсе. Шуңа күрә аңа, еллар аша булса да, тиешле бәяне биреп китәргә кирәк.

Иң беренчедән, бу вакыйга безнең татар студентларында да җан бар икәнлеген бик яхшы күрсәтте. Димәк, тып-тыныч капчаклар дип, татар яшьләрен озак кысып булмый икән. Алар үзләренең ризасызлыкларын сиздерә башлаячак икән! Һәм шактый кыю алымнар да кулланачак икән алар! Ә бу инде — каршы як өчен искә алынырга тиешле көчле факт.

Икенчедән, яшьләр журналы хакындагы үтенечләргә җитдирәк карар вакыт җитмәдеме икән? Һәр нәрсәнең өлгерү һәм бозыла башлау чоры була бит. Әнә шуны искә алмау бер дә яхшыга илтми. Бигрәк тә югары урында утыручы кешеләр массаларның психологиясен дөрес чамалый алмаса — торгынлык чоры өчен бер дә кирәкмәгән ЧП килеп чыкса — алла сакласын! Урыныңнан очып төшүең дә бик мөмкин!

Өченчедән, бу вакыйга яшьләрнең үзләре өчен бик тә әйбәт стимул иде. Тырышканда, тәвәккәлләгән чагында, хаким сыйныфлар игътибар итә алырдай адымнар да эшләп була икән! Димәк, әле барысы да югалмаган — көрәшебезне эчтән дә, һәм башка чаралар белән дә дәвам итәргә өмет бар икән!

Дүртенчедән, әлеге факт Мәскәүдәге түрәләргә мәсьәләнең җитди икәнлеген аңлату өчен бер саллы дәлил булды! Татар яшьләре белән озак шаярырга ярамаганлыгын күрсәтте.

Әмма 400 елдан артык «Россия төрмәсе» шартларында яшәгән татар яшьләренең ул чакта әнә шуннан артыкка көче дә җитәрлек түгел иде шул... 400 ел изелгәннән соң тере калу, җан саклый алу да бик зур ныклык сорый бит.

Аннан соң тагын шунысы да бар. Листовка ташлау ише мондый алымнар белән шаяру ярамый. Чөнки урыс патшаларының акыллары үзләре белән — аларга бернинди дә ышаныч юк! Тулы бер халыкны юк итәргә мөмкиннәр... Әнә бит кырым татарларын, калмыкларны, Идел буе немецларын һәм тагын әллә ничә милләтне гомер иткән җирләреннән аерып, кайларга сөрмәделәр?! Безнең милләт турында да гайбәтләрне күп чыгара иделәр. Урыс авторлары язган дәреслекләр гел татарларның «ерткычлыкларын» гына яза. Әйтерсең лә, мәңгә бу империяне төзүчеләр беркемне дә басып алмаган, беркемне дә суймаган, асмаган! Гүяки бу империя миллионнарның каны һәм сөяге өстендә төзелмәгән! Әйтерсең калган бөтен милләтләр гаепле, ләкин «олы туган» гына гаепсез — ул саф, ул ак!

Әнә шул сәбәпле — урыстан кала бөтен милләтләргә төрледән-төрле гаепләр өелгән һәм бары тик бер милләт кенә өскә, югарыга күтәрелгән бер чорда, үз өстебезгә тагын яңа «гөнаһлар» да алу дөрес булмас иде. Ул чагында без торгынлык чорының яңа капкынына килеп эләгер һәм рәсми пропаганда өчен бер начар мишеньгә әйләнгән булыр идек. Безнең милләт тагын да начар хәлдә калыр иде.

Әйе, безнең милли хәрәкәтебез бер генә чорда да тып-тыныч тормаган. Анда гел дә диярлек хәрәкәт, дулкынлану барган. Биредә мин сүз алып, журнал чыгару өчен барган көрәш эпизодлары турында язам икән, бу әле һич тә моңарчы эш булмаган дигән сүз түгел. Бу көрәш тарихы әле еллар үтү белән тагын да тулыланыр, башка кешеләр дә үзләре шаһит булган күренешләр хакында бәян итәрләр. Мисал өчен, миннән соң эшләгән редакторлар Х. Халиков, К. Кәримов, Н. Гыйматдиновларда да кызыклы фактлар бардыр, бәлки... Мин исә биредә бары тик үзем катнашкан һәм шаһит булган хәлләрне генә язам.

Альманах турындагы мәгълүматны дәвам итик. Ул, Татарстан язучылар берлеге органы булып, елга бер мәртәбә басыла иде. Ләкин «язучылар альманахы» дип саналса да, чынлыкта ул китап нәшрияты белән иҗат берлеге арасындагы сөер генә бер «ызгыш алмасы» шикеллерәк яшәде. Хикмәт шунда: редактор дигән кеше, ягъни мин, яшьләрдән әсәрләр җыям, аларның альманах өчен бару-бармавын редколлегия әгъзалары белән берлектә хәл итәбез, әсәрләрне кондиция дәрәҗәсенә җиткердәй итеп редакциялим һәм әнә шуннан соң бу әйберләр, гап-гади бер авторның кулъязмасы сыман, өр-яңадан китап нәшрияты редакторы кулына килеп керә! Өр-яңадан теге әсәрләрне (альманах редакциясендә никадәр вакыт һәм көч сарыф ителгән әсәрләрне!) төзәтү, кыскалау, редакцияләү башлана!

Биредә «кат-кат редакцияләү әсәрне яхшырта гына» дигән бер караш яшәвен дә искәртеп үтәсе килә. Менә бу караш безнең әдәби һәм рәсми оешмаларда шактый киң таралганга күрә, аны тиешенчә ачыклап үтәргә кирәк дип саныйм, шуңа күрә биредә аңа бераз урын бүлмәкче булам. Аның бу тарихка турыдан-туры кагылышы да бар.

Һәммәбезгә дә мәгълүм: әдәбият-сәнгать дөньясы ул — бик тә субъектив дөнья. Чөнки ул хисләргә, кичерешләргә корылган. Шуларның тирәндәге катлаулы яшәешенә нигезләнгән. Алай икән — димәк әдәбият һәм сәнгать әсәрләрен кабул итү процессы да шактый ук субъектив процесс дигән сүз. Һәркем теге яки бу әсәрне үзенчә, үзенең эчке дөньясы рөхсәт иткән дәрәҗәдә, шул тирәнлектә кабул итә, шул дәрәҗәдә рухи эшкәртә, үзләштерә ала дигән сүз.

Менә шушы объектив хакыйкатьне аңлаган тәкъдирдә, без әсәргә бары тик авторның гына чын хуҗа икәнлеген танырга тиеш булабыз. Ягъни әсәр өчен нигездә автор җавап бирә — ул аның шәхесенең күңел җимеше, ул аның рухи дөньясы.

Ә безнең редакторлар бик еш очракларда үзләрен әсәр өстендә тәләсә нишли алырдай хуҗа итеп саныйлар. Кешенең күңел җимешенә карата тупаслык, хәтта кыргыйлык күрсәтәләр!

Бер үк әйберне озак вакытлар яткырып, аны берничә кеше тарафыннан кат-кат редакцияләү бары тик әнә шул рәвешчә генә бәяләнә ала!

Безнең татар дөньясында матбугат аз булу, ә кулъязмалар күп килү һәм аларны, һичшиксез, борырга кирәк булу «сәбәпле»: әнә шундый начар гамәл бик нык колач җәйгән иде.

Бераз гына читкә китү кебек тоелса да, ләкин чынлыкта куелган мәсьәләнең үзәген тәшкил иткәнгә күрә, тагын бер мөһим фикерне тәфсилләү зарур. Авторлар алдында нәкъ әнә шундый киртә, таш стена үтә калын һәм көчле булганга күрә, бездә соңгы елларда Тукайлар һәм Гаяз Исхакыйлар тумады! Без элек яшь талантларга каршы үзебезнең административ система белән бергәләп көрәштек! Кайбер редакторлар аеруча зур «өлеш» керттеләр яшь талантларның активлыгын, димәк, Тукайлыгын бетерү, сүндерү, аларны пассивлаштыру эшенә! Кызганыч, әле мондый караш, болай эшләү байтак редакторлар стилендә һаман да дәвам итә. Алар авторларны тигезләп кенә, чират саклыйсаклый гына бастыру ягында торалар. Болай эшләү аларның үз тынычлыклары өчен мөһим, билгеле. Тегесе дә монысы да: «Нигә аны бастыгыз, ә мине — юк»,— дип әйтә алмый. «Әнә чират!» — дип кенә җавап бирәсең!

Тыштан зур гаделлек булып та күренергә мөмкин болай эшләү. Язучылар да басылу өчен сугышмый, тәртип саклана. Эш, бигрәк тә тынычлык яраткан редакторның эше, гөрләп бара диярлек була.

Ләкин асылда бу — торгынлык чоры җимеше. Бу — әдәби иҗатны сүндерә торган тәртип. Аның максаты — бары тик тыныч яшәү генә!

## Бәхәс! Бәхәс!

«Идел» альманахын үстерү, аны популярлаштыру буенча без бик күп оештыру чаралары күрдек, яшьләрне альманах тирәсенә тарту буенча яңа алымнар да кулландык.

Бәхәс клубы — арада иң кызыгы һәм яшьләрне күп туплаганы булды дисәм, ялгышмам, мөгаен. «Аның фикере, идеясе каян туды соң әле?» — дип уйлап торам да, шушындый ике сәбәпкә килеп терәләм. Берсе — университетта укыган чакта ук безнең татар журналистлары оештырган «Яңавыз» түгәрәгенә бар иде, миңа аның башында йөрергә туры килде. Ә аннары, университеттан аерылгач, әнә шул ялкынлы оешмадан башка яшәү читен сыман иде, нәрсәдер юксындыра иде... Икенче яктан алсак, Ерак Көнчыгышта А. И. Герценның «Былое и думы»сын мин бик тәмләп әр-яңадан укып чыктым. Сез инде бик яхшы беләсез — ул китапта студентлар арасында революцион фикерләр, хәрәкәтләр барлыкка килү күренешләре бик шәп тасвирлана. Россиядә революцион ситуация өлгерү алшартлары эчтән, тирәннән ачыла. Бигрәк тә интеллигенциянең, яшьләрнең рухи яшәешләре тулы чагыла анда. Революцион яшьләр түгәрәкләре күрсәтелә. Яшь әдипләрнең романтик тормышы да кызыктыра.

Альманах тирәсендә йөрүче яшьләр өчен бәхәс клубы оештырып җибәрү дә әлеге уйларның һәм университетта башланган эшчәнлекнең табигый бер дәвамы булды сыман. Һәм тагын бер мөһим мотив, сәбәп бар. Яшь язучыларга, зыялыларга үзара күрешү, сөйләшү, аралашу өчен әнә шундый бер нәрсә кирәклеге дә нык кына сизелә иде. Ягъни тормышта моңа объектив ихтыяҗ зур иде.

Яшьләр белән үткәрелгән эш булгач, аның рәвеше дә яшьләрчә иде, яңача иде! Без кешенең «колагын торгызырдай», игътибарын тартырдай әйберләр уйлап чыгара идек. Шундыйларның берсе яшь һәм бик талантлы шагыйрь Эдуард Мостафин иҗаты буенча «суд» процессы булды. Эдуардның зур сәләткә ия икәне барыбызга да мәгълүм, шул елларда аның беренче китабы да басылып чыккан иде. Ләкин басылмаган шигырьләре аннан да күбрәк иде аның. Һәм алар — бик кызыклар! Язучылар союзы коридорында да, яшьләр очрашкан урыннарда да Эдуард шигырьләре хакында сүзләр еш чыга, капма-каршы фикерләр очрый.

Без ул тикшерүне Эдуардның үзе белән килешеп эшләдек, «суд» рәвешендә алып баруны да хуплады ул. «Кызык бит!» — диде.

Кыскасы, Эдуард шигырьләре буенча ике «гаепләүче»не һәм ике «яклаучы»ны алдан ул билгеләп куйдык. Тикшерү шәп үтте, кайнар рухта барды!

Бу кичәне үткәрүгә бәйле бер кызык кына хәлне сөйләми үзсам, шулай ук хакыйкать тулы чагылмас сыман. Эш шунда: безнең бәхәс барышында тыңларга килеп утырган таныш түгел бер егетнең кесәсеннән кечкенә генә прибор ялгыш идәнгә төшеп киткән! Мин үзем, утырышны алып баручы булганга күрә, моның шаһиты түгел идем. Ләкин «процесс» тәмамланып, халык тарала башлау белән шундук ике-өч егет килеп, миңа әлеге хәлне сөйләп бирде. Ә мин исә шик белдердем, магнитофон түгелдер, бүтән әйбердер ул, дидем. Ләкин тегеләр: «Юк инде, юк, без бит бик якыннан күрдек!» — дип, мине ныклап ышандырыга тотындылар. «Егет үзе кызарып та чыкты әле, тиз генә тыгып куйды!» — дип тә өстәделәр...

Үз күзем белән күрмәгәч, егетләр сөйләгән бу вакыйгага әллә ни әһәмият бирмәдем ул чакта. Нәкъ баштагыча оештыруны, яңа эшләр үткәрүне дәвам иттек... Ләкин ул хәл һич тә истән чыкмады. Аннан соң байтак кына егетләребезнең сакланып, үзләрен бик тә тыярга тырыша-тырыша гына сөйләшүләрен дә искәрә башладым. Ни әйтсәң дә, әлеге оешманың халык, ил алдында «хезмәтләре» бик зур бит! Аннан халык әле хәзер дә курка. Ә инде торгынлык елларында яшьләрнең дә ул оешмага исе китми иде, дип булмый. Чөнки «дөнья бу!» дип яшәүчеләр иҗат кешеләре арасында бар ул.

Бәхәс клубының утырышларын һәр атна саен, язучылар берлегенең иң зур бүлмәсендә үткәрдек. Җыелган саен бәхәс өчен бер мәсьәлә, аерым бер тема алабыз. Шул хакта коридорга белдерү дә эләбез. Без куйган яңа мәсьәләләрнең, үткен-үткен проблемаларның ул чакта — шоп-шома сүзләр һәм аннан да шомарак кешеләр вакытында — кемгә ничек тәэсир ясавын сөйләп, аңлатып кына бетерерлек түгел! Сез бераз күз алдына китерә алсын өчен менә бер генә мисал. Партия өлкә комитеты һәм ул чактагы Язучылар берлегенең рәсми җитәкчеләге күрә алмаган «ата дошман» Нурихан Фәттах иде. Аның дошманлыгы нәрсәдә? Ул татар милләтенең тарихы турында әсәрләр яза башлаган! Ул производство темасына теше-тырнагы белән каршы икән! Язучы кешенең теге янсә бу эштә эшләп йөрүенә дә каршы чыга — әдипнең иң олы һәм төп эше иҗат дип саный ул! Язучыларның ай саен диярлек шау-гөр килеп үтә торган җыелышларына йөрми! Җитмәсә әле, ничәмә ничә роман язуына да карамастан, партия әгъзасы да түгел! Шул кешегә югарыда ничек әйбәт мөнәсәбәт булсын ди инде?!

Аңа менә шушындый тискәре мөнәсәбәт чәчәк аткан елларда без тотабыз да Язучылар союзы коридорына мондый зур белдерү чыгарып эләбез: «Тарих, әдәбият һәм Нурихан Фәттах».

Халык бик күп җыйналды, әңгәмә катнаш бәхәс тә кызыклы булды. Ул кичне кысага сыймастай сүзләр дә байтак әйтелде. «Теге кешеләргә» эш шактый чыккандыр — чөнки безгә таныш түгелләр дә килә, чакыруларны күп җиргә җибәрә идек.

Нурихан аганың исеме чыккач, әйтеп үтим: альманахта эшли башлау белән язучының бер кызыклы әсәре барлыгын әйттеләр. «Яшь язучы белән әңгәмә» икән ул... Әлеге әңгәмәне «Казан утлары»ннан борганнар, бер җирдә дә чыгармыйлар икән...

Хөрмәтле әдипкә шул хакта махсус хат язып, үзе белән берничә тапкыр сөйләшеп, тәки ул әңгәмәне кулга төшерә алдык бит!

Бу чорда яшьләрне көтү-көтү итеп дигәндәй, төрле объектларга сөрү, шунда җибәреп аларны тормышка өйрәтү, язарга өйрәтү гадәте бар иде. Союз, алай гына да түгел, бөтен ил җитәкчелеге тарафыннан ук якланган әлеге рәсми караш җитмешенче елларда үзенә байтак татар язучыларын корбан итте. Хәтта махсус юнәлеш тә барлыкка килде шикелле — өлкә комитетының рәхим шәфкатен һәм яклавын сизеп яза торган бер катлам язучылар! Аларның производство әсәрен бастырмыйча аз гына торсалар да — өлкә комитетына чабучылар!

Шундый чорда Нурихан Фәттахның каршы фикере, әлбәттә, зур киртәгә очрады. Нәшриятта өлкә комитетының сөекле кешеләре шулай ук күп иде — алар сакта уяу тора иделәр! Ләкин ул әңгәмә барыбер безнең альманах өчен әйбәт кенә күләмдә басылып чыкты.

Бәхәс клубында Әмирхан ага Еники белән очрашу да җитәкчеләргә ошамады. Чөнки аңа мөнәсәбәт өлкә комитеты кушуы буенча — тискәре. «Рәшә» белән «Әйтелмәгән васыять» шикелле повестьлар язган кешегә партия һәм җитәкчеләр мөнәсәбәте тагын нинди була ала соң?! Әмма яшьләр белән очрашуга дәшкәч, Әмирхан ага үзе бик шатланып риза булды. Аның белән әңгәмә Фәрваз абый Миңнуллин тырышлыгы аркасында «Казан утлары»нда басылып та чыкты.

Шул рәвешчә, атна саен җыела-җыела, төрле якларга хәбәрләр тарала торгач, без шактый киң даирә яшьләрне туплап өлгердек. Бу кичәләргә артистлар һәм рәссамнәр дә, композиторлар һәм җырчылар да — студентларны инде әйткән дә юк — һәммәсе дә бик теләп, кызыксынып йөри иде. Бик тиз популярлашып китте бәхәс клубы!

Бервакыт «Идел» өчен көрәш турында язам дип вәгъдә ителгән булгач, кайберәүләрне бәлки гел конфликт, бәрелеш һәм сугыш кына күрәсе киләдер. Әйе, алда андыйлары да чыгар. Ләкин шулай да, беренчедән, вакыйгаларның торгынлык чорында баруын күздән ычкындырырга ярамый. Шуңа күрә ул еллардагы конфликтлар да хәзерге сыман халыклар бәрелеше кыяфәтендә, урамнарга чыгып атышулар төсендә була алмый иде. Әлеге дәвердәге бәрелешләр алар тулы бер система белән аерым фидакарь шәхесләр яисә төркемнәр арасындагы бәрелеш иде. Көрәш турында уйлаган вакытта болларның барысын да истә тотарга кирәк. Шул конкрет чор чынбарлыгыннан чыгып карарга кирәк. Гаять тә нык буйсындыру системасын үз кулында тоткан хакимиятнең яшәве хәтердән чыгарылмаска тиеш.

Тагын да мөһимрәге: әгәр дә «Идел» өчен көрәш аерым кешеләр эше булып кына калган булса, югарыда күреп үткәнебезчә, аңа күпләгән яшьләр һәм зыялылар тупланмаган булса — ул көрәшне сүндерү, туктату да кыен эш түгел иде. Әлеге «өч хәрефле оешма» моны бер сәгать эчендә эшли ала иде.

Ләкин, күрәсең, ул чакта ходай үзе безнең белән бергә булган, бергә уйлаган. Нәтиҗәдә, дөресрәк юл сайланды.

## Яшьләр туплана...

Ул еллар өчен гаять мөһим тагын бер күренеш бар. Язучылар берлегенең әдәби консультанты булып Илдар Юзиев эшли башлау белән, яшьләр өчен бер зур чара тормышка ашырылырга тотынды. Республикада яшь язучыларның зона һәм район семинарларын үткәрү гадәткә кереп китте. Билгеле, бу эшкә торгынлык чорының шау-шу чыгаруга корылган чарасы дип караучылар да очрады. Андый караштa торучылар хәзер дә бар төсле. Ләкин яшьләргә игътибарны арттыру ягыннан да, әдәби процессны активлаштыру буенча да — ул башлангыч бик тә зур әһәмияткә ия иде.

Менә күз алдына китереп карагыз. Район җирендә, бер авылда әдәби сәләте булган кеше яши. Ул өз-мөз шигырьләр язып маташа. Ләкин аңа авыл җирендә тиешле бәяне бирә алучы юк. Әле киресенчә: «сәер кеше» дип, көлебрәк карарга мөмкиннәр. Бусы бер. Район газетасы шулай ук төп эше итеп шигырьләр белән шөгыльләнүне санамый: аларга ит, май, күкәй, сөт кирәк! Тирес чыгару кирәк! Әле район газетасы каршында әдәби түгәрәкләр дә бик аз җирдә эшли...

Менә шушындый хәлдә калган яшь каләм иясе ничек яшәргә, ничек көн күрергә тиеш соң инде?! Аңа бит, кемгә карaганда да, аңлану һәм бер сүз ишетү кирәк! Югыйсә, ул үзенең таланты нәрсә икәнен дә аңламый калырга мөмкин!

Кабат искә төшереп үтик — биредә сүз гаять тә кысылган татар милләте турында бара! Әгәр дә, гадәти ирек шартларында яшәүче бер милләт булып, аның күп санлы матбугат органнары чыгып килсә, бәлки әлеге оештыру чаралары соралмас та иде. Үзендә сәләт тойган яшь каләм иясе турыдан-туры берәр редакция белән элемтәгә керер һәм әсәрләрен шунда юллар иде. Үзенә үсеш өчен җирлекне дә, тиешле киңәш бирердәй остазларны да табар иде ул...

Ләкин вакыйга безнең көннәрдә, Россиянең «ашказанындагы» Татарстанда бара иде шул! Торгынлык елларында. Татар мәктәпләре күпләп-күпләп ябыла килгән, «татар теле

озакламый бетәчәк» дигән фикер югары оешмаларда һәм халыкта да һаман ныгый килгән чорда!

Әнә шундый бер караңгы чорда үткәрелгән яшь язучылар семинарлары районнарда әдәби атмосфера булдыру өчен, яшь сәнәтләрне онытмау өчен бик тә кирәкле эшне эшләде. Соңга таба бу әйбәт эш татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә дә үткәрелде. Димәк, ул якта да бетеп баручы милләттәшләребезгә карата кечкенә генә булса да бер күтәрү адымы ясалды. Бер төннек тишелеп, аларга аз гына микъдарьда булса да саф һава — милли рух бөркелде.

Шушы семинарларга бәйле рәвештә тагын бер кызыклы хәлне искә алып үтәргә кирәк дип саныйм. Сүз «Бездә ничә яшь язучы бар?» — дигән, бер карауга гап-гади, икенче карауга бераз сәеррәк тоелган сорау тирәсендә бара. Бәлки, бу мәсьәлә бүтән чорда янсә башка бер милләт өчен ул актуаль булып тормас иде. Һәм аңа хәзер аерым тукталу кирәкмәс тә иде. Ләкин... Ләкин биредә бик зур «ләкин» бар шул! Әнә шул «ләкин» аркасында дөньяның капма-каршы ягы килә дә чыга.

«Идел» өчен кәрәштә исә бездәге яшь язучылар отрядының зурлыгы гаять тә мөһим роль уйный иде. Моның нәрсә икәнен аңлашылса кирәк. Сүз югары оешмаларны чынлап торып ышандыру хакында бара. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, нәкъ әнә шул 800 саныраслану аркасында Татарстанның Чаллы шәһәрендә язучылар бүлекчәсе ачылды. Ә бу бик тә файдалы күренеш иде.

Яшь язучылар исемлеген төзүгә без Илдар Юзиев эшли башлаганчы ук керешкән идек. Без дияем шул — аңа кадәр әдәби консультант булып берничә ай Тәүфикъ Әйди эшләп торды. Татар мәдәнияте һәм әдәби процессы белән азмы-күпме таныш кешегә бу исем яхшы таныш. Журналыбызда без язучы һәм режиссер Роберт Батулла кәрәше хакында кыскача гына язып үткән идек (№ 7, 1990 ел). Торгынлык елларында язучылардан шушы ике кеше үз җилкәләренә бик тә олы йөк алдылар. Фидакарь көрәшләре белән торгынлыкның тулы бер системасына каршы тордылар, каһарманлык үрнәге күрсәттеләр! Тәүфикъ Әйдинең Казанда татар мәктәбе өчен ничек тырышып йөрүләрен, үзе яшәгән төбәктә һәр өйгә диярлек кереп, милләттәшләребезне үгетләүләрен миңа үз күзләрем белән күрергә һәм өлешчә үземә дә булышырга туры килде.

Әйе, биредә Тәүфикъ Әйди исеме яшь язучылар исемлеген төзү уңаеннан килеп керде бит әле. Менә шушындый исемлек булдыру кирәклеге һәм анда яшь язучылар турындагы бөтен мәгълүматлар да язылырга тиешлеге дә Тәүфикътан чыкты. Тулы исеме-фамилиясе дә, кайсы жанрда язуы һәм нинди әсәрләре кайда дөнья күрү дә, авторның яшәү һәм эшләү урыны да — һәммәсе дә ачык күренә иде әлеге исемлектә.

Тулы мәгълүмат бирүче бу исемлекне төзүгә без бик күп көч салдык, ул озак вакытыбызны алды. Илнең төрле төбәкләрендәге һәм республика районнарындагы танышбелешебезне дә эшкә җиктек. Хәер, бу исемлек, нигездә, Татарстан буенча дип төзелде, шуңа күрә аңа читтәге бик күп өлкәләрдә яшәүчеләр керми дә калды кебек ул чакта.

Озакка сузылган ул мәшәкатьле эш тәгәлләнгәннән соң шуны күрдек: республика һәм район матбугатларында актив катнашып, әсәрләрен бастырып килүче яшь һәм башлап язучылар саны 800 дән артып китә икән. Әлеге исемлек, күп данәләрдә машинкада чыгарылгач, дистәләгән биттән тора иде! Без аңа карап ихлас күңелдән куана, горурлана идек! Чөнки, бердән, үзебез шушы шактый мәшәкатьле эшне башкарып чыга алдык, икенчедән, милләтебезнең әнә шул кадәр сандагы яшь каләм ияләре бар икәнен белдек — бу сөенмәслек түгелмени?! Мин моны хәзер, дистә еллар узгач та, олы ышаныч һәм сүрелмәгән шатлык хисе кичереп әйтә алам: безнең яшьләребез, чыннан да, күп санлы!

Ләкин диеп, монда тагын бер кызык күренешне әйтми ярамый. Хәтта аны болайрак итеп, фәлсәфи уйлануга төребрәк тә бендерәсе килә әле. Безнең татарның милли тормышы, милли үзенчәлеге шулкадәр катлаулы, шулкадәр каршылыклы — тора-тора исең китәрлек! Әйбәт, һичшиксез, дөрес һәм файдалы булган күп нәрсә бездә каршылыклы фикер уята, еш кына үзенә киртә дә таба!

Менә бу исемлеккә караш та шундыйрак булды. Нигездә, төзеп, Илдар абый эшли башлагач аны тагын да тулыландырып һәм әлеге исемлеккә 800 яшь язучы теркәлгән икәнлеген сүз араларында кыстыргалый башлагач, безгә карата шундый сүз әйтә башладылар: шуның кадәр яшь язучы буламыни?! Әдәбият кебек үтә җитди эшне сез нигә уен-муенга әйләндерәсез, җитди һәм таләпчән карамыйсыз?

Әлеге карашка җавап биреп үтик. Без — «яшь язучыларыбыз күп» дип чын күңелдән сөенүчеләр һәм аларны тагын да арттыру, үстерү өчен тырышучылар — ул чагында да үзебезгә каршы төшүчеләргә әйтә килдек, сүзебезне бүген дә шикләнмичә кабатлый алабыз. Әмма җавапны тәфсилләбрәк аңлату сорала.

Безнең белән бәхәсләшүчеләр татарның матбугаты аз булган торгынлык чорь дәрәҗәсеннән торып фикер йөртәләр. Алар якынча болай уйлый: матбугат һәм китап нәшриятыбыз бик аз икән, димәк, яшь язучылар да, шуңа бәрабәр рәвештә, аз булырга тиеш. Алар һич тә 800 була алмый!

Ләкин, әйдәгез, Сталин һәм аның нәрченнәре куйган тар кысадан чыгып түгел, ә милләтебезнең чын, объектив зурлыгыннан чыгып фикер йөртеп карыйк. Җиде миллионнан артык татар кешесе өчен 800 яшь каләм күпме, әллә бик азмы?!

Бәхәсләшеп тә тормастан, укучыбыз шундук әйтер дип уйлыйм: әйе, бу сан да бик аз безнең өчен! Безгә әле әллә ничә меңләп кирәк яшь һәм башлап язучылар! Әнә шулай күп булсалар гына тора-бара алар арасыннан менә дигән, зур, көчле әдипләр үсеп чыгарга мөмкин!

Сүзебезгә куәт төсендә тагын бер саллы дәлил китерик.

Бездән күпкә азрак санлы Кавказ һәм Урта Азия халыклары әллә җүләрләрме икән — аларда хәтта союз әгъзасы булган каләм ияләре дә һәркайсында меңәрләп исәпләнә. Чөнки милләтнең рухи ихтыяҗын канәгатьләндерү (ә ул ихтыяҗ бик күп тармаклы, күп катлы — моның өчен сан да күп сорала, сыйфат та яхшы кирәк) шунсыз мөмкин түгел.

Безгә киртә төсендә тагын моны күрсәтергә мөмкиннәр: ә бит аларда китап нәшриятлары һәм газета-журналлар бик күп! Шуңа күрә аларда яшь язучылар байтак булу аклана!

Менә шулай дип әйтү инде әлеге карашның ялгыш икәнен ачып сала. Сәбәп-нәтиҗә баскычында кирегә таба баруны күрсәтә. Чөнки нәшрият булмаган өчен генә яшь әдипләр булмаска тиеш дип кую — дөрес түгел! Халык зур икән — яшьләр дә күп булырга тиеш, нәшрият белән матбугат та ишле яшәргә тиеш! Мәсьәләнең дөрес логик бәйләнештә куелуы менә ни рәвешле генә була ала! Кысан шартларга карап, халык һәм милләт ул кысага яраклаша алмый! Ул кыса үзе халык өстеннән алып ташланырга тиеш! Ә без, тырыша-тырыша, шул кысалар куйган тар гына мәйданны дөрес дип расларга теләбез. Һәр очракта да шунда гына — шул кысада гына бииибез!

Әйтелгән сүзгә тагын бер дәлил. Җитмешенче еллардагы мәгълүмат буенча, Казакъстанда бер елга 10 нан артык санда роман, 100 дән артык санда повесть дөнья күрә иде. Ә бездә бу сан нәкъ ун мәртәбә ким! Ягъни бездә елына бер яки ике роман һәм уннан артык повесть басыла.

Хәзер инде шушы саннар буенча әдәбият өчен нәтиҗә чыгарып карыйк. Яхшы роман һәм повестьлар уку кайда мөмкинрәк — бездәме, әллә алардамы? Язучыга материалны эзләнү һәм өйрәнү өчен дә, язу өчен дә, матди яктан да — һәммәсен дә күзләгәндә, алардагы шартларның күпкә яхшырак икәнен аңлыйсың. Чөнки әдәбият ул тормыш шартларына бәйле нәрсә. Бигрәк тә проза шикелле авыр артиллерия өчен матди шартларның яхшы булуы сорала — иҗат кешесенә күп вакыт, матди җитенкелек таләп ителә. Шунсыз югары сыйфат була алмый.

Дәвамы төсендә моны да әйтмичә ярамый: әнә шундый шартлар тудырылмаганга күрә бездә иҗат өстәмә эш буларак кына яши. Ягъни чит эш арасында гына эшләнә ул! Вакыт һәм мөмкинлек калса гына! Әдәбият бездә икенче, өченче дәрәҗәдәге эш, шундый вазыйфа дип куелган. Без әнә шул тәртипләр буенча яшибез, язабыз... Менә каян килеп чыга бездә югары сыйфатлы проза әсәрләренең бик аз булуы. Хәлтурага якын торган калын-калын романнар күбәю... Укучыга күңел ләззәте, җан рәхәте китерердәй чын сәнгать матурлыгының әсәрләрдә сирәк кунак булуы...

Әлеге «800 яшь язучы» дигән төшенчә безне менә нинди үткен проблемаларга алып кереп китә! Озак еллар дәвамында игътибар ителмичә, күрелмичә һәм өйрәнелмичә, шуңа күрә чишелмичә һәм хәл дә ителмичә килә биргән мәсьәләләр бит алар! Бүген өчен дә бик үткен тора алар — Яңарыш чорында да!

Шушыңа якын уйлар «Идел» альманахында эшләүнең беренче чорында ук туа башлаган иде инде. Уйлаган саен мәсьәлә тирәнгәрәк китә, зуррак көч кирәклеген ача бара иде.

«Идел» тирәсенә оешкан яшьләр белән үткәрелгән чаралар исә андый уйларны тагын да күбәйтәләр, мәсьәләне тагын да үткенәйтәләр иде. Ә инде альманахның басылып чыккан өзер саннарын тикшерүгә багышланган утырышларда без аны ешрак чыгару кирәклеген аңлауга килмичә һич тә булдыра алмый идек. Күреп узуыгызча, тормышыбызның бөтен ягы, һәммә чынлык — уйны да, атлыйсы адымнарны да бер генә якка: яшьләр өчен журнал сорауга таба гына илтә иде. Башка юл юк иде безнең алда!

Ә шулай да конкрет эш, ул чактагы беренче адымнар каян, нәрсәдән башланды соң?

## Беренче адымнар...

Альманах тирәсендә яшь зыялылар күбәйде, дип әйтеп узган идем — алар ишәю белән бергә үк, әсәрләр дә күзгә күренеп артты. Сайлап алу өчен мөмкинлек күбәйде. Сыйфатка ныграк басым ясарга мөмкин була башлады. Альманахның дөньяга чыккан саннары, чыннан да, яшьләребез иҗатының һәммә яктан активлаша баруын чагылдыра иде.

Әмма әдәби басма булган һәр журналны, һәр альманахны, редакция теле белән әйткәндә «тотып тора торган» жанр бар: бу — укучының төп игътибарын били алырдай зуррак күләмле проза әсәре. Һәр редакция үзенең алдагы язмышын, киләчәк тормышын кузаллаган вакытта иң беренче чиратта әнә шундый проза әсәрләреннән — роман һәм повестьлардан чыгып эш итә, үз карамагында андый кулъязмаларның күпме икәнен барлый, басу өчен барырдай һәм бармастайларын аера, аныклый.

Редакциядә повестьлар болай да кубәя төшкән иде инде, авторлардан сораша торгач, әле алар кулында байтак проза әсәре барлыгы беленде. Тиз арада алары да альманах өстәленә килеп ятты!

Шулай итеп, «Идел» өстәлендә егермегә якын повесть җыйналды. Аларның авторлары барысы да диярлек яшь һәм башлап язучылар... Җыюын җыйдык — әмма хәзер аларны нишләтергә? Аларны авторларыннан алганда һәммәсен дә «Идел»гә дип алдык. Димәк, һәркемнең өмете бар дигән сүз! Билгеле, үз тирәбездәгеләр «Идел» буенча зур һөҗүм башлау өчен плацдарм әзерләнеп ятканын һәм әсәрләр күплеге әнә шуның өчен кирәк икәнен яхшы белә иде.

Икенче эш итеп, әсәрләрнең иң яхшыларын редколлегия әгъзаларына укытырга һәм шуннан соң бу мәсьәләгә багышлап махсус утырыш үткәрергә булдык.

Безнең әдипләрнең гел язып кына ятканы, «профессионалы» бик сирәк дип алда әйтелгән иде инде. Аларның һәммәсе дә диярлек казна эшендә көн уздыра, көч түгә. Димәк, үзенең бөтен вакытын, көчен һәм энергиясен шунда түгел, шунда сыгып бетереп кайта ул! Ә өйгә кайткач аннан инде гаиләне, бала-чаганы кайгырту көтелә бит. Гаилә башлыгы икәнлегеңне расларга кирәк! Инде бөтен кеше ял итәргә, йокларга яткач, язучы икәнлегеңне раслау өчен, укучылар синең язучы икәнеңне оныткасыннар өчен һәм үз күңелең теләгән бердәнбер эшне башкару өчен, күңелне тынычландыру өчен әсәр язарга утырырга кирәк!

Күрәсез, татар язучысының хәле каторжанныкы кебек! Ул үзен-үзе әнә шундый ритмга куып кертә дә, тиен кебек, гомер буена чаба! Алны да, ялны да белмичә! Ә бүтәнчә татар язучысы булу мөмкин түгел! Тормышта башка юл юк аңа!

Әнә шулай тиен кебек чабып, эш-мәшәкатьтән кая керергә тишек тә таба алмаган язучыга без тагын бер мәшәкать өстибез: аны редколлегия әгъзасы итәбез һәм яшьләр язган шактый зур күләмле әсәрләрне укып баруын үтенәбез. Бушлай, бер тиен акча да түләмичә! Язучының кыйммәтле вакытын алып!

Шуңа күрә әсәрләр укыту һәр редакция тормышындагы иң авыр эшләрнең берсе дип санала. Билгеле, башка республикаларда — союздаш булганнарында — мондый өстәмә йөк тартканга байтак кына кызыксындыру чарасы карапган.

Ә миңа, ул чактагы автономияле Татарстан республикасында яшәгән һәм милләтләргә бөтенләй игътибар күрсәтмәгән торгынлык елларында, үзе дә нибары йөз генә сумлык эш хакпы редакторга, ни калә? Бер генә чара, иң мескеннәр чарасы: ялыну, ялвару, үтенү...

Бу күренеш хакында уйлануны тәгәлләп, мөгаен, шундый бер нәтиҗә чыгарырга кирәктер. Халык көткән, тормыш алга куйган нинди булса җитди эшне башлап, оештырып җибәрер өчен бер кешенең чынлап торып тотынуы — шул вазифага чынлап торып алынуы кирәк! Даими рәвештә һәм берәзлексез йөрүче, кайчакларда хәтта артыграк та көч куючы һәм үзе өчен зур гына җайсызлыкларга баручы әнә шундый бер шәхес булмаса, безнең ил шартларында оны эш башкару мөмкин түгел! Бигрәк тә милли мәсьәләгә кагылган эшне! Бүген без менә шушы хакыйкатьне истә тотсак иде. Чамасы, мөмкинлеге булган яшь шәхесләребез милләт мәнфәгате өчен олы эшләргә алынудан курыкмасыннар иде!

Шулай итеп, альманахны журналга әйләндерә башлау юнәлешендә, шундый максат белән эш кузгату буенча беренче практик, конкрет адым ясалды. Редколлегия утырышында «Яшь әдипләрнең бик күп әсәрләре бар һәм озак еллар буена басыла алмый ята» дигән карар кабул ителде.

Инде чиратта икенче зур адым ясау иде.

## Идарәгә әзерлек

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе каршына бу проблеманы куюга ирешү! «Идел» альманахы шушы оешма органы сыйфатында яшәп килә икән, димәк, аның киләчәк язмышын да Язучылар берлеге хәл итәргә тиеш.

Менә «язмышын... хәл итәргә тиеш» диеп яздым да, ирексездән елмаеп куйдым. Ирекле берәр илдә яшәсәк — чыннан да, шулай эшләнер иде: язучылар үзләре ничек теләсәләр, шулай эшләр иделәр! Аларга альманах кирәкме, яисә ай саен чыгучы журнал мәслихәтрәкме — моны алар үзләре хәл итәрләр иде. Беркемнән дә сорамыйча! Әмма ул чакта безнең илдәге ахмак тәртипләрнең бөтен хикмәте дә шунда шул: беркем дә бернәрсәгә дә хуҗа түгел — барысы белән дә бары тик партия генә идарә итә! Ул гына командалык итә! Алар рөхсәтеннән башка җил дә исми, яфрак та селкенми...

Ә матбугат инде бигрәк тә партия кулында! Партия матбугатны, әкиятләрдәге дию гүзәл кызны япкан сыман, җиде кат йозак белән биклап куйган! Совет системасының

әнә шул тимер законын без, әлбәттә, белә идек. Мәсьәләне партия органнары каршына куярга кирәклеген аңлый идек. Әмма моңа кадәр сөйләгәннәр бит әле безнең беренче адымнар гына — проблеманың нигезен ныгыту гына!

Димәк, алда — Язучылар берлегенең идарәсе...

Хәзер — бүгенге көндә минем үземә дә аңлау кыенрак тоеле: язучылар өчен кирәк булган шушы журнал турындагы мәсьәләне идарә утырышына кую, әйтерсең лә — иң зур эш! Гүя бу — бик тә олы эш майтару! Сезнең башка да менә хәзер, һичшиксез, шундый уй киләдер — «Бик кечкенә эшне дә зур итеп күрсәтергә тырыша бит бу җегет кисәге!» — дисездер бу юлларны укыганда... Ләкин күңелегездән шушы уй үткәч тә, сез бер бик мөһим нәрсәне аңларга, истә тотарга тырышыгыз: торгынлык дигән чорның бөтен хикмәте әнә шунда иде бит аның — эшләнүе иң гади тоелган нәрсәләрнең дә эшләнмәвендә иде хикмәт! Һәр адымга гаять тә көчле тоткарлык ясала иде!

Язучылар берлеге идарәсе шуңа бик тә ачык мисал була ала.

Хәзер инде барыбызга да мәгълүм: тулаем, бу оешманың төзелүе үк иҗат кешеләрен властька бәйле итеп, тезгенләп тоту өчен кирәк була. Революциягә кадәр үзебезнең әдәбиятның алтын чоры булган Бишенче елларны карагыз сез: Тукайлар, Әмирханнар, Исхакыйлар — берсеннән-берсе зуррак һәм хөррәк фикерле затлар, фигуралар! Алар күпме олы әсәрләр язган! Халык тарихына мәңгегә кереп калган. Ә бит берниндә дә союз булмаган, милләтләргә «бәхет бирүче» коммунистлар партиясе дә яшәмәгән... Сибгат ага Хәкимнең шундый уйларын ачып салган юллары бар бит:

*Хакыйкатьне әйтеп бирер өчен*
*Союз түгел,*
*Йөз язучы түгел —*
*Бер Толстой җиткән,*
*Бер Тукай!*

Утызынчы еллардан алып сиксәненче елларга кадәр — төп-төгәл ярты гасыр буена, әлбәттә, партия һәм КГБ Язучылар берлеген тулысынча үз кулында тотты. Моның шулай булганлыгын хәзер барыбыз да аңлый, белә. Хәзер инде бу фикерне яңа фактлар китерә-китерә яңадан да раслап торасы юк! Бигрәк тә үзәк матбугат ул хакта күп язды, миллионлаган факт китерде... Безнең республикада да нәкъ шундый хәл кабатланды. Әле бәлки күпкә катырак режим яшәгәндер безнең Татарстанда ул чакны?! Чөнки без кемнәрдер өчен аеруча «куркыныч халык» бит!

Җитмешенче еллар уртасында һәм ахырында да партия өлкә комитетының кулы бик көчле иде әле союзда.

Идарә утырышына «Идел» мәсьәләсен чыгаруны иң элек аксакаллар белән киңәшүдән башладык. Гомәр ага Бәширов белән Нәкый ага Исәнбәт безнең фикерне берсүзсез якладылар.

Язучылар союзының Илдар Юзеев белән без икәү утырган бүлмәсенә Сибгат ага Хәким дә килгән саен керми китми иде. Хәтта әле ул иң элек шунда кереп, хәлләрне, яңалыкларны белешә иде. Аннан соң, аларның Илдар абый белән серләре дә бик килешә иде.

Сибгат аганың бер керүендә Илдар абый аңа иллә кенә серне чишә башлады. Хәлне аңлатты. Хәтерлим, Сибгат ага шундук җитдиләнеп китте һәм берсүзсез килеште дә! «Кайчан керәбез соң...» — дип кенә куйды бугай ул... Инде төгәл хәтерләмим: шул ук көнне ме, әллә бераз үткәч ме — ләкин Сибгат ага белән Илдар абый союз председателе Гариф Ахунов янына кереп, алдагы идарә утырышларының берсенә — иң якындагысына бугай — «Идел» альманахы мәсьәләсен куярга булдылар.

Куелуын куела мәсьәлә — ләкин бит әле сүз ни рәвешле барыр? Редколлегия утырышы мисалында минем инде бераз авыз пешә язган иде бит.

Шуңа күрә, идарә әгъзасы булган әдипләр белән алдан сөйләшмичә, киңәшмичә һич тә ярамый иде. Идарә утырышында безгә бер сүздәрәк булырга: фикерне «ай саен чыгучы журнал» дигән карарга таба этәрергә кирәк иде!

Бу утырыш озак, бик тә озак барды. Анда катнашкан бер генә кеше дә сүз алмыйча, үзенең фикерен белдермичә калмады. Ә ул фикер барысыныкы да уртак иде: мәсьәлә, чыннан да, өлгергән, аның буенча тиешле документлар әзерләргә һәм югары оешмалар каршына куярга кирәк! Бу эшне тормышка ашыру өчен бигрәк тә Язучылар берлеге рәисе, СССР Верховный советы депутаты Гариф абый Ахуновка күп йөрергә туры киләчәге әйтелде. Аксакаллар әнә шуңа басым ясадылар.

Идарә утырышының менә шушы 1976 елгы карары безнең алдагы хәрәкәтебез өчен нигез дә, җирлек тә булды. Чөнки анда Татарстандагы барлык иҗат союзлары вәкилләре һәм партия белән комсомол кебек җитәкче оешмалардан килгән иптәшләр дә бар иде. Димәк, инде бу нәтиҗәгә барыбызның уртак, килешенгән фикере дип карарга ярый!

Тагын-тагын киңәшә торгач, мондый уйга килдек — яшьләр өчен чыгарылачак журнал турында сүз баргач, иң элек комсомол Үзәк Комитетына мөрәҗәгать итәргә

кирәктер. Республиканың барлык иҗат оешмалары һәм комсомол өлкә комитеты исеменнән!

Комсомол өлкә комитеты вәкиле Ринат Закиров безнең утырышта катнашты. Ул эшне тулысынча белә һәм безне аңлый. Тик менә аның мөдире Шәймәрданова дигән ханымга килеп җиткәч, эш озакка тәрәлде, туктап калды. Хикмәт шунда: үзенең хезмәт вазифасы кушу буенча ВЛКСМ Үзәк Комитетына дигән әлеге хатны менә шушы Шәймәрданова язарга тиеш. Ә ул, күрәсең, мондый эшне — алар өчен гадәти түгел адымны — башкара алмый. Аның хәленнән килми бу! Яшьлегем, тәҗрибәсезлегем аркасында аның кулыннан килмәгәнлекне мин дә аңлап җитмим әле... Шуңа күрә, көн саен диярлек аның янына барып: «Эш ничек тора?» — дип сорыйм... Арттырып әйтүем түгел: бер унлап мәртәбә генә барганмындыр! Аптырагач, теге ханымның ачуы ук кабара башлады! Мине күрәсе ук килми тегенең... Шулай, байтак кына мине дә газаплагач, үзе дә шактый гына тинтерәгәч — ниһаять, көннәрдән беренде, Ринат әлеге хатның башланган вариантын үз бүлмәсенә алып чыкты да, без ул хатны бергәләп тиз генә арада язып та куйдык!

Әле бу гына да түгел. Ринат Закиров белән без әзерләгән ул хат инде тәмам кысасына кереп җиткәч, теге Шәймәрданова дигән бүлек мөдире дә аның белән килешкәч, комсомолның идеология буенча секретаре бар бит әле. Бу елларда анда Газизуллин дигән иптәш иде. Менә шул секретарь безгә болай димәсенме:

— Бик җитди проблема бу. Ашыкмыйк... Әйдәгез, махсус комиссия төзеп, тагын бер кат тикшерик! Хатны җибәрми торыйк.

Моңа кадәр дә бит инде аларның бүлек мөдире артыннан йөреп, ярты ел чамасы гомер үткән. Хәзер бусы, яңадан өйрәник, ди, комиссия төзик, ди! Шунда мин түзеп тора алмадым, кызып китеп, аңа болай дип тездем:

— СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким, Тукай бүләге лауреаты Хәсән Туфан һәм бүтән бик күп абруйлы әдипләр фикере сезгә дәлил түгелмени! Сездә әдәбиятны һәм аның проблемаларын болардан да ныграк аңлый торган тагын кем бар? Сез кемнәргә тапшырып, вакытны тагын да сузарга уйлыйсыз?!!

Менә шушы ике кеше турында сөйләгәннән соң, бераз гына нәтиҗә чыгарып китәсе килә. Комсомолның зур гына урындагы ике түрәсе, «Идел» мәсьәләсенә бер нинди дә файдалы адым ясамыйча ярты елга якын гомерне суздылар! Әле бу беренче этапта гына! Соңрак бу тагын да күбәячәк әле. Ул түрәләр ни өчен шулай суза? Үз өсләренә җаваплылык алудан куркалар, әнә шундый җаваплылыкны аласылары килми! Чөнки алар хезмәт иткән системага мондый адым ясау кирәк түгел. Алар акыллары белән бик яхшы аңлыйлар: Язучылар союзындагы ниндидер әдипләр карар чыгарса да, бу эш — «Идел» журналы сорап йөрү — алар утырган ботакка балта чабу кебегрәк. Турыдан-туры ук булмаса да, нигездә, әнә шундый зур каршылык ятканын һәм әнә шуңа күрә бу адым өчен үзләренә өстән һич тә рәхмәт әйтелмәячәген алар, әлбәттә, чамалый. Дөрес чамалый! Эш күп дию, өлгермәгән булып кылану янсә «комиссия тикшерсен» дигән хәйлә табулар — болар барысы да вакытны сузу өчен генә кирәкле нәрсәләр иде! Болар торгынлык чоры өчен бик тә типик сыйфатлар иде.

Ниһаять, безнең иҗат союзлары һәм комсомол өлкә комитеты исеменнән язылган хат комсомолның Үзәк Комитетына китте. Без инде никадәр көч түгеп йөргәч һәм, әле ул чакта комсомол хакындагы югары сүзләр тәэсирендә, үзебезнең беркатлылыгыбыз белән — ул хатка зур өметләр баглыйбыз. Көннәрне дә санап кына торабыз!

Ләкин шулай да, ул хат җибәрелгәнче, мондый фикергә дә килгән идек: хатка тагын да көч бирү өчен, проблеманың дәреслегенә өстәгеләрне ышандыру өчен, халыктан Мәскәүгә хатлар җибәрергә кирәк!

«Идел» альманахы тирәсенә тупланган барлык таныш-белеш шушы эшне оештырырга керешге. Хатларны бер үк вакытта комсомол Үзәк Комитетына да һәм партия Үзәк Комитетына да җибәрә идек. Чөнки матбугат мәсьәләсенең комсомол тарафыннан гына хәл ителмәгәнлеген чамалыйбыз. Югарыда әйтелгәнчә, безнең илдәге бөтен матбугат ул чакта КПСС кулында гына иде бит.

Әлеге хатлар, менә шул чактан алып, «Идел» операциясе ахырына җиткәнче — күп еллар буена язылды. Алар аерым авторлардан да һәм олы-олы предприятиеләрдән, оешмалардан да була иде. Аңа ил күләмендә югары исем, дәрәҗә алган бик тә абруйлы кешеләр күп куялар иде. Һәм ул хатлар бер Татарстаннан гына да түгел, ә илебезнең татарлар яши торган барлык төбәкләреннән: Башкортстан һәм Чувашстаннан, ерак Сахалин һәм Балтик буеннан, төньяктагы Воркута шахтерларыннан һәм Казахстан, Үзбәкстан татарларыннан, Мәскәү белән Ленинградтан да күпләп-күпләп языла иде.

Хәзерге чордан чыгып караганда, бу эш шактый җиңел башкарылган сыман тоелырга мөмкин. «Файдасы булдымы икән соң?» — дигән шик тә тууы мөмкин кайберәүләрдә...

Ләкин озак еллар дәвам иткән торгынлык чорында бу безнең төп чараларыбыздан берсе иде. Ул бит халык сүзе, массалар фикере иде! Баштарак ул хатларга «мәсьәлә өйрәнелә» дигән стандарт кына җаваплар да килә иде. Соңрак алары да туктады...

Керештә чираттагы адым — партия өлкә комитеты иде... Безнең Язучылар берлегеннән әнә шул югары оешмага рәсми бер делегация барырга тиеш. Киңәшкәч, шундый фикергә килдек.

Өлкә комитетында исә идеология секретаре булып М. Ф. Вәлиев, ә культура бүлеге мөдире булып М. М. Мусин эшли. Болар — торгынлык чорының, шул системаның типик вәкилләре. Һәр икесе дә бик матур, бик ыспай сөйли. Һәр икесе — тыштан бик интеллигент кыяфәтле, «шәп» кешеләр. Алар безнең язучы халкы алдына чыксалар, икешәрөчәр сәгать буена бер өзлексез сүз сөйли алалар. Халыкны авызларына каратып тота алалар. Ләкин милләт өчен, культура өчен алар дәверендә эш кенә эшләнми! Милли мәктәпләр ябыла бара, татар китапларын басу бик нык кими. Ә болар Мәскәү карарларын үти.

Биредә ул чактагы команда-административ системаның бер каты закончалыгын искә төшереп үтү мөһим. Анда барлык эшләр югарыдан кушу буенча гына башкарыла иде. Бөтен карарлар да югарыдан төшә, теге яки бу проблемага нинди мөнәсәбәт булдыру кирәклеге дә өстән күрсәтелә — кыскасы, һәммә яшәү бары тик өстәгеләр кушуы буенча гына. Берсүзсез буйсынып кына!

Яшьләр журналына карата да югарыдан әнә шундый тискәре мөнәсәбәт көйләп куелган иде. Күп еллар элек! Һәм ул канунны бозу астагылар өчен бик хәвефле адым санала иде. Тыныч кына озак еллар эшләргә теләгән карьеристлар мондый канунны бозу турында бигрәк тә уйламаска тиешләр!

Менә шушы олы каршылык безгә бик нык сизелә башлады.

Ничек итеп, ни рәвешле сизелә?

Иң элек үзебезнең Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гариф абыйның үзен тотышында чагылды ул. Идарә утырышыннан соң байтак кына гомер узса да, ул ни өчендер өлкә комитетына барырга ашыкмады...

Шактый гына гомер узгач, инде тагын Сибгат агадан ярдәм сорадык. Өлкән һәм хөрмәтле фронтовик шагыйрь буларак, Сибгат аганың партия өлкә комитетында сүзен тыңлыйлар, үтенеченә колак салалар.

Берничә көннән Сибгат ага партия өлкә комитеты секретаре Вәлиевнең ризалыгын алды. Вәлиевкә кемнәр барасын да киңәштек: Сибгат ага Хәким үзе, Гариф абый Ахунов, Шәүкәт абый Галиев һәм мин.

Шунысын да әйтеп китик: ул чакта өлкә комитетының куркыту көче, безгә тәэсире хәзергегә караганда нык зур иде. Шуңа күрә анда бару, бигрәк тә ничә еллар буена безне өркетеп яшәгән идеология секретаре Вәлиев янына бару безнең һәммәбез өчен зур вакыйга иде!

Билгеле, бу хәлдә безне аңламыйча, барысына да төкереп кенә караучы, кыланчык егетләр дә булды. Алар бездән: «Ха-ха! Булмас эш артыннан йөрисез, ә!..» — дип мыскыллап көләләр иде. Ләкин алар үзләре әнә шул чорда да, хәзер, заманнар җиңеләешкәннән соң да, милләт тормышын һәм татар әдәбиятының хәлен җиңеләйтү өчен кыл да кыймылдатмадылар! Ул чордагы үзебезнең шактый мескенлегебезне күз алдына китергәндә дә мин янәшәмдәге әлеге «бөекләр»не уйлыйм да — аларның кыяфәт чыгарудан башка бүтән берни дә кырмауларын күрәм.

Ниһаять, айлар буе борчылып йөргән, никадәр кайгырган көн дә килеп җитте. Без, авылча әйткәндә, киенеп-ясанып, өч язучы һәм мин үзебезнең «патша» янына киттек. Мин әле ул чагында КПСС члены да түгел, шуңа күрә обком бинасына үтү өчен алдан ук махсус шалтыратып, миңа пропуск әзерләделәр. Без, каләм ияләре, әллә ничә милиционер берьюлы саклаган ишекләрдән үтеп, идеология секретаре утыра торган зур бүлмә янына килеп җиттек. Мирзаһит Фәтхиевич безне үз кабинеты ишегеннән кабул итү бүлмәсенә үк чыгып, бик сөенгән, чын күңелдән шатланган кыяфәттә каршы алды. Һәммәбезнең кулын кысты, бертуктаусыз елмайды... Ә минем белән күрешкәндә, шулай ук елмая-елмая, һәм бер үк вакытта аркага каккандай итә-итә, русчалатып кына:

— Самый агрессивный что ли?— дип куйды. Бу сүз мине мактау тоны белән әйтелде әйтелүен. Исәнләшкән көйгә аны миннән башка бүтән беркем дә ишетмәде дә, искәрмәде дә... Ләкин әлеге сүзләрдә мине каты гына кисәтү дә бар иде. Артык узынмаска, чама хисен югалтмаска, янәсе!

Менә хәзер, күп кенә еллар узгач, уйлап куям. Бу бит инде шул Вәлиев — язучыларның VII съездында: «Революциягә кадәр татар китаплары хәзергедән күбрәк чыккан»,— дип сөйләгән өчен Рафаэль Мостафинны «Казан утлары»ның баш редакторлыгы вазыйфасыннан азат иткән Вәлиев!

Чын хәлне ул белмәгән дисезме?!

Белгән, белүен! Ләкин аңа үзенең урынын ныгыту өчен илдә хөкем сөргән рәсми политика сүзен сөйләү кирәк булган. Һәр адымда: «Бары тик урыс халкы гына бөек, бүтән халыкларга урыс халкы гына ярдәм итте, социалистик революция генә татарны яктыга чыгарды — шуңа күрә сез социалистик революциянең кадерен белегез, бүгенге системаның кадерен белегез!» — дигән фикер үткәрү мөһим булган аңар. Әнә шулай итеп,

алар үз урыннарын, үзләренең рәхәт һәм бай яшәү рәвешләрен ныгытканнар! Безнең күңелләргә керә башлаган тәрле шик-шөбһәләргә каршы әнә шулай итеп көрәшкән алар!

Һәрбер чор карьеристы өчен бик тә мөһим сыйфат бу: үз милләтеңә яла ягу, башка милләткә хезмәт итү. Шул юл белән үзеңә югары урын, рәхәт тормыш яулау! Җитмеш ел буена безнең өлкә комитетын һәм башка югары постларны биләгән түрәләрне карагыз — аларның күбесен менә шушы бер сыйфат берләштерә! Аларның күбесе татар милләтенә каршы көрәшеп, үзенә югары урын яулый. Аны озак кына биләп тора. Алай гына да түгел — күп җирдә, официаль чыгышларда «олы туган»ны мактый, үзебезне сүгә. Шулай итеп, югарыдагыларга, Мәскәүләргә ошый. Һәм күп чакта максатына ирешә дә! Аңы җылы урын бирәләр! Гомәр Усманов карьерасы һәм аның «Вечерняя Казань»да (8 май, 1991 ел) басылган әңгәмәсе моңа бик ачык мисал.

Юк, димәгез — карьеристларның мондый алымы әле бүген дә актив кына куллана. Тирә-юнегезгә карасагыз, андыйларны бик күп табарсыз! Усманов ишеләр әле дә татарга каршы көрәшә!

Ул чактагы Вәлиев белән Мусин — һәр икесе дә әнә шундый типлар иде. Беренче секретарь Табиевның инде әйткән дә юк!

Ярый, шуларның берсе янына, Вәлиев янына яшьләр журналы сорап, зур гозер белән кердек бит инде. Әле тагын да дөресрәге: сугышка кадәр басылган журналларның берсен торгызу хакында гына сүз бара. Болай итү эшне шактый җиңеләйтер дип уйлыйбыз...

Кергәч, инде сүзнең каян һәм ничек башлануы сезне кызыксындыра.

Менә хәзер ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк — әмма барысы ике сәгатьләп вакытны алган ул сөйләшүнең баштагы бер сәгать ярымы бөтенләй бүтән нәрсә турында барды! Әңгәмәнең башында ук Вәлиев безнең союз җитәкчебез Гариф абыйга кайсыдыр классик язучыбызның юбилеен ничек үткәрү хакында сорау бирде дә, (күрәсең ул бу сорауны юри алдан ук әзерләп куйган, үзенә вакыт сузардай мөмкинлек алган) шуннан соң Гариф Ахунов белән Вәлиев арасында телефоннан да сөйләшеп һәм хәл итеп була торган гап-гади әңгәмә куерып китте. Шулай итеп, чит темага сөйләштереп, өлкә комитеты секретаре безне шактый алҗытты, арытты. Арабыздагы иң өлкән кеше Сибгат ага өчен мондый озакка сузылган сүз бигрәк тә авыр иде... Әле, шуның өстәвенә, Вәлиев без кергәч телефоннан берничә кешегә шалтыратып та алды, шулай итеп тагын күпмедер вакыт югалды...

Менә шуннан соң гына өлкә комитеты секретаре безнең мәсьәләгә күчүне кирәк тапты. Аның мөнәсәбәте: «Әйе шул, кирәк шул, кирәк!» — дигән стандарт сүзләр рухында булды һәм бераздан шундый ук стандарт булган «ләкин...»гә килеп терәлде. Ә аларның «ләкине» нәрсә булу безгә күптәннән билгеле инде: илдә кәгазь белән хәл авыр бит әле, автономияле республикаларның берсендә дә андый журнал юк, без алсак, бүтәннәргә дә бирергә кирәк була, кәгазь бик күп сорала...

Ул боларны шаярган төсле генә, бик тиз арада гына әйтеп алды, җитди әһәмият бирмичә генә...

Аннары оста артистларча безнең алда тагын бер «сәхнә номеры» башкарды ул — телефоннан тиз генә Үзәк Комитетны җыеп алды. Тегеннән әйтелгән сүзне шундук безгә дә кабатлагандай итте:

— Леонид Ильич аша гына дисезме?...

Бу инде «проблеманы Брежнев кына хәл итә ала» дигән сүз иде, янәсе.

Шул рәвешле безгә дә җавап бирү кебек иде инде бу! Шуннан соң Вәлиев, без утырган өстәл янына килеп, һич тә кәефен төшермәстән, үзе өчен бик күңелле темага әңгәмә кылгандый, сүзен дәвам итте. Ә бераздан безнең җитәкчебезгә болай диде ул:

— Давай, Гариф, без сине ни өчен депутат итеп сайладык! Давай йөр, теләсәң кая йөр — синең хәзер бөтен полномочиелар да бар бит!

Гариф абый аның белән килешкән сыман, шул ук вакытта ризалашып та бетмәгән тавыш белән нидер әйтте...

Сүзнең ахырга таба якынлашуын сизеп, мин гадәттәге пырдымсызлыгым белән әңгәмәгә кушылдым:

— Бүтән республикалар ни өчен алалар соң? Безгә кәгазь юк диләр, ә бүтәннәр һаман ала торалар!

Вәлиев миннән:

— Кая, кемнәр ала?— дип сорады.

Ә мин аңа «Литературная газета» битләрендә чыга торган информацияләрнең берничәсен китердем. Ул вакытта Молдавия белән Казахстанда яшьләр өчен аерым нәшрият ачылган иде. Кайсыдыр бер республикада яңа журнал чыга башлаган иде... Мин шуларны атадым.

Өлкә комитеты секретаренең моңа да җавабы әзер иде:

— Егетләр, алар бит союзный...

Аннан соң Гариф абый китәргә ашыга башлады. Вәлиев та кабул итү беткәнлеген сиздерде. Кыскасы, без саубуллашып, чыгып киттек.

Ә Вәлиев һаман элеккечә — иң якын дусларын озаткан шикелле, гаять тә җылы мөнәсәбәт күрсәтеп, елмая-елмая озатты безне...

Менә шул. Ни гомер көтелгән һәм «Идел» өчен көрәштә әллә ниләр бирер сыман тоелган кабул итү чынлыкта бик күңелсез тәэсир калдырды. Югарыда күргәнегезчә, бер яктан — никадәр көчле теләк, тормыш ихтыяҗы, ә инде икенче яктан, түрәләр тарафыннан мәсьәләгә ис китмәү, битарафлык... Ике көчнең бәрелеше озак еллар дәвам итте...

Бу «Идел» өчен көрәшнең башлангыч этабы гына иде. Аннан соң да бик кызыклы эпизодлар булды: мәсәлән, Фикрәт Табеев янына һәм Мәскәүдә Сергей Михалков янына берничә мәртәбә бардык. М. А. Сусловка керергә тырышып карадык. РСФСР Министрлар Советында һәм Госкомиздатында йөрдек. КПСС Үзәк Комитетына да барылды... Боларның һәммәсе — үзенчә бер кызыклы хикәят. Ләкин инде алары турында башка вакытта. Әлегә сүзне йомгаклап әйтәсе килгәнем шул: 1989 елда яшьләрнең озак еллар көтелгән журналы «Идел» яңадан чыга башлаган икән — бу җиңүгә ирешүдә күпләгән фидакарь җаннарның өлеше булды. Андый көрәшләр туктамасын иде!

---

*Котлыйбыз!*

## Гәрәй Рәхимгә 50 яшь



Гәрәй Рәхим (Родионов Григорий Васильевич) 1941 елның 15 июлендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Федотовка (халык телендә «Аланлык») авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлый, берничә ел колхозда һәм авыл китапханәсендә эшли. 1962—67 елларда — Казан университеты студенты. 1967—80 елларда Г. Рәхим «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында редактор, республикабыз Язучылар берлегендә әдәби консультант, «Казан утлары» журналында проза бүлеге мөдире булып эшли.

1980—87 елларда әдип Мәскәүдә яшәде, М. Горький исемендәге әдәбият институтының Югары әдәби курсларында укыды, РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә Россия милли әдәбиятлары буенча өлкән консультант, Идел буе һәм Урал төрки әдәбиятлары комиссиясенең җаваплы секретаре булып эшләде.

Утыз еллык иҗат гомерендә Г. Рәхим поэзия, проза, драматургия һәм балалар әдәбияты өлкәсендә 25 китап бастырып чыгарды.

1984 елда Г. Рәхим, «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы либреттосы өчен ТССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. 1986 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

Г. Рәхимнең әдәби-фәнни һәм тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә игътибарга лаек. Ул «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н төзүчеләрдән һәм СССРның «Совет энциклопедиясе» нәшриятында дөнья күргән «Әдәби энциклопедик сүзлек» дигән академик басма авторларыннан берсе. Озакламый Татарстан китап нәшрияты Г. Рәхим тарафыннан төзелгән «Татар поэзиясе антологиясе»н ике китап күләмендә бастырып чыгарачак. Г. Рәхим Давыт Көгелтдиновның «Иркенлек» дигән шигырь китабын һәм Сергей Есенинның «Анна Снегина» дигән поэмасын туган телебезгә тәрҗемә итте.

1987—89 елларда Г. Рәхим Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары булып эшләде. Хәзерге көндә ул — Язучылар берлеге идарәсе, шулай ук «Казан утлары» журналы һәм «Шәһри Казан» газетасы редколлегияләре әгъзасы.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр!

# ХАЛЫК УЛЫ



Талантлы режиссер, актер, театр педагогы Ширьяздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков — милли сәхнә сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Аның күпкырлы иҗади эшчәнлеге дистәләрчә ел буена Г. Кариевның реалистик традицияләрен үстерү, туплыландыру, баетуда зур мәктәп, аларны бүгенге көн белән тоташтыручы ышанычлы күпер хезмәтен үтәде.

Ш. Сарымсаков сәнгать дөньясына шаулы егерменче еллар ахырында аяк баса.

1928 ел. Казан.

Ул чорда республикабыз башкаласы талантлы шәхесләргә байлыгы, фикерләр төрлелеге, иҗади юнәлешләрнең күплеге белән аерылып тора. Һәр иҗат кешесенең ихластан кабул иткән социализм идеяләре, сәнгатьтә тоткан кыйбласы өчен җанын-тәнен кызганмый көрәшкән чагы. Казан театр техникумының беренче сыйныф шәкерте, үнҗиде яшьлек Ширьяздан баш-аягы белән әнә шул кайнап торган дөньяга чума. Бу иксез-чиксез шаулы иҗат диңгезендә башта аңа остазы, күренекле режиссер Гомәр Девишев юл күрсәтә, актерлык осталыгы, режиссура буенча төгә күнекмәләрне бирә. Алга таба Ш. Сарымсаков укуын Мәскәү үзәк театр техникумында (соңрак ГИТИС) танылган рус режиссеры И. Я. Судаков һәм педагог А. П. Грипич классында дәвам итә. Булачак сәхнә остасы алардан психологик төгәллек, уй-хис, кичереш дөреслеге, тормыш кысаларында иҗат итү төп канун итеп саналган режиссура дәресләрен үзләштерә. К. С. Станиславский нигез салган бу театраль юнәлеш Ш. Сарымсаковның иҗат кыйбласына әверелә, алга таба аның үсеш юлын билгели.

Татар дәүләт академия театрына Ш. Сарымсаков 1936 елда кайта. Инде сәнгать дөньясында егерменче еллардагы фикерләр, юнәлешләр төрлелеге, бәхәсләр кайнарлыгының эзе дә калмаган. Ил өстендә арта барган шикләнү, курку атмосферасы куера бара. Күп кенә олы шәхесләр төрле рәвештәге эзәрлекләүләргә дучар ителгән. Штат кыскарту сәбәбе белән ТДАТтан К. Тинчурин, С. Булатов кебек режиссерлар чыгарылган. Утызынчы еллар башыннан ук академия театрының сәнгать эшләрен җитәкләгән Р. Ишморат «укырга» китәргә мәҗбүр булган. Шулай ук талантлы яшь режиссер Г. Исмәгыйлев та, эзәрлекләүләргә түзә алмыйча, бүген-иртәгә Казаннан китәргә тора. Шушы шомлы мохиткә килеп кергән яшь режиссерның төүге адымнары кыюлык ягыннан әллә ни аерылмый. Ул беренчеләрдән куйган Вс. Ивановның «Бронепоезд 14-69», А. Н. Островскийның «Төшемле урын» әсәрләре коллектив репертуарына яңалык алып керсәләр дә, Ш. Сарымсаковның бары үз иҗат җимеше булудан бигрәк, Мәскәү театрлары спектакльләренә нияру булырак кабул ителә. Шулай да эш барышында яшь режиссер характерындагы кайбер сыйфатлар ялтырап кала. Ул да булса — тырышлык, хезмәт сөю, үз дигәнен булдыруда максатчанлык, бай эрудиция...

Ш. Сарымсаков — татар театр сәнгатенә К. С. Станиславский системасын кертү эшен башлаган Г. Исмәгыйлов эстафетасын иң актив дәвам иттерүчеләрнең берсе. Бу аның Х. Уразиков, Х. Сәлимҗанов белән берлектә Г. Исмәгыйлев башлаган һәм генераль репетицияләргә китереп җиткергән «Ташкыннар» спектаклен чыгаруда катнашуында гына түгел, бәлки андагы бөтен эшчәнлегендә дә чагылыш таба. Шунысы кызык, алар пропагандалаган Станиславский дәресләре Г. Кариев мәктәбенә нигезләнгән милли сәхнә сәнгатенә ят түгел, киресенчә, аны баетучы, үстерүче мәктәп булып чыга. Дөрес, утызынчы елларның икенче яртысыннан «МХАТ нормаларын» ил күләмендә рәсми төстә, мәҗбүри итеп уздыра башлыйлар. Бу үз чиратында иҗатчыларның фантазиясен чикли, аларны билгеле бер кысаларга бикли, сәхнә сәнгатен ярлыландыра. Дөрес, Ш. Сарымсаковның режиссурасында Станиславский системасы мәҗбүрият түгел, ә шул мәктәп шәкертенең ихлас кагъбәсе, ирекле иҗат өчен бик кирәк булган мөһим шарт.

Ш. Сарымсаковка беренче зур уңыш М. Әблиевның «Шәмсекамәр» әсәрен сәхнәләштергәннән соң килә. Революциягә кадәр яшәгән татар хатын-кызларының тра-

гик язмышын сурәтләгән бу әсәр тамашачыларны чын-чынлап дулкынландыра, уйланырга, борчылырга мәҗбүр итә. Спектакльне театр тәнкыйтьчеләре дә, башка коллективларда эшләүче режиссерлар да яратып карыйлар.

1939 елда куелган «Тукай» драмасы Ш. Сарымсаковның үз иҗат биографиясе өчен генә түгел, хәтта бөтен татар театр сәнгате өчен дә этап булып саналырга хаклы. Ә. Фәйзи тарафыннан язылып, халкыбызның сөекле шагыйре образын сәхнәгә беренче кат чыгарган бу әсәрне режиссер Тукай тормышына һәм иҗатына караган күп санлы тарихи, этнографик материалларга таянып эшли. Шуңа күрә дә үзәгендә И. Гафуров, Камал III кебек танылган артистлар иҗат иткән Тукай образы драмада тарихи дөреслек белән югары поэзияне берләштерә, алга таба да шушы юнәлештәге эзләнүләргә юл ача.

1941 ел башыннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Мәскәүдә узачак татар сәнгате декадасына әзерлек эшләре башлана. Ш. Сарымсаковка Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасын сәхнәләштерү бурычы йөкләнә. Ул елларда театр тәнкыйте өлкәсендә актив эшләгән Г. Кутуй, шул уңай белән язган мәкаләсендә, Ш. Сарымсаков иҗатының кайбер үзенчәлекле якларына туктала. «Ташкыннар» спектаклен сәхнәгә режиссер Ш. Сарымсаков иптәш куя,— дип яза ул.— Театр культурасын яхшы үзләштергән һәм хәзер үзенең иҗат үсешен дәвам итеп барган үзенчәлекле бу иптәшнең режиссерлык хезмәтләрен без берничә спектакльдә күреп үттек инде. Тамашачылар арасында популярлык казанган «Шәмсекамәр» һәм «Тукай» шикелле постановкалар — Ш. Сарымсаков хезмәте. Татар тормышын белү, авторның пьесадагы идеясен геройларның эчке кичерешләре аша тирәнәйтеп бирү, артистлар иҗатына киң юл ачу һәм шуны яхшы уйналган ансамбльдә, совет художнигы буларак, бер идеяга юнәлтү — менә болар Татар дәүләт академия театрында Ш. Сарымсаков өчен иң характерлы яклар». («Кызыл Татарстан», 1941, 18 май).

Бөек Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соң Ш. Сарымсаков иҗатында туган ил, туган җирне саклау, халкыбызның рухи байлыгын, батырлыгын чагылдыру, аның каһарман уллары һәм кызларының героик язмышын сурәтләү темасы мөһим урын алып тора. Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар», «Ялкын», «Изге амәнәт», К. Симоновның «Рус кешеләре», «Ят күләгә» һ. б. әсәрләр буенча куелган спектакльләр ватан өчен җаннарын да кызганмый сугышканнарга мәдхия булып яңгырый. Батырлыкны, ил саулыгы өчен зур эшләрне, нинди дә югары катлау кешеләре түгел, ә гади эшчеләр, хезмәткәрләр, колхозчылар башкара. Ш. Сарымсаковның бу чордагы күп кенә спектакльләре әнә шул төп фикерне раслый, шуның аркылы гади кешеләрне зур эшләргә рухландыра.

1945 елның язында, Россия федерациясе Совнаркомы карары белән, автономия республика һәм өлкәләрдә милли театрлар смотры уздырыла. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры смотрда В. Шекспирның «Король Лир», А. Островскийның «Яшенле яңгыр», М. Әмирнең «Миңлекамал», Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр күрсәтә. Соңгы пьесаны режиссер Ш. Сарымсаков сәхнәләштерә. Смотр комиссиясе уен стихиясе ярылып яткан, җиңел, динамикага бай, үткен сатирик комедия тудырган режиссерның эшенә аеруча зур бәя бирә. «Совет сәнгате» газетасында күренекле театр тәнкыйтьчесе И. Крути спектакльне «ачык фикерле, тирән мәгънәле милли тамаша» дип билгеләп үтә.

Ачык фикер, тирән фәлсәфи мәгънә, югары гражданлык хисе Ш. Сарымсаков иҗат иткән «Мылтыклы кеше» спектакленә дә хас. 1947 елда Н. Погодин пьесасы буенча эшләнгән бу спектакль татар театр ленинианасын ачып җибәрә. Режиссер тулы, бербөтен актерлар ансамблe тудыруга ирешә.

Кырыгынчы елларның икенче яртысында һәм илленче еллар башында Ш. Сарымсаков иҗатында рус һәм милли классик драматургия үрнәкләренә игътибар артуы күзәтелә. М. Горькийның «Варварлар» (1946), «Соңгылар» (1952), Н. Гогольнең «Ревизор» (1949), Г. Камалның «Бәхетсез егет» (1954) әсәрләре инде шактый бай тәҗрибә туплаган, иҗатының үрләренә якынлашып килгән режиссердан да зур көч, энергия сорый.

Илленче еллар уртасыннан илебез сәнгатендә яңарыш чоры башлана. Утызынчы елларда репрессиягә эләккән күп кенә әдәбият әһелләренең иҗади мирасы, ниһаять, халкыбызга кире кайтарыла. Шушы чорда Ш. Сарымсаков театр тарихы битләреннән умырып алынган сәхифәләрне барлау эшенә беренчеләрдән булып тотына. Кыска гына вакыт эчендә ул сәхнәләштергән «Зәңгәр шәл» (1956), «Җилкәнсезләр» (1958), «Таһир-Зөһрә» (1959) әсәрләре традицияләрне яңарту гына түгел, бәлки К. Тинчурин, Ф. Бурнаш кебек хаксызга гаепләнгәннәрнең саф исемен кайтару, озак еллардан соң хаклык һәм дөреслек тантанасы булып яңгырый.

1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырыла. Баш режиссер Ш. Сарымсаков җитәкләгән Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры декадада В. Шекспирның «Король Лир», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Зифа», М. Әмирнең «Миңлекамал», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар», К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» пьесалары буенча куелган спектакльләр белән катнаша. Декададан соң башкала театр белгечләре тарафыннан уздырылган сөйләшүдә аеруча уңышлы әсәрләр рәтендә Ш. Сарымсаков сәхнәләштергән «Зәңгәр шәл», «Ташкыннар» спектакльләре дә атала. Шул ук 1957 елда Ш. Сарымсаковка РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме би-

релү баш режиссерның декаданы хәзерләү һәм уздырудагы хезмәтләрен тәкъдир итү булып тора.

Декададан соң бер ел вакыт үткәч, Ш. Сарымсаковка, художник Ә. Тумашев, артистлар Х. Әбҗәлилов, Ф. Кульбарисов, А. Хәйруллина белән бергә, К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» әсәрен сәхнәгә куйган өчен республикада беренчеләрдән булып Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге бирелә. Олы драматургның бу үлмәс сатирик комедиясе образлары режиссер һәм башкаручы артистлар ихтыяры белән тарихи анықлык, социаль тирәнлек алалар.

Театрда эшләү дәверендә аның тарафыннан барлыгы җитмешкә якын әсәр сәхнәләштерелә.

Ш. Сарымсаков иҗатының тагын бер зур тармагы — театрларыбызга яңа алмаш әзерләүдәге эшчәнлек. 1945 елдан алып ул Казан дәүләт консерваториясенең опера классында, Театр училищесында, Казан дәүләт мәдәният институтында актерлык осталыгы һәм режиссура дәресләрен алып бара. Аның шәкертләре арасында СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, ТССРның һәм РСФСРның халык артисты В. Аполлонов, ТССРның халык һәм РСФСРның атказанган артисты И. Ишбүләков, Ленинград консерваториясе профессоры Г. Абросимова һәм башкалар бар. Казан дәүләт мәдәният институтында егерме ел дәвамында тәрбияләп чыгарган йөзләгән мәдәният хезмәткәре Татарстанда гына түгел, илебезнең башка бик күп төбәкләрендә халыкка хезмәт итә.

Халкыбызның талантлы улы Ширьяздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаковка 80 яшь тулды. Юбилярга озын гомер, нықлы сәламәтлек телибез.

**Гали АРСЛАНОВ,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

# БЕР КАНАТЫ ҖЫР ИДЕ

Бакый Урманче үзенең күпкырлы таланты белән сәнгатьнең барлык төрләрендә диярлек, шул исәптән музыка өлкәсендә дә лаеклы урын алып тора иде. Аның шәхесе гасыр башының революцион чорында, ягъни татар сәнгатенең «яңарыш дәвере» кичергән чагында формалашты. Бу нисбәттән иҗатчы табигатенең эчке сафлыгын, бөтенлеген, халык сәнгате белән тирән, табигый бәйланышларында да онытырга ярамый. Аның нәкъ шул сыйфатлары милли мәдәният байлыгын ишәйтүдә бөтен тулылыгы белән ачылды.

Без бүген Бакый аганың музыкаль сәләте турында сөйлибез. Музыка өлкәсендә ат уйнатырга бөтен мөмкинлекләре булса да, ул җырчы да, музыкант та булып китмәгән. Табигать аңа яхшы музыкаль сәләт, көчле матур тавыш биргән. Аның тышкы кыяфәте дә сәхнә җырчысы өчен килешле иде. Ул яшьтән үк музыканы бик ярата, тамашачылар алдында җырлап уңыш казана. Сынлы сәнгатьне үзенең төп эше итеп сайлагач та ул музыкадан аерылмый, аны гомерлек юлдашы итеп йөртә.

Бакый аганың музыкаль сәләте кечкенәдән үк беленә. Ул әбисеннән җырлар өйрәнә, осталардан өйрәнеп, урман өрәнгесеннән үзенә скрипка ясый һәм күңеленә хуш килгән көйләрне уйный. 1914—29 елларда Урал, Донбасс якларында, Глазов, Мәскәү һәм Казанда булганда скрипканы һаман үзе белән йөртә. Хәтта аның үзебезнең Тәтештә «оркестр» оештырып йөргәнен дә хәтерләүчеләр бар. Аның остаханәсендә танылган оста Иттаки Халитов ясап бүләк иткән скрипка бүген дә саклана.

Бакый ага туксан яшьне тутыргач та җырлады. Өйдә һәм кунак мәҗлесләрендә генә түгел, зур залларда җырлаганда да аның тавышы иркен яңгырый, көчле, зур диапазонлы югалтмый иде.

Җыр осталыгына аны махсус өйрәтүче булмаган. Бу гүзәл байлык аңа табигатьнең үзе тарафыннан мул итеп бирелгән. Шул ук вакытта, башка өлкәләрдәге эшчәнлегенә дә хас булганча, ул осталыкта камиллеккә омтыла. Мәскәүдә яшәү чорында аның музыкаль осталыгын үстерүдә композитор Прозоровскийның, музыка профессоры Клыков, итальян дирижеры Молла һ. б. ның ярдәме зур була. Урманче белән концертларда катнашып, алар аның тавышы гаҗәеп аһәңле булуын, итальянча куелуга якын икәнен билгелиләр.

Татар музыка әһелләре дә рәссамнең бу сәләтен югары бәялиләр. С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, Ф. Туишев, Н. Даутов, С. Садыковалар белән ул Мәскәүдә чагында якыннан таныш була. Казанга кайткач, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, Р. Яхин һ. б. композиторлар белән якыннан аралаша, иҗатлары белән кызыксына, аларга борынгы җырларны җырлый.

Җырчы булып китмәсә дә, сәнгатенең бу өлкәсенә ул сизелерлек өлеш кертте дияргә була. Әле татар профессиональ сәнгате туып кына килгәндә, шундый җырчының булуы милли мәдәниятта сизелми калмый. Татар халкының бай орнаментлы көйләрен ачык, аһәңле тавыш белән башкаруы — аларны әкрен генә, ягъни Г. Тукай билгеләгәнчә, «мыек астыннан» гына җырларга мөмкин дигән фикерне юкка чыгара. Егерменче елларда Мәскәүнең Көнчыгыш телләре институтында һәм Әсәдуллаев йортында узган кичәләрдә, Казан сәхнәләрендә җырлавы буенча, шул чор кешеләре Бакый аганы яхшы җырчы дип беләләр.

Музыкаль фольклорны тирәннән белүе — аны халык җырларының югары этик һәм эстетик сафлыгын саклаучы уникаль башкаручы итеп таныта. Беркайчан тыңлаучылар зәвыгына яраклашырга тырышмый. Гел үзенчә, үзе яратканча, бөтен күңелен салып, җырда ул яшәүнең асыл ягын бәян итә. Гүя ул җырламый, җыр үзенең моңы, тарихы, эчтәлеге белән аның күңеленнән агып чыга. Б. Урманче башкарган һәр җырда югары идеаллар сурәтләнә. Борынгы озын көйләрне башкаруында гаҗәеп төзеклек, көйнең архитектоник тәмамланышы, ритмик ысуллар, бизәкләрне сайлауда җитдилек һәм җиренә җиткерү сизелеп тора. Аның импровизация осталыгына да кабатланмас милли үзенчәлек, характерлылык һәм көйнең орнаменталь байлыгын ассызымлау хас.

Бакый ага Урманчеда, хәзерге җырчыларда булмаган тагын бер сыйфат — җыр сүзләренә зур игътибар бар иде. Бу — дикциянең кристаллдай сафлыгы гына түгел, ә һәр музыкаль фразаның сүзләрдә бирелгән бөтен мәгънә нечкәлеген тыңлаучы күңеленә җиткерү, ягъни җырны төгәл интерпретацияләү осталыгы.

Күренекле рәссамның музыкаль сәләте аның сынлы сәнгатендә дә чагыла. Шуңа күрә аның һәр ясаган сынына, портретына кабатланмас яңгыраш, халык теле белән әйтсәк, моң салынган. «Сөембикә», «Сагыш», «Нәфисә», «Студентка», «Язгы моңнар», «Флейтачы» кебек әсәрләре махсус шул моң, музыка авазларын ташта, агачта, киндердә сынландыруга багышланган диярлек. Яисә Сәйдәш, Җиһанов, Яруллин портретларына бер күз салуга ук музыка яңгырап киткәндәй була. Алар портретларында тышкы охшашлык камиллегеннән башка, көчле рухлы музыка әһелләренең гомумиләштерелгән образын күрәсең.

Г. Гаҗибәковның мәшһүр «Аршин мал алан»ы 1950 елда Алма-Ата опера театрында Б. Урманченың уңышлы декорацияләре белән куелуы совет сәхнәсендә сизелерлек вакыйга булган иде. Үзебезнең сәхнәдә ни өчендер Бакый аганың бу төр осталыгыннан тиешенчә файдалана алмадык. Шулай ук аның остаханәсендә калын папкалар эчендә Татар филармониясе өчен 1938 елдан бирле ясала килгән һәм тарихи кыйммәте әйтеп бетергесез булган йөзләрчә костюм эскизлары хәзинә булып ята.

Бакый аганың үзе язган шигырьләрендә дә иң әүвәл музыкаль аһәң ишетелә. Татар музыкасында бик сирәк булган гимник оданың композитор Р. Еникеев тарафыннан Б. Урманче сүзләренә язылуы да очраклы хәл түгелдер.

*Күңел багладым эшем уңасына,*
*Тәвәккәл иттем кодрәт иясенә.*
*Өметем камил, ышанычым нык*
*Бу фәкыйрьгә бәхет иңәсенә.*

Ренат Еникеевның Бакый ага Урманчыга багышлап язган скрипка һәм фортепьяно өчен романсында да шул ук рух сизелә.

Урманченың «Шүрәле» темасына дистәләрчә график рәсемнәр, агачтан композицияләр ясаганы билгеле. Аның шушы тема буенча сәхнә өчен дә эш алып баруы игътибарга лаек. Эш шунда ки, ул Ф. Яруллин музыкасын яраткан, югары бәяләгән хәлдә, әсәрнең либреттосы, сәхнәгә куелышы белән баштан ук килешмәгән иде. «Пәри башка, җен башка», дигәндәй, шүрәленең бу балетта, башка халыклар иҗатына хас булганча, явыз көчләрне гәүдәләндергән трактовкасын ул өнәп бетерми. Г. Тукай үзе дә шүрәлегә кире карамый, аны «урман сарыгы» дип кенә атый, үзенең күп кенә әсәрләрен «Шүрәле» псевдонимы белән бастыра. Бакый ага иҗатында да әлеге зат гөлләр, күбәләкләр белән кәефләнүче, кеше белән дә шаярып кына кети-кети уйнап алырга уйлаган ахмаграк бер урман иркәсе. Шүрәлегә багышланган акварельләрендәге йомшак төсләр балкышы композиторларны яңадан-яңа әсәрләргә рухландыра. Бакый аганың иксез-чиксез иҗат хәзинәсе төбендә шүрәленең халык музыкасы һәм риваятьләре рухында эшләнгән сәхнә варианты да ятуы тагы бер әһәмиятле факт.

Рәссам Бакый Урманче иҗатының музыкаль якларын махсус тикшеренүләр — киләчәктә музыка фәнен генә түгел, тулаем сәнгатебезне дә баетыр иде.

**ШАМИЛ МОНАСЫЙПОВ,**
сәнгать фәннәре кандидаты,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

**Нурмөхәммәт Хисамов,**
филология фәннәре кандидаты

# ЯҢАЧА ФИКЕРЛӘҮ ҺӘМ УРТА ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮНЕҢ ПРИНЦИПИАЛЬ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Яңача фикерләү безнең сәясәт өлкәсендәге, иҗтимагый аң һәм, гомумән, идеология системасындагы үзгәртеп коруга кагылган таләп кенә булмыйча, тарихка, фәлсәфи һәм әдәби мираска мөнәсәбәтебезне дә билгеле торган универсаль императив ул. Аерым алганда, урта гасыр әдәбиятын өйрәнү ул ничек чагыла? Борынгы әдәбиятны анализлау һәм бәяләү принципларыбызда без нәрсәдән баш тартырга тиешбез? Нинди яңа таләпләр алга килеп баса?

Кызганыч ки, урта гасырның гаять камил әдәби үрнәкләреннән торган мирас ул чаклы киң колач белән һәм тирән итеп өйрәнелде дип әйтә алмыйбыз әле. Моңарчы эш фактологик, текстологик югарылыкта, аерым авторларны исә монографик рәвештә өйрәнүдән гыйбарәт. Азмы-күпме тәҗрибә тупланган, таянып эш итәр өчен күпмедер нигез салынган. Иске караш, догматик стереотиплар тулаем урта гасыр мирасын кимсетүдә, аның әһәмиятен үткәнне төшенүдәге мәгълүм бер чыганак буларак кына тануда, аның идея-фәлсәфи кыйммәтен асылда инкяр итүдә чагыла иде. Күп кенә әсәрләрнең фәлсәфи һәм сәнгатьчәлек җәһәтеннән бүген дә буй җитмәс югарылыкта торуын әдәбият фәне башка да китерә алмый иде. Дәүләт күзлегеннән исә бу эшләргә акча әрәм итү кебек кенә карала иде.

Яңача фикерләүнең чагылышы бирeдә барыннан да элек урта гасыр әдәбиятының әһәмиятын яңача бәяләүдә күренә. Ягъни, урта гасыр әдәби мирасы бүгенге кешенең сәламәт әхлагын тәрбияләүдә, рухани камиллеге өчен көрәштә, аны кешелекле омтылышлар белән баетуда зарури һәм алыштыргысыз чара буларак бәяләнә. Мәсьәлә теоретик яктан болай куелмаса да, гамәли адымнарның характеры шуны күрсәтә.

Урта гасыр әдәбиятын тикшерүдә яңача фикерләү төп өч өлкәдә чагылырга тиеш:

1) Әдәбиятның фәлсәфи-идеологик эчтәлеген яктыртуда;
2) Әдәбиятның социаль эчтәлеген яктыртуда;
3) Әдәбиятның сәнгатьчә эшләнешен яктыртуда.

1. Идеологик тоталитаризм шартларында иң читен өлкә — беренчесе иде. Бу яктан себереп түгү өчен иң кулай, яклавы читен булган әдәби дәвер — урта гасыр. Чөнки аның хаким идеологиясе — дин. Тикшеренүче икмәксез калмас өчен, асылда исә халкын, замандашларын рухани икмәксез калдырмас өчен, ул дәвер әдәбиятында дингә каршы мотивлар эзләргә мәҗбүр. Бу җәһәттән иң кулай, иң отышлы шагыйрь — Гомәр Хәйям. Чөнки аның шигырьләре илаһият белән тәвәккәл тартыштан тора. «Син минем кувшинымны аударып ваттың, мәемне түктең,— ди аның каһарманы.— Мин исерек булсам, син бит аек, сиңа килешәме соң мондый юньсезлек?!» Һәм менә ислам диненең мәҗүсилектән өстенлеген раслаучы «Кыйссаи Йосыф»тан да автор шундый «мотивлар» таба. Йосыфның чак кына үзбаш хәрәкәтен «Аллага каршы бунт», ди. Әсәр каһарманның «Алла пәйгамбәре» икәнен оныта. Ти-шеренүченең иң мактаулы хезмәте һәр әсәрдән шушындый бунт эзләүгә кайтып кала.

Хезмәтләрне рус телендә чыгару өчен бу бигрәк тә кирәк була. Аларча, «Иң эшәке дин» ислам саналгач, урта гасыр авторының Исламны тәнкыйтьләве, Ислам белән каршылыкка керүе нәширләр өчен иң кыйммәтле табыш була. Андый каршылыкны тикшерүче күбесенчә уйлап чыгара. Хәлбуки, урта гасыр мөселман авторы ислам диненең бернинди авыр басымын күрми, үзенең дөньяга карашын, тормышны аңлавын тулысынча шушы идеологиягә кора. Бу аңа замандашлары әхлагына, аларның үзара мөнәсәбәтенә, эш-гамәлләренә үтемле итеп тәэсир ясарга мөмкинлек бирә. Тикшеренүче еш кына бу хакыйкатьне дә таный, ләкин шуннан бөтенләй акылга ятышмаган искәрмә чыгара. Янәсе, шагыйрь шулай дингә ышанган халыкка идеяләрен дини кабыкка төреп бирмәсә, замандашлары кабул итмәс иде, аннан да бигрәк динчеләр аңа юл куймас иде. Тел төбеннән шул аңлашыла: шагыйрь үзе, һичшиксез, безнең заман атеистларының лекцияләрен тыңлап урта гасырга безнең оешмалардан җибәрелгән агитатор. Ул шартларда конспирация ядәмендә эш итәргә мәҗбүр. Бу схема Тукай турындагы хезмәтләргәчә сузыла. Әмма мондый методологиядә иң бозык алшарт шунда ки, сәнгатькәрнең шигъри иҗатка һәм аның адресаты булган халкына мөнәсәбәте үтә әхлаксыз бер күренеш булып баса. Шигъриятнең асыл сыйфаты — ихласлык. Халкының улы һәм җырчысы булган шагыйрь аның белән беркайчан да битлек киеп уйнамый. Кыскасы, бу методологиянең асылында узган унъеллыкларыбызга хас и-ейөзлелек идеологиясе ята.

Яңача фикерләү урта гасыр иҗтимагый һәм әдәби чынбарлыгын объектив итеп, ничек булганга яктырту булырга тиеш. Дини философия тирән һәм, тормышның төрле ягын исәпкә алып, күпкырлы итеп эшләнгән булган. Ислам, бар да Алла кушканча эшләнә, дисә дә, дин гыйлеме тәкъдир кысаларында бәндә үз гамәлен ирекле кыла, дип өйрәтә. Урта гасыр әсәренең сюжет борылышларында көтелмәгән яңалыклар, каһарманнарның эш-хәрәкәтендә төрлелек менә шуннан килеп чыга.

Шагыйрь дин өйрәтүендәге гомумкешелек идеалларын аның җирдәге тормышын камил итеп коруга юнәлтә, аны ахирәткә рухани хәзерләгәндә дә җирдәге тормышын саф вөҗдан белән узарга өйрәтә. Болар кай ягы белән безгә идеологик дошман була ала?

Без урта гасыр әдәбиятында күтәрелгән гаделлек, мәрхәмәт-шәфкать идеяләрен әдипнең тарихи һәм сыйнфый чикләнгән булуыннан килеп чыга һәм моның прогрессив әһәмияте урта гасыр белән төкәнә, дип аңлата идек. Хәлбуки, мәрхәмәт һәм шәфкать, игелек идеясе сыйнфыйлыктан өстен гомумкешелек әхлагы казанышы булып хисаплана. Аның гуманистик әһәмияте дә, урта гасыр белән генә чикләнмичә, хәзерге чор өчен дә үзенең көчен саклый. Конкрет әсәрләрдә аларның тәэсир һәм сәнгатьчә ышандыру куәсе хәзерге укучы өчен артык садә һәм беркатлы булырга мөмкин. Бигрәк тә дидактик әсәрләрдә. Ансы икенче мәсьәлә.

2. Әдәбиятның социаль эчтәлеген яктыртуда яңача фикерләү нәрсәдә күренергә тиеш? Барыннан да элек, каһарманнар даирәсен шәрехләүдә. Бу нәрсә дигән сүз соң? Мәгълүм ки, урта гасырның эпик әсәрләре генә түгел, «Мәхәббәтнамә» кебек асылда лирик әсәрләрнең дә каһарманнары — патшалар, бәкләр, хөкемдарлар. Аларда мәгълүм чорның тарихи шәхесе алынып, ул макталса, ә макталган зат исә Алтын Урда кебек империя хөкемдары да булса, шагыйрь бөтенләй демократия дошманы булып күз алдына килә. Тикшеренүче, шагыйрьнең абруен коткару өчен, ул хөкемдарга бәйле булганга, аны мактый, бу бары алым гына, асылда ул хөкемдарга үгетләр бирә, өйрәтә, аның үз-үзен тотышын төзәтергә омтыла,» — дип тезеп китә. Бу — өлешчә дөрес. Әмма шагыйрь хәтта Харәзми кебек, бәк мәҗлесендә аны мактап шигырь сөйләсә дә, үзенең ризыгын аклар өчен яки әдәби алым буларак кына мондый темага һәм каһарманга мөрәҗәгать итми, бәлки үзенең олы иҗат бурычын тормышка ашыруда, ягъни, кеше идеалын раслауда теләсә игелек кылу, теләсә явызлык кылу мөмкинлеге зур булган шәхескә мөрәҗәгать итә. Бу дөньядагы мәгълүм үрнәкләрдә дәлиллерәк һәм үтемлерәк чишелә ала. Фольклор тәҗрибәсе дә моңа этәргеч бирә. Әсәр каһарманы патша булу шагыйрьнең апологетлыгы гына түгел, авторлар моны әсәр саен раслыйлар. Харәзми мәсәлән:

*Кылыч тик тел берлә тоттым җиһанны,*
*Канәгать милке эчрә падишаһ мин.*

. . . . . . . . . . . . . .

*Ничә хәшмәтле солтан булса булсын,*
*Әйтмән мал өчен мәдх вә сәна мин,— ди*

Котб үзенең каһарманы Хөсрәүдә күп кимчелекләр күрү, аларны Шириннең мәхәббәте ярдәмендә төзәтә. Мәхәббәт нинди генә юлдан язган хөкемдарны да камил әхлакка юнәлтә ала, ди. Хөсам Кятиб исә каһарманың аз гына гаделсезлеге өчен дә тамуг газабына сала. Кыскасы, мондый күренешләр шагыйрьнең гомуми эстетик принциплары яссылыгында гына төгәл аңлатыла ала.

3. Сәнгатьчә эшләнешне тикшергәндә яңача фикерләү ни дигән сүз соң? Мин бер генә моментны: урта гасыр төрки поэзиясендә шигырь төзелешен алам. Мәгълүм булганча, ул гарәп-фарсы системасы гарузга нигезләнгән. Безнең читтән тәэсир дигән нәрсәне яратмаучы патриотларыбыз, дөресрәге, гарәптән алынган әйберне күрмәскә тырышучы коллегаларыбыз: «гаруз төркиләрнең үзендә булган, аның нигезе төрки телдә үк бар», димәкчеләр. Әмма бу дөрес түгел. Урта гасыр төрки шигыре ул шактый көчләнгән төрки синтаксис җимеше. Мәсәлән, әзербайҗаннар, гаруз — халык синтаксисына зур зыян китерде, диләр. Безнең төрки шигырьдә ул иярченле кушма җөмләләр бирелешендә чагыла. Вакытмы, урынмы, рәвешме, шарт җөмлә — барысы да бер кисәкчә (ки) белән бирелә һ. б. Әмма урта гасыр төрки шигъри яте шушы гаруз кануннары нигезендә шигърилекнең искиткеч бай чараларын эшләгән. Шулар бер бөтен буларак өйрәнелгәндә генә шигъриятнең тулы байлыгын күреп була. Безнең транскрипция дә моны истә тотарга тиеш. Ягъни сүз бирелеше, кушымча бирелеше итеп түгел, транскрипциягә шигырь бирелеше итеп карарга кирәк. Текстны аваз, морфологик формалар яңгырашы буларак түгел, шигъри яңгыраш тәгъбир итәрлек эшләргә кирәк. Бездә хәзергә иң зур куркыныч — урта гасыр гаруз текстын хәзерге татар теле күренеше буларак яңгыратуда.

*Татарстан Республикасы язучыларының*
*1991 ел, 15 мартта булган*
*чираттан тыш съездында расланды.*

# Татарстан республикасы язучылар берлеге
# УСТАВЫ

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге — Татарстан язучыларын демократик нигездә берләштерүче һәм мөстәкыйль юридик хокукка ия җәмәгать оешмасы.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, татар әдәбиятының күпгасырлык гуманистик традицияләрен дәвам итеп, әдәбиятны үстерү һәм аның халык тормышындагы ролен көчәйтү максатына хезмәт итә. Иҗат иреге, төрле карашларның һәм инануларның бәйсезлеге, язучының халык алдындагы җаваплылыгы әдәбиятны үстерүнең бәхәссез шартлары булып тора. Бер милләтне икенчесеннән өстен кую, рәнҗетү катгый тыела.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Мөстәкыйль иҗат оешмасы буларак, килешү нигезендә СССР Язучылар берлегенә керә; башка республикалар һәм чит ил язучылары оешмалары, мәдәният хәрәкәтләре белән элемтә урнаштыра; СССР Язучылар берлегенең халыкара эшчәнлегендә актив катнаша.

Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең СССР фондына килешү нигезендә керүче үз Әдәби фонды бар. Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары СССР Әдәби фонды тарафыннан язучыларга күрсәтелә торган һәртөрле матди ярдәм алуга һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга хокуклы.

## Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең төп максатлары һәм бурычлары:

— камил әсәрләр иҗат итүгә булышлык күрсәтү;

— язучының иҗади, гражданлык, сәяси, икътисади, социаль хокукларын яклау; язучының намусына һәм абруена кер тидермичә саклау;

— язучының иҗат шартларын яхшырту һәм хезмәтенә түләү өчен закон нигезендә эш йөртү;

— Республиканың һәм бөтен илнең рухи һәм иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнашу;

— һәр халыкның рухи мирасына сакчыл булу;

— яшь язучыларга, өлкән әдипләргә ярдәм күрсәтү, мәрхүм язучыларның мирасын һәм аларның варислары хокуклары турында кайгырту;

— Татарстан Республикасындагы, илдәге иҗат оешмалары, җәмгыятьләр һәм ассоциацияләр белән иҗади дуслыкны ныгыту; чит илләрдәге язучылар оешмалары, мәдәният эшлеклеләре белән элемтәләр урнаштыру.

## Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, аларның хокуклары һәм бурычлары

Татарстан Республикасы Язучылар берлегенә әгъза итеп Татарстанда яшәүче һәм әдәбиятның берәр өлкәсендә — проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть, әдәби тәрҗемә өлкәсендә — актив эшләүче, шулай ук Республикадан читтә яшәп тә татар телендә яки башка берәр телдә язып, татар әдәбиятын үстерүгә мөһим өлеш керткән әдәбиятчы кабул ителә ала.

Язучылар берлегенә кабул итү язучылар съездында яки гомуми җыелышында сайланган Кабул итү коллегиясе тарафыннан башкарыла; коллегия үзенең эшен язучылар съездында расланган Кабул итү Положениесе нигезендә, профессиональ таләпләр югарылыгында алып бара. Коллегиянең яңа әгъза кабул итү турындагы карары Идарә утырышында раслана.

Язучылар берлегенә кабул ителүчегә әгъзалык билеты бирелә. Язучылар берлеге әгъзасы керү һәм еллык взнослар түли. Взносларның күләмен Идарә билгели.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы Берлектән чыгу һәм башка язучылар оешмасына керү хокукына ия.

СССР Язучылар берлегенә кергән һәм икенче бер иҗат оешмасында торучы да Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы була ала.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы Язучылар берлегенең җитәкче органнарына сайлый һәм сайлана ала, шулай ук үзе исәптә торган иҗат оешмасына кагылышлы теләсә нинди мәсьәләне тикшерүдә катнашырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, үзенең иҗат мәнфәгатьләреннән чыгып, иҗат лабораториясе яки семинар оештырып, әдәби алмаш хәзерләүгә өлеш кертә ала.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы үзенең матди-көнкүреш шартларын яхшырту өчен Язучылар берлегенең һәм Әдәби фондның барлык мөмкинлекләреннән файдалана ала.

Татарстан Республикасы язучылары съезды яки гомуми җыелышы шушы Уставны бозган яки озак еллар дәверендә профессиональ эшсезлек күрсәткән язучыны (авырып яисә картаеп эшли алмау исәпкә керми) берлектән чыгару хокукына ия.

## Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең төзелеше

Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең иң югары органы — язучылар съезды. Съезд 5 елга кимендә бер тапкыр чакырыла. Анда Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең һәр әгъзасы хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән катнаша.

Кичектергесез мәсьәләләрне хәл итү өчен чираттан тыш съезд яки гомуми җыелышлар уздырырга мөмкин. Чираттагы яки чираттан тыш съездларны, шулай ук гомуми җыелышны уздыру турындагы карарны Язучылар берлеге идарәсе кабул итә.

Съездлар арасында Язучылар берлеге идарәсе җитәкче орган булып тора. Идарәгә ничә кеше сайлауны съезд хәл итә. Идарә съездда яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

Идарә рәисе съездда яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана; рәис итеп бер үк язучыны рәттән ике генә мәртәбә сайларга мөмкин.

Идарә рәисе урынбасары съездда яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

Язучылар берлеге секретарьларын, рәис тәкъдиме буенча, идарә раслый.

Матур әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе Язучылар берлеге идарәсендә раслана.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге оешмаларының җитәкчеләре шул оешма әгъзаларының гомуми җыелышларында яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана, һәм алар Язучылар берлеге идарәсендә раслана.

Язучылар съезды яшерен тавыш бирү юлы белән Контроль-ревизия комиссиясен, аның рәисен сайлый. Комиссиягә ничә кеше сайлануын съезд хәл итә.

## Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең юридик хокуклары

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге юридик шәхес булып тора. Үзенең эшчәнлеген шуннан чыккан хокуклары, бурычлары нигезендә һәм гамәлдәге законнарга туры китереп башкара.

Язучылар берлегенең хокуклары:

— үзенең нәшриятын, газета һәм журналларын, клуб һәм китапханәләрен, китап кибетләрен булдыру, шулай ук иҗат йортлары, санаторийлар төзү, кооператив һәм уртак предприятиеләр оештыру;

— әдәби мирас буенча эш алып бару, архив материалларын саклау һәм аларны матбугатта чыгару;

— ил күләмендә, шулай ук чит илләрдә барлык дәүләт һәм җәмәгать оешмалары каршында язучыларның мәнфәгатьләрен яклау;

— кредиттан файдалану, судларда һәм дәүләт арбитражларында дәгъва белдерү яисә белдерелгән дәгъва буенча уңаеннан җавап тоту;

— халыкара элементлар урнаштыру һәм тышкы икътисади эшчәнлектә катнашу.

Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең нәшрияты, газеталары, журналлары, шулай ук башка басмалары Язучылар берлегенең үз милке булып санала. Нәшрият директоры һәм барлык баш мөхәррирләр язучылар съездында яки гомуми җыелышында

сайлана. Язучылар берлегенең үз нәшриятыннан һәм көндәлек басмаларыннан алынган керем Язучылар берлеге милкәте булып тора, һәм ул язучыларның социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә һ. б. максатларга тотылырга мөмкин.

Әдәби фонд, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге карамагында булу белән бергә, СССР Әдәби фондына да керә. Җәмәгать, иганәт, хуҗалык оешмасының, ягъни Әдәби фондның Уставы язучылар съездында раслана. Әдәби фондка, гадәттә, Язучылар берлеге әгъзалары гына кабул ителә.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге средстволарын түбәндәгеләр тәшкил итә:

— керү һәм еллык взнослар;

— китап нәшрияты һәм көндәлек матбугат басмалары китергән керемнәр;

— Язучылар берлегенең мәдәни программасында, шулай ук Әдәби фондның иганәтлек эшчәнлегендә катнашырга теләк белдерүче учреждение, предприятие һәм җәмәгать оешмалары күчергән акча.

Әдәби фонд, милли әдәбиятыбызны үстерү максатын күздә тотып, иганәт исәбе булдыра.

Уставка язучылар съездында үзгәрешләр кертелергә мөмкин, ләкин моның өчен съездда катнашучыларның кимендә өчтән ике өлеше тавыш бирергә тиеш.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге съезд карары белән бетерелергә мөмкин, ләкин моның өчен Татарстан язучыларының кимендә өчтән ике өлеше тавыш бирергә тиеш.

*Татарстан Республикасы язучыларының*
*1991 ел, 15 мартта булган*
*чираттан тыш съездында расланды.*

# Татарстан республикасы әдәби фонды
# УСТАВЫ

Татарстан Республикасы Әдәби фонды — җәмәгать, иганәт, хуҗалык оешмасы — СССР Әдәби фондының тигез хокуклы әгъзасы булып тора.

## Татарстан Республикасы Әдәби фондының төп максатлары һәм бурычлары

Татарстан Республикасы Әдәби фондының төп бурычы — Язучылар берлеге Уставы нигезендә Әдәби фонд әгъзаларының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту, яшь язучыларга ярдәм итү.

Әдәби фонд үзенең эшчәнлегендә:

— Әдәби фонд әгъзаларына иҗат мөмкинлекләре тудыру йөзеннән пособие, кире кайтару шарты белән акча (ссуда), иҗат командировкалары бирә, аерым очракларда стипендия түли;

— Әдәби фонд әгъзалары хезмәткә вакытлыча сәләтен югалткан, мохтаҗлык кичергән чакларда аларга матди ярдәм күрсәтә;

— тиешле очракларда язучы гаиләләренә, әдәбиятта өметле эшләүче яшьләргә ярдәм итә;

— Әдәби фонд әгъзаларына һәм аларның гаиләләренә медицина ярдәме күрсәтүне һәм курорт-санаторийда дәвалануны оештыра;

— Әдәби фонд әгъзаларына һәм аларның гаиләләренә мәдәни-көнкүреш хезмәте күрсәтә; язучыларның яшәү шартларын яхшырту буенча эш алып бара;

— вафат булган язучыларның исемнәрен мәңгеләштерү, аларның иҗатына кагылышлы булган истәлекле урыннарны һәм әдәби һәйкәлләрне саклау буенча чаралар күрә.

Әдәби фондның хокуклары:

— Әдәби фонд әгъзалары, аларның гаиләләре өчен санаторийлар, ял йортлары, иҗат йортлары, пансионатлар, дачалар, эшли алмаучы (картайган яки инвалид) язучылар өчен йортлар, балалар бакчалары һәм яслеләр, башка предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү һәм аларны тәртиптә тоту;

— Әдәби фонд мәнфәгатенә җавап бирүче производство һәм төзелеш оешмалары булдыру, төрле җәмәгать, дәүләт һәм кооператив предприятиеләрендә катнашу, шулай ук уртак предприятиеләр (шул исәптән чит ил фирмалары белән) оештыру, Әдәби фондның капиталын һәм төп средстволарын арттыру максатында илебездә һәм чит илләрдә китап кибетләре һәм аларның филиалларын ачу;

— Законда каралган тәртиптә редакция һәм нәшрият эшчәнлеге белән шөгыльләнү, әдәби журналлар, газеталар һәм башка басмалар чыгаруга булышлык итү;

— Әдәби фондның бүлекләрен раслау;

— Әдәби фонд әгъзаларының чит ил язучылары белән элемтәләрен киңәйтү максатында халыкара эшчәнлектә, чит илләрдә апарның ялын һәм эшен, шулай ук үзебездә чит илләрнең әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләренең ялын һәм эшен оештыруда катнашу.

Әдәби фонд:

— Илебезнең татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә, үз компетенциясе чикләрендә, эшчәнлеген җәелдерә;

— юридик шәхес хокукына ия — законда каралган барлык операцияләрне башкара ала; мөстәкыйль балансота тора; Әдәби фонд тарафыннан бирелгән ышаныч кәгазьләрен нотариаль раслау таләп ителми.

Әдәби фонд дирекциясе Казан шәһәрендә урнаша һәм аның «Татарстан Республикасы Әдәби фонды» дигән мөһере бар.

## Татарстан Республикасы Әдәби фонды әгъзалары

Татарстан республикасы Язучылар берлегенең керү һәм еллык взносларын түләүче әгъзасы Әдәби фонд әгъзасы булып тора.

Аерым очракларда, Язучылар берлеге идарәсе тәкъдиме белән, Язучылар берлегендә тормаган янсә чыгарылган профессиональ әдәбиятчы Әдәби фонд әгъзалыгына кабул ителергә мөмкин.

Уставны бозу Әдәби фондтан чыгаруга нигез була ала. Әдәби фондтан чыгару мәсьәләсен, Язучылар берлеге идарәсе карары нигезендә, Әдәби фонд идарәсе президиумы хәл итә. Әдәби фондтан чыгарылучыга керү һәм еллык взнослар акчасы кире кайтарылмый.

## Татарстан Республикасы Әдәби фондының идарә органнары

Әдәби фондның иң югары җитәкчелек органы — Әдәби фонд әгъзалары — Татарстан Республикасы язучыларының гомуми җыелышы.

Идарә, аның җәмәгатьчелек тәртибендә эшләүче рәисе һәм урынбасарлары Әдәби фонд әгъзалары — Татарстан Республикасы язучыларының гомуми җыелышында ачык яки яшерен тавыш бирү юлы белән 5 елга сайлана.

Гомуми җыелыш һәр елны кимендә бер тапкыр уздырыла. Җыелыш, ә ике җыелыш арасында Язучылар берлеге идарәсе, Әдәби фонд эшчәнлегендә иң әһәмиятле мәсьәләләр буенча үзенең карарларын кабул итә, бер еллык эш планын раслый, хуҗалык эшенең нәтиҗәләрен тикшерә.

Әдәби фонд идарәсенә гомуми җыелыш раслаган еллык план нигезендә төрле мәсьәләләрне хәл итү һәм Әдәби фондның дирекциясенә җитәкчелек вазифасы йөкләнә.

Язучылар берлеге һәм Әдәби фонд идарәләре чыгарган карарлар Әдәби фонд карамагындагы барлык оешма, учреждение, предприятие өчен мәҗбүри.

Әдәби фондның агымдагы хуҗалык эшләрен Әдәби фондның дирекциясе башкара.

Әдәби фондның директоры Әдәби фонд идарәсе рәисенең урынбасары булып санала.

Әдәби фонд директоры һәм аның урынбасарлары Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе булган берлектә раслана.

Әдәби фонд дирекциясе үзенең көндәлек эшендә шушы Уставка, ә Әдәби фонд әгъзаларына, аларның гаиләләренә матди-көнкүреш, медицина һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүдә Әдәби фонд идарәсе тарафыннан расланган инструкциягә, шулай ук Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм СССР Әдәби фонды идарәләренең карарларына таянып эш итә.

Әдәби фонд эшчәнлегенә ревизияне Язучылар берлегенең Контроль-ревизия комиссиясе үткәрә.

## Татарстан Республикасы Әдәби фондының акча средстволары

Әдәби фондның акча средстволарын түбәндәгеләр тәшкил итә:

— керү һәм еллык взнослар;

— билгеләнгән тәртиптә ВААП бүлекчәләре күчерә торган акча;

— Әдәби фонд карамагындагы предприятие һәм оешмаларның амортизация өчен түләгән акчасы;

— СССР Язучылар берлегенең нәшриятлар табышыннан күчерә торган акчасы;

— СССР Язучылар берлегенең махсус карарлар нигезендә күчерелә торган акча;

— Татарстан Республика Язучылар берлеге һәм Әдәби фонд идарәләре карамагында басмалар («Казан утлары», «Идел», «Салават күпере» журналлары һ. б.) биргән табыштан бүленә торган акча;

— Әдәби фонд һәм аның урыннардагы оешмалары алып бара торган производство һ. б. төрле эшчәнлегеннән, шулай ук кичә, концерт, күргәзмә һ. б. чаралардан алына торган керем;

— әдәби әсәрләрне матбугатта басып чыгарган яисә киң даирә алдында башкарган өчен авторларга тапшырырга дип махсус оешмалар тарафыннан җыелып та, аларга тапшыру вакыты чыккан яисә авторы ачыкланмаган гонорарлар;

— Иганәт, җәмәгать, кооператив, дәүләт предприятиеләре һәм оешмалары, шулай ук аерым кешеләр үз теләкләре белән Әдәби фонд ихтыяҗлары өчен күчергән акча.

### Татарстан Республикасы Әдәби фондын үзгәртү яки бетерү тәртибе

Әдәби фондны үзгәртү яисә бетерү мәсьәләсе гомуми җыелышта Әдәби фонд әгъзалары — Татарстан Республикасы язучыларының өчтән ике өлеше тавыш биргән очракта хәл ителә. Әдәби фонд бетерелгән очракта, бурычлар түләнеп беткәннән соң калган мал-мөлкәт Татарстан Республикасы Язучылар берлеге карамагына күчә.

*Татарстан Республикасы язучыларының*
*1991 ел, 15 мартта булган*
*чираттан тыш съездында расланды.*

## Татарстан республикасы язучылар берлегенә кабул итү һәм Татарстан республикасы язучылар берлеге идарәсенең кабул итү коллегиясе турында ПОЛОЖЕНИЕ

Язучылар берлегенә кабул итү өчен, язучының әдәби кыйммәте булган проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть һәм әдәби тәрҗемә әсәрләренең матбугатта чыгуы шарт булып тора.

Кабул итү коллегиясе язучылар съездында яки гомуми җыелышында ачык яисә яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана. Коллегиянең рәисе язучылар съездында яки гомуми җыелышында сайлана. Коллегиянең эш кәгазьләрен алып бару өчен Идарә раслаган сәркәтипнең коллегия әгъзасы булмавы да мөмкин.

Язучылар берлегенә әгъза булып керүче коллегиягә түбәндәге документларны тапшыра:

а) кулдан язылган гариза;

б) әдәби әсәрләр яки әдәби тәнкыйть хезмәтләре;

в) Язучылар берлегенең кимендә биш ел стажы булган өч әгъзасыннан рекомендацияләр;

г) язучыларның җирле оешмасы яки иҗат секциясенең күпчелек тавыш белән кабул ителгән үтенеч язуы.

Гаризадан тыш, һәр документ өчәр данәдә тапшырыла.

Коллегия әгъзаларының өчтән ике өлеше уңай тавыш биргән очракта кандидатура Язучылар берлегенә кабул ителгән дип санала.

Коллегиянең яңа әгъза кабул итү турындагы карары Язучылар берлеге идарәсе утырышында раслана.

Беренче тикшерүдә тавышны кимрәк алган әдәбиятчының эше, игътибарга лаек яңа әсәрләре матбугатта басылып чыкканнан соң, Коллегиядә кабат каралырга мөмкин.

Аппелляция кабул ителгән очракта, Идарә Кабул итү коллегиясенең бу әдәбиятчының иҗатын шикаять (гариза) кергән көннән башлап өч ай эчендә кабат тикшерергә мәҗбүр итә.

Коллегия утырышлары гаризалар керүгә бәйле рәвештә үткәрелә. Бер утырышта биштән артык гариза карапмаска тиеш.





## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ — МӨСТӘКЫЙЛЬ ТАТАРСТАННЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ

Инде матбугатта хәбәр ителгәнчә, 12 июнь көнне Татарстанда ТССР президентын сайлаулар үткәрелде. Ул тыныч шартларда узды. Сайлаучыларның 60 процентган артыграгы тавыш бирүдә катнашты. Бюллетеньгә бер кандидат — ТССР Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев кертелгән иде. Аның кандидатурасын яклап, барлыгы 1 миллион 131 мең 91 сайлаучы тавыш бирде. Бу — сайлауларда катнашучыларның 70,6 проценты дигән сүз.

Сайлау нәтиҗәләре Татарстандагы сәяси хәлнең асылын тамырдан үзгәртте. Татарстан моңа кадәр автономия кысасында — «икенче сортлы» республикалар рәтендә йөргән булса, мөстәкыйль ТССРның үз Президенты булу узган елның 30 августында кабул ителгән Татарстан җөмһүриятенең суверенлыгы турындагы Декларацияне тормышка ашыруда хәлиткеч роль уйнаячак. Беренче Президентны халык үзе сайлады. Россия һәм башка союздаш республикаларга алга таба Татарстанның хокуклары белән исәпләшми мөмкин түгел.

Төкле аягың белән, беренче Президентыбыз!

* * *

Шул ук 12 июнь көнне Россиядә президент сайлау да үткәрелгән иде. Татарстан, мөстәкыйль җөмһүрият буларак, әлеге сайлауларда рәсми төстә катнашмады. Шулай да Татарстан Югары Советы карары белән, кеше хокукларын ихтирам итү йөзеннән, республикадагы теләгән сайлаучыларга сайлау хокукы ирекле куелды. Әйтергә кирәк, Казан шәһәренең кайбер участокларында сайлаучыларга РСФСР президентлыгына кандидатлар язылган бюллетень кәгазен көчләп бирергә маташулар да күп булды. Шуның ише закон бозулар күзәтелүгә карамастан, республикабызда Россия Президентын сайлауларда азчылык катнашты: бу сан нибары 35,5 процентны тәшкил итә.

Шулай итеп, җөмһүриятебез сайлаучылары Татарстанга РСФСР Президенты кирәк түгеллеген бик ачык раслады.

## ЮГАРЫ СОВЕТ ҮЗ СҮЗЕН ӘЙТӘ

4—6 июль көннәрендә Татарстан ССР Югары Советының чираттан тыш бишенче сессиясе эшләде. Көн тәртибенә унбишләп мәсьәлә куелган иде. Анда Татарстан Республикасының Президенты итеп М. Ш. Шәймиевне сайлау нәтиҗәләре расланды. Аннары Татарстан ССР Президенты тантаналы төстә ант бирде.

Әлеге сессия барышында Татарстанның вице-президенты итеп В. Н. Лихачев, республикабыз Югары Советы Рәисе итеп Ф. Х. Мөхәммәтшин, Татарстан ССР Премьер-министры итеп М. Г. Сабиров иптәшләр сайланды.

Союз договорын әзерләү комитеты әгъзасы, Татарстан ССР Президенты Шәймиевнең «Суверен дәүләтләр Союзы договоры проекты турында» доклады депутатларда һәм киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды. Фикер алышуда катнашучы депутатлар, Татарстан бу договорга СССР субъекты буларак мөстәкыйль кул куярга тиеш, дигән фикерне катгый яклап чыктылар.

Сессиядә, Татарстан Министрлар кабинеты составын раслау белән бергә, тагын күп кенә мәсьәләләр каралды һәм карарлар кабул ителде.

## ҺӘРКЕМГӘ БАРЫП ҖИТСЕН

Безнең милли матбугат, дөресрәге, аңардагы уй-фикерләр һәм яңалык сөземтәсе рус телендә укучыларга барып ирешми диярлек. Шушы бушлыкны тутыру өчен Татарстанда рус телендә «Суверенитет» газетасы чыга башлады. Аның девизы: «Татарстан — суверен демократик дәүләт».

Яңа газетаның беренче саны республикабызның беренче Президентын сайлауга кагылышлы материаллар белән ачылып китә.

«Бүленмәс һәм таркалмас Россия» дигән империячел принципка ябышып ятып, бездә чыга торган русча матбугат Татарстанның суверенлыгын күпвакыт берьяклы һәм бозып күрсәтә. «Суверенитет» комитеты тырышлыгы белән чыга торган бу газетаның исә бер мөһим ягы шунда: ул русча укучыларга дөрес һәм тулы информация бирәчәк, мөстәкыйльлек идеясен алга сөрәчәк.

## САБАН ТУЕ — ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

Республикабызның авыл, район һәм шәһәрләрендә сабан туйлары гөрләп узды. 1991 елны чын мәгънәсендә сабантуйлар елы дип әйтергә мөмкин һәм ул Татарстанның суверенитетын якыннан тою, аңлау, яклау рухында барды.

Казанның үзендә генә дә 21 һәм 28 июнь көннәрендә ике зур сабан туе узды. Аларның берсен — халык депутатларының Казан шәһәр Советы һәм аның башкарма комитеты, «Сәфәр» иҗат үзәге, «Шәһри Казан» газетасы, республика һәм Казан каласының та-

тарча көрәш федерацияләре; икенчесен — ТССР физкультура һәм спорт комитеты, ТССР Мәдәният министрлыгы, «Социалистик Татарстан» газетасы оештырды. Соңгысында, ягъни спортның милли һәм халык төрләре буенча II Бөтенсоюз фестивалендә — республиканың иң олы сабан туенда ТССР Президенты М. Ш. Шәймиев тәбрикләү сүзе белән чыкты.

Кичке Сабантуй — Бөтенсоюз фестивале киләчәктә һәр елны июнь аеның соңгы көнендә үткәреләчәк.

## ЫК ЕЛГАСЫ — ДУСЛЫК ЕЛГАСЫ

Татар иҗтимагый үзәгенең икенче корылтаенда ук инде Башкортстан егетләре дусларын һәм туганнарын үзләренә Сабан туена кунакка чакырган иде.

Ул көн килде. 9 июньдә — бәйрәмчә киенеп, җыр һәм гармуннар белән — Татарстанның Казан, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Лениногорск, Азнакай шәһәрләреннән, Актаныш һәм Баулы районнарыннан күп кенә вәкилләр автобусларда Ык буена килеп туктадылар. Елганың теге ягында — күрше Башкортстан, Октябрьск шәһәре. Анда инде кунакларны Башкортстанның төрле районнарыннан килгән хезмәт ияләре көтеп тора.

Бәйрәмдә катнашучыларны Октябрьск шәһәр Советы рәисе урынбасары Риф Зиннәтуллин тәбрикләде. Бөтенсоюз татар иҗтимагый үзәгенең Башкортстандагы бүлек рәисе Кәрим Яушев һәм Үзәк президиумы әгъзасы Хәләф Гарданов котлау сүзе сөйләделәр. Җыр-бию, спорт ярышлары һәм татарча көрәш бәйрәмгә тагын да ямь өстәде.

Телләре, җырлары, гореф-гадәтләре бер булган халыкны икегә бүлеп кую — гаделсез эш. «Ык елгасы «Берлин стенасы» булмаска тиеш!» — диделәр дуслык-бердәмлек җыенында катнашучылар.

## ХӘЕРЛЕ ЮЛ, «АРГАМАК»!

Каләм ияләренә үсү һәм иҗади күтәрелеп китү өчен мәйдан кирәк. Кама буе төбәгендә яшәүче язучыларның үз әдәби журналы юк иде. Мондый ихтыяҗ үзен гел сиздереп килде. Шуны истә тотып, быел Чаллы шәһәр Советы башкарма комитеты татар һәм рус (тәрҗемә) телләрендә «Аргамак» исемле әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал чыгару турында карар кабул иткән иде.

Мәгълүм булганча, «Аргамак» — «КамАЗ» акционерлык җәмгыятенең фирма билгесе. Журналны гамәли оештыручылар булып Чаллы шәһәр Союзы башкарма комитеты, «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте һәм Чаллы язучылар оешмасы тора. Яңа журнал өчен бина, зур күләмдә акча, берничә торак фатир, алмашка кәгазь алып кайту өчен ике автомашина бирелде. «Аргамак»ны «КамАЗ» акционерлык җәмгыятенең газета-китап нәшрияты типографиясендә быел ук 30 мең данә бастырып чыгару күздә тотыла.

«Аргамак» журналының баш мөхәррире итеп язучы Айдар Хәлим сайланды.

## ЯҢА КИТАП ЮЛГА ЧЫКТЫ

11 июльдә Татарстан газета-журналлар нәшриятының конференц-залында публицист язучы Айдар Хәлимнең быел Вильнюста русча чыккан «Книга печали или Записки аборигена» дигән китабын укучыга тәкъдим итү булды. Презентациядә журналистлар, язучылар, галимнәр һәм автор үзе катнашты.

Чыгыш ясаучылар Башкортстан җирендә яшәүче татарларның рухи, мәдәни хәле турында борчылып сөйләделәр, беренчеләрдән булып чаң кагучы Айдар Хәлимнең хакыйкатькә тугрылыгын, зур хезмәт башкаруын билгеләп уздылар.

Презентациядә катнашучылар исеменнән Литваның «Мокслас» нәшрияты коллективына рәхмәт телеграммасы җибәрелде.

## ХАЛЫКАРА ЯҢА ОЕШМА

Яңа заман җилләре дөнья буйлап сибелгән татар өчен күп якты әләмтәләрне ныгыту һәм үстерүдә зур мөмкинлекләр ачты. Июль аенда АКШ, Австралия, Германия, Төркия һәм Финляндия татар җәмгыятьләре вәкилләре Бөтендөнья татар лигасының оештыру корылтаен үткәрү өчен Казанга җыйналдылар. Халыкара яңа оешманың Президенты итеп Европа татар-башкорт милли хәрәкәте башлыгы, 74 яшьлек Али Акыш әфәнде сайланды.

## ТАТАР ГАЛИМЕ СОГУД ГАРӘБСТАНЫНДА

Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, философия фәннәре докторы, профессор Яхъя Абдуллин Бөтендөнья мөселманнар лигасының чакыруы буенча күптән түгел Согуд Гарәбстанында булып кайтты. Ул Мәккә, Мәдинә, Таиф һәм Җиддә шәһәрләрендә булды, андагы мәдәният эшлеклеләре, социаль һәм икътисади үсеш баскычлары белән танышты. Бөтендөнья мөселманнар лигасында, язучыларның Мәккә клубында, Мәккә һәм Мәдинә университетларында очрашулар вакытында ул әңгәмәдәшләрен татар халкының үткәне, мәдәнияте, аның этник чыгышы, Татарстанда хәзер бара торган хәлләр белән таныштырды.

*Журналыбызның бу саны тәҗрибә рәвешендә компьютерда җыелды.*

# КОРЪӘН САВЫТЫ

Тышлыкның беренче битендә сез, хөрмәтле укучылар, югары зәвык белән эшләнгән, сәнгатьчә үтә камил Коръән савыты белән таныша аласыз. Аны кайбер якларда «бөти» дип тә йөриләр һәм ул, гадәттә, күз тиюдән, явыз рухлар касәфәтеннән, чир-сырхаудан саклый дип исәпләнелә. Мондый савытларда нәни Коръән яисә аның аерым сүрәләре, аятьләре, догалар саклапган.

Коръән савытлары нәфис чылбыр белән муенга асыла, кайбер очракларда култык астында йөртелүе дә мәгълүм. Алар борынгы Болгар чорыннан ук билгеле. Күрәсең, бу йоланың нигезендә бик борыннан килүче аерым ышанулар ята.

Татарстан дәүләт музеенда саклапучы әлеге Коръән савытының бай шәһәр хатынынықы булуы бәхәс тудырмый. Шулай ук, билгесез татар остасының иҗат җимеше икәнлеге дә шиксез. Алтын һәм көмешне бөрчекләү һәм пәрәвезләү дип аталган ысул бары тик Казан татарлары һәм Болгар зәргәрләренә генә хас. Ләкин аның кайчан ясалганлыгын билгеләү кыенрак. Эш шунда, татар алтынчылары үз әйберләренә металлның кайсы тордән икәнлегенә тамга суктырмаганнар. Шунлыктан, татар алтынчыларының сакланып калган кләймә-тамгалары безгә мәгълүм түгел.

Зәркән сәнгатенең иң нәфис үрнәге саналырга хаклы бу Коръән савытын XVII гасыр урталарында яисә XIX гасыр башларында ясалган дип фарыз итәргә тулы нигез бар. Хәлбуки, аның тагын да ераграк чорга каравы да ихтимал. Ясалу ысулындагы үзенчәлекләр — күп санлы бөрчекләр, эре борылмалы пәрәвездәй бизәкләр — нәкъ менә татар зәркән сәнгатенең әүвәлге чорына хас.

Иң затлы көмештән һәм алтыннан эшләнгән бу зиннәт таж эчендәге сыек зәңгәр фирәзә белән дә игътибарны җәлеп итә. Күпчелек шәрыкъ халыклары, шул исәптән, татарлар, бу асыл ташны «бәхет ташы» дип саный. Шуның өстенә, безнең халыкта тагын «фирәзә көч бирә, бәла-казадан саклый, йөрәкне ныгыта, куркуны ала, дошманнар өстеннән җиңү китерә» дигән ышану да яши. Фирәзә ташлы бу зиннәт саклагыч бөти ролен үтәгән дип әйтергә дә тулы нигез бар. Асу җайланмаларының урнашуыннан аның уң якта, култык астында йөртелүен чамаларга була. Ә борынгы ипанулар кешенең җаны уң култык астыннан чыга дип исәпли. Саклагыч бөти, шулай итеп, кешенең җанын, тынычлыгын саклаган да инде.

Ничек кенә булмасын, алдыбызда татар алтынчыларының мөкәммәл әсәрләреннән берсе.

Гүзәл **ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА**,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** һ. Х. Андерсен исемендәге халыкара диплом лауреаты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, күренекле шагыйрь Шәүкәт Галиев.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# Хөрмәтле дуслар!

«Казан утлары» — татар телендә чыга торган бердәнбер калын күләмле әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал. Ул хаклы рәвештә халкыбызның яраткан, көтеп алынган журналына әверелде. Тарих тегермәннәрендә уалып та исән калган, илебезнең төрле төбәкләренә сибелгән эшчән татар халкы өчен ул бүген дә туганлык, тупланганлык, аралашу һәм үзара аңлашу мәйданы булып хезмәт итә. Нурларын еракка сибеп, халкыбызның милли үзаңын, әдәби һәм эстетик зәвыгын үстерүгә зур өлеш кертә, үз укучыларын татар әдипләренең «табадан гына төшкән» өр-яңа әсәрләре белән даими таныштырып бара.

Кеше күңеленә тәрбияви яктан йогынты ясауда зур көч буларак, әдәбиятның рухи тормышыбыздагы роле беркайчан да кимемәячәк — журнал шушы хакыйкать сулышы белән яши, уй-фикер һәм әхлак нурлары чәчә.

Илебездәге үзгәртеп корулар, ачыктан-ачык сөйләшү заманы журналның эчтәлегенә һәм эшчәнлегенә шифалы йогынты ясады. Без халкыбыздан тимер сейфларга «яшерелгән» «Идегәй» дастанын, кайчандыр исемен телгә алырга да ярамаган әдип һәм көрәшче Гаяз Исхакый әсәрләрен, аның тормыш һәм иҗат юлыннан яңа мәгълүматларны, Коръәннән сүрәләр, гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләрен киң катлам укучыларга җиткерә алдык. «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә» дигән яңа рубрика да һәркемнең игътибарын җәлеп итте. Тыелган темаларның бетерелүе халкыбыз тарихын тулырак һәм хакыйкатьне «бозмыйча» язарга мөмкинлек ачты. Бу юнәлештәге эзләнүләр алга таба да дәвам итәчәк, билгеле.

Татарстанның дәүләт суверенитетын яклау, ныгыту һәм аны тормышка ашыруга үзеннән өлеш кертүне журнал иң җаваплы бурычларының берсе дип саный.

Редакция коллективының төп максаты — укучы өчен кызыклы, тирән эчтәлекле журнал чыгару, әдипләр сүзен үз вакытында халык күңеленә җиткерү, милләттәшләребезне рухи яктан бергә туплау. Ләкин соңгы вакытларда матбугат өчен килеп туган матди кыенлыклар «Казан утлары»н да читләп узмады. Илдәге кәгазь кытлыгы, почта һәм полиграфия чыгымнарының чиктән тыш күтәрелүе, тормыш кыйммәтчелеге үз чиратында журналыбыз тиражы кимү — ягъни байтак кына укучыларыбызның бүгенге әдәби хәзинәдән мәхрүм калу куркынычын китереп чыгарды. Моны ачыктан-ачык әйтергә кирәк.

Тирәннән уйлап карасак, журнал язмышы — әдәбият һәм халык язмышы ул. «Казан утлары» белән дус булу һәм аны алдыру — милләтен яраткан, аның язмышын үз иткән ватандар рухлы һәркемнең намус эше, зур максатларга теләктәшлек билгесе.

«Казан утлары» — сезнең журнал. Ул үз укучыларына игелек һәм яктылык нурларын алдагы елда да мул сибәчәк.

Бәясе 1 сум 50 тиен. Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог